ISSN 0206—4189



# Казан утлары

1. 1986





*Фатих Әмирхан*

1886—1926

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**1**

**1986**

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


1986 ЕЛ — ТЫНЫЧЛЫК ЕЛЫ

М. ШАБАЕВ. **Дөнья тыныч.** *Шигырь* . . . . . 4

КПССның XXVII СЪЕЗДЫН КАРШЫЛАП

В. ЕРМАКОВ, М. ЗАРИПОВ. **Үрдән-үргә** . . . 5

Ф. ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

И. НУРУЛЛИН. **Фатих Әмирхан.** *Документаль повесть* . . . . . . . . . . . . . 14

М. МӘҺДИЕВ. **Яңа Бистә Прометее** . . . . . 59

З. ӘМИРХАНОВА. **Абыем турында** . . . . . 69

Х. ГОМӘРЕВ. **Фатих Әмирхан — Әстерханда** . . 73

М. ӘХМӘТҖАНОВ. **Ф. Әмирхан архивыннан** . 76

Г. ДӘҮЛӘТШИН. **Ф. Әмирханның кульязма мирасы** 80

Н. ВӘЛИЕВ. **Әдип көлә** 84

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. **«Әльислах»чы Гарифҗан Мостафин** . . . . . . . . . . . . . . . 85

Н. АРСЛАНОВ. **Уйланулар.** *Шигырьләр* . . . 87

Э. КАСЫЙМОВ. **Җир балкышы.** *Роман* . . . . 94

К. СИБГАТУЛЛИН. **Җырлый-җырлый...** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 144

Н. ИЗМАЙЛОВА. **Бер диңгез мәхәббәт.** *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 147

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Р. КОРБАНОВ. **Сандугачлы таллар.** *Шигырьләр* . 151

Д. ХӘЙРУЛЛИН. **Сорау...** *Шигырьләр* . . . . 154

Г. ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

**Кушлавыч.** *Т. Хаҗиәхмәтов рәсеме* . . . . . 156

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

Р. ЗАРИПОВ. **Нурминкәнең көмеш суы.** (Кукмара районы) . . . . . . . . . . . . . 158

ӘДӘБИ ПОСТ — АЭС

М. ӘМИРХАНОВ. **Низаг.** *Төзелеш көндәлегеннән* 163

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИННУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
СИБГАТ ХӘКИМ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60,
баш редактор урынбасары — 53-07-09,
җаваплы секретарь —53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар —53-07-63.

ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Ф. МУСИН. Күркәм бәйрәмебез . . . . . . . . 168

БИБЛИОГРАФИЯ

Б. КАМАЛОВ. Биеклек . . . . . . . . . . . . 178

СӘНГАТЬ

Ч. БӘХТИЯРОВА. Музыка сарае . . . . . . . 181

АЕК БУЛ — ЗАМАНГА ЛАЕК БУЛ!

А. ХӘСӘНОВ. Кагылмый? *Хикәя* . . . . . . . 184

Культура тормышы көндәлеге . . . . . . . . 189

Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

1986 год — год Мира. Стихотворение М. ШАБАЕВА.
Навстречу XXVII съезду КПСС. Беседа писателя М. ЗАРИПОВА с председателем Госплана ТАССР, заместителем председателя Совета Министров ТАССР В. В. ЕРМАКОВЫМ.
К 100-летию Фатиха Амирхана: документальный роман И. НУРУЛЛИНА «Фатих Амирхан», статья М. МАГДЕЕВА «Прометей из Татарской Слободы», воспоминания З. АМИРХАНОВОЙ, Х. ГУМЕРОВА, статьи М. АХМЕТЗЯНОВА и Г. ДАВЛЕТШИНА об архиве Ф. Амирхана, а также материалы Н. ВАЛЕЕВА, Х. ГУБАЙДУЛЛИНА.
Роман Э. КАСЫМОВА «Сияние земли».
Стихи Н. АРСЛАНОВА, К. СИБГАТУЛЛИНА, Н. ИЗМАЙЛОВОЙ, молодых поэтов Р. КУРБАНОВА, Д. ХАЙРУЛЛИНА.
К 100-летию Г. Тукая: рисунок Т. ХАЗИАХМЕТОВА, зарисовка «Кушлауч».
В рубрике «Татарстан — родной мой край» статья первого секретаря Кукморского РК КПСС Р. ЗАРИПОВА.
Литературный пост — ТатАЭС: очерк М. АМИРХАНОВА.
Статья Ф. МУСИНА о становлении татарского романа.
В рубрике «Библиография» рецензируются повести Р. Карами.
Статья Ч. БАХТИЯРОВОЙ о деятельности Казанской госконсерватории.
В рубрике «За трезвый образ жизни» рассказ А. ХАСАНОВА.
На нашей обложке — творчество художника Н. Кузнецова.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Г. Салихҗанова, А. Садыйкова.*

Производствога бирелде 19.11. 1985 ел. Басарга кул куелды 17.01. 1986 ел. ПФ 05011. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 62549. Заказ Ф-497. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1986 ел.

*1986 ел — Тынычлык елы*

✦

**Милитаризм һәм сугыш көчләрен авызлыклау, ныклы тынычлык һәм ышанычлы иминлек тәэмин итү — хәзерге заманның төп проблемасы.**

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре М. С. Горбачевның Октябрь (1985) Пленумында ясаган докладыннан.

✦

**Советлар Союзы киләчәктә Европаның һәм барлык башка континентларның тынычлыгын, азатлыгын, чәчәк атуын тәэмин итүгә үз өлешен кертергә әзер тора. Без моның өчен бернәрсәне дә кызганмыйбыз.**

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре М. С. Горбачевның Франция парламентарийлары белән очрашуындагы (3 октябрь, 1985) чыгышыннан.

✦

**Барлык илләр халыклары! Атом-төш сугышы куркынычын бетерү өчен, космоста ашкынып кораллануны булдырмау һәм җирдә аны туктату өчен көрәшне көчәйтегез!**

**Атом-төш коралын тулысынча бетерү өчен көрәшегез!**

КПСС Үзәк Комитеты Өндәмәләреннән.

## Марс Шабаев

### Дөнья тыныч...

Кичке тынлык, кичке эңгер,
Әкрен генә җырлый кемдер:
Булмас җырны ишетмәгән,
Ачык калган ишекләрдән
Йорттан-йортка моңы йөрер,
Күңелләргә шатлык керер —
Дөнья тыныч, иминлек.

Шомландырмый алсу офык,
Таңнар атса — шом, курку юк,
Кичләр җитсә — яңа шәфәкъ,
Алсу кояш байый фәкать.
Җилләр йоклый тирәкләрдә,
Гамь-хәсрәт юк йөрәкләрдә —
Дөнья тыныч, иминлек.

Әмма дөнья кыл тартылган,
Көн үтсә дә көн артыннан,
Бәллүрдән дә бәллүр дөнья —
Әй кешелек, бул син уяу!
Юкса кемдер сиздерми дә
Бер орынган бер мизгелдә
Коелып төшәр дөнья-бәллүр...
Кешелек, син сак була күр!
Шул куркыныч...

Ә бүгенгә дөнья тыныч...

# ҮРДӘН — ҮРГӘ

Республикабыз Госпланы председателе, ТАССР Министрлар Советы председателенең урынбасары ВЛАДИМИР ВАСИЛЬЕВИЧ ЕРМАКОВ белән язучы МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ әңгәмәсе.

М. ЗАРИПОВ. Статистика барын да белә, дигән сүз, мөгаен, дөрестер. Үткәндәниләр булган, хәзер нәрсәләр эшләнә — санап баручыларга бу турыда һәр яктан әллә никадәр мәгълүмат җыйнала. План төзүчеләрнең тагын бер өстенлеге бар: алар киләчәкне дә белеп торалар. Бу бит — фараз кылу, юрау белән мавыгу гына түгел, төгәл һәм ныклы исәп-хисап ясап, тормышка ашырылачак эшләрне билгеләү.

В. ЕРМАКОВ. Киләчәк үткәнсез булмый. Алдагы көнгә план төзү дә моңа кадәр эшләнгәннәрне анализлаудан, тикшерүдән, нинди шартлар барлыкка китерелүен, якындагы ай, квартал, ел, биш елда һәм тагын да ераграк киләчәктә нинди казанышларга ирешү мөмкинлеген ачыклаудан башлана. План объектив, реаль мөмкинлекләрне яхшы белеп, үсеш юнәлешләрен алдан чамалап, кыю фикерләргә таянып төзелергә тиеш.

М. ЗАРИПОВ. Мондый таләп киләчәк тормышны күзаллауга бәйләнгән теләсә кайсы программага кагыла. Республикабызның төп планлаштыру үзәге — Госплан хезмәткәрләре даими кайгырта торган экономик, иҗтимагый, техник, фәнни, экологик үзгәрешләрнең, социалистик хуҗалык үсешенең үзенчәлекләре, аларны планлаштыру хасиятләре нindirәк?

В. ЕРМАКОВ. План гади бер документ кына түгел, ул — камил идарә итү коралы да. Төгәл һәм объектив план өчен ике нәрсә шарт: беренчедән, ул реаль, ягъни аның барлык өлешләре балансланган булсын; икенчедән, ул үтәүчеләрне яңа резервлар һәм мөмкинлекләр табарга, аларны иҗади, тырыш хезмәткә рухландырсын. План белән танышкач, аны башкаруда катнашучы һәр кеше үзенә ни бәйле икәнен белсен, кыю, оешкан рәвештә эшли һәм фикер йөртә алсын. Идарә итүнең төп буыны булган Госплан исәп-хисап ясалган вакыттагы һәм киләчәктәге мөмкинлекләрне бик төгәл билгеләргә тиеш. Менә шунлыктан уникенче бишьеллыкның программасын төзү XXVI съездан соң узган киеренке хезмәт казанышларын, совет халкы, республикабыз эшчәннәре алдында торган бурычларны анализлаудан башланды.

Күрсәткечләр, мисаллар, саннар күп. Аларның барысы да хәлиткеч роль уйнамый, әлбәттә. Ләкин план коручыларга һәммәсен — экономикабызның нигезе булган төп җитештерү фондларын да, хезмәт хакы белән хезмәт җитештерүчәнлеге үсеше нисбәтен дә, пенсияләр, киносеанслар санын да, шырпы, тоз, сабын кебек вак-төяк әйберләр сату күләмен дә исәпкә алырга туры килә. Калын бер том тәшкил итә торган мәгълүматларның барысын да санап бирү озынга сузылыр. Шуңа күрә Татарстанда унберенче бишьеллыкта эшләнгәннәрнең иң кирәклеләренә һәм егерме беренче гасырга кадәр дәвердә ачылачак төп перспективаларга кагылу да җитеп торыр.

М. ЗАРИПОВ. Вакыйгалар агышы бик кызу бара. Инде XXI гасыр көнкүрешебезгә кереп бара, димәк? Ике меңенче елның практик исәп-хисаплары тормышыбыз чынбарлыгына әйләнә?

В. ЕРМАКОВ. Кыска вакытлы планнар белән бергә озаграк дәвергә исәпләнгән гомум дәүләт программасын төзү — совет экономика фәненең һәм

социалистик хуҗалык практикасының казанышы ул. Республикабызда экономик һәм иҗтимагый үсешнең перспектив планнарын әзерләр өчен махсус комиссия төзелде. Аңа план коручылар, галимнәр, хуҗалык белгечләре, партия, совет, профсоюз җитәкчеләре керә, тулаем эшкә партия өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Исмәгыйлевич Усманов юнәлеш бирә. Бу рычларны дөрес билгеләү — эшне яртылаш үтәү дигән сүз.

М. ЗАРИПОВ. Алайса эшкә якынрак килик — республикабыз Госпланы уникенче бишьеллык планны төзегәндә нинди күрсәткечләргә таяна?

В. ЕРМАКОВ. Төп нигезебез — КПССның XXVI съезды карарларын, унберенче бишьеллык планнарын үтәү өчен җәелдерелгән ярышта ирешкән казанышларыбыз, билгеле. Узган ел бәрәкәтле хезмәт, фән-техника прогрессын тизләтүдә яңа юллар эзләү, иҗтимагый җитештерүне тагын да көчәйтү еллары булды. Беренче исәпләр буенча, республикабыз халык хуҗалыгына унөч миллиард сумлык капитал салынды. Бу дәвердә промышленность товарлары җитештерү — унтугыз, хезмәт җитештерүчәнлеге унбиш процентка үсте, әйбер ясауны арттыруның өч чиреге эш урыннарын үрчетмичә генә барлыкка китерелде. Гомумән алганда, республикабыз экономикасы тотрыклы рәвештә алга барды, һәр ел планы арттырып үтәлде, планнан тыш та ярты миллиард сумлык әйбер чыгарылды. Машина төзү, металл эшкәртү, энергетика, химия, нефть химиясе кебек, хуҗалыкның бүтән тармаклары үсешен хәл итә торган төп өлкәләрдә казанышларыбыз аеруча зур. Дүрт ел эчендә үсеш: машина төзелешендә — 39; прибор ясауда — 43; электротехника әйберләре җитештерүдә — 59 процент булды. Авыл хуҗалыгында эшләр катлаулырак. Унынчы бишьеллык белән чагыштырганда җәмәгать секторында уртача еллык җитештерү: сөт — җиде, ит — биш, йомырка — утыз дүрт, яшелчә илле биш процентка артса да, корылыклы 1981 ел бәласеннән тәмам арынып бетмәдек әле. Барлык тырышуларыбызга карамастан, дәүләткә бөртекле ашлыкны, шикәр чөгендерен, бәрәңгене пландагыдан кимрәк саттык. Әмма терлекчелекне тотрыклы үстереп, халыкны азык-төлек белән яхшырак тәэмин итүгә ирештек. Шәһәрләрдә һәм эшчеләр поселокларында ит ризыклары сатуны — сигез, сөтне унсигез процентка арттырдык.

Узган бишьеллыкта промышленность, авыл хуҗалыгы, фән тармаклары төп җитештерү фондлары кыйммәте 25 миллиард сумнан ашты. XXVI съезд алдыннан сафка баскан Кама автомобиль берләшмәсе генә дә республикабыз эш җегәрлеген ике тапкыр диярлек үстерде.

Социаль үзгәрешләребез дә игътибарга лаек. 1984 елда бер миллион 800 мең квадрат метр торак мәйданы, шуның ярты миллион чамасы — авыл җирендә төзелде. Соңгы күрсәткеч бигрәк тә әһәмиятле. Чөнки авыл җирендә яңа йорт-җир кору борын-борыннан бик күп көч түгүне таләп итә, яхшы торак җитмәү байтак халыкның шәһәрләргә күчеп китүенә сәбәп була иде.

Саннар озын нотыкларга караганда тәэсирлерәк, әмма шулай да җитештерелгән байлыкларны үз күзең белән күрү әйбәт. Соңгы биш елда республикабыз халык хуҗалыгын үстерүгә тотылган унөч миллиард сум акча миллионнарча тонна нефтькә, авыр йөк ташучы автомобильләргә, җегәре һаман арта баручы уникаль Түбән Кама нефть химиясе комплексына, ит, сөт, май, йомырка фабрикаларына, Түбән Кама электр станциясе агрегатларына әверелде. Татарстан атом станциясе, Менделеевскидагы минераль ашламалар заводы, Алабугадагы трактор заводы да күтәрелеп килә. Мехлар, кинотасма, приборлар, авиалайнерлар, шәһәрләребездәге яңа кварталлар, мәктәпләр, балалар бакчалары, шифаханәләр — уңганнар хезмәте ниләр генә булдырмый?! Әгәр хәзерге үсешебезне элекке заман, легендар беренче бишьеллыклар казанышы белән тиңләсәк, аерма искиткеч зур. Хәзер республикабызда бер эш көнендә генә дә элекке Казан губернасында ел дәвамында эшләнгән кадәр мал җитештерелә. Гыйбрәт өчен Татарстанның көндәлек хезмәт күрсәткечләренең кайберләрен санап китик: 98,4 миллион киловатт сәгать электр энергиясе, 152 мең тонна нефть һәм 5,6 миллион куб. метр газ, 6,6 мең данә сәгать, 28,1 мең пар күн аяк киеме, ике миллион кирпеч, 6,1 мең куб. метр җыелма тимер-бетон, 1,4 мең тонна икмәк! Тимер юл буенча 60, автомобильләрдә 700 мең тонна йөк кабул итә һәм тәяп җибәрә, 5,1 мең квадрат метр торак кора. Республикабыз халкы көн саен 10,2 миллион сумлык төрле әйбер сатып ала, 315 мең сумлык көнкүреш хезмәтеннән файдалана. Тәүлекләр бик киеренке хәзер, һәр сәгать, һәр минут, һәр секунд кадерле.

Бер генә мисал: әгәр республикабыз нефтьчеләре бер сәгать вакытны бушка уздырса, илөбез биш мең тоннадан артык кара алтыннан коры калачак.

М. ЗАРИПОВ. Бу бишьеллыкта ирешкәннәребез алдагы көннәр өчен план төзегәндә төп таянычтыр инде?

В. ЕРМАКОВ. План төзегәндә «ирешелгәннәргә таяну» идарә итүнең иң аклана торган ысулы түгел. Кагыйдә буларак, нигез итеп соңгы елларның уртача нәтиҗәләре алынса да, объектив мөмкинлекләр һәм шартлар истә тотыла.

Мәгълүм булганча, халык хуҗалыгын планлаштыру, ил күләмендәге азык-төлек, энергетика, «Себер» кебек озак вакытка исәпләнгән аерым программаларны искә алмаганда, биш еллы цикллар рәвешендә партия съездларында кумәкләп кабул ителә. Андый план закон кебек һичшиксез үтәлергә тиеш. Уникенче бишьеллыкта республикабызның экономик һәм иҗтимагый үсеше өчен барысы унөч миллиард күләмендә капитал салыначак. Бу — сугыштан соңгы өч бишьеллык дәвамында үзләштерелгән суммага тигез.

Татарстан үзенә тәгаенләнгән сумманы халык хуҗалыгының йөз тармагына сарыф итәчәк. Аларның байтагы гомум Союз экономикасында да күренекле роль уйный. Нефть, кино материаллары, полиэтилен, синтетик каучук, фототелеграф тасмасы, компрессорлар һәм приборлар, электр-хисаплау һәм суыту машиналары, вертолетлар, самолетлар... Гомумән алганда, чыгымнарның ике юнәлештә — экономикага; культура-көнкүреш хезмәте күрсәтүгә тотылуын, һәр ике тармакның да әһәмияте булуын, һәр ике юнәлештә бурычларны үтәргә кирәклеген онытмаска кирәк.

Барысын да кешеләр хәл итә. Әмма гел план, план дип кабатлаучы һәм шуннан башканы күрмәүче, белмәүче, план һәм йөкләмәләрне үтәүнең, җитештерү нәтиҗәлелеген күтәрүнең кеше хезмәтенә, ул кешеләрнең әйбәт яшәве һәм ял итүе өчен яхшы шартларның булу-булмавына бәйле икәнлеген танымаучы чамасыз берьяклы эшкуарлар да очрый әле. Табигый ки, мондый мөнәсәбәт аларны бик еш ярык тагарак алдында калдыра. Мәсәлән, авылда елына ярты миллион квадрат метр торак төзү уен эш түгел, моңа бөтен республика белән — колхозлар һәм совхозлар көчен, төзүчеләр тырышлыгын, шәһәрләрдәге шефлар ярдәмен бергә берләштерү генә мөмкинлек бирде — зур социаль программа бары шулай гына уңышлы үтәлде.

Үткән бишьеллыкта матди кыйммәтләр җитештерми торган тармакларга барлык капитал салуларның чиреге туры килде. Бу әйбәт адымнарны уникенче бишьеллыкта тагын да ныгытырга, мәктәпләргә, җәмәгать туклануына, сәламәтлек саклауга, спорт корылмалары төзүгә әүвәлгедән зуррак игътибар бирергә кирәк. Әйтик, колхоз һәм совхозларның, зур-зур авылларның берсендә дә әлегә кадәр йөзү бассейны булмау, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүдә аксау һич тә нормаль күренеш түгел. Ике генә сан атыйм: 1984 елда, җәмәгать туклануын да кертсәк, дәүләт һәм кооператив ваклап сатуындагы товар әйләнеше өч миллиард җиде йөз егерме сигез миллион сум, ягъни җан башына 1068 сум тәшкил итте. Ә көнкүреш хезмәте җәмгысе 115 миллион сумлык — һәр кешегә утыз өч сумлык кына күрсәтелде.

М. ЗАРИПОВ. Матди кыйммәтләр җитештерүгә тоткан чыгымнарның болай әйләнеп кайтуы дәүләтне канәгатьләндермиме?

В. ЕРМАКОВ. Юк шул. Киресенчә, ягъни халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү күләмлерәк булса яхшы. Конвейер, модага, ихтыяҗга яраклашырга өлгерсә дә, аерым кешене түгел, массаларны күздә тотып хәрәкәт итә. Әшне болай оештыру исә ялгышуларга, аңлашмаучылыкка урын калдыра. Сатып алучы — кибеткә, кибетләр промышленностька дәгъва белдерә, үтмәс товарлары белән базарларны һәм кибет киштәләрен тутырган завод-фабрикалар исә сатып алучыларның «назлануын» гаепли. Ләкин барыбер сатып алучы хаклы. Узган бишьеллыкта Дәүләт стандарты инспекторлары республикабызда киң куллану товарлары җитештерә торган промышленность предприятиеләрендә меңнән артык тикшерү уздырды һәм һәр ике тикшерүнең берсендә җитди кимчелекләр ачылды. Инспекторлар 340 очракта конвейерны туктатты, 225 очракта бәясе ун миллион сумнан ашкан товарны сәүдә челтәренә тапшыруны тыйды. Җиңел промышленность предприятиеләре аеруча аксый.

М. ЗАРИПОВ. Ул ун миллион сумлык товар бөтенләй булмаса, байтак материал, байтак хезмәт әрәмгә китмәс иде.

В. ЕРМАКОВ. Әлбәттә. Минә шуңа күрә кулланучы белән тәэмин итүчеләр мөнәсәбәте заказ нигезендә үссә, түләүле хезмәт күрсәтү күбрәк тарала яхшырак. Ике меңенче елга халык заказы буенча торак төзетү — дүрт, йортлар салу — өч ярым, коммуналь уңайлыклар тудыру ике ярым тапкыр артырга тиеш.

Алдагы бишьеллык сыйфат бишьеллыгы булырга тиеш. Димәк, идарә итү осталыгын үстерү, һәркемнең җаваплылык тоюы — эшченең дә, игенченең дә, галимнең дә, төзүченең дә, министрның да үзен чын мәгънәсендә дәүләт кешесе дип хис итүе кирәк. Моның өчен һәркемне югары җитештерүчән хезмәткә этәрүчән, аларның инициативасын, сакчыллыгын, чималны бәрәкәтле тотып, кимрәк көч түгеп, кыска вакыт эчендә күбрәк товар булдыруга ирештерә торган экономик, иҗтимагый чаралар күрергә тиешбез.

М. ЗАРИПОВ. Максатлар кую җиңел. Аларга ирешү юлларын, мөмкинлекләрен табу кыенрак.

В. ЕРМАКОВ. Халык хуҗалыгын тизрәк үстерү бурычлары элек тә куелды. XXVI съездда, мәсәлән, иң мөһим стратегик максатларның берсе шул булды. XXVII съездга әзерләнү мәсьәләләрен тикшергән КПСС ҮКның апрель Пленумында (1985) Михаил Сергеевич Горбачев: «Әгәр экономиканы интенсивлаштыруны һәм фән-техника прогрессын тизләтүне бөтен эшебезнең үзәгенә куйсак, идарә итү һәм планлаштыруны... үзгәртеп корсак, һәркайда оешканлык һәм дисциплинаны күтәрсәк, эш стилен тамырдан яхшыртсак, үсеш темпын тизләтү, өстәвенә, бик нык тизләтү бурычы тулысынча үтәлерлек»,— диде. Нәтиҗәләрне күпме акча үзләштерү, дәүләттән күпме матди байлык, техника, механизмнар һәм аппаратлар алу, күпме хезмәт түгү буенча түгел, ә нинди табыш бирүгә карап бәяләргә кирәк.

М. ЗАРИПОВ. Әле менә мондый гадәт тә бар. Предприятиегә, колхоз һәм совхозга, бөтен бер тармакка акча бүлеп бирәләр, нәрсәгә тотылырга тиешлеген күрсәтәләр, бу суммалар планга керә, акчаны үзләштерәсе генә кала. Кайберәүләр төп фондларны — завод, фабрика, шахта һәм промыселларның яңа җегәрлекләрен сафка бастыру планы «койрыклы» итеп төзелсә, тагын да уңайлы дип фикер йөртәләр. Ул чакта гадәтнең холыкка әйләнүе дә ихтимал. Әле бүген дә кайберәүләр өстәмә капитал салу «могҗизасына», шәһәрдә икән — яңаны кору һәм эшли торган базаны киңәйтүгә, авылда икән — гигант комплекслар, кыйбатлы зур объектлар төзүгә өмет баглый. Әлбәттә, бу очракта идарә итүнең бүтән алымнары, төгәл һәм пөхтә эшләү, нәтиҗәле ярыш, хезмәтнең иң әйбәт ысулларын файдалану онытыла, монысы исә яңа куәтләрне тулы көчкә файдаланмауга китерә.

В. ЕРМАКОВ. Чыгымнарны яңа предприятиеләр, җегәрлекләр сафка бастыру белән генә планлаштыру — артык гадиләштерелгән, якынча гына ясалган сызым. Гадәттә, төзелеш мәйданыннан төзүчеләрнең эзе суынырга өлгерми, яңа предприятие, яңа цех инде җитештерү программасын үтәргә тиеш була. Төзелеш тәмамланганчы ук план бирелү очраклары да еш. Монысы да эш түгел. Бу фактларны белеп тору гына җитми, алардан дөрес нәтиҗә ясау кирәк. Идарә итү ысулларын камилләштерү — алга бару өчен беренче адым. Тормыш планлаштыруны гына түгел, бөтен хуҗалык механизмын үзгәртеп коруны, идарәнең сакчыл, югалтуларны булдырмый торган, кулланучылар белән җитештерүчеләр, югары белән түбән буын җитәкчеләре арасында мәгънәле, нәтиҗәле эш алымнары таләп итә. Социализмның, шәхси хуҗалыкка нигезләнгән капитализм белән чагыштырганда, зур өстенлекләре бар. Башкаручыларның эшлеклелеге, дәрте белән бергә үрелгән ачык планлы система иң югары нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Мәскәү киңәшмәсендәге докладта басым ясап әйтелгәнчә, беренче адымны иң югары эшелоннан башларга кирәк. Бернәчә санга игътибар итик. Республикабыз халык хуҗалыгына унынчы һәм унберенче бишьеллыкларда чама белән бердәй — унөчәр миллиард сумлык капитал салынды, ләкин промышленность продукциясе җитештерүнең уртача еллык үсеше беренчесендә — җиде ярым, икенчесендә дүрт процент булды. Уникенче бишьеллыкта чыгым артмаячак, әмма җитештерүне 19 процентка үстерү күздә тотыла. Җитмәсә, бу программаны бөтәйтү хезмәт күрсәтү өлкәсендә ашыгыч һәм ныклы үзгәрешләр ясау белән, экономиканың социаль резервын киң

файдалану белән бергә тормышка ашырыла. Торак төзү, мәсәлән, унынчы бишьеллыкта 8 миллион 672 мең квадрат метр, унберенчедә — 9 миллион тәшкил итте, уникенчедә исә 10 миллион квадрат метр торак кору күздә тотыла.

М. ЗАРИПОВ. План, башка төрле эш программалары кебек, уртадагы һәм азаккы максатларны билгеләүдән тыш, ниятләрне тормышка ашыру мөмкинлекләрен, чараларын һәм алымнарын да исәпкә алырга тиеш. Югыйсә, план реаль җирлектән аерылып буш хыялга әйләнүе ихтималдыр? Уникенче бишьеллыкны үтәүдә нинди резервлар күздә тотыла?

В. ЕРМАКОВ. Бурычларыбыз катлаулы, планлаштырылган тизлекне тәэмин итү җиңел булмас, ләкин алдынгы хезмәт коллективлары практикасы күрсәткәнчә, моңа ирешү бик мөмкин. Аның ышанычлы юлы — фән-техника прогрессын һәрьяклап тизләтү, фән белән практиканы бергә кушу, промышленность предприятиеләрен, колхозларны һәм совхозларны яңа техника белән коралландыру, яңа казанышларга таянган нәтиҗәле технология системаларын үзләштерү. Советлар Союзында миллион ярым фәнни хезмәткәр — теләсә кайсы илдәгедән күбрәк акыл иясе бар. Татарстандагы югары уку йорты, академик институт, төрле проектлау-конструкторлык, фәнни-тикшеренү оешмалары һәм башка гыйльми учреждениеләрнең саны йөзгә якын. Зур көч! Кызганыч, практика фәнни ачышларның бик нәни өлешеннән генә файдалана. Кагыйдә буларак, яңа заводларда бар нәрсә «соңгы сүз» буенча эшләнә, ә искеләрендә җитештерүне тизрәк яңартып корудан, фән белән бәйләнешләрне көчәйтүдән, яңа юллардан тәвәккәл атлап китүдән сакланалар.

М. ЗАРИПОВ. Әйтергә дә юк, үзгәртеп кору, төзәтү, кыю рәвештә техник яңалыклар кертү, авыр эшләрне автоматларга, роботларга йөкләү — мәшәкатьле, читен, нерв туздыра торган шөгыль, күнегелгәнчә яшәү рәхәтрәк.

В. ЕРМАКОВ. Фән-техника прогрессының артына гына тагылып бару бигрәк җиңел. Ләкин юлчылар перронда көтеп торганда поездның узып китүе мөмкин. Хәзерге яңа ачышлар дәверендә, иң алдынгы җитештерү формасы да үзе төзелгән вакытка, ягъни биш ел чамасы тормыштан артка кала. Ун ел элек ясалган станоклар, технологик аппаратлар, ун ел элек корылган заводлар инде ветеранга әйләнә, техник яктан картая, аларны кискен рәвештә үзгәртеп корырга, яңартырга, алмаштырып торырга кирәк. Юл уңаенда республикабыз станок хәзинәсенә кагылсак, җиңел промышленностьта аларның чиреге унбиш «яшен» тутырган, химия һәм нефть химиясе тармагында да шул ук хәл. Партия өлкә комитеты пленумнарының берсендә техниканы болай әкрен яңарту җитди тәнкыйтькә очрады. Хуҗалык эшендәге ваемсызлыкка, хезмәттәге сүлпәнлеккә, киләчәк турында борчылмастан, көндәлек мәшәкатьләргә күмелеп кенә яшәүгә мисал итеп Казанның данлы «Органик синтез» берләшмәсен мисалга китерделәр. «Оргсинтез» — яшь берләшмә, республикабызның сугыштан соңгы удар төзелеше җимеше, яшьлек шәһәре Түбән Каманың, легендар КамАЗның әлгәресе, монда барысы да — аппаратлары да, технологик системалар да өр-яңа иде. Үзебездә юклары чит илләрдән сатып алынды. Комплекс 1963 елда эшли башлады, әмма үсеш-үзгәрешләр бик кызу барган атом һәм космос гасырында ул бик тиз «аксакалга» әйләнде. Җиһазларының нибары бер ярым проценты гына алмаштырылган. Белгечләр исә агымдагы яңартуны биш-алты процентка җиткерүне тәкъдим итә. Байрак йөртүче берләшмәне бүтән предприятиеләрнең узып китүе менә ни өчен бер дә гаҗәп түгел. Күңелсез, әмма бик гыйбрәтле хәл бу!

Шунысы кызганыч, бу — гадәттән тыш мисал түгел, киң таралган күренеш. Шушы көнгә кадәр яңаны кору перспективалырак, файдалырак дип саналды һәм искене яңартуга чыгымнарның егерме проценты гына тотыла иде. Менә шуңа күрә, уникенче бишьеллыкка планлаштырылган капитал салуларның яртысыннан артыгын элек корылган предприятиеләрне яңартуга бирү хәерле. Моның сыйфатны яхшыртуы, саллы артым бирүе бик мөмкин.

М. ЗАРИПОВ. Гафу итегез, ә җитез нейтроннарны эшкә җигәчәк, җегәрлеге буенча республикабызның барлык электр станцияләренә тиң Татарстан

атом электр станциясе, Менделеевскидагы минераль ашламалар заводы, кырда берничә төрле эш эшли алачак универсаль тракторлар җитештерергә тиешле Алабуга авыл хуҗалыгы гиганты салыначакмы соң?

В. ЕРМАКОВ. Бу предприятиеләр халык хуҗалыгына чиктән тыш кирәк. Унөч миллиард — зур акча, акыл белән тотсак, яңа төзелешләргә дә җитәчәк.

Хәзер Казан мех берләшмәсе фабрикаларын тулысынча яңарту бара. Сугышка кадәр ук корылганлыктан, ул соңрак сафка баскан завод-фабрикалардан, хезмәт шартлары буенча, шактый калыша. Менә шул сәбәпле, хәзер аңа эш көче тарту кыенлашты, кешеләр машиналар хезмәтенә таянган, заманча җиһазландырылган предприятиеләргә урнашырга омтыла. Яңаны кору йөз миллионга төшәр иде, мех берләшмәсен үзгәртүгә исә шуның яртысы да җитәчәк. Көтелгән иң зур отыш — хезмәт шартларының яхшыруы. Илебездәге сарык тиресенең элеккечә үк яртысын эшкәртү, бүрекләр, туннар, бияләйләр тегү өчен киләчәктә көч азрак түгеләчәк. Үзгәртеп кору, промышленность һәм авыл хуҗалыгына, транспортка һәм төзелешкә яңа техника кертү — гөрләп үсә торган фән-техника революциясенең баганалы юлы.

М. ЗАРИПОВ. Хезмәт ресурслары мәсьәләсенә бик урынлы кагылдыгыз. Узган сугыш нәтиҗәләре, гаиләләрдә хәзер балаларның азлыгы киләчәктә бу мәсьәләне тагын да катлауландырачак. Шәһәрләрдә эш көче җитми, авылда да халык кимеде. Шәһәрләшү күзгә күренеп көчәя. Киләсе гасыр башында Казанда бер миллион ике йөз мең чамасы кеше булыр, Брежневтагы халык саны бер ярым тапкыр үсәр, Түбән Камада өч йөз меңгә җитәр, нефть якларында да артыр. Зур төзелешләр башлангач, борынгы Алабуга, Менделеевск яклары да җанланыр. Илебезнең трактор җитештерүче зур үзәгенә әвереләчәк Алабугада яшәүчеләр саны, мәсәлән, шулай ук өч йөз меңгә якынлашыр.

Аларны азык-төлек белән ничек тәэмин итәргә? Калачлар һәм кабартмалар, печенье һәм макаронга яраклы шәп бодайны көньякта үстерерләр. Ә итне? Сөт, эремчек, каймакны кайдан алырга? Яшелчә, җиләк-җимеш, бәрәңгене? Аларны үзебездә өлгертергә туры киләчәк. Авылда яшәүчеләр исә һаман кими бара, хәзер анда республикабыз халкының 35 проценты гына калды, ике меңенче елда ул 25 процент кына тәшкил итәр. Республика халкы исә дүрт миллионга җитәр. Безнең план коручылар, җитәкчеләр мондый үзгәрешләрне күздә тотамы, аларга карата әзерлек чаралары күреләме?

В. ЕРМАКОВ. Без моны, әлбәттә, искә алабыз. Авылда күпме кеше калачагын гына түгел, аларның күпмесе җир эшкәртәчәген, иген үстерәчәген, күпмесе терлек, кош-корт, бал корты үрчетәчәген дә исәплибез. Хәзер авылда эшкә яраклылар 547 мең, ике меңенче елда аларның саны 311 меңгә калыр, дип фараз итәбез. Алар исәбенә врачлар, укытучылар, сатучылар, төзүчеләр дә керә. Авыл хуҗалыгында тәҗрибәбез шактый. Брежнев шәһәренең халкы, мәсәлән, унбиш елда ярты миллионга җитте. Шул тирәдәге авыл хуҗалыгы да шәһәрдән калышмаска тырышты. Нәтиҗәдә, Тукай районының бер үк мәйданында соңгы өч бишьеллыкта ит җитештерү — өч, сөт — ике, бәрәңге — өч, яшелчә — егерме дүрт мәртәбә артты. Ничек дисезме? Капитал салу, эшләү аркасында. Акчаны да, көчне дә җәлләмәдек, тир түгүдән, сөял чыгарудан да курыкмадык. Җимеше көттермәде. Бу тирәдәге авыллардан шәһәргә китү бүтән тарафлардагыдан хәтта артыграк та булды. Димәк, җирнең уңдырышы, фермаларның ризыкны мул бирүе эшләүчеләр санына гына түгел, фән-техника казанышларын файдалануга күбрәк бәйле.

М. ЗАРИПОВ. Димәк, шәһәрләшү, авыл хуҗалыгы үсеше тизләнү аркасында, биш елдан соң һәр игенче, терлекче ике тапкыр күбрәк ашамлык җитештерергә тиеш. Моңа шартлар бармы соң? Нинди ысуллар мөмкинлек бирер?

В. ЕРМАКОВ. Шәһәр, шефлык бәйләнешләрен үстереп, камилләштереп, бу мәшәкатьләрнең бер өлешен үз өстенә алачак. Икенче юлы — промышленность предприятиеләренең ярдәмче хуҗалыкларын булдыру.

М. ЗАРИПОВ. Алар игенче эшен белерме, җир эшкәртерме соң?

В. ЕРМАКОВ. Хезерге көндә промышленность предприятиеләренең 70 мең гектар җире, 900 тракторы, 378 комбайны, 423 йөк машинасы бар. Дөрес, хуҗалыклар арасында әгыйфьләре, җир бирергә лаек түгелләре дә очрый. Мисалга, «Вакууммаш» берләшмәсен, «Сантехприбор» заводын, КамАЗны алыйк. Әмма игенче, терлекче эшен үрнәк башкаручылар да аз түгел. Нефтьче, химик казанлыларның «Залесный» ярдәмче хуҗалыгы бик әйбәт. Иген игү һәркемнең кулыннан килми, мондый очракта күмәкләшү отышлы. Республикабыз башкаласының дистә ярым промышленность предприятиесе, пайчы тәртибендә алты миллион сум тотып, аерым комплекс төзеде. Хәзер шул базада ел саен 15 мең тонна ит җитештерелә. Терлекләр көненә ярты килограммга симерә, чучка баласы җиде айда алты потка җитә. Терлек азыгының яртысын табыннарыбыздан җыйналган калдыкпостык тәшкил иткәнлектән, итнең үзкыйммәте шактый түбән — центнеры 72 сум гына, аны сату бәясе исә өч ярым тапкыр югарырак. Ярдәмче хуҗалык тотылган барлык чыгымнарны инде күптән кире кайтарды. «Залесный» бишьеллык планын ярты ел элегрәк үтәде. Мактанырлык күрсәткечләр! Гадәти колхоз-совхоз фермаларында исә җиде йөз мең баш чучка икенче ел асрарга калдырыла.

Шулай да ярдәмче хуҗалыкларның әһәмиятен күпертү ярамас. Хәзер алар, чама белән, сөтнең — ярты, бөртеклеләрнең һәм яшелчәнең — ике, итнең алты процентын бирә. Әгәр алар киләчәктә үз күрсәткечләрен ике мәртәбә арттырса да, төп йөк барыбер колхоз-совхозлар җилкәсендә кала. Җитештерүне нәкъ менә шуларда алга җибәрергә кирәк. Аның юлы бер генә: игенчелекне, терлекчелекне яңа югарылыкка күтәрү, яңа резервлар эзләү. Дөресен әйткәндә, аларны эзлисе юк, алар мәгълүм, тизрәк эшкә җигәсе генә бар. Мисалга, ясалма сугару колхоз-совхозларыбызга, гидростанцияләр салганда су астында калган менә дигән ярты миллион гектар болын уңышын кайтарып алырга; азыкны мул туплау терлекләр санын арттырырга мөмкинлек бирде. Әшне нәтиҗәлерәк, яхшырак оештыруның бүтән юллары да күп әле. Мәсәлән, мал азыгы җитешми, дип зарланабыз, шул ук вакытта уңыш җыйганда, зур югалтуларга юл куябыз, аны саклаганда да әрәм-шәрәм итәбез. Сенажны манараларга тутырып саклау ысулын өйрәнеп җиткәнебез юк. Ашата белмәвебез аркасында күпме азык терлек ашказанында әрәм була? Көтүләрне дөрес тәрбияләмәү, кырчылык белән терлекчелек нисбәтен дөрес көйләмәү аркасында да, байтак чимал дөрес файдаланылмый кала. Бу фикер ачык аңлашылсын өчен, бер мисал китерик. 1984 елда Казан бройлер фабрикасында азык бирүне бер мең тоннага киметкән хәлдә ит җитештерүне 600 тоннага арттыруга ирештеләр. Монда һичнинди гайре табигый нәрсә юк. Кошчылыкның нәтиҗәле технологиясен, осталыгын үзләштергәннәр.

М. ЗАРИПОВ. Һәр эш осталык таләп итә...

В. ЕРМАКОВ. Анысы шулай, тик, кызганычка каршы, кагыйдәләр һәрвакыт тормышка ашырылып җитми. Ни өчен кызыксыз китаплар, тонык сурәтләр, күңелсез кинофильмнар, җайсыз аяк киемнәре, начар телевизорлар, радиоалгычлар, магнитофоннар чыгып тора? Осталык җитмәүдән, оештырудагы кимчелекләрдән, яки техник киртәләр комачаулаганлыктан гынамы? Юк. Бу, барыннан да элек, эшкә җавапсыз караганлыктан, һөнәренең кадерен белмәгәнлектән килә.

Икенче мисал да китерик. Мәгълүм булганча, бик озак еллар, чынлыкта, сугыштан соңгы бөтен бишьеллыклар буенча сөтчелек фермалары алдына сыерлар санын арттыру һәм көтүләрнең продуктлылыгын үстерү бурычы берьюлы куелды. Терлек азыгы җитешмәгән шартларда мондый план төгәл исәп-хисапка түгел, өметкә таянып кына төзелде. Баш санына караганда сөт азрак артты. Унберенче бишьеллыкта таләп үзгәрде: баш санын кайгырту һәр хуҗалыкның эчке эше, итне-сөтне генә тиешенчә җитештер. Нәтиҗәдә, бөтен артым малларның һәм сөтнең сыйфаты яхшыру хисабына барлыкка килде. 1984 елда республикабыз терлекчелегендә беренче тапкыр Балтач районы фермаларында һәр сыердан уртача 3503 килограмм сөт алынды. Алар артыннан Кукмара, Лаеш, Питрәч, Биектау терлекчеләре дә өч мең чиген узып китте...

М. ЗАРИПОВ. Ярыш шәхси фидакарьлеккә, отышлырак, файдалырак алымнарны куллануга киң юллар ача. Берәүләр алга чыга, икенчеләр аларны куып җитәргә телиләр.

В. ЕРМАКОВ. Илебездә сыерларның сөт бирүен бер тоннага күтәрү — 2200 килограммга җиткерү өчен алтмыш ел кирәк булды. Тик без хәзер мондый тизлеккә риза түгел. Унберенче бишьеллыкның дүрт елы дәвамында республикабыздагы һәр сыердан савыла торган сөт уртача 290 килограммга артты һәм өч тоннага якынлашты. Балтачлылар казанышына тизрәк җитәргә, уңышны тагын да ныгыта барырга кирәк. Алдынгыларның тәҗрибәсен яхшырак өйрәнү, осталык серләрен ачыклау мөһим.

Балтач районы фермаларында да, бүтән яклардагы кебек, «Холмогор» токымын асрыйлар. («Бестужев», «Швиц» һ.б. токымнарның мөмкинлекләре күпкә югарырак). Монда гигант комплекслар да юк, терлек абзарлары гадәти генә. Белгечләре дә бүтән яклардагы кебек, әмма күрсәткечләре шактый югары. Нидән бу? Хезмәт культурасы яхшырак, идарә итү алымнары нәтиҗәлерәк булудан. Монда җитәкчелек итү дөрес юлдан бара, терлекчеләрнең намусы, җаваплылыкны тоюлары, аңнары югарырак. Әгәр барлык фермаларда эш балтачлылар дәрәҗәсенә җитсә, өч ярым тонна да чик булмаячак. Алдынгылар һәр сыердан дүрт-биш тонна сөт саву турында уйларга тиеш. Ул чакта без сыерлар санын дүрт йөз меңнән арттырмаган хәлдә, тагын 300 мең тонна өстәмә сөт алачакбыз.

Хезмәт нәтиҗәлелеген күтәрү мөмкинлеген безнең хуҗалыкның һәр тармагында табарга мөмкин.

М. ЗАРИПОВ. Без ачылмаган мөмкинлекләр турында күп сөйлибез, авылга кагылсак, яңа бурычлар куябыз, аның күбрәк бирүен көтәбез. Тик ул күбрәк бирсен өчен башта алырга тиеш ич әле. «Известия» газетасында китерелгән мәгълүматлар шәһәрнең озак еллар буе авылга караганда, өстенрәк шартларда үстерелүен күрсәтә. Коллективлашу башланганнан бирле узган илле ел эчендә промышленностьта эшләүче бер эшчегә салынган капитал авыл хуҗалыгы белән чагыштырганда, җитештерү сферасында өч тапкыр, башка сфераларда унбер тапкыр күбрәк. Мондый хәл киләчәктә дә кабатланмас микән?

В. ЕРМАКОВ. Моңа юл куелмас, дип санарга мөмкин. Азык-төлек программасы бар яктан да уйлап төзелгән, аның җитештерү һәм иҗтимагый нигезләрен гармоник үстерү, авылны техника, игенчелек, терлекчелек, яшелчәчелек, бакчачылык чималын эшкәртү машиналары белән тәэмин итү каралган. Без 1984 елда авылда ярты миллион квадрат метр торак төзүне казаныш дип саныйк. Киләчәктә бу күрсәткеч тагын да үсәр. Уникенче бишьеллыкта авыл көнкүрешен, культурасын күтәрүгә уртача чыгым унынчы бишьеллыктагыдан ике ярым мәртәбә артыграк тотылачак. Өч миллион квадрат метр торак, 57 мең урынлы мәктәпләр, 28 мең урынлы балалар бакчалары кору күздә тотыла. Авыл барлык яктан шәһәргә тиңләшергә тиеш. Шәһәргә күчүне туктатып булмый, ләкин аны тәртипкә салырга мөмкин.

М. ЗАРИПОВ. Фән-техника прогрессын тизләтү, аның колачын киңәйтү, бар байлыктан бәрәкәтле файдалану, хуҗалык белән җитәкчелек итүне камилләштерү, халык хуҗалыгының таянычы булган машина төзелешен өстенлекле үстерү, киң куллану товарларының санын арттыру һәм сыйфатын күтәрү, азык-төлек программасын, шәһәрләрдә һәм авылларда социаль үзгәрешләрне тормышка ашыру, табигатьне саклау — КПССның XXVII съездын каршы алганда партиябез һәм хөкүмәтебез җәелдереп җибәргән эшләр менә шулар... Хәзер безгә бу максатларга ирешү чараларын күрергә, бурычларның кайсы кичектергесез, кайсы икенче, өченче нәүбәттә генә үтәлергә тиешлеген ачыкларга кирәк.

В. ЕРМАКОВ. Хәзер чимал эшкәртүне камилләштерү, калдыкларны киметү, энергияне, материалларны сак тоту, хезмәтне отышлырак итү иң зур бурычлардан санала. Әйтергә кирәк, республикабызда уңай тәҗрибә җитәрлек. Зәй ГРЭСында, мәсәлән, җылылык агрегаты эшләп чыгарган газлардан кабат файдалану тормышка ашырылды. Саба урман хуҗалыгы 1963 елда 1,3 миллион сумлык әйбер ясый иде, хәзер — 4,7 миллионлык. Элек ул утын, бүрәнә, такта кебек тугыз төр әйбер сатса, хәзер фанера, паркет, көрәк, балта саплары, себерке, мунчала, кухня кирәк-ярагы, истәлек бүләккә яраклы савыт-саба, ылыс оны — җәмгысе кырык төр әйбер тәкъдим итә. Егерме ел элек ябылырга йөз тоткан урман хуҗалыгы хәзер менә шулай яшәргә сәләтле икәнлеген исбатлады. Бу хуҗалыкның урман кисүне әрәм-шәрәмсез башкаруы, чималны сак тотуы, бер үк вакыт яшь үсентеләрне тәрбияләве, кыскасы, акыллы эшли белүе башкаларга үрнәк була ала.

Игътибарның иң зурысы кешеләргә юнәлтелергә тиеш, әлбәттә. В. И. Ленин өйрәткәнчә, социалистик тәртипләрнең дә, коммунистик байлыкның да — бернәрсәнең дә күктән яумаячагын, нәтиҗәле идарә итүне һәрчак оештыру кирәклеген истә тотыйк. Оештыру — эш башкаруга йогынты ясау дигән сүз. КПСС ҮКның апрель Пленумында (1985) М. С. Горбачев, безнең алда торган мәсьәләләрне хәл итәр өчен, барлык резервларны хәрәкәткә китерү, кешеләрне активлаштыру, һәркемнең үз урынында бөтен көчен биреп намуслы эшләвенә ирешү кирәклеген басым ясап әйтте.

Алда олы, катлаулы һәм җаваплы эшләр тора. Үткәндә тупланган барлык тәҗрибәне анализлыйсы, эшчедән министрга, колхозчыдан академикка кадәр һәркемнең тулы җегәрлеккә эшләвенә ирешәсе бар. Ярышның тәэсирлерәк формаларын файдаланырга, матди үсендерүне, шәхеснең һәм коллективның әхлакый абруен күтәрүне түгелгән хезмәткә бәйләп түгел, аның җимешенә карап тормышка ашырырга кирәк. Татарстанда әлегә һәр өч кешенең икесе генә хезмәтне оештыруда бригада ысулына җәлеп ителгән. Идарәнең мондый формасына эрерәк берләшмәләрне — цехларны, заводларны, төзелешләрне дә күчерергә, хуҗалык исәбе мөнәсәбәтләрен үстерергә вакыт. Аерым кеше ихтыяры түгел, идарә системасы үзе ваемлы, сакчылларны күтәрсен, үсендерсен, җәмгыять милкенең кадерен белмәүчеләрне, исрафчыларны җавапка тартсын иде!

Егерменче гасыр — зур тизлекләр, искиткеч техника казанышлары заманы. Бу казанышлар көндәлек эшчәнлегебездә киң файдаланылса, җитештерүче көчләр галимнәрнең отышлы идеяләре белән ныграк коралланса гына, тормыш тиешенчә алга китәчәк. Ачышлар, яңа тикшеренүләр завод конвейерына,фермаларга һәм кырларга тизрәк кереп, җитештерүне яңа баскычка күтәрергә тиеш. Иң бөек ачыш та, әгәр ул тормышта файдаланылмаса, акыл һәм мускул көчен, матди чыганакларны һәм кыйммәтләрне бушка әрәм итү генә булачак.

М. ЗАРИПОВ. Съезд алдыннан үткәргән бу әңгәмәбездә без әле үтәлмәгән, киләчәктә үтәлергә тиешле эшләргә күбрәк игътибар бирдек.

В. ЕРМАКОВ. Бу аңлашыла да. Партия съезды — политик зур тантана. Анда ил, коммунистлар партиясе, бөтен халык җәмгыятьне иҗтимагый, политик, экономик яктан үстерү, идарә итү буенча туплаган тәҗрибәсен уртага чыгарып сала, яңа, тагын да югарырак максатларын, бурычларын ачыклый.

Казанышларыбыз олы, һәр көн космосны тикшерүдә, дәвалау өлкәсендә, авыл хуҗалыгында, промышленностьта, казылма байлыкларны үзләштерүдә, аларны эшкәртеп адәм баласына кирәкле йөзләгән меңләгән әйберләр ясап чыгаруда, җәмгыятьнең алга китүе өчен яңа эзләнүләр алып баруда уңыш арты уңыш китерә. Юлда яңа кыенлыклар, яңа мәсьәләләр килеп чыгу табигый. Аларны вакытында күреп, аларның катлаулы икәнлеген аңлый белсәк һәм бу киртәләрне җиңү юлында барыбыз бергә туплансак, план һәм программаларыбызның тормышка ашырылуына шик юк.

**Ибраһим Нуруллин**

# ФАТИХ ӘМИРХАН

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

## «Нәни мулла»

### I



рхивта Әмирхановларның баштүбән әйләндерелгән куакны хәтерләтә торган шәҗәрәләре саклана. Кәүсәнең иң очындагы «Гәрәй мирза» дигән исемне укыйбыз да кәүсә буйлап түбән төшә башлыйбыз. Ботактан ботакка, тармактан тармакка күчә-күчә, бик күп бабалары, шул исәптән, Әмирхан һәм Хөсәен аша узып, безне кызыксындырган тармакка җитәбез: Мөхәммәтфатих.

Хәзер инде буыннар арасын егерме биш-утыз ел итеп билгелик тә (мулла балалары — мәхдүмнәр бик иртә өйләнмәгәннәр), ата-бабаларының тереклек итү вакытларын исәпли-исәпли, яңадан өскә күтәрелик.

Гәрәй мирзаның улы Җәлмәт, «бәхет эзләп» булса кирәк, Сембер ягыннан Чистай төбәгенә килеп чыга һәм Чирүле Шонталы авылына туктала. Үзе турында да, улы Әхмәт һәм Әхмәтнең улы Кадермәт турында да күп мәгълүмат калмаган.

Ниһаять, шәҗәрәдә мулла пәйда була: «Морад хәзрәт». Бу зат Чирүле Шонталы авылында яшәп, шунда вафат булган, шунда күмелгән. Тереклегендә ул шөһрәт казанган булса кирәк, Р. Фәхретдиновның «Асар»ендә әйтелгәнчә, бае-фәкыйре, олысы-кечесе каберенә баралар икән.

«Исмәгыйль бине Морад,— диелә «Асар»дә,— Талкыш авылында зирагать илә иштигаль идәр иде». Әмирханнар ыруының төп ватаны булып танылган Талкыш авылына (хәзер Чистай районына керә), димәк, беренче башлап Морад улы Исмәгыйль килеп төпләнгән.

Аннары — Исмәгыйль улы Габделмәннан. Әллә ни исем чыгара алмаган булса кирәк, чыганаклар аны читләтеп узалар.

Тагын бер баскыч төшкәч, без Әмирхан муллага җитәбез. Аның турында мәгълүмат күбрәк.

Башта агасы, ягъни Исмәгыйль улы Сәфәр хәзрәттән, аннары Казан арты авылларының берсендә күпмедер белем алгач, ул Бохарага китеп укыган. Соңра Югары Курса, Тимер шәех һәм Төрек авылларында имам булган. 1809 елда мәхәллә халкының чакыруы буенча Казанга күчеп килеп, Яңа бистәнең соңрак 9 мәчет дип йөртелә башлаган мәчетенә мулла булып урнашкан. Укыту-тәрбия эшләрен ул, күрәсең, тиешле югарылыкка күтәргән. 9 мәчет каршындагы мәктәпнең Хөсәен һәм Зариф муллалар вакытында да «Әмирхан мәдрәсәсе» дип йөртелүе әнә шул турыда сөйләсә кирәк.

Әмирхан мулла остазы Мөхәммәдрәхим Йосыф улы эль-Ашытыйның кызы Газизәгә өйләнгән һәм Хәсән, Ибраһим, Хөсәен һәм Фатима исемле бала-

лары бер-бер артлы дөньяга килгән. Үлгән елы да тәгаен билгеле: 1827.

Тарихчылар Әмирхан хәзрәтнең соңыннан танылып киткән шәкертләренең дә исемнәрен саныйлар. Берсен генә укучының зиһененә кертеп калдыруны кирәк табам: Фәхретдин Мостай улы эль-Норлатый.

Әдипнең бабасы Хөсәеннең үсмер чагы бик үк көяшлы, аяз булмаган. 1816 елда дөньяга килеп, унбер яшендә атасыз кала. Башта Чистай шәһәрендә, аннары Казанда һәм, ахыр килеп, Мәчкәрә авылында белем эсти. Бу елларда ул кардәш-ырулары тәрбиясендә булган дип уйларга кирәк. Кайсыдыр елны Бохарага китеп, Хөсәен андагы гыйлем чишмәсе бирә алган кадәр гыйлем белән зиһенен баеткач, 1847 елда Казанга кайта һәм, указ алып, мәрхүм атасы мәчетенә Байморад мулла янына икенче иптәш мулла булып урнаша.

Күп еллардан соң Ф. Әмирхан болай дип язды: «Казан имамнарының, бер-беренә дошман фиркаларгә аерылышып, Мәрҗани исеме вә мәсләге тирәсендә мөҗадәлә[1] кылышкан вакытларда минем атам да, соңгарак таба бабам да Мәрҗани тарафдары фиркага мәнсуб[2] булганнар».

Ни өчен Хөсәен хәзрәт соңлабрак Мәрҗани тарафдары булып киткән? Ник баштан ук түгел? Монда ике ихтимал булырга мөмкин. Беренчесе: Мәрҗани гадәттән тыш талантлы, кыю һәм тәвәккәл кеше буларак, гасырлар буе ныгытылган дини догмаларның заман барышы белән каршылыкка кергәнлеген тизрәк аңлап алган һәм көрәшкә ташланган. Хөсәенгә исә моның өчен күбрәк вакыт кирәк булган. Икенчесе: алар арасында көндәшлек дигән нәрсә яшәгән. Бохарада ул Мәрҗани белән бер үк вакытта укыды. Мәдрәсәләре төрле булган тәкъдирдә дә очрашмый торуларын күз алдына китерү кыен. Укуны тәмамлаулары арасы да бер-ике ел гына. Казанда да бер үк мәҗлесләрдә еш булганнар. Кыскасы, уздырыштан гыйлем алалар, уздырыштан сүз сөйлиләр, уздырыштан яза башлыйлар. Ш. Мәрҗани үзенең кыю һәм төпле фикерләре, тирән эчтәлекле әсәрләре белән танылгач та, Хөсәен хәзрәт башта аңа иярмәгән, дөресрәге, иярергә теләмәгән. Нәселдән килә торган сыйфатлары шул: һәр әйткәнгә ләббәйкә дип торырга, кеше эзенә басып барырга яратмыйлар. Әмма заман таләбе үзенекен иткән, ахыр чиктә Хөсәен сукмагын Мәрҗани сукмагына китереп кушкан, икесен дә татар мәгърифәтчелегенең олы юлына чыгарган.

Билгеле мәгълүматлар Хөсәен мулланы таза бәдәнле, мәһабәт һәм гайрәтле адәм итеп җанландыралар. Үзенең төп вазифасын — намаз укыту, балага исем кушу, никах уку, үлгәнгә ясин чыгу кебек эшләрне ул чынлап та яратып һәм җиренә җиткереп башкармаган. Мондагы тәкәллефләр, гореф-гадәтләр, туйдыру өстенә, шул кадәр искергәннәр ки, дөньяга яңача карый башлаган хәзрәткә бу эш рәхәтлек китермәгән.

Хөсәен хәзрәтнең яратып башкарган һәм күп вакыт, зур көч сорый торган төп эше бар. Ул да булса мөхәррирлек. Язу-сызу эшеннән күзәткән асыл максаты, билгеле инде, ислам идеологиясенең катып калган күп кенә догмаларын тәнкыйть астына алу, исламны яңа заманга, яңа таләпләргә яраштыру, яңа фикер, яңа идеяләргә юл ачу. Ул сайлаган өлкә — тарих. Әмма без белгән тарих ук түгел, пәйгамбәрләр, изгеләр, ханнар, солтаннар тарихы. «Нөҗүм эль тәварих» («Йолдызлар тарихы» —1884) исемле китабының керешеннән хәзерге телгә күчереп бер өзек китерик. «Мин бер фәкыйрь кол, халыкка файда китерер өчен һәм укучыларның догасын өмет итеп, бу китапны пәйгамбәрләрнең һәм изге әүлияләрнең күренеклеләрен могтәбәр китаплардан җыеп төзедем, каршылыклы сүзләрдән арындырдым, нык нигезләнгәннәрен генә керттем».

Бу китабында Хөсәен хәзрәт Мөхәммәткә кадәрге пәйгамбәрләрдән алып төрек солтаны Габделхәмиткә кадәр, шәрыкның бик күп билгеле шәхесләренең тормышына кагылышлы мәгълүматлар биргән. Моның өчен күпме китап укырга, чагыштырырга, уйланырга кирәк булгандыр!

Тарихчының моннан тыш тагын берничә басма китабы чыккан һәм шактый кулъязмасы сакланып калган. Аның шигырьдә дә каләм сынаганлыгы билгеле.

Шушы хезмәтләре белән Хөсәен хәзрәт үз заманының күренекле мөәррихы, ягъни тарихчысы булып танылган.

Бохарадан кайткач, Хөсәен, артык күп гомер үткәрмичә, Бәдриҗамал исемле кызга өйләнә, һәм менә шушы гаиләдә 1853 елның иске стиль белән 10 январенда, беренчеме, икенчеме бала булып, Мөхәммәтзариф дөньяга килә.

[1] Мөҗадәлә — бәхәс, ызгыш, гауга.
[2] Мәнсуб — караган, бәйләнгән.

Аның бала чагы һәм үсмерлек еллары Яңа бистәдә, әнисе канат астында үткән. Башлангыч белемне дә шунда ук, «Әмирхан мәдрәсәсендә» алган.

Үз кул астында күпмедер укыткач, Хөсәен Зарифны Курса мәдрәсәсенә җибәрә. Аннары Хвалыйн өязеннән килеп үзендә укый башлаган Сәгъдетдин исемле шәкерт белән икесен бергә, Норлат мәдрәсәсенә илтеп, бер хөҗрәгә куя. Егет булып җиткән Зариф, 1872—74 елларда шунда укып, «хәтме китеп» итә.

Ник Курса һәм Норлат? Ник Бохара яисә Казан үзе түгел? Бохараи шәрифнең Казан имамнары һәм мөселманнары күзендә абруе төштемени инде? Алай дияр идең, бохари хәзрәт балалары китә торалар. Моннан соң да әле китәчәкләр. Күп еллардан соң Зарифка иптәш мулла булачак Садыйк Иманколый да әле Бохара гыйлемен дыңгычлап тутырып кайтачак. Атасы бар дисә, юллык һәм киченерлек акчасын бирсә, Зариф китмәс идемени? Ләкин Хөсәен ул сүзне әйтмәгән. Чөнки Бохара гыйлеменең дәрәҗәсен һәм кыйммәтен ул үзе татып белә.

Казан мәсьәләсенә килгәндә, мондый бер гыйбрәтле хәлгә игътибар итик. XIX гасырның ахырларына кадәр Бохарага китмәгән яшьләр, хәтта Казан, Оренбург, Уфа, Әстерхан, Уральскида туып үскән балалар да (күбесенчә мәхдүмнәр) төрле авылларга китеп укыганнар. Андый авылларның күпчелеге Казан тирәсенә урнашкан. Бу хәл крайны колонизацияләүгә бәйле булса кирәк. Оялары туздырылган морзалар һәм бүтән бай гаиләләр, авыл җиренә китеп төпләнеп, яңа экономик үзәкләрнең калкып чыгуына һәм, шуңа бәйле рәвештә, яңа гыйлем учакларының барлыкка килүенә сәбәп булганнар. Зур талант һәм белемияләре тарафыннан нигезләнгән кайбер мәдрәсәләр үсә, зурая, камилләшә һәм дан казаналар. Татарлар яши торган шәһәрләрдә исә мондыйлар белән ярышырлык уку йортлары XIX гасыр ахырына таба гына баш калкыта башлый. Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең 1882 елда, Оренбургтагы «Хөсәения»нең 1896 елда, Уфадагы «Галия»нең исә 1906 елда гына дөньяга килүләрен искә алыйк.

Норлат мәдрәсәсе дә, күрәсең, заманы өчен алдынгы уку йорты булган. Зарифның белем эстәү юлын шунда төгәлләве, моннан кала, мәдрәсә башлыгы Фәхретдин мулланың Әмирхан хәзрәт шәкерте булганлыгы белән дә аңлатылса кирәк.

Ничек укыган соң Мөхәммәтзариф? Тумыштан ук зирәк, зиһенле егет алдынгы шәкертләрнең берсе булган дип уйларга туры килә. Сәгъдетдин мулланың күп еллардан соң биргән белешмәсенә караганда, Зариф мәдрәсәдә чакта ук коръәнхафиз булган, ягъни коръәнне яттан белгән. Кыйраәт остасы да икән. Тавышы калын һәм матур. Норлат мәчетендә дә, атасы мәчетенә кайтып та, коръән укып күрсәткәнлеге билгеле.

Әмма Зариф дин гыйлеменә мөкиббән киткән фанатик шәкерт булган икән дип уйларга ярамый. Таза һәм дәртле бу егет дөньяны да сөйгән, тормыш ләззәтләреннән дә баш тартмаган, дөнья хәлләре һәм иҗтимагый мәсьәләләр белән дә кызыксынган.

1874 ел. Зарифның укуы тәмам. Шуннан нәрсә? Казан губерна идарәсенең 1875 елның 1 февралендә Диния назаратына җибәргән кәгазеннән без түбәндәгеләрне беләбез.

Яңа бистәнең Зур соборный мәчете мәхәлләсе кешеләре Мөхәммәтзариф Әмирхановны мәрхүм Мөхәммәтсафа мулла урынына әтисе Хөсәенгә иптәш мулла итеп сайлаганнар. Идарә булачак муллага әйбәт кенә характеристика бирә дә имтихан алырга үтенә. Зариф Уфага киткән һәм, 1875 елның маенда имтихан тапшырып, имам, хатыйп һәм мөдәррис дигән исем алган. 23 яшьлек егет өчен аз түгел!

Ел артыннан ел узган. Зариф мулланың да тормышы майлагандай гына бармаган. Күңелсезлекләр дә чыккалаган, бәлагә дә юлыккан. Моңа гаҗәпләнергә туры килми. Яңачарак уйлый, яңачарак гамәл кыла. Руханилык вазифасын башкаруга мөкиббән китмәгәне хәлдә, дөнья сәүмәк «чир»еннән дә азат түгел. Дус бар, дошман бар дигәндәй, иске фикерле муллаларның Зариф Әмирханыйны өнәмәүләре табигый.

Алма агачыннан ерак төшми дигәндәй, Зариф мулланың калыплашуы, дөньяга карашының билгеле бер рәвеш алуы, барыннан да бигрәк, Хөсәен хәзрәт йогынтысы белән бәйле. Соңрак китаплар язарга керешүе дә очраклы хәл булмаса кирәк. Фикри үсеше, күрәсең, тукталып калмаган, Ф. Әмирхан әйткәнчә, атасыннан әлегрәк ул Ш. Мәрҗани тарафдарына әверелгән.

Дөрес, Зариф хәзрәтнең иҗтимагый-сәяси иманы моннан күп алга китми.

1905 елгы революциядән соң без аны либераль карашлы мулла итеп күрәбез. Полиция агентурасының күзәтүләренә караганда, ул кадетлар партиясенә күңел баглаган. Яңа гасырга кергәч, уртарак юл тота торган Зариф белән сулашып киткән улы Фатих арасында әле каршылыклар чыга башлаячак, үзара мөнәсәбәтләре соңрак гаять кискен төс алачак. Хәер, без бик күп алга сикердек бугай, хикәяләвебезне үз урыныннан ялгап китик.

...Яшь мулла Мөхәммәтзариф, ниһаять, Зиннәтулла кызы Бибирабигага никахлана. 1882 елда аларның кызлары дөньяга килә. Исемен Бибисәгадәтбану дип куялар. Тагын дүрт елдан соң, ягъни 1886 елда, бу китапның герое, булачак олы язучы, публицист һәм тәнкыйтьче Фатих Әмирхан дөньяга килә. Язмыш шуклыгыдырмы, ул апасы белән бер үк көндә — иске стиль белән 1 гыйнварда туган.



## 2

Казан, бигрәк тә аның бистәләре, еш кына зур-зур янгыннарга дучар булып торган. Саный китсәң, сәбәпләре күп, билгеле. Тоташ агач өйләр. Җәйнең коры килүе. Ата-аналары эштә булып, караучысыз калган балаларның шуклыклары. Үч алу өчен төртеп яндыру...

1749 елда Иске бистәне ялмап алган зур янгын Яңа бистәнең барлыкка килүенә сәбәп була. Татарларны христиан диненә көчләп кертү кампаниясенең гаять куәтләнгән, ямьсез һәм шәфкатьсез рәвеш алган дәвере иде бу. Татарлар арасында Аксак Каратун дигән кушамат белән мәшһүр булган епископ — Лука Канашевич, бу фаҗигадән файдаланып, ярлы татарларның тире белән сугарылган, көлгә әйләнгән хезмәтләре белән ашланган җирне чиркәү файдасына тартып алуга ирешә. Йортсыз-җирсез калган халыкка моннан күчеп китәргә боерык бирелә, урын да күрсәтелә. Әнә, Иске бистәнең аръягында, Иделгә таба саеккан күлләр һәм сазлыклар белән әйләндереп алынган ярымутрау бармы, менә сезгә урын! Янгыннан соң ук өч йөзләп фәкыйрь гаилә шунда күчеп китә. Шул ук елларда Казан татарлары әлеге ярымутраудан зират өчен дә җир бүлеп алалар. «Яңа бистәгә үлгәннәр һәм бөлгәннәр генә бара»,— дигән әйтем әнә шуннан килеп чыккан.

Яңа бистәнең шәһәргә таба ягы да үзәнлек булганга күрә, яз-көз айларында кешеләр шәһәргә бата-чума чыкканнар. Ташу вакытында исә ярымутрау утрауга әверелгән, көймә һәм паром белән йөргәннәр.

Шунысын да әйтик, Яңа бистәнең хәзерге вокзалга караган ягы, мичкәләр белән шәһәрдән китереп аударыла торган нәҗес урыны булып, бик үк татлы тоелмаган ис таратып яткан. Моңа тагын сазлыклардан килеп ябырылган озынборыннарны өстик. Күнегелгән гадәттерме, әллә инде кәҗә күп асрагангамы, бистә халкы яшелчә үстермәгән, ашаганнары өйрә, токмач, бәрәңге кыстыбыеннан узмаган. Әнә шуларның нәтиҗәсе буларак бизгәк, чахотка, балаларда рахит хөкем сөргән. «Кыйгач кашлы, кәкре аяклы Яңа бистә кызлары» дип юкка гына җырламаганнар. Үлем-җитем күп булып, бигрәк тә балалар кырылган.

Беренче килеп утырган кешеләр хисабына Яңа бистә халкы бик үк ишәймәсә дә, шәһәрдән күчә торучылар, бигрәк тә тирә-як авыллардан килеп төпләнүчеләр хисабына ул киңәйгән, зурайган, XIX гасырда инде өч мәхәлләгә бүленгән, өч таш мәчете булган.

Яңа бистә кешеләренең баштагы төп кәсебе — кустарьчылык. Ирләр кием-салым, бүрек, читек-кәвеш теккән, хатын-кызлары кәләпүш, калфак каеган, такыя чиккән. Товарларын Иске бистә байларына сатканнар. Хәллерәкләре ат тоткан, ямщик булып йөргән, һөнәрсезләре Усиядә крушник булып йөк ташыган, Бакалтайда утырып калган салларны утынга тураганнар. Ач та булмаганнар, тамаклары да туймаган.

Узган гасырның урталарына таба Яңа бистәдә борынгыдан калган кәсепһөнәрләрдән сабын кайнату, тире иләү, мех эшкәртү предприятиеләре калкып чыга башлый. Дөрес, аларны фабрика дип атау да кыен. Эшчеләр саны 2-3 тән башлап, 30-40 ка кадәр генә. Хуҗаларыннан Глинкин, Утәмишев, Кәҗә Якуб кебекләрне атап китәргә мөмкин. Аның саен арта торган эшче кулларны бу предприятиеләр генә йотып бетерә алмаган. Күпләр Крестовников заводында, Петсольдның сыра заводында һәм бүтән җирләрдә ялланып эшләгәннәр. Билгеле инде, квалификация сорамый торган кара эштә.

Әнә шул килеш Яңа бистә Казанның зур булмаган бер административ

төбәгенә әверелә. Халык ишәйгәч кирәк бит: кибетләр, сәүдәгәрләр саны арта, кустарьларның товарларын җыеп алып, ары таба җибәрә торганнары килеп чыга. XX гасыр башында без Яңа бистәдә яшәгән өченче, икенче, хәтта беренче гильдия купецлары белән дә очрашабыз. Шулай инде, байлар байый, ярлылар очны-очка гына ялгап баралар.

Тагын ние белән мактана ала Яңа бистә? Пекарнясы, көянтәсен бер тиенгә сата торган «фанталы», бер татар «духтыры», «божий фирка» башлыгы Гайнан Вәисеве, камчылы ишаны, Насыйр бутышнигы, «акушерка» Әчәтте Гаффәсе, сукыр карые һ. б. белән.

Кыскасы, бистә дисәң бистә. Ни авыл, ни шәһәр түгел. Авыл дияр идең, иген икмиләр, шәһәр дияр идең, бер-беренә сырышкан кечкенә агач өйләрдә гомер итүчеләр тавык-каз, сыер-кәҗә асрый. Иске гореф-гадәтләр, шәригать кушканнар белән миләре агуланган. Байлар да алардан күп ерак китмәгән. Искечә тора, искечә сәүдә итә, иске тәкәллефләргә буйсына.

Моннан соң инде Әмирхан, Хөсәен һәм Зариф хәзрәтләрнең дөньяга яңача карый башлап та, күкрәкләрендә көч-гайрәт асрап та, урта юл тотулары, алга таба бик үк ыргылмыйча яшәүләре аңлашыла. Авыл бит ул: һәр эшең, һәр фигылең, һәр адымың күз алдында. Итәк-җиңне җыеп йөрергә, сүзеңне үлчәп сөйләргә кирәк. Артыграк яңарып киттеңме, кара халыкны биздерүең, байлар алдында ышанычны югалтуың мөмкин. Бөтен тормышың — торак-җирең, өс-башың, ашау-эчүең, мәдрәсәң шулардан килгән доходка бәйләнгән бит. Кечкенә генә бер деталь дә әмирханныкыларның мохитка җайлашырга мәҗбүр булулары турында сөйли. Карт хәзрәтне әйтеп тә тормастан, Хөсәен бер генә тапкыр да фоторәсемгә төшмәгән. Хәтта Зариф та, Тукайны күмгәндә, үзе дә сизмичә объективка эләккәнен искә алмаганда, рәсемен алдырмаган.

**...Шәһәр ягыннан килеп, Яңа бистәнең трамвай йөри торган урамына күтәрелик. Бу урам элек Мало-Симбирский дип аталган, хәзер — Мәҗит Гафури. Урамның сул як тротуары буйлап атлыйк. Әһә, менә килеп җиттек: 35 нче капка. Капка дигәч тә, үзе юк инде, урыны гына калган. Буп-буш ишегалдының аргы башында яңы белән салынган алты почмаклы өй күренә. Кайчандыр зур һәм матур булган бу йорт хәзер инде, чүгә төшеп, төсен җуйган. Җентекләбрәк карасаң, сырлап эшләнгән наличниклы тәрәзә араларында канатларын җәйгән күгәрчен сурәтләрен күрергә мөмкин. Өйнең ике ягында бакча, эреле-ваклы куаклар. Кайчандыр анда карга оялары белән чуарланган мәһабәт тупыллар шаулап утырган.**

Фатих Әмирхан туган йорт шушы була инде... Ул дөньяга килгәнче күп еллар элек әмирханныкылар Мало-Симбирскийга чыгарып салынган һәм, хыялны бик көчләсәң, ике катлы дип исәпләрлек өйдә яшәгәннәр. Хәзер инде ул йорт юк. Кайсыдыр елларда Рабига остазбикә аның бер бүлмәсендә кыз балалар укыткан, бүтән бүлмәләрендә хәзрәтнең хезмәтчеләре яшәгән, фатирчылар торган. Ишегалдының капкадан кергәндәге уң ягында келәт, ат, сыер абзарлары һәм бүтән төр каралтылар тезелеп киткән. Әмирхан һәм Хөсәен ничек булгандыр, әмма Зариф хәзрәтнең атлар тотканы, сыер асраганы билгеле. Фатих имчәк баласы чакта сыерны Рабига үзе сауган.

Артык мәшһүр кеше кызы булмагандырмы, Рабига остазбикә хакында мәгълүмат күп түгел. Менә алтмыш яшенә җитеп килгән чагының онык кызы Разия язып калдырган портреты. «Чандыр гына, кечерәк буйлы, бик хәрәкәтчән, озын кара чәчле бу карчык гаҗәеп зирәк һәм кабилиятле[1] кеше иде... Аның бик купшы һәм пөхтә киенергә яратуы, кунакка барырга җыенганда, көзге алдына басып, кара күзләренә сөрмә тартып торулары күз алдымда калган». Моннан аның кыз чагын һәм яшь хатын вакытын да беркадәр күз алдына китерергә мөмкин.

Ул заманның гадәтенчә, мулла хатыннары мәхәлләдәге кыз балаларны укытырга тиеш булганнар. Ләкин Рабига Зариф муллага гыйлем иясе булып килмәгән. Шуңа күрә яшь остазбикәне бу эшкә мулла үзе әзерләгән дип уйларга кирәк. Эшкә башлагач та әле Рабига һәр дәресен, хәзерге тел белән әйтсәк, ире консультациясеннән соң үткәргән. Разия Әмирханованың язмасына караганда, илленең теге ягына авышкан чагында да ул һәркөн кич иреннән гарәп грамматикасы буенча дәрес ала икән.

Билгеле инде, Рабига остазбикәнең белеме акрынлап арта, караш даирәсе киңәя, укыту ысуллары камилләшә барган. Яңа гасыр башында, мәктәбе шактый киңәеп һәм ныгып абруй казангач, ул инде үзендә укып бетергән сәләтлерәк кызларны мөгаллимә итеп калдыра башлаган. Шәхси кулларда саклана

---

[1] Кабилият — сәләт.

торган түбәндәге документ та бу сүзләрнең дөреслеген раслый.

«Шәһадәтнамә.

Бу шәһадәтнамәне күрсәтүче Нәфисә иптәш Габделхаликъ кызы Миниева 1916-18 елларда Яңа бистәнең Әмирхания кызлар мәктәбендә беренче, икенче һәм өченче сыйныфларда мөгаллимәлек итте. Мәзкүр мәктәп мөдирәсенең вафаты сәбәпле, шул вакыйганы игълам вә тасдыйк итү мөдирәнең варисларыннан берсенә йөкләнәдер.

Бу хосуста шәһадәт бирәм.

Фатих Әмирхан 27/X-20».

Үзенең башына килгәнме, яки инде ире киңәш биргәнме, бервакыт Рабига остазбикә диннең элементар мәсьәләләрен яктырткан китапчык — кулланма язарга карар итә. Менә ул кечкенә китап безнең алдыбызда: «Нәҗат әльмөкәлләфин» (якынча: «Үсеп җиткәннәр өчен котылу»). Титул битендә мондый сүзләр укыла: «Ибтидаи мәктәпнең соңгы сыйныфлары өчен игътикадка даир мәсьәләләр. Бу рисалә берничә еллар кызлар мәктәбендә хифзан укытылып, файдасы тәҗрибә ителгәндән соң нәшер ителде. 2 нче, 3 нче, 4 нче сыйныфлар өчен.

Мөрәттибәсе: Р. Әмирхания.

Нашире: «Юл» китапханәсе.

Казанда «Үрнәк» матбагасы, 1910».

«...Мин 188* ел гыйнварының таңында тудым. Туган вакытымның ел башы һәм ел башының да таң вакыты булуын хәтергә төшерсәләр, укучы әфәнделәр үзләре дә минем буш кеше түгел икәнемә ышанырлар дип уйлыйм».

Ф. Әмирханның «Минем тәрҗемәи хәлем» исемле юмористик автобиографиясе әнә шулай башланып китә. Билгеле инде, ник мин бу фани дөньяга килдем дип уйлап тормаган, ата-баба эшләгәнне эшләргә кирәк дип, кычкырып елый башлаган. Аны бу дөньяга кабул итүчеләрнең моңа бер дә исләре китмәгән, «Ир бала, ир бала!» — дип шатланышканнар да, ашыкмый-кабаланмый гына, чүпрәккә төреп авызына ими каптырганнар. Шуннан малай шып була: тамак тук, өс бөтен, тагын ни кирәк?

Тудыңмы, үсәргә тиешсең. Безнең кечкенә Фатих та үсә башлый: теш чыгаруы кирәк, тәпи йөреп китүме, сөйләшә башлауы кирәк — һәркайсы җирле җиренчә. Әмма бу үсүнең, язучы үзе әйткәнчә, күңелсез яклары да чыга башлый: «...аякларымны кычыткан чагуы кирәк, җиргә түп итеп, кулымны авырттыруы кирәк, әнә карагы тотам дип йөри торгач, аннан бармагымны тешләтүме кирәк, берәр малайны үчекләгән өчен әни мәэмә итүме кирәк — һәммәсе бу фәкыйрегезнең башына килеп үттеләр». Һәм гаҗәп тә түгел: әнисенең әйтүенә караганда, ул бик тә тынгысыз, тиктормас, шаян бала булган. Сыер саварга чыкканда да Рабига абыстай аны чыгырга утыртып, бәйләп куя икән.

Бераз үсә төшкәч, безнең Фатих казлар белән дә конфликтка керә башлаган. «...без тора торган җирнең зыярәте буендагы үләнлектә бәбкәләрен саклап йөри торган казлар ни өчендер мине әүвәл танышуымда ук дошман күрә башладылар. Алар миңа кайда гына туры килсәләр дә «пх-х-х-х...» дигән бер төрле ямьсез вә минем өчен тарихи куркыныч тавыш чыгарып, куып йөри торган яман гадәткә өйрәнделәр. Кайда гына бәбкәле бер каз очрамасын, ул мотлак, муенын сузып, минем артымнан кууны үзенең вазифаи казыясыннан [1] хисаплый иде».

Монда бер шик туа: бу конфликт күбрәк малайның үзеннән чыкмадымы икән? Әнә бит ул апасы Сәгадәт белән энесе Ибраһимны елатканчы үчекләргә һәм иптәш малайларының ачуын китерергә дә бик оста булган. Ата казлар белән булган конфликтка кайтсак — әгәр бусы хыял җимеше булмаса — аны үз файдасына хәл итүгә дә ул хәйлә тапкан. Каз муенын сузып килә башладымы, кечкенә генә матур ак этен өстерә икән дә, алар сугыша торганда, үзе тая икән. Балигъ булып кулына каләм алгач, Фатихның чалмалы һәм чалмасыз казларны котыртырга бик маһир булганын искә төшерсәк, әлеге ихтималның чынлыктан ерак тормаганына ышанырбыз.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсенә килүенең очраклы хәл булмаганлыгын күрсәтеп һәм юмор катыштырып, әдип тагын болай дип яза: «...мин 5-6 яшь-

[1] Вазифа казыя — казлык вазифасы, бурычы.

ләргә җиткәндә инде таш тәти (чынаяк ватыклары) мөхибләреннән[1] идем. Хәтта бик озак заман һәм тырышлык сарыф итеп, мөкәммәл бер таш тәтиләр коллекциясен дә җыярга муаффәкъ булган идем...» Юморын юмор, әмма безнең буын да әле чынаяк ватыклары белән әвәрә була иде. Кемнәрнеңдер өй җылысын сиздереп торган әнә шул зәңгәр, яшел, сары, кызыл, шәмәхә, ал бизәкләрдә ниндидер серле дөнья күреп, татлы хисләргә бирелә иде.

Язучы булачагын хәбәр итә торган эш-фигыльләренә килгәндә, алары китап белән бәйләнгән. Өч яшьлек Фатих бабасының китап читләрен диңгез дулкынына охшаш сызыклар язып тутыра башлый. Өйдә китап күп, каракаләм бар, үрнәк тә бар, ник ул гына язмасын? Ләкин бу эше ата-анага бик үк ошап җитмәгәнгә, китапларны аның буе җитмәс төшкә куя башлыйлар. Кечкенә мөхәррир моңа да аптырап калмый, җае чыккан саен һәрбер яссы нәрсәгә язгалый тора. Бармагын карага манып, әлеге дулкыннарын Ибраһимның битенә дә төшереп караган. Бусы инде бигрәк тә әнисенә ошамаган. Чөнки олы улының «иҗатын» кече улының битеннән тиргәнә-тиргәнә юып төшерергә туры килә.

Ләкин бу вакытларда әле бабасы һәм әтисе, мөхәррирлектән бигрәк, Фатихны мулла, хәзрәт булулары белән кызыктырганнар. Чалма-чапан киеп, озын таяк тотып, намазга барулары, намаздан кайтулары, юлда очраган агайларның кулларын күкрәккә куеп, «әссәләмәгаләйкем, хәзрәт» дип олылап калулары малайның хыялына аеруча нык тәэсир иткән. Әдип үзе дә моны раслый, «Мин мулла баласы булганга, бик кечкенәдән үк муллалык дәрәҗәсенең, пәйгамбәр вә сәхабәлектән кала, иң зур дәрәҗә икәнен бик яхшы төшенә идем».

Биш яшеннән безнең Фатих намазга йөри башлый. Тәрәвих вакытларында, тәрәзә төбендә йоклап китеп, сәҗдәгә киткән абзыйларның өсләренә дә егылып төшкәләгән. Соңыннан өстәлгән булмаса, биш яшьлек «мәчет карты» тапкыр җавапка осталыгын да күрсәткән. Бервакыт шулай мәчеткә килгән малайлар белән сөйләшә башлагач Вәли карт: «Намаз эчендә сөйләшергә ярамый, мәхдүм»,— дип кисәтә. Фатих аптырап калмаган, аңа да үз янындагы Сәгыйть карт белән сөйләшә-сөйләшә намаз укырга киңәш биргән.

Көннәрдән бер көнне кечкенә Фатихның башына шәп фикер килә: нигә үз яшьтәшләре арасында аңа мулла булып йөрмәскә? Ул бит сиңа Яңа Бистә малайларыннан бер малай гына түгел, карт хәзрәтнең оныгы, Зариф мулланың улы. Менә безнең Фатих, үз гәүдәсенә таман булган чалма-чапан таләп итә. Малайның теләге кызык тоелганмы, әллә инде үзенекен итмичә туктамаячагын белгәнгәме, олылар каршы килмиләр. Әтисенең иске бикасап казакиен сүтеп, чапан тегәләр, шундый ук иске чалмадан кисеп, кечкенә чалма булдыралар. Инде таяк кирәк. Урамда каз куа яисә атланып чаба торган таяк ярамый монда. Әнә бит бабасының таягы нинди! Мәсьәләне әнисенең эшкә ярамый торган зонтигы хәл итә. Фатих шуның сабын суырып чыгара да мәчет таягы итеп тота башлый.

Тиктормас, шук һәм тәтелдек малайның, алмаштырып куйгандай, кинәт җитдиләнеп китеп, таягын тукылдата-тукылдата намазга баруын, намаздан кайтуын күз алдына китерү кыен түгел. Ишегалдында яисә лапасларында яшьтәш малайларын сафка бастырып намаз укытканлыгына, апасын яки берәр иптәш кызын остазбикә ясап уйнаганлыгына да шикләнмәскә мөмкин.

Күп еллардан соң ул болай дип язды: «Мин шулай итеп намазга йөрим дә йөрим, ә мәхәлләнең сакаллы сабыйлары мине кечкенә клоун дип йөрисе урынга, «нәни мулла» дип йөриләр...» Бу сүзләрендә инде юмор һәм ирония генә түгел, бәлки оялу һәм үкенү тойгысы да ишетелә. Үкен-үкенмә, тик ул вакытта бүтәнчә була алмаган. Ата-ана шат, авыру карт хәзрәт тә канәгать: булыр моннан, җилле мулла чыгар. Тирә-күрше, дус-иш һәм мәхәлләнең карткорылары: «Әссаләмәгаләйкем, кечкенә хәзрәт»,— дип, күңелен үстереп торалар.

Өй дә мәчет, мәчет тә өй... Бистә малайлары белән бер дә уйнамаганмыни соң ул? Уйнаган, билгеле. Сазлыкларны да ерып йөргән, балык та сөзгән. Бакалтайга да чыккан. Так-каравыл, шар сугу, лапта кебек уеннардан да читтә калмаган, сугышкан да, үкереп кайткан чаклары да булган. Кем белә, бәлки әле Бистә урамында яисә болында итекче Мөхәммәтвәлинең асрарга алган малае Габдулланы да күргәндер. Ләкин күргән тәкъдирдә дә аралашып китмәгән: ул кем дә, Фатих кем! Фикердәш, көрәштәш һәм якын дуслар булып, бер аяктан атлап барасылары, билгеле инде, ул вакытта ике ятып бер төшләренә дә кермәгән.

Бу урында ассызыклап шуны әйтергә кирәк: архивта саклана торган

[1] Мөхиб — яратучы.

автобиографиясеннән күренгәнчә, Ф. Әмирхан бала чагында, бигрәк тә мәктәп яшенә кергәч, туйганчы уйный алмаган. Өйдәгеләр урамга чыгармаска, күздән бик үк ычкындырмаска тырышалар. Озаграк югалып торса, өйдә шау-шу куба, эзләргә чыгалар, әрли-әрли алып кайталар. Хикмәт бәла-казага юлыкмагае дип куркуда гына түгел. Хикмәт тагын Фатихның бистә малайларыннан бер малай булып үсүен теләмәүләрендә. Әлеге автобиография-сеннән күренгәнчә, ата-анасы аңа һәрвакыт тукып торган: мулла буласы кешегә үзенең булачак мәхәллә кешеләре белән уйнарга ярамый, килешми. Тыңламаса, куркытудан да кире тормаганнар: — Чыбык ашыйсың килмәсә, яхшылык белән тыел!

Алты яшь ярымда Фатих мәктәп бусагасын атлап керә. «Безнең хәлфә юан гына, ялкау гына бер мишәр иде,— дип яза Әмирхан «Тәрҗемәи хәл»ендә.— Ул миңа кәгазь өстенә ясалган таш тәтиләр шикелле нәрсәләрне күрсәтте дә, болар баш «ба», урта «ба» булалар, диде. Мин аның белән бәхәсләшеп тормадым, боларның таш тәти сурәтләре икәнен бик яхшы белсәм дә, урта «ба», әллә нәрсәләр дип ышанып йөргән кыяфәт күрсәтә торган булдым. Акрын-акрын хәлфә миңа, табагач сурәтләре күрсәтеп, кечкенәсен «һәмзә», зуррагын «гаен» дип йөрергә кушты. Башыңа төшкәч, бернәрсә эшләр хәлең юк: табагачларны «һәмзә» һәм «гаен» исемнәре белән йөртә башладым. Хәлфәмнең иң ахыргы ялганы — шикәр ваткыч сурәтен «ләм-әлиф» дип ялганлавы булды. Шул ялганга ышанган көннән башлап, мине язу таный торган бала дип йөртә башладылар».

Нәрсә бу, авылдан күчеп утырган фәкыйрь көнлекче баласы кебек, шыр надан хәлдә мәктәпкә килдемени Фатих? Юк, һич юк! Хәлфәгә барганда инде малайның, хәрефләрне ятлап бетереп, сүзгә әверелдерә башлаганы турында кистереп әйтергә була.

Акыл керә төшкәч, аңардан китапларны, билгеле, яшерми башлаганнар. Элек китап тышындагы, аннары эчендәге кайсы таякка, кайсы табагачка, кайсы кайчыга охшаган серле билгеләргә, әлбәттә, ул игътибар иткән, нәрсә икәнлекләрен белергә теләгән. Апасының укый башлавы да аның күз алдында. Әнисе кыз балаларга дәрес биргәндә Фатихның кереп, еш кына тыңлап утырганлыгына да шикләнмәскә мөмкин. Кыскасы, кечкенә Фатихка хәреф танытырлык кешеләргә кытлык юк.

Соң ник шулай язган Фатих Әмирхан? Беренчедән, бу, әйткәнебезчә, юмористик автобиография. Икенчедән, әдип анда гомумиләштерә, иске мәктәпләрдә язу таныту, укытуның гомуми хәлен, типик күренешен җанландырырга омтыла. Бәлки әле хәрефләрне белгән килеш укый башлаган булуы үзе үк Ф. Әмирханны мәктәптәге беренче адымнарын әнә шулай мәзәкләштереп язуга этәргәндер. Хәлфә, бүтән шәкертләр белән беррәттән, Фатихка да бусы, урак төслесе «йа» ди-ди өйрәтергә керешкәндер. Малай «мин аларны беләм» дип әйтер иде, ярамый. Хәлфә кеше бит. Үзе зур, үзе юан. Иләшә төшкәч, шуклыкка бирелүе, «бу нәрсә?» дигән сорауга, белмәмешкә сабышып «табагач», «шикәр ваткыч» дип әйтеп ташлавы да мөмкин.

Хәер, нигә юрап маташырга? Архивтагы автобиографиясендә әдип үзе үк, мәктәптә үткәргән ике елын күздә тотып, болай дип яза: «Монда мин шактый зур уңышларга ирештем».

Фатих мәхдүмнең хәзерлеген күреп алгач, хәлфәсе аны «сикертебрәк» укыта башлаган дип уйларга туры килә. Хикмәт шунда: кадим мәктәпләрдә сыйныф, ягъни класслар, булмаган. Балаларның белем дәрәҗәләре нинди китап укулары белән билгеләнгән. Башта «Иман шарты» укытылган, аның артыннан «Һәфтияк», төрки китаплар һ. б. тезелеп киткән. Бер укучы «Иман шарты»н җиңә алмый азапланганда, икенчесе «Һәфтияк»кә керергә, аны узып, төркине дә башларга мөмкин.

«Иман шарты»нда озак тукталмыйча, укуының беренче елында ук Фатих, «Һәфтияк»не ерып чыгып, төркигә кергән дип уйларга кирәк. Икенче елында да, әнә шулай «сикеребрәк» укып, бу мәктәп бирә алырлык гыйлемне зиһенендә сеңдереп бетергән булыр. Үз мәктәбендә ике ел укыткач, Зариф хәзрәтнең Фатихны, чагыштырмача яшь булса да, абруй казаныргa өлгергән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә күчерүе әнә шул турыда сөйли. Икесен бергә алып бару, алып кайту җайлырак булыр диптерме, кече улы Ибраһимны да ул «Мөхәммәдия»гә бирергә карар иткән.

1893 елның январь аенда Хөсәен хәзрәт вафат була. Гаиләдәге бу беренче үлем, бигрәк тә шундый олы шәхеснең вафаты Фатихка ничек тәэсир иткәндер, без моны белмибез. Баба белән онык арасында нинди мөнәсәбәт яшәгәнлеге хакында да мәгълүмат юк. Тарих һәм дин фәлсәфәсенә чумган кырыс рак

табигатьле Хөсәен хәзрәт төчеләнмәсә дә, үт-үт итеп кенә тормаса да, оныгына битараф булмаган дип уйларга кирәк. Беренче улының беренче ир баласы бит ул. Аның эшен дәвам иттерергә тиешле бала. Бабасыннан бераз өрексә дә, Фатих та аны яраткан булыр.

Үлеп киткәч, бабаның кадере тагын да арта, сыны зурая, эреләнә бара, исеме Шиһаб Мәрҗани белән берлектә телгә алына башлый. Киләчәктә Фәтхулла хәзрәтләр йогынтысыннан арынуда күпмедер дәрәҗәдә Фатихка бабасы сурәте дә ярдәм иткән.

## Маяклар алышынганда

### I

Казан сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Галиев улы Галимҗан, Бохарада укып кайтканнан соң, 1881 елда Тихвинский урамындагы[1] 4 мәчет мәхәлләсенең приговоры нигезендә икенче мулла итеп куелган. Берникадәр заманча уйлый, яңача фикер йөртә торган кеше буларак, ул, күрәсең, Бохарадан ук үзенчә зур планнар корып кайткан. Туган җиренә аяк басу белән үк яшь мулла атасы акчасына мәдрәсә салдыру чарасына керешә һәм 1882 елда үз мәктәбендә балалар укыта башлый. Соңыннан «Мөхәммәдия» дигән исем астында дан казанган мәдрәсә әнә шулай калкып чыккан. Билгеле инде, Казанның «Фәтхулла хәзрәт»ләренә болар ошамый. Шулай бервакыт Мәрҗани өендә булган кечкенә мәҗлестә, кемнәрдер «ул солдат малае», фәлән-төгән дип, Галимҗан мулланы яратмый сөйли башлагач, Шиһаб хәзрәт кырт кисеп туктаткан: «Ул солдат малае булса да, Казанның һәммә имамнарыннан өстен. Аңарга тел озайтмагыз».

Ел артыннан ел уза, шәкертләр арта, мәдрәсә киңәя, укыту-тәрбия эшләре камилләшә бара. Хәзрәтнең үзенә зур укымышлы, олуг остаз дигән мәгънәне аңлата торган «дамелля» сүзе аерылмаслык булып ябыша. Шулай дип әйттеңме, исемен-нием кушып торасы юк. Баруди дигән яңгыравыклы псевдоним — фамилиясенә килгәндә, бусы — нәсел-нәсәбенең Пороховой бистәдә тереклек иткәненә ишарә. Баруд — гарәпчә дары дигән сүз.

Казан мөдәррисләреннән беренче буларак, Галимҗан Баруди 1891 елда укырга-язарга өйрәтүдә «ысул җәдит» дип йөртелгән яңа метод кертә һәм «Савадхан» исемле дәреслек-кулланма язып бастыра. Уй-фикер һәм эш-гамәлендә яңарак юл тоту өстенә, кадим-җәдит көрәшенең кызган вакытында бу адымны ясавы Барудиның хәлен җиңеләйтмәгән, әлбәттә. Вәхшиләр арасына килеп чыгып, шулардан очкан уклар астында, йорт коручы кеше хәлендә калган дип әйтсәк, шаять хата булмас.

Шактый еллардан соң булган бер вакыйга да әнә шулай уйларга мөмкинлек бирә.

1897 елда агач мәдрәсәсе янып көлгә әйләнгәч, Галимҗан хәзрәт, байлардан акча җыеп, яңа зур мәдрәсә салу чарасына керешә. 1901 елның көзендә, ниһаять, өч катлы мәһабәт таш бина калкып чыга һәм мәдрәсәне ачу вакыйгасы тантаналы рәвештә билгеләп үтелә. Ф. Әмирханның шәкертлек дәфтәренә теркәлгән язмадан күренгәнчә, ул түбәндәгечә узган. Мәҗлескә Казанның зур байлары, хәзрәтләре, хәлфә-укытучылары чакырылган. Мәдрәсә каршындагы рус классларының берсендә учитель булып торучы Һади Максуди котлау өчен сүз ала һәм, кадимчеләргә төрттереп, мондый сүзләр әйтә:

— Алла мөбарәк итсен, тәкъсир. Сез милләткә олуг хезмәт кылдыгыз, күп мәшәкать чиктегез. Без Сезгә булышлык күстәрүдән бигрәк, төрле сүзләр ирештердек, сүктек, хәсәдлек[2] иттек, хурладык. Әмма безнең бу эшләребез Сезне туктатмады, Сезгә тырышлык һәм ныклык кына өстәде.

Ташның кем бакчасына төшкәнен шундук абайлап алган Шакир, Сабир, Йосыф һәм Хисам муллалар тавыш куптаралар:

— Туктат нотыгыңны, зиндикъ[3], сөйләмә! Без хәсәд тә итмәдек, сүкмәдек тә!

---

[1] Хәзер Тукай урамы.
[2] Хәсәдлек — көнчелек.
[3] Зиндикъ — динсез.

Тантана чәй мәҗлесе белән тәмам була. Әлеге дүрт хәзрәт, аштан олы булып булмый дигән мәкальне дә онытып, ташлап чыгып киткәннәр.

Шунысы кызык, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең архитектур ансамбле үзе үк ул заманның иске-яңа тартышын гәүдәләндерә.

Хәзерге Тукай урамындагы 34 йортның капкасыннан атлап кергәч тә, уң якка карасагыз, бер генә катлы, кечкенә таш өй күрерсез. Заманында ул югарыда телгә алынган Йосыф ахун Сәгыйтов мәктәбе булган. Шушы өйгә терәтеп салынган (соңыннан кушылып ук киткән) өч катлы зур, мәһабәт һәм зиннәтле бинага игътибар итегез. Бусы «Мөхәммәдия»нең 1901 елда тантаналы төстә ачылган корпусы. Ансамбльнең үзәге булса да, капкадан керми торып, аны юньләп күрә дә алмыйсың.

Эш болай булган икән. Яңа корпусны планлаштырганда Баруди, фасадын урамга чыгарып салу нияте белән, Йосыф хәзрәткә мондый тәкъдим ясаган: мәктәбеңне, тәкъсир, әйдә сүтеп ташлыйк. Яңа бинадан үзең теләгән кадәр мәйдан алып, үзең теләгәнчә дәрес әйтерсең. Ахун хәзрәт башта риза була. Ләкин яраннары киңәшен тыңлаптырмы, соңра кирели. Менә ни өчен «Мөхәммәдия», урамны бизәп тору урынына, эчтә посып калган.

Без киләчәктә күрербез, Йосыф ахун Баруди тормышында гына түгел, бәлки Ф. Әмирхан тормышында да үзенчәлекле урын тоткан. Монда исә Фәтхулла хәзрәт прототибының нәкъ менә шушы Йосыф ахун булганлыгын әйтү белән генә чикләник.

Кара яссылык өстендә соры тап та якты булып күренгән шикелле, Галимҗан Баруди — төрле кыяфәттәге «Фәтхулла хәзрәт»ләр фонында, һичшиксез, прогрессив шәхес. Әмма XIX гасыр ахырының иң алдынгы иҗтимагый фикереннән ул беркадәр уңдарак торган. Сәбәпләре, билгеле, күп. Бохарада калыпланган белеме, караш һәм гореф-гадәтләре, уртагасырчылыкка кендекләре белән береккән дин әһелләре йогынтысында яшәүче мәхәллә кешеләренең йөз дүндерү ихтималлары, хөкүмәт чиновниклары һәм охранканың мәдрәсәне, мәдрәсә башлыгының һәр адымын күзәтеп торуы. Байлар хакын хаклау мәҗбүрияте үзе генә дә ни тора. Мәдрәсәнең бар чыгымы шулар өстендә бит. Чыгым исә аз түгел. Яңа гасыр башында инде аның азмы-күпме вазифа ала торган унбишләп хәлфәсе, ярыйсы гына җиһазландырылган тулай торагы, кухнясы, шифаханәсе, врачы, төрле мастерскойлары, сад-бакчасы, ишегалдында хәтта катогы булган. Моңа тагын читтән килгән фәкыйрь шәкертләрнең тулай торак һәм укыган өчен бер тиен түләмәгәнлекләрен өстик.

Әнә шулар барысы бергә Барудины, хәттыйн ашмыйча, уртарак юл сайларга, үлчәү тәлинкәләрен чәүмәлтмичә, тигезрәк тотар өчен дипломат булырга мәҗбүр иткән.

Ысулы җәдитне кертүе заман өчен, әлбәттә, кыю адым. Әмма бу башлангыч сыйныфларга гына карый. Рөшдия, игъдадия һәм галия бүлекләрендә исә, аз-маз яңарту һәм сипләүләрне искә алмаганда, дәресләрнең эчтәлеге дә, укыту ысуллары да борынгыча кала килгән.

Дамелляның Троицк ишаны Зәйнулла Рәсүлигә кул биргәнлеге, ә соңрак үзенең дә, ишанлыкка дәгъва итеп, шәкертләреннән мөрит җыя башлаганлыгы билгеле. Кем белә, бәлки бусы да дипломатик максат белән эшләнгәндер. Ләкин моның белән ул Казанның күпчелек байлары һәм мөселманнары күзендә отса да, яңара башлаган яшьләр күзендә нык оттырган.

...1895 елның көзендә Зариф мулланың ике улы — Фатих һәм Ибраһим — унөч яшен генә тутырган шушы мәдрәсәдә укый башлыйлар.

**Шул вакытларда «Мөхәммәдия» шәкерте булган Миргазиз Укмасый югарыда телгә алынган истәлегендә ике мәхдүмнең мәдрәсәгә килү-китүләрен болайрак сурәтли.**

Кышкы иртә. Нечкә тимер табанлы нәфис чанага җигелгән кара ат мәдрәсә ишек төбенә, кар туздырып, килеп туктый. Көмеш тәңкәләр тезелгән эшлия, җиңел күн камыт, тасма дилбегә, нечкә тубылгы дуга... «Көмеш» тезелгән йөгәннең тезгене, икегә аерып, дуганың ике ягыннан тарттырып куелган.

Тулып кигән кучер чана башыннан карга сикерә дә, малайларның тезен каплаган йомшак тирене ычкындырып, төшәргә булыша. Шәһәрчә ыспай киенгән һәм кулларына яхшы сумка тоткан ике мәхдүм ашыкмыйча гына мәдрәсә ишегеннән кереп китәләр.

Көндезге сәгать ике. Әлеге кара ат тагын мәдрәсәнең баскыч төбенә килеп туктый. Кучерны беркадәр көттереп, мәхдүмнәр ишектән килеп чыгалар, бик артык кабаланмый гына, матур чанага менеп утыралар. Кучер тирене иплап кенә тезләренә яба, әләктерә дә чана башына менеп кунаклый.

Тасма дилбегәне бер чиертүе була, кара ат, ыргылып, капкадан чыгып китә.
Мәхдүмнәрнең китап-дәфтәр, карандаш-каләм һәм бүтән әсбаплары да җиту икән. Ашаганнары да ләвеш тә сумса.

Авылдан килгән фәкыйрь шәкерткә, бәлки Зариф хәзрәт мәхдүмнәренең казы күркә булып күренгәндер, ярты гасырга якын вакытның зәңгәр томаны аша карагач исә, дөя коршы булып үскәндер. Хатирәнең 1940 елда, Фатих Әмирхан либераль буржуа язучысы итеп саналганда, язылган булуын да истән чыгармыйк.

Ләкин, истәлекче күпмедер арттырган очракта да, әдип балачагында һәм мәктәп елларында матди кытлык күргән дип әйтә алмыйбыз.

Фатих укый башлаган елларда ук «Мөхәммәдия» дүрт баскычтан торган: дүрт сыйныфлы ибтидаия (башлангыч), дүрт сыйныфлы рөшдия (тулы булмаган урта), өч сыйныфлы игъдадия (урта) һәм галия (югары). Соңгысы башта вакыт ягыннан чикләнмәгән булса да, тора-бара өч еллык курс рәвешен алган.

Укыган фәннәреннән чыгып хөкем итсәк, Фатихны ибтидаиянең соңгы сыйныфына утыртканнар дигән фикергә килербез. Беренче хәлфәсе — Таһир Габделхәким улы Мәчкәрәви дигән казый булган. Озын буйлы, киң җилкәле, кара сакаллы, битенә кара сипкел төшкән бу кеше, гыйлеме белән аерылып тормаса да, тәрбия эшендә үрнәк булырлык икән. Вәкарь белән, ягъни борын аша тыңкышланып сөйли белә, юк кына гаеп өчен дә шәкертләрне, бөтен шартын китереп, чаж-чож суктырырга оста.

Зур мәдрәсәнең зур хәлфәсе шундый булырга тиеш дип белеп, безнең Фатих бик дәртләнеп укый. Таһир казыйның камчысы һәм ата каз кебек ысылдавы да, аңа бик үк кагылмаганга күрә, сүрелдерми. Сабагын белә, тәртибе яхшы. Өстәвенә, яшькә кечкенә булып, билгеле хәзрәтнең улы.

Зирәклек һәм тырышлык бушка китми: еллык шәһадәтнамәсендә, китабәттән (язудан) кала, барлык «фән»нәрдән дә — әгъла, ягъни «отлично». Бу фәннәр арасында гарәп сарыфы (морфология) дә бар.

Икенче елында, бүтән «фән»нәрдән тыш, нәху (синтаксис) һәм мантыйк башлавыннан чыгып, Фатихның рөшдигә күчкәнлеген чамаларга мөмкин. Еллык шәһадәтнамәсендә ике «тәхсин» (яхшы) нән бүтән билгеләре — тагын «әгъла». Төп хәлфәсе шул ук Таһир казый. Әмма аңа Җәгъфәр Сираҗетдин улы дигән хәлфә өстәлгән.

Өченче уку елында Фатих аеруча дәртләнеп укыган булса кирәк. Барлык «фән»нәрдән дә — әгъла. Беренче бүләккә лаек булып, «Могаллакате сәбгы» исемле китап алган. Бу ел, Таһир казыйдан котылып, риясыз, нифаксыз [1] дәрвиш табигатьле һәм йомшак холыклы Җәгъфәр хәлфәнең шәкерте булып киткән.

Дүртенче елында шул ук хәл: тоташ — «әгъла», бүләк. «Фән»нәре, укыган китаплары да инде ни житте генә түгел. Хәдис, викая, кодури. Фатих «Исагуҗи» башлавы белән аеруча горурланган булса кирәк. Соңыннан ирония белән ул болай дип язды: «Фәтхулла хәзрәтнең бу китапны бик тырышып укыганлыгын ишетә идем, мин дә тырыштым һәм, шул тырышлыгым аркасында бер ай укыгач та, үземнең «хайваны натыйк» [2] икәнлегемне белдем». Төп чыганагы Платон һәм Аристотель әсәрләренә кайтып кала торган бик борынгы бу мантыйк китабын Фәтхулла хәзрәт кенә түгел, Фатихның бабасы һәм әтисе дә тырышып «кимергәннәр» иде. «Исагуҗи»ны ашап чыккач, безнең Фатих та моназыйр, ягъни оста бәхәсче булып китә.

Укучы бәлки игътибар иткәндер, Фатихның «Мөхәммәдия»дә моңарчы укыганнары — дин дә мантыйк. Физика, химия, геометрия кебек фәннәрне әйтеп тә тормастан, тарих, әдәбият, география кебекләрнең исеме дә юк. Игъдадиядә дә, галиядә дә шулай булачак. Яңа гасыр керү белән үк мәдрәсәдә ислах, ягъни реформа өчен көрәшнең кызып китүе очраклы хәл түгел.

Хәзергә әле безнең Фатих шулай булырга тиеш, шулай гына була ала, дигән ышаныч белән укый бирә. Бер дә файда алмаган, вакытын бөтенләй бушка уздырган дисәк, хакыйкатьтән шактый читләшкән булыр идек. Гарәп телен тирәнтен үзләштерүе үзе генә дә ни тора! Фатих бу телне чынлап та яратып һәм теләп укыган. Зариф хәзрәт һәм Рабига остазбикә дә тел белүне зур дәрәҗә санаганнар һәм, балаларын тизрәк өйрәтү максаты белән, өйдә гарәпчә сөйләшүне кертергә тырышканнар. Бервакыт шулай Сәгадәт, юынган чагында, 9 яшьлек энесенә «вәһәпте ләкә» дип, калфагын тоттырган.

[1] Нифак — икейөзлелек.
[2] Хайваны натыйк — сөйләшүче хайван.

Аннары кире алмакчы була, Фатих бирми.

— Бүләкне кире алмыйлар,— ди икән.

— Мин сиңа тотып торырга гына бирдем ич.

Шунда малай «вәһәпте ләкә» — «бүләк итәм» дигән сүз дип ярып салган һәм апасы «тотып кына торырга бирәм» дигән җөмләне гарәпчә әйтергә өйрәнгәнгә кадәр калфакны кайтармаган.

«Мөхәммәдия»дә укуының икенче елында ук Таһир хәлфәнең ниндидер гарәпчә китапны укытып чыгаруы да, Фатихның гарәбияттә шактый иркен йөзә башлаганлыгы турында сөйли.

Ел артыннан ел уза, «фән» артыннан «фән» артта кала, китап артыннан китап зиһенгә кереп урнаша. Рөшдине сикертебрәк узган кебек, Фатих игъдадида да озак утырмый. 1901 елда инде 15 яшьлек егет кисәген без галиянең әүвәлге сыйныф шәкерте, хәзергечә әйтсәк, беренче курс студенты итеп күрәбез.

Ундүрт-унбиш яшьләренә кадәр Фатих укудан бүтәнне белмәгән, китапка гына чумып яшәгән кебек күренсә дә, алай ук булмаган, билгеле. Ул да бала бит. Дөрес, Фәтхулла хәзрәт дәрәҗәсенә ирешүгә, хәтта аңардан да уздырып җибәрүгә дәртсенгән малайга уйнар өчен вакыт күп калмаган. Җитмәсә, югарыда әйтелгәнчә, ата-анасы Фатихны бистә малайларына катышудан, алар белән уйнаудан тыярга тырышкан. «Мөхәммәдия»дә үткәргән вакытның баштагы ике елында, килеп-китеп укыганлыгы сәбәпле, мәдрәсә шәкертләре белән дә аралашмаган, дип әйтерлек.

Фатихның укудан калган вакыты шулай да ничек узган соң?

Үз яшьтәшләренә катышкан ул, уйнаган да. Ләкин башлыча баерак гаилә балалары, эти-әнисе йөрешкән мулла мәхдүмнәре белән.

Әмирхановлардагы күңел ачуның бер төре — язларын, үз атларына утырып, боз киткәнне карау өчен, Усиягә чыгу. Өелешеп аккан бозларны тамаша иткәч, алар хәрчәүнәгә кереп, ләрәмәчләп, әфлисунлап чәй эчәләр. Җәйләрен, самавырлар белән кая булса да, урман-ялангa пикникка чыгалар.

Һәр җәй саен дип әйтерлек Зариф хәзрәт гаиләсен пароходка утыртып Чистайга энесе Нәҗип муллага кунакка алып бара. Мөхәммәтнәҗип Әмирханов — ул вакытларда мәхәллә имамы, шактый гына зур мәдрәсәнең башлыгы, мөдәррис. Хөкүмәт чиновникларына байтак борчу, мәшәкать тудырган кеше.

Халык училищелары инспекторы Гайев белән Нәҗип мулла тартышы бер ел буе барган. Инспектор чакырта, хәзрәт килми. Чиновник үзе мәдрәсәгә барырга мәҗбүр. Русча белмәгәнгә салышып, Нәҗип мулла тылмач ярдәмендә сөйләшә. Ә дә юк, я дә юк. Шулай да килешкән булып, тегене озатып җибәрә. Эштә исә үзгәреш күренми. Тагын шикаять, тагын Казаннан — усал кәгазь. Аны муллага тапшырырга, аңлатма таләп итәргә кирәк. Бер бара инспектор, ике бара, тота гына алмый бит кирәк кешесен. Аптырагач, остазына тапшырырга кушып һәм кулыннан подписка алып, кәгазьне бер шәкерткә тапшыра. Әмма җавап тагын юк. Кат-кат исенә төшерү дә файда бирми... Ниһаять, көннәрдән бер көнне Нәҗип мулланың шәкерте төнге сәгать унберд, Гайевны уятып, җавап кәгазен китереп бирә.

Шунысы да мәгълүм булсын: Нәҗип мулла заманында исеме шактый киң таралган Закир ишан Камаловның кияве һәм варисы. Ишан инде үзе вафат. Кече хатыныннан бер ир бала һәм тугыз кыз дөньяга килгән. Күбесе үсеп җиткән, берничәсе инде кияүдә. Фатих белән яшьтәшләре һәм кечерәкләре дә бар.

Зариф хәзрәт гаиләсенең Чистайда вакыт үткәрүе дә бер рәвешлерәк булган. Кунакка бару, кунак чакыру, ашамлык, савыт-саба, самавыр төяп, табигатькә чыгу. Нәҗип хәзрәтнең балалары әле кечкенә булганга күрә, Фатих белән Ибраһимның вакыты күбрәк олылар арасында үткән. Тора-бара Фатих, үзеннән күп олы булса да, Закир ишан улы Ибраһим белән аралаша башлый. Сеңелләре белән аралашуы хәзергә әле үчекләшүдән ары китми. Хәер, Шәмсениса исемлесенә Фатихның ул чакта ук аерыбрак каравы ихтимал. Әмма шушы кызга гашыйк булачагы, татлы да, газаплы да хисләр кичерәчәге, язмыш аларны аергач, бу кызны гомере буе оныта алмаячагы ул вакытта әле аның башына да кереп чыкмаган...

Ике елдан соң мәдрәсәдә торып укый башлавына да карамастан, Фатих, күпләгән җан дуслары табып, шунда кереп эрегән дип әйтеп булмый. Атнакич җиттеме, әлеге дә баягы, атларына утырып өенә кайтып китә. Ана кеше улларын һәрвакыт юксынгандырмы, атна арасында да, теге яки бу сылтау табып, мәхдүмнәрне килеп алалар. Үсә төшкәч тә, Фатихның сердәш дус-

лары бик артмаган. Фикер ягыннан күпкә узып киткәнгә, яшьтәшләре, бигрәк тә авылдан килгән шәкертләр белән ул кызык таба алмый. Үзеннән олыракларга тартылса да, баш иеп бармый, бәйсезлеген сакларга тырыша. Аннары узышу, җиңешү дигән нәрсә дә бар бит. Ниһаять, Фатихның гаять күзәтүчән, ironияле икәнен һәм ничектер әйләндереп китереп, оста көлә белүен дә онытмыйк.

Ләкин бу әле Фатих кырга чыгып үскән ялгыз агач булып яшәгән дигән сүз түгел. Аңа якынаерга, сердәш булырга теләүчеләргә кытлык юк. Күп белә, кыюлыгы бар, сүзгә оста, мәзәкчел. Үзе күреп, әтисе даирәсендә ишетеп яисә китаптан укып белгән нәрсәләрен хыял катыштырып сөйләп җибәрсә, шәкертләр авызларын ачып тыңлыйлар.

Ләкин Фатих әшнәлеккә дәгъва итүчеләрне ераграк тотарга, арада күпмедер бушлык калдырырга тырыша. Авторитетын танып, сүзсез буйсына, чәнечкеле сүзләргә җәберсенми торган бер-ике шәкерткә генә Фатихның дусты дигән исем казанырга насыйп булган. Шуларның берсе — Ризван Ибраһимов-Алуши. Буе озынлыгын искә алмаганда, бу шәкерт бер ягы белән дә аерылып тормаган. Соңыннан да гадәти укытучы булудан ерак китми. Шушы егет күп еллар буе Әмирханның ахирәт дусты булып калачак, араларында туктаусыз хат йөреп торачак, ара ераклыгына карамастан, күрешүләр дә булачак. (Хәер, үзенә тиңнәргә рәсми мөнәсәбәттә калган хәлдә, даһиның гадәти кешеләрне дус итүе — тарихта очрый торган нәрсә).

Бу урында Әмирхановлар гаиләсендә булып үткән бер истәлекле вакыйганы телгә алып китми ярамас. 1899 елдамы, бер ел соңракмы, Сәгадәт туташны Бишбалта мулласы Габдулла Әмирхановка кияүгә бирәләр. 13-14 яшьлек Фатих, билгеле инде, туй вакыйгаларының үзәгендә булган. Замандашының язуына караганда, аңа хәтта җаваплы вазифа тапшырганнар. Хәзрәтләр һәм могтәбәр кунаклар утырган зур табын бүлмәсенә бер вакыт ыспай киенгән яшь шәкерт Фатих килеп керә. Кулында — көмеш поднос, поднос өстендә — ширбәтле ике касә. Тартынмый-нитми, кыю атлап түргә уза да касәләрне ике хәзрәткә тәкъдим итә. Алар, ширбәттән авыз итеп, күршеләренә бирәләр. Касәләр табын тирәли әйләнеп чыкканнан соң, көмеш подноска алтын, көмеш һәм кәгазь акчалар ява башлый.

...Әнә шул гыйлеме, шул фикер-карашлары һәм гадәт-холкы белән безнең Фатих, XIX гасырны төгәлләп, яңа гасырга аяк баса. Коръәнгә, аның тәфсирләренә, хәдискә тирән үтеп керүе, ислам диненең тарихын һәм фәлсәфәсен үзләштерүе шулай ук зарарга гына булды дип әйтә алмыйбыз. Безнең Фатих татар дөньясындагы искелеккә, туңлыкка, схоластика һәм догмаларга каршы баш күтәрәчәк, тора-бара яңалык өчен көрәшүче яшь көчләрнең җитәкчесенә әвереләчәк. Моның өчен исә, дошман кулындагы коралның хасиятен яхшы белү бик тә мөһим.

Әмма иң әүвәл Фатихның үзе изге санап йөргән нәрсәләргә бүтән күзлектән каравы, акны карадан, караны актан аера башлавы, фәнчә әйтсәк, дөньяга карашының үзгәрүе кирәк иде. Бусы да үзен озак көттермәде.

## 2

Бер гасырның төгәлләнеп килүе, яңа гасырның ишек шакуы гына түгел иде бу еллар. Гасыр ахырында Россиядә азатлык хәрәкәтенең яңа, пролетар этабы башланды. Сан һәм сыйфат ягыннан гаять үскән эшчеләр сыйныфы самодержавие һәм капитализмга каршы көрәшнең авангардына әверелде. Җирсезлек, салымнарның күплеге һәм капитализмның авылга да үтеп керүе нәтиҗәсендә бөлгенлеккә төшә барган крестьяннар да тавышларын ишеттерә башладылар. Бүтән демократик катлаулар, шул исәптән, укучы яшьләр дә хәрәкәткә килде.

Революциянең якынлашып килүен сиздерә торган галәмәтләр иде болар. Казан да читтә калмады. 1898 елда Казан эшчеләре әүвәл мәртәбә 1 Майны бәйрәм итәләр. 1901 елда революцион эшчеләрнең һәм студентларның беренче политик демонстрациясе булып уза.

Давыл күтәреләсен хәбәр иткән җилләр татар тормышын да хәрәкәткә китерә. Татар эшчеләре, рус иптәшләренә ияреп, кайберләре исә оештыручылар сыйфатында, көрәшкә кушылып китәләр. Учительская школа укучылары арасында марксизм идеяләре белән кызыксынучылар килеп чыга.

Казан мәдрәсәләренең урта гасыр ташыннан салынган калын диварлары

да инде көрәш авазларының, азатлык фикерләренең үтеп керүенә тоткарлык итә алмый башлый.

Яңалыкка аеруча сизгер мәдрәсә, әлбәттә, «Мөхәммәдия» иде. Яшь Әмирханны Фәтхулла хәзрәт белән арасын өзүгә китергән сәбәпләрне, барыннан да элек, әнә шуннан, мәдрәсәнең үз эченнән эзләргә кирәк. Фатихка кадәр дә анда фикер, туң хәлендә калмыйча, азмы-күпме хәрәкәт иткән. Аек карашлы хәлфәләр һәм, йокыдан уянып, як-ягына карый, укыган сабагыннан канәгатьләнми, татар дөньясының кимчелекләрен күрә башлаган шәкертләр килеп чыккан. Түгәрәк сыман нәрсә оештырып, чыш-пыш итеп сөйләшү, фикер алышулар башланган, кулъязма матбугат кебек нәрсә барлыкка килгән. «Мөхәммәдия»дә укыган чагында, мәсәлән, Хөсәен Ямашев «Тәраккый» исемле газетаны чыгаручыларның берсе була. Галиәсгар Камал да бу газета эшенә якыннан катнашкан. Галиәсгар һәм Хөсәен белән Фатих аралашканмы, юкмы, без белмибез. Үзеннән өч-дүрт яшькә олы Борһан Шәраф белән якын мөнәсәбәткә кергәнлеге, аның йогынтысында күп нәрсәгә күзе ачылганлыгы билгеле («Шушы елларда мин Сәгъди әфәнде (хәзер «Вакыт» мөхәррирләреннән) белән дусландым. Ул әдәбият гарәбия мөхибләреннән[1] һәм мәдрәсәдәге схоластикага иң әүвәл каршы тора башлаган шәкертләрдән берсе иде»).

Күп еллардан соң, төгәл әйтсәк, 1908 елда Ф. Әмирхан болай дип язды: «...моннан ун ел элек мин, яңа язу танып җиткән бала, «Тәрҗеман» газетасының почтадан алынганыны дүрт күз белән көтеп, баштагы игъланнарыннан башлап, ахырдагы имзаларына кадәр укып чыгып, үзем йөри торган мәктәпнең тышындагы дөньядан бәгъзе эшләр белән белешләнә вә татар мәгыйшәтенең ноксаннары тугрысында бик гайре мөгайян һәйәттә[2] булса да, фикеремдә бер нәрсә калдыра алдым». («Яңа язу танып җиткән бала» дип язса да, Фатих ул вакытта инде рөшдидә укыган).

Әмирхановларның газетага мөнәсәбәтенә кагылышлы мондый риваять яши. Зариф хәзрәт газетаны улыннан укытырга ярата икән. Менә ул аштан соң диванга килеп мендәргә таяна да Фатихка эндәшә:

— Яле, улым, җәриданe укып җибәр әле.

Фатих гадәтенчә шуклыкка бирелә:

— Кай төшеннән укыйм?

— Башыннан укы.

— Нумира 14, мөхәррәм эль хәрам 27 сәнәи һиҗрия 1324...

— Алары кирәкми...

— Кайсысы кирәк соң, тәкъсир?

— Астанрак укы,— ди әтисе.

— Баш өсте, тәкъсир,— ди дә Фатих җитди кыяфәт белән берәр сәүдә фирмасының игъланын укырга керешә.

— Анысы да кирәкми!

— Ярый алайса.

Фатих, коръән укыгандагы кебек итеп, көйләп, сузып баш мәкаләне укырга тотына. Зариф хәзрәт көләргә дә, ачуланырга да белмичә, газетаны алып, үзе укырга керешә. Фатих газетаның бу санын, билгеле инде, башыннан ахырына кадәр укып чыккан, шуңа шуклыкка бирелә.

Төрле язмалар өчен тота торган дәфтәренә Фатих шәкерт түбәндәге сүзләрне теркәп куйган: «1901 сәнәнең 2 үктәбер яуме[3] чәһәршәнбедә остазымыз дамеллядан шәргы гакаид башладык». Ягъни ул, үзеннән дүрт-биш яшькә олы сыйныфташлары белән берлектә, дин фәлсәфәсен өйрәнә башлаган, гакаидханлык дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Бу фәнне өйрәнүдә ул вакыт төп кулланма булып «Гакаидел-Нәсифи» исемле китап хезмәт иткән. Төп өлешен XII гасырда яшәгән Нәсифи язган. Әмма бу китап Тәфтазани (XIV) тарафыннан язылган шәрехе белән атаклы «Галләмә», ягъни галимнәр галиме булып танылган Тәфтазани мөселман дөньясында шул кадәр дан казанган ки, аның һәр сүзе энҗе-мәрҗән урынына йөртелгән, һәр әйткәне иң соңгы хакыйкать саналган.

Ф. Әмирханның «Безнең хыялларда Мәрҗани күләгәсе» исемле мәкаләсеннән без түбәндәге юлларны укыйбыз: «Еллар үтте, мин, мәдрәсәдә укып, гакаидханлык дәрәҗәсенә ирештем. Кирәк «Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дәге

---

[1] Әдәбият гарәбия мөхибе — гарәп әдәбиятын сөюче.
[2] Гайре мөгайян һәйәт — бик анык булмаган рәвештә.
[3] Яум — көн.

барыш вә кирәк хәлфәләремнең бәгъзеләренең дәлаләте белән, мин Мәрҗанинең «Әлхикмәтел-балига»сын да моталага кыла[1] башладым».

Гакаид һәм шуннан соң «Әлхикмәтел-балига»... Җир йөзе, коймак сыман яссы һәм түгәрәк булып, бик зур үгезнең мөгезенә эленеп тора дип ышанган баланың учительдән «җир ул карбыз кебек түгәрәк һәм кояш тирәсендә әйләнеп йөри» дигән сүзләрне ишеткәч, гаҗәпләнүен йөз мәртәбә арттырсак һәм мәгънә ягын баетсак, Фатихның шул вакыттагы кичерешләрен беркадәр күз алдына китерә алырбыз.

Мәсьәлә аңлашылсын өчен, укучыдан гафу үтенеп, үткәнгә таба бер чигенеш ясап китәргә мәҗбүрмен.

Ислам диненең төп өйрәтмәләре, мәгълүм булганча, коръәнгә һәм хәдисләргә тупланган. Алланың барлыгы, берлеге, дөнья, аның яратылышы, ахыр заман, җәннәт, тәмуг һ. б. турындагы догмалар да шунда (бусы — игътикад), кешеләр арасындагы хокук мөнәсәсәбәтләре (бусы — фикъһы) һәм әхлак кагыйдәләре дә шунда. Барысы бергә буталган, бер-беренә керешкән, очы-очка ялганмый. Коръән һәм хәдисләр дөньяга килгәч, аларны системага салу, бер рәвешле итеп аңлау һәм аңлату ихтыяҗы туа. Озын-озын шәрехләр язылa, бөтен бер «фән» тармагы барлыкка килә. Коръән һәм хәдисләргә дөрес аңлатма бирү өстендә эшләүчеләрне мөҗтәһидләр (иҗтиһад итүчеләр, ягъни көч куючы, тырышучылар) дип йөрткәннәр.

Менә бер заман эш тәмам була, барысы да үз урынына утыртыла, какшамас канун һәм догмалар барлыкка килә. Мөселман кешегә баш ватасы калмый. Шул канун һәм догмаларга сүзсез ышанырга һәм шулар кушканны җиренә җиткерергә генә кирәк. Мөҗтәһидләр заманы узды, иҗтиһад монкарыйз (бетте, юкка чыкты), диләр.

Гасыр артыннан гасыр уза тора, мөдәррис һәм хәлфәләр әлеге мөҗтәһидләр, борынгы дин галимнәре әйткән сүзләрне, алар язган китапларны бердәнбер хакыйкать санап, шәкертләренә өйрәтәләр, соңгылары ятлый, йота бирәләр.

Менә XVIII гасыр килеп җитә, аны XIX йөз алыштыра. Зирәк акыллы аерым шәхесләр абайлап алалар: изге канун һәм догмалар заман рухына, тормыш таләпләренә туры килми икән ич. Бүтәнчә була да алмый: борынгы китапларда коръән һәм хәдисләргә феодализм таләпләрен ныгыту максатыннан чыгып аңлатма бирелгән. Хәзер исә ашын ашаган, яшен яшәгән бу җәмгыять җимерелеп бара, алмашка капитализм килә. Аерым акыл ияләре диннең төп чыганакларын кайтадан җентекләп өйрәнергә, борынгы изге китаплар белән чагыштырырга, догма һәм кануннарны тәнкыйть иләге аркылы үткәрергә керешәләр. Һәм ныклы нәтиҗәгә киләләр:

— Юк, иҗтиһад монкарыйз түгел!

Татарлардан бу фикерне беренче башлап мәйданга ыргыткан кеше Габденнасыйр Курсави дисәк, һәрьяктан нигезләп, ныклы дәлилләр белән ныгытып, дөньяга таратkан зат Шиһабетдин Мәрҗани була.

Әмирханнар гаиләсендә Мәрҗани, абруйлы шәхес буларак, һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән телгә алынган. Сабый чаклардан ук Фатих түбәндәге сүзләрне ишетеп үсә.

— Мәрҗани яхшы атлар җигә, мәһабәт туннар кия, кибаранә[2] кыяфәт тотарга ярата иде...

— Мәрҗани үз вакытының бик мәшһүр Кышкар дамелляларына, Күл буе мәдрәсәсе мөдәррисләренә бер дә әһәмият бирми, аларны наданга саный иде...

— Мәрҗани гавамнан бирәүгә дә тәлинкә тотмый гына түгел, бәлки алардан, хәтта зур байларыннан үзенә ихтирам таләп итә иде...

— Мәрҗани булган мәҗлесләрдә аның дошманнары ачыктан-ачык аңа һөҗүм итәргә җөрьәт итә алмыйлар иде...

Көннәрдән бер көнне әнисе Фатихка, беркемгә дә әйтмәү шарты белән, Мәрҗанинең рәсемен дә күрсәткән.

Фатихның хыялында акрынлап, буй җитмәс зур, олы хәзрәт сурәте җанлана, аның өчен маяк, идеал барлыкка килә.

— Их, шул Шиһап хәзрәт шикелле имам булырга!

Инде менә уналты яше белән бара торган безнең Фатих Мәрҗанинең «Әлхикмәтел-балига»сын укып чыкты. Тәфтазанинең шәрехенә язылган ха-

[1] Моталага кылу — уку.
[2] Кибаранә — олы, горур булып.

шия, ягъни аңлатмага аңлатма икән ул. Шиһаб хәзрәт анда «галләмә»не элеп алып селкеп сала, һәр сүзен көчле дәлилләр ярдәмендә юкка чыгара һәм нәтиҗәдә Тәфтазанины гади бер компилятор итеп калдыра. Яшь Әмирхан күзендә Мәрҗани хәзер бар имамнардан өстен имам гына түгел, бәлки олы язучы булып калка, үзе әйтмешли, дөньяның мәшһүр язучылары тезмәсенә килеп тоташа. Тәфтазани һәм башка борынгы авторитетлар бөтенләй кечерәеп калалар, моңарчы укыган һәм укып ята торган дин сабакларының кыйммәте бермә-бер кими.

Юмористик тәрҗемәи хәлендә Ф. Әмирхан болай ди: «Бу елларда мин гарәп вә төрек әдәбияты белән шөгыльләнә һәм һәрбер яңа чыккан татар китапларын укып чыга башладым. Горфи[1] дәресләрем булган «Гакаид» вә «Тәһзиб»ләрне Фәтхулла хәзрәт белән очрашканда сүгешә алырга җитәр кадәр генә укый идем».

Гарәп әдәбиятыннан кемнәрне укыгандыр — без белмибез. Борынгы поэзиясе белән куәтле булганга, шагыйрьләрен, аерым алганда, Мәгарриныукыган дип уйларга мөмкин. Шәкертлек дәфтәренә берничә гарәпчә шигырьне теркәп куюы да шул фикерне куәтли.

Төрек әдәбиятына килгәндә, гасыр ахырына таба татар яшьләре игътибарының шул якка юнәлүе гомуми күренеш иде. Мәгърифәтчелек хәрәкәтеннән үсеп чыккан татар әдәбиятының алга барышы, ныгуы өчен читтән ярдәм һәм үрнәк кирәк булды. Мәгърифәтчелек реализмы юнәлешендә беркадәр алданрак формалашкан һәм тел җәһәтеннән татарларга якын булган төрек әдәбияты нәкъ менә шул вазифаны үтәде. Н. Кәмалның «Зәвallы чужык» пьесасының Г. Камал тәрҗемәсендә «Кызганыч бала» исемендә дөньяга чыгуы, яисә Тукайның төрек әдәбияты белән кызыксынып китеп, башлангыч шигырьләрен күбесенчә шул телдә язуын гына искә төшерик. Төрек әдәбиятыннан кемнәргә күңел багланганын Фатих атап әйтми. Әмма 1902—03 елларда язган хатларының һәм әлеге дәфтәрендәге язмаларның төрекчәгә якын телдә язылганлыгын төрек әдәбияты тәэсире итеп карарга кирәк.

Татар әдәбиятыннан кемнәрне һәм нинди әсәрләрне укыганлыгын чамаларга мөмкин.

Барыннан да элек, билгеле инде, Каюм Насыйри. Еш кына «Урыс Каюм» дигән кушамат белән йөртелгән бу галим турында да Фатих яшьтән үк ишетеп үсә. «Мөхәммәдия»дән ике генә адымда яшәгән Насыйриның үзен күргәләвенә, хәтта таныш булуына шикләнмәскә мөмкин.

Шушы елларда булса кирәк, Фатих базарда К. Насыйриның «Ләһҗәи татари» исемле аңлатмалы сүзлеген сатып алган. Хөҗрәсендә бик бирелеп укып утырганда, шәрикләреннән берсе — озын буйлы, таза гәүдәле, гаять тәкъвә мишәр егете килеп керә. Нәрсә укыганы белән кызыксынып, китапны алып карый. Һәм күзе «йомрык» дигән сүзгә төшә. Аңлатмасын укыгач, ул, авызын чалшайтып һәм зәһәрләндереп, зур йодрыгын Фатихның борынына тери дә болай дип куя:

— Аны китаптан укеп беләсе юк. Вата күреп кал.

Фатихның көндәлек дәфтәрендә мондый юллар бар: «Һиҗри белән («милади» сүзе урынына ялгыш язган — И. Н.) 1902 елның 21 августында ислам галимнәреннән милләт хадиме Габделбәдыйг мулла улы (галимнең атасы — Габделнасыйр — И. Н.) эль-Насыйри вафат булды. Халык милләткә хезмәт итүчеләрнең кадерен белмәгән бер заманда хезмәт иткән бу зат бик күп китап иясе булса да, язганнарының кадере соңгы заманнарда гына беленә башлады». Унҗиде яшьтә мондый дөрес фикерләрне язу өчен, билгеле инде, К. Насыйри иҗаты белән танышлык кирәк.

Олы буын мәгърифәтчеләре эшчәнлекләрен тәгәлләргә өлгермәделәр, яңа буын җитеште. Күбесе әдиплек каләме тотып мәйданга атылды. Менә Риза Фәхретдинов һәм аның «Сәлимә» белән «Әсма»сы. Менә Ф. Кәрими һәм «Җиһангир мәхдүм», «Салих бабай», «Шәкерт һәм студент» хикәяләре. Менә «Җәһаләт, яхуд Галиәкбәр агай» һәм «Яфрак асты, яки Мәкәрҗә ярминкәсе» повестьлары авторы Ш. Мөхәммәдев. Менә Г. Камал һәм аның «Бәхетсез егет» белән «Өч бәдбәхет» пьесалары. Менә «Фәкыйрьлек белән үткән тереклек» хикәясен һәм «Себер тимер юлы» поэмасын биргән М. Гафури.

XIX гасырның икенче яртысында башланып, яңа гасыр кергәндә куәтләнгән уяну дәвере, барыннан да элек, милли уянуга кайтып кала иде. Мәгърифәтчеләр татарларны алдынгы милләт янына куеп күрсәтәләр дә әйтәләр:

[1] Горфи — гадәти

әнә карагыз, алар кая киткән дә, без кайда торып калганбыз. Моның сәбәбе, диләр, борынгы гореф-гадәтләргә ябышып ятуыбыз, схоластикага чумып, яңа фикергә юл куймавыбыз, дөнья өчен кирәкле белем һәм гыйлемнәрдән йөз чөерүебез. Арада кыюрак һәм зирәгрәкләре милли яктан изелүне дә бер сәбәп итеп күрсәттеләр.

Мәрҗанинең көр тавышыннан уянып киткән безнең Фатих та, колагына кергән яңа тавыш, яңа сүз, яңа фикерләрнең мәгънәсен төшенеп алгач, үзен татар милләтенең бер улы хис итеп, аның артталыгына ачына, алга җибәрү, мәртәбәлерәк урынга күтәрү теләге белән яна башлый.

Менә 1902 елга караган тагын бер язмасы. Яшь Әмирханның уй-фикер һәм хис-тойгыларын чагылдыру белән бергә, ул киләчәктә аңардан куәтле публицист һәм әдип чыгачагыннан хәбәр бирә.

8 июнь көнне Тихвинский урамында туксаннан артык йорт янган. Ике чиркәү һәм бер мәчеткә дә ут кабып, соңгысы күмергә әйләнгән.

Манарасы гөрселдәп авар алдыннан мәчетнең зарланып әйткән сүзләре гүя ки аермачык ишетелгәндәй була:

— И, әсир татарлар! Миңа әсирлектән капкан ут сезнең эчегездә ялкын кабызыр дисәм дә, күрәм, башымның иелүенә, аемның җиргә кадалуына гына ярдәм итәрсез ахры.

Бу сүзләр, ди Фатих, эчемдә ялкын кабызды, һәм күзләрем су сипмәсәләр (ягъни яшь коймаса), ул мине һәлак итәчәк иде.

Янгын «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә дә килеп җитә, игъдадия бинасына ут каба. Булачак әдипнең сүзләрен бу урында тәрҗемә итмичә китерергә тиеш табам.

Түбәсенә кызыл әтәч кунган мәдрәсәгә эндәшеп, Фатих, янәсе, болай дигән: «И бостаны гыйльмемез[1] и җәннәте әмәлемез[2], и дәлиле һидаятемез[3], и галәме тәрәккыемез[4], әсирлек уты синең башыңа һәм тукынды, сәмаватә[5] чыкмыш башыңи каплаярак (бер сүз танылмый — И. Н.) йибәрде». Мәдрәсә аңа түбәндәгечә җавап биргән: «И монтазар һәдия[6], и талибе тәрәккый[7], имин ул ки, ошбу әсирлек уты капламыш баши, бер вакыт улачак ки, хөррият байраклары каплаячактыр».

Милләт кайгысы, милләтне тәрәккый иттерү фикере бу елларда инде гомум хезмәтендә ат уйнаткан шәхесләрне генә түгел, бәлки азмы-күпме күзе ачылган шәкертләрне дә били ала. Ничек, нинди юл белән? Бу мәсьәләне милли азатлык өчен көрәш белән бәйләп караучылар берән-сәрән очраса да, социаль азатлык өчен көрәшкә китереп терәүчеләр әле күренми. Иң зур күпчелек, XIX гасырдан ук килә торган идеяне анык бер рәвешкә китереп, әлеге сорауга болай дип җавап бирә:

— Мәдрәсәләрне ислах итү, ягъни белем учакларын тамырыннан үзгәртеп кору юлы белән!

Ягъни схоластикадан азат булып, дөнья көтәр өчен кирәкле гыйлемнәр белән коралланган кешеләр җитештерми торып, милләт тәрәккый итмәячәк.

Милли азатлык мәсьәләләре турында уйлый башлаган яшь Әмирхан өчен дә бу фикер, бу идея якындагы маяк, әгәр шулай әйтергә яраса, программа минимум булып китә, һәм ул ислах өчен көрәшкә баш-аягы белән чума.

Шушы ук вакытларда, Фатихның тормышында аның сукмагын зур юлга алып чыгуда мөһим роль уйнаячак үзгәреш була: 1901 елда ул рус теле өйрәнә башлый.

Моңарчы без, Казан училищелар советының архивта саклана торган таныкнамәсенә карап, Фатих Яңа бистә мәдрәсәсе каршындагы өч еллык рус классында укыган һәм аны 1901 елда тәмам иткән дип йөри идек. Ләкин алай булмаган икән. Архивтагы автобиографиясеннән без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Бер заман рус теле белән дә танышырга вакыт җитте. Әтинең тизрәк минем муллалыкка имтихан тапшыруымны теләве сәбәпле, гражданлык законнары муллаларның русча грамоталы булуларын таләп иткәнгә күрә, мин өч ай буе татар учителеннән рус теле өйрәндем».

«Татар учителе» дигәне шактый еллар элек Казан учительская школа-

---

[1] Бостаны гыйлем — гыйлем бакчасы.
[2] Җәннәте әмәл — өмет җәннәте.
[3] Дәлиле һидаять — дөрес юлга керергә юл күрсәтүче.
[4] Галәме тәрәккый — прогресс дөньясы.
[5] Сәмаватә — күкләргә.
[6] Монтазар һәдия — көтелгән бүләк.
[7] Талибе тәрәккый — алдынгы шәкерт.

сын тәмамлап Яңа бистәдәге рус классында укытып яткан Миңлегаффар Шәфиев булса кирәк. Кул астында гына учитель булгач, нигә әллә кайдан эзләп йөрергә?

Таныкнамә мәсьәләсендә ике ихтимал күңелгә килә. Яки ул, ягъни таныкнамә, Зариф хәзрәт тырышлыгы белән имтихансыз-нисез алынган, яки инде Фатих имтиханга кергән һәм этисенең таныш-белешләре һәм шул ук Шәфиев ярдәмендә ничек кирәк алай ерып чыккан.

Тел өйрәнүгә булган табигый сәләтенә дә карамастан, Фатихка рус теле авыр бирелгән. Чөнки, беренчедән, ул тел өйрәнүне соң һәм аны бөтенләй диярлек белмәгән килеш башлады. Яңа бистә — тоташ татар төбәге, «Мөхәммәдия»дә рус теле предмет итеп кертелми, үзара сөйләшү гел татарча, я гарәпчә. Икенчедән, рус теленә ул, кирәге чамалы булган өстәмә эш итеп карап, этисе кушканга гына, теләми һәм яратмыйча керешә.

1901 елда Әстерханга барып кайтуы уңае белән дәфтәренә теркәлгән кулъязмасындагы мондый сүзләргә алданырга ярамый: «Сембергә кадәр Симбирский корпуста укучы рус шәкертләре илә мөсахәбә итеп килдем». Белмим, өч айлык гыйлем саф рус телендә әңгәмәләшү өчен җитте микән. Сөйләшү ярым русча, ярым татарча, ярым төрекчә (әлеге укучылар төрек офицерлары белән дә аралашалар икән), ә күбрәк халыкара телдә — кул ишарәсе ярдәмендә булган дип уйларга кирәк».



### 3

«1901 елда Казандагы «Мөхәммәдия» шәкертләре арасында «Иттихад» исемле яшерен бер җәмгыять төзелде. «Иттихад»ның төп максаты Казандагы барлык шәкертләрне берләштереп, мәдрәсәләрен ислах итүгә чакыру иде. Җәмгыятьнең әгъзалары Фатих Әмирхан, Ризван Алушев, Гали Могыйнов, Хаҗи Түләки, Бари Сәедгалиев һәм Сибгать Шәриф улы иделәр. Бу җәмгыять «Әль-мәгариф» исемле яшерен газета чыгарып, аның мөхәррире Фатих, язучысы (секретаре) Ризван иде. Фатих ул вакытта буйга кечкенәлеге белән баладан аермасыз булса, яше дә 14-15 ләрдә генә иде».

Ризван Ибраһимов-Алуши истәлегеннән китерелгән бу өзек шунда ук Ф. Әмирханның «Егерменче гасырның әүвәлге еллары» дигән аңлатма белән басылган «Милләт тәрәккый иттерү» (1908) исемле хикәясен хәтергә китерә.

Хикәянең төп каһарманы Хөсәен — җәдит мәдрәсәсендә гакаидхан. Икенче ел инде «Тәрҗеман»ны яздырып алып укый. Яңа чыккан китапларның һәркайсын күздән кичереп бара.

Бу персонажда яшь Әмирхан үзе төсмерләнә түгелме?

Ары таба китик.

Хөсәен фикеренчә, милләтне тәрәккый иттерү өчен, мөселманнарны берләштерергә, бер фикергә китерергә кирәк. Моны исә түгәрәкләр, җәмгыятьләр ярдәмендә генә тормышка ашырырга мөмкин. Хөсәен, фикере ачыла төшкән шәкертләргә сүз сала башлап, алты әгъзасы булган бер җәмгыять оештыруга ирешә (Р. Алуши истәлегендәге «Иттихад» җәмгыятенең әгъзалары да — нәкъ алты шәкерт!).

Җәмгыятьнең беренче мәҗлесе билгеләнә һәм «Сарай» кунакханәсеннән номер алына. Менә мәдрәсә «шагыйре» Йосыф һәм «дин галиме» Мөхәммәтҗан гаять җитди кыяфәт белән килеп керәләр, Хөсәенгә сыңар кул биреп (бу инде яңалык) күрешәләр дә, ят кеше юклыгына ышангач, кәләпүшләрен салып куялар (бусы да тәрәккый-пәрвәрлек галәмәте). Калган өч әгъза да килеп җитә. Арада берсе — мишәр шәкерте — гадәттән тыш озын буе белән аерылып тора.

Алты прибор һәм 18 пәрәмәч китертелә. Коридордан куркыныч нәрсә көтелмәгәнлек билгеле булгач, эш башлана. Хөсәеннең кереш сүзеннән соң җәмгыятькә исем бирү мәсьәләсе карала. Кызу-кызу бәхәстән соң, Хөсәен тәкъдиме уза: «Әль-иттихад» (Р. Алушида да — «Иттихад»).

Мәҗлеснең төп өлешендә алдан әзерләп килгән доклад, мәкалә һәм шигырьләр укыла. Барысында да бер үк маузуг: милләтне тәрәккый иттерү, ислах һәм иттихад. Һәркайсы, ахырданрак сүз алып, иптәшләрен шаккаттырырга тели. Бигрәк тә үзсүзле мишәр гыйлем ягыннан бик үк аерылып тормаса да, үзенә игътибар таләп итә. Бүтәннәр басып укыганда, ул миссионерлар белән дәһриләрне хур итеп ташлаган докладын утырып укый һәм моны, мәзәк кулланып, нигезләгәндәй итә:

— Мин дә басып укер идем дә, башларегезне сузып карәргә кирәк булыр дип куркәм.

Мәҗлес тәмам булу белән хикәя дә бетә. Җәмгыять әгъзалары, канәгать булып, һәм моннан соң инде милләт тәрәккый итәр, итми хәле юк дигән нык-лы ышаныч белән таралалар.

Хикәя сатира дәрәҗәсенә җитә язган юмор белән сугарылган. Бүтәнчә булса да аңлый: әсәрен язган вакытта Ф. Әмирхан инде, дөньяга карашында зур сикереш ясап, мәсьәләләргә бөтенләй бүтәнчә карый иде. Ләкин 1905 елгы революция шаулап узуга һәм иҗтимагый фикернең яңа баскычка күтәрелүенә дә карамастан, кыска ыштаннан калып, милләтне тәрәккый иттерү турын-дагы әллә кайчангы фикерләрне әйләндерә-әйләндерә сөйләп йөрүчеләр бай-гак. Шундыйларның кабыргаларына төртми ярамый.

Шулай да Казандагы шәкертләр хәрәкәтенең юлбашы якынча хикәядәге-чә булганлыгына шикләнмәскә мөмкин. «Иттихад» җәмгыятенең инициато-ры, билгеле инде, Фатих. Түгәрәкнең беренче утырышы хикәядәгечә, әмма җитдирәк һәм эшлеклерәк узган. Арада калкыбрак күренергә теләгән, эчтән генә үзен Фатихка көндәш итеп тойган бер-ике шәкерт булырга мөмкин. Ләкин, малай кыяфәтле булуына карамастан, Фатихның өстенлеге һәм авто-ритеты инде бәхәссез. Шуңа күрә дебатсыз-нисез генә җәмгыятьнең секретаре итеп ул сайлана. Исем биргәндә дә аның тәкъдиме уза. Курку-сагаю белән доклад, мәкалә һәм шигырьләр укыла (хур булмагаем). Шул ук утырышта кульязма газета чыгарырга карар ителә. Редакторлыкка Фатихны сайлый-лар.

Без, дип яза М. Укмасый, «түбәнрәк шәкертләр, үзебезгә аерым кружок төзегән идек. Безнең кружок башында, ягъни аның җитәкчесе булып Фатих Әмирхан тора иде». «Иттихад» һәм бу түгәрәк икесе бер үк түгелме? Түгел. М. Укмасый раславынча, мәдрәсәдә түгәрәкләр сыйныф-бүлек принцибын-нан чыгып оештырылганнар. Рөшдиянең үз түгәрәге, игъдадиянең — үзене-ке, галиядә дә — махсус түгәрәк. «Иттихад» исә гомуммәдрәсә түгәрәге бу-лым мәйданга килгән. Аның әгъзалар саны бик тиз үсә башлый һәм, 1904 ел кергәч, 75 кә җитә. «Җәмгыять»кә башлык булу белән бергә, энергиясе та-шып торган Фатих, күрәсең, игъдадия түгәрәген дә алып барган.

«Иттихад» җәмгыятенең төп максаты, төп бурычы — мәдрәсәдәге уку-укыту тәртипләренең яраксызлыгын шәкертләрнең аңына сеңдерү һәм алар-ны ислах өчен актив көрәшкә әзерләү. Күп төрле рәвештә, күп төрле чаралар ярдәмендә алып барыла бу эш.

Фатих шәкертләрне эчтән генә түгел, тыштан яңартуга да зур игътибар биргән. Башта, әлбәттә, үзе үрнәк күрсәтә. Бүтән шәкертләр чабуы тубыкка җиткән, изүе каплаулы казаки белән йөргәндә, Фатих тезенә җитәр-җитмәс тора торган тужурка киеп ала. 1903 елга таба ул, мәдрәсәдән тыштагы мәдәни мәҗлесләрдә катышу өчен, костюм, ак яка, манжетлар, галстук, бант, штиб-лет булдыра, бераз соңрак борынына пенсне элэктереп куя (замандашы **«Фатих сау күзенә пенсне киде» дисә дә, моңа шикләнеп карарга туры килә: аның чаклы укысаң, синең дә эшең күзлеккә калыр иде).**

Читек-кәвеш, казаки-җиләнгә каршы көрәштә Фатих, үгет-нәсихәт һәм юмор-сарказм белән генә чикләнмичә, казакины алыштыра торган кием уй-лап чыгарган. Изү төймәләрен каптырып бетерсәң, казакидан аерылмый диярлек. Өске төймәләрен ычкындырып, күкрәк тирәсен як-якка ачып җибәр-деңме, җәйге пальто була да куя. Пальто алырга хәле җитмәгән, фәкыйрь шәкертләр өчен — нәкъ үзе! Фатихтан һәм энесе Ибраһимнан күрмәкче, күп шәкертләр әнә шундый кием киеп йөри башлыйлар һәм, җөббә-пәлтә дигән-не кыскартып, исем дә кушалар: җөкпә.

Шәкертләрне рус-европа мәдәниятенә якынайту һәм халык җырлары, халык көйләре ярдәмендә милли тойгы тәрбияләү максаты белән Фатих һәм аның фикердәшләре әдәби-музыкаль кичәләр үткәргәннәр. Шундый кичә-ләрнең 1904 ел январенда булып узган берсен М. Укмасый болайрак тасвир итә.

Мәдрәсәнең урамга таба сузылган очында кеше тормый, дәрес үткәрел-ми торган бер бүлмә бар. Парҗылыткыч кертелмәгәнгә күрә, салкын һәм иң ерактa булганга, ара-тирә карцер хезмәтен дә үтәгәнгә, аны «Сахалин» дип йөрткәннәр. Нииндидер гаебе өчен бервакыт Фатих та утырып чыккан икән.

Кичә әнә шул бүлмәдә уздырыла. Фатих, кайдандыр табып, граммофон алып килгән. Шәкертләрнең кесә ягы такыр булу сәбәпле, бик үк сату итә алмаса да, буфет та оештырылган.

Кичәнең үзәге, рух бирүчесе — Фатих. Үз язганы белән чыгыш ясаучы түгәрәк әгъзаларын, мәзәк катыштыра-катыштыра, мәҗлескә тәкъдим итүче — конферансье да ул. Граммофонны борып, тәлинкәләрен алыштырып торучы һәм шәкертләргә танцы кагыйдәләрен өйрәтүче дә ул. Ут борчасы кебек тыз-быз чапканда, сикергәндә, биегәндә, нечкә чылбыр белән пиджак якасына тоташтырылган пенснесе борынында төшеп-төшеп киткәнен күз алдына китерү кыен түгел.

«Иттихад» җәмгыятенең тагын бер эш формасы — шул заманның күренекле милләт хадимнәрен утырышка чакырып тыңлау. Рәшит казый Ибраһимовның, мәсәлән, «Мөхәммәдия» шәкертләре белән әңгәмә үткәреп киткәнлеге мәгълүм.

Соңрак «тарихи кыңгырау» дип йөртелә башлаган Рәшит казый —XIXгасырның ахырында татарлык хакына, татар милләтен алга җибәрү, мәртәбәләрен урынга күтәрү хакына көрәш мәйданына атылган шәхесләрнең гаять кызыклысы. Бу тынгысыз җан Россиянең татарлар яши торган төбәкләрен йөреп чыга, чит илләрне гизә, кая барса, анда тәрәккый фикерләрен ялкынланып сөйли, эшкә чакыра, китап яза. 1900 елда ул татарча журналларның яралгысы итеп санарлык «Мирьат» (көзге) исеме астында брошюралар чыгара башлый: менә карагыз үз-үзегезгә, күрегез, нинди хәлдә яшисез...

Әнә шул зат үзенең кыңгыравын шәкертләр колагына чыңлатмый каламы соң! «Ул үзенең речьләрендә,— дип яза М. Укмасый,— мәдрәсәләрнең яраксызлыгын, анда укыла торган мантыйклар урынына физика, математика, җәгърәфия, төрек һәм татар теле, фәлсәфә, коръән тәфсире кертергә тиешлекне, Европа милләтләренең алга китеп, безнең йокы хәлендә икәнебезне, ислам гыйлеме саф вакытта гарәпләрнең шәрыктан гарепкә кадәр үсүләрен, татарларның да шанлы вакытлары булганлыгын сөйләп безне таң калдыра иде».

Рәшит казыйны чакырып китерүнең Фатих эше булганлыгына шикләнмәскә мөмкин. «Милләт тәрәккый иттерү» хикәясендә мондый сүзләр бар: Хөсәен «... зыялылар мәҗлесеннән дә калмый. Сәгыйть (ягъни Рәшит — И. Н.) казыйның Казанга һәр килүендә номерасына барып күрешә вә яңа фикерләр тыңлап кайта».

«Зыялылар мәҗлесеннән дә калмый» дигән сүзләргә игътибар итик. Унбиш-уналты яшьлек Фатих, димәк, милләт хадимнәренең һәм каләм ияләренең ара-тирә булып торган киңәш-табыш мәҗлесләренә үтеп керә башлаган, кайберләре белән танышырга һәм якын мөнәсәбәт урнаштырырга тырышкан.

Журналистика өлкәсендәге беренче адымнарына карата Әмирхан үзе болай дип яза: «Ундүрт яшьләремдә инде мәдрәсәдә кульязма нәшер итеп торган яшерен журналларга бик фәлсәфи, чикылдаган фәлсәфи мәкаләләр яза торган идем». Кульязма журнал да чыгарылганмы, чыгарылса, кем тарафыннан, нинди исемдә, аллә инде юмористик, автобиографиясендә әдип газета һәм листовкаларны ирония белән журнал дип атыймы — без моны белмибез. Мөхәррире Фатих булган «Әл-мәгариф» газетасының да нөсхәләре табылганы юк. Төрекчәләтеп язылган һәм шушы газетада чыккан мәкаләсеннән бер өзек кенә Алуши истәлегендә теркәлеп калган. Аны, хәзерге телгә күчереп, бу китапка да кертеп җибәрик. «Тәрбия итү — күркәм әхлакны баланың гадәткә кергән сыйфатларына әверелдерү дигән сүз. Бу исә ике яшеннән җиде яшенә кадәр була. Чөнки ул вакытта әле балага бозык әхлак йокмаганга күрә, яхшы әхлакка өйрәтү, аны күңеленә сеңдерү бик тә мәшәкатьсез эш. Ә инде бу вакытны уздырсаң, бала начар гадәтләргә биреләчәк, һәм аны шулардан биздерү, шуларның киресе булган яхшы әхлак сыйфатларын кертү гаять кыен булачак. Димәк, балага тәрбия бирү ана кулында чактагы яшь вакытларында була. Әнә шуңа күр... кызларыбызны дәртле һәм тырыш милли галимә итүгә кадәр укыту тиеш» (1902,19 май).

1903-04 уку елында Фатих һәм фикердәшләре ч...кән орлыклар тишелеп чыга: Казан мәдрәсәләре тарихында беренче буларак «Мөхәммәдия»дә кузгалышлар башлана. «Көннәрдән бер көндә,— дип яза Ф. Әмирхан,— без мөдәррис хәзрәтләреннән мәдрәсәгә фөнүне җәдидә [1] һәм фәлсәфи диния кертүне таләп кылдык». Дамелла, петиция белән таныша, уйлана һәм, кырт кисеп кире кагарга базмыйча, яңа низамнамә төзи һәм, «озын бер хөтбә» сөйләгәч, шуны шәкертләргә игълан итә.

[1] Фөнүне җәдидә — яңа фәннәр.

Мондый ярты-йорты чаралар шәкертләрнең алдынгы өлешен, бигрәк тә әгъзалары җитмештән узып киткән «Иттихад» җәмгыятен канәгатьләндерми, билгеле. Яңа ел кергәч, ислах өчен көрәш тагын да көчәеп китә. Менә Баруди кулына яңа петиция килеп керә. Уен-муен гына түгел икән бу, эшләр җитдиләшеп бара. Нишләргә?

Бохара җимеше булуына карамастан, дамелляны шәкертләрнең теләкләрен аңламаслык дәрәҗәдә кара киселгән хәзрәт дип булмый. Тарих, җәгърәфия, математика кебек дөньяви фәннәр кертүгә дә, дин фәлсәфәсе һәм хәдисләр укытуга да каршы түгел ул. Тик бер кыенлыгы бар: тиз арада гына шул фәннәрне укытырдай кешеләрен кайдан табасың? Тапкан тәкъдирдә, мәдрәсәне асраучы байлар моңа ничек карар?

Алай да уйлап карый хәзрәт, болай да, киңәш-табыш итә һәм мондый бер маневр кулланырга була. Ярар, ди, киләсе көздән сез теләгән фәннәр кертелер, үзем дин фәлсәфәсен укыта башлармын.

## 4

Фатихның дөньяга карашы ай үсәсен көн үсә, ел үсәсен ай үсә. Рәсми яктан да инде ул галия шәкерте генә түгел. Югары сыйныфның иң сәләтле шәкертләрен укытучылык эшенә тарту традициясе буенча Фатихны хәлфә итәләр. Бер хатында, юмор катыштырып, үзе дә бу турыда әйтә: «Камилән хәлфә булып йиттем. Борыннан сөйләшергә генә өйрәнәсе калды» (1904, 25/XII). Икенче бер чыганактан аның рөшдидә география укытканлыгы аңлашыла.

Менә сыйныф ишеге кинәт һәм киң генә ачыла да җитез адымнар белән Фатих килеп керә. Калын алсу иреннәре чак кына елмая, үткен карасу күзләре көлемсери. Мәзәк катыш кереш сүздән соң нәүбәттәге темасын башлый. Очлы таягын харита буйлап йөртә-йөртә сөйли, укыганнарыннан чыгып, үзе белгәнчә, үз системасы буенча сөйли. «Күз алдында,— ди шәкертләреннән берсе,— Сена елгасы, Эйфель манарасы, Латин кварталы, Елисей кыры белән мәһабәт Париж каласы баса, томанга өртелгән Темза буендагы соры Лондон калка». Истәлекче күп арттырмаган дип уйлыйсы килә. 1902 елда ук инде Фатих мәгълүм дәфтәрендә сыйныфташларының берсенә — гадәттән тыш озын буйлы һәм күсәкнең күсәге булган шәкерткә биргән характеристикасында «Эйфель» сүзен кулланган иде. («Буе — Эйфель манарасы кадәр, акылы чыпчык авызындагы су чаклы»).

1902-04 елларда инде Фатих мәдрәсәдән тыштагы дөньяда да шактый гына күренекле фигура булып китә. Казанның күп кенә билгеле гаиләләренә үтеп керә, төрле даирәләрдә күренә, студент һәм гимназистлар, курсистка һәм гимназисткалар, шулай ук бүтән төр дәүләт мәктәбе укучылары белән аралаша башлый.

Казанның тәрәккый пәрвәр купецы Сөләйман Аитов йортында ул күптән инде үз кеше. Ш. Мәрҗани һәм К. Насыйри белән якын мөнәсәбәттә булган һәвәскәр тарихчы Мөхәммәтҗан Аитов гаиләсендә туып буй үстергән Сөләйман без ишетеп белгән гадәти кибетче-сәүдәгәр генә түгел. Аның эше — зур сәүдә фирмаларына арадашлык хезмәте күрсәтү. Көнчыгыштан партия-партия чималны Көнбатышка, Көнбатыш товарын Көнчыгышка озата. Казанда, Оренбургта һәм Кокандта конторалары бар.

Сөләйман әфәнденең уй-нияте, күрәсең, табыш арттыру белән генә чикләнмичә, күпмедер дәрәҗәдә ул милләтнең киләчәге турында да уйлаган. XIX гасырның ахырыннан башлап мәгариф эшенә шактый акча сарыф иткәнлеге мәгълүм. «Аитова мәктәбе» дип дан казанган уку йортының Сөләйман бай акчасына яшәгәнлеге үзе генә ни тора! С. Аитовның мондый эшчәнлеге, табигый, охранканы сагайткан. Күзәткәннәр, тикшергәннәр һәм, карашлары ягыннан ул кадетларга якын тора дип, беркадәр тынычланганнар.

С. Аитов киңәшләре һәм акчасы беләнрәк кенә катышса, аның җәмәгате Фатиха ханым Аитова татар кыз балаларын укыту, агарту һәм һөнәргә өйрәтү эшенә бөтен гомерен багышлый. Бу вакытларда ул — үрнәк итеп йөртелгән кыз балалар мәктәбе мөдирәсе. Гаять тырыш, энергияле, уйлаганын таш яуса да, ахырына җиткерә торган хатын. Ире Сөләйман юкка гына аны «Батый» дип йөртмәгән. Атка утырып чыкса, дилбегәне үзе тота, кызу чаптырып

йөрергә ярата икән. Кызлар укыту арбасының дилбегәсен дә ул нык тоткан булыр.

Әнә шул Фатиха ханым Петербургта халык мәгарифе министры иптәшенә (урынбасарына) кадәр җитеп, 1915 нче елда беренче татар кызлар гимназиясе ачуга ирешә.

Фатих бу гаиләдә ничек үз кеше булып киткән? Барыннан да элек, Зариф хәзрәт белән Сөләйман Аитов үзара якын мөнәсәбәттә булганнар, тегеләйме-болаймы аралашканнар дип уйларга туры килә. Иске бистәдә яшәгән тәрәккый пәрвәр купецның Яңа бистәдәге рус классының почетлы караучысы булуы һәм акчалата ярдәм итеп торуы да шуны расласа кирәк. С. Аитовның уллары Исмәгыйль һәм Ибраһим шул ук «Мөхәммәдия»дә укыйлар. Беренчесе Фатихның сердәш дусты булып китә, икенчесе, шәкерте сыйфатында география дәресләренә йөри.

Аитовлар аркылымы, әллә инде бүтән юл беләнме, яшь Фатих Казанның күренекле гаиләләреннән берсе — Терегуловлар семьясына да үтеп кергән.

Ибраһим Терегулов башта Казанның ветеринария институтын, аннары университетын тәмамлап чыга. Яңа гасырга кергәндә без аны Татарская учительская школада (моннан соң аны, татарчалаштырып, КТУМ дип атарбыз) табигать укытучысы итеп күрәбез. Татарларны агарту, культура-мәгариф эшләрендә дә ул җиң сызганып катнашкан. Аның мәсәлән, 1902 елда Гогольнең «Ревизор» комедиясен татарчага тәрҗемә иттергәне, Петербург аша эш йөртеп, бастырып чыгарганы һәм татарлар арасында таратканы билгеле.

Ф. Әмирхан катышкан гаиләләрдән тагын 1900 елга, ягъни үлгәнчегә кадәр, КТУМ инспекторы (икенче төрле әйткәндә, директоры) булып торган Шаһбазгәрәй Әхмеров, Син-Цзянда Россия илчелегендә эшләгән Шәрәфетдин Габитов (бу вакытта инде дөньяда юк) һәм надворный советник Гали Саинов гаиләләрен күрсәтергә мөмкин. Ф. Әмирханның тормышында шактый зур роль уйнаган тагын бер даирәгә тукталып китик. Ул да булса, әлеге КТУМ, ягъни Казан татар укытучылары мәктәбе. Хөкүмәтнең азчылык милләт балаларын русча укыту турындагы карарын тормышка ашыру йөзеннән, рус теле укытучылары әзерләү өчен 1876 елда ачылган бу мәктәптән 25-30 ел эчендә йөзләгән татар егетләре укып чыгып, мәгариф, фән, әдәбият, сәнгать өлкәләренә һәм шулай ук революцион хәрәкәткә зур өлеш керттеләр. Мәктәпнең укучылары, кагыйдә буларак, кичәге шәкертләр иде. Школаны абитуриентлар белән тәэмин итүдә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе беренче урынны тотты дисәк, шаять, хата булмас. Хәсәен Ямашевның, мәсәлән, «Мөхәммәдия» җиләнен салып ташлап, КТУМ формасын киеп җибәргәне турында әйтелгән иде. Яңа гасыр башлангач, андыйларны инде дистәләп санарга мөмкин. Кичәге шәкертләр мәдрәсә белән араны өзеп бетермиләр, килеп-китеп йөриләр, яшьтәшләрен тегe яки бу уңай белән школага китерә башлыйлар. КТУМның татар яшьләре укыган иң алдынгы уку йорты булганлыгы, идеяләрнең, аерым алганда, марксизм тәгълиматының аңа тизрәк һәм җиңелрәк үтеп кергәнлеге, гасыр башында инде социал-демократик түгәрәкләр барлыкка килгәнлеге мәгълүм. Без әле күрербез: 1905 елгы революция башлангач, аеруча кызып киткән шәкертләр хәрәкәтендә «Мөхәммәдия» шәкертләре авангардта барып, социал-демократлар йогынтысында булганнар. Моның төп сәбәбен Учительская школа белән «Мөхәммәдия» арасындагы тыгыз бәйләнештән эзләргә кирәк.

Фатихның «школьниклар» белән дуслашып, КТУМ бусагасын атлап кергән шәкертләрнең беренчеләреннән булганлыгына шикләнмәскә мөмкин.

КТУМның тагын бер тарихи хезмәтенә — татар яшьләрен театр сәнгатенә якынайту юнәлешендәге эшләренә тукталып китәргә кирәк.

Школада рус теле һәм әдәбиятын укыту чагыштырмача яхшы куелган булган. Драматик әсәрләрне өйрәнгәндә рольләргә бүлеп укыту инде күптән гамәлдә. Бу алым, бу ысул, күрәсең, укучыларны спектакль кую фикеренә китергән. Фатих белән бер вакытта «Мөхәммәдия»дә гыйлем алып яткан, соңрак «Әльислах» газетасының рәсми редакторы булып киткән Вафа Бәхтияров яза: «Һәр кыш «Татарский учительский школ» да укучыларның пасха, рождество бәйрәмнәрендә берничә тапкыр рус телендә театр уйнала торган иде. Ел саен мәшһүр «Ревизор»ны уйнамый калмыйлар иде... «Мөхәммәдия» шәкертләре тамашачы булып бара иделәр».

Үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, шәкертләр дә кабынып китеп, татарча театр уены уйнау фикеренә килә.ләр. Иң элек кем башына килгән бу фикер, кем аны тормышка ашырырга керешкән? «Без,— дип яза В. Бәхтияров,— театр уйнау фикерен Гыймад хәлфә Нугайбиковка һәм Фатих Әмирханга

белдердек. Гыймад Нугайбиков башта каршы торды. «Дамелля белсә, яхшы булмас, барыбызга да бер-бер хәл булмасын дип куркам»,— диде. Фатихка белдерү белән үк хуплап каршы алды, үзенең катышачагын белдерде». Кем ул «без»? В. Бәхтияров үзе һәм аның белән бер сыйныфта укыган һәм школадагы спектакльләргә йөргән берничә шәкерт дип уйларга кирәк. Болар башлаган була, Фатих кушылып киткән була...

Татар театры идеясе, руслар әйтмешли, күптән инде һавага сеңгән, баш өстендә әйләнә. XIX гасырның беренче яртысында рус театры бусагасын атлап кергән татарлар ук инде (билгеле, өстен катлау вәкилләре): «Эх, безнең татарда да шундый уеннар булсын иде»,— дип хыялланганнар. Гасырның икенче яртысында, мәгърифәтчелек хәрәкәте куәт алгач, театрның кирәклеге үзен бигрәк тә нык сиздерә башлаган. «Бичара кыз», «Рәдде бичара кыз», «Комедия Чистайда» пьесаларының мәйданга килүе шуны күрсәтә. Бу вакытларда инде «аристократлар» гына түгел, бәлки урта катлау вәкилләре, «разночинецлар» да, рус театрына теләп йөри башлыйлар. Шуларның берсе — безнең Галиәсгар Камал. Йөри генә түгел, үзе дә 1899 елда «Бәхетсез егет» исемле пьеса язып ташлый.

Мәгърифәтчеләр әзерләгән рухи азык белән тукланып буй үстергән Фатих аларның театр турындагы уй-хыялларын колак яныннан гына үткәреп җибәрә ала идеме? Әлбәттә, юк. Шуңа күрә кемнәрдер башлаган эшкә кушылып китүче итеп кенә күрү дөрес булмас иде. Ул, һичшиксез, бу эшнең дә үзәгендә булган, бу эштә дә тон биргән. Моны В. Бәхтияровның үз язмасыннан да чамаларга мөмкин.

Менә Гыймад хәлфә, Ф. Әмирхан, В. Бәхтияров һәм тагын берничә шәкерт, әлеге «Сарай» номерына җыелып, спектакль кую турында киңәш коралар. Нәрсәне, кайда һәм кайчан уйнарга? «Бичара кыз»ны, ди берсе, «Бәхетсез егет»не, ди икенчесе. Соңгысына тукталалар. Ләкин пьеса сәхнә таләпләренә җавап биреп җиткерми. Нишләргә? «Нугайбиков һәм Фатих,— ди Бәхтияров,— «Бәхетсез егет»нең кайбер җирләрен төшереп калдырырга, кайбер җирләренә арттырулар ясарга өсләренә алдылар» (күренә ки, тагын Фатих!). Әнә шул килеш «ремонт ясалган» пьеса буенча «Сарай»да берничә репетиция үткәрелгәч, театр уенының көне һәм урыны тәгаен ителә. Декорация һәм костюмнар әзерләнә.

Ниһаять, көткән көн килеп җитә. 1903 елның декабре. Иртәгә җомга дигән көнне кич, дамелля һәм хәлфәләрнең зур мәҗлескә китүләреннән һәм, шәкертләр кайсы-кая таралганга, мәдрәсәнең бөтенләй диярлек бушап калуыннан файдаланып, өченче кат коридорында сәхнә сыман нәрсә әмәлләләр, чаршау коралар да тамашачы сыйфатында катнашкан 15-20 шәкерткә «Бәхетсез егет»не уйнап күрсәтәләр. Башкаручыларның кайберләре: Ибраһим Әмирханов (Закир), Хәлил Әбелханов (Кәрим бай), Касим Габдуллин (Җәмилә), Вафа Бәхтияров (Сәгыйть Сабитов), Солтан Рахманкулов (Әхмәт), Габдрахман Мостафин (Гайшә).

Укучы игътибар иткәндер, уйнаучылар арасында Фатих юк. Аның эше — суфлерлык һәм грим салу. Режиссер кем? Белмибез. «Артистлар»ның әле махсус режиссер кирәк булганлыгын аңлау дәрәҗәсенә ирешмәгән булуы да ихтимал. Бу эшне азмы-күпме Фатих башкарган дип уйларга туры килә. Бит ул пьесаны сипләп чыкты. Репетиция вакытында да киңәш бирми калмас. Суфлерлык итүе дә кәгазьдә язылганны «артистларга» җиткерү белән генә чикләнмәгәндер. Өстәвенә, бу вакытта инде Фатих үзе чын «артист». «Шимбәчеләр» түгәрәгенә йөреп, алар куйган спектакльдә роль башкарган кеше.

1904 елның апрелендә «труппа», Барудиның авырып ятуыннан файдаланып, тагын бер спектакль күрсәткән. Мәдрәсә эчендә уйнау мөмкин булмый башлагач, Яңа бистәнең Вахит мәзин өендә берничә тапкыр уйнаганнар (мәзиннең бу вакытта «Мөхәммәдия»дә укып йөргән улы Мәхмүт соңыннан күренекле партия-совет работнигы булып китә). «Репертуар» да байый: «Бәхетсез егет»кә «Бичара кыз» һәм «Рәдде бичара кыз» өстәлә.

Хәер, беренче спектакльнең инициаторы Фатих булмаска мөмкин. Соңгы еннарда да тиресеннән чыгып тырышмавы ихтимал. Чөнки дәрәҗәләрәк «труппа»да катышкан Фатих мәдрәсә һәвәскәрләренә зур өмет багламый. Беренчедән, мәдрәсәдә тиешле шартлар юк, икенчедән, хатын-кыз рольләрен дә егетләр башкарырга тиеш. Шулай да ул аларның күңелләрен суытмый, катыша, булыша: дәртләре кузгалган икән, әйдә маташтырсыннар.

1903 елда Казанның югары һәм урта мәктәпләрендә — университет, ветеринария институты, югары курслар, гимназия һәм реальное училищеда

укый торган бер төркем татар-башкорт егетләре һәм кызлары оешып алалар да. Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятлары белән берлектә, татар әдәбиятын өйрәнүне максат итеп куеп, эшкә керешәләр. Моның белән генә калмыйча, татар телендә өй спектакльләре куя башлыйлар. Тора-бара түгәрәкнең эшчәнлеге политик төс ала.

Беренче рәсми утырышлары Шаһбазгәрәй Әхмеров йортында булып, Мулланур һәм Нәби Вахитовлар, Әминә Терегулова, Суфия, Сара һәм Ильяс Әхмеровлар, Зәйнәп Габитова, Гайшә Богданова, Фатымаи-Зөһрә, Зәйнәп һәм Солтан Саиновлар, Әхнәф Мамлеев һәм Сөләйман Чанышевлар катнашкан. Һәр атнаның шимбә көнендә әлеге дүрт гаилә өендә чиратлаштырып җыела башлыйлар. Әгъзалар өстәлә тора. Мәдрәсәдән Фатих, Гыймад Нугайбиков һәм Гарифҗан Мостафин килеп кушыла.

Унҗиде-унсигез яшьлек Фатих — мәдрәсә шәкерте — бу даирәдә үзен ничек тоткан? Ишек катындарак, урындыкның кырыена гына утырып, ярты-лаш русча сөйли торган мирза кызларына, ялтыр төймәле студентларга исе китеп, сокланып карап тормаганмы? Бу сорауга Ф. Әмирханның «Урталыкта» исемле романыннан азмы-күпме җавап табарга мөмкин. Әсәрнең 8 һәм 9 бүлекләрендә «Шимбә» түгәрәгенең Сөләймановлар өендә узган бер мәҗлесе тасвир ителә. Яңа спектакль куярга әзерләнәләр.

Иң элек мәҗлестә катнашучыларның икесе белән танышыйк: беренчесе — Шәриф. Әсәрдән күренгәнчә, ул элеккеге мәдрәсә шәкерте. Хәзер — газетачы һәм «модага кереп бара торган» язучы. Урта буйлы, чандыр. Куе кара чәчле, кылыч борынлы. Муенында зур кара бант. Хәтфә паласлар, йомшак урындык һәм кәнәфиләр арасында эреп югала торган йомшак, акрын тавыш белән сөйли. Һәр сүзендә дип әйтерлек юмор, ирония.

Икенчесе — гамәленнән дә бигрәк, хыялында үзен куркыныч революционер итеп күреп, шапырынып йөрүче Саматов. Күп сөйли, сөйләп бетергәч, тыңлаучысына җиңгәнсыман карап, борыныннан «кеңкых» дигән тавыш чыгарып куя.

Булачак спектакль өчен сайланган пьесаны укырга керешәләр. Бөтен шартын китереп Шәриф укый. Түгәрәк әгъзалары игътибар белән тыңлыйлар. Саматов кына борын җыерып, кыбырсып утыра: р-р-революционный эш урынына сафсата белән шөгыльләнәләр, янәсе. Аннары түзми, журнал ала да чыштырдатып актара-актара укыган булып утыра башлый. Шәриф, укуыннан бүленеп, йомшак, ягымлы тавыш белән өй хуҗасының улы Мөхәммәткә эндәшә:

— Синең иске журналларың күп иде, матурым. Шулардан берәр экземплярын кунакларга өләшеп чыксаң, алар да күркәмлек өчен укып утырырлар иде.

Шәриф белән Саматов арасында тагын бер инцидент булып ала. Куелачак спектакльдән килгән акчаны нәрсәгә тоту турында сүз башлангач, Мөхәммәт университетыннан чыгарылу алдында торган ике фәкыйрь студентка бирергә тәкъдим итә. Саматов исә политик гаеп өчен төрмәдә утыручылар файдасына тотарга кирәк, ди дә, төкерек чәчә-чәчә, бу кешеләрнең халык файдасы өчен җәфа чигүләрен исбат итәргә керешә. Аны тыңлап бетергәч, Шәриф, кулларын чалбар кесәсеннән чыгарып, өч мәртәбә шапылдата да болай дип куя:

— Яшә, Саматов туган! Син сөйләмәгән булсаң, бу халык төрмәдәге политическийларны медаль алыр өчен кереп утырганнар дип уйлап йөргән булыр иде.

Шәриф образында Ф. Әмирханның кайбер чалымнарын абайлау кыен булмаса кирәк.

Дөрес, романдагы вакыйгалар 1906 елга карый. «Шимбәчеләр» инде өй спектакльләре куйганнар, хәзер исә ачык, публичный спектакль әзерлиләр.

1903 ел башында Фатих, «Шимбә» түгәрәге бусагасын атлап кергәч, азмы-күпме җайсызлык хис итми булмагандыр. Әмма ул сиздермәскә, үзен иркен һәм хөр тотарга, түгәрәкнең тулы хокуклы әгъзасы булып күренергә тырышкан. Бу вакытларда Фатих беренче рольләрне башкармаса да, өченче, дүртенче рольләрдә дә торып калмаган.

Роль дигәннән, 1904 елның 20 февраль хатында Фатих мондый сүзләр яза: «Студентлар вә гимназисткалар илә үткән ел башында татар лисанында ике уен уйнадык. Берсе — «Кызганыч бала», берсе — «Гыйшык бәласе». Мин «Кызганыч бала»да Хәлил булып уйнадым. «Гыйшык бәласе»ндә Габде-

самат әфәнде булып уйнадым. Халык тарафыннан шаян [1] тәхсин улынды».

Ничек башкарган бу рольләрне Фатих, нинди буяулар кулланган, тамашачыда нинди тәэсир калдырган — без моны белмибез. Игътибарны җәлеп иткәне шул: Фатих җиде яшьтәге егет ике очракта да шактый өлкән яшьтәге кеше булып уйный. Беренче пьесада ул — төрек бәге, гаилә башлыгы. Икенчесендә — егет булып җиткән яшь бәкнең хәлфәсе. Бу пьесаларны уйнаганда Сөләйман байны һәм бүтән гаилә башлыкларын күзәтүдән кала, баритон тавышы да ярдәмгә килгән дип уйларга кирәк.

«Гыйшык бәласе» пьесасында мондый бер эпизод бар: Габдесамат хәлфә сандыкка кереп качкан шәкерте Әдип бәкне бүлмәдән күтәреп алып чыга. Бу эпизодны ничек хәл иткәннәрдер, билгесез: юка бәдәнле Фатихның Әдип булып уйнаган «артист»ны сандыгы-ние белән күтәрә алуын күз алдына китерүе кыен.

Тагын шуны да әйтик: яшь Әмирханның «Шимбә» түгәрәгенә баглаган өметләре артыгы белән аклана. «Шимбә»челәрнең 1906 елның 22 декабрендә шул ук «Кызганыч бала» һәм «Гыйшык бәласе» пьесалары белән публичный спектакль күрсәтүләре һәм бу көннең соңыннан профессиональ татар театрының туган көне итеп билгеләнүе кечкенә нәрсә түгел.

«Шимбә»челәр даирәсендә Фатих, характерына хас булганча, үзен тигез һәм хөр итеп тоткан дисәк тә, әчтән кимсенергә һәм язмышын каргарга җитди бер сәбәп булган. Ул да — русчасының зәгыйфьлеге. Әнә бит студент һәм гимназисткалар телләре-телгә йокмый русча сөйләшәләр, татарча сөйләгән чакларында да ирекле-ирексез рус сүзләре, рус җөмләләре килеп керә. Чиста итеп үз ана телендә сөйләргә теләгән гимназисткаының, башлаган җөмләсен бүлеп: «Ходаем, татарча ничек була соң?» — дип өзгәләнеп куюы Фатихны елмайта да, сокландыра да, ачындыра да. Аларның бит әле руслардан дусишләре, әшнәләре дә бар. Болар белән очрашырга туры килгәндә Фатихның хәле тагын да мөшкелләнә.

Хөкүмәт мәктәпләрендә укучы «шимбәчеләр»нең табигать фәннәреннән генә түгел, бәлки социаль фәннәрдән, шулай ук Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятлары тарихыннан әллә ничаклы нәрсә белүләре дә Фатихны уйландырмый калмаган. Дөрес, бу яшьләр шәрыктан килгән гыйлемдә Фатих белгәннең меңнән бер өлешен дә белмиләр. Әмма Россия мәмләкәтендә яшәгән татарлар Көнбатышка таба йөз белән борылган бер чорда бу зур юаныч түгел.

Нишләргә? Билгеле инде, рус телен ныклап торып өйрәнергә кирәк. Белем хәзинәсенә ачкыч — шул. 1903 елда Фатих әнә шундый фикергә килә («Бу көннәрдә русча укымак сададында [2] горам, алла ни язмыштыр», 19 май) һәм, архивтагы автобиографиясеннән күренгәнчә, ниятен тормышка ашыра башлый: «Зур кыенлык белән булса да, мин аңардан (әтисеннән — И. Н.) тагын бер өч ай русча укырга рөхсәт алдым».

Зариф хәзрәт уенча, имтихан тотып указ алыр өчен, Фатихның русчасы бик җиткән. Шуннан артыгы, аны бүтән юлга кертеп җибәреп, атаның күңелдәге хыялларын җимереп ташлавы мөмкин. Бу бер. Икенчедән, учитель яллап, бу кирәкмәс эшкә акча тотарга туры килә.

Картның курыкканы чынлап та тормышка аша башлый. 1904 елның җәендә Фатих, энесе белән берлектә, ике ай буе Самарада (хәзер Куйбышев) ниндидер курста укып кайткан. Шул ук елның көзендә — әтисе рөхсәте беләнме, рөхсәтсез генәме,— аның, китап-дәфтәрләрен күтәреп, тагын учительгә йөргәнлеге мәгълүм. Бу укытучысы — китапка әле әйләнеп кайтачак студент Сергей Николаевич Гассар булган дип уйларга нигез бар.

Фатих Әмирханның тагын бер сыйфаты шул: читтә йөреп кайтырга, сәяхәт итәргә ярата. Яшь чагында да шулай, олыгайгач та шулай булачак. 1901 елда ул, әтисенең дусты Габдрахман мулла Гомәригә ияреп, Әстерханга барган һәм үзе генә әйләнеп кайткан иде. 1904 елда Фатих, күргәнебезчә, Самарада булып кайтты. Шушы яшенә җитеп, Мәкәрҗәне күрми торуын күз алдына китереп булмый. Ел саен, җәй килдеме, Чистайга китеп бара. 1903 елгы сәяхәтендә инде ул Закир ишан улы Ибраһим белән дә якынайган. Хәер, соңгы бер-ике елда аны Чистайга Нәҗип хәзрәт гаиләсе һәм Ибраһим Камалов кына тартмаган. Анда бит уналты яшен тутырган Шәмсениса туташ та бар...

Ярар, Фатихның «Мөхәммәдия»дәге хәл-әхвәлен яздык, аны мәдрәсәдән тыштагы даирәләрдә күрсәттек. Казаннан чыгып йөрүләрен дә телгә алдык.

[1] Шаян — лаек, тиешле дәрәҗәдә.
[2] Садад — аек караш, уй-исәп.

Аның бит әле Яңа бистәсе, туган йорты, ата-анасы бар. Мәдрәсәдә торып укыса да, ул өенә еш кайтып йөри, кунып та кала. Әмма соңгы вакытта бу, үзенә элеккегедәй рәхәтлек бирмәгән кебек, ата-анасына да бик үк шатлык китерми башлый. Чөнки ата белән угыл арасы бозылып бара: Фатих бик тиз һәм бик нык суллашты, ата исә бер урында торып калды, димәк, аралары ерагайды.

Зариф хәзрәт бәлки Фатихның кайбер эшләренә күз йомып, булган хәл белән килешер дә иде. Ләкин ул Казанның могтәбәр байларыннан, дус-иш муллаларыннан, бигрәк тә Галимҗан Барудидан сүз ишетеп тора: тый улыңны, хәзрәт. Урыс булып бетте. Шәкертләрне аздыра, фетнәче, марҗалар белән шаяра, патшага каршы бара торган студентлар шайкасына кергән.

Үгетләп тә карый хәзрәт, куркытырга да азаплана. Кая ул! Әллә кайдан китереп, әллә ничек кенә әйләндереп әйтә дә, көлке хәлгә төшкәнеңне сизми дә каласың.

Өч ай буе учительгә йөреп сабак алгач, 1903 елның җәй ахырында булса кирәк, Фатих болай дип белдерә:

— Мәдрәсәне ташлыйм. Учительская школага күчәм!

Зариф хәзрәтнең өстенә бозлы су сиптеләрмени! Олы улын бабаларының эшен дәвам иттерүче итеп күрү хыяллары челпәрәмә кылә дигән сүз бу. Тиз кабынып китә торган үзсүзле, үҗәт хәзрәт кырт кисә:

— Моннан соң син миңа ул түгел, дүрт ягың кыйбла!

Әнисе, Рабига абыстай, елый башлый, ярсып китеп һуштан яза.

Характер ныклыгы ягыннан әтисеннән калышмый торган Фатих картның сүзләренә бәлки карап та тормас иде. Әмма сөекле әнисе дә, ире ягыннан торып, улының бу карарына каршы төшкәч, һәм моны шулай авыр кичергәч, Фатихка, әлеге ниятеннән кайтып, язмышка буйсынудан бүтән чара калмый.

Хәер, улының мәдрәсәне ташлау ихтималы гына, белмим, Рабига абыстайны бу чаклы кайгыга салыр иде микән. Күңеле белән яңалыкка тартыла торган ананы Фатихның чәч җиткереп, костюм киеп, галстук бәйләп йөрүе дә, шәкертләргә утаман булып китүе дә, каланың мәшһүр зыялы гаиләләренә катышуы да аз борчыган булыр. Аны иң изгәне — ата белән угыл арасының бозылып китүе. Ир хакы да бар, бала да газиз. Бер кулы белән картына, икенчесе белән улына ябышкан, якынайтмакчы, килештермәкче. Тегеләр исә, бичара ананы урталай өзәрдәй булып, ике якка тартылалар.

Конфликт гаилә эчендә генә калмый. Фатихның төс-кыяфәте, өс башы, үзен тотышы, эш-гамәле Фәтхулла хәзрәт иярченнәренең күптән инде саруын кайната башлаган. «Иске-изге» дип белүче бу даирә вәкилләре, шау-шу килеп, Фатихның гайбәтен сату, атасына әләкләү белән генә чикләнмичә, турыдан-туры һөҗүмгә күчәләр. Фатих зарарына кылган гамәлләренең барысын да без белмибез. Әмма берсен — иң әшәкесен әдип үзе теркәп калдырган.

1904 елның көзендә була бу. Фатих атнасына берме-икеме тапкыр шәһәрнең «рус ягына», учителенә дәрес тыңлатырга йөри. Димәк, Болак күпере аркылы чыгарга кирәк. Көннәрдән бер көнне шул тирәдә клиентлар көтеп йөри торган урам кызы Фатихка тагылып ала да, дөньяда нинди әшәке сүз бар, берсен дә калдырмыйча, хурлый башлый. Әллә ни чаклы җир ияреп барып, сүгә дә сүгә. Икенче тапкырында да әлеге кыз каршы ала, өченчесендә дә... Бу хәлдән гаҗиз булып, Фатих бүтән күпердән йөри башлый. Әмма тынычлыгы озакка бармый, фахишә аны тагын эзләп таба. Күпмедер вакыттан соң бу сәер, ямьсез вакыйганың хикмәте ачыклана. Әдипнең үзе әйтүенчә, «Казанның иң фахиш, иң хулиган байларыннан берсе Печән базарында болай дип мактанган:

— Чукындырдым бит Зариф мулланың теге чукынчыгын: ул кяфергә хәзер Болак күпереннән үтеп йөрергә дә калмады инде».

...1904 ел бетеп килә. Маяктан-маякка күчә-күчә, дәртләнеп, ялкынланып яшәгән безнең Фатих, киләчәккә зур өметләр баглап, яңа, 1905 елның ишеген шакый. Бу ишек артында аны тагын да зуррак вакыйгалар, кайгышатлыклар, яңа маяклар көтә.

## Җәмәгать хадиме булырга теләп

1

Фатихның 1905 ел 4 март тарихлы хатында түбәндәге сүзләр бар: «Монда, иптәш, Казан кайный да тора. Һәр төрле яңа вакыйгалар тулып ята».

Бүтәнчә ничек булсын? «Канлы якшәмбе»дән соң үзәктә күтәрелгән революция дулкыны Казанга тәгәрәп килеп җиткән көннәр бу.

Барыннан да элек, революцион социал-демократлар җитәкчелеге астында эшчеләр хәрәкәткә килә, забастовка көрәше башлана.

Бер вакыйгага гына тукталып китик.

20 январь көнне Алафузов фабрикасының җеп эрләү цехыннан 70 ләп хатын, эшләрен ташлап, фабрика ишегалдына чыгалар да эш вакытын киметү, хезмәт хакын арттыру, штрафларны бетерү турында таләп куялар. Ул да булмый, йөздән артык ир аларга килеп кушыла. Төшке аштан соң эшчеләрнең яртысы эшкә керешмәгән. Чөнки яшерен оешма әгъзалары (арада Казан университеты студенты Скворцов та бар) эшкә килүчеләрне забастовкага өндиләр, агитациягә бирелмәүчеләрнең фабрикага үтеп керүенә тоткарлык ясыйлар. Скворцов җитәкчелегендә бер төркем цехтан цехка йөреп, үгетли, өлтә. Нәтиҗәдә фабрика туктап кала.

21 январьда да станоклар хәрәкәткә килми. Ике йөзләп эшче бүтән заводларда эшне туктату нияте белән Бишбалтага юнәләләр. Ләкин аларны атлы стражниклар каршылый. Янадан Ягодный бистәсенә кайталар. Фабрика тирәсе халык белән тулы. Забастовкачыларны таратырга, «котыртучыларны» кулга алырга теләгән стражникларга таш һәм таяклар белән коралланып каршы торалар. Властьларга бер рота солдат китерүдән башка чара калмый. 25 январьга кадәр Алафузов фабрикасы тукталып торган.

Татар эшчеләре үзләрен ничек күрсәткәннәр? «Пролетарская революция» дигән җыентыкта бер автор хәтта болай дип җибәрә: «Алафузов эшчеләре арасында татар эшчеләре иң алдынгы элемент булып чыктылар. Рус эшчеләренә караганда нык эксплуатацияләнгән, җәберләнгән татар эшчеләре эш ташлауларда, хәрәкәтләрдә һәрвакыт авангард булып бардылар». Татарларның активлыгы һәм кыюлыгы күбрәк яшерен җыелыш барган чакта сакта тору, ораторларны полиция кулыннан йолып алу, стражник яисә казакларга таш ату кебек эшләрдә күренгән, әлбәттә. Эшчеләр тарафыннан сайланган вәкилләр сыйфатында хуҗа яки управляющий каршына барганда исә алар рус иптәшләре артынарак сыенганнар. Нишлисең, тел бик үк тыңламый.

Ләкин шунысы бәхәссез: сан ягыннан азрак булса да, татар эшчеләре арасында стачка комитеты әгъзалары да, РСДРП(б) членнары да байтак. Алафузов заводы вакыйгалары уңае белән кулга алынган унҗиде эшченең, мәсәлән, өчесе — татар: Зариф Сәфәргалиев, Гали Сәгыев һәм Зариф Сәгыев.

Казанның завод-фабрикаларында булып торган мондый вакыйгалар һәм татар эшчеләренең катнашы турында Фатих белгәнме? Әлбәттә, белгән. Беренчедән, бу хакта бөтен Казан шаулый. Икенчедән, көрәш уты кабызучы социал-демократлар арасында Фатихның танышлары бар. Бишбалтада яшәгән Сәгадәт апасы янына барып йөрүе дә, эшче бистәләренең хәл-әхвәлләреннән хәбәрдар булып торуга ярдәм итми калмаган.

Каршы як та тик ятмый.

Сарай мәйданындагы залплар яңгыравы тынарга да өлгерми, әлеге дә баягы Рәшит казый Ибраһимов эчке эшләр министрына үтеп керә дә, аңардан кайбер вәгъдәләр алгач, татар төбәкләренә сәяхәткә чыгып китә. Уфада, Оренбургта, Троицкида була. Кызылъяр, Чистай, Буби якларын әйләнеп килә. Бай йортларда уздырылган аш-су мәҗлесләрендә милләт һәм дин, тәрәккый һәм мәгърифәт турында күп сүзләр сөйләнелә, берләшү, оешу турында киңәш-табыш корыла. Баш министр Витте исеменә мөселманнарның ихтыяҗын түбәнчелек белән белдергән петицияләр җибәрү эше башлана.

Февраль ахырларында Рәшит бабаны без Казанда күрәбез. Ул шәһәрнең атаклы байлары, либераль карашлы зыялылары, яңа фикерле руханилары белән очраша башлый.

Март башында татар сәүдә корольләренең берсе Әхмәт бай Хөсәенов өендә 60—70 кеше катнашында зур мәҗлес үткәрелә. Күп сүзләр була, күп фикер-тәкъдимнәр әйтелә. Мәҗлеснең беренче карары — пайтәхеткә петиция җибәрү. Аны язу либераль адвокат Сәетгәрәй мирза Алкинга тапшырыла. Икенчесе — карар дисәң дә ярый, теләк дисәң дә — Россия мөселманнарының съездын чакырып, бер оешма яисә партия барлыкка китерү. Кырым, Кавказ, Урта Азиянең күренекле шәхесләре белән бу турыда язышу, мәслихәтләшү эше булачак партиянең булачак идеологы Йосыф Акчурага тапшырыла.

Бу вакыйганы Фатих белгәнме? Белгән генә түгел, бәлки әлеге мәҗлескә үтеп кергәнлеген ышаныл әйтергә мөмкин. Җитезлеге бар, кызыксынучан.

Рәшит казыйның күптәнге танышы. Казанның могтәбәр затлары игътибарын да җәлеп итеп өлгерде. Өстәвенә Фатих — шәкертләр хәрәкәте лидерларының күренеклесе. Милләт хадимнәренә исә бу хәрәкәтне үз артларыннан ияртү кирәк.

Ике котып булып яшәгән социаль көч әнә шулай революция чорына килеп керде. Алар арасында тора торган социаль катлаулар да бар әле. Шәһәрне күздә тотканда, власть ияләрен аеруча борчый торганнары — приказчиклар һәм шәкертләр. Приказчиклар, әйдә, хәрәкәткә килсеннәр, оеша башласыннар, союз ясасыннар, без исә шәкертләр хәл-әхвәленә күз ташлыйк.

Авангарды «Мөхәммәдия» булган Казан шәкертләре хәрәкәтендә 9 гыйнварь фаҗигасеннән соң яңа этап башланды. Күзе ачылган шәкертләр дөньяви фәннәр кертү, коръән тәфсире, ислам тарихы укытуны таләп итүдән инде ары киттеләр. Алар мәдрәсәләрне тамырыннан үзгәртеп кору мәсьәләсен куя, ул гына да түгел, укыту-тәрбия эшләрен илдә барган политик вакыйгалар белән бәйләп карый башладылар. Ислах хәрәкәте сәяси төс алды.

Шул вакытның ярыйсы гына ышанычлы шаһитләреннән берсе М. Укмасыйны тыңлыйк: «...халык арасында без төрле партияләр — кадетлар, социалист-революционерлар, социал-демократлар, максималистлар бар икәнен аңладык. Аңладык дигәч тә программалары, тоткан юллары белән җентекле танышып түгел, исемнәрен ятладык та, кайсы партиянең кемнәргә, нинди сыйныфларга таянганын белеп алдык. Социалист-революционерлар крестьяннарга, социал-демократлар завод-фабрика эшчеләренә таяна икән. Шулай да бу ике партиянең кайсы дөрес юл белән бара, без кайсын алда күрергә тиеш,— моны аера алмый идек. Икесенең дә бара торган юлы, теләге бер төсле күренә иде».

Фатих 1905 ел башында мәдрәсә шәкерте саналса да, курсны инде тәмам иткән булып, хәлфәлек вазифасын башкара. Бер үк вакытта ул шәкерт тә: югарыда исеме телгә алынган студент Гассардан дәрес ала. Бар вакытын, бар көчен биреп башкарган эше исә — шәкертләр хәрәкәтенә юлбашчылык итү. Революция җәелә һәм тирәнәя барган саен бу хәрәкәтнең элекке хәле, элекке рәвеше канәгатьләндерми башлый. Барыннан да бигрәк таркаулык күзгә ташлана. Һәр мәдрәсәнең үз түгәрәкләре, үз оешмалары бар. Һәркайсы үзенчә хәрәкәт итә, үзенчә мөгез чыгара. Идея берлеге, оешма берлеге кирәк! Фатих һәм аның фикердәшләре Казан шәһәрендәге шәкертләрнең барысын бер оешмага туплау инициативасын үз өсләренә алалар. «Мөхәммәдия» вәкилләре бүтән мәдрәсәләрдә булалар, киңәш-табыш коралар, аларны «Мөхәммәдия»гә чакыралар.

Тора-бара мәмләкәтнең татарлар яшәгән барлык төбәкләрендәге шәкертләр хәрәкәте белән җитәкчелек итү өчен үзәк оешма, үзәк орган барлыкка китерү фикере туа.

Алга җитди сорау килеп баса: нинди юлдан барырга, нинди тактика тотарга, нинди программа буенча хәрәкәт итәргә?

Революция башлангач, Фатих бер нәрсәне аңлап ала: самодержавие деспотизмы яшәп килгәндә, мәктәп-мәдрәсәләрне үзгәртеп коруның бик үк зурдан булмаган программасын гына тормышка ашыру да, ай-һай, мөмкин микән? Әнә бит таләпләр куя башладыңмы, мөдәррисләр һәм мәдрәсәне тәэмин итә торган мәхәллә байлары куркыта башлыйлар: малайлар, азмагыз, хөкүмәт әһелләренә барып җитәр, полиция килеп басар, мәдрәсәне ябарлар.

Самодержавие белән инде сугыш башланды. Илдә яңа тәртип урнаштыруның юлларын һәм ысулын аңлатып, халыкны үз артыннан ияртергә тырышкан партияләр кыюланып киттеләр. Арада эсер дигәннәре аеруча гайрәт ора. Алар да халыкны, бигрәк тә крестьяннарны хөкүмәткә каршы күтәрү ягында. Гомуми восстаниене көтеп тормыйча, жандарм, губернатор һәм министрларны, хәтта патшаның үзен үтерү юлы белән максатка ирешү фикерен алга сөрүчеләр дә бар. Татарлардан да байтак кеше эсер булып китте. Агитаторлары мәдрәсәләргә дә килеп керделәр һәм үз иманнарын тукый башладылар.

Кем хаклы? Эсерлар әйтә: патшаны төшерәбез, республика урнаштырабыз, җирләрне крестьяннарга бирәбез, һәм шуннан социализм туа. Юк, диләр социал-демократлар, моның белән генә эш бетми әле. Властьны пролетариат кулына алып, завод-фабрикаларны халык милкенә әверелдерергә, авылда да, шәһәрдә дә кеше көченнән файдалануның чыганагын ук бетерергә кирәк, шул булыр социализм, диләр.

Мәсьәләнең нечкәлекләренә төшенеп җитмәсә дә, Фатихның зирәк акы-

лы соңгыларының хаклылыгын сизеп ала: социал-демократларга йөз тоту, эшне алар өйрәткәнчә алып бару дөрес булыр.

Сәер түгелме? Ф. Әмирханны без кызыллатмыйбызмы? Бит ул либераль карашлы рухани гаиләсендә үсте, ун ел гомере мәдрәсә диварлары эчендә узды. Иманы алышынып торса да, соңгы маягы Ш. Мәрҗани, И. Гаспринский, Р. Ибраһимов кебек милләт хадимнәре сурәтеннән күп ерак китмәгән иде. Пролетариат белән танышлыгы Яңа бистә һөнәрчесен танып-белү янсә Крестовников заводы эшчеләрен ара-тирә күрүдән узмый.

Ниһаять, Фатихның укытучысы студент Гассарны сәхнәгә кертергә вакыт җитте.

Сергей Николаевич Гассар, Казанда чиновник гаиләсендә туып, гимназия тәмам иткән һәм шактый олыгайгач, 27 яшендә университетның физика-математика факультетына укырга кергән. РСДРП(б) сафына ул Казандагы марксистик түгәрәкләрдә «пешеп чыгып» килгән булса кирәк. 1904—05 елларда инде ул губерна партия оешмасының күренекле работнигы булып җитешкән. КГЖУ[1] начальнигы рапортыннан без түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Ныклап тикшерелгән агентура белешмәләренә караганда, Гассар социал-демократик партиянең җирле комитеты карамагындагы Крестовников районында (Крестовников заводы) оештыручы вазифасын үти һәм комитетның эшлекле работнигы булып тора».

Фатих дәрес ала башлаганда, С. Н. Гассарның берсе җиде, икенчесе биш яшьлек ике улы һәм бер яшьлек кызы булган. Хатыны акушерлыкка укып йөри икән. Репетиторлыктан бүтән кәсебе һәм бүтән килере юк. Әтисе вафат, әнисе кече кызы белән үзе пенсиягә яши.

«Урталыкта» романында Гассарның без төс-кыяфәтен һәм кайбер характер сыйфатларын да чамалыйбыз. Ни хикмәттер, Ф. Әмирхан әсәрнең «герое» Хәсән Арслановны аттестатка әзерләүче репетитор студентның исемен үзгәртүне дә кирәк тапмаган.

«Сергей Николаевич,— диелә романда,— озын буйлы, озын борынлы, сап-сары озын чәчле 29—30 яшьлек бер студент иде. Аның зәп-зәңгәр күзләре һәммә кешегә генә түгел, бәлки һәммә нәрсәгә дә әллә ничек йомшак итеп, сөеп карыйлар да бик изге булып күренәләр иде». Шактый вакыт дәрес тыңлатырга йөргәнлектән, Сергей Николаевичны төрле хәлләрдә күргән булса да, Хәсән аның ачуланганын, каты сүз әйткәнен хәтерләми.

Әнә бит күңелле мәҗлесләрне яратуы һәм иренчәклеге сәбәпле, ул рус әдәбиятыннан рәтле-башлы җавап бирә алмагач, учителе беравык дәшми тора да йомшак кына тавыш белән:

— Сез, Хәсән, боларны ныграк укыр идегез... Имтихан өчен дә, гомумән, үзегез өчен дә кирәк алар,— дип куя. Хәсәнгә бу тавышны күтәреп әйтелгән шелтәгә караганда да катырак тәэсир итә: комачтай кызара ул, тирләп чыга, белгәннәрендә дә бутала башлый. Сергей Николаевич, сизгер һәм нәзакәтле кеше буларак, шәкертен кыен хәлдән чыгарырга ашыга:

— Алгебра белән ничек? Чыгара алмый калган задачаларыгыз булмадымы?

Әнә шундый кеше булган Фатихның хәлфәсе Гассар.

Сергей Николаевичны якыннанрак белгәч һәм яратып өлгергәч, Фатих, акылы беләнме, әллә күңеле белән генәме, бер хакыйкатьне сизеп ала: мәмләкәтне астын өскә китереп үзгәртергә җыенучы революционерлар һич тә канга сусаган таш йөрәкле кешеләр түгел икән лабаса. Аларның ныклыгы үз кул көче белән көн күрүче гади кешеләрне кызганудан, кимсетелгән, кыерсытылганнарның хәленә ачынудан, тартып алынган хокукларын кире кайтару теләгеннән килеп чыга икән.

С. Н. Гассарның хәлфәлеге, билгеле, гимназия программасы кысасында гына калмаган. Ул шәкертен сынаган, күзәткән һәм акрынлап үз карашларын сеңдерә башлаган. Диктант яздыргаңда, текстны төрлечә сайларга мөмкин бит. Сочинение темасын да максатка ярашлы итеп бирергә була. Рус әдәбиятын да тиешле юнәлештә аңлата аласың. Тарих турында инде әйтәсе дә юк: бер үк вакыйгадан төрле нәтиҗә чыгарырга мөмкин.

Шәкертенә ышанычы ныгып җиткәч, Гассар Фатихны агымдагы хәлләр белән таныштыра, марксизм буенча сабак бирә башлаган. Ә көннәрдән бер көнне, тәмам ачылып китеп, шәкертен яшерен эшләргә тартырга мөмкин дигән карарга килгән. Ибраһим Аитов истәлегеннән Фатихның, Гассар белән бергә, гектографта листовкалар басып таратуда катнашканлыгы билгеле.

[1] КГЖУ — Казан губерна жандарм идарәсе.

Болардан тыш, Фатихның үз остазыннан әдәп һәм әхлак дәресе алганлыгын да әйтеп китәргә кирәк. Чәнечке-пычак тотудан башлап, кешеләр белән аралашу этикетына чаклы, хәлфәсеннән ул күп нәрсә үзләштергән.

С. Н. Гассар чәчкән орлыклар бөтенләй әзерлексез туфракка төшкән дип әйтеп булмый. Без Фатихның беренчеләрдән булып, КТУМга сукмак салганлыгын беләбез. Х. Ямашев белән очрашулары да яшерен җыелышларда гына булмаган. Г. Сәйфетдинов белән якыннан танышлыгына да шикләнмәскә мөмкин.

Шәкертләр лидеры Фатих үзе дә, шул заман тәгъбиренчә әйтсәк, «демократлар» ягын куәтләгәч, үзләрен «революционер», ягъни эсер санаучы шәкертләрнең хәле бөтенләй мөшкелләнә. Яшь Әмирханның нечкә көлү, ачы ирония белән сугарылган дәлилле сүзләре «революционер»ларның кызыл күлмәк өстеннән киң каеш буып җибәргән агитаторларын тәмам хур итеп ташлый. Эсерлыкка «язылучы»ларның саны кими һәм, гомумән, «Мөхәммәдия»дә бу политик агымга җирлек тараеп кала. Таңчыларның, ягъни татар эсерлар группасының бераз соңрак, «Ислах комитеты»на көндәш итеп, «Берек» исеме астында яңа оешма барлыкка китерүләре очраклы хәл түгел.

«Мөхәммәдия» шәкертләренең социал-демократлар тәэсиренә бирелү сәбәпләрен Фатихка гына кайтарып калдыру, әлбәттә, дөрес булмас иде. РСДРП(б)ның Казан комитеты укучы яшьләр арасында эшләүгә зур игътибар биргән, моның өчен махсус кешеләр билгеләгән. 1905 елда комитет әгъзалары булып алган Х. Ямашев һәм Г. Сәйфетдинов та шәкертләрнең политик аңын үстерүгә күп көч куйганнар, күп вакыт биргәннәр.

Беренчесе турында сүз озайтырга хаҗәт юк. «Мөхәммәдия»гә ул еш килеп йөргән, яшерен утырышларында да булган, шәкертләр белән аерымаерым да сөйләшкән. Хөсәеннең монда сүзе аеруча үтемле. Чөнки ул «үз кеше»: шундый ук шәкерт булган, кайчандыр шушы ук йортта укып йөргән.

Икенчесе, ягъни Г. Сәйфетдинов хакында өстәп берничә сүз әйтми булмый.

Курку белмәс бу тынгысыз революционер 1904 ел башларында ук охранкада борчу тудыра башлаган. КГЖУ күрсәтмәсе буенча КТУМ педсоветы шул елның 12 октябрендә школадан сөреп чыгаргач, репетиторлык белән тамак туйдырганы хәлдә, Г. Сәйфетдинов, бөтен көч-куәтен җигеп, революцион эшкә чума. КТУМ инспекторы Пинегинның губернаторга җибәргән язуында мондый сүзләр бар: «...Татар укытучылар мәктәбе укучыларына һәм, ишетүемә караганда, хәтта мәдрәсә шәкертләренә юлдан яздыргыч йогынты ясавы сәбәпле, Сәйфетдиновның Казанда яшәве гаять зарарлы». Сорау алу беркетмәсендә дә шуңа охшаш сүзләр укыла: «Үз-үзен тотышы һәм телдән пропаганда ясавы белән мөселман укучы яшьләренә гадәттән тыш куәтле аздыргыч йогынты ясый». Төрмәдән язган хатыннан күренгәнчә, Галимҗанны нәкъ менә шәкертләр җыелышыннан тотып киткәннәр. Г. Сәйфетдиновның күбрәк «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә булуына, «Мөхәммәдия» шәкертләре белән аралашуына шикләнмәскә мөмкин.

Инде килеп, югарыда әйтелгәннәрне ул вакытта Уфада булса да, шәкертләр хәрәкәтенә якыннан катнашып, Казандагы хәлләрдән хәбәрдар булып торган Галимҗан Ибраһимов кебек авторитет сүзләре белән ныгытып куйыйк. 1905 елның көзенә таба оешып җиткән «Әльислах комитеты»н күздә тотып, ул болай ди: «Бу татар социал-демократлары тәэсирендәрәк барырга тырыша иде».

Ләкин ассызыклап шуны әйтергә кирәк: йогынтыга бирелү әле «Ислах комитеты» социал-демократик оешма булып мәйданга килде, ә аның җитәкчесе яшь Әмирхан большевистик позициягә басты дигән сүз түгел. Социал-демократлар белән аралашу, марксистик идеяләр белән танышу, Фатихның соңгы маягы сүнеп, алдында яңа маяк кабынуга гына китерде. Ачыграк әйтсәк, социал-демократлар йогынтысында ул, либераль-буржуаз лагерьга арка белән борылып, революцион демократизмга таба адым ясады.

## 2

Фатих һәм фикердәшләре социал-демократларга ориентация тотсалар да, либераль буржуазия һәм аның идеологлары белән дә араны өзмиләр. Бүтәнчә була да алмый. Бу сиңа эшчеләр хәрәкәте түгел. Хәл кайчан тамырыннан үзгәрер әле, мәдрәсәләр хәзергә татар байлары, татар купецлары

субсидиясендә яши. Капитал хуҗалары һәм милләт хадимнәренең чабуына ябышып бармый хәлең юк. Аларга таләпләр кую, мәдрәсә ислахы файдасына эш башкарту иң дөрес тактика булыр. Менә ни өчен Фатих либералларның хәрәкәтен җентекләп күзәтеп тора, алар үткәргән чараларның берсеннән дә калмаска тырыша. «Чистай туе» дип тарихка кергән вакыйгага катнашмый калуын, мәсәлән, күз алдына китерү кыен.

1905 елның 20 маенда Чистай ишаны Мөхәммәтзакир кызы Әсмаигалия белән Ростов-Дон мулласы Муса Җарулла улы Бигиевнең никахлары метрика дәфтәренә теркәлә һәм зурдан кубып туй үткәрелә. Кем генә юк бу туйда! Мөселман дөньясында танылган милләт хадимнәре дисеңме, Казан, Уфа, Чистай һәм башка шәһәрләрнең зур байлары дисеңме, могтәбәр имам һәм мөдәррисләр дисеңме... Атаклы Рәшит бабаның түр башында утыруы үзе генә ни тора!

Билгеле инде, бу кадәр олы затлар мәрхүм ишан һәм М. Бигиевкә ихтирам йөзеннән генә килмәгәннәр. Пылау һәм бәлеш ашау, лимон салып варенье белән чәй эчү, ике яшь йөрәккә ходайдан бәхет сорау, тигез мәхәббәт һәм озын гомер теләүләр арасында милләт кайгысын кайгырталар, якындагы бурычлар турында киңәш-табыш коралар. Казанда туган фикер — съезд җыеп, Россия мөселманнарының уртак оешмасын, төгәлрәк әйтсәк, партиясен булдыру фикере нәкъ менә шушы туйда анык бер рәвеш ала.

Фатихның урыны түрдә үк булмаса да, ишек төбендә дә түгел. Чөнки монда ул күптән инде үз кеше. Бикәч — Нәҗип абзасының балдызы, димәк, Фатихка кодача тия. Әтисе Зариф хәзрәт туйдагы могтәбәрләр арасында йөри, җизнәсе Габдулла мулла — егет ягыннан шаһитларның берсе.

Фатихны Чистайга барудан таш яуса да, туктатып кала алмаслык тагын бер сәбәп бар. Ул да булса, зифа буе, сөрмәле күзе белән егетне иләс-миләс иткән кодачасы Шәмсениса...

Май ахырларыннан башлап, съездны әзерләү кампаниясе аерата җанланып китә. Казан, Кырым, Кавказ, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Төркестан арасында язышу бара, «эмиссарлар» йөреп тора. Шул төбәкләрдән Петербургка бер төркем вәкилләр килә. Тиешле учреждениеләргә кереп, гозерләрен сөйлиләр, петиция тапшыралар. Сановникларның икеле-микеле җавапларын ризалык билгесенә юрап, мәслихәтләшәләр дә, тәвәккәлләп, ныклы карарга киләләр: җыярга съездны! Моның өчен иң кулай урын, билгеле инде, Нижний Новгород, Мәкәрҗә ярминкәсе. Ник дигәндә, империянең кесәсе дип йөртелгән бу ярминкәгә һәр елның августында миллионерлардан башлап шәкертләргә чаклы әллә никадәр мөселман килеп тула.

Карар шәкертләргә дә ирешә, съездда катнашу фикеренә киләләр, вәкилләр сайларга керешәләр. «Мөхәммәдия»дән сайланучыларның берсе, әлбәттә инде, Фатих. Дөрес, аларга беркем дә тәкъдим ясамады, беркем дә чакырып тормый. Мондый эштә чакырганны көтәргә ярый мыни? Әнә әсерләр да тик ятмый ди, берничә яраннарын ияртеп, съездга барырга булганнар икән.

Менә август урталарында Казаннан сайланган рәсми делегатлар үзләре, «чакырылмаган кунаклар» үзләре, пароход белән Мәкәрҗәгә килеп төшәләр. Бүтән төбәкләрдән дә вәкилләр килеп җитә. И. Гаспринский, кавказлы бай адвокат Г. Тупчибашев, Р. Ибраһимов та бар. Й. Акчура һәм С. Алкин да хуҗалар сыйфатында тыз-быз йөриләр. Зур байлар, исеме танылган муллалар да байтак.

Оештыру эшләре башлана. Иң могтәбәрләрдән берничә затны рөхсәт сорар өчен губернаторга җибәрәләр. Әмма вәкилләрнең борыны салынып кайта: шәһәр хәрби хәлдә булганлыктан, губернатор рөхсәт бирә алмавын әйткән икән. Алай уйлап, болай уйлап карыйлар да, буржуага бик үк хас булмаганча, кыю фикергә киләләр: рөхсәтсез үткәрергә. «Густав Струве» исемле пароходны, 300 сум түләп, бер көнгә сатып алалар да пикникка чыгу сылтавы белән съездны шунда ясарга карар итәләр.

Тагын бер кыенлык бар бит әле. Үзләрен социалист дип йөргән яшьләр дә килгән икән. Съездда катнашмакчылар. Җанҗаллы халык, мәҗлеснең ямен җибәрмәгәйләре. Ничек котылырга? Балачакта булгалап тора торган мондый манзара күз алдына килә. Берничә малай иртән иртүк торып балыкка барырга киңәшәләр. Берсенең энесе «мин дә барам», ди. Син әле кечкенә, дип, үгетләп карыйлар. Юк! Чат ябыша теге малай. Хәйләгә керешүдән бүтән чара калмый: ярар, барырсың, уятырбыз. Иртән исә шыпырт кына чыгып сызалар. Авылдан чыгарга да өлгермиләр, артларына борылып карасалар, әлеге бала, үкереп елый-елый, болар артыннан чаба. Нишләсеннәр, ияртергә мәҗбүр булалар.

Әнә шуның шикелле, олы абзыйлар иртәнге 10 да китәргә тиешле пароходны унынчы яртыда кузгатып, «малайларны» йоклатып калдыралар. Инде котылдык, ходайга тапшырып, эш башларга вакыт дип уйларга өлгермиләр, теге «малайлар», тиз йөрешле катерга утырып, куып җитмәсеннәрме! Бүтән чара юк, пароходка алалар, әмма бик каты кисәтеп куялар: бу сезгә социалистлар митингысы түгел, бу иттифак мәҗлесе, тыныгызны чыгарасы булмагыз. Югыйсә, ярга төшереп калдырачакбыз.

Котлаулар, котлашулар була, докладлар укыла, сүз алып сөйләүләр яңгырый. Нәтиҗәдә Россиядә яңа бер партия туганлыгы игълан ителә. Исем дә кушыла: «Иттифакы мөслимин». Партиянең үзәк комитеты сайлана. Россиядә яшәүче мөселманнар уналты районга бүленә, һәркайсының үзәк шәһәре билгеләнә, һәркайсына үз комитетын булдырырга кушыла. Съезд резолюция сыман нәрсә дә кабул итә. Анда без җир янсә мөселман эшчеләре турында бер сүз дә тапмабыз. Булган кадәресе шул: барлык мөселманнарны үзара якынайту, мөселманнар хокукын чикләүгә каршы закон рөхсәт иткән чаралар кулланып көрәшү һәм мәктәп, китапханә, газета-журналлар булдыру эшләрен җайга салу. Ат уйнатучылары зур байлар һәм аларга ләббәйкә дип торган миллэт хадимнәре булгач, бу «партиядән» шуннан артыгын көтәргә туры килми.

Татар социал-демократлары Мәкәрҗә ягына әйләнеп тә карамаганнары хәлдә, эсерлар, шәкерт һәм приказчик вәкилләре, күргәнебезчә, олы абзыйлар мәҗлесенә әрсезләнеп барып керделәр. Ниятләре изге иде югыйсә. Трибунага менеп, мондый сүзләрне ярып салу иде:

— Мөселманнар бер бөтен түгел, бае бар, ярлысы бар, крестьяны бар, морзасы бар. Бүре белән куйны иттифакка китереп булмаган кебек, мөселманнарны бер партия җитәкчелегендә берләштерү мөмкин түгел!

Үзләрен күрсәтү, «без яшь булсак та, мәсьәләне дөресрәк аңлыйбыз», «чын халык хадимнәре», «чын миллэт арысланнары — без ул» дип, татар дөньясының игътибарын үзләренә таба юнәлтү теләкләре дә ярыйсы гына куәтле. Әмма никадәр кыбырсынып утырсалар да, ара-тирә кычкыргалап куйсалар да, мөнбәргә менеп сүз әйтү насыйп булмый.

Фатих та мөселманнар өчен уртак партия мөмкин түгел дигән фикердә. Әгәр сүз бирсәләр, ул да иттифакчыларның «программасын» элеп алып селкеп сала алыр иде. Социал-демократлардан үрнәк алыбрак эш йөртүенә карамастан, «чакырылмаган кунак» булып катнашуына килгәндә исә, әлеге дә баягы бер сүз: шәкертләр хәрәкәте эшчеләр хәрәкәте түгел.

Үзе өчен, киләчәге өчен съездга килүенең файдасын да инкарь итеп булмый. Беренчедән, Фатих кайчандыр үзе табынган Исмәгыйль бәк Гаспринскийны, ишетеп кенә белгән күп кенә бүтән мәшһүр шәхесләрне күрде, фикерләрен тыңлады. Миллэт хадиме булырга җыена торган унтугыз яшьлек егет өчен бусы да аз түгел. Икенчедән, ул яңа партия пешеп чыккан кухняның эчендә булды. Оешу принципларын, структурасын үз күзе белән күрде. Фатих та бит Россиядәге татар шәкертләрен берләштерә торган оешма ясау уе белән яна. Программасы ярамаса да, «Иттифак»ның кайбер тәҗрибәсе ярап куяр. Ниһаять, өченчедән, су өстендәге мәҗлес либералларның чын йөзен таныр алып, моңарчы нур эчендә йөзә кебек тоелган кайбер миллэт хадимнәренең йогынтысыннан котылуга да булышмый калмый. Алар да затлы камырдан ясалмаган икән бит. Гыйззәте нәфес, яки самолюбиеләре бар. Һәркайсы үз фикерен өскә чыгарырга тырыша. Үпкәләшүләр дә, интрига да коралар.

Бу яктан мәҗлеснең ахыры аерата гыйбрәтле.

Менә «Густав Струве» пароходы кайту ягына борыла. Һәркем күләч, һәркемнең күңеле куаныч белән тулы булырга тиеш иде кебек... Сөйләсе сөйләнгән, язасы язылган, резолюция кабул ителгән, ашыйсы ашалган, эчәсе эчелгән. Барыннан да бигрәк, күптән хыялда йөргән оешма дөньяга килде. Ләкин кояш болыт астына кереп, салкынча җил исеп куйган шикелле, бер заман халыкның йөзенә пошаманга төшү галәмәте чыга. Пристаньда полиция көтеп торса? Беркетмә, карарлар, резолюция полиция кулына эләксә? Гаскәр чолганышында төрмәгә илтеп япсалар? Әүвәл пышылдап, аннары ачыктан-ачык вәсвәсәләрен тышка чыгара башлыйлар. Нишләтик бу кәгазьләрне, кая куйыйк? «Мин алмыйм,— ди И. Гаспринский,— әнә суга ташлагыз». «Яндырырга кирәк»,— ди кайсыдыр. Бер йөрәкле адәм табыла. Ул да булса, әлеге дә баягы Рәшит казый Ибраһимов: «Бирегез миңа».

Төнге сәгать унберләрдә пароход, яны белән шыгырдап, пристаньга килеп терәлә. Куркa-курка чыгалар. Ләкин... тып-тыныч, полициянең исәбендә

дә булмаган. Берәүләрнең, шактый җайсыз хәлдә калып, битләре яна башлаганын, берәүләрнең акланырга керешкәнен күз алдына китерү кыен түгел.

## 3

Мәкәрҗәдән кайткач, Фатих шәкертләр хәрәкәтен юлга салу эшенә башы-аягы белән чума. Киңәш-табыш ясала, Казан мәдрәсәләренә вәкилләр китә, бүтән төбәкләрдәге уку йортлары белән язышулар башлана.

Көз җитә, шәкертләр җыела башлый. Ләкин укуның рәте-чираты юк. Искечә укыйсылары килми, яңача укуны көрәшеп аласы бар. Илдә революция аның саен куәтләнә, үзенең югары ноктасына якынлашып килә. Шәкертләр мәдрәсәдән мәдрәсәгә яшерен җыелышларга йөриләр, митингларга чабалар.

1905 елның көзен Фатихның шактый матур, парлак һәм бәхетле чоры дип атасак та, хата булмас. Эшләр уңышлы бара. Казан мәдрәсәләрендәге түгәрәкләр берәм-берәм уртак оешма эченә керергә ризалыкларын белдерәләр. Бүтән шәһәрләрдән дә шундый ук уңай хәбәрләр килеп тора.

Ноябрь аенда, ниһаять, «Мәркәз ислах комитеты» исеме астында җитәкче оешманың дөньяга килүе рәсми рәвештә игълан ителә. Социал-демократлар лозунгысына охшатып уйланган «Уяныгыз, бөтен татар шәкертләре!» дигән чакыру белән башлана торган мөрәҗәгать Оренбург, Уфа, Чистай, Буби, Кырым һәм Себер мәдрәсәләренә җибәрелә. 29 ноябрьдә җилем басмада яшерен рәвештә чыгарыла башлаган атналык «Әльислах» газетасының беренче саны дөнья күрә. Аның да исеме астында шул ук сүзләр укыла: «Уяныгыз, бөтен татар шәкертләре!».

Кыскасы, барысы да җирле җирендә. Барысы да зурдан кубып эшләнә. Комитетның хәтта түгәрәк печате дә бар. Печать кенәме әле! Партия урынын тота торган җитди оешма гимнсыз була ала мыни? Гарифҗан Мостафин «Беренче сада» дип телгә кергән җыр яза, «Икенче сада» дигәнен Муллаәхмәт Бәдигый исемле егет чыгара. Шәкертләр ятлап алалар да гимн итеп җырлый башлыйлар:

Кояш чыкты, нур балыкты,
Тәрәзәдән өйгә аркылды.
Ятма йоклап, уян, шәкерт,
Кузгалырга вакыт җитте!

«Бөйлә золмың даим булса, и Николай, аңлагыл, күрәчәгең күрсәтерләр балалары татарның» дигән сүзләрне эченә алган җыр да популяр булып китте. «Әльислах»та хәтта «Марсельеза»ның да тәрҗемәсе басылып чыга. Көен отып алып, шәкертләр аны да җырларга керешәләр.

Революция дулкыннары аның саен куәтләнә бара. Забастовка, митинг, демонстрацияләр ешая. 17 октябрь манифесты да бу дулкынны туктата алмый. Большевиклар эшчеләрне коралллы восстаниегә әзерлиләр. Халык милициясе оештырыла башлый. Милициягә, эшчеләрдән кала, студентлар, гимназия укучылары һәм күпмедер санда шәкертләр языла. «Мөхәммәдия» шәкертләренең алгы сафта барганына шикләнмәскә мөмкин. 3 ноябрьдә булган коралллы бәрелештә, Дума бинасына бикләнеп, хөкүмәт гаскәренә каршы торган каһарманнар арасында берничә шәкертнең дә булганы билгеле.

Фатих, һичшиксез, митингларга да йөргән, демонстрацияләрне дә тамаша иткән. Әмма аның, корал тотып, турыдан-туры бәрелешләрдә катнашканлыгы турында мәгълүмат юк. Күрәсең, ул, берничә иң якын көрәштәше белән күбрәк «штаб»та булган, шәкертләр хәрәкәтенең дилбегәсен кулында тоткан.

Әле бит шәкертләрнең үзләренә генә караган максатлары һәм бурычлары да бар. Фатих кулы белән әнә булачак оешманың программа проекты язылды. Аны мәдрәсәләрдә укыйлар, тикшерәләр. Россия шәкертләренең беренче съездын чакыру буенча хәзерлек эшләре дә башланды. Әлеге проект шунда каралачак һәм гамәлгә кертеләчәк.

Ислах өчен көрәш инде кабынды. Съездны һәм шәкертләр «партия»сенең рәсми рәвештә туганын көтеп торып булмый. Мәдрәсә башлыкларына һәм мәхәллә байларына бүген үк таләпләр куярга һәм шуларның тормышка ашырылуы өчен тартлашырга кирәк. «Казан мөхбире» газетасының 1906 елгы 19 март санынннан без түбәндәге юлларны укыйбыз: «17 үктәбердә Казан

шәкертләре иттифакан[1] хәзрәтләренә мәдрәсәләрнең һәммә җәһәтенә дә ислах кыйлуларыны сорап гариза биргәннәр. Шул матлабларына җавап бирмәенчә, дәрес укымаска булып, дәрес ташлаганнар. Күбрәк мәдрәсәләрдә бу көндә забастовка (дәрес ташлау) дәвам итмәктәдер».

Иттифакчылар да тик ятмыйлар. 17 октябрь манифестыннан соң кыюланып китеп, Сәетгәрәй Алкин агымдагы хәлләр турында сөйләшер өчен мәҗлесләр ясарга губернатордан рөхсәт ала. Төп бурыч — «Мөселман иттифакы»ның программасын эшләп, чираттагы съездда тәсдыйк иттерү һәм булачак Дума вәкилләрен сайлауга әзерләнү. «Сарай» номерында, Әхмәт бай һәм Сөләйман Аитов өйләрендә шундый мәҗлесләр булып уза. Үрнәк өчен ике программа игътибар үзәгенә куела: кадетлар һәм октябристлар программасы. Эсерларның һәм бүтән төр демократ яшьләренең кирегә сукалаулары, тавыш куптарулары сәбәпле, мәҗлесләр бик үк шома үтмәгәннәр. Шулай да берсе әйбәт кенә узган, һәм Габдулла мулла Апанаев ахырда болай дип сөйләгән:

— Ошбу мәҗлесемез әлхәмделилла бик гүзәл булды. Сәбәбе исә — бу кичә социал-демократ (эсерлар белән бутый — И. Н.) мәзһәбендәге яшьләр юктыр. Килгәннәре дә җиңелү сәбәплеме, әдәпкә килделәрме, сөйләмәделәр.

Әнә шул мәҗлестә кадетлар программасына тукталалар. Чәчен китәреп, сакалын кыскартып, мыегын нечкәртеп, кәләпүш кидерергә карар кылына. Бер үк вакытта икенче «съезд»ны үткәрүгә әзерлек эшләре дә бара. Ниһаять, урыны һәм вакыты тәгаен ителә: 1906 елның 15 январе, Петербург.

Бу юлы инде таңчылар һәм ислахчылар да рәсми төстә катнашачак. Күрәсең, «Иттифак»ның башлыклары эсерлар ничаклы куркыныч сүзләр сөйләсәләр дә, ул кадәр үк хәвеф-хәтәр китерә алмаганлыкларын, ислахчыларны исә үз артларыннан ияртергә кирәклеген абайлап алганнар.

Фатихның Петербургка китү тарихына карата М. Укмасый мондыйрак мәгълүмат бирә.

«Казан шәкертләренең уртак бер җыелышында теңкәгә тигән шул ук нәрсәне — ислах мәсьәләсен көн тәртибенә куеп тикшергәннәр. Чыгып сөйләүчеләр күп булган, һәркайсы үз карашын белдергән, үз планын тәкъдим иткән.

Менә Фатих Әмирхан сүз ала һәм мондый фикер әйтә:

— Мәдрәсә ислахы матди нигезсез мөмкин түгел. Ул акчага бәйле. Мәдрәсәләрне асраучы татар байлары без таләп иткән ислахка беркайчан да риза булмаячаклар. Без үз ниятебездә калсак, алар мәдрәсә файдасына бер тиен дә бирмәячәкләр... Шуңа күрә Петербургка вәкилләр җибәрергә, хөкүмәткә керергә, татар халкыннан җыела торган земский сборның мәгарифкә китә торган процентын мәктәп-мәдрәсәләр файдасына калдыруны таләп итәргә кирәк.

Укмасый әйтмешли, бу «шәп фикергә таң калган» шәкертләр, рухланып китеп, вәкилләр сайлый башлаганнар. Ахыр чиктә бер тавыштан Фатих сайланган. Барып кайту, ашау-эчү чыгымнары өчен һәр шәкерттән 50 шәр тиен акча җыярга карар ителгән. Фатих, янәсе, махсус җөббә тектереп алган да Петербургка китеп барган.

Монда — чыны һәм уйдырмасы бергә катыш.

Әлбәттә, Казан шәкертләренең уртак җыелышы булган. Фатихны вәкил итеп сайлаганнар. Ләкин министр янына керү өчен түгел, бәлки «Мөселман иттифакы»ның икенче съездында катнашыр өчен. Юл чыгымына акча да җыйганнардыр, Фатих өс-башын да рәтләгән булыр. Ләкин ул җөббә тектермәгән, бәлки менә дигән пальто һәм яңа костюм булдырган.

М. Укмасый китергән мәгълүматларның кыйммәте шунда: без Фатихның ул вакытта ук татар мәктәп-мәдрәсәләрен хөкүмәт уку йортлары белән хокукта тигезләү тарафдары булганлыгын аңлыйбыз. Яшь Әмирхан фикеренчә, идарәсе үз кулыбызда калган хәлдә, уку йортлары дәүләт хисабына яшәргә тиешләр. Бу хокукны исә министрга баш ору белән түгел, бәлки «Мөселман иттифакы»ның программасына һәм съездның карарына керттереп, чакырылачак Дәүләт Думасы көче белән генә хөкүмәттән яулап алырга мөмкин.

...1906 елның 12 январе. Казан вокзалы Петербург съездына китүче делегатларны озатырга килгән мөселманнар белән тулы. Руслар да байтак: чиновниклар, гаскәриләр. Хәрби оркестр уйнап тора. Бу нинди тамаша? Оркестр белән озатылырлык, хөкүмәт әһелләренең дә игътибарын җәлеп итәрлек бик кирәкле һәм кадерле кешеләрмени соң безнең иттифакчылар? Түгел

[1] Иттифакан — бергәләп, сүз берләштереп.

икән, оркестр да, гаскәри һәм чиновниклар, шулай ук русның бүтән зур кешеләре дә икенче урынга күчерелү сәбәпле Казаннан китеп баручы губернатор Рейнботны озатырга килгәннәр икән. Әнә шул очраклылык безнең вәкилләрне озатуга да тантана өстәгән икән.

Шунысы кызык: бу ике төркем бер-берсенә битараф калмыйлар. Әхмәтҗан бабай Сәйдәшев, Рейнботка мөрәҗәгать итеп һәм рус сүзләрен ватып-сындырып, барлык мөселманнар исеменнән губернаторга саулык, яңа урында яңа уңышлар теләде. Рейнбот җавап сүзендә рәхмәт әйтә һәм Казанны беркайчан да онытмаячагын белдерә.

Вокзалның бер башында, милләт хадимнәре белән патша чиновникларының төчеләнеп бер-берсенә мәхәббәт игълан итүләренә аз гына да игътибар итмәстән, 150 ләп шәкерт үз вәкилләрен уратып алганнар. «Алар,— диелә «Казан мөхбире»ндә чыккан репортажда,— үз вәкилләренә бик мөһим эштә игътимад[1] иткәнлекләрен вә ничә мең шәкертнең аларга максудларында ярдәм итәчәкләрен сөйләделәр. Вәкилләрдән Фатих әфәнде Әмирханов өсләренә алган эшнең бик әһәмиятле икәнен сөйләде вә бар куәте илән шуңар тырышачагын вәгъдә итте».

Колокол өч мәртәбә суккач, поезд акрын гына кузгала, тизлеген бик үк арттырмыйча, алга таба шуыша башлый. Озатучылар вагоннарга ияреп баралар, соңгы сүзләрен әйтеп калырга ашыгалар, хушлашалар, кул болгыйлар, баш киемнәрен салып селкиләр. Шәкертләр исә, куакка сырган корт иле кебек, вәкилләре утырган вагонга ияреп барган килеш, яшь күкрәкләрдән ургылып чыккан гайрәтле тавышлары белән оркестрны күмәләр:

— Яшәсен шәкертләр!

— Яшәсен ислах!

— Яшәсен хөррият!

...15 енә билгеләнгән мәҗлес, хөкүмәт органнарыннан рөхсәт ала алмау сәбәпле, 17 январьда гына ярым яшерен сурәттә ачыла. Дөрес, делегатлар моңарчы да кул кушырып утырмадылар. Билгеләнгән кешеләре рөхсәт артыннан йөргән арада мөселман байлары үткәргән аш-су мәҗлесләрендә булдылар, «Өлфәт» газетасы әйтмешли, бер-берсенә «дустанә мәхәббәтлек» күрсәттеләр, мактадылар, макташтылар.

Унҗидесеннән башлап егерме бишенә кадәр төрле урыннарда рәсми утырышлары була. Өч мәсьәлә тикшерелә: программа проекты, устав һәм булачак думада кайсы партия белән бару. «Картлар» фикере, билгеле инде, бер эздән барган, «яшьләр» исә кирегә сукалаганнар. «Яшь зыялыларыбыз,— диелә «Казан мөхбире»ндә,— бөтен мөселманнарның бер генә гомуми хизыб[2] берлә оешып йөрүләре мөмкин булмаганны исбат итәргә тырыштылар». Кемнәр! Билгеле инде, таңчылар һәм ислахчылар. Соңыннан язылган бер истәлегендә Ф. Әмирхан үзе дә моны раслый: «...без, съездга оппозициядә торган бернечә яшь җилбәзәкләр (шулар арасында мин дә), бюро мәҗлесләренең бер икесендә үзебезнеңioktаи назарларны[3] әйтеп калырга теләдек». Димәк, төп мәсьәләләр буенча безнең Фатих та чыгып сөйләгән. Бөтенроссия татар шәкертләренең лидеры сыйфатында килгәнлектән, ул, билгеле инде, авыз йомып кала алмый иде. Нәрсә сөйләгән, ничек сөйләгән, бу турыда ул язмый, яшьләрдән берсе (Ф. Туктаров булырга мөмкин) тарафыннан сөйләнгән озын, усал һәм шактый буталчык речьне генә телгә ала. Бу нотык вакытында мәҗлестә шау-шу күтәрелгән, протест авазлары яңгыраган, ораторны туктатырга азапланганнар. Бернечә мөхтәрәм иттифакчының, шул исәптән И. Гаспринскийның, салкын канлылык саклап калулары һәм бүлдермәскә чакырулары аркасында гына ул нотыгын очлый алган. Фатих сөйләгәндә дә шундый ук шау-шау кузгалган дип уйларга кирәк.

23 январь көнне Петербургның тәрәккый пәрвәр бае Галим Максудов өендә уздырылган мәҗлестә соңгы мәсьәлә буенча да карар кабул ителә: сайлауларга кадетлар белән бергә барырга. Шуннан соң Фатих кабат сүз ала һәм, мәдрәсәләрне ислах итү турында тәпле һәм кайнар речь тотканнан соң, мәктәп-мәдрәсәләр мәсьәләсен көн тәртибенә кертергә һәм, фикер алышып, карар кабул итәргә тәкъдим кертә. Съезд шәкертләр башлыгының тәкъдимен кире кага һәм бу мәсьәләне өченче съездга калдырырга карар итә.

[1] Игътимад — ышаныч, таяныч.
[2] Хизыб — партия.
[3]Ioktаи назар — караш, фикер.

Бер-бер артлы ике телеграмма сугыла һәм «Казан мөхбире» газетасында басылып чыга.

«Петербург җыелышы.

Сәр мөхәррир [1] Сәетгәрәй Алкиннан алынган телеграм:

Съездга рәсман рөхсәт итмәсәләр дә, алай да булды. Мөселманнар партиясенең програмын ясады. Думага беренче сайлауда конституционно-демократический партия белән бергә хәрәкәт итәргә карар бирелде.

Шәкертләр вәкиленнән (Ф. Әмирханнан — И. Н.) алынган телеграм:

Җыелулар дәвам итә, мәдрәсә мәсьәләсе 15 нче августка кичектерелде».

Съезд тәмам, делегатлар таралып китәләр. Фатих белемен арттыру максаты белән күпмедер вакытка Петербургта торып кала, ниндидер курсларга йөри.

Нәкъ шушы вакытларда Фатихның биографиясенә яңа сәхифә өстәячәк бер вакыйга була: ул прогрессив карашлы дәүләт хезмәткәре Заһид Шамиль белән таныша. Бу кеше балалар өчен Мәскәүдә бер журнал чыгару артыннан йөри икән. Ул, күрәсең, съезд мәҗлесләрендә чын интеллигент кыяфәтле яшь егетнең төпле һәм үткен чыгышларын тыңлаган. Ә соңыннан, танышып аралаша башлагач һәм бу егетнең сәләтле, хәзерлекле һәм киң карашлы икәненә ышанып җиткәч, булачак журналның секретаре вазифасын тәкъдим иткән.

## 4

Фатих, әйдә, Петербургта юансын, без Казанга кайтыйк.

Февраль башларында шәкертләр хәрәкәте тагын да киңрәк колач ала. Укучы хәтерлидер, без шәкертләрне мөдәррисләргә һәм мәхәллә байларына таләпләр язып керткән һәм, җавап булмый торып, дәрескә кермәскә карар иткәннәре хәлдә калдырып киткән идек. «Мөхәммәдия» идарәсе һәм мәдрәсәне карауччы байлар бу таләпне кабул итмәгәннәр һәм башлап йөрүче дүрт шәкертне куарга карар иткәннәр. Инде сүзне «Хәбәрче Т.» имзасы белән «Казан мөхбире» газетасының 27 февраль санында мәкалә бастырган кешегә бирик. «Дамелля һәм берничә мәхәллә бае мәдрәсә идарәсенең әнә шул карарын белдергәч,— дип яза ул,— игъдади 1 вә 2 нче сыйныфлар вә рөшдия 4 нче сыйныфтан 20 гә кадәр шәкерт боларның мәдрәсәдән чыгарылуына разый булмаячакларын вә аларны чыгартмаячакларын вә, алар чыгарылса, үзләре дә чыгарачакларын ихтилал вакытындагы тавышлар илән иглан иттеләр.

Мәхәллә кешеләре үзләре коты очкан җиз төймәләрдән шәкертләр дә куркыр өмеде илә палисә чакыртамыз дип иглан иттеләр. Шәкертләр чакыртамыз дигәннән генә курыкмаганнан, байларның гайрәте интикам [2] тамырлары кузгалып, мескен шәкертләр өстенә пристав, 10 кадәр городовойлар китерделәр.

Алар, килгәч тә, шәкертләрне чыгарырга төрле тавышлар илән сөйләп карасалар да, сәгать 4 ләргәчә (Ислах комитетыннан катгый хәбәр алганга кадәрле, имеш) тәвәккыф [3] иттеләр.

Соңра ул 4 шәкерт чыкты вә башка сыйныфташлары өйләренең лампа вә тәрәзәләрене ватып, мәдрәсәне хәрабә хәлендә калдырып, «Беренче сада», «Икенче сада» дигән мөнәҗәтләрне җырлап, 82 шәкерт чыгып киттеләр».

Сиксән ике эчендә Фатих булмаган кебек (ул әле — Петербургта), куылган дүрт шәкерт арасында да ул юк. Укучыда сорау туарга мөмкин: шактый еллар буе шәкертләрне аздырып килүче бу «кызыл авыз»га ничек бер дә кисәтү ясалмады, җәза бирелмәде, ничек шушы көнгә кадәр мәдрәсәдән куылмады икән? Кисәтү, әлбәттә, булган, җәза да бирелгән («Сахалин»да, ягъни карцерда утырып чыкканын хәтерлик). Куылу мәсьәләсенә килгәндә, исемфамилия ягыннан адашы Ф. Әмирхан II [4] болай дип яза: «Галимҗан Баруди Фатихның атасы Зариф мулла белән якын кеше, Зариф мулла үзе дә — Казанның иң атаклы муллаларыннан берсе. Шулай булгач, Зариф мулла улы Фатихны ничек итеп бу шартларда мәдрәсәдән куарга? Калдырырга тагын

---

[1] Сәр мөхәррир — баш редактор.
[2] Гайрәте интикам — үч алу гайрәте.
[3] Тәвәккыф — тукталып тору.
[4] Ф. Әмирханның җизнәсе Габдулла мулла Әмирхановның энесе. Соңрак «Ф. Әмирхан» дигән имза белән яза башлый.

ярамый! Менә шуңар күрә дә Галимҗан Баруди, тиешле шәкертләрнең исемлеге төзелгәнгә кадәр ук, Зариф муллага «үз ихтыяры белән» Фатихны мәдрәсәдән алырга киңәш бирә. Башка дус-ишләре дә бу киңәшне яклыйлар. Нәтиҗәдә, русча укырга керешү сылтавы белән Фатих мәдрәсәдән чыга».

Моңа өстәп шуны гына әйтергә мөмкин: күптән инде шәкертлектән чыккан Фатих 1905-06 уку елы башлангач, рәсми рәвештә дә мәдрәсә белән арасын өзгән.

Менә бервакыт безнең Фатих Петербургтан кайтып төшә дә кырык төрле эш-мәшәкать эченә чума.

Кичектермәс беренче эш — «Мөхәммәдия»не ташлап чыккан шәкертләрне торакка урнаштыру, тамак якларын кайгырту, русча укуларына булышлык итү. Моның өчен, билгеле, акча кирәк. Фатих кайтканчы ук шәкертләр файдасына иганә җыю кампаниясе башланган була. «Казан мөхбире» газетасы акча бирүчеләрнең исемнәрен һәм керткән суммаларын игълан итеп тора. Шунысы игътибарга лаек: бу кампания азмы-күпме укымышлы татарлар катышы белән генә чикләнмәгән. Иганә кертүчеләр арасында мәсәлән, С. Н. Гасеар да бар. Казан университеты студентлары да, үзара акча җыеп, Ф. Әмирхан кулына тапшырганнар икән.

Икенче мөһим эш — бөтен татар шәкертләренең 1 съездын әзерләү. Программа һәм устав төзелеп ята, «Әльислах» оешмасының урыннардагы шагъбәләрен, ягъни бүлекләрен булдыру буенча эш алып барыла. Мәркәз комитетның «Казан мөхбире»ндә чыккан белдерүендә мондый сүзләр бар:

«Шәкертләр съезды хакында комитетның күптәнге карары булса да, ошбу көндә мәдрәсәләр илә шәһрәт тотмыш йирләрнең һәр каюсында тәэсис[1] иделмәктә улан шагъбәләр карар тапканчы игълан итми торырга мәҗбүрдер. Май числосына кадәр ничек вә кайда булачагыны гомум шәкертләргә игълан идәчәктер.

«Әльислах».

«Ислах» оешмасы белән Ф. Әмирхан бу вакытта атасы йортында яшәп җитәкчелек итә. Комитет утырышлары, «Әльислах» газетасын язу, гектографта басу, листовка һәм өндәмәләр җитештерү эшләре төрле урыннарда — пәрәмәчләп чәй эчү сылтавы белән «Сарай» номерында, мәдрәсә хөҗрәләрендә, аерым өйләрдә, әйтик, С. Аитов яисә Вахит мәзин йортларында башкарылган.

Зариф белән Фатихның бер-берсенә мөнәсәбәтләре күптән киеренке төс алган иде инде. Хәзер исә, Фатих мәдрәсә белән арасын өзгәч һәм Петербург якларыннан урап кайткач, ата белән угыл арасындагы каршылык үзенең югары ноктасына якынлаша. Икесендә дә характер бер чама, икесе дә әйткән сүзеннән бер карыш та чигенми. Хәзрәтнең дус-ишләре, яраннары, матди ягын тәэмин итүче байлар мәхдүмнең тәмам бозылып, кып-кызыл «социалист» булып җитүе турында бәреп әйтә торалар. Өстәвенә Фатих энесе Ибраһимны аздыра, үз артыннан ияртә.

Бу сәбәпләр әлек тә бар иде. Хәзер инде каршылык сәяси төс алды, капма-каршы ике политик агымның бер гаилә эчендәге чарпышына әверелде. Әнә бит Зариф хәзрәт иттифакчылар арасында үз кеше булып йөри, кадетларга күңел баглап өлгерде. Әхмәт бай өендәге мәҗлестә, кияве Габдулла Әмирхани белән берлектә, Зариф мулла да булган иде. Булган гына түгел, бәлки кадетлар программасын яклап сүз дә әйткән иде. Улы исә, социал-демократлар мәсләген алга сөреп, «Иттифак»ны да, кадетларны да эштән чыгарып хурлый. Петербург мәҗлесендә дә, кирегә сукалап, бөтен съездны үзенә каршы куйган.

Ата белән угыл өйдә еш кына әләгешеп алалар, пычакка-пычак килгән чаклары да була. Фатихка бердәнбер юл калып бара: өйдән китеп, мөстәкыйль яшәү. Ләкин ана кызганыч. Әнә бит ул, ике яктан очкан укларның күкрәгән җәрәхәтләвенә карамастан, араларына керә, килештерергә тырыша.

Көннәрдән бер көнне шундый бәрелеш вакытында Зариф хәзрәт, күрәсең, кызып китеп, Фатихка ишек күрсәткән. Соңгысында да горурлык җитү: ишекне каты ябып чыгып китә. Ф. Әмирхан Пнең әйтүенә караганда, Фатих, Собачий переулокта яшәүче бер рус гаиләсеннән бүлмә алып, шунда күченгән. Истәлекче сүзләре «Урталыкта» романы белән дә раслана. Әсәр Хәсән Арслановның нәкъ шул урамга, гимназиядә укый торган кызы булган бер рус хатынның буш бүлмәсенә күчеп килүе белән башланып китә. Дөрес, Хәсән

[1] Тәэсис — нигезләү.

белән Фатих арасына тигезлек билгесе куярга ярамый. Шулай да, Г. Флоберның «Мадам Бовари — ул мин» дигәне кебек, әдип күпкырлы характерының аерым сыйфатларын героена күчерә икән, бу бер дә гаҗәп түгел. Хәсәнгә кагылышлы кайбер шәхесләр дә, тормыш-көнкүреш вакыйгалары да, һичшиксез, Фатихның үз тормыш тәҗрибәсеннән алынган.

Мөстәкыйль яшәи башлагач, Фатих бәйдән ычкынгандай була. Ни әйтсәң дә, егермесен тутырып, егерме бергә чыккан егет бит ул. Тамырларында Морад хәзрәт, Әмирхан, Хөсәен һәм Зарифлар каны йөгерә. Буйга озын булмаса да, гәүдә килешле, өс-баш заманча, биткә дә ярыйсы чибәр.

Моңарчы да Фатихның зыялы егетләр һәм кызлардан танышлары байтак иде: Габитовлар, Саиновлар, Терегуловлар, Әхмеровлар... Әмма рус кызларыннан танышлары юк иде.

Фатих күчеп килгән өй хозяйкасының да бәлки гимназистка кызы булгандыр. Гимназистка икән, аның сабакташлары була, килеп йөриләр. Фатих та бәлки, Хәсән кебек, хуҗа кызының кавалеры сыйфатында театр яисә концертка баргалагандыр. Әлекке әшнәләре дә бит яртылаш рус даирәсендә яшиләр: кайсы гимназистка, кайсы курсистка. Фатихның русчасы хәзер ару гына. Ара-тирә хаталар җибәрә-җибәргән, әмма сакланыбрак сөйләшсә, рус гимназисткасының игътибарын җәлеп итәрлек хәле бар.

М. Укмасый «Музуров кунакханәсе»ннән номер алып тора башлаган Фатихның бер рус кызы белән сөйләшеп утырганлыгы турында яза. Бер таныш кызының Мария исемле булганлыгы хакында да риваять бар. Архивта саклана торган хат шулай ук кызыклы. 1908 елның 28 сентябрендә аны Ярославльдән С. П. Смирнова дигән укытучы кыз язган. Эчтәлегеннән күренгәнчә, ул Казанда укыган, татар яшьләре, аерым алганда «Соня Кулахметова» (Гафур Колахметовның сеңлесе Сафия) белән аралашкан.

Хаттан бу туташның Фатихны хөрмәт иткәнлеге, дус күргәнлеге, хәтта ярата башлаганлыгы сизелә.

«Җәйдән соң сезнең тормыш гадәти эзенә төшкәндер дип беләм: язасыздыр, укыйсыздыр, сезнең инициатива белән милли кичәләр, спектакльләр үткәреләдер. Бер генә кичне булса да иске дуслар арасында уздырыр өчен әллә ниләр бирер идем». «Мин сезне еш искә төшерәм». «Миңа язып торуыгызны үтенәм, Фатих, сезнең хатларга шат булачакмын». «Үзегезне күрсәң иде, яздан соң шактый үзгәргәнсез дип беләм. Карточкагызны еш карыйм, әмма ул бит акылга да, йөрәккә дә күп нәрсә әйтми торган җансыз кәгазь».

Шактый еш һәм тиз гашыйк була торган Фатих 1906 елның яз, җәй һәм көз айларында татарыннан һәм русыннан, кызлардан һәм кияүдәгеләрдән байтак хатын-кыз белән мавыгып алган дип уйларга туры килә. Бәлки ул да «Кадерле минутлар»дагы Рәшат кебек, Кабан күле ярында берәр Аля белән, орынырга да базмыйча, әмма үзен чиксез бәхетле хис итеп, таң аттыргандыр, кызны озатып куйгандыр. Кереп китәр алдыннан, кыз үзе тәҗрибәсез иреннәре белән Фатихның ирен кырыеннан үбеп алгандыр. Бәлки яңа гына кияүгә чыккан берәр Хөршитның мәхәббәте Фатихка баглы калгандыр. Кем белә, бәлки шул Хөршит кебек бер яшь ханым, сөйгәнен соңгы мәртәбә күреп калыр өчен, кузгалып өлгергән паромга сикергәндер...

Укучының, аптырый төшеп, болай уйлавы мөмкин: Шәмсениса туташны онытты мыни инде Фатих? Аңа хыянәт иттеме? Юк, онытмады да, хыянәт тә итмәде. Беренчедән, Шәмсениса еракта: күрешү, сөйләшү, бергәләп таң аттыру ихтыяҗы туган саен Чистайга чыгып чабә алмыйсың. Икенчедән, ул вакытта әле Чистай кызына карата туган хисе Фатихка гадәти бер мавыгу булып тоелган, бу хиснең чын мәхәббәт булганлыгы әле аңына барып җитмәгән.

1906 елның язын һәм җәен Фатих театр һәм концертларда, танцы һәм аш-су мәҗлесләрендә, дача һәм пикникларда гына үткәргән, күбәләк кебек, чәчәктән-чәчәккә күчеп йөргән, еш мавыккан, еш суынган икән дип уйларга ярамый. Болары да булган. Әмма алар искиткеч энергиягә, эшне тиз һәм җиңел башкара алу сәләтенә ия булуы сәбәпле, Фатихның шәкертләр хәрәкәтендә лидерлык итүенә кимчелек китермәгән.

Шәкертләрнең I съездына кызу әзерлек бара. «Әльислах» газетасы ай саен ике тапкыр чыгып тора. «Басылган» материалларның яртысы — Фатих иҗаты.

1906 елның 10 маенда, ниһаять, Россия татар шәкертләренең I съезды ачыла. Казан, Уфа, Оренбург, Әстерхан, Буби, Троицк, Самара һәм Себер мәдрәсәләреннән килгән утызлап вәкил катнаша. Съезд уздыруга рәсми рөхсәт-фәлән юк. Шуңа күрәдерме, әллә инде беркадәр «Иттифак» съездына охша-

тыпмы, күңел ачарга чыгу сылтавы белән съездны Кабан күле өстендә көймәләрдә ачып җибәрәләр.

Өч мәсьәлә карала: 1) Мәдрәсәләр ислахы; 2) Шәкертләр хәле; 3) Хәрәкәтнең методлары. Ислах хәрәкәтендә активлык күрсәткән һәм тора-бара Фатихның якын дусларыннан булып киткән Ибраһим Биккулов болай дип язды: «Бу съездны «Ислах комитеты» җыя. Ләкин бөтен программасы, докладлары, шул җөмләдән мәдрәсәләрне ислах турындагы доклад,— һәммәсе Фатихның үзе тарафыннан, яки аның юл күрсәтүе буенча эшләнәләр. Съездның рәисе, рухы Фатих була».

Менә «съезд» тәмам. Оешманың киләчәктәге эшчәнлеген, әгәр шулай әйтергә яраса, стратегия һәм тактикасын билгели торган зур гына карар кабул ителә. Вәкилләрнең һәркайсы аңа имзасын куя. «Әльислах комитеты» рәсми рәвештә бөтенроссия татар шәкертләренең үзәк җитәкче органы итеп таныла. Карарда тагын бер пункт бар: оешманың матбугат органын легаль төстә чыгарырга, моның өчен мая тупларга, әзерлек эшләренә керешергә. 1907 елның октябрендә рәсми чыга башлаячак «Әльислах» газетасы әнә шул карарның нәтиҗәсе иде.

1906 елның май һәм июнь айлары да Фатих тормышында чагыштырмача хозур, парлак һәм бәхетле чор булды дисәк, шаять ялгышмабыз. Мәдрәсәнең тынчу һавасыннан һәм атасы йортындагы җәнҗаллардан котылып, якты дөньяга чыкты, хөр яши башлады. Аннан да бигрәк, шәкертләр хәрәкәте күрелмәгән колач алды, организацион яктан да анык рәвешкә керде. Дилбегәне үз кулында тотып, хәрәкәткә керткән өлешенең сизелерлек булганын тоеп тору егерме яшьлек егет өчен азмыни? Татар милләте, дөресрәге, аның үз кул көче белән яши торган күпчелеге, бәхете хакына көрәшә торган милләт хадиме булырга теләүче Фатихның хыяллары тормышка ашып килә түгелме?

Тик бер нәрсә җитми хәзергә. Ул да булса — о б р а з о в а н и е. Мәдрәсә г ы й л е м е белән — никадәр ул тирән булмасын — бүген ерак китә алмыйсың. Фатихның якын елларга исәп иткән программасы шул: тиешле имтиханнарны тапшырып, өлгергәнлек аттестаты алу. Аннары — университет, юридик факультет.

Ләкин быелгы укуы белән Фатих бик үк мактана алмый. Әллә ничаклы эш-шөгыльне берьюлы тигез итеп алып бару, хәтта аның көч-куәтенә ия булган кеше өчен дә җиңел түгел. Быелгы сабаклары беркадәр «Урталыкта» романындагы Хәсәннекен хәтерләтә. Аннан-моннан гына караштырган хәлдә Сергей Николаевич каршына бару оят. Дәрес арты дәрес кала. Гассарның зәңгәр күзләрен текәп, сүзсез генә шелтәләп каравы Фатихны да кызарырга мәҗбүр иткәләгән дип уйларга кирәк.

Фатихның 1906 елгы язы һәм җәе берьюлы ике кояш чыккандай balкып узган дисәк, шулай ук бик дөрес булмас иде. Борчулар да туып торган. Хәтта җитди, хәвефле борчулар. 6 март хатыннан түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Бу көннәрдә Казан башыма тар булып тора: Йосыф Акчураны арестовать иттеләр, хәлфәм Гассарны арестовать иттеләр, бәлки үземне дә ошбу көндә итәрләр». Дөрес, С. Н. Гассар бу юлы төрмәдә утырып калмаган. Жандарм идарәсе начальнигының губернаторга җибәргән кәгазендә болай диелә: «Ул вакытта әле 1035 статья буенча сорау алу өчен формаль нигезләр булмаганга, кулга алыну аны тетрәткәнгә һәм, күзе яшьләнгән хәлдә, азат итүне үтенүен, революцион даирә белән арасын өзәргә вәгъдә бирүен һәм, ниһаять, сырхаулыгын исәпкә алып, ул азат ителде, әмма өстеннән җентекле яшерен күзәтү билгеләнде».

Фатих тынычланырга өлгерми, 17 март көнне «Әльислах комитеты» әгъзасы Нургали Маминны кулга алалар. Ә бит комитетның язу-сызу эшләре, газета чыгару әсбаплары һәм төрле материаллар аңарда саклана иде!

Шуннан соң безнең Фатих ярым легаль хәлгә күчә: дусларында кунгалап йөри, бүлмәсен алыштыра, туган йортына кайтканда, шәһәр ягындагы янәшә урамнан бакчалар аша арт яктан керә башлый.

Н. Мамин, күрәсең, беркемне дә сатмаган. Фатих һәм аның фикердәшләре полиция кулына эләкми калалар. Тормыш элекке эзенә төшкәндәй була. Әмма озакка түгел...

21 июньгә каршы төндә С. Н. Гассарга тентү белән киләләр һәм, квартирасын астын өскә китереп, үзен алып китәләр. Бу юлы инде хөкемгә тартырга нигез җитәрлек булган. «Төрмәдән чыгарылу белән үк,— диелә әлеге кәгазьдә,— Гассар яңадан революцион мохиткә керде һәм эшче районнарының тырыш организатор-пропагандисты булып китте. Ул шулай ук Россия социал-

демократик эшчеләр партиясенең Казан комитеты хәрби дружиналарын коралландыру мәсьәләсен хәл итүдә якыннан катнашты».

Тикшерү, сорау алу һәм язышулар белән ике айга якын вакыт үтә, һәм менә губерна төрмәсендә яткан Гассарны 14 сентябрьдә, «Казанец» исемле пароходка утыртып, Себергә ике еллык сөргенгә җибәрәләр.

Фатих төрмәгә аны күрергә бардымы, киткән чагында озатып калдымы, соңгырак елларда алар күрештеләрме — бу хакта безнең кулда мәгълүмат юк. Тик шунысы бәхәссез: иманына турылыклы булып калган, Октябрь революциясен көрәшчеләр сафында каршылаган, 1918 елда ак чехлар тарафыннан үтерелгән бу гүзәл кеше татар демократик культура үсешенә турыдантуры өлеш кертү белән бергә, Фатихның зур әдип булып формалашуына зур булышлык күрсәтте. Моның өчен без аның алдында рәхмәт әйтеп баш ияргә бурычлыбыз...

15 август көнне Мәкәрҗәдә «Мөселман иттифакы»ның 3 съезды ачыла. Монысында Фатих булганмы? Бу турыда анык мәгълүматлар очрамады. Әмма кистереп әйтергә мөмкин: әгәр нинди дә булса гадәттән тыш хәл комачауламаса, аның бу съездга бармый калуы мөмкин түгел. Чөнки көн тәртибенә куелган мәсьәләләрнең берсе — мәктәп һәм мәдрәсәләр хәле.

Съезд шаулап узып китә: докладлар укыла, чыгып сөйләүләр, фикер алышулар, бәхәс, үпкәләшү, кычкырышулар була. Кырмыска оясына таяк тыгып бутаучылар, әлеге дә баягы, яшьләр — «таңчылар» һәм «ислах»чылар. Съездның мәктәп-мәдрәсәләргә багышланган утырышы чагыштырмача җәнҗалсызрак узып, яшьләр тырышлыгы белән шактый киң һәм радикаль программа кабул ителгән.

Менә көз керә. Фатих «Музуров номерлары»ндамы, түләүле бүлмәсендәме, торып ята. Шөгыле — «Ислах комитеты», газета, үзлегеннән уку, дусишләре, кыз-кыркыннар белән аралашу, театр, концерт, әдәби һәм гадәти кичәләрдә булу.

Әтисе белән конфликт югары ноктасына җитә. Фатих Мәкәрҗә съездында җәнҗалчыларның берсе сыйфатында катнашкан булса, моңа гаҗәпләнергә туры килми. М. Укмасыйга ышансак, Фатих туган йортын ташлап чыкканнан бирле Зариф хәзрәт аңа, аттестатка әзерләнер өчен, сукыр бер тиен дә бирми башлаган. Фатих биш-алты баланы русча укытып алган акчасын репетиторына түли икән. Рабига абыстайның картыннан яшереп күрсәткән ярдәме дә арага кергән дип уйларга кирәк.

Көз үз хокукын яулап алгач, кояшның яктысы һәм җылысы кимегән шикелле, Фатихның Казандагы тормышы шактый шыксызланып кала. Арагтирә теләсә кая баш ала качасы килгән минутлары да була. Ихтимал, болай ук сабырсызланмас, әтисе белән арасы бозылу, иткеләрнең эт кебек өрүләре, шулай ук акчасызлык та аны ул кадәр борчуга салмас иде: аңарда моңа гына бирешмәслек көч тә, ныклык та бар. Хикмәт шунда: иртәме-соңмы, аның Казаннан китәчәге инде хәл кылынган. Мәскәүдә Заһид Шамиль «Тәрбиятел-этфаль» журналын чыгаруга кызу әзерлек алып бара. Вакыты җиткәч, Фатихны чакырып хәбәр бирәчәк. Булса, тизрәк булсын иде инде!

Ниһаять, көтелгән хәбәр килә, һәм Фатих сәер, каршылыклы хис-тойгылар кичерә башлый: бер яктан куаныч, икенче яктан сагыш. «Иптәшләремнән аерылам, дөньяда мине иң якын күрә торган бер йөрәккә (әнисенә — И. Н.) яра салам — авыр. Казаннан вә аның татарларыннан котылам — шатлык. Эш башлыйм, үземнең истигъдатымны[1] күрәм — изтыйраб[2] вә мәҗһүлият»[3].

19 октябрь көнне җомга вакытында Фатих, энесе Ибраһим белән берлектә, вокзалга юнәлә. Бер төркем иптәшләре анда көтеп торалар икән. Кемнәр? Якын дуслары, «Ислах комитеты»на кагылышлы иптәшләре һәм «Шимбә» заманыннан якынаеп калган егет һәм кызлар дип уйларга кирәк.

Зарыктыргыч соңгы минутлар... Сөйләшәсе мөһим нәрсәләр турында инде сөйләшенгән. Онытыла язганнары хакында ашык-пошык әйтеп калу, киеренкелекне йомшарту, күңел күтәрү өчен мәзәк сүзләр җибәрү. Менә колоколның беренче чыңы, икенчесе... Хәерле юл теләү, кочаклашу, үбешү башлана.

Поезд акрын гына кузгала. «Хуш, Фатих!», «Онытма, хат яз!» — дигән тавышлар, кул болгау.

Хатыннан күренгәнчә, вагонда Фатих бер сәгать чамасы уйга чумып, эч-

[1] Истигъдад — сәләт, булдыклылык.
[2] Изтыйраб — икеләнү, аптырау.
[3] Мәҗһүлият — билгесезлек.

ке кичерешләрен барлап, тикшереп, үз-үзен аңларга тырышып утырган. Казандагы соңгы көннәре, китәргә әзерләнүләре, туган шәһәреннән аерылу күренешләре яңадан хыялыннан кичкән.

Менә күзләре яшьләнгән әнисе:

— Улым, зинһар безгә ачуланма. Хат яз.

Менә шактый җиңел табигатьле, ваемсыз энесе Ибраһимның, җитдиләнеп китеп, хафага төшүе:

— Абый, мине онытма! Беләсең әтинең холкын. Син киткәч, миңа тагы да уңайсызрак булыр.

Алда — мәмләкәтнең икенче пайтәхете Мәскәү. Нәрсә көтә анда Фатихны? Теләкләре, хыяллары тормышка ашармы?

## 5

Шунысы да мәгълүм булсын, милләт балаларын тәрбияләү кебек изге эшне башлап җибәрү өчен Фатих Әмирхановны көтеп утыручы Заһид Шамиль — легендар Шамильнең оныгы.

Шамиль карашлары, тоткан юлы һәм гамәлләре белән каршылыклы шәхес. Тик ни генә булмасын, үзенең шәхси мәнфәгатен бер якка атып, егерме биш ел буе патша сатрапларына каршы кыю һәм оста көрәш алып барган, соңгы чиккә кадәр үз иманына турылыклы булып калган бу талантлы шәхес ихтирамга лаек. Кулга төшкәч, ботарлап ташлыйсы урында, Шамильнең исән калдырылуы һәм Калуга шәһәренә сөргенгә җибәрелүе очраклы хәл булмаса кирәк.

Сөргендә дә, күрәсең, Шамильнең яшәү шартлары бик үк начар булмаган. Олы улы Газиз-Мөхәммәт Төркиягә китеп укыган. Икенче улы Мөхәммәт-Шәфи, Россиядә укып, гаскәри хезмәткә кергән, полковник дәрәҗәсенә ирешкән. Кайсыдыр елда аны, генерал-майор чины өстәп, отставкага чыгаралар. Шуннан соң Шәфи Шамиль Казанга күчеп килә һәм, күпмедер вакыт үткәч, хәзерге Тукай урамындагы «Шамиль йорты» дип йөртелә торган өйне салып кера.

Шәфи Шамильнең улы Заһид 1870-71 еллар тирәсендә Калугада дөньяга килгән. Ни өчендер Төркиядә агасы Газиз-Мөхәммәт гаиләсендә үскән, шунда лицей тәмам иткән. 1898 елда ул Казанга, әтисе йортына кайта һәм озакламый касимлы купец Байбеков кызына өйләнә. 1902 елда инде без аны Мәскәүдә, кайнатасының Цветной бульвардагы ике катлы өендә яшәп ятканы хәлдә күрәбез.

Ф. Әмирханның хөрмәт белән телгә алуына караганда, Заһид Шамиль прогрессив карашлы кеше булган. Татарлар белән якыннан аралашкан, ул гына да түгел, тәрәккый пәрвәр милләт хадимнәренең берсе санала башлаган. Балалар өчен саф татар телендә журнал чыгарырга керешүе шуның бер күрсәткече булса кирәк.

...22 октябрь. Фатих — Мәскәүдә. 24 октябрь тарихлы хатында мондый сүзләр бар: «Заһид әфәнде саясендә[1] вакыт бик рәхәт уздырыла. Заһид әфәнденең истикъбаль[2] вә мөгамәләләреннән типичный редактор бюрократ түгел, бәлки башка иптәшләр кеби бер күңелле иптәш идеке күренмәктәдер. Хәзер Москваның иң әгъла бер урамында (Петровка) Мәрьям Шамиль квартирында гостинаяда икамәт итәм».

Тагын бер «Шамиль»! Бусы кем тагы? Сораштыру, архивка керү, актарыну Әмирхановларның электән үк Шамильләргә кечкенә генә кагылышлы булуын күрсәтте.

Казанда Апаков фамилиясен йөртә торган берничә могтәбәр гаилә яшәгән. Арада беренче гильдия купецы да бар. Фатихның тутасы, ягъни Зариф хәзрәт сеңелесе Мәрьям, Апаковларның берсенә — уртакул сәүдәгәр Шәкүргә кияүгә чыккан. Хәтта телгә алынган Мәрьям, дөресрәге, Мәрьямбану исә — потомственный почетный гражданин Ибраһим Апаков кызы. Калугада чагындагы беренче хатыны (Заһидның анасы) үлеп киткәч, Мөхәммәт-Шәфи Шамиль Казанда әнә шул Мәрьямбану Апаковага өйләнгән. Димәк, бу ханым Фатихның җизнәсенә туган тия.

Фатих килгәндә генерал Шамиль инде үлгән була. Мәрьямнән туган ике кызы, кияүгә чыгып, бу оядан очып киткәннәр, олыгайган Мәрьям ханым япа-ялгыз торып калган.

---

[1] Сая — күләгә, ышык.
[2] Истикъбаль — киләчәк, булачак. Монда: каршы алу, хөрмәтләп каршылау.

Фатихның Мәрьям Шамильгә килеп төшеп, бай җиһазлы зур квартирада яши башлау сәбәбе аңлашылса кирәк.

Казаннан гаип булып тору ихтыяҗыннан тыш, безнең Фатих Мәскәүгә зур өмет, хыял һәм планнар белән килгән иде. Барыннан да элек, хезмәт хакы ала башлап, һичкемнән бәйсез һәм хөр яшәү. Икенчедән, типографиядә басыла торган чын журналда гади хезмәткәр генә түгел, бәлки җаваплы секретарь булып эшләү, үзе дә язу, язганын журнал сәхифәләрендә дөньяга тарату, кыю, радикаль фикерләрен балалар һәм балаларның ата-аналары аңына сеңдерү. Ниһаять, өченчедән, Казанда аксап-туксабрак барган һәм ахырда өзелеп калган укуын дәвам иттерү, яңача һәм тәртипле алып бару.

Баштагы икесе төрмышка ашты. Ә менә өченчесе...

Егерме берен тутырып килә торган безнең Фатих Мәскәү чаклы Мәскәүгә килеп урнашты, яңа даирә эченә керде. Җитмәсә, кесәдә акча чылтырый башлап, кием-салымны яңа шартларга яраклы рәвештә алыштыру мөмкинлеге туды, төшкә дә кермәгән җиһазлы «апартамент»та яши. Кыскасы, аның Мәскәүдәге беренче айлары кәеф-сафа беләнрәк үтә башлый. («Москвадагы татар вә хәтта рус аристократларыннан, хәтта бюрократларыннан әллә никадәр гаиләләр белән таныштым. Һәр кич дип әйтерлек вечерларда, балларда йөрергә туры килә» — 9 январь, 1907 ел).

Фатихның килү хөрмәтенә Заһид Шамиль, күрәсең, үз өендә мәҗлес уздырган. Игътибар үзәгенә эләккән Казан егете сынауны уңышлы үткән булырга кирәк. Кунак ашы кара-каршы диләр бит: Мәскәүнең могтәбәр гаиләләре дә шундый ук кичәләр ясый башлыйлар. Боларында да Фатих кадерсез кунак булмаган.

Шамильләрдәге кичәдә Фатих бер генерал кызы белән таныша. Танцевать итәләр, сөйләшеп утыралар һәм, үзе әйтмешли, «и так далее». Аннары генералның өендә очрашалар. Сөйләшә-сөйләшә тагын танцевать итәләр. Бервакыт генерал кызы, кыюланып китеп, егетне аулак бүлмәгә алып керә. Араларында мондый сөйләшү була.

— Мин сездән бер нәрсә сорасам, гаеп итмәссезме? Һәм дөрес җавап бирерсезме?

Фатих, югары тәрбия алган кешеләрчә, нәзакәтле итеп:

— Пожалуйста,— дип куя.

— Миңа әйттеләр, сез будто-бы социалист? Шул сүз дөресме? Өмет итәм, дөрес түгелдер...

Фатихның ул вакыттагы яшьлек максимализмына аристократка кызның игътибарын җәлеп итү теләге кушылган булса кирәк, ул кырт кисеп җавап бирә:

— Совершенно верно, социалист.

Кыз башта куркып китә, аннары, тынычлана төшеп, егеткә томылып карый да болай ди:

— Соң бит сез бик милый, бер дә куркыныч түгел.

— Разве вы думаете, что социалисты все страшны?

— Это несомненно.

Социалистларның очраган бер кешене үтерә торган явызлар булмаганлыгын кызга төшендерү өчен, Фатихка ярым сәгатьләп вакыт кирәк булган.

Укуы мәсьәләсенә килгәндә, нинди дә булса курс тапканмы, әллә репетитор яллаганмы, нәрсә укыган, ничек укыган, без боларны әлегә белмибез. Тик шунысы билгеле: беренче айларда аның укуга бик үк вакыты калмаган. («Хәзер инде ул вечер-балларны ташлап, чынлап укырга тотынам».—7 декабрь). Гыйлем эстәү артыннан йөрүе соңрак күпме җимеш биргәндер, бусы да безгә караңгы. Тик шунысын әйтергә мөмкин: танышларының рус яшьләре хисабына да артуы укып йөрүе белән бәйле булырга тиеш. Шулардан берсе, соңрак кайдадыр провинциядә стоматолог булып эшли башлаган Кузнецова фамилияле тугаш яисә ханым Фатихка язган хатында болай ди: «Безнең Мәскәүдәге хәл-әхвәлебезне бик рәхәтләнеп искә төшерәм». Хәтта тагын гомуми танышларыннан Люда һәм ниндидер Гали телгә алына.

«К. М.» инициалын имза итеп, Германиядән хат язган бер рус егете дә Ф. Әмирханның Мәскәү танышы булса кирәк.

Аттестатка әзерләнүенә һәм, гомумән, китапларга тупланган гыйлем белән зиһенен баетуга комачаулык итсә дә, әлеге кичә һәм баллар, театр һәм концертлар, төрле кешеләр белән танышу, утырдаш булу, уйнау-көлү

Фатих өчен һич тә зарарга гына булмаган. Тарих һәм хәзерге хәл, сәясәт һәм фәлсәфә, мәхәббәт һәм гаилә, милләт язмышы һәм балалар тәрбиясе буенча ничаклы фикер ишеткән ул! Кайсын хуплаган, кайсы белән телдән һәм эчтән бәхәсләшкән. Казаннан алып килгән иманы асылда шул килеш калса да, байый төшкән, берьяклылыктан һәм артык кискенлектән арына барган.

Мәскәүдә уздырган алты ае тагын Фатихның киләчәк иҗаты өчен шактый мул азык биргән. Үтәр бер-ике ел, бәхетсезлек килеп, яңа төр милләт хадиме булу хыялыннан ул ваз кичәр, үзен әдәбиятка багышларга карар итәр. Менә шунда инде Казан һәм Мәскәүдә күреп белгән кешеләрнең төс-кыяфәтләре, гадәт-холкы һәм кылган гамәлләре ярдәмгә килер, күп сыйдырышлы типлар тууга җирлек булыр.

Тагын шунысын да әйтеп китик: Мәскәүнең үзенә күрә бер аристократик даирәсенә килеп кергән Фатих беренче мәртәбә калага аяк баскан авыл малае, яисә пишкадәмнәр мәҗлесенә эләккән рөшдия шәкерте хәлендә калмаган. Беренче көннәреннән үк ул үзен бер дә ким кеше түгел итеп куя. Торабара Мәскәү могтәбәрләренең дә әллә кая ерак китмәгәнлекләрен, күбрәк тыштан ялтыраганнарын күрә, аларга үзе өстән карый башлый. («Шундый вакытлар була ки, шул аристократка вә аристократларның кыланышларыннан (извини за выраж.) косасылар килә»).

Фатихның төп эшенә — «Тәрбиятел-әтфаль»дә секретарьлык вазифасын башкаруына кайтыйк.

Журналның дөньяга чыгып калган биш санынннан күренгәнчә, «Тәрбиятел-әтфаль» — Ф. Әмирханның беренче «законлы» баласы, яраткан баласы («законсызы» — яшерен «Әльислах» иде).

Иң элек журналның теленә күз ташлыйк. Төрекчә, французча, русча, билгеле инде, аварча яхшы белеп тә, татарча ярты-йорты гына сөйләшеп, бөтенләй яза белми торган З. Шамиль редакторлыгындагы журнал гарәп-фарсы гыйбарәләре белән чак кына авырайтылган саф татар телендә чыгып килә. Кем редакцияләгән аны? Билгеле инде, Фатих.

Кемнәр язган журналга? Материалларның күпчелеге имзасыз чыкканга күрә, бу сорауга җавап бирү кыен. Шулай да күбесенең Фатих тарафыннан язылганын яисә тәрҗемә ителгәнен чамаларга мөмкин. Бер хатында үзе үк бу турыда әйтеп уза. Биш номерның да «Идарәдән» дигән исем астындагы баш мәкаләсе аныкы икән. Истамбул, Москва һәм Петербург шәһәрләре турындагы мәкаләләр, «Күктә күренә торган нәрсәләр», «Зилзилә», «Гөл агачы», «Дума ачылды», «Менделеев», «Галимәтел-Бәнат» исемле материаллар да аның каләменнән чыккан. Моңа тагын Андерсен әкиятен «Мәхәббәтсез үрдәк баласы» дигән исем астында тәрҗемә итеп бастыруын өстик. Галимҗан Баруди һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе турындагы мәкаләне дә Казанга заказ биреп яздырмаган дип уйларга кирәк. Журналның һәр санындагы биш-алты материал, димәк, Фатихныкы. Димәк, ул вакытын кәеф-сафа корып кына үткәрмәгән...

Тема һәм материал сайлауга килгәндә, наширның катышуын, билгеле, инкяр итә алмыйбыз. Әмма җаваплы секретарьны да кушканны үтәүче итеп кенә карарга ярамый.

Тагын шунысы игътибарны җәлеп итә: шәкерт чагында ук шигырьдә каләм сынаган Фатихның ни тезмәдә, ни чәчмәдә оригиналь әдәби әсәре бөтенләй очрамый. Балалар тәрбиясенә караган тәрҗемә дә публицистика. Безнең Фатихта әле, күрәсең, әдип булу теләге тумаган. Һаман әле ул милләт хадиме «карьерасы» турында уйлап яши.

Публицистикасына күз ташлап, Фатихның билгеле бер рәвешкә кергән дөньяга карашы белән танышып үтик.

Югарыда телгә алынган хатында безнең өчен гаять кыйммәтле искәрмә бар. Журналда басылган мәкаләләрен санаганда, Фатих «ләкин кирәкле җирләре төшереп калдырылган», «кирәкле җирләре төшерелгән», «иң кирәкле җирләре калдырылып» дигән сүзләрне, җәя эченә алып, кыстырып бара. Кулъязмалары сакланмаганга күрә, ул мәкаләләрдән нәрсәләр сызылганын без, әлбәттә, белмибез. Соң нәрсә калган?

Менә 15 февраль датасы белән чыккан 4 санның Дәүләт Думасы мәсьәләсенә багышланган баш мәкаләсе. 17 октябрь манифестында Дума чакырырга вәгъдә ителгән булса да, ди автор, хөкүмәт моны башта ук иске тәртипләргә кире кайтуга исәп тотып эшләгән иде. Думага ул «патша хөкүмәтенең те-

ләгенә юл куярга тиешле бер җәмгыять дип кенә карый иде». Шуңа күрә Беренче Дума белән хөкүмәт арасында низаг чыкты, һәм Дума таратылды. «Һәм икенче Дума да әүвәлгесе шикелле тыңлаусыз булмасын өчен, аннан башка да үзенең максудына ирешүдә һич нәрсәдән чиркәнми торган хөкүмәт золым вә истибдат[1] сәясәтене тагын да куәтләндерде». Күренә ки, хөкүмәт ачыктан-ачык тәнкыйтьләнә һәм халыкка каршы көч итеп бәяләнә. Мәкаләдә патшаның үзенә карата да итагать күрсәтү сизелми. Төшереп калдырылган урыннарда тәнкыйть тагын да кискенрәк булган дип уйларга кирәк.

Мәкаләдән күренгәнчә, татарның демократик карашлы бүтән кайбер язучы һәм фикер ияләре кебек үк, яшь Әмирхан да бу вакытта конституцион иллюзияләрдән азат. Самодержавие исән-имин калган тәкъдирдә Думаның халыкка көткәннәрен бирә алмаячагы аның өчен инде көн кебек ачык. Бу исә революцион-демократик позициягә басу дигән сүз. Икенче Дәүләт Думасының ачылуына багышланган язмасы да бу фикерне куәтли.

Дума утырышы булачак көнне меңләгән халык Таврида сарае каршына җыелган икән. Бина полиция һәм казаклар тезмәсе белән уратып алынган. Менә депутатлар килә башлый. Уң депутатларны халык салкын каршылый. Уртарак юл тотучыларны, «Сәяси гаепләләр өчен гафу!», «Җир һәм ирек!» дигән тавышлар белән каршы алып, беркадәр якты чырай күрсәткән хәлдә сарайга үткәреп җибәрә. «Кызыл бантлар таккан социал-демократлар вә башка сул әгъзаларны,— дип дәвам итә автор,— бигрәк тә шатлык вә мәхәббәт белән каршы алып, куллар өстендә йөрткәннәр вә һәр яктан «Иптәшләр, сәясиләргә гафу, йир, ирек алыгыз!» дигән тавышлар белән бөтен Петербургны яңгыратканнар».

Фатихның үзен социалист хисаплавы белән әлеге ике мәкаләдә язылганнарның үзара ярашканын күрү кыен түгел. Хәзер аны Мәскәүдән Казанга озатырга вакыт җитте.

## 6

Казаннан, аның бер ише кешеләреннән, гаиләдәге җәнҗалдан туеп киткән булса да, Мәскәүдә вакытын хозур белән үткәргәне хәлдә, шактый яраткан эш белән шөгыльләнсә дә, озакламый туган шәһәрен, туган-тумачасын, дус-ишләрен, бигрәк тә анасын сагына башлый. «Һәр хат, һәр кечкенә генә хәбәр, шул тарафтан искән һәр җил бик кадерле була икән». Февраль кергәч үк, ул Заһид Шамильгә язын Казанга кайтып ял итеп килү теләген белдергән. Нашир исә, секретаренның яңадан килмәү ихтималыннан куркып, җәйне үзе белән бергә сәяхәттә үткәрергә тәкъдим иткән. Сәяхәт итүне ярата торган Фатих бик риза булыр иде дә сагындырган Казанда күпмедер вакытын үткәрүдән баш тарта алмый. Бер хатында ул Мәскәүдән китү вакытын да тәгаен билгели: 10 апрель.

Җир яшәрә башлаган, Идел дәрьядай җәелеп киткән һәм кош-кортлар дәртле чыркылдашкан көннәрнең берсендә Фатих, ниһаять, Казанга кайтып төшә. Ананың, билгеле инде, куанычы эченә сыймый, улын кая утыртырга, ни белән сыйларга белми. Ата да караңгы чырай күрсәтми. Туган-тумачалардан, дус-ишләрдән ишек ябылып тормый. Йөремсәк Фатих үзе дә визитлар ясый, иптәшләрен барлый: кем бар, кем юк, ни уйлый, ни белән яши.

Үзе әйткәнчә, бу елның җәен ул фәкать истирәхәт кылып, ягъни ял итеп үткәргән. Былтыргы кебек Фатихның күп вакыты Югары Осланда, Ибраһим Кулиевларда һәм Аитовлар дачасында уен-көлке, шаяру, бәхәс белән узган дип уйларга кирәк.

Әмма быел Фатихның дуслары башында бер фикер туган: күмәкләшеп бер дача алырга да бергәләшеп яшәргә. Бу идея күпмедер күләмдә тормышка ашкан булса кирәк. Моннан соң һәр елны «ислахчылар»дан берничә кеше Кабан күле буенда «коммуна» булып яшәячәкләр.

Элек тә игътибар үзәгендә булган Фатих бу җәйдә билгеле бер даирәнең төше, җаны булып китә. Аның Казаннан югалып торуы үзен, күрәсең, нык кына сиздергән. Юксынганнар, сагынганнар. («Күптән түгел генә Ибраһимнан хат алдым. Казанда мине бик көтәләр, имеш. Һич көтмәгәндә, Фатыйма Юнусовадан да бер хат алдым. «Гаҗәеп сагындык, Казанга кайтыгыз»,— дип яза). Өстәвенә ул Мәскәү күргән, Мәскәү һавасын сулаган, «карт» башкала-

---

[1] Истибдат — реакция.

ның зыялы даирәләрендә кайнаган, күпләр белән утырдаш булган, күп сүз ишеткән кеше.

Иптәшләренең, дус һәм таныш кызларының өметен җимермәс өчен, Фатихка югартын торып, акыллы сүзләр генә сөйләргә, фәлсәфәгә чумарга кирәк иде дә, характеры андый түгел. Ул күбрәк «җүләр сата», Мәскәүдәге булган хәлләрне, үзеннән дә кушып, мәзәкләндереп сөйли, могтәбәр затларның кайберләрен, үзләренә охшатып көлке кыяфәткә кертеп күрсәтә. Тыңлаучылар эчләрен тотып көләләр. Берәрсе, үзенең төшеп калганнардан түгел икәнлеген күрсәтәсе килеп, сүзне җитди мәсьәләгә борырга теләсә, Фатих мондыйрак реплика белән чабуыннан тартып җиргә төшерә:

— Мелла кем, мин юкта йоклап ятмагансың икән, үскәнсең. Карале, кемнән тектерәсең син? Костюмың ифрат килешеп тора.

Фатихның бу елгы язы һәм җәе тоташ уен-көлке, кәеф-сафа, «җүләр сату» белән генә узмаган, билгеле, җитди сүзләр дә булган, укыган да ул, «Ислах» оешмасына кагылышлы кайбер эшләр дә башкарган. Дөрес, шәкертләрнең каникулга таралып китүе сәбәпле, «комитет» шулай ук вакытлыча ял итә. Әмма шәкертләр съездының легаль газета чыгару турындагы карары бар бит әле. Фатих, үзенең фикердәшләре белән берлектә, газета өчен мая туплау, бүтән якларын хәл итү юнәлешендә, һичшиксез, байтак эш башкарган. Югыйсә, шушы елның октябрь аенда «Әльислах» газетасы ялт итеп килеп чыга алмас иде.

Үзендә әллә ни чаклы көч-куәт сизгәне хәлдә, якты дөньяга, тормышның матур якларына гашыйк булып, киләчәккә зур өметләр баглап яши башлаган Фатихны Казанда коточкыч фаҗига көтеп торган икән: 15 август көнне паралич сугып, аның аяк-куллары хәрәкәтсез кала, бер күзе күрмәс була...

Казанның татар төбәге шау килә, бигрәк тә печән базарчылары тантана итәләр:

— Зариф мулланың урыска сатылган чукынчыгын каһәр сукты!

— Кызыл авызга остаз бәддогасы төште!

Нидән шулай булды? Сәбәп нәрсә? «Авыру тарихы» сакланмаганга күрә, без бу сорауга кистереп җавап бирә алмабыз. Телдән-телгә күчеп йөргән имеш-мимешләр, истәлекләргә кереп калган фараз һәм раслаулар белән генә чикләнергә туры килә. Мещаннар уйлап чыгарган һәм әдипнең шәхесен кимсетә торган уйдырмаларны, ике дә уйламый, читкә атыйк. М. Укмасый версиясе дә тәнкыйтьне күтәрми. Хәл белергә килгән Укмасыйга Фатих, янәсе, бу хәлгә төшүенең сәбәбен болай аңлаткан:

— Трамвай юлын (Мәскәүдә — И. Н.) аркылы чыкканда гына шулай булдым. Ток сукты бугай.

Ф. Әмирхан II версиясен кабул итәргә мөмкин. Әссе бер көнне дачадамы, кемнеңдер бакчасындамы вакыт үткәргәндә Фатих, энесе Ибраһим һәм Вафа Бәхтияров белән берлектә, тирләгән килеш төшеп су коенган. Аннары, беркадәр юангач, шәһәргә кайтырга чыкканнар... Кольцога җитәрәк Фатих кинәт туктаган да: «Миңа нидер булды, үземне начар хис итәм»,— дигән. Ул да булмый, аяклары хәлсезләнеп җиргә чүгә. Извозчик яллап, Фатихны үз бүлмәсенә кайтарып салалар.

Булачак әдипнең көннәре больница һәм клиникаларда уза башлый. Дәвалау нәтиҗәседерме, әллә инде организмы җиңгәнме, беркадәр вакыттан соң куллары хәрәкәткә килә, күзе элекке хәленә кайта. Ә аяклар... Организм үзе дә, дәва һәм вакыт та көчсез булып кала. Алар инде беркайчан да йөрмәячәкләр...

Әнә шул килеш Ф. Әмирханның тормышында яңа чор, батырлык үрнәге итеп санарлык яңа дәвер башлана. Фаҗигага юлыкмаса, киләчәктә аның нинди юл сайлаячагын төгәл генә әйтү кыен. Бу хәлендә исә, аның өчен иң кулае — нәфис әдәбиятка, сурәт дөньясына, хыял дөньясына йөз тоту.

Хәерле юл сиңа, бәхетсез дә, бәхетле дә Фатих...

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ЯҢА БИСТӘ ПРОМЕТЕЕ

### 1

Хәсән Туфан 1924 елда Казанга килгәч, яңа дусты Һади Такташ аны Фатих Әмирхан янына алып килә. Бу очрашу Туфанга бик нык тәэсир итә. Бер дә гаҗәп түгел, Туфанның яшьлеге туры килгән унынчы еллар татар әдәбиятында, тәнкыйть һәм публицистикасында Фатих Әмирхан исеме аеруча затлы бер мәгънә белән телгә алына торган булган. Озак еллар узгач, Туфан бу очрашуны искә алып, (бу очрашу Ф. Әмирханның Казандагы күп санлы яшәү урыннарының соңгысында — хәзерге Жуковский урамының уникенче йортында булган), болай язды:

Бу көрешүдә безнең күңелләрдә
Шундый фикер туды тулаем:
Тукайның бу, Фурмановлар кебек,
Комиссары булган, мөгаен!..

Шагыйрь инде, әлбәттә арттырган. Унынчы еллар татар алдынгы яшьләренең комиссары, әлбәттә инде Хөсәен Ямашев булган. Ләкин һәр язучының гиперболага хакы барлыгын онытмыйк. Шулай да Тукайның шагыйрь булып формалашуында, аның телен халыклаштыруда, иҗатын буржуаз тәнкыйтьтән саклау юлында Ф. Әмирханның роле зур булган. Әмирханның биографиясе — безнең әдәбият тарихында шактый гына «ак таплар» белән чуарланган. Безнең фәндә бигрәк тә Ф. Әмирханның совет чоры аз өйрәнелгән. Ул бит әле октябрь революциясеннән соң да тугыз ел чамасы яшәгән, эшләгән, иҗат иткән. Шуның өстенә, аның, авыру булуга карамастан, совет властен пропагандалап, тарантаска утырып Казан тирәсе авылларында чыгыш ясап йөргәнлеге турында халык арасында истәлекләр йөри. «Могикан» дигән шигырендә Х. Туфан моны искә ала:

Без ишеткән идек, ничек аның
Октябрьне көтеп алганын;
Ат җиктереп, арба-трибунага
Авылларга китеп барганын,
Аны яклап аваз салганын
Белә идек.

Ф. Әмирхан биографиясендә менә бу әһәмиятле хәлне документлар белән беркетәсе бар. Ниһаять, Ф. Әмирханның нәсел шәҗәрәсен истәлекләргә, документларга таянып тикшерәсе, ачыклыйсы бар. Нинди гаиләдә туып үскән ул, аның нәселе каян? Казан губерна жандарм идарәсе (КГЖУ) документларында, мәсәлән, аның әтисенең фамилиясе дә очрый. Дәреслекләр буенча без Фатихның әтисе мулла дип кенә белә идек, ә монда — политик ышанычсыз кеше?

Менә бер документ. Казанда бишенче ел революциясенең күтәрелеш көннәрендә — 19 нчы ноябрьдә шәһәрдәге бөтен политик партия вәкилләренең җыелышы була. Җыелыш «Сарай» кунакханәсендә уздырыла. Политик карашлары буенча бик чуар төркемнәрдән торган бу җыелышта «мөселманнар өчен аерым партия төзү» мәсьәләсе карала. Җыелышта катнашкан социал-демократия вәкилләре «мөселманнар өчен махсус политик партия була алмый, чөнки буржуй белән пролетарийның бер партиядә торуы мөмкин түгел», диләр.

Бу җыелышта Г. Камал, аталы-уллы Әмирхановлар (Зариф хәзрәт һәм улы Фатих), бу гаиләнең дуслары аталы-уллы Сөләйман һәм Исмәгыйль Аитовлар катнаша[1]. Җыелышта Ф. Әмирхан укучы яшьләр исеменнән Бөтенроссия мөселманнарының 2 нче съездына делегат итеп сайлана.

---

[1] ТАССР Үзәк дәүләт архивы (алга таба — ТАССР ҮДА) 51 ф., тасв., 633 эш, 36 б.

Зариф Әмирханов шулай беренче мәртәбә яшерен күзәтү-контроль астына алына. 1908 елның 20 августында Россия Эчке эшләр министрлыгының канцеляриясенә Казанның 12 присяжный мулласы тарафыннан донос килеп керә: анда Яңа Бистә мулласы Зариф Әмирхановның үз мәхәлләсендә патша хөкүмәтенә каршы идеология алып барганы турында әйтелә. Шул көннән башлап Зариф Әмирханов ачык күзәтү астында тора. Аның турында бик күп кәгазьләр язылганнан соң (ике ел буе!) Казан жандарм идарәсе начальнигы 1910 елның 12 июнендә карар бирә: «Зариф Әмирханов турында язышуларны туктатырга, аның өстеннән яшерен күзәтү булдырырга»[1].

1911 елда аның исеме яңадан жандармерия кәгазьләрендә кабатланачак, ләкин бу турыда матбугатта язылган инде[2].

2

Фатих 1886 елның 1 (13) гыйнварында туа. Сабый вакытта Яңа Бистә мәдрәсәсендә элементар белем алганнан соң әтисе аны шул чор өчен алдынгы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә бирә. Мәдрәсәләр тарихы бездә аз өйрәнелгән. Бездә аларны «наданлык оясы», «кадимчелек баткагы» дип җиңел кулдан сүгеп китү гадәткә кергән. Хәлбуки, шул ук мәдрәсәләрдән Г. Ибраһимов, Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Камал, М. Гафурилар чыккан. «Мөхәммәдия»нең дә тарихында З. Бигиев, Ф. Бурнаш, С. Габәши һ. б. бик күп әдәбият-сәнгать әһелләре бар. Фатих Әмирхан әнә шунда белем алган. Без «Мөхәммәдия»не «шул чор өчен алдынгы» дидек. Алдынгылыгы нәрсәдә? Мәсәлән, укуны бөтен шәкерт өчен дә көзнең бер көнендә башлап, язлыкта билгеле бер көндә тәмамлап тәгтыйль (каникуллар) игълан итәләр. Дәресләр расписание, кыңгырау белән алып барыла. Һич тә без уйлаганча, «һәфтияк» кенә ятлатмыйлар, дин кануннары, дин тарихыннан тыш логика, элементар юриспруденция, гигиена, хисап, география, тарих, шигырь төзелеше, элементар физика, химия, рус теле, әдәбияты укыталар. Мәдрәсә җитәкчелеге, хәтта инглиз теле өйрәтергә дә кайбер омтылышлар ясый. Шәкертләрнең көнкүрешендә дә яңалыклар кертелә: алар дәрестән кайтышка тулай торакта озын плитә өстендә чуен-чүлмәк кайнап тора, кизүләр мичне карый, лавкада исә пачкалы аш сатыла: суган, кипкән бәрәңге, ит, борыч, токмач. Биш-ун минутта кайнар аш әзер, тик лавкага түләргә биш тиен акчаң гына булсын. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе заманына күрә әйбәт кенә белем биргән. Дөрес инде, дини дәресләр шәкертнең миен бушка туздырган, ул заманда шунсыз мөмкин дә булмаган. Ләкин совет властеның беренче елларында төп укытучы кадрлар шул «Мөхәммәдия», «Галия» «Буби» мәдрәсәләрен тәмамлаган кешеләр булды. Шуңа күрә РСФСР Мәгариф Халык Комиссариатының махсус приказында «Мөхәммәдия» һәм «Галия»не тәмамлаган укытучыларның белемен тарификацияләгәндә аларны Учительский институт тәмамлаганнар белән тигез бәяләргә диган күрсәтмә бар иде.

Фатих Әмирхан әнә шул мәдрәсәдә тулы курс белем ала. Ләкин ул вакыттагы күп кенә зирәк шәкертләргә хас булганча, мәдрәсә белеменә генә риза булмый, үзлегеннән русча белем ала. Алдынгы татар яшьләре өчен көн тәртибенә куелган бер ихтыяҗ була ул. 1904 елның июнь—сентябрь айларында Самарага барып анда русча белем ала. Игътибар итегез, бу чорда Фатихка 18 яшь. Чибәр, зирәк, кеше белән тиз контактка керүчән, акыллы. Истәлекләр һәм аның яшьлегендә төшкән фоторәсемнәре аның шул заманның укымышлы кызлары-егетләре арасында бик тә абруйлы булганын, һәрвакыт игътибар үзәгендә булганын сөйлиләр. «Хәят» повестеның төп җирлеге, урын-вакыт җирлеге, әлбәттә инде Самара шәһәре һәм шул чор булачак. Әле аның Хәяты да, тормыштандыр? Казаннанмы, Самараданмы? Казанга кайткач, Фатих үзенә рус теле буенча шәхси укытучы эзли. Аңа социаль-демократ Сергей Николаевич Гассар белән танышу мөмкинлеге туа. Студент Гассар аңа рус теле, әдәбияты өйрәтә. Фатихның хыялы — экстерн юлы белән өлгергәнлек аттестаты алып, Казан университетына керү. Тагын игътибар итегез: Ф. Әмирхан әсәрләрендә экстерн юлы белән өлгергәнлек аттестаты алырга йөрүчеләр, моңа ирешеп университетка керүчеләр, моңа ирешә алмаучылар байтак күренә. Һәрхәлдә, алдынгы татар яшьләре өчен Казан университеты — гыйлем дөньясы һәм прогрессив культураның кояшы булып күренгән һәм бик күпләрнең бу кояш астына керәселәре килгән.

С. Н. Гассар тәэсирендә Фатих политик, экономик әдәбият укый башлый. Бу хәл исә аның дөньяга карашларын тагы да киңәйтеп җибәрә. Ул арада 1905 ел вакыйгалары башланып китә. Революциянең барыш даталары буенча Казан зур шәһәрләр — Петербург, Мәскәү, Рига, Киевләр рәтеннән атлый. Үзен политик көрәшкә инде әзер дип ышанган Фатих революция көннәрендә «Мөхәммәдия» шәкертләренең идеологик җитәкчесенә

[1] ТАССР УДА 199 ф., 1 тасв., 1715 эш, 156 б.
[2] «Казан утлары», 1976, 1 сан.

әйләнә дә куя. Фатих Әмирхан шәкертләр исеменнән прокламацияләр төзи, бу прокламацияләрне патша администрациясе алдында ышанычлы саналган Аитовларның өендә җилем басмада күбәйтәләр, бу эшкә студентлар чуалышында катнашкан өчен реальное училищедан куылган Солтан Рахманколый да тартыла.

1906 елда Ф. Әмирхан бик киеренке рәвештә өлгергәнлек аттестаты алырга әзерләнә. Шушы елда Фатих татар яшьләре арасында иң популяр шәхескә әйләнә. Политик, идеологик эш алып барудан тыш ул төрле клубларда, «Сәйяр» оешканчы ук барган спектакльләрдә катнаша.

1906 елның көзендә Ф. Әмирхан Мәскәүдә яшәүче Заһит Шамилнең (1868—1920) чакыруы буенча аның янына китә. Заһит Шамил—Кавказлы Шамилнең оныгы. Кавказлы Шамилнең ике улы булып, шуның берсе — генерал Шәфигулла (Шәфи Шамил) — Казан кияве, ул Казан бае, Апаковның кызы Мәрьям Апакованы ала һәм Казанда яши (Хәзерге Тукай урамындагы «Шамил пулаты» дигән йорт. Ул йортны Шәфи Шамилдән Казан бае — бакалея сәүдәсе тотучы Вәлиулла Ибраһимов сатып ала, анда конфет фабрикасы ачып җибәрә). Шәфинең улы Заһит Шамил Мәскәүдә балалар өчен «Тәрбиятел-әтфаль» («Балалар тәрбиясе») исемле журнал оештыра һәм журналны алып бару эшенә Фатих Әмирханны күндерә. Бу — татар телендә беренче балалар журналы. Ф. Әмирхан журналның җаваплы секретаре булып эшли. «Тәрбиятел-әтфаль» озын гомерле булмый. Нибары биш сан чыгып кала. Ләкин яшь журналист Мәскәүдә зур тормыш мәктәбе үтә. Ул монда Мәскәү аристократиясе белән аралаша. Заһит Шамилнең дә аңа йогынтысы була.

Мәскәүдәге тирәлеге Фатихның күзләрен тагы да ныграк ача, дөньяга карашын киңәйтә.

1907 елның маенда Фатих яңадан Казанга кайта. Фатих кайтканда Казан яшьләре бераз басыла төшкән инде — кадимчеләр реакция якынайганын сизеп тагын котырыналар, тагын яшьлек идеалларын, азатлык өчен көрәшне буарга җыеналар. Фатих әдәби эшкә чума. Алда планнар — пьеса язу, очерклар, көндәлек вакыйгаларга күзәтү, тәнкыйть мәкаләләре һәм хикәяләр.

Ләкин 1907 елның августында Фатихны кинәт кенә паралич суга һәм ул гомерлеккә аяксыз кала. Шул айдан башлап Ф. Әмирхан 19 ел буе коляскада йөри, киенү, ашау-эчү һәм хәрәкәт итү кебек мәшәкатьләрендә кеше ярдәменә мохтаҗ булып кала. Хәсән Туфан без алда телгә алган шигырендә аны «аяклары бәйле Прометей» дип атаган икән — бу гыйбарә Ф. Әмирханның әнә шул трагедиясен аңлата.

1905—1907 еллар революциясе эчендә кайнаган, татар шәкертләренең рухи атасы булган, Петербургка 2 нче мөселман съездына яшьләр арасыннан делегат булып барган, Мәскәү кадәр Мәскәүдә балалар өчен журнал чыгарган, өлгергәнлек аттестаты алып университетка керергә хыялланып йөргән яшь бөркетнең шулай кинәт кенә канатлары киселә... Бик кинәт була бу фаҗига. һәм шуннан газаплы, кеше кулына бәйле тормыш башлана.

Алга таба узып шуны әйтик: Ф. Әмирхан инвалид булуы аркасында яшьтәшләре катнашкан (мәсәлән, танышы М. Вахитов) Октябрь революциясендә катнаша алмый, гражданнар сугышы елларында кулына корал тотып совет властен яклап көрәшә алмый. Кызыл көрәшчеләрдән ул яхшы мәгънәсендә көнләшеп яши, кулыннан килгәнчә каләмен эшкә җигә. 1921 елда ул бер генә сан чыгып калган «Кызыл дәфтәр» журналында «Чәчәкләр китерегез миңа!» исемле нәсерен бастыра. Бу әсәрен ул «Гражданнар сугышын галәбәле (җиңүле — М. М.) тәмам итеп, хезмәт мәйданына кайта торган иптәшләргә» багышлый.

«Китерегез миңа әнҗе чәчәкләр! Мин шул бәхетле көннәремнең шигъри төшләрен исемә төшерермен. Миңа әнҗе чәчәкләр китерегез! Аларның газаплы исертүчән салкынчарак исләре минем тирә-ягымны аңкытсын, бәлки, шул газаплы ләтыйф истә мин, б ә х е т м ө м к и н б у л а т о р ы п т а, бәхетсез уздырган яшьлегемнең назирасын[1] табармын! (Курсив безнеке — М. М.)

«Бәхет мөмкин була торып та...» Бу гыйбарә игътибар сорый. Ф. Әмирханның иң гүзәл яшьлек еллары кадими Яңа Бистәдә — иске тип сәүдәгәрләр, бистә мещаннары арасында уза. Ә егетнең хыялы татар бистәсендә генә түгел, рус һәм Европа культурасында кайнау, гимназист һәм гимназисткалар, студент һәм студенткалар белән дөньяви уку йортларында, кичәләрдә, концерт-танцыларда йөрү, зур дөньяда гөж килеп яшәү. Бу хыялы аның бөтен әсәрләрендә дә үзәк сызык булып бара: «Кадерле минутлар», «Хәят», «Картайдым», «Танымаганлыктан таныштык», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Беренче ашкыну» — барысы да шул турыда сөйли. Ни генә әйтсәң дә, Фатихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе һәм Яңа Бистә мохиты канәгатьләндерми. Аның эстетик идеалы — татар милли культурасын үзләштереп, шуннан һич тә баш тартмыйча рус һәм Европа культурасы биеклекләренә ирешкән яшь егет, яшь кыз. Шуңа күрә, ул үзе ирешә алмаганнарны үз әсәрләренең геройларына бирергә тырыша: аның геройлары гитарада уйныйлар, романслар, арияләр

[1] Назира — охшашлык.

җырлыйлар, аларның телендә Гете, Тургенев, Лермонтов, Пушкин әсәрләреннән өзекләр, мисаллар.

Үзенең мохитыннан риза булмаган Фатихка язмыш тагын бер һөҗүм ясый — ул авырып китә. «Бәхет мөмкин була торып та...» Әлеге нәсернең мәгънәсе безнеңчә, нәкъ менә шунда... Әйтергә кирәк, Ф. Әмирханның бу җөмләсе алынма җөмлә. Ул бик яраткан һәм күп урыннарын күңелдән белгән «Евгений Онегин»га мөрәҗәгать итсәк, анда мондый юллар табарбыз: бәхетле булырга тиеш булып та, бәхеткә ирешә алмаган дворян кызы гүзәл Татьяна ачынып анда болай ди:

А счастье было так возможно,
Так близко!..

Ф. Әмирханның бөтен иҗатында да яшьлеген сагынуы әнә шул ике хәлгә кайтып кала: ул риза булмаган мохит; аның көрәшкә күтәрелеп килгәндә генә авырып егылуы.

«Әльислах» — демократик яшьләр һәм алдынгы карашлы шәкертләр органы. Революция елларында ул Ф. Әмирхан катнашында гектографта яшерен рәвештә басылып килгән. Газета 1907 елның 3 октябреннән рөхсәт белән Казанда чыга башлый (рәсми редакторы — Вафа Бәхтияров). Бу газетаның татарда демократик фикерне җәелдерүдә әһәмияте искиткеч зур. Ф. Әмирханның әдәбиятка, сәнгатькә кагылышлы бик күп тәнкыйть мәкаләләре, Казан хәлләре, иҗтимагый мәсьәләләргә багышланган очерклар, информацияләренең зур күпчелеге «Әльислах»та басыла. «Әльислах» ачылган көннәрдә генә Казанга ерак Уральскидан Тукай кайтып төшә һәм туп-туры Ф. Әмирхан йогынтысына барып керә. «Әльислах» Тукай әсәрләренә түрдән урын бирә.

...Реакция еллары. Ф. Әмирхан «Әльислах»та эшли. «Болгар» номерларында тора. Редакциядә эшләүдән тыш хикәяләр яза. Менә «Картайдым» хикәясе. Язучы гомер буе үзен-үзе яза, диләр. Бу — хактыр. Хикәянең герое — өлгергәнлек аттестаты алып, университетка кергән егет Мостафа. Тирәлектән риза түгел. Шәхес дулый, шәхес бунт күтәрә. Нәрсә җитми соң? Яшьлек җитми, ул узган, ул югалган. Яшьлек бушка узган, җәмгыять Мостафага ихтыяҗ белдерми һәм бөтен хикәя авторның бу тирәлекне каргавыннан һәм бер генә лозунгысыннан тора: «Кайтарып бирегез миңа шул яшьлек, мөкаддәс яшьлегемне... мин сезгә бөтен уздырган гомеремнең махсулатын бирәм»[1].

Мостафа буржуаз җәмгыятьне әнә шулай кире кага.

Менә боларны аңламаган көе Ф. Әмирхан иҗатының төп аһәңенә бәя бирү мөмкин түгел.

## 3

1908 ел июнь-июль айларында Фатих Әмирхан Серноводскида дәвалана. Аларның — Тукай белән икесенең — гадәт шулай: нинди генә максат белән кая гына бармасыннар — юлъязма. Ф. Әмирхан да санаторийда дәвалануы чорында үз сәламәтлеге турында уйлаудан бигрәк, тормыш, әйләнә-тирәгә күз сала, уйлана. Бу уйлануларын кәгазьгә төшерә һәм «Авырулар галәмендә» исеме белән «Әльислах»ка җибәрә. Дәреслекләрдә, гадәттә, Ф. Әмирханның бу очеркында социаль контрастларны күрүе турында гына әйтелә. Авыру Фатих төнлә өенә кайтып барганда, кичтән үк ятып йоклаган фәкыйрь, караңгы крестьян йортларын күрә һәм гөлт итеп торган дачаларда кокетка дамаларның чыркылдашып көлгәнен, гитара тавышларын ишетә. Юк, дөнья тигез түгел! Әле кайчан гына «Мөселманнар иттифакы» партиясе «без — мөселманнар, безнең аллабыз да, динебез дә, пәйгамбәребез дә бер, без — бертигез» дигән программа белән чыккан иде, юк, мөселманнар да, башкалар да тигез түгел!

Ф. Әмирханның социаль карашлары ап-ачык булып әнә шунда чагыла. Ләкин очеркта әле тормыш, яшәеш фәлсәфәсе башка яклары белән дә кузгатыла. Язучы елга дулкыннары белән фикер алыша, үзе яшәгән шартларда кеше мөмкинлегенең чикләнгәнлеге турында уйлана. «Шаулагыз, гөрләгез, хәлегездән килгән кадәр шикаять итегез![2] Сезнең әтрафыгызны чолгап алган менә бу кешеләр дә шулай шауларлар, гөрләрләр иде дә, ләкин алар булдыра алмыйлар. Алар да, сезнең шикелле, үзләре аңламый торган җил белән урыннарыннан кузгатылганнар, тынычлыкларыннан аерылганнар; алар да шикаять итәрләр иде дә, ләкин сездәге хөррият аларга бирелмәгән!»

Бу төр фәлсәфә — егерменче йөз башы татар әдәбияты өчен бик тә характерлы. Кеше мөмкинлекләрен табигать көчләре белән параллель куеп тасвирлауны Г. Коләхметовның «Ике фикер» драмасында, Тукай поэзиясендә, Г. Коләхметов тәрҗемә иткән «Уалган

---

[1] Бу сүзләр Гетеның «Фауст» әсәреннән. Анда Фаустның бөтен тормышын билгәгән бер максаты бар: «Миңа яшьлегемне кайтарып бирегез!»

[2] Шикаять итү — зарлану.

мол» (Г. Гершунин) нәсерендә, ниһаять, Ш. Камалның «Акчарлаклар» повестенда күрә алабыз. Мондый фикерләү егерменче йөз башы татар әдәбиятының нигез ташларыннан берсе иде һәм, әлбәттә, монда Горький иҗатының йогынтысы да сизелә иде.

1907—1910 еллар — Ф. Әмирханның тәнкыйть, публицистика жанрында иң актив эшләгән чоры. «Әльислах» газетасының Ф. Әмирхан мәкаләсе кермәгән саннары бик аз. Моның кадәр энергия аңа каян килгән? 1907—10 еллар Казан тарихын, иҗтимагый фикер, мәктәп-мәдрәсә, матбугат-әдәбият тарихын Ф. Әмирхан эшчәнлеген өйрәнүдән башка белү мөмкин түгел. Бөтен татар җәмәгатьчелеге, аның эшчәнлеге — Ф. Әмирхан каләме очында. Бер үк газетада бик еш басылганлыктан, ул үзенә күп кенә псевдоним ала: Ташмөхәммәт, Зәмзәметдинов, Дамелла һ. б. Ләкин псевдоним алуның башка сәбәбе дә бар: усал телле Фатих, ни әйтсәң дә, Яңа Бистә мәхәлләсе мулласы Зариф хәзрәтнең улы бит әле. Агай-эне бар, мәхәллә халкы, күрше-тирә бар. Псевдоним алуның бер сәбәбе әнә шуннан. Әдәбият тарихында билгеле: 1909 елда, «Фәтхулла хәзрәт» повестен язганда Ф. Әмирхан материалны әйләнә-тирәсеннән генә ала. «Фәтхулла хәзрәтнең үлгәч терелүе» дигән кыйссаны яза башладым. Әти: «Йосыф хәзрәтне тәнкыйть итәсең,— дип, башыма кыямәтләр куптара»,— дип яза Ф. Әмирхан бер хатында.

Шундый күләмле һәм шау-шулы әсәрнең һәр басмасында да «Ташмөхәммәт» псевдонимы куелуы һич тә нигезсез түгел, әлбәттә.

Ф. Әмирханның иҗат биографиясендә «Әльислах» чоры аеруча зур урын алып тора. Иксез-чиксез публицистикасы белән беррәттән аның шул чорда (иң актив иҗат елы — 1909) «Фәтхулла хәзрәт», «Гарәфә кич төшемдә», «Бәйрәмнәр», «Картайдым», «Татар кызы», «Танымаганлыктан таныштык», «Рәхәт көн» кебек проза әсәрләре һәм татар драматургиясендә фәлсәфи юнәлешкә нигез салган «Яшьләр» драмасы языла.

Куелган проблемалары, бирелгән типлары белән Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасы И. С. Тургеневның «Аталар һәм балалар» әсәренә авваздаш икәнлеге фәндә инде әйтелде. Әмма алай гына түгел, Ф. Әмирханның бөтен иҗаты И. С. Тургеневның «Аталар һәм балалар» әсәре белән аваздаш: «Хәят», «Көндезге сәхәр, яки рузасызлар», «Кадерле минутлар», «Хәзрәт үгетләргә килде» — болар бар да бит аталар һәм балалар, ягъни искелек белән яңалык көрәше! Дөрес, татар әдәбиятында бу тема Әмирханга чаклы да бар иде. Бу көрәш бигрәк тә кадимчелек белән җәдидчелек арасындагы көрәш буларак сурәтләнә иде. Ф. Әмирхан исә бу көрәшкә яңа эчтәлек бирде: бу яңа фронтта, Җ. Вәлиди әйткәнчә, «иң беренче урынны гаилә хәяты, аталар белән балалар көрәше ала». Аталар белән балалар көрәше исә фактта феодализм богауларына, «яшь буынга җәелеп үсәргә ирек бирми торган урта гасыр калдыкларына каршы» көрәшкә әйләнә. Гаилә хәяты, аталар һәм балалар темасы рус әдәбиятында нәкъ менә И. С. Тургенев иҗатында ачык чагылыш тапкан иде. Һәм ул ярты гасыр чамасы соңгарак калып Ф. Әмирхан иҗаты белән татар әдәбиятына килеп керде. «Россия мөселманнары» дигән мәкаләсендә бу мәсьәләгә инглиз галиме Г. Вильямс та туктала. «Рус әдәбияты, бигрәк тә Тургенев иҗаты, Әмирхановка зур тәэсир ясады,— ди Г. Вильямс.— Әмирханов иҗатына гүзәллекне сиземләү, тойгылар җылылыгы хас. Бу сыйфатларны сак эш итүче, тыныч характерлы сөйләмгә өйрәнгән Идел татарлары арасында бик үк еш очрата алмыйсың...»[1]

4

1909—1911 елларда Ф. Әмирхан татар әдәбиятының энҗе-таҗыннан булган «Хәят» повестен яза. Сәнгать тарихында шундый бер легенда яши: имештер, бер скульптор үзе ясаган мәрмәр сынга — үсмер кызга гашыйк булган һәм шуның белән илһамланып яшәгән, башка бер хатын-кызны да ярата алмаган. «Хәят» повестен укып чыккач та, укучы шундый фикергә килә: юктыр, булмастыр, салкын кан белән язылган образ түгел бу. Ф. Әмирхан моңа яза башлаганда ук гашыйк булган һәм бу гыйшкы аның повесть ахырына таба гел үскән, гел дөрләгән... Ф. Әмирхан хатын-кыз дөньясын яраткан. Туганы Р. Алушиның хатыны Фәрханәгә язган хатында ул «мин инде бер кат Ш. туташ Камалованы сөйгән» дип белдерә, икенче бер кыз белән таныштыру тәкъдименнән баш тарта[2]. Клиникада ятканда да Ф. Әмирхан янына кызлар күп килә. «Кичләрдә иптәшләр вә хосусан татарка вә марҗа белешләрем һәркөнне тулып яталар, конфет белән бик сыйлыйлар» дип яза ул Р. Алушига[3].

Хәят исемле кыз, яки шуның прототибы бүлырлык тышкы кыяфәтле, язучы сурәтләгәнчә, мөлаем, белемле һәм акыллы бер яшь кыз клиникага килеп, Ф. Әмирхан белән сөйләшеп утырмагандыр дип кем әйтә ала? Язучының хыялын, иҗат фантазиясен

[1] „The Russian Review" London, 1914, p. 115

[2] «Казан утлары», 1960, 3 сан, 115 б.

[3] Шунда ук, 113—114 б.

кузгатырлык шундый кыз булганмы?.. Бу — шактый катлаулы мәсьәлә, монда дилетантлыкка авышып, әдәби образның бөтен әһәмиятен, затлылыгын югалтырга мөмкин. Шулай да, «Хәят» басылып чыкканнан бирле бу турыда укучылар арасында төрле фикер яшәп килә. «Хәят» образының ничек туувы, повестьның нинди материалга нигезләнеп язылуы турында Х. Хисматуллин һәм А. Шамов шактый кызыклы фикерләр йөртәләр. «Кояш»та басылган мәгълүматларга һәм кульязмаларга таянып А. Шамов «Хәят»ның икенче кисәге язылган булуын әйтә. Бу кисәкнең кульязма вариантыннан хәтта 28 юллык бер өлеше дә табылган. Октябрь революциясеннән соң, Ф. Әмирхан повестьның беренче кисәгенә яңадан кайткан, аны төзәткән, тагы да камилләштергән. Ләкин икенче кисәген бастырмаган. «Хәят»ның дәвамы, шулай итеп, әдәбият тарихы өчен сер булып калган. Икенче кисәкнең (булачак кисәк) планы безгә мәгълүм. Ул план 1909 елда ук инде Ф. Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык» китабының тышлык битендә басылып чыккан. Аннан күренгәнчә, Хәят үзе теләмәгән Салихка кияүгә бирелә, Салихның энесенә гашыйк булып, аның белән әтисе йортына кайта, бераздан аннан да туеп, ире йортына кире килә. Бәхетсез, фаҗигале, сирәк очрый торган язмыш... Чыннан да, бу — гадәттән тыш образның прототибы булмаганмы? Х. Хисматуллин шулай ди бит: Ф. Әмирханның күп кенә әсәрләрендә үз мохиты кешеләре чагылыш тапкан. Әгәр шулай икән — Хәятның да прототибы булуы бик мөмкин.

Кыскасы, «Хәят» образы татар әдәбиятында гел игътибар үзәгендә булып килә. Хәзер инде Ф. Әмирхан дөньяда юк. Заманында аңа бу мәсьәләдә матбугат аша сорау бирелмәгән. Үзара сөйләшүләр булгандыр, ләкин алар кәгазьгә теркәлеп калмаган. Шулай булгач, бүгенге көнне Хәят образы кемнән алып тудырылган, дигән мәсьәлә тирәсендә сүз куерту ул кадәр үк әһәмияткә ия дә була алмый инде.

Әмма Хәят — Ф. Әмирханның эстетик идеалы. Татар кызын әнә шундый итеп — үз милли телен, гореф-гадәтләрен, ата-анасын ихтирам итү белән бергә рус культурасын, Европа культурасын да үзенең хол-ына сеңдергән бөтенбер шәхес итеп күрәсе килгән аның. Хәер, Әмирхан иҗатының бу сыйфаты турында алда әйтелде инде.

Ф. Әмирхан иҗатында шундый бер үзенчәлек бар: хатын-кыз образлары анда, ничектер, ирләр образына караганда тулы канлырак, җанлырак. Хатын-кыз образлары арасында «урталыкта» торучылар юк диярлек: я алар татар кадими тормышы белән изелгәннәр («Татар кызы», «Яшьләр»дә Хәерниса, «Рәхәт көн» дә Гайниҗамал), яки алар яңалыкка омтылганнар, русның һәм Европаның прогрессив идеяләрен үзләштергәннәр («Танымаганлыктан таныштык» — Разия, «Хәят» повестенда — Хәят, «Кадерле минутлар»да Хөршит һ. б.), ләкин татар тормышы аларның бу матур омтылышларын богаулап тора.

## 5

1911 ел — татар зыялылары өчен аеруча кыен чор. Тукай Уфада М. Гафури белән очрашкач «әле генә язмыш ханым кыйнады» дип болай гына әйтмәгән. Яңа революцион күтәрелеш башлангач, патша хөкүмәте 1905 елдагы кайбер хаталарын искә ала. Ул хата нәрсәдә соң? 1905 ел революциясендә рус эшчесе һәм крестьяны белән берлектә әрмән, украин, татар, грузин, белорус эшчесе, крестьяны күтәрелде. Болар самодержавиегә каршы көрәштә ничектер уртак тел таптылар. Моны исәпкә алмыйча ярамый.

Һәм эчке эшләр Департаменты рус православие чиркәве, Мәгариф министрлыгы белән берләшеп Махсус Киңәшмә уздыралар. 1910 елда уздырылган бу киңәшмә милли окраиналарда милләтләрнең үз-үзләрен тану политикасына каршы көрәшнең тулы бер программасын эшлиләр. Бу проблема Казан губернасына бик кыйммәткә төшә.

Ф. Әмирхан бу турыда матбугатта үзе бик ачык әйтә: «Соңгы вакытларда,— ди ул,— карагруһлы рус газеталары татарларда милли хис кузгала башлады, аңар каршы ничек тә булса бер чара табарга кирәк, аның ахыры рус хөкүмәте өчен яхшыга барып чыкмый дигән мәһфүмдә яздылар. Алар фикеренчә, бу миллият рухы ысул җәдид мәктәпләре аркылы нәшер ителә икән дә, шуңар күрә бу мәктәпләр дини булудан бигрәк миллиләр имеш».[1]

Алда күрсәтелгән программа, шулай итеп, татар мәгърифәт учакларына — мәктәп, мәдрәсә, нәшрият, китапханәләргә бердәм удар ясауны күздә тота. Бу максатта татарлар арасыннан җасуслар (доносчылар) төркеме булдырыла. Болар ачыктан-ачык һәм яшерен эш итүчеләр. Ачык эш итүчеләрнең башында кадимче динчеләр, барыннан да бигрәк Ишми ишан тора. Җасусларның иң кабахәтләре исә Ф. Әмирхан, Тукай, Камал, Коләхметов, Ибраһимовлар арасына үтеп керә һәм бер фикердә булган булып, эзлекле рәвештә барысын да сата. Татар прогрессив интеллигенциясен кырып бетерү өчен патша хөкүмәте болар арасына «акрын хәрәкәт итүче» мина ташлый: татарлар, имеш, панисламизм хәрәкәтенә кушылганнар (бөтен мөселманнарны берләштергән зур дәүләт төзү идеясе), һәм бу зур дәүләтнең башында имеш Төркия торырга тиеш икән; шуңа

[1] «Йолдыз» газетасы, 1910, 569 сан.

күрә, имеш, татарлар арасында Төркия флотына иганә (взнос) җыю башланган.

Кара милләтчеләр, кадимчеләр эшкә керешәләр. Хөкүмәтнең зирәк политикасы үзен аклый: татарлар үзләре үк берсен-берсе охранкага сата башлыйлар. М. Гафури шулай Ишми ишанның корбаны була. Г. Камал өстеннән донос язалар. Ниндидер бер хаин тагы да ераграк китә: Ф. Әмирхан «Төркия флотына акча җыя» дигән ялган доносын Петербургка полиция департаментына ук җибәрә. Эш зурга китә, бөтен Казан «җасус»лар турында шаулый, аларны каргый. Доносчылар исә башкала белән генә эш итәләр. Казаннан С. Зәбиров дигән бер әүлия Эчке эшләр министры Макаровка яза: Оренбург Духовное Собрание әгъзасы Хәсәнгата Мөхәммәтов (Габәши — М. М.) учительская семинария төзү өчен акча җыя. Мөфти юбилее уңае белән ул инде 500 мең сум җыйды. 1911 елның 27 гыйнварында ул Казанга килде һәм мәүлет бәйрәме көнендә Галеев мәчетендә намаз укыды. Казан муллалары Зариф Әмирханов, Мансуров һәм Галеев тантаналы рәвештә рус патшасына бәддога укыдылар[1]».

Доносчы арттырып ук җибәргән, юк, алай булмас. Мәхәллә алдында ук патшага тел тидерергә Зариф Әмирхановның башына ат типмәгән! «Алла, бәрәкалла» дип утырсалар да, сәҗдәгә киткән кешеләр арасында күпме җасус утырганын белмимени ул!

Тикшерү исә кызыклы гына нәтиҗә бирә: З. Әмирханов патшага түгел, доносчыларга бәддога укыткан икән![2] Менә бу инде осталык! Бәддогага җасусларның үзләреннән дә кул күтәрткән Зариф хәзрәт...

Язмышы Петербургта полиция Департаментында уйнаган татар язучылары ничәү? Безнең әдәбият тарихы өчен алар күп түгел: ике, өч, бәлки, дүрттер? Арадан иң зур борчу уятканы «Яңа Бистәдәге Зариф мулла улы Фатих, язучы...»

Кем нәрсә белән шөгыльләнә бу дөньяда? Бу вакытта Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Ә. Хәсәни һәм аның хатыны З. Хәсәни татар прогрессив яшьләре өчен яңача әдәби-эстетик журнал чыгару өчен оештыру эшләре алып баралар. Кемнәрдер берәзлексез Казан губернаторына, жандарм идарәсенә, Петербургка донос язалар. Бер яктан татарлар өчен өр-яңа матбугат органы — әдәбият, сәнгать матурлыгын үзенә туплаячак «Аң» журналы әзерләнә, икенче яктан... коточкыч кабахәтлек, каралык.

...Казан губерна жандарм идарәсенең Тәтеш, Зөя һәм Чабаксар өязләре буенча ярдәмчесе үзенең «шеф»ына хәбәр итә: Казанда, ди, Зариф Әмирханов малае (Ф. Әмирхан турында сүз бара), Салихов (монысының Газиз Гобәйдуллин булуы мөмкин — М. М.) һәм Мәрҗан Баһаутдинов малайлары (Ш. Мәрҗани малае) яшьләргә бик зур йогынты ясыйлар[3]».

...Казан губернаторы да борчыла: Петербургтан Фатих Әмирхан турында информация сорыйлар. «Секретно» дигән шифр белән патша хәзрәтләре сараеның камергеры губернатор Стрижевский үзенең жандарм идарәсенә күрсәтмә бирә: Фатих Әмирханны тикшерегез әле һәм шул уңайдан Хәсәновларның да берсен тикшерегез, Төркия флотына акча җыяларммы, юкмы? һәм губернатор Казан полицмейстерына конкрет задание бирә: миңа килеп кергән мәгълүматларга караганда, ди Ф. Әмирхан инде Төркия флотына ярдәмгә 200 сум кадәр акча җыйган, подписной кәгазе юк, биргән кешеләрнең исемен үзенең кесәдәлек дәфтәренә язып бара. Бу акчаның бер өлешен Хәсәновлар җыйган һәм Ф. Әмирханга тапшырган. Бу акчаны җыю рөхсәт ителми генә түгел, бәлки тыелган икәнен дә искә алып, бик ашыгыч рәвештә бу кешеләрне җавапка тартыгыз, җыйган акчаларына конфискация ясагыз...

Шунда ук губернатор түбәндәге чинны өркетеп тә куя: бу турыда мин сезгә элегрәк тә хәбәр иткән идем. Ләкин сездән әлегә кадәр бер информация дә кергәне юк. Минем күрсәтмәләремне санга сукмау киләчәктә сезне бик авыр нәтиҗәләргә китереп чыгаруы мөмкин икәнлеген исегезгә төшерәм.

Полицмейстерга нәрсә кала инде: ашыгыч тентү ясарга. Бер көн эчендә бик күп кәгазь языла: Ф. Әмирхан Яңа Бистәдә яши икән, аяклары хәлсез икән: Хәсәниләр Евангелистлар урамында 2 нче частьта әтиләре йортында икән.

6 нчы часть приставы Желиговский хәбәр итә: Ф. Әмирхан — авыру, әтисе йортында яши һәм өлгергәнлек аттестатына әзерләнә...

Соңгысы истәлекләрдә расланмый: Ф. Әмирхан 1912 елларда инде ул уеннан кайткан булса кирәк. Димәк, пристав бернинчә ел элекке информация белән эш итә.

13 ноябрь көнне шулай бик күп кәгазь языла һәм шул ук көнне кинәт кереп тентү дә ясала.

[1] ТАССР УДА, 199 ф., 1 тасф., 2269 эш, 145 б.
[2] Шунда ук. 199 б.
[3] Шунда ук. 145 б.

## VI

1912 елның көзе — Ф. Әмирхан, Тукай, Әхмәтгәрәй Хәсәнинең яңа журнал чыгарырга әзерлек күреп йөргән көннәре. Ф. Әмирхан бу көздә чыгачак журнал өчен ике хикәя яза: «Хәзрәт үгетләргә килде» һәм «Бер хәрабәдә». Ләкин Фатих әле болар белән генә дә канәгать түгел: чыгачак журналның беренче санынннан ук программ әсәр биреп укучыларны җәлеп итәргә һәм үзеңә иртәгегә. Аң-белемгә, сәнгатькә, чын әдәбиятка сусаган яшьләр бар. Алар өчен нәрсә дә булса эшләп булмыймы шушы яңа шартларда?

Яңа журнал чыгару идеясе Фатихка тынгылык бирми. Дөрес, 1905 ел революциясе нәтиҗәсе буларак татар халкында азмы-күпме журнал, газета яшәп килә. Ләкин боларның күбесе инде прогрессив яшьләрне канәгатьләндерми. Гел сәүдәгәр, ишан, мулладан көлеп, карикатура биреп кенә дә әллә ни алга барып булмый. Искене инде байтак җимерелде, ә менә шул җимерек урынына яшьләргә нәрсә бирәсе?

Сәнгать, яңа әдәбият журналы бирәсе иде. Бу журналны чыгаруны кем үз өстенә алыр? Моңа кем секретарь (фактта журналның бөтен эшен оештыручы) булыр? Ф. Әмирхан белән Тукай әнә шул турыда уйланалар. 1912 елның эссе җәй көннәренең берсендә Әхмәтгәрәй Хәсәни үзенең Юдино янындагы дачасына (хәзерге Аккош күленнән сулга Юдино урманына кергәч) кунакка Ф. Әмирханны чакыра. Ләкин бер шарт белән: кунакка йөрергә яратмый торган Тукайны да алып киләсе. Тукай белән Әхмәтгәрәй һәм аның хатыны Зәйнәп ханым — якташлар. Шулай дачага берничә көнгә киләләр. 1912 елның бу эссе җәендә Аккош күле урманында өч кешенең киңәшеннән соң матур бер идея туа: татар яшьләре өчен әдәбият-сәнгать органы булган яңа журнал чыгара башларга; журналны чыгаруны Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәп ханым Хәсәниләр үз өсләренә алалар; журналга Тукай һәм Фатихның бердәм тәкъдиме белән «Аң» дип исем бирергә. Тарихи карар әнә шулай кабул ителә. Тукай беренче сан өчен махсус «Аң» исемле шигырь яза. Бу шигырьне журналның беренче санында тышлыкка бирәләр. Ф. Әмирхан исә беренче сан өчен махсус «Шәрык йоклый» дигән политик нәсер яза. Журналның беренче саны 1912 елның декабрь уртасында дөнья күрә. Беренче сан яшьләр арасында чын мәгънәсендә сенсация куптара. Журналның беренче битләрендә үк Париж салонынннан репродукция бирелгән. Рәссам Леконт де Ной картинасы. Анда бер көнчыгыш кешесе (төрек яки гарәпкә охшаган) йомшак паласларга таянып, наргилә тартып (төтен чигеп) йокымсырап, мәлҗерәп утырганы сурәтләнгән. Ф. Әмирхан әнә шул рәсемгә «аннотация» бирә, үзенең нәсеренә ул «рәсемгә даир» дип искәрмә бирә (ягъни шушы рәсемгә карата). Ф. Әмирхан халыкара, политик темаларга күп мәкалә, очерк язган кеше, әмма арадан иң югары поэтик һәм мәгънәви яңгырашлысы — шушы нәсер. Бу әсәр актык киеренкелектә тартылган музыкаль инструмент кылы. Язучы монда бөтен көнчыгыш-мөселманчылык дөньясына бер селтәнү белән тулы характеристика бирә: мөселманчылык идеологиясе шәрыкны артка тарта, практик эштән читләштерә, ул аны хыял белән генә яшәүгә дучар итә. Кайчандыр Ибн Сина, Әль-Фараби, Ибне Рөшдләрне тудырган көнчыгышның гыйльми көче йоклый, ул — шәрык — татлы хыяллар эчендә йоклый. «Аның бу хәленнән файдаланып, уяулар аның мәмләкәтләрен бүлешәләр, хәзинәләрен талыйлар, үзенең аяк-кулларын багълап, мәңге коллыкта сатып җибәрмәкче булалар — ул һаман йоклый!»

Ф. Әмирхан бу нәсерендә Европа империализмының көнчыгышка карата алып барган дипломатиясен, политикасын кискен гаепли, ул — бөтендөнья халыклары мәнфәгатеннән чыгып сүз сөйли: «Аның бөтен Африка шимален [1] кисеп алалар, Ираннарын, Төркстаннарын билиләр, Европадан кисәгән кубарып маташалар — ул һаман йоклый!»

«Шәрык йоклый» нәсере Ф. Әмирханның бөтен мөселманчылык торгынлыгына каршы кискен протесты булды. һәм ул шуңа күрә бүген дә заманча яңгырый.

## VII

«Кояш» 1912 елның 10 декабреннән чыга башлый. Газетаның юнәлешен аның редакторы Зәкәрия Садретдинов билгели: газета — либераль-буржуаз юнәлештә. Ягъни, самодержавиенең асылына, нигезенә тел тидерми, хосусый милекчелеккә дә тәнкыйть юк. Ләкин газетаның фактическая төп хезмәткәре Ф. Әмирхан була һәм «хуҗа»ның артык вакланмавыннан файдаланып Ф. Әмирхан монда карагруһчылыкны, милләтчелекне, империалистик дәүләтләрнең реакцион халыкара политикасын тәнкыйть иткән байтак материал урнаштыра. Шуңадыр инде, редактор З. Садретдиновның полициянең яшерен күзәтүе астыннан башы чыкмый, гел тикшерелә, гел җавапка тартыла. Фатих Әмирхан исә «Кояш»та җиң сызганып эшли, киң планлы матбугат көрәше ача. Либераль матбугатны ничек файдаланасын яхшы белә ул: «Кояш»ка кадәр ул үткен генә мәкаләләрен үтә либераль

[1] Шималь — төньяк.

газета «Йолдыз»да бастырып караган иде. «Йолдыз» — күпме генә әрләмәсеннәр, татар прогрессив культурасы үсеше өчен зур эш эшли. Анда Ф. Әмирхан, Тукай, Г. Ибраһимов, Г. Камал, М. Гафури, Х. Искәндәрев һ. б. искиткеч кыю әдәби әсәрләрен, тәнкыйть-публицистика бастыралар. «Кояш» та шул юлны сайлап ала. Ф. Әмирхан монда милли сәнгать-культура үсеше мәсьәләләрен күтәрә, рус әдәбиятының дөньякүләм әһәмияте (Лермонтов, Короленко) турында кыю-кыю чыгыш ясый, татар морзаларының үз халкына карата алып барган «бариннарча» кимсетүле карашларын фаш итә. Нәрсә турында гына язмасын, Ф. Әмирханның бөтен иҗаты буенча җитәкче, әйдәп баручы идея ярылып ята: ул — аның дөньяга карашында тирәнтеннән килүче интернационализм. Бу мәсьәләдә Ф. Әмирхан — таш кыя кебек нык, ортодокс.

Тәнкыйтьче буларак, Ф. Әмирхан гомере буе Тукай иҗатын ялгыш бәя алудан саклап, шагыйрь исән вакытта аңа ярдәм итеп килде. Ф. Әмирханның иҗат эшчәнлегендә, ничектер, Тукай белән параллель туа. Тукай 1911—1913 елларда нинди генә тема күтәрмәсен, я бөтен ил күләмендә, я бөтен дөнья күләмендәге мәсьәлә. Ф. Әмирханда да шулай.

Ф. Әмирхан публицистикасының октябрь революциясенә кадәрге югары нокталарыннан берсе — ихтимал, аның «Богаулар өзелделәр» исемле мәкаләседер. Самодержавиенең бәреп төшерелүен ул «богаулар өзелү», «коллык мөһере» ватылу дип бәяли, царизмның моңа кадәр татарлар арасында алып барган реакцион политикасын гаепли. Дөрес, мәкаләдә әле чикләнгәнлек бар: февраль революциясе әле изелгән милләтләргә тулы хокук бирә алмады, моны бары тик Октябрь революциясе нәтиҗәсе буларак Совет власте гына хәл итте. Әнә шуңа күрә, «Кояш» газетасы Ф. Әмирхан катнашы белән язылган 1917 ел 26 ноябрь санындагы мәкаләсендә Совет хөкүмәтенең Россия халыклары хокукларының Декларациясендәге «Милли һәм дини чикләүләрне бетерү турында» положениене яклап чыга.

Өйрәнәсе мәсьәләләр арасыннан бер өлкәне әйтеп үтмичә мөмкин түгел: Ф. Әмирхан — татар реалистик әдәби тәнкыйтенә нигез салучы әдип. Ул яза башлаган елларда татарда әдәби тәнкыйть формалаша. Ләкин тәнкыйть белән тәнкыйть арасында аерма бар. Бирәүләр әдәби әсәрнең эчтәлеген сөйләп чыгалар да «Мәүзугы (сюжет) бик кызыклы, яхшы кәгазьдә басылган, бәһасе 10 тиен» кебек «бәя» бирүдән уза алмыйлар. Ф. Әмирхан исә яңа әсәргә бәя биргәндә ике яктан — әдәби-эстетик һәм социаль-политик яктан торып бәя бирә. Нинди генә әсәргә бәя бирмәсен, Г. Камал пьесаларынамы, Г. Тукай шигырьләренәме — ул әлеге әсәрне татар мәгыйшәтен (тормышын) ни дәрәҗәдә дөрес чагылдыруыннан чыгып бәяли һәм язучыга теләк формасында алга таба юл күрсәтә.

Ф. Әмирхан язган тәнкыйть мәкаләләре арасында үзенең социаль яңгырашы һәм реализмга өндәве белән иң көчлесе, әлбәттә, «Ачлык кушты» драмасына язган рецензиясе (Я. Вәли әсәре). Драманың эчтәлеге реаль вакыйгаларга нигезләнгән: ачлык елны бер гаиләдән буй җиткән кызны Урта Азиядән килгән маклерга сатып җибәрәләр. Ул кыз кулдан-кулга сатылып йөреп, ахырдан үзен-үзе харап итә.

Драматургның язуынча һәм әйтергә теләвенчә, бу кызның фаҗигасенә әнисенең явызлыгы сәбәп була. Кызны сатып җибәрер алдыннан йортта бәхәс бара: әтисе, бирмик, ничек тә булса исән калырбыз, ди, әмма әнисе кызны сату ягында була. Ф. Әмирхан бу әсәрдәге реализмга уңай бәя бирә дә, иң йомшак урынын тотып ала: «мондый олуг темалар, хосусан, бөтен бер халыкның хәтта бер мәмләкәтнең халәте икътисадиясеннән (экономик хәленнән) килгән күренешләр хакында язылган драмалар социальный характерда язылырга вә асыл сәбәп булган яманлык... укучы күз алдында тәрсим ителергә (сурәтләнергә) тиештер. Әмма «Ачлык кушты» драмасы нәкъ шушы нәрсәләрдән мәхрүм». Әсәрдә, ди Ф. Әмирхан, «ачлыкның сәбәпләренә гаид (кагылышлы) бернәрсә дә күренми».

Әдәби әсәрләргә шундый ук таләпләр аның «Китаплар хакында мөхакәмә» (хөкем чыгару) исемле мәкаләләр циклында да нигез итеп алынган. М. Гафуриның «Ярлылар, яки өйдәш хатын» дигән хикәясендә дә ачлыкның социаль күренеш буларак тасвирланмавы тәнкыйтьчегә ошамый. Тәнкыйть өлкәсендә Ф. Әмирхан бик кыю: ул тәнкыйтьтә тарихилыкны яклый, әдәби әсәрләрдә гуманистик идеяләр үткәрү кирәклеген әйтә. Мәсәлән, З. Бигиевнең «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исемле әсәрендә ул буржуаз фикерләр уздырылганын әйтә. Урта Азия буйлап сәяхәт иткәндә, З. Бигиев Аксак Тимерне искә ала һәм төрки халыклар арасыннан шундый Җиһангир чыгуы белән горурланам, дип яза. Үткен күзле тәнкыйтьче (Ф. Әмирханны заманында «татарның карчыга күзле тәнкыйтьчесе» дип атаучылар да була) Ф. Әмирхан исә авторның бу фикеренә каршы чыга. Җиһангир булыр өчен генә түгелгән каннар, җимерелгән шәһәрләрне исәпкә алганда, ди ул, бу сүзләр урта гасыр рыцарьларына гына хас сүзләр.

«Гомуме инсаният сәгадә-е өчен эшләнгән эш — менә нәрсә генә мәдаре ифтихардыр»[1].

[1] Гомуме инсаният — бөтен кешелек; сәгадәт — бәхет; мәдаре ифтихар — мактану чарасы.

Совет чорына Ф. Әмирхан күпмедер дәрәҗәдә хаталар, адашулар, эзләнүләр аша атлый. Әмма хаталардан тиз айный. В. И. Ленин шулай ди бит: «Акыллы кеше ялгышлар ясамый торган кеше түгел. Андый кешеләр юк һәм булуы мөмкин дә түгел. Бик үк зур булмаган ялгышлар ясап та, аларны җиңел һәм тиз төзәтә белгән кеше акыллы»[1].



*Ф. Әмирхан. 1916 ел, июнь (Матбугатта беренче тапкыр басыла).*

Ф. Әмирханның марксизмга мәхәббәте күптәннән килә иде. Әле 1906 елда ук яшь Фатих «Әлгасрел-җәдид» журналының 6 нчы санында Париж Коммунасына багышланган тәрҗемәсен бастыра. Әдипнең бу тәҗрибәсе «символик мәгънәгә ия. Ул Ф. Әмирханның тормышта нинди юл сайлавын, дөньяга карашы һәм рухи-политик үсешенең, эзләнүләренең кай тарафка юнәлгән булуын ачык күрсәтә»[2].

Бу вакытта аңа — 20 яшь. Беренче империалистик сугыш елларында да, Ф. Әмирхан сугышка мөнәсәбәттә ленинчыл позициядә тора. Аның бу мөнәсәбәте патша жандармериясенә дә мәгълүм була. Аның турында сугыш вакытында язылган бер справкада болай диелә: «...бу сугышта Россия җиңеп чыкса, ди Ф. Әмирхан, реакция бик нык көчәячәк, ә реакция көчәюдән, иң башлап, инородецлар, шул җөмләдән, мөселманнар да бик нык зарар күрәчәкләр»[3].

Шунысы характерлы, Октябрь революциясеннән соң язган хезмәтләренең астына ул «Марксист» дигән псевдоним белән имза куя башлый. Ф. Әмирхан Октябрь революциясеннән соң яңа рух белән шәрыкъ халыкларының азатлыгы мәсьәләсен күтәрә. 1912 елда «Шәрык йоклый» дип ачынган язучы 1920 елда инде «Шәрык уяна» дигән көчле пафослы мәкалә язып чыга. Мәкаләнең язылу мөнәсәбәте дә тарихи. 1919 елның ахырында Мәскәүдә Көнчыгыш халыклары коммунистларының съезды җыела. Съездда В. И. Ленин чыгыш ясый. Чыгышында ул Октябрь революциясе тәэсире белән Көнчыгышта азатлык хәрәкәте кабынып китү, көнчыгышның уянуы турында сөйли. Ул вакытта В. И. Ленин болай дигән иде: «Көнчыгыш халыклары практик эш итү өчен һәм һәрбер халык бөтен кешелекнең язмышы мәсьәләсен хәл итсен өчен уяналар»[4]. Ф. Әмирханның бу мәкаләсе В. И. Ленинның шул чыгышы йогынтысында язылган.

«Богауланган Прометей» әнә шулай яңа шартларда эшлекле, көрәшле, тулы тормыш алып бару турында хыяллана. Ләкин паралич кына түгел, мәкерле үпкә туберкулезы да аны эчтән кимерә инде.

* * *

Озакка сузылган каты авырудан соң Ф. Әмирхан 1926 елның 9 мартында дөньядан китә.

...Казан шәһәренең читендә, карт юкәләр белән капланган чал зират сукмакларының берсе кырыеңдагы каберда Фатих Әмирхан ята. Ул яшь килеш үз халкын яңа, якты тормышка чыгарыр өчен, каләм белән көрәш башлады, ул кыска гына гомерендә титаннарча эшләп гасырларга, күп буыннарга мәгънәле, файдалы иҗат калдырды.

Чәчәкләр китерик аның каберенә!

[1] Ленин В. И. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 31 т., 20 б.
[2] Әмирхан Ф. Әсәрләр, 1 т. 1984, 460 б. М. Хәсәнов мәкаләсеннән.
[3] ТАССР ҮДА, 199 ф., 1 тасв. 3620 эш., 165 б.
[4] Ленин В. И. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 30 т. 147 б.

## Зәйнәп Әмирханова

# АБЫЕМ ТУРЫНДА

*Зәйнәп апа (1893—1977) белән Фатих Әмирханның әтиләре Нәҗип һәм Зариф бертуган. Шуңа күрә абый белән сеңел бер-берсенә карата бик якын, дусларча мөнәсәбәттә булганнар. Зәйнәп апа югары белемле кеше иде, үз вакытында ул Бакуда география һәм медицина факультетлары тәмам итеп, ике дипломга ия булган, 30 ел врач (әле пенсиягә чыккач та берничә ел эшләде), 20 ел укытучы булып эшләгән. Үз вакытында Фатих Әмирхан турында истәлекләр язарга бик җыенса да, картлар гадәтенчә, һаман кәефе килгәнне көтеп, кичектерә килде һәм теләген тормышка ашыра алмый калды. Түбәндә язылган фактларны ул миңа (гомумән, бик күп туганнарына) дистәләрчә мәртәбә сөйләгән булганлыктан, алар хәтердә бик тирән сеңеп калганнар. Кайвакытта мин аның фикерен төзәткәләгәндә, ул үзе дә хәйран калып, боларын син каян беләсең, дип сорый торган иде. Зәйнәп апа белән 5-6 ел бергә тору, 15 еллап якыннан аралашу дәверендә аннан Фатих Әмирхан турында ишетеп калган нәрсәләрне түкми-чәчми кәгазьгә салуны үземнең изге бурычым дип саныйм. Уңай булсын өчен, истәлекләрне беренче заттан, Зәйнәп апа исеменнән бирүне кирәк таптым.*

*Равил ӘМИРХАНОВ,*
*тарих фәннәре кандидаты.*

...Минем иң ихтирам, хөрмәт иткән кешеләрем әти белән Фатих абый булды. Искиткеч кешеләр иде алар. Фатих абый белән исә теләсә нинди проблеманы уртага салып сөйләшергә, хәл итәргә була иде. Ул безнең гаиләне бик үз итә, аның шатлыкларын, кайгыларын уртаклаша. Миңа һәрвакыт олы кешегә мөрәҗәгать иткән кебек сөйләште, беркайчан да тупас ирония кулланмады. «Сеңелем», «сеңелкәем», «газизем» сүзләрен ул «Зәйнәп»кә караганда ешрак файдаланды. Безнең гаилә ишле иде. Исән балалар гына җиде, яшьли үлгәннәрен дә кушсаң, уннан артып китә иде. Мин гаиләдә иң олы бала булып үстем. Мәхмүт, Гомәр, Габделкадыйр, Госман, һава, Рәшит — миннән соң туганнар. Мулла гаиләсендә үссәк тә, балда-майда йөзмәдек без. Тормыш авырлыкларын да аз кичерергә туры килмәгәндер. Шуңа күрә Фатих абыйның ачынып, «бигрәк күп инде сез, сеңелем, җыеп алып булмый бит», дип әйткәләгәне исемдә...

Фатих абый белән беренче танышу миңа 4—5 яшьләр чамасы вакытта булгандыр. Бик бәләкәй идем әле мин. Әмма бу танышу миндә бер дә артык күңелле булып хәтердә сакланмаган. Дәү әтинең Яңа Бистәдәге йортының ишегалдында Фатих абый миңа үзенең «абыйлыгын» болай күрсәтте: ул җиргә чүгәли дә «дөя» була. Янәсе сеңелесен җилкәсенә утыртырга өнди. Мин, шундый шатланып, абыйның муенына атланырга дип йөгерәм. Инде аңа ябышам дигәндә генә, бу торып йөгереп китә. Мин елыйм. Абый, юаткан булып, тагын чүгәли. Шул рәвешле ишегалдын 5—6 мәртәбә елатып урагannan соң, «дөя», ниһаять, «кәрванбашын» җилкәсенә атландыра. Их, күңелле дә соң абый җилкәсендә! Ләкин озак йөртми, «өркәчләрем талды» дип хәйләләп, кире җиргә төшерә. Мин тагын балавыз сыгам, ул тагын юата.

Фатих абыйның шул рәвешле мәзәкчеллек сыйфаты яшьтән үк күзгә ташланып тора иде.

Кичке чәйдән соң дәү әтинең өендә газит уку гадәткә кергән хәл. Дәү әти, күбесенчә үзе укымыйча, мендәргә таянып, Фатих абыйның укуын тыңлый.

— Фатих, бүгенге хәбәрләрне баштан ук укып җибәр әле, улым.

— Баштан ук дисезме, тәкъсир? Баш өсте. Әүвәлге сәхифә. Милади фәлән сәнә, март фәлән, сәнәи һиҗрия фәлән, рабигыль әүвәл фәлән, еллык бәһасе фәлән тиен,— дип тезеп китә.

— И, улым, мин бит сиңа аларын укырга димәдем, баштан гына, дидем.

— Баштан ук шулай диләр аны.— Шуннан соң, Фатих абый «Казан, фәләненче көн» дигән баш мәкаләне сайлап ала да, моңлы итеп сузып, үзе әйтмешли, «мисыр мәкаме» белән азан әйткән кеше кебек суза башлый иде. Дәү әти, түзмичә, урыныннан тора да, газитне кулына алып, үзе укый башлый. Фатих абый, «мин укыган ошамадымыни?»» дип, үпкәләгән булып, күзлек пыялаларын сөртергә тотына...

Фатих абый минем күз алдымда европача фикер йөртә торган, киң диапазонлы интеллигент бер кеше булып калган.

Аның бүлмәсе үзенә аерым. Шунда шәхси китапханәсе бар. Фатих абыйның Ж. Верн, М. Ю. Лермонтов, Н. В. Гоголь, В. А. Жуковский, В. Г. Короленко, И. А. Бунин әсәрләрен укып утырганын еш күрә идем. Аңарда К. Насыйри китаплары, Ш. Рәхмәтуллин календарьлары «Әбугалисина», «Кәлилә вә Димнә»[1], М. Гафури әсәрләре дә бар иде. Заменгофның «Эсперанто»[2] исемле китабын да хәтерлим.

Фатих абый төннәр буена яза, укый, көндезләрен дә ашарга-эчәргә аңа еш кына бүлмәсенә кертәләр. Соңрак, Казанда гимназиядә укыганда, мин аның янында еш булам, кайвакытта куныл та кала торган идем. Фатих абый, төнлә йокламаганга, язуыннан тукталып торган чакларында, без аның белән таң атканчы сөйләшеп чыгабыз. Нинди генә проблемалар турында сүз кузгатмый иде ул! Чит илләр, рус, татар әдәбияты, эсперанто, тарих, астрономия, театр, культура мәсьәләләре... Фатих абый Көнчыгышның философлары, тарихчы галимнәре белән дә кызыксынды. Әл-Җәзири, Әхмәт Мидхәт, Мөхәммәт Габдеһ, Сәгадетдин Тәфтазани, Җамалетдин әл-Әфганилар турында сөйли, билгеле, мин кайбер нәрсәләрне аңлап та җиткермим. Шуннан соң кызыксынып китеп, аларның китапларын сорап алып укый торган булдым. Әдип рус һәм татар әдәбияты, татар театры, татар халкының киләчәге турында сүз ача, кайвакыт бәхәсләшеп тә китәбез. Ул Луи Блан, Лассаль тәгълиматларын үзләштерде. «Демон», «Фауст» операларын ярата иде. Сирәк кенә аның ул операларны тыңларга барганын да хәтерлим. Буш вакыты булдымы, бер-ике уен-көлке казып чыгару гадәте бар иде:— Зәйнәп, минем аякларым синекеннән яхшырак, шөйлә аларны синекеләргә һич тә алыштырмас идем.

Мин абыйның гайре табигый, йөрми торган аякларына карыйм да, көрсенеп:— Нишләп, Фатих абый, алай дисең, синекеләр йөрми бит,— дип куям.

— Һи, юләр, аның бөтен хикмәте дә шунда шул, минем аяклар ботинка туздырмыйлар...

Бервакыт мин Фатих абыйны искиткеч күтәренке кәефле бер хәлдә күрдем. Минем кергәнне күргәч, ул утырырга ишарә ясады да:

— Беләсеңме, сеңелем, мин нәрсә яздым әле? Бер мөтәгассыйб картны кырык ике елдан соң тергезеп, аның яңа дөньяда үзен ничек тотышын тасвирладым. Менә тыңла...— дип, ниндидер хәзрәтнең йомыркалар, тәлинкәләр атып, җикеренеп, каядыр чыгарга тырышып азапланганын укый башлады. Минем бик бирелеп тыңлавыма кәефе килеп, Фатих абый тагын да шәбәеп китте. Нәкъ сәхнәдәге артистларча... Күп еллардан соң гына мин бу язманың «Фәтхулла хәзрәт» булуын белдем һәм үземнең бу көчле сатирик әсәрне беренче тыңлаучылардан булуымны аңладым. Ул вакытта әдәби мәсьәләләрдән бик ерак идем шул мин. Уналты-унҗиде яшьлек үсмер гимназистка кызның башы боларны бик сыйдырмагандыр күрәсең...

Фатих абый үзенең тышкы кыяфәте турында югары фикердә түгел иде. Аннан еш кына «минем иреннәрем негрныкы кебек калын», үзем «мәхәббәтсез» һ. б. шундый сүзләрне ишетергә туры килә иде. Ләкин монда көенүнең әсәре дә юк! Аның белән аңгәмәдәш булган кеше Фатих абыйны, һичшиксез, искиткеч мөлаем, игътибарлы, сөйкемле, ачык күңелле кеше дип таный иде. Ул кызык, җанлы, мавыктыргыч итеп сөйли, эрудициясе ташып тора, кискен сүз әйтсәләр дә, кашын-күзен җыермый, иләп кенә үз фикерен әйтеп бетерә, гасабиланып, кызып китми.

Аның бер әчке сыйфатын да әйтеп китми булмый: аңарда мәзәкчәнлек белән бергә, яшерен, нечкә ирония бик көчле иде. Йомшак әйтеп, каты утырта белә иде ул. Бу сыйфаты күп кенә әсәрләрендә дә чагыла. «Сәмигулла абзый», «Таңс кичәсе», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Салихҗан кари» хикәяләрен генә алыйк. Күпме нечкә ирония, читләтеп көлү җыелган аларда.

Абый татар халкының үткәне, бүгенгесе, киләчәге белән бик кызыксына, шул проблемаларны уйлап яна иде. Фанатик адәмнәргә, надан муллаларга, аңгыра мәхдүмнәргә, байбәтчәләргә карата ул ифрат тискәре, иронияле мөнәсәбәттә булды, алар турында чәнечкеле сүзләрне теленнән төшермәде. Хәтта шул җирлектә Фатих абый белән дәү әти арасында низагълар да чыга торды. «Идел буе татарлары, гарәпләрнең корәеш кабиләсе[3] кебек, төрки халыклар арасында иң алга киткәннәре. Әнә шул кара йөз мөтәгассыйб адәмнәр аркасында бездә хәзер сәфаләт тә җәһаләт»,— ди торган иде ул.

Фатих абый мине дә туган халкыма, аның мәдәниятына ихтирам рухында тәрбияләргә тырышты. Чистайга язган бер хатында ул миңа: «Казанга килеп чык, юләр кызый. Монда кил, татар яшьләренә катышырсың, дөньяга күзең ачылыр», дип язды. Казанга килгәләп йөргәндә, ул мине гел үз тирәсенә тартырга омтылды, минем гарәп телен яхшы белүемне файдалану мөмкин булачагын тәкърарлады. Гарәпчәгә мине әти өйрәтте, фар-

[1] «Кәлилә вә Димнә» — Һиндстанда барлыкка килгән әдәби ядкарь, хайваннар турындагы хикәяләр аша патшаларны, дәүләт җитәкчеләрен гадел идарә итәргә өйрәтүче дидактик әсәр. Г. Фәезханов тәрҗемә иткән.
[2] Эсперанто — халыкара аралашу өчен 1877 елда Варшава врачы Л. Заменгоф тарафыннан эшләнгән ясалма тел. Шул исемдәге китап 1889 елда Варшавада чыга.
[3] Корәеш кабиләсе — гарәпләрдә иң алга киткән кабиләләрдән саналган. Мөхәммәт пәйгамбәр чыгышы буенча шул кабиләдән.

сыга әйрәтеп җиткерә алмаганга ул еш кына уфтана иде. Ике-өч мәртәбә Фатих абыйга ияреп, «Әльнслах»ка баруым хәтеремдә калган. Бер мәртәбә күземә Тукай да чалынып китте. «Чалынып» дим, чөнки абый белән ниндидер кәгазьләрне тәртипкә салып утырганда ишектән бер малай сымак яшүсмер кереп, түргә таба килә башлаган иде, мине күргәч, корт чаккандай, атылып чыгып китте. Фатих абый: «Кер, монда минем кечкенә сеңелем генә, башка хатын-кыз юк»,— дип кычкырып караса да, «малай»дан җилләр исте. «Кем ул!»— дип соравыма каршы, Фатих абый гади генә итеп: «Тукай» — дип куйды.

— Тукай? Теге мәшһүр шагыйрьме? Нигә соң син мине аның белән таныштырмадың?

— Һе, таныштырырсың Тукай белән! Коярык кыска шул аның.

1914 елда Казанга килеп, Ряхинаның хосусый гимназиясенең[1] 8 нче сыйныфына укырга кергәч, безнең Фатих абый белән аралар тагын да якынайды. Без инде шәхси пландагы мәсьәләләр хакында да бик җитди рәвештә сөйләшә башладык. Бу вакытта әти белән әни миңа кияү эзләү хәсрәтенә чынлап торып керешкәннәр һәм тирә-юньдәге барлык «асыл егетләрне» кыл иләктән үткәреп бетергәннәр иде. Әни дә, әти дә, яучылар кабул иткәннән соң, миңа булачак кияүләрнең теләкләрен, тәкъдимнәрен ирештереп тордылар. Әмма мин барысыннан да баш тарта килдем. Ул замандагы бульвар романнарындагы арыслан йөрәкле, мәһабәт рыцарь һаман очрамый иде әле. Өметсезләнә башлаган ата-ана тезгенне тарта төшәргә булганнар ахры. Кайдадыр Төркестаннан кунакка килгән бер бай егетне (Муса Акъегетов исемлерәк түгел микән? — Р. Ә.) миңа күккә чөеп мактадылар. Бай, яшь (25 тә) куркәм, ыспай, бозылмаган икән үзе, кибетләре, таш пулатлары бар, алтын-көмеше бихисап... Минем бер гимназист егеткә гашыйк тотып йөргән чак булдымы, байбәтчәдән кискен төстә баш тарттым. Әти үпкәләде. Мин: «Әти, сезне ташлап, еракка китәргә теләмим»,— дигәч, йомшарып: «Кызым, үзең кара инде, без сиңа яхшылык кына телибез»,— диде. Көчләп кияүгә бирү дигән нәрсә әтигә хас нәрсә түгел, ул аны кыргыйлык дип хисаплый, шуның өстенә ул мине бик ярата иде.

Күрәсең, димләү эшенә Фатих абыйны да тартканнар. Аның миңа зур йогынтысын һәм туганнарча мөнәсәбәтен яхшы белгән әти, әни, дәү әти мине «туры юлга күндерү»не Фатих абыйга тапшырганнар, күрәсең. Бер заман, 1915 ел булгандыр, абый мине тарантасына утыртып шәһәргә алып чыгып китте. Проломныйдан Воскресенскига Лобачевский урамы турысыннан менәбез. Атны үз җаена куеп, шактый озак уйланып барганнан соң, Фатих абый миңа болай диде:

— Зәйнәп, менә инде буй җиткән кыз булдың, гимназияне дә тәмам иттең. Дөньяны да акны карадан аерасың. Кыскасы шул: үзеңә уңышлы партия ясарга вакыт. Бай кешегә чыгам дисәң, Мусадан (исеме тәгәлмә юкмы, белмим.— Р. Ә.) да кулае булмас... Егет җавап көтә...— һәм ул миңа фоторәсем сузды.

...Төскә-биткә тел-теш тидерерлек түгел анысы. Тик менә мыегы куерак булсачы, бер як чылгые да күтәрелебрәк тора. Маңгае да таррак түгелме соң моның? Аларына гына түзәр идең әле, түбәтәен артык кыңгыр салган, хәерсез.

Фатих абый мине дикъкать белән күзәтеп торды. Күрәсең, мәсьәләгә җитди карый иде.

— Фатих абый, аның белеме ничегрәк соң, нәрсә тәмамлаган?

— Мәдрәсә. Зыялы гына егет.

Мин уйга калдым. Ксенинская гимназия[2] турысына җитеп киләбез. «Соң бит ул «зыялы» егет мин укыган алгебра белән геометрияне дә белми. Мин, гимназия бетергән учительница, ниндидер сәүдәгәргә... Тиремазар белән сату итми микән әле үзе? Бәлки Чистайдагыча «кәләвәнең кайнары, агып тора майлары» дип базар тутырып сөрән сала торгандыр?! Бррр — Бармыйм, бармыйм, бармыйм! Теләсәгез нишләгез,— дип үрсәләнә башладым мин.

Фатих абыйның йөзе башта кырысланып киткән төсле булды да, аннары ул елмая төшеп: «Чү, юләр, тыпырчынма, сине берәү дә көчләп кияүгә бирергә җыенмый. Бигайбә, үз язмышың үз кулыңда»,— дип куйды. Мин үрсәләнеп, үзем дә сизмичә, тарантастан төшеп тә калганмын. Фатих абый атын юри чаптырып китмәсенме! Мин йөгергән саен ат кызулый бара. Фатих абый миннән көлә, «Кире беткән кәләштән өректе бит бахбай»,— ди бу.— Тәпи-тәпи генә бар әле, ат әзрәк ял итәр»,— дип өсти. Мин ялынып, шактый җир җәяү үтәргә мәҗбүр булдым. Ахыр, ул атны туктатып мине утыртты да, кияү турында янә башка беркайчан да сүз катмады.

Хәтерем ялгышмаса, Фатих абый беркайчан да исәпкә нигезләнгән никахны хупламады. Әнинең сеңлесе Өммегөлсем апа фабрикант Акчуриннарның берсенә кияүгә чыккач, аның бик кәефе кырылды: «Тапкан икән чыгар кеше!» Кемдер аңа: «Ул бит Акчурингa яратып чыкты» дигәч, Фатих абый: «Яратты пычагым, аның Акчурин алтыннарына һушы китте»,— дигән.

Фатих абый мине гимназистка вакытта гадәтенчә йомшак кына үртәргә теләп булса кирәк, еш кына хатын-кыз, кәләш мәсьәләсен кузгата торган иде. «Зәйнәп, өйләнимме? Барысы да синең киңәшкә терәлгән. Фати-

---

[1] Ряхина хосусый гимназиясе хәзерге Горький урамындагы Кекин йортына урнашкан булган.

[2] Ксенинская гимназия — хәзер СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы бинасы.

хаңны бирсәң, абыең бүген-иртәгә башлы-күзле булачак». Йөрми торган абыемның чыннан да өйләнергә теләге бар дип уйлап, мин чын күңелдән: «Өйлән соң, Фатих абый! Кәләшең кем?»— дип сорап куям. Абый азрак уйга бирелгән булып тора да: «Их, иннеккершәнне дә азрак ягынса»,— дип, «кәләшеннән» тагын «җитешсезлек» таба. Икенче вакыт мин аңа өйләнмәскә киңәш бирәм дә, ул мине үртәп, чын-чынлап бер «фәрештәне» күккә чөеп мактарга тотына. Бу хәлләр креслога береккән кешенең үз күңелен үзе юату идеме, тирә-юньдәгеләрнең аның өйләнүенә фикерен белергә теләү идеме — ачык әйтә алмыйм. Һәрхәлдә аның аяксыз вакытта да талпынгалап куйганын хәтерлим.

— Карале, сеңелкәем,— ди ул миңа бервакыт.— Шәмсениса туташның[1] күзләре матур бит? Мин зәгыйфь кешенең хәтере калмасын өчен бәхәсләшмим. Шәмсениса апа әнинең кече сеңелләреннән берсе, миңа калса, төскә-биткә әллә ни искитәрлек түгел иде. Мәгәр күзләренең сөрмәле сихрилеген инкарь итә алмыйм. Фатих абый минем алда аның турында шактый еш искә төшерә торган иде. «Өйләнсәм, шул Шәмсениса туташка гына өйләнер идем»— дигәне дә хәтеремдә калган.

Фатих абый Казанда мине алдынгы татар яшьләре тормышына алып керергә тырышуы турында әйткән идем инде. Әти Чистайда булгач, Казанда төрле кичәләргә йөрүгә миңа киртә юк иде. Тора-бара инде мин шушындый бернично кичәгә барып, татар яшьләре белән аралашуда ләззәт ала башлаган идем. Фатих абыйларда да еш булам, кунып та калгалыйм.

Бервакыт чираттагы әдәби-музыкаль кичә бик соң, ялгышмасам, сәгать өчләр тирәсендә генә бетте. Яңа Бистәгә, Фатих абыйларга кайтырга кирәк. Мөгаен, ул әле бүлмәсендә язып ята торгандыр. Һич булмаганда аның янына гына керергә була, дәү әтигә сиздермәссең бит инде. Хәвефләнүләрем урынсыз булды. Шылт иткән тавыш та юк. Мин йокы бүлмәсенә тәрәзәдән генә кердем дә, кайтканымны кеше-фәлән сизмәде дип куанып, тынычланып йокларга яттым. Иртә белән чәйгә торсам, ни күрим, өстәл артында гәпләшеп дәү әти белән әти утыра. Җылы итеп күрештек, өй-гаилә хәлләре турында әңгәмә куерып китте. Әти минем хәл-әхвәлне кат-кат сорашты, өс-башымны, чыраемны мөлаем гына күздән кичерде. Мине сагынганлыгы сизелеп тора иде. Чәй килгәч, азрак утырганнан соң, аны-моны уйлап тормый торган дәү әти:

— Бүген төнлә Зәйнәп туташ ишектән кергәнме, тишектәнме — белми калдык,— дип куймасынмы!

Мин җир ярылса, җир астына төшеп китәргә әзер идем. Димәк, сизгәннәр... Әтигә карадым: аның ачык йөзенә кинәт кенә тирән ризасызлык, рәнҗү билгесе чыккан иде. Күзләрем ирексездән Фатих абыйның күзләре белән очрашты. Ул мәгънәле көлемсерәп, сиздермичә генә ымлап куйды: каушама, янәсе. Һәр ике як (әти һәм мин) өчен уңайсыз булган киеренкелекне йомшарту йөзеннән ул тиз генә әтигә хитаб итеп,сүзне уратып алып китеп, аның Чистай хәлләрен, гаиләсенең исән-иминлеген сораштыра башлады. Сүз «Камалия», «Әмирхания» мәдрәсәләре, андагы мәдәни тормыш турында кузгалып китте. Әти Фатих абыйны бик якын күргәнгә, алар арасындагы әңгәмә гел дустанә рәвештә бара иде. Әти, көрсенә төшеп, Чистайның Зәңгәр Сәлах ише байлардан зарланды, аларның мәгърифәт эшенә аяк чалуларын, үзенә яла ягып, төрле корткычлыклар-эшләүләрен бәян кылды. «Китәр идем шул фиргавеннәрдән, мәктәпләрем кызганыч»,— диде. Ул Чистайда ике мәртәбә өенә ут төртүләрен, донос язып тентү ясатканнарын сөйләде. Думага сайлаулар алдыннан үзенең төрмәгә утыртылуын әйтте һәм Казанга күчеп килергә күптән хыялланиуын белдерде.

Фатих абый, минем өскә төшәчәк күңелсезлекне шулай оста таратуына куанып, миңа икенче бүлмәгә шылырга ишарә ясады. Кызу әңгәмә белән мәшгуль булган әти белән дәү әти минем чәй бүлмәсеннән чыгып китүемне сизми дә калдылар...

Фатих абыйны соңгы мәртәбә 1916—1917 елларда күргәнмендер. Ләкин соңгы очрашуларның хатирәләре хәтердән җуелган инде. Шуннан соң мин Бакуда яшәдем, Казанга 50 елларның азагында гына кайта алдым. Шулай итеп, унынчы елларның ахыры, егерменче елларның башларында минем Фатих абый белән аралашуым хатлар рәвешендә генә булды...

Игътибарга лаеклы тагын бер фактны әйтеп үтәсем килә. Фатих абыйның бертуган энесе Ибраһим алдында абруе зур булуын, Ибраһимның абыйсы фикере белән нык хисаплашканын мин кече яшьтән үк күреп үстем. Ибраһим абый 1918 елның февралендә большевиклар партиясе сафына керде. Миңа язган хатларыннан аңлашылганча, монда, Ибраһимның үз теләге өстенә, әдипнең дә тәэсире зур булган. Ибраһим абый гомеренең соңгы көннәренә кадәр Октябрь революциясе идеалларына турылыклы булып калды...

[1] Шәмсениса туташ — Шәмсениса Закир кызы Камалова (1886—1930) — укытучы.
[2] Ибраһим Зариф улы Әмирханов (1889—1939) — Кырымда, Татарстанда юстиция органнарында, 1924—1926 елларда Сөгуд Гарәбстанында Совет илчелегендә эшләгән.
Сүзлек: сәфаләт — хурлык, түбәнлек; җәһаләт — наданлык.

Хәмит Гомәрев

# ФАТИХ ӘМИРХАН — ӘСТЕРХАНДА

Мин 1923 елның ахырларында Казанда булдым. Бер-ике атналар чамасы Әмирхановларда тордым.

Аларның гаиләсендә ул вакыт ошбу кешеләр бар иде: Фатих Әмирхан, аның энесе Ибраһим Әмирханов, Ибраһимның хатыны Нәфисә ханым, Нәфисә ханымның энисе, Әмирхановларның туганнан-туган сеңелләре Разия исемле туташ, тагын шул Әмирхановларга туган тиешле яшүсмер егет[1] (монын исеме хәтеремдә калмаган).

Ибраһим Әмирханов Татарстанның Главсуд идарәсендә югары дәрәҗәле вазифада хезмәт итә иде. Аны һәр эш көне өйдән — эшкә, эштән өйгә яхшы ат җигелгән махсус фаэтон йөртә иде.

Нәфисә ханым һәм энисе өй эше белән һәм аш-су хәзерләү белән генә маташалар иде. Нәфисә ханым, теге фаэтон белән файдаланып, кибетләргә барып кайта иде. Разия туташ югары дәрәҗәле уку йортында укый булып исемдә калган. Үсмер егет Фатих Әмирханга киенү-юыну, аны чыгару кебек эшләрдә ярдәм итә иде.

Шул квартирада Фатих Әмирханның шактый гына зур бүлмәсе бар иде. Уку-язуы, ашау-эчүе, кунаклар кабул итүе, төн уздыруы шул үзенең бүлмәсендә генә була иде.

Ара-тирә мин, Фатих аганың бүлмәсенә кереп, уңай булса, анда бераз утырып кала идем. Шул көннәрдән исемдә калганнарның берничәсен язмакчы булам.

Шул көннәрдә беренче татар операсы «Сания»не иҗат һәм тәртип итү буенча беренче тәҗрибәләр ясалган булса кирәк. Исемдә — бер көн Әмирхановларга кичкә таба Солтан Габәши, Газиз Әлмөхәммәтов һәм Мәхмүт Бөдәйлиләр килеп керделәр. Алар Фатих ага бүлмәсендә булдылар. Бервакыт Нәфисә ханым белән мин дә алар янына кердек (чакырылган булсак кирәк). Шунда Газиз Әлмөхәммәтов булачак операдан аерым арияләрен җырлап күрсәтте. Ул арияләр буенча фикер алышуның мәзмуны хәтеремдә калмаган.

Шул ел Казанда булган көннәремнең берсендә университет залында дини моназарә (диспут) булды. Диспут христиан диненә бәйле маузугда иде. Дингә каршы һәм динне яклап сөйләүчеләр руслар иде. Диспутлар белән гомумән кызыксынганга күрә, мин дә бардым. Югарыдан сәхнәне, сәхнәдәге өстәл артында утырган вәкилләрне һәм сөйләүчеләрне күреп, аларның нотыкларын ишетеп, тыңлап тордым. Шунда фаҗигалы бер вакыйга да булган иде: югары дәрәҗәле бер кәшиш бик югары тавыш белән, бик кычкырып сөйли башлаган иде дә кинәт егылды, кафедра янында хәрәкәтсез калды. Тиз генә аны күтәреп алып чыктылар. Соңыннан халык авызыннан ишеттем: аның йөрәге ярылып, шунда ук үлгән имеш.

Моназарәдән кайткач, Фатих аганың шул турыда сөйләгәннәремне бик кызыксынып, бик дикъкать белән тыңлаганы, ара-тирә сөальләр биреп, бәхәснең кайбер нокталарын ачыклавы хәтеремдә яхшы сакланган. Аның шунда «Рәхәтләнеп шундый сүз-фикер көрәштерүләрне үзем тыңлар идем!»— дигән бер теләк белдергәне дә исемдә тора...

Әмирхановларда торган көннәремдә берәү, кем турындадыр, баласының пионерлыкка кергәнен, атаның бу эшкә бик нык ачуы килеп, «вон!» дип, баланы өйдән куып чыгарганын сөйләгән иде. Шуны ишеткәч, Фатих ага: «Безнең әтиләрнең үземле булганнарына хәйран калмыйча булмый! Без яшьләрнең ул дәвердәге яңалыклары хәзерге пионерлыкка, комсомолга керүдән ким түгел иде бит»,— дигән мәгънәдә әйтеп куйган иде.

Габдерахман Гомәринең[2] көен дәфтәрендә түбәндәге сүзләр язылган: «1925 сәнәдә июнь 9 ында Фатих Әмирхан бездә миһман булды».

Ул вакытларда мин тулар-тулмас 20 яшьлек егет идем. Фатих әфәнде Әмирханның безнең өйгә киләсе көнне мин фаэтон яллап, аны алырга гостиницага бардым. Гостиницасы Братская урамында иде. Фатих Әмирханны мөсафирханәнең икенче катындагы бүлмәсеннән фаэтонга, фаэтоннан Гомәревләрнең хәнәсенә, соңыннан кайтышлый юлда Гомәревләрнең өеннән фаэтонга вә аннан мөсафирханәдәге бүлмәсенә мин ялгызым күтәреп, күчереп йөрдем.

Истәлекне И. Нуруллин тапшырды. Авторның үз кулы белән гарәп шрифтында язылган оригиналы И. Нуруллинда саклана.

Габделхәмит Габдерахман улы Гомәров (1905) — тимер юл инженеры, техник вузда укытучы. Хәзер — пенсионер. Владимир өлкасенең Александровск шәһәрендә яши.

[1] Ф. Әмирханның апасы Сәгадәт улы Зәкәрия Әмирханов.

[2] Габдерахман Исмагыйль улы Гомәри (1867—1933) — Әстерхан мулласы, мөдәррис, «Идел» газетасының нашире һәм редакторы.

Шул көн Фатих ага көнозын диярлек минем әтием белән булды. Алар икәве бик күңелле сөйләшеп утырдылар. Мин Фатих Әмирхан белән әтинең алларына бер кереп, бер чыгып йөрдем. Шуңа күрә миңа аларның күп сүзләрен тоташ, тулысынча тыңларга туры килмәде. Шулай да булса аратирә алар янында утырып та кала идем.

Аларның әңгәмәләреннән хәтеремдә сакланган парчаларны түбәндә язам. Әлбәттә, аларның бу сөйләшүләрен нәкъ үз сүзләре, җөмләләре белән бирә алмыйм. Хәтеремдә калган гомуми мәгънәне генә үземчә язам.

Ф. Әмирханның: «Нугай җырлары» ның[1] дәвамын ни гә дөньяга чыгармадыгыз?»— дип соравына каршы Гомәри: «Ул җырлар буенча миндә байтак материал җыелган иде. Ләкин 1914 елның башыннан ук Әстерханнан мәҗбүри китүем[2] белән аларны тәртипләп бастыру эшен гамәлгә ашыра алмадым» мәзмунендә җавап бирде.

Шул маузугтагы сөйләшүдә Гомәри кыскача гына үзенең шәкерте Габделхәмит Җанбиковның нугай халык әдәбиятын җыю белән мәшгуль икәнен һәм бу Габделхәмитнең атасы Чәһәршәнбә турында, аларның «Карагач» нугайларыннан икәнлеген, Габделхәмит Җанбиковның хәзер гаиләсе белән Дагстанда яшәгәнен сөйләде.

Ф. Әмирханның: «Шулай башланып та ташланып калган эшләрегездән тагы «Мәхтүмколый диваны»н[3] да күрсәтергә була?!»— дигәненә Гомәри «Ул диванны тәртип итүче мин түгел, минем истигъдатлы бер шәкертем, Габдерахман Ниязи. Ул үзе төрекмән таифәсеннән, аның Мәхтүмколый диваныннан башка, тагы бер-ике әсәре басылып чыкты: хотбәләр мәҗмугасы һәм Әстерхан мөгаллимнәре вә имамнарының бер мәҗлесен тасвир кыйлган кечкенә бер рисалә-мөзахат, дигән мәзмумда җавап бирде. Бу соңгы әсәрнең гүя сәхнәдә күрсәтелеш өчен язылган бер пәрдәлек комедия икәнлеген аңлагач, Әмирхан: «Ул әсәрне күргәнем дә, ишеткәнем дә юк»,— диде. Гомәри исә: «Күрмәгән, ишетмәгән булсаң, һичнәрсә югалтмагансың, чөнки әһәмиятсез, ćатхи бер нәрсә»,— диде.

Ф. Әмирхан ничектер сүз уңае белән Нәҗип Гасрыйның[4] хәзергә көндәге эшләре турында сорашты. Аның исемен әйттеме, әллә башкача искә алындымы — Гомәри сүзнең, сөальнең кем турында икәнлеген аңлап, Нәҗип Гасрый хакында белгәнен әйтте. Кыскасы, Нәҗип Гасрый 1918 елдан бирле җәмәгать эшләреннән аерылган, шәһәрдән ерак түгел Казавыл дигән кариядә гаиләсе белән яши һәм бакча эше һәм шуның хасыйлатын сату белән мәшгуль,— диде. Үз бакчасыннан гына түгел, бәлки башкаларның, хәтта башка авыллардан да бакча малын алып, җәй буе Идел белән югарыга (Нижний Новгородка) алып барып, анда күпләп сатып йөри,— диде. Аның шулай мәдәни, мәгариф, яисә матбугат эшләреннән читкә чыгып калуына икесе дә тәәссеф иттеләр.

Сүз уңае белән тагы байтак кешеләрнең исеме ядка алынды. Аларның һәркайсысы турында ниләр сөйләнгәнен мин тулысынча ишетмәдем яисә хәтеремдә калмаган. Тик исемнәре генә хәтеремә килә: Муса Җарулла[5], Ризаэтдин бине Фәхретдин, Зариф Бәшири, Бикбулат Салиев, Гани Ниязи, Габбас Душанов, Газиз Гобәйдуллин вә башкалар... Ялгышмасам, Зариф Бәшири турында Гомәри Ташкентта булган көннәрендә (әллә Сәмаркандтамы?), 1923 елда, аның Гомәригә һәм Риза хәзрәткә килеп күрешкәнен, сөйләшеп утырганын сөйләде кебек. Шул елда Зариф Бәшири ул шәһәрләрдә булганмы, юкмы, ягъни шундый күрешү мөмкинме, юкмы,— моны мин кисеп әйтә алмыйм.

Гомәри белән Әмирханның әңгәмәсендә Төркестан халкы, алардагы гыйлем, мәдәният-мәгърифәт эшләре турында сөйләнелде. Фатих Әмирхан татар интеллигенциясенең, төрле сәбәпләр һәм төрле максатлар белән, Урта Азиягә, кардәш милләтләр арасына барып, анда хезмәт итүләрен ике якка да әһәмиятле һәм файдалы дигән фикер сөйләде.

Ф. Әмирхан белән Гомәри рәхәтләнеп сөйләшеп, ашап-эчеп утырган вакытта, шулар өстенә көтелмәгән бер мөсафир килеп керде. Казан артындагы бер авылдан, пәхтә киенгән, мулла кеше булса кирәк. Исеме хәтеремдә калмаган. Бу кеше Фатих аганың бик күптәнге (мәдрәсәдә укыган дәверләрендәге) яхшы танышы булып чыкты. Аларның көтелмәгән очрашулары бик кызыклы булды.

Ул кеше саубуллашып чыгып киткәннән соң, Фатих ага мәҗлестәге халыкка карап, елмаеп: «Бу кеше минем бер хикәямдә тасвирланган шәхес»,— диде. Безнең әти кайсы хикәя икәнен сорагач, Фатих Әмирхан «Габделбасыйр гыйшкы» дигән хикәясендәге шәкертне һәм аның гыйшкын тасвирлаганда, шушы кешенең сурәте, холкы вә маҗарасыннан файдаланганын сөйләде. Әтинең «Кемгә гашыйк булган иде ул?» диюенә каршы Фатих Әмирхан, бераз тукталып торып, «Кызый мотлакка!»— дип, барчаны көлдергән иде.

Әстерхан татар коммунистларының җитәкче оешмасы 1925 елның июнь урталарына билгеләп, «Дин вә гаилә» маузугында ачык моназара (диспут) үткәрергә теләп Габдерахман Гомәригә шунда оппонент сый-

[1] «Нугай җырлары» (1912) исемле җыентык.
[2] 1914 елда Г. Гомәри дүрт елга сөргенгә җибәрелгән.
[3] Мәхмүтколый (?) — XVII гасыр төрекмән шагыйре.
[4] Нәҗип Гасрый (Аллабирдиев — 1886—1934) — «Мөхәммәдия» шәкерте, соңыннан язучы һәм журналист.
[5] Муса Җарулла... — дин галиме Муса Бигиев (1873—1949).

фатында катнашыр өчен чакыру кәгазе килгән иде. Фатих Әмирхан, безнең өйдә утырган көн бу хәбәр турында сөйләнелгәч: «Гаилә мәсьәләсе ислам динендә иң мөкәммәл тикшерелгән, эшләнелгән мәсьәлә»,— дигән фикер әйтеп, шуның өстенә Гомәринең көчле моназир икәнлеген исәпкә алып: «Мин докладчы иптәш урынында булырга теләмәс идем»,— диде.

Сәбәп нәрсә булгандыр, ул моназара үткәрелмәде һәм бөтенләй үткәрелмәячәк булып төшеп калды.

Фатих Әмирханның Габдерахман Гомәри белән бергә булган көн бу мәҗлескә өй хуҗасы һичкемне чакырмаган булса да, аның өенә гадәттәге кебек, килүче-китүче булып торды. Аларның кайберсе, Фатих Әмирхан алдына да үтеп, күрешеп, гомуми мәҗлестә утырып та калгалады. Ләкин баштан ахырга кадәр һичкем озак утырмады. Кемнәрнең килгәне-киткәне минем хәтеремдә начар сакланган. Тик Габдерахман Ниязи, Габделвәһап Гомәрев һәм Бәдретдин Килачи әфәнделәрнең мәҗлестә аз-маз катышканнары исемә төшә. Аларның кайсысы кайсы маузугтагы сүзгә катышканы хәтеремдә юк.



Ф. Әмирхан. 1904 ел. (Матбугатта беренче тапкыр басыла).

Гомәри өендә булып киткәннән соң, Ф. Әмирханның Әстерханда тагы ничә көн торганы хәтеремдә сакланмаган. Тик шуны беләм: Габдерахман Гомәри шул көннәрнең берсендә Фатих Әмирханны ул торган гостиницага барып күргән, аның белән саубуллашып кайткан. Аларның шул саубуллашуларында тагы берәр кеше булганмы-юкмы, саубуллашу мәҗлесендә бу икәве нәрсә сөйләшкәннәр,— бу турыда һичбер мәгълүматым юк.

Ф. Әмирхан Әстерханнан Идел буйлап йөрүче зур пассажир теплоходына утырып, махсус бүлмәдә (каютада) китте. Каютасы беренче класстанмы, икенче класстанмы,— исемдә юк, ләкин, әлбәттә, шул ике класс-ның берсендә. Аның белән пароходның алгы салонында һәм шул тирәдәге палубада булдык кебек исемә төшә.

Мин аны озатырга дип пристаньга бардым, пароходына мендем. Озатучы кешеләр белән Фатих ага Әмирхан янында булдым. Мин барганда озатучылардан Борһан Бадамшин гына бар иде. Бераз вакыт без өчәү генә булдык. Шул вакытта Ф. Әмирханның Әстерханда татар яшьләре оешырга тиеш, үзләренең музыкалары, әдәбиятлары, тарихлары белән кызыксынырга тиешләр, дигән сүзләре һәм (Бадамшинга карап) аларга бу эштә ярдәм итәргә кирәк, дигәне хәтеремдә калган.

Фатих Әмирхан Әстерханнан киткәч, миңа кемдер аның Гали абзый Шакировларда булганында, аларның балалары белән таныштырылган арада, Фатыйманың бер сеңелесенең исемен төзәткәнен әйткән иде. Кызның исеме Мәрваридә дип йөртелә. Шуны Фатих Әмирхан җиңелчә генә «Мәрварид» дип куйган икән.

[1] Сүзлек: мәзмун — мәгънә; маузуг — тема; кәшиш — христиан рухание; сатхи — сай; мозахат — мәзәкләр;
диван — шигырьләр җыентыгы; хасыйлат — керем, табыш, файда; монда — уңыш мәгънәсендә; тәэссеф — уке-
неч; яга — яр; кызый мотлак — билгесез, абстракт кыз; мөкаммәл — тулы; моназир — бәхәсләшүче.

# Ф. ӘМИРХАН АРХИВЫННАН

*Татар әдәбияты классигы, күренекле прозаик һәм публицист Фатих Зариф улы Әмирханның тууына йөз ел тулу юбилеена хәзерлек йөзеннән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты хезмәткәрләре көче белән әдипнең, беренче тапкыр буларак, дүрт томлык әсәрләр җыелмасы хәзерләнде. Томнарга кертелгән материаллар Фатих Әмирханның көндәлек матбугатта һәм аерым китаплар рәвешендә чыккан басмаларыннан алынды. Шулай ук бу басмага әдип архивыннан исән калган өлешеннән күп кенә материаллар кертелде.*

*Ф. Әмирхан фондындагы материалларның күбесе әле матбугатка чыкмаган. Аларның басылып, укучыларыбыз кулына җиткерелүе Фатих Әмирхан иҗатының һәм тормышының яңа сәхифәләрен ачуга ярдәм итәчәк. Укучылар игътибарына түбәндә тәкъдим ителгән, Институт архивыннан алынган көндәлек битләре һәм бер хат әнә шундый игелекле эшкә хезмәт итәрләр.*

**Марсель ӘХМӘТҖАНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты.*

*19.X. 1921. Чәршәмбе.*

Бүген миңа Бишбалта имамы Габдулла бине Насретдин Әмирханов[1] килгән иде. Аның моннан унбиш көннәр әүвәлге бер килүендә без миңа кыш көне өчен чана-креслоның (атсыз, кеше этеп кенә йөртә торган кресло) бик кирәклегеннән бәхәс иткән идек тә, ул миңа шундый креслоны үзе ясап бирә алачагын, моның өчен бары берәр җирдән венский кресло табып, шуны кулга төшерергә кирәклеген сөйләгән иде. Бу килүендә ул үз мәхәлләсендәге берәүдән кресло-качалка табып алганлыгын һәм шушы көннәрдә аңар карда йөрерлек табаннар хәзерләп, тәмам бер кресло-чана ясап чыгарачаклыгын сөйләде. Мин бу вәгъдәгә гаять шатландым, аның мин мондый эшләрне булдыра ала икәнен дә беләм, безнең гаиләгә биргән вәгъдәсен артыгы белән үтәргә тырыша икәнлеген дә беләм. Бу елга кадәр мин кыш көннәрендә шундый бер креслоның булмавыннан күп мәхрүмлекләр чигә килә идем. Ямщикның бик кыйммәтлеге, аның өстенә төннәрдә табылмавы да мине кышларда үзем теләгән бик күп җирләргә барудан тотып кала иде. Мин былтыр ук инде шундый бер кресло ясату фикеренә килгән идем. Ләкин үткән кыш шуны ясатырга һичбер җай туры китерә алмаган, кыш буе шул креслоның булмавыннан әллә никадәр мәхрүмлекләр күреп чыккан идем.

Хәзер көннәр былчырак булганлыктан миңа креслом белән чыгып йөрү бик уңайсыз, шунлыктан мин тизрәк кар явып, минем креслоҗаным да өлгереп, шуның белән чыгып йөри алу имкянен көтеп, шуны теләп ятам. Менә бу да аяксызлык хәлләремнән бер хәл.

* * *

*2.XI. 1921.*

Бүген миңа Таһир Ильяси[2] килеп утырды. Ул үзенең гарәп лөгатенә тыга торган хезмәтен дәвам иттерә бирә икән. Үзенең сөйләвенчә, ул хәзер инде «Татарча-гарәпчә лөгать китабы» өчен кирәкле материалны тәмам хәзерләп куйган, бары бер тәртипкә китереп, кыяфәткә кертәсе генә калган. Киң гарәп теленең сүзләренә каршы татар сүзләрен табып, аларны тәфтиш итеп тә ул күп шөгыльләнгән. Шуңар күрә мин аңар татарчага бер лөгать китабы эшли башларга инде беренче мәртәбә генә түгел тәүсыя итәм. Ул үзе бу гарәп лөгате китабының хәзергә кадәр нинди генә бер телдә чыкканнарының һәммәсенә караганда күбрәк лөгатьне хави һәм күбрәк тәфтиш белән җыелган икәнен сөйли: кирәк Мисырда, кирәк Гарәбстанда торганда, ул лөгатьне гарәпнең

[1] Габдулла Насретдин улы Әмирханов (1871—1933). Казанның Бишбалта бистәсенең имамы. Ф. Әмирханның Сәгадәт апасының (1883—1911) ире. Алар Казанның хәзерге Киров районындагы Большая урамы, 66 йортта яшәгәннәр. Ф. Әмирхан алар йортында апасы исән вакытта да һәм ул үлгәч тә еш булган.
[2] Таһир Ильяс — Таһир Әхмәтҗан улы Ильяси (1881—1933), күренекле телче, гарәп теле белгече.

нәкъ үз авызыннан җыю белән шөгыльләнгән һәм шуңар бик күп әһәмият биргән икән. Һәм мин аның бу сүзенә ышанам да: ул сүзне үлчәп сөйли торган, дөрес сөйләргә ярата торган кеше. Бичара төрек кабиләләренең бер кызыклы бәхетсезлекләре бар. Иске гасырлардан бирле аларның тел фәненә әһәмият биреп килгән әһле гыйлем үз теленә бер җитди, фәнни хезмәт итү урынына, гарәп телен эшләү, аңар хезмәт итү белән мәшгуль булып килгәннәр. гарәп теленең инде бәйнәлмиләл сәхнәдән җуялу гарәфәсендә бер төрек баласы аның лөгатен җыеп шөгыльләнә һәм шуңар никадәр хезмәт һәм гайрәт сарыф итә, ә үз теле, үз теле шул хезмәтнең яртысын гына да күрә алмый.

Ул үзенең бу әсәрен гарәпчә өйрәнә торган татар шәкертләрен күз алдында тотып тәэлиф итә икәнлеген сөйли. Ләкин хәзер бастырырга имкян юклыктан зарлана: миңа шуны бастырту турысында Татгосиздат белән сөйләшеп карау турында мөрәҗәгать итә. Мин аңар сөйләшеп карауны вәгъдә итәм. Ләкин алдан ук күреп торырга мөмкин ки, бу сөйләшеп караудан бер нәтиҗә барып чыкмас.

* * *

*4.XI. 1921*

Үткән төннән әүвәлге төндә өйдә, үткән төндә Казанның иске буржуаларының берсенең углы өендә преферанс уйнап чыгып йокысыз уздырдым. Төне буе утырасың да көндез берничә сәгать йоклап алган шикелле итәсең, тагы төне буе утырып чыгасың. Бүген сәгать унбердә генә өйгә кайтып, сәгать дүртләргә кадәр йоклап алдым. Ә үзем әле яңа авырудан терелеп киләм... Мондый гайре табигый тормышның гаять ахмаклык, үземнең исәнлегемә каршы, эшли алуыма каршы җинаять икәнен дә беләм, ә шул рәвешчә тереклек итүне дәвам иттерүне дәвам иттерәм. Ник? Ахмакны чәчеп үстермиләр,— ди татар мәкале. Моның дөрес җавабы шул булыр иде. Ләкин мин үз-үзем алдында акланырга юл табам: көннәр буе өеңдә, караватың өстендә ауныйсың, театрга, музыка кичләренә барыр идең, атың юк, кешең юк, ямщиклар яллап, кешеләр яллап теләгәнең вакытта йөрерлек матди байлыгың юк, гаиләң юк, шул бертөрлелекнең соң дәрәҗәсендәге тормышыңны төрләндерерлек шараитының меңнән берсе юк. Торасың, торасың, укыйсың, язгалыйсың, укыйсың, язгалыйсың, ләкин ялыктыра. Кайвакытларда бик тә ялыктыра: язылмый башлый, укыйсың килми башлый... Нишлисең? Шул преферанс өстәле тирәсенә барып утырасың да, шуның белән нервларыңны кытыклаңдырырга тотынасың. Бу — шул ахмак карта уенының иң акыллы, иң мантыйклысы. Оста һәм тыныч гасабилар белән уйланучы кешеләр белән уйнаганда, белеп уйнаганда — иң кызыклысы дадыр дип уйларга кирәк.

Кичә мин барган җирдәге уенчылар икесе, моннан әүвәлге елларда, гражданнар сугышының иң кызу көннәрендә Себердә, аклар ягында йөреп кайткан егетләр иде. Алар үзләренең һәм гомумән андагы буржуазиянең шул вакыттагы тормышына даир күп вакыйгалар сөйләделәр. Миңа андагы, ул вакытлардагы тормышка даир хикәяләрне моннан алда да шунда үзләре булган, шул тормышка үзләре мөшарәкәт иткән кешеләр авызыннан күп мәртәбәләр ишетергә туры килгән иде. Шул хикәяләрнең барысыннан миндә менә мондый тәэсират хасил була. Контрреволюция гаскәре артына качкан буржуазия ул көннәрдә шундый бер типтерүгә, бер сафахәт, исереклек һәм спекуляциягә бирешкән булганнар ки, бу тәмам бер фәхеш, эшсезлек, идеалсызлык, оятсызлык мәйданына әйләнгән. Контрреволюциянең болай җиңеллек белән черүендә, җиңелүендә, мин хасил иткән фикерчә, буржуазияне каплап алган шушы хәл зур роль уйнаган булырга кирәк.

---

Сүзлек: тәгъбир иттем — аңлаттым; лөгать — сүзлек; тәфтиш итеп — тикшереп; тәүсыя итәм — киңәш итәм; хави — эченә алган; әһле гыйлем — гыйльме ияләре; бәйнәлмиләл — интернационал; гарәфә — алда торган көн; тәэлиф — җыйнау, төзү; имкян — мөмкинлек; мөшарәкәт иткән — катнашкан; тәэсират — кичерешләр; шараит — шарт; мантыйк — логика; гасаб — нерв; даир — бәйләнешле.

# Хат

Ризван Алушига [1]

*1907 ел, 25 ноябрь, Казан*

«Әльислах» газетасының идарәсе — Казан, клиника нервных болезней

Казан

Болгар номерында

1907 сәнә, 25 нче ноябрь

Газизем Ризван! [2]

Сиңа вә мөхтәрәмә Фәрханә ханыма [3] сәламнәрем!

Күптән, хәтта бик күптән бирле сиңа хат язарга лязем икәнен хәтеремдә тотсам да, бу көнгә кадәр фәкать тәкъдирнең каршы торуыннан наши яза алмадым, гафу итүеңә ышанам.

Москвадан Казанга кайтып бөтен җәй буенда фәкать истирахәт кылып җәйне уздырсам да, билахир һәр кәлләнең бер зәвале дигән кабилдән 15 нче августта паралич сугып, аякларымнан мәхрүм калдым.

Авыруымның башында күрсәң, бәлки танымаган да булыр идең: куллар вә аякларны кыймылдатырлык булсын куәткә дә малик булмаганым өстенә, бер күзем дә паралич тәэсиренә бирелгән иде. Авыруыма өч-дүрт көн үтәр-үтмәс хәбәре бөтен Казанга җәелеп, хәтта хәзрәтләр мәҗлесе вә абыстайлар ашларында да төрле-төрле шәрехләр белән сөйләнергә өлгереп, Казан татарларына минем авыруым мәсьәләсе бик күп вакытларга кадәр сөйләргә бер сүз булды: печән базарчылар «каһәр сукты» дип, тәҗвидчеләр [4] «остаз бәддогасы» дип һәр төрле тәфсыйлләт бирделәр. Әүвәл мәртәбә хәлемне белергә килгән иптәшләремнең бәгъзесе обморокка егылды, вә бәгъзеләре дә минем алда яшергән яшьләрен урамга чыккач түккәннәр.

Хәзер инде хәлем бер дәрәҗәдә яхшыланып терелү тарафына китте: кулларымнан вә күземнән паралич китеп, аякларымда да аз-маз хәрәкәт күренә башлады. Алай да бөтенләй сәламәтләнүне тиз көтмим!

Хәзер 5 нче ноябрьдән бирле клиникада ятам. Авыруның берникадәр файдасы да булды: өч ай эчендә күп нәрсә укып чыктым, вә «Әльислах» газетасында сәркәтиплек хезмәте иттем һәм хәзер дә итәм. «Әльислах»сезгә барып ирешкән булса: баш мәкаләләр вә «Дамелла» имзалы мәкаләләрне аяксыз дустым Фатих кулы белән язылган дип укырсың! Вә шуларга карап авыруның миңа рухани тәэсире булганмы-юкмы икәнене белерсең. Әүвәлге номерда Казан шәкертләре имзасы белән язылган «Печән базары татарларына ачык хат»та авыруымның куәтле вә көчкә-көчкә генә утырып тора ала торган вакытымда минем кулым белән тәртип ителмештер.

Ризван! Син Исмәгыйльгә [5] язган хатыңда «миңа галәкә тотмый» әйтте дип үпкәлисең? Шулай түгелме? Андый нәрсә хәтереңә китерүдән ходайдан курыкмасаң, миннән оялырга тиеш! Ишетәмсең!

Синең белән уздырган көннәрем һәрвакыт минем гомерем сәхифәсендә матур көннәрдән хисапланып язылып калачактыр. Минем авырганны гына көтеп торганнар икән, хәзер төрле яктан үземне чакыра башладылар: Казанда чыгачак «Әхбар» газетасында иштиракка, Петербургка [6] тагы берәр җиргә чакырган хатлар алдым.

Клиникада яту [7] бик күңелсез булырмы дип уйлаган идем, лакин алай ук түгел икән: көндезләрне — эш-уку вә язу белән уздырам, кичләрдә иптәшләр вә хосусән татарка вә марҗа белешләрем һәр көнне тулып яталар, конфет белән бик сыйлыйлар. Бу хатны алган көнне үк бик озын, бөтен Ачинскидан күчү [8] тарихыңны һәм Читадагы мәгыйшәтеңне бик мөфассал сурәттә язарсың дип ышанам.

Дикъкать ит, әгәр ике табактан ким булса, хатыңны китергән почтальонның башына кыяматләр кубарачакмын!

Фәрханә ханымга әйт: әгәр син үзеңне бик зур тотып, ир булып кылана башласаң, ул миңа гына бер шикаятьнамә язсын, сине ничек тәэдиб итәргә үзем белермен!

Валлаһи, язып арыдым!

---

[1] Хат беренче мәртәбә басыла. Төп нәсхәсе Г. Ибраһимов исемендәге институтның фәнни архивында саклана (16 ф., 3 тасв., 1 эш, 23—24 б.).

[2] Ризван Ибраһимов (Алуши) (1883—1938) — Ф. Әмирханның якын дусты, журналист, педагог.

[3] Ризван Алушиның хатыны. Фәрханә Рәхимгәрәй кызы Бәхетгузина. Ул үзенең мәкалә һәм нәсерләре белән көндәлек татар матбугатында катнаша, күп еллар гомерен укыту-тәрбия эшенә багышлаган.

[4] Мәктәп реформасын Коръән укуны тагын да яхшырту юлына юнәлтүчеләр.

[5] Исмәгыйль Сөләйман улы Аитов (1888—1938) — Ф. Әмирханның яшьлек дусты.

[6] Ф. Әмирханны Петербургка Мәскәүдәге дусты Заһид Шамиль чакырган булса кирәк.

[7] Ф. Әмирхан дәваланган клиника адресы ачыкланмаган.

[8] Ризван Алуши хатыны Фәрханә белән 1907 елның җәендә Ачинскидан Читага укытырга күчеп китәләр.

Бакый кардәшем, сау бул!
Һәр, икеңезгә гарыз мөддәтем!

Фатих Әмирхан.

Адрес — өйгә яз!

P. S. Если имеешь возможность, то старайся привлечь подписчиков «Эль-Ислаха».

---

Сүзлек: лязем — тиеш; наши — ... дән барлыкка килгән; истирахәт — ял итү, рәхәтләнү; билахир — ахырында; калла — баш; завал — югалу; кабилдән — киләчәктән; малик — ия, хуҗа; шәрех — аңлатма; остаз баддогасы остаз каргышы; тәфсыйләт — тәфсилле; сәркатип — секретарь; галәка — бәйләнеш, элемтә; иштирак — катнашу; мөфассал — тулы; мәгыйшәт — тормыш; шикаятьнамә — зарлану хаты; тәэдиб — җәза бирү, тәрбияләү; гарыз мөддәтем — үтенгән вакытым.



*Уңнан сулга: Ф. Әмирхан, Р. Ибраһимов (Алуши), И. Аитов. 1906 ел, 28 май (Матбугатта беренче тапкыр басыла).*

**Гамир Дәүләтшин,**
тарих фәннәре кандидаты

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ КУЛЪЯЗМА МИРАСЫ

Бүгенге көндә СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивында 20 меңгә якын эшне берләштергән 95 шәхси фонд һәм иҗтимагый, гуманитар фәннәрнең төрле тармакларына караган коллекцияләр саклана. Шул ук вакытта институт архивы республикада татар язучылары кулъязмаларын туплаган иң эре үзәкләрнең берсе булып тора. Анда утызга якын татар әдибенең шәхси фонды саклана.

Ф. Әмирхан мирасы әдип вафат булган елны ук июль аенда Галимҗан Шәрәф һәм Ибраһим Бикколов тарафыннан барлана. Архивта сакланган, алар имзасы куелган бу исемлектә язучының 48 кулъязма әсәре һәм биографиясенә караган 17 документ теркәлгән.

1940 елның 29 гыйнварында атаклы татар артисты Касыйм Шамил әдипнең «Фәтхулла хәзрәт» повесте буенча эшләнгән сәхнә әсәренең төп нөсхәсен институтка тапшыра. Шулай итеп Ф. Әмирхан фондына мая салына. Касыйм Шамил үзенең истәлегендә 1922 елда Казанда сәхнә әсәрләренә һәм аеруча комедияләргә кытлык булу турында яза. Ул иптәшләре киңәше белән тиз арада «Фәтхулла хәзрәт» повестен сәхнәләштерүен үтенеп Ф. Әмирханга мөраҗәгать итә. «Ул бер кычкырып көлде,— дип дәвам итә К. Шамил.— Чыннан да, мелла Шамил, син хәзрәтләрне яхшы башкарасың, ләкин «Фәтхулла хәзрәт» романыннан, белмим, нинди генә сәхнә әсәре чыгар икән, ә шулай да мин уйлап карыйм әле, бер-ике көннән керерсең»,— диде. Ике көннән соң, Фатих Әмирханга баргач, ул миңа «Фәтхулла хәзрәт» комедиясенең планын сөйләде һәм шул план буенча бер 10 көндә язып өлгертәчәген белдерде. Шулай итеп Ф. Әмирхан минем сәхнә бәйрәмем өчен «Фәтхулла хәзрәт» комедиясен 12 көннәрдә тәмамлап, шул елның җәендә... Большой театр бинасында уйналды. Спектакльдә Фатих Әмирхан үзе бар иде. Спектакльдән булган тәэсире хакында сөйләгәндә ул: «Ничек тә бик ашыгыч бүлды. Башта мин комедия әсәре чыгар дип уйламаган идем, ләкин өстендә ныклабрак утыргач, әйбәт кенә сәхнә әсәре чыгуына ышандым инде»,— диде.

61 биттән торган күн тышлы гомуми дәфтәргә язылган кулъязманың беренче битендә әдипнең «Халыкның атаклы артисты Касыйм Шамилгә багышлыйм. 21 август 1922 ел» дигән искәрмәсе дә бар.

Ф. Әмирхан кулъязмалары һәм аңа кагылышлы материаллар сугыш һәм сугыштан соңгы елларда да керүен дәвам итә. 1953 елда Х. Хисмәтуллин тарафыннан Уфага булган экспедиция вакытында шактый материал алып кайтып тапшырыла. 1958 елда филология фәннәре кандидаты Авзал Кудашевтан әдипнең өч кулъязмасы һәм Ф. Әмирханның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә бергә укыган якын дусты Ибраһимов (Алушев) Ризван һәм аның хатыны Фәрханәгә язган 30 дан артык хат алына. А. Кудашев бу материалларның үз кулына керү тарихын аңлаткан язмасында Р. Ибраһимовның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлагач, революциягә кадәр Себердә мөселман мәдрәсәләрендә укытучы, татар газеталарының корреспонденты булуы турында яза. Р. Ибраһимов революциядән соң БАССРда төрле журналларда әдәби сотрудник булып эшли, гомеренең соңгы елларында театр техникумында ана теле һәм әдәбиятын укыта. Аның хатыны Фәрханә дә заманының мәгърифәтле хатын-кызларыннан була. Революциягә кадәр татар хатын-кызларын укыту һәм аларның азатлыгы темасына мәкаләләр язышa. А. Кудашев эшләгән институт белән Р. Ибраһимов укыткан техникум бер бинада урнашкан була. Ризван ага институттагы җыелышларга еш йөри. А. Кудашев аның белән шул җыелышларның берсендә очраша. «Сөйләшүләрнең берсендә,— дип яза А. Кудашев,— Ризван абзый, мин... татар, башкорт әдәбиятлары өлкәсендә эшләгән кеше булганлыктандыр, ахыры, миңа үзенең Ф. Әмирхан белән «Мөхәммәдия»дә бергә укуы, дус булуы, революциягә кадәр аның белән хатлар алышуы, 1926 елның кышында Ф. Әмирхан үлгәч, аның турында доклад ясавы, тыңлаучыларның аңа Ф. Әмирханның иҗаты, политик йөзе турында язма һәм телдән күп сораулар бирүләре турында сөйләгән иде.

1938 елның азагында Ризван абзый үпкә шешүеннән тиз генә үлеп китте. Мин аның тормыш иптәше Фәрханә апага бардым һәм ул миңа Ризван абзыйның татар газета-

ларында басылган кайбер мәкаләләрен, Ф. Әмирханның хатларын бирде. Ризван Алушевка бүләк иткән автографлы экземплярларын да күрсәтте, ләкин аларны бирмәде. «Болары кадерле дустым, гомерлек тормыш иптәшем Ризванның онытылмаслык истәлеге булып үземдә саклансын инде»,— диде.

Ф. Әмирхан фондының тулылануы соңгы елларда да дәвам итә. 1965 елда өлкән язучы А. Шамов институт архивына әдипнең «Татар кызы» хикәясенең кульъязмасын бүләк итә. Ул аны Татарстан мәгариф министрлыгының өлкән инспекторы Хәким Шамкиннан ала. «Х. Шамкинның әйтүенә караганда,— дип дәвам итә А. Шамов үзенең аңлатма язуында,— Ф. Әмирхан үлгәннән соң аның барлык әдәби архивы, китапханәсе, киемсалымнары, өй җиһазлары күмү комиссиясе тарафыннан исәпкә алынган һәм шул турыда акт төзелгән. Бу кульъязма шул актка 8 нче номер белән теркәлгән икән. Беренче дәфтәрнең тышына кем кулы беләндер, «актта № 8» дип, бүгенге әлифба белән язылган. Актның хәзер кайда һәм кем кулында икәнен белмим. Хәтерем ялгышмаса, аның кайда саклана икәнен Х. Шамкин да белми шикелле».

Ф. Әмирхан 1924—1926 елларда «Татар кызы»ның яңа басмасын чыгарырга әзерләнгән булса кирәк. Ул аны яңабаштан карап чыккан, үз сүзләре белән әйткәндә, «ыйбарә ягыннан төзәткән һәм акка күчерткән». «Татар кызы»ның 1909 һәм 1925 еллардагы басмалары белән чагыштырып караганнан соң, әдипнең үзе исән чакта бу варианты матбугатка чыгармаганлыгы билгеле булды».

1974 елны Хәким Шамкиннан Ф. Әмирханга язылган 10 данә ачык хат һәм «Хәят» повестенең бер бит кульъязмасы алынды.

Хәзерге көндә 16 номерлы Ф. Әмирхан фонды 4 тасвирламадан торып, үзенә 150 гә якын эшне берләштерә. Беренче тасвирламада әдипнең 30 дан артык кульъязмасы тупланган. Югарыда телгә алынган кульъязмалардан тыш анда 1905 елның 19 маенда чыгарылган кульъязма «Бәнд» (Союз) газетасы, «Яшьләр», «Тигезсезләр», исемсез «башлангыч балалар өчен» һәм тәмамланмаган бер пьесаның, «Кадерле минутлар», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Татар кызы», «Танс кичәсе», «Сәмигулла абзый», «Сәлихҗан кари», «Корбан» (балалар өчен) һәм 8 исемсез хикәянең, «Чәчәкләр китерегез миңа» дигән шигъри прозаның («мәнсүр шигырь») вариантлары, «Шәфигулла агай» исемле «дустанә шаржның» кульъязмалары саклана. 1908 елның 28 сентябрендә язылган «Хан мәчете» (Сөембикә манарасы турында) кульъязмасының ахырында әдипнең «Печән чабучы» шигыре урнаштырылган. Моннан тыш бу тасвирламада Ф. Әмирханның үз әсәрләреннән булган өземтәләр җыелган кульъязма дәфтәр саклана. Шулардан «Татар кызы» хикәясенең бер варианты булган биш битлек кульъязма фондка куптән түгел генә кертелде.

«Икенче интернационал тормышында ике дәвер» исемле сәяси-публицистик әсәрендә Ф. Әмирхан күренекле әдип булып кына түгел, ә бәлки политик яктан шактый өлгергән, бу дәвер тарихын яхшы белгән шәхес буларак та күз алдына килеп баса. Тасвирламадагы ике эштә әдип тарафыннан төзелгән «Ихтисаб» җәмгыятенә һәм «Шәрыкъ» китапханәсенә бирелергә әзерләнгән китаплар исемлеге урын алган. Бу исемлекләр аша язучының нинди китаплар белән таныш булуын күрә алабыз.

Русчадан татарча тәрҗемә ителгән юридик терминнар сүзлеге һәм «Җинаять — эш йөртү кодексы» кульъязмалары терминнар сүзлеге төзегәндә игътибарга алынырлык.

Ф. Әмирхан фондында 150 гә якын хат саклана. Аларның 50 гә якыны Ф. Әмирханныкы, ә 100 гә якыны әдипнең үзенә килгән хатлар. Алар 1902—1926 елларга карыйлар. Бу хатлар Ф. Әмирханның тормыш һәм иҗат юлын өйрәнү өчен генә түгел, ә бәлки шул чорларның күп якларын ачыклау өчен дә кыйммәтле документлар булып торалар. Чыннан да, алардан шул чорлар рухы бөркелеп тора. Бу хатларның һәрберсе турында да бәйнә-бәйнә сөйләргә мөмкин булыр иде. Әмма аларның иң зур күпчелегенең матбугатта чыкканлыгын һәм әдип әсәрләренең томнарында урын алганлыкларын исәпкә алып без кайбер моментларга гына тукталып үтәбез.

Ф. Әмирханга килгән хатлар гына түгел, әдипнең корреспондентлары да күп. Алар арасында Ризван Ибраһимов, Исмәгыйль, Сөләйман һәм Рауза Аитовлар, Вафа Бәхтияров, Зариф Бәшири, Кәбир Бәкер, Муса Бигиев, Камил Мотыгый һ. б. бик күп шәхесләрнең хатларын күрсәтеп булыр иде. Ф. Әмирханның Мәҗит Гафури һәм Мөхетдин Корбангалиевкә иҗат юбилейлары уңае белән язылган хатларда әдипнең бу шәхесләргә карата тирән хөрмәте чагыла. Бүгенге көнгә кадәр фондта булган 20 дән артык хатның авторлары ачыкланып бетмәгән әле. Моннан тыш күптән түгел әдипкә килгән 48 хатның конверты фондка кертелде. Хатлары булуга карамастан конвертлардагы адреслар һәм почта штемпельләре язучының кайчан, кайда яшәгән һәм эшләгән булуы турында; кайчан, кайдан хат алуы хакында мәгълүматлар бирә алалар.

1908—1926 елларга караган һәм төрле шәһәрләрнең шул чордагы күренешләре төшерелгән 10 ачык хат әдипкә Томск, Уфа, Сембер, Чистай, Хвалынск, Әндиҗан шәһәрләреннән килгән. Шундый ачык хатларның берсендә мәшһүр немец шагыйре Гете портреты. Мөгаллим Мозаффар Мөштәринең (профессор Хәмит Мөштәринең атасы)

кызларына язылган бу хатта әдипнең җылы юморга бай кеше булганлыгы күренә:

«Мәрьямбану, Бибимаһирә туташлар!

Мәнә бу матур күзле шагыйрьне мин сезгә җибәрәм. «Бәйрәм котлы булсын» дияргә җибәрәм. Әгәр шул сүзне яхшылап әйтә белмәсә, колагын борыгыз. Фатих».

Шәхси архивларда еш кына башка кешеләргә караган материаллар да очрый. Алар гадәттә шәхси архив иясенә теге яки бу әсәр белән танышу, рецензияләү өчен бирелгәннәр. Шундый әсәрләр Ф. Әмирхан фондында да урын алганнар. Болар Надим Габдулланың «Чын вә тугрылык», Т. Ченәкәйнең (Симавиның) «Мәхәббәт чәчкәләре», «Әлфирак» исемендәге шигырь җыентыклары, Авзал Таһировның «Яңгура» пьесасының кульязмалары һәм Ибраһим Аитовның куен дәфтәре.

Фондның икенче тасвирламасында Ф. Әмирханның биографиясенә, эшчәнлегенә караган материаллар тупланган. Монда әдипнең туу һәм үлү турындагы таныклыкларының рәсмиләштерелгән күчермәләре, Яңа татар бистәсе каршындагы рус классларын уңышлы тәмамлау турындагы таныклык (30 июль 1901 ел), Әмирхановлар шәҗәрәсе (1902 елның 8 мае), 1925 елның 15 маеннан 1926 елның 16 маена кадәр чорга бирелгән еллык паспорт, әдипнең Татар театр техникумында татар әдәбияты укытучысы булуы турындагы таныклык (1923 елның 12 июле), 1925 елның 1 июлендә бирелгән шәхси һәм «Татарстан» газетасы корреспонденты булуы турындагы таныкламаларның төп нөсхәләре саклана. Документлар арасында 1923 елның 19 мартында бирелгән һәм Ф. Әмирханның Милләтләр эшләре Халык Комиссариаты каршындагы Бөтенроссия фәнни ассоциациясе тарихэтнография бүлегенең татар культурасын өйрәнү үзәк комиссиясенең әгъзасы булуы турындагы белешмә бар. Әдипнең авыруы турындагы материаллар арасында Башкортстан Үзәк Башкарма Комитетының Уфа станциясе начальнигына бирелгән күрсәтмәсе игътибарга лаек (2 июль 1923 ел). Анда кымыз белән дәвалануга бару юлында әдипкә төрлечә ярдәм итәргә кирәклеге җиткерелә.

Ф. Әмирханның иҗатын, тормыш юлын өйрәнүче галимнәр аның фондта сакланган 170 биттән артык булган көндәлегендә (1901—1902 еллар) һәм мемуарларында бик кызыклы мәгълүматлар табалар.

Архивта шулай ук язучының әсәрләре басылу мәсьәләләренә кагылышлы Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты Академик үзәге коллегиясе утырышы беркетмәсеннән өземтә һәм нәшрият белән килешүләр саклана.

Фондта Ф. Әмирхан аерым һәм замандашлары белән төшкән 13 фотоның төп нөсхәсе саклана. Аларның шактыенда Ф. Әмирханның автографы бар.

Фондта әдип турында истәлекләр күп түгел. Алар 5 кешенеке генә. Шулар арасында Ф. Әмирханның идея-политик карашларын, аның революциягә, совет властена, В. И. Ленинга мөнәсәбәтен чагылдыру ягыннан 1957 елда Ленин орденлы өлкән педагог-коммунист Гаяз Байкиев истәлеге кызыклы. Институт архивындагы Ф. Әмирхан фонды турындагы сүзебезне шушы истәлек белән тәмамлыйбыз:

«Мин Фатих ага Әмирхан белән берничә ел бер йортта күрше булып яшәгәнлектән, аның турында кайбер истәлекләр белән уртаклашасым килә. Без аның белән 1924—1926 елларда бергә яшәдек. Ул энесе Ибраһим, аның хатыны Нәфисә, сеңлесе Разия һәм Газизә апа белән тора иде. Газизә апа Фатих аганы үз улы шикелле кайгыртучанлык күрсәтеп ихтирам белән тәрбияләде. Сеңлесе Разия педагогия институтында укый иде. Ул институтның тарих факультетына Фатих аганың киңәшен тотып керде.

Ул елларны инде Фатих ага фәкать коляска белән генә йөри һәм һәр көн көндезен саф һавага чыгып утыруны үзенә гадәт итеп алган иде. Мин эштән кайтканда аның янында бераз тукталмыйча кереп китә алмый идем. Фатих ага безнең (укытучыларның) эше белән аерата кызыксына иде. Ул балаларның сәламәтләре турында сораша, мәктәп тормышы белән кызыксына иде. Мин аның татар яшьләренең рус яшьләре белән берләттән белем алырга Совет власте мөмкинлек биргәненә шатланып сөйләгәнен хәтерлим. «Татарларның да хәзер гимназияләре бар бит»,— дип кабатларга ярата иде ул.

Фатих ага бик аралашучан кеше иде. Аның янында һәрвакыт кешеләр, бигрәк тә яшьләр була иде. Бу хәл аерата театрда ачык күренә иде. Антрактта Фатих аганың яшьләр белән фикер уртаклашуын, көлдереп сөйләшүен хәтерлим.

Миңа Фатих ага белән еш кына сөйләшергә туры килә иде. Бик күбесе хәтеремдә калмаса да, аның шат рухлы булуы минем хәтеремдә бик ачык. Үзенең сәламәтлеге начар булуга, физик кимчелегенә (йөри алмау) карамастан, ул бер вакытта да зарланмый иде. Гомумән, Фатих аганың тормышка оптимистик карашы көчле иде. Мәсәлән, ул шул вакыттагы политик хәлләргә карата: «Мин большевикларга зур өмет белән карыйм, алар рус монархиясе хәл итмәгән күп мәсьәләләрне хәл иттеләр. Аерата милли мәсьәләләрне тиз чиштеләр. Хәзер инде татарлар арасыннан инженерлар, врачлар, техниклар, юристлар үсеп чыгар. Университетта татарлар бик күп укый»,— дип шатланып сөйләде.

Ленин турында Фатих аганың сөйләгән сүзләрен әйтәсем килә: «Ленин бөек кеше,

даhи иде», «Минем Ленинга ихтирамым зур», «Ленин бик галим, XX гасырның көчле кешеләреннән». Аның бу сүзләре Ленинга чын күңелдән булган ихтирамын аңлаталар. Әле ул вакытта (1923—1926 елларда) интеллигенция арасында Советларга кире караштa булган (актив формада булмаса да) элементлар бар иде. Шуңа карамастан мин Фатих аганың Советларга кыеклата гына булса да кире фикерләрен ишетмәдем. Бәлки сүз чыкканда ул һәрвакыт уңай карашлы фикерләрен әйтә иде. «Минем Советка ышанычым зур», «Истикъбал бик парлак» (перспектива бик якты), «Совет кешеләрне аның шәхесенә карамастан эшләргә өйрәтә»,— дия иде. Моңа мисал итеп, ул үзенең апасының тормыш тарихын сөйләде.

Фатих аганың дуслары, якыннары күп иде: доктор Мөхәммәдъяров, Кәрим Тинчурин, Галимҗан Шәрәф, доктор Терегулов һәм башкалар.

Аның янына студентлардан да килүчеләр күп иде. Аларның барысын да яратып сөйләгәнен хәтерлим. Бигрәк тә ул Кәрим Тинчурин белән дус иде. «Мин Кәримгә шундый киңәшләр бирдем», «Әле мин Кәримне ачуландым»,— дип якын итеп әйтә иде.

Фатих ага үзенең әсәрләре турында сүз чыкканда «язучыга иҗтимагый фәннәрдән, медицина һәм биология фәннәреннән өлеше булырга кирәк икән. Бу хәл миңа Фәтхулла хәзрәтнең улгач терелгәнен язганда бик сизелде. Шуның аркасында минем әсәрләрнең сәльби (кире) яклары да булды. Әле ул хезмәтләрне төзәтәсе бар»,— дип сөйли иде. Мин Фатих агадан: «Фәтхулла хәзрәт» әсәрендә мәчетне мәhабәт итеп күрсәтүнең сәбәбе нәрсәдә?»— дип сорагач, ул миңа түбәндәгечә җавап бирде: «Әсәр нигездә үзенең бурычын үтәде. Аңлаган кешегә ул дингә каршы һөҗүм иде. Ләкин әле ул вакытта дәһрилек рухы белән әсәр язарга иртә иде. Аның язылганына 20 елдан артык бит. Ул вакыт «дин мәгыйшәтчеләр, ишмичеләр» халыкта дини тәгассыбны (фанатизм) көчәйтеп торалар иде»— диде.

Фатих ага һәр әңгәмәсендә диярлек Габдулла Тукайны искә алмый калмады. Аның шигырьләреннән мисаллар китерә, талантына соклана иде. Ләкин аның хакында һәрвакыт сөйләгәнгәмедер, Тукай турында конкрет сүзләре хәтеремдә калмаган.

Фатих аганың һәрвакыт рухлы булуы югарыда әйтелгән иде инде. Бервакыт авыруын ишетеп мин аның янына кердем. Хәлен сораштыргач, ул миңа: «Миндә туберкулез булса кирәк, ләкин мин аннан курыкмыйм, җәй генә җитсен, мин Берсутта нарат урманында аның кирәген бирермен»,— диде.

Фатих Әмирханның сәламәтлеге турында партия һәм хөкүмәт бик зур кайгыртучанлык күрсәттеләр. Авыруы белену белән һәрвакыт специалист-врачлар аның янында булдылар. Хәле җитдиләшкән вакытта безнең парадный яныннан җиңел машиналар китмәде. һәр сәгать консилиум булып торды. Обком, Совнарком вәкилләре бер-бер артлы килеп тордылар. Шул вакыт Фатих ага миңа: «Бу ни хәл? Хөкүмәт һәм бөтен Казан аякка баскан»,— дип үзенең бу кайгыртуларга ризалыгын аның дулкынлануыннан аңларга мөмкин иде.

Фатих аганың хәле җитдиләшкән икәнен белгәч, мин аның янына кердем. Китмәгәндә ул миңа: "Ярый хуш, Гаяз, исән бул, киттек без»,— дип бик гади итеп үзенең үлеме турында әйтте. Дөрестән дә мин эштән кайтканда Фатих ага инде өзелгән иде. Аның үлү, аны күмү көннәре минем хәтеремдә нык сакланган. Фатих аганы күрү өчен студентлар, эшчеләр, интеллигенция оешкан рәвештә килделәр. Күрергә килүчеләрдән зур чират тезелеп торды. Күмү көне гаять көчле матәм тантанасына әверелде. Озатканда партия, хөкүмәт тарафыннан оештырылган митингта Ирек мәйданы халык белән тулган иде. Озаткан вакытта Жуковский урамыннан Тукай урамына кадәр озатучы халык сузылган, урамнарның һәр ике ягы халык белән тулы булды. Халык арасында русча «Знаменитый татарский писатель»— дигән сүзләр еш ишетелә иде. Бу картина Фатих Әмирханны халык никадәр яраткан, никадәр аңа югары бәя биргән һәм аның үлүен нинди зур югалту итеп санаганлыгын күрсәтә иде. Талантлы, үзенең сөекле язучысы Фатих Әмирханны халык бервакытта да онытмас.

6.04.1957 ел.

Гаяз БАЙКИЕВ».

**Наил Вәлиев,**
филология фәннәре кандидаты

# ӘДИП КӨЛӘ...

Фатих Әмирхан үз иҗаты белән провинция мещаннары тормышына, шәригать кануннары буенча яшәгән дөньяга актив мөрәҗәгать итә. Алдынгы карашлы һәм революцион-демократик юнәлештәге әдип өчен әлеге мохит нигездә көлке объекты булып тора. Язучы ул дөнья кешеләреннән, андагы тәртип-гадәтләрдән рәхәтләнеп көлә. Ләкин шунысы да бар: аның көлүе кычкырып, авыз күтәреп көлү түгел. Бу көлү — артык усал да һәм артык көчле дә булмаган көлү. Ягъни, икенче төрле итеп әйткәндә, күз яшьләре аралаш көлү.

Үзе сайлаган «караңгылык патшалыгы»н фаш итү өчен әдип нинди принциплардан файдалана соң? Мисалга Ф. Әмирханның бер әсәрен — «Габделбасыйр гыйшкы» хикәясен алыйк. Бу хикәяне игътибар белән күздән кичергәндә шуны күрәсең: әдип күпчелек очракта өч төрле алымнан файдалана. Ул я бик нык арттырылган, гротеск хәленә күтәрелгән ситуацияләр куллана, яисә сатирик читләштерүгә бара. Я инде геройга карата ироник караш хасил итүче көлке атмосфера тудыра. Әнә шуларның барысын да истә тотып инде, күрәсең, профессор Ибраһим ага Нуруллин үзенең «XX гасыр башы татар әдәбияты» исемле китабында бу әсәрне Ф. Әмирханның иң яхшы сатирик әсәрләреннән берсе дип атады. Мондый төгәл бәя белән килешмичә мөмкин түгел, әлбәттә.

Беренче карашка бу хикәядә әллә ни мөһим вакыйгалар да сурәтләнми шикелле. Бер мәдрәсәдә укучы Габделбасыйр исемле шәкерт янәшәдә генә яшәгән байның кызына гашыйк була һәм кыз да аны ярата башлар дигән хыял белән өметләнеп яши. Әсәрдә бары тик әнә шул гына сурәтләнә. Ләкин хикәяне игътибар биреп укыганда аның тирән эчке мәгънәсе ачылып китә. Ул бөтенләй бүтәнчә, көчле яңгыраш ала.

Габделбасыйр кыз да ярата башлар дип көтә... Әмма кыз, аны ярату түгел, әле Габделбасыйрның барлыгын да белми. Габделбасыйр, гомумән, аны күрмәгән дә, авыз ачып бер сүз әйтмәгән дә әле.

Алай булгач, әллә соң бу Габделбасыйр бераз тилемсәрәк кешеме? Менә шушы урыннарда инде әсәрне әсәр иткән мәгънәләр ачыла, ачыклана башлый.

Габделбасыйр — бик үк ярлы булмаган крестьян малае. Атасы аны кеше итәргә теләп әлеге кадими мәдрәсәгә биргән. Габделбасыйр еллар буе әнә шунда яткан һәм ул чор мәдрәсәләре өчен бик тә типик, мескен бер адәмгә әйләнгән. Аның бай кызына гашыйк булгач үз-үзен тотышына күз салыйк. Юк, Габделбасыйр кызны очрату, күрү өчен җан атмый. Йөрәген юлларында аны сагалап тормый. Күрү бәхетенә ирешеп, йокысыз да кала алмый. Кызга үзенең кайнар хисләрен дә белгертми, хат та язмый... Менә боларның берсе генә чынга аша калса да, Габделбасыйр үзе булмас иде. Ул инде башка кешегә әверелер иде. Ә биредә, безнең алда нәкъ менә шушындый Габделбасыйр, авыл крестьянының мәдрәсә бетереп килүче малае!

Бу тип — дөньяны, тормышны яхшырту, нинди дә булса берәр якка үзгәртү түгел, ә бөтенләй чынбарлыктан куркып яшәүче, аңа борын тыгарга да өркүче мескеннәр вәкиле. Иске татар мәдрәсәләре нигездә нәкъ менә шундый кешеләр әзерләп чыгара иде инде.

Үзенең хәле кызганыч һәм көлке булу вакыт-вакыт Габделбасыйрның аңына барып житә. Ләкин чынлыктагы эшләрнең ничек торуын күз алдына гына китерү дә аны чамасыз куркыта, котын ала — ул вакыт инде Габделбасыйр өчен, гомумән, дөнья беткәндәй тоела. Яңадан хыял дөньясына китү, онытылу гына Габделбасыйрны коткарып кала.

Кыз турында уйлаганда да шулай килеп чыга. Көнел төбендәге бер уй Габделбасыйрга гел тукып тора — «син кем дә, ул кем?» Хыял дөньясында исә бөтенләй бүтән. Анда бай кызы Габделбасыйрны ярата, аның кочакларына ташлана. Менә ничек алдана герой! Дөресрәге, куркудан, башка чара булмаудан, бичара булып үзен-үзе алдый. Габделбасыйр тормышта яшәгән нинди дә булса реаль кызны түгел, ә үз хыялында үзе үк тудырган бер шәүләне, ялган бер образны ярата. Ягъни биредә безнең алда платоник мәхәббәт. Урта гасырлардагы һәм борынгы греклардагы платоник мәхәббәт хакында В. Г. Белинский әйткән түбәндәге сүзләр Габделбасыйр уңае белән ирексездән хәтергә килә: «Алар бары тик ярату өчен генә яратканнар. Яратам һәм яратылам диган хыялый ышанудан хасил булучы йөрәк хисләре — алар өчен иң бөек бүләк, иң зур канәгатьләнү булган...» (Белинский В. Г. Әсәрләр өч томда. 3 том, 223 б.).

Ләкин биредә Габделбасыйрның әле тагын шул ягы кызык — ул үз хыялы тудырган

шәүләне генә түгел, үзенең иске бишмәтен дә сөйгәне кебек күреп ярата. Ул бөтен йөрәк хисләрен аңа бушата, һәммә серен һәм теләнә килгән барлык назлы сүзләрен дә шушы бишмәткә әйтә. Хәтта Габделбасыйр үзенең сөйгәне булып күренгән бишмәткә исем дә куша: башта аны Диләфрүз дип атый, аннары инде бишмәт Газизәбануга әйләнә.

Шулай итеп, әдип үз героеннан чынбарлыктагы хәлләрне арттыра-арттыра көлә, реаль тормыштан күтәрелеп көлә. Габделбасыйрның бу рәвешле кылануын сурәтләү дә фрейдизм карашлары белән, җенси мәсьәләне куерту белән бәйләнмәгән. Биредә бөтен хикмәт түбән катлам кешесенең психологиясенә кайтып кала. Җәмгыятьнең кискен социаль бүленеше, катламнарга бүленүе — шуның ише мистика тудыра.

Әсәр хакында сүз алып барганда тагын шуны да әйтми ярамый: анда сатирик-юмористик юнәлеш нечкә һәм оста язылган лирика белән дә үрелеп китә. Язучы әнә шул кичерешләрне бик табигый итеп һәм шул ук вакытта тирән социаль мәгънә белән дә тасвирлый. Безнең алда билгеле бер социаль шартлар тудырган тормыш, аның көлке дә, кызганыч та тибы пәйда була. Хикәядәге хәлләрнең буш хыял гына түгеллеген тагын шул да раслап тора — Габделбасыйр үзенең гыйшкы турында иптәшләренә әйтмичә дә булдыра алмый. Габделбасыйр гыйшкы турында инде бөтен мәдрәсә белә башлый. Бу урында элекке кадими мәдрәсәләр тәртибе тагын бер мәртәбә көлке утына алына. Чөнки бары тик кадими мәдрәсәдә генә әнә шундый мистика озак яши ала иде.

Мондый сәер, көлке мәхәббәтне сурәтләүнең тагын бер ягы бар. Әдип әнә шул ысул аша мәдрәсә тормышының чыдап булмастай күңелсезлеген күрсәтә. Әлеге гаҗәп «рату күңелсезлеккә каршы ирексездән бер чара булып аңлашыла. Шуңа күрә, күпмедер дәрәҗәдә Ф. Әмирхан үз героен кызгана да. Аның мәдрәсә тормышын яратмавы, матуррак яшәү теләп хыяллануы әдип йөрәгендә яклау да таба.

Бу хикәядән күренебезчә, язучы «рухи сынау»га үз иҗатындагы уңай геройларны гына түгел, ә бәлки көлке, хәтта сатирик типларын да дучар итә. Геройның күрмәгән-белмәгән кызга карата сәер гыйшкы биредә әнә шундый сынау булды. Җансыз бишмәт Габделбасыйр өчен илаһи затка әйләнде. Димәк, бу гадәти түгел — бозылган, үзгәртелгән хәл. Автор яшәгән җәмгыять шартлары барлыкка китергән гариП мәхәббәт. Анда кешедәге матур сыйфатларны үстерергә, иҗади көчләрен камилләштерергә мөмкинлек юк. Үзенең бар булган көчен, хис-омтылышларын бишмәт яратуга юнәлдергән кешенең иҗтимагый үсеш өчен дә, сәламәт тормыш өчен дә никадәр зыян китерүе ап-ачык, әлбәттә.

Ф. Әмирхан бик тә үтемле итеп әнә шундый фикерне укучы зиһененә үткәрә. Хикәяне укыганда укучы күз яше аша көлә-көлә уйлана...

# «ӘЛЬИСЛАХ»ЧЫ ГАРИФҖАН МОСТАФИН

Фатих Әмирханның тормышына, иҗатына караган материаллар көндәлек матбугат битләрендә әледән-әле чыгып тора. Бу язмада исә без «Әльислах» газетасы секретаре булган Гарифҗан Мостафин турында әйтеп китәргә телибез.

Гарифҗан Мостафинның улы Искәндәр чакыруы буенча 1985 елның сентябрь аенда Уфага барып килдем. Без Искәндәр белән мәктәп яшеннән үк дус булып үстек. 1932 елны Казанга укырга китәр алдыннан мин аларда шактый вакыт тордым. Шуннан бирле Гарифҗан ағаны яхшы белә идем.

Искәндәр миңа әтисенең үз кулы белән язып калдырган «Беренче садә» («Беренче тавыш») белән «Озату-бәхилләшү» текстларын бирде. Билгеле булганча, аларның баштагысы Беренче рус революциясе елларында татар шәкертләренең гимны булып китә. Ә бу әсәрнең авторы кем соң?

«Беренче садә» заголовкасы илә язылган стихотворение 1905 ел революциясе башларында Россия бөтен татар шәкертләре яшерен подпольный организациясе «Ислах» («Реформа») комитеты тарафыннан язылып, татар телендә гектографиядә басылып таратылды. Авторы Гарифҗан Мостафин»,— дип язылган безнең кулда булган бер документта.

Гарифҗан Мөхәммәтҗан улы Мостафин 1884 елның 28 октябрендә Татарстанның хәзерге Апас районы Колгына авылында туа. 1906 елны «Мөхәммәдия»не тәмамлый. 1904 елны «Әльислах»ны оештыруда актив катнаша һәм аның секретаре була. Реакция һәм яңа революцион күтәрелеш елларында авылда яши, мәктәпләр оештыра. 1917 елны Уфага күчә, төрле җирләрдә эшләп 1972 елны вафат булды. Шәриф Байчура үзенең бер мәкаләсендә: «...Казан шәкертләренең «Мәркәз әльислах комитеты» исемле яшерен бер оешмасы да барлыкка килә. Фатих Әмирхан шул комитетка башлык итеп сайлана.

Хәзерге көндә Уфада яшәүче 81 яшьлек Гарифҗан Мостафин яшерен «Мәркәз әльислах комитеты»ның члены һәм секретаре була»[1],— дип яза.

Гарифҗан Мостафин «Мөхәммәдия»дә укыган чагында ук Ф. Әмирханның якын сабакташы була. Аларның дустанә якын булулары әдипнең соңгы көненә кадәр дәвам итә. Ф. Әмирхан 1924 елны Уфага баргач Гарифҗан дустына төшә. Азатлык рухында язылган «Беренче садә», «Озату-бәхилләшү» шигырьләре авторы Гарифҗан иҗатына Ф. Әмирханның турыдан-туры тәэсире булуы бик мөмкин.

Гарифҗан аганың үз кулы белән язып калдырган «Беренче садә»нең тексты түбәндәгечә:

Кояш чыкты нур балыкты
Тәрәзәдән өйгә аркылды.

Уян, шәкерт, ятма йоклап,
Уяныргa вакыт җитте.
Җитәр инде күп йокладык,
Чыга алмаслык сазга баттык,
Бу сазлыктан чыгу өчен
Туды инде зур яктылык.
Бик аяныч шәкерт хәлең,
Бушка әйләнде синең валың.
Һич файда итә алмадың
Исраф булды синең малың.
Моңа кадәр гыйлем эзләп,
Тирә-якны йөрдең күзләп:
Таба алмадың һич нәрсә дә
Фәкать акчаң тузды йөзләп.
Үлек ташып ашау булды
Ашый торган синең ашың.
Иске-москы уку илә
Катырдылар синең башың.
Канча вакыт бушка үтте,
Канча гомер җилгә китте.
Мондан ары китмәс өчен,
Кузгалырга вакыт җитте.
Инде хәзер сүз беркеттек,
Якты юлдан аерылмаска,
Гафләт[2] йортын ташлап китеп,
Кире әйләнеп кайтмаска.



*Гарифҗан Мостафин (1884—1972)*

Курыкмыйбыз бәддогадан,
Күптән аның тамры корган.
Иске-москы кирәкми дип
Кычкырабыз бер авыздан.

Гарифҗан Мостафинның үз кулы белән язылган һәм Вафа Бәхтияров тарафыннан расланган белешмәдә түбәндәгеләр теркәлгән: «Беренче садә» шигыре 1905 ел революциясе башлану илә һәм шулай ук «Озату-бәхилләшү» шигыре 1905 ел революция чорында, революция азагында реакция көч алып бик күп сәяси иптәшләр кулга алыну, сөргенгә җибәрелү һәм Казанда татар мәдрәсәләрендә «реформа» ясауны таләп итүче күп кенә шәкертләр мәдрәсәләрдән куылу вакыйгалары тәэсире илә шуларга багышлап Гарифҗан иптәш Мостафин тарафыннан төзелеп, яшерен рәвештә дәвам иткән «Үзәк ислах комитеты» аша, җилем матбагасында басылып таратылдылар.

Соңра 1907 ел Хуҗа Бәдигый тарафыннан нәшер ителгән «Сайланма шигырьләр» мәҗмугасында басылып чыкты.

Шушы белешмәнең дөреслеген раслыйм.

1907—1908 нче елларда Казанда чыгарылган «Әльислах» газетасының рәсми редакторы һәм 1905—1906 нчы елларда яшерен рәвештә дәвам иткән «Мәркәз ислах комитеты»ның бар эше белән, шулай ук шул комитет тарафыннан яшерен җилем матбагасында басылып таратылган прокламацияләр, шигырьләр белән якыннан таныш булган Вафа Бәхтияров.

Подпись гр-на Бахтиарова заверяю НМШк. № 19 (подпись) 23/IX. 53 год.»

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

[1] Шәриф Байчура. Татар яшьләре хәрәкәте һәм Фатих Әмирхан (Истәлекләр буенча). «Казан утлары», 1966, 1 сан 114 б.
[2] Гафләт — игътибарсызлык, ваемсызлык, гамьсезлек, наданлык.

# Нури Арсланов

## Уйланулар

Кинҗәм дия иде әнкәм минем,
Бик иркәли иде байгышым.
Мин хәятның бер шат улы идем,
Никтер үксез итте язмышым...

Бөек Тукай да бит үксез булган,
Ләкин халкы аны үз иткән:
Күңел кошы йолдызларга кунган!
Түзсәң Тукай кебек түз икән.

Тарсын икән дөнья читлекләрен,
Илең белән бергә ян икән,
Халкын кардәш итеп чит илләрнең,
Үз халкыңа тугры кал икән!

Санамадым күке кычкырганын,
Юрамадым гомер мөтдәтен:
Оныта иде күңелем үксез чагын,
Үтәлгәндә кайбер көткәнем.

Мәрхәмәтсез булса да, бик тугры
Вакыт ача кемнең кемлеген!
Әл дә ярый бер байлыгым булды,—
Ул да булса күңел көрлегем.

Ялгызсынсам, күңелем шифа тапты
Йөз дүндереп күпләр ягына,
Күпләр хәлен үз иткәнгә ахры
Мин канәгать кылдым барыма.

Мөмкин кадәренә без күнеккән...
Ә җан тели мөмкин түгелне:
Җирдән торып космос серен күптән
Инде ачкан идек түгелме?!

Тукай моңын, Хәйям фәлсәфәсен
Байрак итеп күккә күтәрсәң,

---

НУРИ АРСЛАНОВ — 1912 елда туган, күренекле шагыйрь, татар һәм рус телләрендә күп китаплар авторы, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1985), тәрҗемәче.

Калдыралмас иде кебек нәселен
Фани җирдә җаны күгәргән.

Юлларымда булды үлем, дәһшәт,
Күп кичердем сугыш газабын:
Бер дә уйламадым озак яшәп
Күрермен дип тормыш азагын.

Килмәс төсле иде бусагама
Ак сакаллы чагы гомернең;
Инде җырым Ләйлә түгел аңа,
Инде мин дә Мәҗнүн түгелмен...

Кинҗә дия иде туган анам,
Булырмынмы кинҗә[1] илгә дә?
Ил турында тирән уйга талам,
Изге йөгем баскан җилкәмә.

## Бөек сәйях

Ниләр генә борчымый бу җанны,
Нинди уйлар килми бу башка?!
Хыялланам бер дә сыймаганны
Сыйдырырдай булып колачка.

Төн. Мин йоклый алмыйм: җиргә күктән
Хикмәт яусын диеп нур булып,
Кешеләргә вакыт инде күптән,
Йөрмәсеннәр диеп хур булып,

Күңелләре изгелеккә тулып,
Камилләшсен өчен һәр эштә,—
Матдәлектә калмый, мәгънә булып
Ашсын өчен Кеше Гарешкә.

Күпме язган Әбугалисина,
Күпме йөткән юллар тузанын!..
Якты гомер теләп, бәндә, сиңа,
Сизми калган гомере узганын...

Солтан Мәхмүт кебекләрдән качкан
Саклар өчен вөҗдан сафлыгын,
Белгән — сарай колы юлына баскан
Голяманың җаны сатлыгын.

Иске кабыгын салган кебек елан,
Җәһаләттән чыкса кешелек,—
Йөрмәс иде бәндә мәхлук сыман,
Җанварлыгын искә төшерел...

Бөек остаз кабызып бәгырьләрне
Үзе янган, дүнгән йолдызга:
Яктырткан ул аңны, хәтерләрне,
Әверелмәсен өчен җан бозга.

[1] Кинҗә — гаиләдә төпчек бала, иң кадерле бала.

Туганына меңнән артык инде,
Яткан җае шәһри Хамадан.
Гизәр өчен Җиһан диган Илне
Сәфәр чыга ул өр-яңадан!

Ибне Сина әнә атлап бара...
Алып китә мине иртә дә:
Кайчак тәмам шәкерт булам аңа,—
Ара да юк безгә, киртә дә...

Чиксез дала. Ерак кәрваннарның
Адымнары салмак, сиртмәле...
Уйларның да чиге юк бит аның,
Булмагандай Галәм чикләре.

## Тылсымлы кораб

Уяну белән пәрдәң ач алдан:
Күпме соң вакыт? Инде таң алды.
Күрше йорт әнә тәгәл ут алган,—
Балкуда,— димәк иртәнге алты.

Пәрдәләр аша күпме хәрәкәт!
Һәр хәрәкәттә: «Өлгер, кичекмә!»
Һәр бусагадан иңсен бәрәкәт,
Тусын иртәләр иминчелектә.

Ашыгып тора җылы урыныннан
Кырмыска-кеше шундый иртәдә;
Тынгысыз язмыш, килсә кулыңнан,
Үз ит андыйны, сөй син, иркәлә!

Рәхәт кочактан урамга чыккач
Кинәт салкында туңмасын кеше;
Елмай син, язмыш, ач аңа колач,
Михнәт булмасын, дан булсын эше.

Яктыра тирә. Ялтырап тора
Күрше йорт, барлык тәрәздән карап:
Гүя туктаган Идел портында,
Утлар балкытып, тылсымлы кораб.

## Ачылу

Күз яшьләрем аша елмаям гел,
Дус-ишләрем шуны белмиләр:
— Туган чагыңда да җылап түгел,
Көлеп тугансыңдыр син,— диләр.

Ташлар ярып үсеп чыга үлән.
Каян килә диген көч аңа!

Шул үләндәй нәзек булган белән
Баш имәдем Илдән башкага.

Ә Ил — түзем, сабыр, нишләсә дә
Ил иңрәми, Ил күр, Ил көлә:
Чөнки өскә таулар ишелсә дә,
Ярып чыга үлән, ул белә!

Вак-төяктә минем юк бер эшем;
Зур бурычлар белән шәп күңел!
Елап туа икән тусын кешең,
Елап яшәү ләкин шарт түгел.

Гаҗәп! Сыкрап-көлеп торганда да
Сизенмиләр дуслар, белмиләр:
— Җылап түгел, Нури, туганда да
Җырлап тугансыңдыр син,— диләр.

## Кыр казлары

Күктә иркен киек-казга,
Кагынмый оча төсле,
«Каз юлы»ннан йолдызларга
Кагылмый оча төсле.

«Кыйгак-кыйгак!» диюләре
Юллары озынгадыр,—
Үсмер казлар чит илләрне
Күрергә кызыгадыр...

Киек казлар күлгә куна,
Канатлары талганда.
Ялгыз каз төсле талпынам
Япа-ялгыз калганда.

Бигрәк моңлы очып барган
Киек каз тавышлары;
Гомерләрнең яшел яздан
Көзләргә авышканы...

## Күрше

Тар күңеллегә киң дөнья да тар,
Бикләнеп уңмый эшнең берсе дә:
Изгедән-изге «күрше хакы» бар,
Шатлык-кайгыны бүлеш күршеңә.

Беренче булып ул күз төшерә:
Өеңме яна, көеңме яна.
Яхшылык көтсәң күрше кешедән,
Син дә үз итеп күз төшер аңа.

Уңышлар булсын күршеңә юлдаш,
Иминлек тапсын йорты, мал-җаны!
Пешерсәк өйдә берәр тәмле аш,
Уртак бүләбез без бер калҗаны.

Дөнья ул шундый, төрләнә күңел:
Әле шатлана, әле көрсенә...
Тик ни булса да битараф түгел.
Ышгенем ачык минем күршемә.

## Син бәхетле, диләр

Миңа карап: «Син бәхетле,— диләр,—
Сиңа тормыш ипле!»
Эчтә ниләр барын тик белмиләр:
Кеше күңеле бикле...

Ансат кына ачып булмый аны,
Ул — хәзинә, тылсым:
Яратылган шулай кеше җаны,
Посмый нәрсә кылсын?!

Тик кайчакта, көләчлектән әллә
Ачыла микән келә,
Күренеп китә микән бүтәннәргә
Фәкать бәхетем генә?

Хәер, миңа: «Син бәхетле!» дигән
Өчен генә дә мин
Бик бәхетле! Бүтән кирәк микән?
Ул хәтлесен белмим.

## Син генә

Чәчәкнең кызылы син,
Дөньяның кызыгы син,
Бер сыйфатың меңгә күчә:
Җанга ыгы-зыгы син.

Сәбәпсез турсаясың,
Аяусызсың, чаясың,—
Белмәгәнгә шулайдыр шул
Иркәлекнең чамасын.

Тылсымчым, күрәзәчем,
Кояштан күләгәсең:
Күңел багларымда җиләс
Канәферсең, лаләсең.

Тал булып бөгеләсең,
Җам булып түгеләсең,
Зәңгәр төннәремдә тулган
Ай булып күренәсең.

Йөзләрең балкып тора,
Түшләрең калкып тора,
Чәчләреңнән күк күгәрчен
Исләре аңкып тора.

Бер карасаң, назлы син,
Шулай да бик азмыйсың:
Үзең тыйнак, үзең уйнак,
Җан көйдердең азмы син!

Атлыйсың вак-вак кына —
Йөгермисең чак кына...
Озын телләр дә чарасыз:
Сөйлиләр мактап кына.

Канатлы күбәләгем,
Шат җанлы көлгәләгем,
И минем сабыр-салмагым,
Тынгысыз. көйгәләгем...

Син генә, тик син генә
Тынгы бирмисең генә!
Тынгылар бирмәсәң бирмә,—
Миннән башканы сөймә.

## Кирәк микән

Узган эшләр өчен үзебезне
Газаплаудан, юкка кыйналудан
Кирәк микән күңел бозарга? —
Без генәме? Таңда алсу йөзле
Дөнья да бит түзми оятыннан,
Шәфәгына җиткәч кызара...

# Яз

Матур чаклар!
Өстән энҗе тамып тора,
Ерганаклар,
Кар сулары агып тора,
Дымлы, салкын
Җирне нурга манып кына
Кояш алтын
Литаврасын кагып тора.

Китте кышлар
Мамык тунын салып кына,
Кайтты кошлар
Канатларын кагып кына,
Карда посып,
Умырзая калкып чыга,
Килсә гыйшык —
Урын калмый вак борчуга.

Тирәмдә ямь,—
Мин шул хәят тәмен беләм!
Шуңа сөям
Сезне җаным-тәнем белән.

# Экспромт

Каршыларсың дидем
Икмәк-тозың белән,—
Каш-кабагың төйдең
Карың-бозың белән.

Карың-бозың белән
Ташлар идем күрәп,
Тик нишләмәк кирәк —
Юк шул андый кәрәк...

# Акын язмышы

Актукты, булалмадың минем белән!
Юаттың күпме татлы телең белән.
Утырдык комга язмыш дәрьясында,
Мин калдым җырлап зарлы-моңым белән...
Акан-Сире.

1

Акан-Сире [1] кызны алып кача.
Кияү тиеш кеше
Ярәшкән,
Калым-малын биргән килеш кала,—
Колак кагумы бу кәләштән?

Юк, ул алдан сизеп чара күрә,
Йола саклап төшә арага:
Егетләре аның атка менә —
Ауга чыга төнге далага.

Кияү егетләре ике яклап
Куып килә йөгерек атларда.
Сәйран дала кинәт китә шартлап,
Качкыннарга төзәп атканда.

Һәм Актукты [2] шагыйрь кочагыннан
Атыла,—
Бәхет шунда чикләнә,

---

[1] Казах хәлкының атаклы акыны Акан (Акҗегет) ярышларда алган барлык бүләкләрен ярлыларга өләшә, байлык җыймый. Шуңа күрә аның исеменә Сире (рыцарь) кушаматы өстәлә.

[2] Актукты (Акбәрән) шагыйрь алып качкан кызның исеме.

Шуннан бирле камый рухи зиндан,—
Хәйран гомер үтә тикмәгә.

Акан-Сире исән калсын өчен
Кыз буйсына язмыш хөкменә,
Сабырлыкка сарыф итә көчен,—
Тормыш була миннәт-йөк кенә...

2

Акын йөри халык күңелен ачып,
каршылыйлар тиңсез чичәнне
Куйлар суеп, тутырып казан асып:
Төн, думбыра — җырлар кичәсе.

Киң далада өермәләр булып
Күтәрелә шагыйрь сүзләре:
Сайрый җырлар, алтын айга куныл,
Бер уйнак, бер моңлы үзләре,

Бер байларга кагылып мыскыл итә:
Бу чагында ярлы төркемгә
Кызык була,— җыру чәнчеп үтә,
Йомарланып, охшап керпегә.

3

Актуктысы аккош булып куна
Арман күлгә, ярын калдырып,
Колагире [1] туйда һәлак була,
Каратургай китә каңгырып...
Эзәрлекли аны түрә-биләр,
Бәла килә өсте-өстенә...
Актык атын Акан-Сире бирә
Җәяү калган бер карт мескенгә.

Ятим-ялгыз шагыйрь, сынган күңел,
Бәхетсезлек калмый артыннан...
Тик җырлары аның ятим түгел,—
Аерылмаган Акан халкыннан.

Каберен бәлки табып булмас инде...
Кирәк микән кабер акынга!
Һәйкәл куйган аңа казакъ иле —
Үләңнәре [2] җанда, халкында!

*1983—1985*

---

[1] Колагир — шагыйрьнең чабышкысы. Аны ярышта үтерәләр. Каратургай — ау беркете. Ул, картаеп сукырайгач, һавадан кыялар өстенә ташланып һәлак була.

[2] Үләңнәре — җырлары.

# Эдуард Касыймов

# ҖИР БАЛКЫШЫ

РОМАН

## Беренче өлеш

### 1



Чем-кара туфраклы киң басуның бер канатында әфлисун төсендәге ялгыз трактор, тигез гөрелдәп, әрле-бирле чәчү җирен эшкәртеп йөри. Тракторчы Хәнәфи Бариевның җиңнәре сызганулы, куллары идарә рычагларында. Ара-тирә башын артка каерып, тракторына тагылган зур һәм килбәтсез агрегатына күз ташлап ала: ипле барамы, янәсе, алай-болай «пеләшләр» калдырмыймы...

Әлеге чәчү җиреннән ерак та түгел, басу түрендә исә бөтенләй бүтән күренеш, хәтта дәһшәтле диярлек манзара: анда бихисап автоскрепер, бульдозерлар җирнең симез кара туфрагын каезлап, бер тирәдә кайнаша... Анда кара-кучкыл тузан болыты күтәрелә, куәтле гүелдәүләр, ачы ыжгырулар колакны тондыра. Җир катламы вакыт-вакыт авыр ыңгырашып, калтырап-дерелдәп китә. Анда мәхшәрнең үзе купкандыр кебек!

Гомер-гомергә адәм баласын туендырып килгән игелекле туфракны, тупас һәм авыр пычаклар белән умырттырып алалар да, «аждаһа» машиналарны үкертә-бакырта ташый биреләр. Кара-кучкыл сырт калыная, күтәрелә бара. Әүвәле күкрәп игеннәр үскән изге, мәрхәмәтле кыр күкрәгендә, менә сиңа рәхим ит, дигәндәй, чем-кара тау калкып чыга!

Басу йөзендә төзәлмәс җәрәхәтләр булып, әрлән балчык сырлары сузылып китә, тегендә дә, монда да шыксыз шадралар ишәя бара...

Инде мәңге уйнамас монда серкәдә утырган арыш дулкыннары, күз явын алып алтынланмас мул бодай басулары...

Ап-аяз күктә май кояшы. Ул бөтенләй гамьсез — планетаның ниндидер бер ноктасында купкан галәмәткә бөтенләй ис-өн сиздерми. Тик рәхимсез кыздыруын гына белә...

Хәнәфи Бариев әлеге хәвефле якка хәтта күз салудан да тайчана. Аның иреннәре кысылган, гәүдәсен вакыт-вакыт сәер дулкын өшетеп алгандай итә, йөнтәс беләкләренә дә җегәр бер кайта, бер китә кебек. Юкса ул совхозның иң әйбәт җирләре зур заводлар астына китәсен күптән ишеткән, моңа җаны белән күптән инде күнгән дә иде шикелле.

Ә кичә-бүген, күр әле, күңеле белән ихтыярсыздан диярлек туарылды да куйды.

Ярыйсы ук киң басу буйлата авыр һәм шома кәтүкләрне әрле-бирле өстерәтеп йөртүләренең хикмәтен, әлбәттә, Мәнди апаең да төшенер бүгенге көндә: җир өсте беркадәр басыла төшеп, ике-өч көн элек кенә чәчелгән кукурузлары дымлы катламда тыгызланыбрак ятсын да, күбенеп, тизрәк шытым бирсен... Әйе, дым барында шытым бирсен, куәт җыеп калсын! Мул уңыш алам дисәң, моннан соң да әле ничәмә-ничә тапкыр эшкәртәсе булыр бу басуны.

Дым, дым...

Бүген иртән совхозның баш агрономы Ризван, имән бармагын янә текә чөйде — ничәмә көннәр инде гелән бер нәрсәне тукый:

— Көне-сәгате кадерле! Китә бит, югала бит дым дигәннәребез. Син дә тырышмасаң, кияү, кем тагы?

Хәнәфи әллә белмиме, аңламыймы? Шөкер, фронттан кайтканнан бирле диярлек тракторда, иген игүдә... Хәер, аңарчы да юеш танавын сөртештергәләп, ялан тәпиләре белән ат кабыргасына бәргәли-бәргәли, басуда тырма өстерәтеп йөргән чагыннан ук әллә ниләрне күңел түренә сеңдерә башлаган игенче малае ич ул...

Күктәге явым, җирдәге дым...

Язга чыктың исә, җылы җилләр дә шуны искәртеп, крестьян күңелен сызландыра лабаса. Елның-елында...

Керфекләр авыр. Кул аркасын маңгаена тидереп алса, анда салкын тир...

Шушы кукуруз җиренә ул кичә төштән соң күчкән иде. Ә бүген төшкә тикле аны бетереп тә куймакчы иде. Кая ул! Күктәге кояш әнә инде түбән таба тәгәрәүгә дә юл тотты. Аның эшкәртер җире исә әле һаман хәтсез. Аргы очтан янә биш-алты тапкыр әйләнмичә түгәрәкли дә алмас.

Юк, бу як басуга чыгасы калмаган аңа. Тегендә Калмаш авылы янындагы кукуруз җире дә атнадан артык инде эшкәртүне көтеп ята. Анда калкурак төш, булган хәтле дымын да очыртып бетерә язгандыр инде. Чөгендер җирләре тагы... Ә монда, «мәхшәр купкан басу» тарафына икенче берәүне җибәрттерәсе калган. Тик кемне?

Баягынак аның янына Гарәфша сугылды. Гарәфша — бүлекчә управляющие, совхозның үзәк авылына хуҗа кеше. Тарантаска җигелгән җирән кашкасын трактор янына ук китереп туктатты. Хәнәфинең трактор күләгәсендә, җиргә аяк сузып, тамак ялгап утырган чагы иде. Теге, тарантастан авыр гына кубарылып төште дә, йомры, калын гәүдәсен язгандай иттергәч, кояшта янып каралган йөзен ямьшәйтеп:

— Бер-бер җире ватылып ятамы инде моның дип, котны алган идең,— диде.— Болай гына икән, ярый... Ә шулай да акыртынрак кыймылдыйсың түгелме син бүген?

— Бетерербез әле. Ашыгып, ашка пешмик.

— Пешәрсең дә! Менә бит ничекләй кыздыра. Моны тизрәк әтмәлләп чыксаң, юлның әнә теге ягында чөгендер чират көтеп ята. «Беларусь» белән шуны...

— Баш агроном Ризван иң әүвәл кукуруз җирләрен бетерергә кушты. Кайсыгызны тыңларга соң?— дип көлемсерәде Хәнәфи, кулындагы сөтле шешәне селеккәләп.

— Агроном, имеш... Мин әйткәнгә колак сал син, йомры баш! Азаккы сүз минеке булыр.

Гарәфша сүзне, бигрәк тә әмер дигәнен, эредән җибәрүчән. Аның бу холкын бик әйбәт белгәнгә күрә, Хәнәфи сүзне капыл өзәргә булды:

— Ярар, аңлашылды... Артыгын боргычламыйк, дим.

— Җук, аңлашылмады әле...— Гарәфша моның каршысына чүгәләп утырды, йомры тез капкачында юантык бармакларын биеткәләп алды.

Хәнәфи сабырын җыя төшеп, башын кыңгыр салды.

— Таң тишегеннән җабышып, миннән өстә утыручылар кемне боргычларга тотына?— дип тезеп алып китте бүлекчә башлыгы.— Директормы анда, баш агрономмы яисә бүтән берәр «башмы»... Кемне, дим? Мине түгелме? Ә мин кемне боргычларга тиешле? Аның дөньясы шулайрак корылган шул, каһәре: боргычлау югарыдан түбәнгә таба бара. Киресенчә түгел...

— Анысы хак...

— Былтыр, өченче ел һай рәхәттә яшәгәнбез икән — прәме сагынырлык! Ә бу язны... тфү! Механизаторларның звенолары таркалып бетте, әнәтерә бәрәңге утыртырга кеше табу көч. Ул да түгел, фермада ике савымчы — ике җилбәзәк атна буе инде кәҗәләнеп маташа, аннары бүген иртән бер көтүче шалапай... теге кем, Исламгәрәй малае, сырт йонныарын кабартып килгән — анысына тикле, «КамАЗга» китәм», дип яный. Эт талагыры!

— Килешәм, хәлләр яман совхозда,— дип ияк какты Хәнәфи.— Шулай да артыгын уфтанмыйк: бер эзгә төшми калмабыз әле. Тукта, әлеге сүзнең җеп очын югалтмыйча сорыйм әле үзеңнән: менә син, әйтик, мине бик шәпләп, үтем сытылганчы боргычладың, ди. Ә мин кемнең шөрепләрен борырга тиеш инде, ә? Өйгә кайткач, хатынныкынмы? Әллә әчтән генә үз-үзеңне боргычлау да җитәрме? Һич югы, ачу-ярсуны басар өчен, шушы җан кисәгем тракторның тетмәсен тетәргә тотыныймы? Ә бәлкем, бары да җиргә сеңсен дип, шушы ипидәй йомшак туфрактан үч алыйммы?

Гарәфша аягына торып басты һәм күз кырыйлары белән генә югарыдан түбән таба сөзеп карады. Тракторчы Хәнәфи белән ул бер генә тапкыр сүз көрәштереп маташмагандыр, әмма кайчан юньле нәтиҗәгә килгәннәре булды икән?

— Җарар, чытырманлыкка кермик...

Хәнәфи дә ризык букчасын күтәреп, аягына калыкты. Азмы-күпме тәгам җыеп, бер ара тын алудан гәүдәсенә хәл кереп китте. Шуңа күрәдер, тавышы ярыйсы ук көр чыкты:

— Елы-көне килеп, үзебез сынатмасак, ышаныч шушы җирдә инде.

Икесенең дә күз карашы тузан болыты асылынып торган «мәхшәрле» басу ягына төбәлде. Беравык тавыш-өнсез генә күзәтеп тордылар.

— Дөбер дә шатыр... Әбәткә дә юньләп тукталмадылар кебек. Вәт нишләтә бәндәне симез калҗа исе, ә?— Гарәфша юантык гәүдәсен Хәнәфигә таба бора төште.— Синең Айдаш та шунда түгел микән?

— Белмим.

— Ул нәрсәдә, скреперлдамы, әллә бульдозердамы?

— Бульдозер дигән иде.

— Алайса, шунда булмый, кайда тагы? Әлегә КамАЗның башы гына бит... Туган авылы кырларында ут уйнатып йөргән егетең сыпыртсын әле койрыгын сыртка салып!..

— Сүзеңне үлчәп әйт, Гарәфша: рөхсәт белән, комсомол путевкасы белән китте лә ул...

— Булса соң! Аны түгел, сине җәлләп әйтүем...— Гарәфша янә тракторчы агайга күз төшереп алды, әмма аның йөз-кыяфәтендә кызгану, үз итү чалымы тамчы да беленми иде.— Үзеңә бак син, Хәнәфи дус, кай көннәрдә тоташтан икешәр смена кудыра-кудыра әлеп киптергәндәй ябыктың лабаса...

— Әллә зарланганым булдымы сиңа?— Хәнәфи тамак төбенә авыр төер менеп килүен аермачык тойды.— Аннары соң, бер улым китсә, икенчесе янда ич... Әллә Вәсимем сынатамы?

— Вәсимеңме? Егет ул!— Гарәфша хәтта телен шартлатып алды.— Бәрәңге җирендә синең Вәсимең тырышмаса, ай-һай ла!..

— Менә-менә, иң әүвәл шулай дип тел тибрәндерерләр...

Шул арада Гарәфшаның йөзенә янә төксе караңгылык иңеп өлгерде.

— Айдашың исә... Ыһым... Хәл белешергә дә сугылмасын әле. Бульдозерын ыжгыртып килергә чүп кенә ара җугыйсә... Әллә күптән түгел үзе эшләп йөргән әфлисун төсендәге «дытысын» танымас булды микән? Хәер, симез калҗа исе борыныңны кытыклап торса...

Моңа Хәнәфи ни дип җавап бирергә дә белмәде. Тик тракторының чылбырына күтәрелгәч кенә, күңел әрнүен яман тавыш белән кысып чыгара алды:

— Атыңны ал дим, сыбызгы! Йөрисең шунда болай да сызлаган җанны көйдереп!

Гарәфша булсын да, каныңа тоз салып китмәсен, имеш...

Айдаш... Чынлап та, өлкән улы аның шунда, басу түрендә бүтәннәр белән бергә үз «аждаһасын» үкерттереп кайнаша микәнни? Моннан берәр атна әүвәл соңгы мәртәбә Чаллыдан кайтуында «Нинди эштә булыйм? Җан фәрманга җир умырттырам», диебрәк сөйләгән иде. КамАЗ төзелешен галәмәт зур диләр, бәлкем ул бульдозеры белән бөтенләй бүтән төштә эш кыйрата торгандыр? Ә бәлкем, мәлгунь Гарәфша авызыннан хаклы сүз ычкындыргандыр: акча сөременнән, җитмәсә тагы, шундый кара-кучкыл тузан болыты эчендә, Айдаш та онытылып киткәндер?

Хәнәфи кукуруз басуын гөлдер-гөлдер иңләп йөрүендә булды, үзе, «мәхшәрле» тарафка күз салмаска тырышса да, күңеленнән һаман, менәменә улы Айдаш, һич югы, җәяү генә тыпырдатып килеп җитәр дә әтисенең хәлен белешер дип, көтә иде. Торган саен бүтән фаразлары басыла, күңелендә тик шул уй, тик шул теләк кенә көчәя, ныгый бара иде. Әле кайчан гына үзе айкап йөргән һәм игеннәр үстергән туган туфрагы лабаса!

Ниһаять, Хәнәфи кукуруз җирен азаккы тапкыр әйләнеп узды. Узды да тирән сулап, кул аркасын янә маңгаена тидереп алды: һаман да салкын тир... Аннары ул тракторын ызан буенда калдырып, үзе әле генә эшкәртеп үткән басуга кереп, җиргә сузылып ятты.

Көн матур, җылы, җир дә коры булганда, ул шулай басуда берәр эшне тәгалләсә, әзрәк тын алгаларга гадәтләнгән иде. Күбрәк вакытта, кулларын баш астына салган көйгә чалкан ята иде. Якында тракторы басынкы гына гөрли — ул аңа җанны тынычландыручы рәхәт көй сыман булып кына ишетелә, үзе исә зәңгәр күк гөмбәзендә йөзгән болытларны күзли бирә, янсә битен йомшак җил сыйпавын тойган хәлдә, керфекләрен йома да оеп китә. Алар шулай икәүләшеп — хуҗа белән аның корыч айгыры — бүтән эшкә кузгалганчы, бер мәл ипле генә хәл җыеп алгалыйлар...

Бүген Хәнәфи җиргә капланып ятты. Куллары белән ян-яклардан сыпырып, мендәр сыман иттереп, кара туфракны өйде. Аннары туфрак мендәргә кулларын җәеп салды, аның өстенә салкын тирле маңгаен... Күр, җир катламы бөтенләй гүләп, дерелдәп тора ич: тегендә артык авырттырып каезлыйлар ахры аның тәнен...

Ә туфрак, җылы. Исе дә җылы. Мәңге тансык һәм кадерле ис... Киләсе елны монысын да тау иттереп өячәкләр. Соңыннан, зур заводлар калыккач — алар тирәсенә, Яңа кала салынгач — аның түтәл-газоннарына сибәчәкләр, имеш. Гөл-чәчәкләр үсәр, әмма иген бөртеге инде бүтән шытмас... Шулай буласы диләр...

Җир җылысы тәнне түгел, җанны җылыта, әчкелтем-татлы исе ачыргаланган бәгырьне иркәли сыман...

Уйлар оча торды, гәүдәсе авырая барды...

Озак яттымы шулай Хәнәфи, азмы,— кинәт үзенең иңбашына кемнеңдер йомшак кына орынуын тойды. Тавышы да үз һәм якын... Бәй, өлкән олы, зарыгып көткәне Айдаш лабаса!..

— Әти дим, бу хәтле үк оемасаң иде лә!

— Берни булмас, улым, берни... Чак кына... Җир кадере дип уфтанудан гына... Безнең үзебездә генәме, бөтен Чаллы районында иң һәйбәт басулар ич болар! Теләсә нинди елда уңышны мул бирер җирләр.

— Бик беләм! Шуңа күрә бер карышы, бер учы да әрәмгә китмәсен дип изаланабыз да бит инде.

— Артык кәҗүнный сөйлисең кебек, улым... Ата-бабаларыбызның тире дә, каны да тамган туфрак бит! Читтән-яттан килгән халыкка бары да бер, ә сиңа?

— Әйтәм бит, шуңа күрә аны күз карасыдай саклап кына...

— Их, әле кайчан гына ярыша-ярыша эшли идек! Борчак басуында керәшен Әртәми алга чыкса, арыш яки арпа, кукурузда безнең бригад алдырыр иде... Ә былтыр ишелеп уңган бодай соң! Кайсы басуыбыз гына бирә алыр икән тагын шундыйны — уеңа кергәне бармы, улым?

— Ник кермәсен, ди? Шуңа күрә...

— Сез анда дөнья җимерттереп җир каезлыйсыз, ә минем монда бәгырь каезлана... Их, улым, улым!

Хәнәфи, үпкәчел, әмма җылы хис белән улының иңбашына кагылмакчы булды, әмма уң кулы, һавадагы бушлыкта айкалып алгач, коры туфракка орынды. Шул мәлне авыр сискәнүдән торып утырса, янында бер кем дә юк икән. Тик чак кына читтәрәк, басынкы моңга чумгандай, тракторы гына гүелдәп тора...

Төш тә түгел, өн дә түгел, әллә ни... Тәмам исәрләнүеме әллә?

Ах, җир, җир — мәңгелек куаныч, мәңгелек хәсрәт! Син түзәсең, ә мин?..

Әртәми... Әртәми Колчерин... Берничә еллар буе Хәнәфи белән бергә кырлар киңлегендә алышып-ярышып йөргән дусты да, көндәше дә...

Менә кем бу көнне, бу сәгатьтә Хәнәфинең уй-хисләрен аңлап, аның хәленә керә алыр иде. Тик шушындый чалт аяз көнне аны өйдә туры китерүләре генә... Авылы Үтәдем әнә кул сузардай гына җирдә, Шилнә буендагы биек тирәкләр ышыгында гына җәйрәп ята. Алдагы язмыш тамырына инде балта чапкан чибәр авыл — их, дөньялар!..

## 2

Бүтәннәр өйдә югында, аулак сәгатьләрдә Мәтрүнә түти, самавырын яңартып, чәй эчәргә яратучан булып китте әле.

Картая төшсәң, хуш исле сөтле чәй йөрәккә сары май инде ул. Бигрәк тә сулышны куырырдай шушындый кызу көннәрдә.

Ваклап туралган шикәрне тел очына сала-сала бер чынаяк бушатты, икене, өчне... Ниһаять, сусыны басылып, гәүдәсенә рәхәт җиңеллек һәм җегәр кайтканлыгын тойды, зиһене дә тәмам ачылып киткәндәй булды. Моның соңында, өстәлдәге ризык өстенә чиста тастымал каплады һәм урыныннан кузгалды. Кузгалды да яулык очы белән генә авыз тирәсен сөртештергәләгәч, аш арты догасын әйтә-әйтә:

— И ходаем, җирдәге дәүләтең белән туйдырып торганга сиңа шөкер итәбез. Күктәге дәүләтеңнән дә буш калдырма инде,— дип чукынып алды.

Инде хәзер эштән кайтасы кешеләр өчен дә аш салып җибәрсә ярый торгандыр. Кастрюльне урындыкка куеп, су чүмеченә генә үрелгән иде, капыл бүленеп калды: олы як тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп, капка төпләренә трактор килеп туктавын ишетте. Бу ни хикмәт икән? Кем икән? Аларның капка төпләрендә трактор гөрелтесе яңгырамаганга бер атна гына түгел бит инде...

Аптыраган хәлдә болдырга чыгып басуына, капкадан берәү тамак-кырганый-кырганый инде кереп тә килә иде. Тузанга-майга күмелгән, таушалганрак кием — мондыйларга Мәтрүнә түти әллә кайчан күнеккән инде, тик бу адәмнең йөзе-кыяфәте артык алҗыган да, бер үк вакытта ярсыган да кебек тоелды түтигә. Болай таныш та кебек үзе, бик таныш

кебек... Болдыр төбендә тукталып, Мәтрүнә түти белән жылы гына күреште, саулыгын сорашты, аннары ипле генә елмайды:

— Ходага рәхмәт димсең алайса. Әйбәт, әйбәт! Ә мин ни, Әртәми Василичне туры китерә алмаммы дип кенә сугылган идем. Ахры, уңмадым бугай?

Менә шунда гына Мәтрүнә түти чәчәкле алъяпкычы өсләтә бот чапты:

— Бәрәч, Әҗәрдән лә син, үзебезнең Хәнәфи лә син! Әллә артыгын олыгаеп киткәнсеңме дим... Әйдүк, әйдүк, Хәнәфи энем!

Бусы баскан җирендә таптангалап, үз сүзен кабатлады:

— Мин болай гына, Әртәми Василичне күрә алмаммы дип кенә идем...

— Һе, әллә ишетмәгән иеңме? Әртәми Бәчиличең савхузны калдырып, төзелешкә җөри бит ул хәзер. Инде икенче атнасын җөри. Онысым Валүдә дә шулай. Анысы кар сулары төшкәнче үк киткән ие. Шулай Хәнәфи җанкисәгем, аталы-уллы КамАЗга җабышты бит безнекеләр!

— Менә сиңа мә... ишетмәсәң ишет!— дип баш чайкады Хәнәфи һәм шул мизгелдә кисәк тез аслары йомшаруын тойды. Болдыр баскычына утырмыйча чарасы калмады. Колак артын кашып алгач, шунысы да капыл исенә төште: беркөннәрдә ишеткән иде шул, имеш, Гәрдәле җирендә борчак чәчтереп йөргән чагында Әртәми Колчерин, кулында туфрак учлап, «Үз басуларымнан колак каккач, дөньяның кызыгы бетте миңа, борчак җирегезне генә бетерешәм дә үзем дә биштәрне аркага асам әле»,— дип әйткән ди. Тәки үз сүзендә торган икән...

Хәнәфи шулай калын җилкәсен җыергалап утыра бирде, Мәтрүнә түти үзләрендәге хикмәтле үзгәрешләрне үзенчә аңлатырга тотынды:

— Соң, безнең авылның җартысы купты инде шулай. Нишләсен кеше? Чәчкән-урган җирләребез китеп бетте, үзебез завод чолганышында калып җатабыз...

— Кая, тамак чылатырга салкын суың юкмы?

— Ниткән су сиңа? Әлсерәсәң, самавырым гөжләп утыра! Әйдә дим, ризыктан өстен түгелсеңдер әле.

— Бу кыяфәттә өйгә үтүе дә...

— Һе, синең ише трактористны күрми җәшәгәнме әллә без?

Аш өстәле алты почмаклы иркен генә өйнең алгы өлешендә, кече якта иде. Матур ак самавыр, басынкы гына булса да, гөжләп утыруда иде.

Хуҗа карчык көтелмәгән кунак алдына йомшак күмәч телемнәре өйде, шикәрен-маен куйды. Олы гына чынаякка куе иттереп сөтле чәй ясады.

— Син үпкәләмә инде, үзем әлерәк кенә табын артыннан купкан ием. Үрел дим, әйдә, үрел. Ходага рәхмәт, ризыктан өзелдерми бу җылларда...

— Чәйнең бирәгәйлесе бу! Кулларың сырхауны белмәсен, түти!

— Җарый, җарый, син үз җаеңны кара инде иркенләп. Ә мин ашсуымны онытмыйм әле. Фатирчыларым кайтканчы, ичмаса, ите пешә торсын,— ди-ди хуҗа апа чуар чаршау артына кереп, савыт-саба кузгаткаларга тотынды.

— Ниткән фатирчылар ул тагы?

— Соң кем булсын! КамАЗ төзүчеләр инде. Безнең авылга әллә кайчан ук шыплап диярлек тутырдылар бит. Җорт саен! Сезгә барып җитмәделәрмени әле?

— Юк кебек. Хәер, мин таң белән торып китәм, күз бәйләнгәч кенә кайтып керәм, бәлки искәрмәгәнмендер.

— Сезнең Әҗер җырактарак шул... Ә безгә ике җегетне куйдылар. Болай ипләләр үзе. Берсе кыргызмы, казахмы шунда, икенчесе сап-сары башлы — әллә урыс, әллә украин инде. Армиядә чакта ук ахириләр булганнар, ахрысы.

— Алай икән...— Хәнәфи, күз карашын чуар чаршауга төбәгән хәлдә,

үч төбенә йөткергәләп алды, аннары сагаюлы тавыш белән эндәште: — Ә ни... Әртәми Васильич ниндирәк эштә икән инде?

— Һи, аның ишеләргә дөнҗада эш бетәме соң? Аталы-уллы җул салуда алар. Әртәми ниндидер нәрсәкәйдә җулны тыгызлаттыра, ди, ә Вәлүдәбез, үзбушаткычта ташын да, комын да китереп аударып торам, ди.

Ике арада бер мәлгә тынлык урнашты. Хәнәфи өстәл читенә таянып, уйга калды. «Әртәми кайда да төшеп кала торганнардан түгел. Бутаннәр кыздырмаса да, үзе кабынырь»...

Тегендә үз эшен түгәрәкләде ахры, Мәтрүнә түти чаршау артыннан чыкты һәм:

— Анакайгынам, ни уйга батып утырасың әле! Җук-җук, бер җомры белән сусын басыламы соң!— ди-ди, табынга үрелеп, чәй яңартырга кереште.— Әллә ниме, күңелең теге нәмәрсәкәйгә кымырҗылап торамы, хода бәндәсе?

Хәнәфинең ихтыярсыздан авызы ерылды да китте:

— Әртәми дус өйдә булса, бәлкем кәефләнә төшәр идек үзе. Пошаманнарны пыран-заран таратып, дигәндәй.

— Һи, Әртәми дусың булмаса да, куяр гына ием дә бит алларыңа... Җук шул, җиңү бәйрәме көнендә үк инде бүтән тотмаска дип...

— Юк, юк, сүз итеп сөйләмә дә, түти. Чәйләрең бик тәмле!

Кунагының мондый сүзләренә түти бик тә канәгать булды, ахры, җыерчыклы йөзе мөлаем нурларда балкып ук китте:

— Үз чамаңны үзең белгәч, әйбәт инде ул. Ә мин үзем ул «корыткан законнарына» бик тә ризамын болай. Соң, безнең Әртәмине әллә кайчаннардан беләсең ич, ул шайтан суы авызына тисә, әллә нишли: чеп-чи керәшен акылы үзендә — керәле дә чыгалы.

— Ул иблис сөремендә барыбыз да бер иш, түти,— дип кыстырды Хәнәфи, тракторчы дусын беркадәр якларга ниятләп.

— Җарый әле, бәхетебезгә, тегендә барып орына белде, КамАЗга дим. Ходага рәхмәт, соңгы араларда исенә дә төшерми. Әүлиянең үземени!

Мәтрүнә түтинең башка авыл кешесе белән менә болай авыз тутырып сөйләшеп утыруны үтә тансыклавы әллә каян беленеп тора иде, һәм ул үз хәлләре хакында бәйнә-бәйнә тагын ниләр генә тезмәс иде әле, әмма кунагы, чынаягын каплап, аны читкәрәк этәреп куйды да табыннан кузгала башлады.

— Кул-аягың сырхауны белмәсен. Галәмәт булды ла бу!

— Рәхмәт инде ипле сүзеңә! Безне онытмыйча керә белүең өчен тагы. Күр, мәйсез-нисез генә дә байлар төсе инде лә үзеңә!

Чын ахры: Хәнәфи кул аркасы белән маңгаен сыпырып караган иде — юеш. Әмма инде хәзер баягыча салкын тир түгел, кайнар, таза тир бәреп чыккан иде.

— Җомышыңны да әйтмәдең... Әртәми дусыңа ниләр диим соң инде?— дип сорады түтекәй.

Урамда, капка төбендә басынкы гына гөрелдәп тракторы көтә, монда күзләрен челт-мелт йомгалап түти көтә...

— Ни дип... Күп итеп сәлам ирештерерсең. Аннары ни...— Хәнәфи йодрыгын төенләп, югары чөйде:— Җимерттереп эшләсен инде КамАЗ дигәннәрендә дә! Сурәтен тагын да гәҗитләрдә бастырырдай иттереп!..

— И тәмле дә инде телләрең! Үзеңә дә ходай җулдаш булсын берүк!

### 3

Совхоз директоры Таиповның болай да төксе йөзе бөтенләй караңгыланып китте:

— Син нәрсә, берәр котырган эт тешләдеме әллә үзеңне?

— Чынлап әйтәм. Басуда йөрердәй рәтем калмады бүген. Зинһар, дим, Яхъя Таипыч, аер син мине трактордан. Әле үзең дә былтыр ук

механик итеп куярга синнән дә кулай кеше табуы кыен булыр, дип әйткән идең бит.

— Былтыр, имеш. Былтыр без колхоз идек, быел совхоз булдык.

— Бик беләм. Унбер авылдан дүрткә калдырдылар. Бөтенләй бәлакәйләндек... Шулай да урының алмашынмады, һаман да син «баш» бит безгә, Яхъя Таипыч...

— Ә тракторыңа кемне утыртырга боерасың? Үзем утырыйммы?

— Ул гөрләп эшли әле, иясе тиз табылыр. Анда әллә ничә комбайнны төзәтеп бетерәсе бар, ди, бүтәне тагы... Минем бит кул теләсә нинди техникага ябышырдай — үзең беләсең. Ә басуда эш кыйрата алмам инде. Тәмам жаным әрни...

— Минем кыйналмыймыни? Ике мең гектардан артык җирләрең китсен дә... Житмәсә, иң әйбәт, иң уңдырышлы җирләр!

— Ә үзең былтыр актив жыелышына Казанга баргач, КамАЗны котлап, ай-һай да матур, шома сүзләр сөйләдең.

— Иштең! Аны гәҗитләр шулаң матурлап та шомартып язды.— Директорның тавышы капыл чатнап китте, сыкранулы яңгырады.— Мин анда... мин... йөрәгемне уч төбемә салып сөйләдем. Үзем генә беләм!

Кабинетта бер мәлгә урнашкан тынлыкны янә Хәнәфи бозды:

— Анысы бәлкем шулайдыр да. Тик мин әллә кая олакмыйм лабаса, үзем өчен дә, совхоз өчен дә кулайрак эшкә күчерүне генә сорыйм бит.

— Кирәк чагында тракторына да утырырсың, җиң сызганып ремонт ишсенә дә тотынырсың. Теләсә нинди техникага! Бүгенгә шартларыбыз шулай.

— Ай-һай ла...

— Ай-һайлашмыйк. Минем үземә бик ансаттыр, дисеңме?— Таиповның тавышы йомшара төште, ул да үз зарын сиздермичә булдыра алмады.— Бу чәчләр тиккә генә коелып беткәндер дисеңме? Теге чактагы кушылу-эреләнүләр, гигант колхозга әверелүләр, инде менә кире бүленү, кабат вагаюлар. Мең дә бер төрле мәшәкать!

— Мин бик аңлыйм да...

— Көн саен диярлек Чаллыга киңәшмәгә чакыртып торалар, сүзләре һаман да бер: исемегез «Йолдыз», моңа тикле сынатмадыгыз, инде хәзер шәһәр яны зонасында да — сез иң беренче ялтырап-балкып китәргә тиешлесез, диләр. Менә синең кебек үрнәк механизаторларга таянмый, кемгә таяныйм мин бүгенгесе көнне, ә? Шушы коры пеләшем белән генә совхозны балкыттырыйммы?

— Минем үрнәк булырдай чакларым үтте ахры инде.

— Үгми торсын! Әле синең дә, минем дә текәрәк сыртлар ялыйсы бар. Барчабызның да! Бусы бер. Аннан, күземә туры карап, әйтче: нишләп әле син бар семьяң белән совхоз эшенә аяк чалырга тотындың? Сүз куешып баш күтәрүегезме?

Таипов инде аягүрә баскан һәм, ике кулы белән өстәл читенә таянган хәлдә, каршысында җилкә җыергалап утырган адәмне үткер күзләре белән чын-чынлап борауларга керешкән иде. Карашлары очрашкач, Хәнәфинең кара төкләр баскан ач яңагы тартышып ук куйды.

— Ниткән аяк чалу, ниткән баш күтәрү булсын, ди ул?

— Иң әүвәл өлкән улың Айдаш баш калкытты. Килелеген жиңә алмадым. Кыш иде шул. Язын менә мондый дуамал хәлләр туасын сизгән булсаммы? Муенына муенчак элеп, тракторына бәйләп үк куяр идем, билләһи. Кече улың Рәмзи армия хезмәтендә. Ярар, анысына сүз әйтерлегем юк: ил иминлеген саклый. Ә менә син үзең, моның өстенә Васимең...

— Ә Васимгә ни булган?

— Менә күр, күзләреңне зур ачып укы!— Директор юка гына папкадан алып бер бит кәгазь кисәген тракторчы агайга таба очырды.— Гариза. Иртән кертте.

— Минə сиңа!..

— Аның Чаллыдагы комсомолын әйтер идем. Вәсимнең инде җайлап-майлап та кайткан — анда әшнәләре аз түгел ахры. Әллә синең белән киңәшмәгән дә идеме?

Таипов аңа кайчан һәм ничек китереп сугасын алдан ук чамалап куйган иде ахрысы, Хәнәфи бөтенләй бөрешеп калгандай булды, тавышы шыңшыныл чыкты:

— Май бәйрәме алдыннан бер җасканып алган иде үзе, аннан соң ләм-мим...

— Ә хәзер әнә бәрәңгене генә утыртып бетерим.ди. Куалап чыгардым үзен. Мин моны, Хәнәфи туган, директор булып та, партком члены булып та әйтәм: улкаеңны син...

— Мин партийный түгел. Аннары килеп, ул инде...

— Партийный булмасаң, атасы аның. Фронтовик, алдынгы механизатор, җитмәсә, үзеңне әле кайчан гына рабочком члены итеп тә сайлап куйдык.

— Вәсимнең үз акылы үзендә.

— Ни кылсаң кыл, әмма ул егетең моннан ары башны катырып, болай да сызлап торган чи ярага тоз сибеп, бызыкланып йөрмәсен! Ә үз хәлеңне бөтенләй оныт!

— Һай,ансат та соң!

Бу күңелсез тартышу тагын күпме дәвам итәр иде, Таипов тирән иттереп бер сулыш алды да кырт кисәргә булды:

— Ярар, аңыштык кебек. Вакытың буш булса, бар әнә, булыш: авылга ике машинада КамАЗ төзүчеләр килеп төште, партком Садыйков белән авыл советы Галимҗан аларны йорт саен таратып, урнаштырып йөри. Рабочком вәкиле буларак, хет аз-маз эш башлап җибәрүең булыр синең дә.

Хәнәфи урындыгын шыгырдатып кузгалган җиреннән теш аралый сыгып кына чыгарды.

— Икесенең дә җилкәләре калын, телләренә шайтан төкергән. Минсез дә җырып чыгарлар әле.

— Әлбәттә, җырып чыгарлар. Тик үзеңә кулайрак фатирчылар сайлап алыр идең ичмаса. Соңыннан җәфасын күрмәгәең дим!

Кабинет ишегенең каты шапылдап ябылуыннан директор сискәнеп куйды: иртәнге якта улы шулай иткән иде, инде хәзер кичке уңайда — әтисе. Ә бит карап торырга үтә юаш һәм күндәм адәм кебек үзе. Һай, ишәеп китте әле бу араларда ишекне әнә шулай шапылдатып ябулар.

## 4

Урамга чыккач, сулышын җайга салырга теләгәндәй, беравык тукталып торды.

Әнә югары очта бер машина күренә. Түбән очта еракта әнә берәү — монысы шул арада Гыйльметдин тыкрыгына борылып кереп күздән дә югалды. «Димәк, иң әүвәл олы урамнан башлаганнар икән. Таипов хаклы: безгә дә кертәсе итсәләр, юньлерәк адәмнәрне сайлап алмыйча һич ярамас».

Ләкин абзаң бу теләк, бу уе белән дә соңгарган булып чыкты. Урам белән төшеп, үз ихатасына аяк басуга, ни күрсен: ишек алды түрендә, ян бакча баганасына эленгән юынгыч янында ике ят адәм. Берсе — сылу гына гәүдәле, күпереп торган чәчле яшьрәк кенә хатын — җилкәсенә сөлге элгән, икенчесе — ир заты, билгә тикле чишенеп аткан да, ярт-ылаш бөгелгән көенчә, таза гәүдәсенә салкын су сиптерә-сиптерә, ах-ух килә.

«Менә сиңа, апаем, кайнар пәрәмәч!»

Ул арада шул ук янбакчадан, бер учма яшь суган кыягы тотып, хатыны Рәсүлә килеп чыкты. Өстендә әйбәткә кия торган эре ак борчаклы яшел күлмәк, үзенең бит урталары янып пешкән. Тегеләр ягына күз ата-ата хәлне аңлатмакчы булды:

— Өебез иркен, барыбер читтә калдырмаслар ие. Чаллының үзендә өйләргә шыплап тутырганнар, ди, инде. Хәзер авылларга таратталар, ди.

— Беләм. Үтәдемне дә әллә кайчан КамАЗ явы баскан әнә.

— Ирле-хатынлы булсын, дидем инде. Хәзерге жәшләрне беләсең бит: арада әллә ниткәннәре бардыр.

— Ярар, үзең сайлап әйбәт иткәнсең. Бездән генә калмас — илебезжиребез белән күтәрәсе хәлләр бит. Ни, Вәсим кайтмадымы әле?

— Бәрәңгедә үтә дә каты тоталар, ахрысы, күренмәде.

— Тотмыйча ярамыйдыр анысы. Берәр сүз сөйләмәдеме соң?

— Жук. Ә нигә?— Рәсүлә шикле сәерсенү аша иренең күзләренә тутырып карады.

— Болай гына. Ярар, бар, өстәлеңне кара. Юлдан алҗып килгән кешеләрне көттерердәй итмә. Рәмилә өйдә булса әйт: су салып торырга чыксын. Үземә дә бил тиңентен юынмыйча булмас. Әллә нигә бүген бөтенләй тирләп беттем.

— Көне бигрәкләр дә бөркү шул.

Тегендәгеләр йорт хуҗасының кайтып керүен, әлбәттә, шәйләгәннәр иде инде. Ир дигәне ашык-пошык кына сөртенгәләде дә, майкасын, күлмәген киеп алгач, хатынын ияртеп, болай таба атлады. Икесе дә кызгылт чырайлы, житен чәчле, житмәсә тагы, зәп-зәңгәр күзлеләр — тәмам абыйлы-сеңелле диярлегең бар. Каушый төшкәнгәдер инде, уңайсыз гына елмаеп күрештеләр.

— Крутько Аркадий. Ә бу минем җәмәгатем Мила. Людмила ягъни. Сез, зинһар инде, безне менә болай көтмәгәндә генә куктән ишелеп төшкән өчен...

— Төшсәгез, бик әйбәт! Сыярбыз. Дөньялар киң безнең!— дип куллары жәеп жибәрде хуҗа кеше.

— Рәхмәт инде сезгә!— дип пышылдады яшь хатын һәм, тагын да мөлаемланыбрак, тигез ак тешләрен елтыратып елмаеп жибәрде.

Ә Хәнәфи башын кыңгыр салды да карашы белән аларны янә бер иңләп алды.

— Тәк... кайсы якларның җиле китереп ташлады дип белик инде сезне, дускайлар?

— Белоруссиядән без. Витебск тирәсеннән, ишеткәнегез бармы?

— Ишетмәгәннәр кая! Сугышта үзем үткән яклардан икән. Әле сөйләшер сүзләребез булыр. Хәзер хуҗа апагызны зарыктырмыйк. Юл кешесенең хәлләрен бик беләм мин. Ризык капмый — җан эреми, дип тә әйтәләр шикелле.

Кунаклар өйгә кереп китүгә, аннан кызы Рәмилә килеп чыкты. Иң төпчекләре. Әмма буй житкереп, менә-менә пешеп өлгерәм инде дигән чагы. Хәйран гына кыланчык, шактый ук житез һәм боларыннан да бигрәк үтә телдәр кызый баскычтан ук сайрый-сайрый төште:

— Әти, дим, әти, синә әнкәй әйтмәгән дә икән әле: бүген Рәмзи абыйдан тагын бер хат килде.

— Шулаймы? Йә, ниләр язган соң солдат? Кайчанрак кайтып төшәм дигән?

— Кайту синә. Бераз вакыт тоткарланырга туры килә әле дигән.

— Ә? Нишләп икән? Приказ чыкканына әллә кайчан бит инде.— Ата кешенең кашлары капыл җыерылды.— Хезмәтендә бер-бер хәл китереп чыгарды микән әллә?

— Ник алай булсын? Полк командиры үтенде дигән. Яшь солдатларны бераз өйрәтергә кирәк булгандыр, бәлкем.

— Әһе, бәлкем, шулайдыр. Их, кирәк чагы иде шул монда үзебездә

дә, самый кирәк чагы. Ярар, хәерлегә юрыйк. Минзәләдә кунак булып ятмый, солдат хезмәте диләр шул аны.

Хәнәфи, «ходай китереп ташлаган» кунагы шикелле үк, бил тиңентен чишенеп атты. Калай чапчактагы су әллә ни талыгырга өлгермәгән икән, Рәмилә беренче чүмечне коюга ук, Хәнәфинең кызган тәне чымырдап китте:

— Син чамалабрак, кызый.— Тузанга күмелеп, каралып беткән битмуеннарын сабынлаган гына иде, янә ачуланып эндәште:— Син нәрсә, баскан җирендә йокыга киттең тагы? Сал!

— И әти,— дип чәрелдәде Рәмилә, тулы бер чүмечне бер юлы коеп.— Әнә урамнан тагын бер машина узды. Җәяүлеләре гитара чиртеп, җыр җырлап бара. Кемнәргә урнаштыралар микән?

— Эшеңне бел дим, чәтертек! Кемгә кертәсен синнән сорамаслар.

Рәмилә әтисенең түбән иелгән шәрә гәүдәсенә суны коя торды, үзе һаман сөйләнүендә булды:

— Их, бер генә ел алдан туган булсам икән лә! Һич югы, алты яшьтән үк мәктәпкә барып кергән булсам икән.

— Нишләр идең, сыбызгы?

— Быел мин дә менә унны бетереп ятыр идем. Анда безнең унынчылар «КамАЗ» дип бөтенләй шашкан. Бигрәк тә Чуарныкылар белән Үтәдемнекеләр. Минем дә, дим, ичмаса, дүрт ягым кыйбла булыр иде.

— Кыйбла сиңа! Әледән үк киртә буе сикерергә иртәрәк түгелме?

— Сикерсәм соң? Мәктәп — теләсәң кая очып китәр өчен старт мәйданы гына. Син, эткәй, кайчагында теге заманда үлеп, бүген терелгән хәзрәт кебек кыланасың.

— Кыланырсың да сезнең белән. Кая, китер әле сөлгене!

Рәмилә кулындагы алюмин чүмечне чапчак төбенә шапылдатып төшерде дә, әтисенең иңбашына сөлге элгәч, ятьрәк урамга чыгып сызды.

Дөньяның асты өскә килгән диярсең, билләһи, дип уйланды Хәнәфи, сөлге белән сөртенә-ышкына. Чын әгәр: әллә кайчан түгел, былтыр гына үлеп, бүген терелсәң дә, тәмам акылыңнан шашар идең бүгенгесе хәлләрдән.

— Әтисе дим, бигрәк әкрен кыймылдыйсың ла! Кунакларны бу хәтле көттермәсәң соң...

Рәсүлә кулына зур гына табак белән кашык тоткан көе, ишегалдын кыек кистереп, нәүрәпкә таба бара иде. Хәнәфи, бауда эленеп торган чиста ак күлмәкне тартып алды да хатынына таба атлады.

— Салкын катык шәп инде ул, әнисе. Әмма ни...

— Анда өстәл түрендә кайнары да бар, кунагың буш кул белән килмәгән.— Рәсүлә тукталган җиреннән иренә күз чекрәйтеп карады.— Тик үзең «ураза» дигән иең ләбаса.

— Анысы да хак, кеһ-һем.

## 5

Кичкә таба көн сүрелә төште. Әмма урам-тыкрыкларга көтү каршыларга чыккан Әҗер халкының телендә сүз бер тирәдәрәк әйләнде:

— Боерган булса, җаумый калмас. Бу тикле бөркүләнеп торсын да сиңа.

— Зират өстендәге карга-чәүкә өерен күрегез сез. Тикмәгә түгелдер шашынулары.

— Исен сизәсезме? Әлмәт, Зәй якларында шәпләп коя да бугай инде.

Бер Әҗерде, бер Чаллы төбәгендә генә микән? Җәйгә чыктың исә, шулай инде: йөзләгән-меңләгән авылларда күзләр офык читләрен инли, игенче җанында өмет чаткылары дөрли.

Көтү куптарган вак тузан җиргә кире куна алмыйча, байтак вакыт һавада эленеп торды. Бераздан абзар-кураларда сыер мөгрәүләре, кәҗә-

сарык бәәлдәүләре тына төште. Ихаталарда яңа сауган сөт исләре таралды.

Менә шул мәлне, кояш кызарып баерга торганда, ниһаять, көньяк-көнбатыш тарафлар бөтенләй караңгыланды. Ишелеп-ишелеп дөбердәүләр офыкка буйдан-буйга таралып китте, моңа чатнап-чытырдап алулар ялганды, яшен чыбыркылары ялт та йолт күк читен кискәли башлады. Өмет дөрләгән җаннарга шик-пошаман да иңми калмады:

— Һай, берүк бәрәкәте белән генә килә күрсен инде! Бу араларда артыгын кыздырды шул. Давыл булмагае.

— Түгелдер, түгелдер. Җирне туендырырга ашыгуыдыр, дөберди-яшенли мул игеннәр — кадерле икмәк булып килүедер.

Ире янына болдырга чыккан Рәсүлә:

— Бу КамАЗ төзүчеләрен әйтәм әле: аяклары җиңелдән ахры,— диде. Иренең кабыргасына төртеп, верандага таба ишарә ясады. Тик үзләре генә әнә бит тын да чыгармый. Бу хәтле дөбер-шатырны ишетмәскә...

Кунакларга урын-җирне верандада әзерләгәннәр иде. Тегеләр аны бик ошатты. Хәтта шунда төпләнебрәк урнашырга да ниятләре юк түгел икәнлеген аермачык сиздерделәр. Көннәр җылыну белән, бу аулак һәм тыныч почмакны үзенеке итәргә өлгергән кызлары Рәмилә, нишләсен, кунаклар хакына күнсә дә күнде, күнмәсә дә күнде.

— Ул Казан аэропортындагы хәлләр, ди. Җарый әле «Метеор»га баш тыга алдык, ди. Чаллыга килеп төшсәләр, кадрлар бүлегендәге тамаша ди тагы.

— Шул инде: юл газабы — гүр газабы.

Күк гөмбәзен күзләгән хәлдә Хәнәфи хатыны сүзен әнә шулай җепләде, үзе күңеленнән улы Вәсимнең өйдән чыгуын көтүдә булды. Табын артында сүз кузгатып тормады. Дөрес, улына ни әйтәсен әле дә ныклап уйлап бетермәгән, әмма иплән бер сөйләшмичә дә ярамый иде.

Күк йөзе чытырдап, бар дөнья ялтырап китүгә, улы белән кызы бусага төбенә чыгып басты.

— Кая инде клубка? Күрмисезмени, ничек җабырылып килә?— дип аваз салды әниләре.

— Курыкма, әнкәй, күтәреп алып китмәс әле,— диде кызы бер дә исе китмәгән тавыш белән.— Клубта бүген шундый да кызыклы кино, ди.

— Электрны сүндереп куйсалар, булыр сиңа кино... Мондыен дәһшәттә...

— Бер сүндерсәләр, ике яндырырбыз!— диде Вәсим, эре генә тамак кыргалап, һәм шакы-шокы болдырдан төшә дә башлады.

Әмма шул минутта әтисе:

— Сабыр ит әле, улым,— диде.— Син кыекламый-мыекламый әйт әле...

— Нәрсәне, әти?

— Нәрсәне, имеш. Без сиңа атамы-анамы? Киңәш-табышка да ярамый башладыкмыни? Нигә дип син ул кәгазеңне туп-турылай директор Таипов өстәленә илтеп салдың?

— Һе... киңәш-табыш итешергә...— Егет чак кына тотлыгып торды, сүз эзләп азапланды.— Соң... Әнә Айдаш абый сыптырганда бер генә дә тоткарлап маташмадыгыз ич.

— Сезгә әйтмәсә, минем белән киңәште ул,— дип сүзгә кушылды Рәмилә.— Тимерне кызуында сукмыйча...

— Син кысылма ичмаса, бытбылдык!— Аннары Хәнәфи, беләгеннән эләктереп, улына эндәште: — Туган туфрагың лабаса бу! Үз совхозың! Аны ниндәен хәлләрдә калдырып китүеңне аз гына абайлыйсыңмы син?

— Таипов сүзләрен сөйлисең, әти... Бар дөнья купканда, мин генә совхозда сөрсеп ятыйммы инде? Менә үзебезнең авылга да кемнәр генә килеп төшмәде инде «КамАЗ» дип.

— Бик дөрес, абый!

Хәнәфи бер тын үзе сүз таба алмый азапланды.

— Ә директор сине кабинетыннан куып ук чыгарган икән. Ул да үзенчә хаклы бит.

Чатнап киткән яшен яктысында Вәсимнең, бер кулы белән күперел торган чәчен йомарлаган килеш, иреннәрен усал җәеп җибәргәнлеге күренеп алды.

— Куса соң! Муеным сынса сынар, әмма ләкин мин үземнекеннән чигенмәм. Ә син, әти, зинһар, юлларыма киртә куйма инде.

— Син кит, бүтәннәр китсен, совхоз дигәнебез кулсыз-тәрәүсез калсынмы?

— Туктале, әти.— Вәсим җәһәт кенә чүгәләп, кайнар сулышын әтисенә таба өреп җибәрде.— Теге елларны син үзең унҗиде яшь тулартулмаста ук военкомат ишеген барып дөбердәткәнсең ич. Ә колхозда хәлләр хәл булган түгелме?

— Чагыштырдың! Ул чакта сугыш — ил өстенә афәт килгән заман иде.

— Ә бүген бернинди афәт тә юк, әҗәлгә дә барып керәсе түгел. Киресенчә!

Ата кеше тагын сүзсез калды, ыңгырашкандай авыр сулап куйды:

— Барыгыз, алайсам, барыгыз... Сезгә нәрсә: ике дөнья — бер морҗа ла!

Улы белән кызы артыннан шапылдап капка ябылгач, Хәнәфи:

— Кай көннәрдә Айдаш өчен дә булыр дип, тракторда икешәр смена куа идем, инде хәзер өчәрне туры килер микәнни?— диде.

Сүзгә катышмыйча, сулышын кысып кына утырган Рәсүлә, кулын иренең иңбашына салып:

— Ул тикле ачыргаланмасана, әтисе,— дип юатты.— Совхозда да хәлләр бер җайга төшми калмас әле. Жазганын күрербез, җазмаганы читләтеп үтәр.

— Анысы алай да бит...

Ә болыт инде баш өстендә үк актарыла-бөтерелә иде. Вәсим белән Рәмилә клубка барып житкәндерме-юкмы, дуамал җил купты. Әллә ниләрне кузгатты, әллә ниләрне шапылдатты.

— Әтисе, дим, әйбәтләп җауса, җаңгыр суларын җыясы булыр. Иртәгә, дим, мунча җакмыйча җарамас. Кунаклар да бөтен арганлыкларын бетереп, бер кинәнгәнче чабынып чыгар, ичмаса.

— Жыярбыз. Түбәләрдән тузанны бер кат юып...

Хәнәфи сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, кинәт, күк гөмбәзе яман чытырдап, зәһәр яктырып китте һәм шуның арты ук югары очта нидер дәһшәтле гөрселдәп куйды.

— Трансформаторны харап итте ахры.

Беренче ябырылуы узгач, җил тына төште. Ләкин давыл болыты кысыр булып чыкты. Болар өстенә килеп җиткәнче коясын коеп бетергән идеме, җиргә тамчы да яңгыр төшмәде.

Өметләр акланмады.

## 6

Бүген эштән иртәрәк кайттылар.

Рәмилә, җиңелчә генә тамак ялгап алды да, җиң сызганып, өй җыештырырга, идән юарга керешге.

Бик тиз арада барын да ялт иттерде! Ишегалдында капкадан болдыр төбенә хәтле сузылып яткан сайгак такталарына тикле саф балавыздай елык-ялык булып калды.

Кайтып керүенә бер мактасын әле әнисе!

Эшен түгәрәкләгәч, мунча казанында калган җылымса су белән коенып чыкты, аның соңында, гәүдәсендә рәхәт җиңеллек тойган хәлдә, өйләренә кереп, олы яктагы трельяж каршысына утырды. Күрче, иреннәре бөтенләй кипшереп, ярылгалап беткән, ә муен-яңаклары исә тәмам чуен төсенә керә язган. Кыздырган кояш астында салам эшләпә генә ни ул? Әллә кайбер иптәш кызлары шикелле, күз тирәләрен генә ачык калдырып, ак яулыкны бөтенләй урап йөрергә микән?

Тегендә ишегалдына кемдер керде. Атылып чыкса, үз бабасы Туры карт икән. Бабай чал төкләр баскан ияген сыйпаштыргалап, тамак кыргалый-кыргалый иң әүвәл исәнлек-саулык сорашты, аннары ян бакча коймасы кырыендагы эскәмиягә барып утырды. Утырды да кәкре бармакларын кәләпүшенә тидереп алды, боларның иҳатасын күз карашы белән иңләп-буйлап чыкты.

— Тәртип!— диде, җыерчыклы йөзенә мөлаем нур йөгертеп.— Әниең өйдә җукмы әллә, кызым?

— Юк, бабай, тагын Чаллыга күренергә киткән иде ул. Иртүк.

— Эһе. Җә, ничек соң?

— Беренче анализлары болай әйбәт кенә, ди. Сонгылары ни дияр тагы. Бу язны әни радикулитыннан алай зарланмады да бит. Бавыры да рәтләнеп килә кебек.

— Рәтләнә генә күрсен.— Туры карт камзулының бер төймәсен ычкындырып, бик тә авыр сулап куйды.— Шул шикәр чөгендере генә харап итте үзен, шикәр чөгендере генә. Теге җылның авыр көзендә, дим. Болын хәтле җирне бүлеп биргәннәр ие шул. Эш дигәндә җыртлачрак инде, артыгын җыртлач. Әниең тап үземә охшаган — суйган да куйган.

Бу минутта Рәмилә, ихтыярсыздан көлемсерәп, кулын йөзенә якынайтты.

— Әле ни... «Врачлар инвалидлыктан төшереп калдырса, ичмасам, кеше рәтендә эшкә җөрер ием».— ди, куанычы эченә сыймый әнинең.

— Берүк шулай була күрсен! Кеше рәтендә эшкә җөрү — иң беренче дәва инде ул. Ә син, кызым, үзең дә егет инде: әниең җугында аулакта әнә ничекләй җалт иттергәнсең ишегалларыгызны, ә?

Салпы ягына салам кыстырудан кызый эреп китә язды:

— Әле бушап калган чиләк-чапчакларны тутырып куясым бар.

Сүзнең шушы рәвеш алуына бик канәгать булып, Туры карт ирексездән тамак кыргалап алды:

— Алай дигәнеңнән, кызым, ни, үземнең чапчакта да, самавыр куеп, чәйләр эчә торган тәмле суым корыган бит әле. Колонка суы, дим. Ә киленне, Тәзкия җиңгәңне, беләсең инде: фермасыннан кайта алмый, тәмамлай батты. Җитмәсә, Сабир да әллә кайда олагып җөри, чуерташ!

— Алайсам, хәзер гөрләтәм мин самавырны, бабай!

— И кызым-гөлием, рәхмәт инде тәмле сүзләреңә! Тик мин сиңа үз өемдә самавыр гөжләтергә суым беткән дим, лә. Фатирчы җегетләрем дә үлеп җарата ул колонка суын. Эшләреннән тирләп-пешеп кайтып төшкәч, чәйне чөмерәләр генә!

Аларның ишегалды почмагында үз коелары бар. Тегенди-мондыйга суны шуннан тоталар. Ә менә самавырга салырга... Һе, чәй өчен колонка суыннан да һәйбәтен, тәмлесен табып кара син бүгенгесе көнне! Бәла тик шунда: бабалары янындагы колонка эшләми. Алар яшәгән түбән урамда җиргә күмеп салынган торбалар, узган кышның зәһәр суыкларына чыдамыйча, шартлаган да куйган. Инде хәзер урамнарын астын-өскә китереп, актарып ташлаганнар, әмма эшләренең очы-кырые күренми кебек әле. Ә Сабир — «чуерташ» дигәне — бабайга гелән дә түшәк җылытучы үз оныгы — сөекле сөяге, тагы да төгәлрәк, картның үз теленә кайтарып әйтсәк, «нәсел ботагы», ә чынлыкта исә, җилкуар бер җан кисәге. Әлбәттә, ул әллә кайда түгелдер, инеш буенда, су кереп күгелҗемләнгәч, кояшка корсак куеп ятудадыр...

— Траншейларга салырга жүнле торба табалмый көдиләр шикелле. Аннан килеп, эшләрдәй кешеләре дә ай-һайрак шул.— дип сөйләнүендә булды карт.— Их, аптырамас нем, җегәр дә бөтенләй үк беткән түгел, шөкер — ике кулыма ике чиләк асып, сезнең җаннан балдан тәмле суыгызны үзем апкитәр генә нем дә... ни... кеше сүзеннән шүрлим шул, күгәрченем. «Һай, нужаларга төшкән лә бу Туры карт».— димәгәйләре, дим.

— Кызгандырыргамы? Мин барындамы? И бабай!— Кыз аяк очындагы бер таш кисәген тибеп читкә очырды.— Соң, кыенмыни миңа чиләккөянтә асып, ике тыкрык аша җил-җил барып кайтулары?

— Теге көндәгесе өчен дә бик рәхмәт инде! Саклап кына тоттым.

— Хәзер үк илтимме, әллә кичкә табанмы?

— Ничек тә җарар. Тукта, ул хәтле кабаланмыйк, кызым. Мин үз туксанымны тукып, әле сорашмадым да бит, тилебаш.— Бабай җыерчыкланып каткан бармакларын тез капкачында биеткәләп алды.— Үз хәлләрең ничекләйрәк соң, үз эшләрең? Тегендә, җәшелчәчелектә, дим?

— Әйбәт. Тагы ике-өч көннән суган-кишер җирен әтмәлләп тә чыгарбыз.

— Аннары ни?

— Ялга таралышабыз. Кайсыбыз кая. Тик безнең үз авылдагыларга атна-ун көннән ерак болынга китәсе ди әле. Печән җыймага. Бүтәннәр барса барыр, ә мин төкерәм. Әнә Гарәфша абый үзе барсын бик кирәксә!

— Менә сиңа! Болында алай сырт сындырырлык эшләр җуктыр ла?

— Управляющий имеш, адәм мәсхәрәсе! Бүген чәйнәп ташлардай булдым үзен.

— Ник тагы? Олы кешенеме?

— Булса соң! Син, бабай, ишетмәгәч, берни белмисең. Бер заман суган җиренә Гарәфша абый әллә каян гына килеп чыкты да житәкчебез Нургаян абыйны котырта башлады. «Син мине тыңла, туганай, ди. Мин яшелчәчелектә эшләп караган кеше, бик әйбәт беләм хатын-кыз холкын, ди. Хатын-кызны аны иң әүвәл үзара яман да иттереп талаштырыргаызгыштырырга кирәк ди, аның соңында алар, бер-берсенә ләм-мим сүз кайтмыйча, көнләшү ачуыннан үлеп тырышырлар, ди. Син, туганай, болар белән дә шуны сынап кара әле, үкенмәссең».— ди. Мин якындарак кына чүп утап азаплана идем, барын да ишетеп тордым. Без нәрсә, котырган эт өереме әллә? Үзенең дә тетмәсен теттем аннары...

— Тетәрлеге дә булган шул ләгыйньнең.

Рәмилә башын түбән иде, тавышы кисәк сытылып чыкты:

— Ә ул миңа «аҗа кәҗә» диде... Авылда кушамат булып китсә...

— «Ата кәҗә» диме? Ах, иблис өшкертеп, үте сытылган нәмәрсә! Очрасын гына, мин аны... мин аны...— Туры карт утырган эскәмиясеннән авыр кубып, кулын кызга таба сузды.— Җарар, кызым, җебемә дә, чапчемә дә пүчтәккә! Гарәфша — бер, ә совхоз бөтенләй икенче нәрсә. Әнәтерә анда эшкә җөрергә кеше житеп бетми, ди. Җәш чагың — үлмәссең! Ие, җомшарма, диюләрем. Тик бүген гөликәем, көянтә-чиләкләренне оныта күрмә инде бу хәлләреңдә.

— Онытмам. Текер-текер артыннан куып та житәрмен әле, бабай.

Рәмилә, әлбәттә, әйткән сүзендә торды: бер көянтә илтте, икене илтте. Алдагы көннәрдә дә бу хәл кабатланды: кыз тәмле суның тамчысын да коймаска тырышып, зифа буй-сынын сыгылдыра-тирбәлдерә аскы урамга таба ике тыкрыкны буйлый торган булды. Кичке уңайда, көтү кайтып, тузаннар басылгач кына һәм авылга шау-шулы төзүчеләр өере — араларында бабаларындагы өч егетнең, бигрәк тә «шәп мыек»ның кайтуын чамалап кына...

Буйларсың да!

Һай, Туры бабасының өйалдында тулы чиләкләрне эмаль чапчакка «шәп мыек» — молдаван егете бушатмаган булсачы, бушаткач, чем-кара

күзләрен тутырып караган көйгә, үзенең таза кулын Рәмиләнең иңбашына салмаган булсачы!

Һич көтмәгәндә, сүтелә-сүтелә тәгәрәп кенә китте лә күңел йомгагы!

7

Учагы дөрли башлады. Төтене әлегә чыкмый; чыкса да, туры күтәрелә шикелле. Аның җиргә сарылып таралуы соңрак булыр.

Бабасының капка төбендә, буш чиләк-көянтәсен иңнәренә аскан хәлендә, ашык-пошык кына сүз алышулар. Клубта очрашулар. Кинода аерым утырсалар да, тын урамнан бергә-бергә кайтулары. Үз өйләренә җитмәс борын, кызның капыл гына йөгереп китүләре һәм капкадан кергәч, ян бакча баганасына сөялгән килеш, күз йомып торулары... Шигәюсагаюлар.

Юк, болар гына түгел. Кызык һәм үтә күңелле хәлләр дә тумый калмады — булды андый хәлләр!

Бер көнне, өй пәрие юри бозган диярсең, телевизорлары күрсәтмәс булды. Күпме боргаласалар да, ни тавышы чыкмады, ни сурәте калыкмады чәнчелгерененң.

— Бер иләшсәң, ансыз бик тә күңелсез икән шул!— дип ухылдады әнисе Рәсүлә.— Бу кадәр сандыкны Чаллының үзенә хәтле үк өстерәргә туры килер микәнни?

Әлбәттә, Рәмзи абыйсы төзеп тә тормас, әллә нинди осталарга ялынып та йөрмәс иде. Җиңнәрен сызганып, үзе ябышыр, актарыныр-сүтәр, бәлкем, кодрәтеннән килсә, рәтли дә алыр иде. Ә монлагыларга — әтисе белән ике абыйсына — ни? Кая инде телевизор хәтле телевизорга орыну! Аларга машинаның эресе — трактор яисә комбайн, һич югы, мотоцикл ишесе — муеннан майга батардае булсын! Андыен, дөрес, әйбәт өшкерә беләләр — үлгәненә дә җан кертәләр үзе. Ә өйнең иң түрендә кукыраеп утырган нәрсәкәй — хикмәтнең дә хикмәтлесе бит!

Бер көнне кич утырмага килгәч, Туры карт, боларның хәленә керергә теләп:

— Үз түбәм астында оста барында ни пычагыма чит албастыларга җалынырга, ди? «Шәп мыек»ны әйтәм мин. Келәткә утны да үзе кертте «эх» тә димәде. Әле коега электр насосы көйләмәкче. «Суга коендырыйм әле үзегезне!» ди, һе-һе... Инде килеп, мондыен да, шәт, эштән чыгармас,— дип гүелдәде.

Баш тарта алмаган егет. Килде ул молдаван сихерчесе Женя Мында.

Хәер, аңа кадәр хәлнең бүтән төрлесе дә булып алды. Өйләренә сөрем тараткан кебегрәге.

Ул кичне Чаллыдан, мотоциклга атланып, Айдаш белән Вәсим абыйсы кайтып төшкән иде. Егетләрнең кыяфәтләре ярыйсы ук җитди, сөйләшүләре дә эрегә тартым. Теге кайтуындагы шикелле, бусында да Вәсим үзенең эше турында:

— Әлегә тәртип! «Беларусь» җаныкайның, очып китәргә җыенган сымаграк иттереп, ике тәпиен ике якка җәеп салам да тотынам ипле генә җир чокырга. Кирәк икән, күмеп тә, тигезләп тә китәм,— диде.

Алар икесе дә Чаллыдагы күптәнге танышларында бергә яшәп яталар иде. «Ни әйтәсең? Хуҗалар әйбәт, өйләре иркен — әлегә һич нигә зарланырлык түгел. Безгә ул хәтле ни кирәк?» имеш... Шушы уңайдан сүзгә саранрак Айдаш эчендәге бәләкәй генә серен дә тишмичә булдыра алмады:

— Миңа озакламый тулай торакта урын бирүләре ихтимал, фатирдан китәргә туры килмәгәе,— диде һәм каш астыннан гына барысына да берәм-берәм күз йөртеп чыкты.

Вәсим, башын артка каерып, авызын гына җәйде:

— Китсәң соң, аптыраганнар, ди. Миңа иркенрәк булыр.

— Тот капчыгыңны! Торгыздылар, ди, җапа-җалгызыңны, җаныңа бер иптәш кертмичә,— диде әниләре аш-су әзерләгән җиреннән.

— Кызык та инде бу дөньялар!— дип сүзгә катышты әтиләре Хәнәфи, баш селеккәләп.— Чаллыга килеп төшкәннәрне безнең авыл җиренә китереп шыплыйлар, ә безнекеләр Чаллыга барып оялый. Әрле дә бирле чаптыралар — машинаң гына чыдасын!

— Чаптырсалар соң? Заманаң өермә куптарса, шулай булмый ни!— диде Вәсим, таза, йөнтәс беләген өстәл читенә куеп.

— Чынлап та, ник үзебездә генә торып җатмаска,— диде әниләре Рәсүлә.— Кул астында мотоциклыгыз бар, җилләр уйнатып кына җөрисе җугыйсә.

— Әйттең сүз,— диде Айдаш коры һәм саллы тавыш белән.— Көн дә саен авыл халкының күзенә арпа кылчыгы булып кадалыргамы?

— Һич ярамый!— дип куәтләде аны Вәсим.

Ләкин, әниләре пешергән ризыктан авыз иткәч, кикрикләре шәлберәеп, беркадәр зар да сиздерделәр: коры-сары капкалап йөрүнең әллә ни рәхәте юк икән, ә инде ашханәдә тамак ялгап чыксаң, көне буе сару кайнап үтерә, ди.

— Соң, өйдә ризык беткәнмени? Алып китегез дә үзегез пешереп ашагыз алайса,— диде әниләре.

— И әни,— диде Вәсим, каш җимереп.— Вакыт бармы соң безнең? Мәшәкате тагы...

— Алайсам, кайның бирсен саруыгыз,— диде әтиләре.

Табыннан соң, тын алмага, түр якка чыктылар. Менә шул чакны гына Айдаш әлегә кадәр яшереп торган хикмәтен күрсәтте: ул урындык артына элеп куйган пиджагының ике як куен кесәсеннән бәйләмебәйләме белән акча чыгарып, өстәлгә салды. Шыгырдап торган җыен унлыклар, егермебишлекләр — бер өем! Өнсез калдылар.

— Каян бу? Ничек болай?— диде әниләре, ниһаять.

— Узган айныкы. Төп-төгәл алты йөз дә алтмыш сум,— диде Айдаш, калын иреннәрен чак кына җәя төшеп.— Ә син кайгырма, әнкәй: авanska алганыңнан фатир өчен дә түләгән идем, әле торып торырга да җитәрлек калдырдым. Бусы сезгә!

— Һай аллам! Бу тиклем... гомердә күрмәгәнне...— Әниләре утырган җиреннән капыл гына кузгалды да, өстәлгә кояш нурлары төшмәсен, ичмаса, дипме, әллә урамнан кеше күрмәсен дипме, тәрәзә пәрдәләрен тартып куйды.

Вәсимнең күзләре тәмам тасрайган иде, ул кулын күпереп торган чәч өеменә батырды:

— Күр, миңа сиздермәде дә, астыртын. Болай булгач, миңа да «Беларусь» белән саубуллашырга туры килә, ахрысы. Әнә автоскреперда эшләргә берме, икеме айлык курс ачмакчылар, ди. Ул эштә дә әкәмәт шәп төшерәләр, ди.

— Котырган акчалардыр ла бу, котырган,— ди-ди баш чайкаштыргалады әтиләре.— Хөкүмәтне савым сыер иттергәннәр икән алайсам бу зилзиләдә.

— Хәраммы әллә, талап алганмы әллә? Хәләл көчләрне түгеп ләбаса...— Айдаш, үпкә сиздергәндәй, ирен турсайтты.

— Кем көч түкми?

— Соң, улым,— дип ике арага кысылды әниләре.— бу кадәрене кемнәр Удмуртиягә җә исә Пермь өлкәсенә шабашка киткәннәр генә төшерсә төшерә торгандыр. Өченче җылны әнә Гарәфшалар сөйләгәннәр ие...

— Сурәтләрен гәҗиткә басалар, үзләренә көрәп акча өләшәләр — эшләр пулный худта!— диде әтиләре теш аралый гына.

— Җыеп куй!— диде Айдаш.

— Кайларга гына куйыйм соң?

— Син, эни, бигрәк инде,— дип шаркылдап ук җибәрде Вәсим.— Анда абый тырыша-тырмаша нормалар үтәп йөри. Икене-өчне үти, ә сез монда...

— Әллә ниме, үз исемеңә касса ачтырыйммы, улым? Тик ни инде, авылда пышын-пышын сүз таралмагае...

Алар соңгы елларда акчага алай интегеп яшәмәгәннәр иде үзе. Ләкин моңа чаклы өйләренә шушы кадәр акчаның берьюлы кайтып кергәне дә юк иде. Үткән айларда Айдаш хезмәт хакының зуррак өлешен шушылай әнисенә тоттыргалаган, әмма аларның иң зур дигәне — май аендагысы да өч йөз сумнан артык түгел иде. Әле анысына да исләре киткән иде. Нәкъ менә шул чакны Вәсимнең, күзләре майланып, авылдан таярга җене котыра башлады да инде.

Шыгырдап торган акча өеме өстәл уртасында тора бирде. һәр кайсының да күз карашы аңа орынып-орынып алгаласа да, кагылучы булмады.

Әтиләре, майлар сеңүдән каралып беткән юантык бармакларын куе төк баскан иягеннән кубарып алалмыйча, һаман да баш чайкавын гына белде:

— Аның нормалары да котыргандыр... котырган башлар куядыр. Соң, мин норма үтәмичә йөримме? Таң тишегеннән ябышып, кояш баеганчы лабаса! Ә шулай да җәйнең җәй буена алганым шушыңарга туламы икән?

— И әти, сөенер урынга, тиккә бәйләнмәсәнә!— диде Вәсим. Син җир сөрүдә, иген игүдә. Ә тегендә Зур төзелеш! Житмәсә, ударный!

— Ә дәүләт бетәнме әллә?

— Куанырга язган булсын!— диде әниләре Рәсүлә.— Әнә, ишектә кемдер бар. Рәмилә дим!

Ана кеше өстәлдәге акчаны ялт кына чуар алъяпкычы итәгенә сыпырып төшерде дә чаршау артына ян бүлмәгә шылды.

Кем дисәләр, ишек төбендә үзләре чакырган Женя Мында икән. Бусаганы кыюсыз гына атлап үтте дә чак кына көлемсери төшеп исәнләште.

Рәмилә җиңел сулап куйды. Аның йөзе шундук нурга күмелде — күләгәдән кояш яктысына чыктымыни!

Айдаш белән Вәсим дә, егетнең кем икәнлеген аңлап алгач, авыз тутырып елмаештылар.

— Төкле аякларың белән!— Әтиләре Хәнәфи, кулларын киң җәеп, яшь останы түр якка үтәргә дәште.

Айдаш белән Вәсимгә Чаллы тарафына китеп барырга вакыт җиткән иде инде. Әниләре ни кыстаса да, алар кунып калырга теләмәде: иртүк торып вахта машинасына чыгасылары бар, имеш. Алгы өйдә бервакыт эштер-өштер килгәч, алар әниләре шыплап тутырган букчаны асып, ишегалдындагы мотоциклларына атландылар.

Ул арада Женя Мында сандык кадәр нәрсәкәйне, киң кочагына кысып, өстәлгә күчереп утыртты. Егет иң әүвәл инструкцияне актарып, сызымына күз текәп торды, аннары чигәсендәге чем-кара чәч бөтеркәсенә орынды:

— Мондыена миңем борын тыккан юк иде әле. Һм, карап карыйк алайсам.

Ул үзе белән кирәк-ярак коралларын да кыстырып килгән, сәер генә приборга хәтле бар. Бер ара уйланып торгач, тотынды егет сүтәргә, актарынырга. Әллә нине чык иттерде, пыж иттерде, әллә нине ычкындырды, кабаттан ялгады. Рәмилә, терсәкләренә таянган хәлдә муенын сузып, өстәл янында утыра иде, егет кул хәрәкәте уңаенда кызның иңенә орынып та алгалады, ә бер мәлне, янә уйга талгач, ялгышып кына кулын аның йомшак беләгенә салды. Рәмилә шул мизгелдә гәүдәсен кымырҗы-

тып дулкын йөгерүен тойды һәм, артка табан ялт кына күз төшереп алгач, кулын ятьрәк читкә тайпылдырды: әтисе белән әнисе күреп калса тагы! Егет исә, җиңелчә генә сызгыра-сызгыра, телевизор эченә иелде.

Әнә шулай ашыкмыйча, ипле генә «өшкерә» торгач, яшь оста, ниһаять, телевизор шнурын стабилизаторга тоташтырды. Чак кына көтүләренә, экран яктырып китте, яман гыжлаган тавыш купты. Егет янә нәрсәгәдер орынган иде, тавыш саф та, тигез дә яңгырый башлады һәм, син күр дә мин күр, экранда ап-ачык сурәт калыкты.

— Һе-һе, кем әйтмешли, шәп һөнәр иясеннән шүрли инде ул эш!— дип кеткелдәде әтиләре Хәнәфи.— Бик рәхмәт инде! Болай булгач, фатирчылар белән бергәләп, күз чекрәйтеп утырабыз икән бу кичне.

Ул, мәле килсә, күңеленә хуш тапшыруларны, аерата «Вакыт» программасын карамыйча калдырмый торган җаннардан иде.

Рәмиләнең күңеле куаныч белән тулды, шуның билгесе рәвешендә бит урталары алсуланып янды.

Ә егет үзе? Кулларын ышкыштырып торган җирендә, аның да какча яңаклары чокырайган иде!

Ул, әлбәттә, кул ялы хакында ишетергә дә теләмәде.

Әниләре шул арада алгы якта җыйнак кына иттереп табын яңартырга да өлгергән икән инде. Яшь оста, мөлаем көлемсерәп, кандай кызыл помидорны сайлап алды:

— Тансыкның да тансыгы. Әллә безнең якныкы инде?

— Болгарныкы,— диде Рәмиләнең әтисе.

Чыгып киткән чагында Женя Мында сизелер-сизелмәс кенә иттереп Рәмиләгә күз кысты. «Күрдеңме инде: син дигәндә аякларым идәндә минем»,— дию булдымы, әллә: «Бүгенгә хуш, акыллым, әле очрашырбыз»,— дию идеме?

## 8

Мәләкәс елгасы аша күперне моңа хәтле Чаллы тирәләрендә булмаган-күренмәгән рәвештә тимер-бетоннан галәмәт киң, хәтәр биек иттереп салып яталар. Соңыннан, Түбән Кама ГЭСы төзелеп беткәч, шушы бәләкәй генә елга үзәнен, шактый эчкәрегә үтеп, су басып китәчәк ди, күпер астыннан купшы катерлар, елгыр моторкалар выж-выж үтеп йөриячәк ди...

Түбәндә елгачык аша җыйнак кына агач күпер салынган. Аны ипле генә узгач, «Уазик» каршы яктагы текә генә ярны выжлатып менде дә, инде үрне алдым дигәндә генә, кисәк алгы тәгәрмәчләре белән ком өеменә чумды. Һе, олы күпернең бу башында да дамба өйдерергә керешкәннәр икән ләбаса! Якында гына буыла-буыла гүелдәгән бульдозерның кабина ишеге ачылып, аннан усал йөзле бер адәм күренде һәм, һавада кара-кучкыл йодрыгын болгап алгач, бармагы белән чигә тирәсендә бөтергәләде: янәсе, күрмисезмени, кая кердегез, аңгыра башлар!

— Үзләре, юлның ябылганлыгын күрсәтеп, бер билге дә куймаганнар, тфү,— дип сукранды шофер Дифгать.— Элеватор тавыннан гына китәсе калган, Яхъя абый.

Таипов эндәшмәде. Ниһаять, азаплана торгач, комны ерып чыга алдылар.

Кызыл Чаллы урамы тар, бетон юл буйлап әллә ни элдертмичә генә киттеләр. Уң кулда тезелешкән йортларның байтагына — я капкасына, я бура почмагына: «Өй ашыгыч сатыла!» дип язылган фанер такталар кадакланган. Арада ник нигездә, матур кукыраеп утырган өйләр дә бар, аударсаң, нибары утынга гына ярардайлары да юк түгел.

— Утырган нигезләрен ярып трамвай юлы үтәчәк бит, сатмый нишләсеннәр?— диде Дифгать.

— Әйе, ни чарадан бичара,— дип баш какты Таипов.— Әнә КБЗ[1] поселогы ягыннан трамвай юлын сузып та киләләр инде.

Орловка авылының шактый озын һәм ярыйсы ук бормаланып сузылган урамы тагы да таррак. Ләкин монда трамвай керми, шул сәбәпле урам да киңәйтелми, йортлар да сатылмый. Соры тузанга күмелешеп утыралар. Агач-куакларга тикле яшел төсләрен җуя язган.

Соры тузан, үтә вак ачы тузан...

Тар урамда машина ташкыны эчендә кысылган килеш бара торгач, ниһаять, авыл артта калды — киң автострадага чыктылар. Дифгать, күкрәген тутырып, иркен-иркен сулап куйды. Маңгаен каплаган слюда козырегын югарырак күтәрә төште. Хәзер инде, теләсәң, сулга каерыл да киң автострада белән Яңа шәһәргә таба элдерт, анда теләмәсәң, уңга борылып һәм әле күптән түгел генә корылган асфальт бождрадан әйләнә төшеп, ТЭЦ юлы белән чаптыр — ничек китсәң дә, барыбер «Йолдыз» совхозы тарафларына барып чыгарсың.

Ләкин Таипов, утырган җирендә алга таба тартыла төшеп, капыл гына:

— Бу әкәмәтне кистер дә үзебезнең иске Минзәлә юлына борып, күпергә кер. Искесенә!— дип боерды.— Тирәкләр астында туктарсың!

Дифгать сәерсенү аша директорга күз ташлап алды, ләкин аны-моны әйтмәде.

Инде шактый таушала төшкән җыйнак кына таш күперне узгач, шундук сулга каерылып, бәләкәй елга ярында кәпрәеп утырган карт тирәкләр ышыгында тукталдылар.

— Күләгәдә бер тын алыйк, ичмаса!— диде Таипов, җиргә аяк баскач, һәм, чуар кепкасын салып, кульъяулыгы белән такыр баш түбәсен, юан муен артларын сөртештергәләде. Кепкасын үз урынына ябыштырып куйгач, соргылт-зәңгәр күк гөмбәзеннән шәфкатьне белми кыздырган кояшка калын каш асларыннан усал иттереп күз кырые белән караштыргалап алды.— Җир йөзен тәмуг итәргә җыена инде әллә?

Аннары ул тирәкләр күләгәсенә таба атлады, әмма кинәт кенә туктап калды һәм, кулларын ян-якларына чапкалап, ухылдап җибәрде:

— Ах, кадалсын ла иде! Онытканбыз бит сугылырга, хәерсез...

— Кая, Яхъя абый?— диде Дифгать.

— Иске Чаллы аптегына инде. Бу эсседә баш миләре җебемиме соң! Син, энем, яшь кеше, иренмичә генә әйлән әле, булмаса. Мин шушында көтеп ятармын. Менә рецептлары. Бусы — Марзия апаңа, кан басымын төшермәгә, ә бусы — үземә. Йөрәк нервыларын тынычландырырга әкәмәт шәп нәмәрсә үзе, тик сирәк кайта, эт талагыры. Алай-болай тоткарлык туса, туп-туры мөдирләре Нина Андреевнага кер. «Яхъя Таипычка» дисәң, таптырмый калмас, ипле хатын ул.

Дифгатьнең буйсынмый чарасы юк, кире руль артына кереп утырды һәм выжлатып китеп тә барды. Таипов яр читенә килде, түбәнгә күз төшерде. «Битне-башны чылатып алганда, зыян итмәс иде»,— дигән уй килгән иде күңеленә, әмма аста карасу-кучкыл үлән арасыннан ямьсез яшькелт төстә агар-акмас кына яткан суны күргәч, ниятеннән кире кайтты. Борылып, тирәк ышыгына таба атлады. Һәм, кепкасын янә салып, йомшак үләнгә, күләгәгә кырын сузылып ятты.

Бая, партиянең шәһәр комитетыннан чыгу белән үк, ул шушы карт тирәкләр ышыгында тын алуны күңеленә беркетеп куйган иде. Секретарь белән авыр һәм ачы гәпләшүдән соң кузгалган уй-хисләрне ничектер бер әрдәнәгә тезәсе, җанны ничектер тынычландырасы иде. Инде менә — хәерсезнең хәере дигәндәй — үз уйлары, үз хисләре белән япа-ялгызы калды.

Таипов авыр һәм тирән иттереп сулап куйды. Кул аркасын маңгай җыерчыкларына тидереп алды. Шәһәр комитетында Низамов белән ике

[1] КБЗ — күзәнәкле бетон заводы.

арада булган авыр гәп нәкъ менә шушы җем-җем иткән өр-яңа Калага бәйле рәвештә куерып китте дә бит.

## 9

Күрешеп, беравык тегесе-бусы хакында сөйләшеп алгач, секретарь аңа:

— Гариза биргәнсез икән, Яхъя Таипыч. Каян сорыйсыз. Яңа Каладанмы?— дип төбәлде.— Уңайсыз булмасмы?

— Әйе, Яңа Каладан инде, Камил Фәтхиевич. Мөмкин булса,— дип ым какты Таипов, җылы гына елмаеп.— Ә ние уңайсыз булсын, ди? Киресенчә, бик тә уңай: Яңа Кала безнең совхозга нибары сигезтугыз чакрымда гына бит. Машинада ун минутлык юл. Аның юлларын да безнең тирәләргә табан бетонлап-асфальтлап яталар. Эшкә дим, җил-җил элдертәсең генә...

— Анысында шикләнмим, элдертерсез. Соң, сезнең үз авылыгызда менә дигән, шыңгырдап торган йорт-курагыз бар шикелле, менә шул җәһәттән уңайсыз түгелме, дим?— Низамов аңа, үткен күзләрен кыса төшеп, сөзеп карый иде инде.— Бүген Чаллыда квартир мәсьәләсе ничегрәк икәнен чак кына абайлый торгансыздыр ич?

Таипов куырылды да калды. Дөрес, ул «йорт-кура» хакында һичшиксез сүз кузгалачагын алдан ук чамалаган һәм, әйтергә кирәк, үзенчә җавабын да әзерләп куйган иде. Ләкин секретарьның менә болай сорау бирү рәвеше, җитмәсә, тавышының корылыгы, үткен күз карашы белән кармалавы... Таипов үзе дә андый кармалауга бик остарганнардан югыйсә, әмма монда үз башы ут астына эләккәч, сулышына тикле юньгә китерә алмый иза чикте.

Әйе, кайсы авылда кайсы колхоз председателе яки совхоз директоры үзенә шыңгырдап торган йорт өлгертмичә ята, ди? Аны да булдырмаса, тавыклар көләр. Ниһаять, Таипов күнелендәгене, йолыккалап булса да, яктыга чыгарып салырдай хәлгә килүен тойды:

— Соң ни бит, картаюга таба барабыз, Камил Фәтхиевич. Балалар таралышып бетте. Ә карчык инде, Марзия апаң дигәнем, ничәмә еллар кан басымы белән интегә. Ул инде совхоз эшенә йөрү түгел, өй арасында да сукранып кына... Мондыен җаваплы бер чорда совхоз белән киеренке җитәкчелек итеп йөргәндә... ни шул... йорт тоту мәшәкатьләре тагы, аңлашыладыр ки...

Низамов саран гына елмайды:

— Ярар, Яхъя Таипыч, уйлашырбыз. Яңа Кала әле салына гына башлады, алай да инде бик күпләр аңа күзләрен майландырып куйган. Әмма сезне, районда хөрмәт казанган кешене, ничек тә рәнҗетмәбез.

Гәп шул рәвешле ипле генә дәвам итәр иде кебек. Таипов ул минутта йомгакның капыл гына кире сүтелә башлаячагын һич абайламаган, ул аны бөтенләй уена да китермәгән иде.

— Димәк, шартлар ярыйсы, хәтта шәп диярлегең бар бу җәһәттән,— дип ялгады секретарь.— Тик менә елның үтә яман килүе генә... Мондый корылыкны, шушылай көйдерүне ай-һай ла, картлар хәтере сакласа гына.

— Алар бик хәтерли: егерме беренче елны гына шушылай булган. Мин дөньяга килгән елны. Карлар эрүгә, бер бөртек яңгыр төшмәгән. Аннары инде ачлык котырган,— диде Таипов.

— Егерме беренче елга тиңлиләр, ә?— Низамовның да киң, ачык маңгаенда җыерчыклар пәйда булды, бер мәл тын торгач, уфылдап ук куйды.— Ә без әле дә шуңа әзерлексез кебек. Әйтегезче, Яхъя Таипыч, нишләп сездә бер генә трактор су сиптерә? Ни хикмәттер, сугарулы көтүлек дигәнегезнең әлегә адәм карарлыгы юк: ни баганалары куелып бетмәгән, ни тимер чыбыклар сузылмаган, ни чәчелгән үләне...

— Шилнә суын ике төштән бөяргә исәп. Тик ПМК траншея казып, торба сузарга тотына алмый һаман.

— Ә ни өчен җир өслэтә генә сузмаска? Шушы җәй өчен генә ичмаса, ә? Бүтәннәргә яраган сезгә килешмиме?

— Соң, Камил Фәтхиевич...

— Әллә, дим, былтыргы кәмит кабатланамы? Былтыр баш агрономыгызны сугарулы көтүлек өчен басу карап йөргән җиреннән куып кайтарган идегез ич. Имештер, сездән рөхсәт сорамаганнар, абруегызны күрәләтә какшаталар. Ә бит алар күрсәткән басуларны барыбер бүлеп алгансыз түгелме? Әллә, дим, тагын мөгез чыгарып ятасызмы?

— Инде кызуларга исәп. Яшелчәчелектә шикеллерәк...

Бүлмәдә галәмәт бөркү иде. Аның кояшы да, баш калкытуына, иң әүвәл секретарь бүлмәсен кыздырырга керешә ахрысы. Таипов маңгаена бәреп чыккан бөрчек-бөрчек тирне кулъяулыгы белән сөрткәләп азапланды, ә Низамов бер электереп алган кылны йолкуын белде.

— Шикләнәсе юк, кызуларсыз да. Бу җәйне әнә күктәге ходай үзе кисәтеп тора: «Миңа өметләнмәгез, торбаларыгызны ятьрәк сузыгыз да янгырны үзегез сиптерегез, ди. Көннәрне юри коры тотам, дөньяны юри көйдерәм, сез адәмнәр кыймылдасын өчен!»— ди. Бер авылда бер председатель шулай дигән иде миңа. Төпле председатель! Сез, Яхъя Таипыч, теге атнада «Коммунизм» колхозында оештырылган семинарга нишләптер килмәдегез? Ә бит шәп үтте ул! Сугаруны һәйбәт көйләгәннәр. Көтүлекләре дә чын мәгънәсендә культуралы! Печәне тез тиңентен диярлек инде: куедыр, сусылдыр үзе. Кунелләр чын-чынлап хушланды! Районда бар булган колхоз председательләре, совхоз директорлары килгән иде, бериш бүтән белгечләр тагы... Сездән исә баш агроном Ризван Әухадиев кына күренде кебек. Ә үзегез? Файдасы тияр дип курыктыгызмы?

— Соң ни, терлекләрнең җәйге лагере белән изаланган чак иде шул, Камил Фәтхиевич, бик теләсәм дә...

— Ә культуралы көтүлекләр терлекләр өчен түгелмени? Иртәгәсе көнне уйласак, асылда азык проблемасы шул сугаруга килеп төртелә түгелме соң? Юк, Яхъя Таипыч, акланмыйк, зинһар! Сез, минемчә, моңа кырынрак карыйсыз сыман. «Чү, ашыкмыйк, күршеләр бер эшләп күрсәтсен әле, аннары без дә карап карарбыз!» дигән шикеллерәк. Хак әйтәмме?

Таиповның тәмам тиргә батып утыруын күреп, Низамов, ниһаять, өстәл түрендәге вентиляторның кнопкасына басты. Вентилятор җиңелчә гүелдәп һәм зәңгәр башын әле тегеләйгә, әле болайга боргалап, җиләс һава өрдерергә тотынды. Сулыш алуы чак кына иркенәйде. Ләкин тирне баса аламы ул? Монда бит тән генәме, җан үзе тир түгә ләбаса!

Низамов шоп-шома кырылган күгелҗем яңакларын сыйпаштыргалап, янә бер тын сүз катмыйча утырды, аннары баягыча, гәпне капыл гына бөтенләй бүтән юнәлешкә борып җибәрде:

— Инде менә Яңа поселок кору мәсьәләсе. Ишеттем, беренче казыкны каккансыз икән, шул уңайдан сарыклар суеп, шашлыклар да кыздырып яткансыз. Табигать кочагында банкет, ә? «Металлургстрой» төзүчеләре белән чәкешә-чәкешә матур тостлар да әйткәнсездер?

— Ырымы шул бит инде аның, Камил Фәтхиевич.

— Ярый, анысын хуп диик. Төзүчеләр вәгъдәләрендә торыр дип ышаныйк. Мин терлекчелек комплексына кагылмыйм әле. Сездә корыласы поселокның кәгазьгә төшкән проекты бармы? Әһе, бар икән. Сезнең шул проектны уртага куеп фикер алышканыгыз булдымы?

— Булмыйча. Кайдамы? Соң үзебездә инде, партком утырышында.

— «Әкәмәт икән, оҗмахның үзе буласы!» диделәр. Хөкүмәткә мең рәхмәтләр инде!

— Рәхмәтен рәхмәт. Проект болай минем үземә дә ошады. Ә гади халык ни дияр икән? Кичәге колхозчы крестьянның, бүгенге совхоз

эшчесенең фикере, дим? Проектны кем әзерләгән? Гомерләрен шәһәрдә уздыручы кешеләр ләбаса! Алар авылның иркен тормышына күнеккән агай-энене уй-теләкләрен һәрьяклап искә-исәпкә алып бетерде микән?

— Алайсам ни, тагын фикер алышырга кирәгер. Кайда, клубтамы?

— Анысын инде үзегез карарсыз. Халык фикерен белми, ничек инде? Таипов бик тә авыр иттереп сулап куйды.

Моңа кадәр ул төрле актив җыелышларында, шәһәр комитеты пленумнарында бер генә тапкыр катнашмады. Низамовны әллә нича тыңлаганы бар, теле телгә йокмас, теләсә кемне авызына каратып, ышандыра белер, кайчагында кызып китеп, әмма чыгырыннан бик үк чыкмыйча, шәп кенә көйдерә дә белер. Былтырмы, әллә өченче ел ук микән, шәһәр газетасы редакциясендә эшләүче болай төпле генә, акыллы гына хатын: «Килер икән безгә дә шундый секретарь! Ипледер сөйләшүе, әкәмәттер хәлгә керүчәнлеге!»— дип авыз суларын корыткан иде. Әмма Таиповның бериш җитәкче агай-энедән: «Аңа әләксәңме! Җаныңны үтәли күргәндәй, айкый да чыга! Йомшак сыйпап катыга да утырта, каты сугып екмыйча да калдыргалый. Кирәк тапса, култык астына кычыткан кыстырып җибәрергә дә күп сорамый»,— дигәнрәк сүзләрне дә ишеткәне булмады түгел. Таипов менә хәзер бер култык астын гынамы, бар гәүдәсен кычыткан пешергәндәй тоя иде.

— Сез бая совхозыгызны, «күз өстендәге каш», диебрәк әйткән идегез, хаклыкка якын сүзләр бу. Ләкин ул «каш»ның йолкынган ягы җәрәхәтләнгән булуын бер генә дә күрәсе килми шул. Ихлас!— Низамов зур күзләрен тутырып, янә бер карап алды.— Әллә ниме?

Юк, азаккы фикерен әйтеп бетермәде, кинәт кенә өзде. Ул өстәлдәге сәгатенә әледән-әле күз төшергәли башлаган иде инде, мөгаен, берәр киңәшмәгә чумар вакыты килеп төртелгәндер. Таипов кергән чагында ук, алгы бүлмәдә берничәләп кеше көтеп утыруда иде.

— Ярый, Яхъя Таипыч, каты гына сүзләр байтак әйтелде инде, нишләмәк кирәк, «кыек сүз сукырайтыр, әмма туры сүзнең күз чыгарганы юк әле», диләр шикелле. Дөресме? Сездә әле, шөкер, җегәр дә, сәләт тә җитәрлек, дарыгыз, кем әйтмешли, һаман да коры булсын! Тик, зинһар, мөгез чыгармыйча гына, Яхъя абый!

...Таипов кулларын баш астына куеп, йомшак үләндә уйланып чалкан ята иде, торып утырды. Дифгать түгел икән: иске таш күпергә кузовына өстәл-эскәмияләр төягән бер машина кереп бара иде. Озакламастыр, Дифгать тә аптекадан әйләнеп кайтырдыр.

Таипов күз карашын кабат Яңа Кала тарафына юнәлдерде. Җемҗем итә йортлары. Ифрат якын да, ифрат ерак та сыман алар. «Рәнҗетмәбез, уйлашырбыз»,— дигән булды Низамов.

Хатыны Марзияне исенә төшерде: «Абруйлы чагында, йоклап йөрмәсәң лә иде, соңыннан үкенмәгәек!»— дип тукып кына тора. Ул да хаклы: дөнья хәлләрен белеп булмый шул.

## 10

Үтәдем авылында дуңгыз фермасы гына торып калган иде. Бүлекчәнең бар булган бүтән мал-туары Гәрдәле ягъсә Әҗер фермаларына инде өченче елны ук күчерелде. Иген игәр җирләре — һәйбәт туфраклы, елның елында куандырып килгән басулар — хәзер корылып яткан заводлар астында ята.

Таянычы нык һәм ышанычлы булганга, Таипов бу дуңгыз фермасына атнасына бер-ике тапкыр гына суғылып киткәли иде. Килгән чагында да алай төпченеп һәм нечкәләп маташмый. Бу тармакның бар нечкәлекләрен юньләп белмәгән башың белән, ферма мөдире Матвей Асановны ягъсә зоотехник Галина Алексеевнаны уздырмакчы булып, нигә юкка-бар-га тыкшынырга? Керәшеннәр гомер буена дуңгыз асраган халык: белеп

һәм җирен җиткереп карыйлар, хәтта якын күреп, яратып тәрбиялиләр, дисәң дә хата булмастыр. Үрчемне тиешенчә алалар, аннары житләккән хәтлесен һәйбәт симертеп, дәүләткә вакытында тапшыра беләләр икән — куанып яшә!

Бүген Чаллыдан кайтышлый Таипов шунда сугылып китмичә булдыра алмады. Ләкин фермада Асанов юк иде: ниндидер йомыш белән Әҗергә төшеп киткән. Ә Галина Алексеевна хакында: «Әле иң кырыйдагы абзарга дезинфекция ясап бетергәч кенә шушы тирәдә йөри ие, җир йотты мәллә? Ә юк, әйбәтләп җунмага өенә кайтып киткәндер, анда, бәлкем, самавырын да яңартып җибәргәндер инде»,— диештеләр.

— Я, ничек, Мария, хәлләр ал да гөлме?— дип сорады Таипов урта яшьләрдәге кызгылт йөзле мөлаем хатыннан. Директор тирәсенә кайсы кулларын алъяпкычына сөрткәләп, кайсы яулыгын төзәткәләп, дуңгыз караучыларның берничәсе якынлашкан иде инде.— Мырык-мырык «бәбиләрен», дим, шәп чиныйлармы? Сау-тазалармы?

— Мин тагы... үземнең хәлне белешәсең дип торам. Һәйбәтләр, шәп чиныйлар!

Һай, чая һәм четердәвек тә соң бу керәшен хатыннары: җай гына бир — минутында чеметергә торалар! Таипов болар алдында тавышын бик тә көр чыгарырга тырышкан иде, ул аны саклаган хәлдә, шундук хатасын төзәтергә ашыкты:

— Юк ла инде, үз хәлеңне сорашуым. Ә болай, карап карауга, сөбханалла, алмадай күренәсең? Җилекләрне куырган мондыен көнне дә. Ярый әле, дим, сукса тимер өзәрдәй ирең — канатың бар, югыйсә монда... Һе-һе!

Мария, йөзен бөтенләй алсуландырып, җитез генә кул изәп алды:

— И, картаеп беткән башың белән, Яхъя абый!

Бу шук сүзләрне бик үк өнәп бетермәгәне, өлкәнрәк яшьтәгесе соры халатының изү төймәсен бөтергәләгән шәйгә ярыйсы ук коры һәм эшлекле тавыш белән:

— Ә болай, Яхъя Таипыч, әйбәт кенә кыймылдап ятабыз!— дип куйды.— Нормальный диярлек! Соң бу эсседә инде... Рационны бозган җук үзе дә бит... Обратың җитсен дә, тагаракларың корымасын! Чүмерүләрен генә беләләр!

— Үзебез соң, Әүдәки [1] апа! Чәй дә квас, квас та чәй генә ләбаса бу көннәрдә! Шушындый эссегә чыдауларына сөен!— дип кыстырды Мария.— Җитмәсә, артымны шәп бирсеннәр, тизрәк симерсеннәр дип дуылдатып кына торасыз үзләрен!

Төчеләнү, кирәгеннән артык хиска юмартлану Таипов холкына ят нәрсә иде, әмма ул бу сәгатьтә ничектер тыелып кала алмыйча, төчеләнә язып, әйтә салды:

— Менә сез үзегез өч бөртек кенә, ә совхозга сездән дә күбрәк табыш китерүче тагын кем бар икән? Бүгенгә юк андыйлар, юк! Мең рәхмәтләр диими, унганнарның да уңганы диими... Валлаһи менә!

— Үзең шулай дисәң дә, фермабызны тамырыннан корытырга җыенасыз түгелме соң? Бүген булмаса, иртәгә,— диде Мария.

— Юк әле, алай ук ашыкмабыз. Район житәкчеләре дә кушмый. «Татарстан» совхозында кайчан әле дуңгызчылык комплексы корылып бетәр, кайчан эшли башлар? Анда бит әле ябыштылар гына. Бүгенгесе шартларда Чаллы тикле Чаллыны ничек итеп иткә туендырмак кирәк?

— Андагы комплекс, илле дүрт мең баш дуңгызга исәпләнгән, имеш. Дөрес булса, ай-һай ла!— дип авызын чәпелдәтте Әүдәки.

— Анда, җитмәсә, бар нәрсә машинага, автоматка көйләнгән буласы ди. Фабрика булмый ни!— дип куәтләде Мария.

— Безнең күк билдән, тирәсктән сазга батып изаланырганмыни?—

[1] Әүдәки — Евдокия.

дип кинәт кенә баш яулыгын төзәткәләргә тотынды Әүдәки.— Менә кайларда эшләп ятарга рәхәт буласы икән бездәй хатын-кызга!

Гәпнең мондый төс аласын Таипов көтмәгән иде, ашыгып баш чайкады:

— Җә, җә, күрше абзарындагы күркәгә кызыкмыйк әле! Үзебез дә ике мең дә егерме дүрт баш сыерга исәпләнгән ферма корачакбыз лабаса, ягъни, комплекс дигәнем. Өр-яңа, заманча!

Үтәдем фермасы үр кашына урнашкан, шул сәбәпле моннан совхозның байтак җирләре уч төбендәге шикелле күренә иде. Таипов күз карашы белән зәңгәр рәшә эченә күмелгән басу түрләрен иңләде.

— Әнәтерә, күгелҗемләнеп торган урман артында гына. Яңа поселок та шунда — кем әйтмешли, ошбу фани дөньяның тап ожмах почмагында. Комплекс та урман куенында гына буласы...

Таиповның тавышы күтәренке, үтә көр иде. Җае чыгып торганда, эшчән хатын-кызның күңелен бер кытыклап алудан ни зыян? Файда гына. Дуңгыз караучыларның авызлары ерылган иде, әмма Әүдәки, янә иреннәрен капыл гына җыя төште дә, директорның сүзен бүлеп, кырт кисте:

— Һи, Яхъя абый, син үтереп мактыйсың да, андыена безнең ише дуңгыз караучылар җарармы икән? Андыена үзегезнең Әҗер белән Гәрдәле хатыннары әзердер әле.

— Безнең ишеләрнең хәлкәйләре әнә җир белән күк арасында инде бүгенгесе көнне. Кайсы болыт кайсылайга таба апкитәр,— диде хатыннарның берсе, авызын киң ерып.

Шул мәлне дуңгыз караучыларның барысы да диярлек, үзара серле рәвештә ым каккалап, читкә, Яңа Кала тарафларына таба күз ташлап алды. Бу сүзләр, бу серле ым кагулар Таиповка совхозның алдагы язмышына кизәнү, һич югы аңа төкереп карау булып тоелды, һәм ул, болай да эссе һавада тамак төбенең тәмам куырылып киткәнлеген тойган хәлдә, ашыгычлык белән үзенекен тезәргә керешге:

— Сездәй уңганнарны читкә кагарга, читкә җибәрергәме? Билләһи, ул чакта безне җир йотар! Соңыннан Таипов абый үзе әйткән иде диярсез әле менә: Яңа поселокта өр-яңа комплекста ап-ак халатлар киеп кенә, үзара иплe генә ярыша-ярыша җирләр җимертәчәксез әле сез, туганкайларым!

— Җарыша-җарыша, имеш. Адәм көлкесенә кала-кала диген, ичмасам!— дип, кинәт сызган шырпыдай кабынып китте Мария. Ул директорны янә бер чеметеп алырга җай көтеп торган ахрысы. Ә бәлкем, сизгер күңелле бу чая хатын, сүзне капыл икенчегә борып, әлеге киеренкелекне бер селтәнүдә тузгытып җибәрергә ниятләгәндер?— Җарыш дигәч тә, җөкләмә дигәч тә... әнәтерә бөтен авыл көлә миннән!

— Менә сиңа, ник көлә, нидән көлә?— дип текәлде Таипов, киң җилкәсен җыерып.

— Көлмәскә. Шул җөкләмәдән инде. Баганаларга фанер такталар кадаклаттырып чыктыргансыз бит. Арада минеке дә бар. Кызыл өслеккә ак хәрефләр белән «Мин, Мария Колчерина, быелгысы җылны һәр ана дуңгыздан унтугыз җарым баш бала алырга җыенам» диелгән.

— Соң, йөкләмәң шулай булгач, дөп-дөрес ич! Ул такталарны кадаклап чыгарга үзем куштым мин. Ике багананың берсендә. Кем нинди йөкләмә алганын әйттереп. Авыл саен!

— Һай аллам, авыл саен! Аларда да көләләрдер инде. Кирәге җук миңа андый җөкләмәнең!

— Менә хикмәт! Соң, үз теләгең белән алдың ич! Аннары ул ак кәгазьгә бик әйбәтләп, өтерге белән дә чокып алмаслык иттереп, язып куелган бит, сеңелкәем,— диде Таипов, баскан җирендә авыр гына таптангалап.— Социалистик йөкләмәләрне кәмит итәргә монда...

— Ак кәгазьдә җараганы баганада җарамый икән шул, абзыкаем!—

Мария хәтәр бер хәрәкәт белән янә кул изәп алды.— Ичмаса, һәр ана дуңгыздан уртача» дип кыстырган булсалар икән, туң башлар! «Уртача» дип! Хәзер әнәтерә авылга килгән җыен КамАЗчы көлә миннән: «Мария апаем, ди, җыл тәүлегендә бер анадан унтугыз башны алырсың алуын — анысына шикләнмибез, ә менә җарты башлы чучканы ничек иттереп алырсың икән — хикмәтнең дә хикмәте булмасмы?»— ди. Чәчрәпләр китим, шулай ди.

Таипов әле һаман аңышмыйча тора иде, аптыраганнан ахры, кулъяулыгы белән юантык муен артын, маңгай тирәсен сөртештерде.

— Социалистик җарыш диґәч тә монда... «Кимендә унтугыз баш» дип җазган булсалар, бәйләнепләр торыр иеммени?— дип чәтердәвен белде Мария.

— Ие, түгәрәклиселәре калган мәнсезләрнең!— дип Әүдәки дә иптәш хатынына куәт бирергә ашыкты.

Ниһаять, директорның авыз тирәсе җәелеп китте:

— Һы, мин тагы... Тукта, түгәрәклисе булгач, нигә «егерме баш чучка баласы» димәскә? Ярый-ярый, күзне шакмакламыйк! Рабочком белән парткомга әйтермен, төзәттерерләр. Иртәгә үк, дим!— Моның соңында Таипов тәмам эрегән кыяфәт белән баш селеккәләде: — Валлаһи, җәһәннәмгә кисәү булып туп-турылай китүең дә бар сезнең аркада. Ярый, эшегез уң булсын!

Керәшен хатыннары, бөерләренә таянып баскан хәлдә, мыштым гына көлешеп калды, Таипов исә, җиргә саллы-саллы басып, үр битендәге юлда көтеп торган машинасына таба атлады.



## 11

Байтак җирләрне айкап йөргәннән соң, менә инде, ниһаять, кичке уңайда кайтып киләләр. Күпне күрде, күпне ишетте, аннан да бигрәк күпне кичерде — бу көн, мөгаен, Яхъя Таипыч хәтерендә шактый озакка уелып калырдыр. Күкрәгендә оялап алган һәм җанын «Әллә ниме?» дип кимереп торган теге шөбһә корты да инде әллә ни бимазаламый, инде тына төште сыман. Һай, бөтенләйгә тынуы булсачы! Ләкин алдагы көннәрендә, бәлкем, атна-ун көн буена, Таипов шәһәр комитетындагы сөйләшүне тора кайтып исенә төшерәчәген, вакыт-вакыт Низамов белән эчтән генә бәхәсләшеп тә куячагын, һәрхәлдә, бөтенләй үк тыныч яшәмәячәген дә бик чамалый иде. Юк, секретарь алай артыгын шөбһәләнеп ятмасын әле анда. Яхъя Таипычның, шөкер, дәрте дә сүрелмәгән, дәрманы да сыекланмаган, ышанып тапшырылган үз хезмәтендә утлар уйнатырлык җегәрләр бар әле аңарда! Бурыч һәм намус дигәнне канында йөртеп, дан-шөһрәт һәм хөрмәт дигәнне җаны белән татып караган, аның татлы тәмен белгән карт гвардия сынатырмы соң? Әйе, чак кына сабыр итегез, үзен күрсәтә белер әле ул карт гвардия!

Үз көч-сәләтенә ныклы ышанудан туган якты өметнең бәһасы ни? Мөгаен, аңа бәһа куеп булмый да торгандыр.

Кайтыр юллары Әҗер очына килеп төртелгәч, Таипов Дифгатькә машинаны туктатырга кушты да:

— Ярар, энем, ичмаса, син иркенләбрәк ял итеп ал. Иртәгә таң тишегеннән торасың булыр. Ә мин бераз әйләнеп кайтыйм әле,— дип шофер егетне төшереп калдырды.

Машина урамга кермичә, бакча артларындагы юлга борылды.

Чаллы тарафларына сәфәр тотканда алай кыюлык итмәсә дә, үз авылы тирәсендә, үз басуларында йөргәндә Таипов рульгә еш кына үзе утыргалый иде.

Яшелчәчелектә, күр инде, адәм затыннан ник берәү күзгә чалынса икән. Ни сәбәптәндер су сиптерүне дә туктатканнар. Нигә болай иртәләделәр икән? Иртәнге планеркада бераз пешереп алмыйча ярамас үзләрен.

Аның караве, яшелчә басуына тоташып киткән сөзәк кенә үр артында һавага нечкәләнеп атылып менгән һәм дугайланып, чуклы-чакланып төшкән су тасмасы әллә кайдан шәйләнә. Үзе, җитмәсә, әкрен һәм ипле генә әйләнеп тә тора.

Хәнәфи Бариев, сменасын тапшырып, китәргә өлгермәгән булса ярый ла...

Бәхетенә, китмәгән икән әле. Әнә «культуралы көтүлек» дип инде телгә керә башлаган һәм әлегә берьяк чите буйлата гына тәбәнәк бетон баганалар тезелеп киткән яшел басу ызаны белән болай таба берәү төшеп килә.

Таипов, машинасын ызан башында калдырып, кәлдин-кәлдин төшеп килүче киң җилкәле адәмнең каршысына таба атлады.

Җылы гына иттереп кул кысыштылар.

— Шөкер, димсең, алайса, Хәнәфи?

— Шөкер...— Тракторчының кояшта, җилдә кипшергән какча йөзендә җиңелчә елмаю чагылып алды.— Сиптерәбез ипле генә. Алны-ялны белми дигәндәй.

— Синең кулалмашчың теге кемме? Чуардан Минһаҗмы?

— Әйе. Төпле адәм. Төнгелекне дә үзе теләп алды.

— Ә үлән шәп, ә! Менә бит дымга туендыра белсәң, ә!— Таипов куе, йомшак үлән арасын ерыштырып, әрле-бирле йөренгәләп алды.— Сиптерүгә эләккән бу кишәрлек ни чамада?

— Егерме гектарлап.

— Чәчелгәннең нибары алтыдан бере генә шул. Калган хәтлесе әнәтерә тилмереп ята... Хәлләр диген!

— Әллә тагын бер-ике тракторны куябызмы?

— Бүтән эшләрдә дә җитенкерәми әле ул трактор. Менә син, Хәнәфи, Суыксу белән Мәләкәс көтүлекләрен күреп кайтсаң икән! Аларда трактор белән дә сиптерәләр, хәтсез генә торбалар сузып, шуларыннан да коендырып яталар. Үләннәре кайбер кишәрлекләрдә менә болай — тездән югары инде! Сыерларны чамасын белеп кенә кертеп тә чыгаралар, үләнне чабып та ашаталар. Аптырыйсы юк икән, җәйге савымда капыл гына алга ыргылуларының хикмәте әнә нидә икән!

Беравык дәшми-тынмый торгач, Таипов авыр гына сулап куйды, аннары янәшәсендәге тракторчыга күз сирпеп алды да зур, җитди нәрсәне түгел, бәлки гадәти бер әйберне хәл иткәндәй рәвештә генә әйтә салды:

— Сиңа, Хәнәфи, тракторыңнан аерылырга туры килер, ахрысы.

Теге сискәнеп үк куйды:

— Ничек инде ул капылт кына?

— Шулай. Теге чакны үзең дә бик теләгән идең бит! Механик итеп күчер, инде басу иңләп йөрүләрдән туйдым дип колак итләремне чәйнәп бетерә язган идең ич.

— Анысы бит теге чакны. Ә мин хәзер бу яңа эшемә дә күнегеп киттем әле: суны сиптерә барасың, артыңнан, күз алдыңда диярлек, ямь-яшел үләннәр дәррәү күтәрелә бара. Җанга рәхәт!

— Әһе, шулай диген! Менә шул сәбәпле мин сине совхозның бар сугару эшләренә баш итеп куярга ниятләдем дә. Тагы да рәхәтрәк булыр.

Хәнәфи көрсенеп куйды: «Менә нинди гозер белән килгән икән бу йомры баш...»

— Үзенә күрә бригад төзеп, ябышсаңмы? Ә аңа кемнәрне тартасын бергәләп уйлашырбыз. Иртәнге планеркага сугылырсың, дим, ишетәмсең? Вазифа дигәнен исә... механик-гидротехник диярбезме яки аны мелиоратор-механик диярбезме...

Ниһаять, Хәнәфи моңсу гына әйтә куйды:

— Хикмәт исемдә түгел, җисемдә.

— Бик дөрес: җисемдә! Ә җисем дигәнең һавада түгел, кешенең үзендә!

— Инде картаеп барганда гына...

— Һы, урыс ничек ди? «Карт алаша буразнаны бозмас»,— дип әйтәме?

— Урыс әйтә дип монда...

Таипов бер уч үлән йолкып алганлыгын үзе дә сизмәде ахры, менә ул аңа үтә гаҗәпсенеп төбәлеп торды да читкә ыргытты:

— Безгә үгезне мөгезеннән электермичә һич ярамый, Хәнәфи! Анна-ры, дарыны һаман да коры тотуның кирәклеген дә онытмыйк — Таипов, кем сүзләрен әйтүен исенә төшереп, чак кына көлемсерәп алды, әмма барыбер шуны кабатлады, инде басым беләнрәк кабатлады:— Дарыбыз коры булсын, дим, гелән дә!

— Артыгын коры тотып, шартлап куйсаң бер заман?

Бер-бер нәрсәгә төрттерүе түгел микән дип, Таипов тракторчыга янә күз ташламыйча булдыра алмады. Юк, Хәнәфинең йөз чалымында киная-мазар тамчы да беленми, ул калын иреннәре арасына бәләкәй генә яфрак кыстырган да җитди, уйчан карашын аяк очындагы яшел үләнгә төбәгән иде.

Монысын инде нык бәгырьле, каты беләкле тракторчы Хәнәфи Бариевның риза-лашуы дип тә аңларга мөмкин иде. Һәм Таипов ике күңелнең бер тирәнлектә айкалуын абайлап, аннан да бигрәк, көне буе уйлаганнарына, ниһаять, үзенә күрә сөземтә ясарга җай чыгуына куанып, бер сулыш белән диярлек әйтә куйды:

— Шартларга хакыбыз да юк, туган!..

## 12

Алны-ялны белмәстән айга якын эшләгәч, бер мәлне Людмила Крутько, вахта машинасын да көтмичә, Чаллыдан иртәрәк кайтып төште. Куанычы эченә сыймагандай күренә — ишегалдына үтүе белән башыннан кызыллы-яшелле яулык кыегын сыпырып төшерде — җитен чәчләре тузгып китте:

— Ниһаять, тырмаша торгач, биш катлы йортны ял иттердек! «Ура!» дигәндәй! Иртәгә ял!

Юынып-сафланып алгач, әмма хуҗа хатыны әзерләгән чәй табыны артына утырмас борын, әле һаман куану дулкынында йөзгән хәлдә:

— Рамилечка дим, бу арада син дә эшкә йөрмисең бит,— диде.— Әйдә, иртәгә җиләккә барабыз! Чаллы базарында без кызлар белән татып карадык инде. Тик шундый кыйбат. Әйбәт җиләклекләр бармы сезнең тирәдә?

Рәмилә муенын эчкә батырды:

— Якында гына юк шул. Җир җиләгенең оясы Кама буенда инде — безнең еракгагы болыннарда.

— Анда тикле ничекләй бармакчы буласың, тилекәй? Аның соңында болын таптаттырдылар, ди, сезгә. Әнәтерә печәнен чаба да башлаганнар икән инде,— диде әнисе Рәсүлә.— Берсекөнгә җыймага бармакчылар, ди. Ишетмәдеңмени, алдан ук кисәтеп үттеләр?

Кыз борынын җыерды. Управляющий Гарәфша кушкан җиргә аның бер генә дә барасы килми иде. Әмма күңеле бер үк вакытта җилкенеп-кытыкланып та куя иде: яшьләрнең бары бердәй өелешеп, машинада җырлый-җырлый болынга барулары, анда баргач, уен-шуклануларны да онытмыйча, гөрләтеп эшләүләре үзе генә ни тора!

— Булмаса, иртәгә үзебезнең авыл урманы тирәсенә барырсыз. Анда кырый-кырыйларда элгәре әйбәт кенә җиләклекләр очрар ие. Таба алмасагыз, Калмаш урманы җагына чыксагыз да җарый. Үзем уятырмын,— диде әнисе.

— Ә еракмы соң? Һи, биш-алты чакрым гына чүп бит ул безгә! Әйеме, Рамилечка?— дип очынып куйды Людмила.

Иртәгесен иртүк торып, юлга чыктылар. Кулларына, җиләкне куркытмас өчен, өчәр литр сыешлы эмаль бидоннар тотып кына.

Басу юлы бормалы, басу юлы тузанлы. Җитмәсә, кояшы да терсәк буе күтәрелүенә үк, әйбәт кенә кыздыра башлады. Атлый торгач, ярыйсы гына әлсерәделәр.

Ләкин Әҗер урманы тирәсендәге ачык аланнарда, сай чокыр битләрендә үлән тапталып беткән булып чыкты. Ары сугылдылар, бире килделәр, әмма юньле җиләклеккә юлыга алмадылар. Рәмиләнең ак бидон төбе әле һаман күренеп тора, ә Людмила исә бидонына бер генә бөртек тә җиләк төшермәде: ул очраган берен, вагына тикле, авызына озата бара иде, талымсыз.

— Калмашлар калдырыр, ди, сиңа! Аларның борын төбендә генә шул!— диде Рәмилә, ике-өч чакрымнарда киң уйсулыкта утырган авыл ягына ишарәләп.— Әнә бала-чагалары чокыр буйлата өер-өер болай таба сузылган да инде.

— Бу хәтле җиргә килеп тә җиләксез кайтырбыз микәнни?— диде Людмила. Аның аксыл йөзе кояшта янып чыккан, ә зәңгәр күзләрендә үртәлү аермачык сизелә иде.

— Урман кырыйлатып менеп карыйк әле,— диде Рәмилә.— Бервакыт, моннан өч-дүрт ел элек, без әбкәй мәрхүм белән һай шәп җиләклеккә очраган идек! Әнә теге яктагы Калмаш урманы почмагына кистереп чыккан-да юлыккан идек. Күрше район белән ике арадагы чиктән әллә ни ерак түгел иде.

Әҗер урманы куе — эченә ерып керәсең юк. Тоташтан яфраклы агачлар: юкәдер, зирек-усактыр, чикләвек куакларыдыр. Кочаклаша-үрелешә үскәннәр. Йөзгә дым бөркелә, борынны юкә чәчәге исе кытыклап-кытыклап ала.

Кырыйлатып шактый күтәрелгәч, сулга каердылар. Сөзәк үр битендә өлгереп килгән арыш басуы салмак җилдә кыеклатып кына дулкыннар тәгәрәтеп ята. Аны тар гына ызан белән аркылы кистереп чыктылар.

Ләкин Калмаш урманы борынына таба сузылып төшкән һәм тез тиңентен үлән баскан ерганак-үзәннәрдә дә әллә ни уңмадылар: я җиләге очрамый, я очраса да, җиләк яфракларына тикле тапталып беткән, хәерсез. Шулай да йөри-эзләнә торгач, бер төшкә, бүтәннәрдән ничектер аерылып торган һәм шулай ук сука-тырма тимәгән тар гына, җыйнак кына коры үзәнгә килеп чыктылар. Чыктылар да, хәйран аптырашта калдылар: монда җир җиләгеннән келәм җәйгән кебек иде.

— Менәтерә: тырышкан табар, ди!

Берәр сәгать үттеме икән, юк микән, Рәмиләнең бидоны түбәләмә тулды, иптәшенеке исә тула гына язды — яшь хатын, туймас тамак, әле һаман өч җиләкнең берсен авызына озатудан туктала алмый иде. Ниһаять, Рәмилә дә булышкач, аның да савыты тулды.

— Булды бу!

Бик канәгать йөз белән, җиңел-җиңел баскалап, урман канаты буйлата түбән таба сузылган чокыр ярына төштеләр. Монда күкрәк тиңентен үлән, кычыткан, чәбәләнеп беткән куаклар! Атлый-карана торгач, Рәмилә, ниһаять, чокыр төбендә бәреп яткан салкын чишмәне дә абайлап алды — бу минутта дөньяда иң кирәклесен.

Сап-салкын чишмә суы тешләрен камаштырды, кулларын куырды. Ләкин шифасын шундук сизделәр: сулыш алулары иркенәйде, буыннарына җиңеллек һәм сафлык кайтты.

Ипле генә өскә, урман куенына таба күтәрелделәр. Агачлар бу тирәдә сирәк иде, җирне куе һәм йомшак үлән каплаган иде. Ялгыз каен күләгәсенә утырдылар. Монда инде, әлбәттә, бидон тоткаларына бәйләп куелган ризык төенчекләре чишелде.

Тамак ялгап алгач, кулларын ян-якларга киң җәеп, чалкан яттылар. Һавада бихисап шөпшәләр, бал кортлары безелди, салмак кына тилпенеп, иренчәк күбәләкләр очып үтә, чәчәкле үләннәрдән баш әйләндерердәй хуш исләр бөркелә. Төпсез күк зәңгәрлегеннән исә йомшак ак болытлар белән бергә купшы каенның яшел ябылдашы да җиңелчә айкалабөтерелә, үз җаена йөзә сыман.

— Мила апа, безнең яңа поселок шушында булачак инде,— дип пышылдады Рәмилә.

— Шушында?! Кит моннан!— Людмила яткан җиреннән капыл торып утырды, әйләнә-тирәсенә күз йөртеп чыкты.— Әнә теге дулкыннар уйнаткан басу урынындамы?

— Әйе.

— Соң... соң дөньяның бер оҗмахтай почмагы ич бу!

— Урынын тикшереп, тишкәләп-нитеп киткәннәр инде. Әле күптән түгел генә, җәй башындарак кына. «Шәп» дигәннәр, имеш.

— Мондагы төзүчеләргә, һай, рәхәт булыр да инде: ике яклап урман, яшел аланнарында чәчәктер, җиләктер. Чылтырап аккан чишмәсе тагы! Ә соңыннан яшәп ятулары? Күз алдыңа китерәсеңме?

— Китермичә!

Рәмилә дә инде торып утырган һәм салам эшләпәсен тез башына каплап куйган иде. Беравык тын торгач, ул сүз сөрешен генә үз җаена борып җибәрде:

— Мила апа, әйтче: кыенмы буяучы-штукатур булып йөрүләре? Үкендермиме?

— Ниткән үкенү булсын, ди? Дөрес, мин әле остарып бетмәгәннәрдән, шулай да... Көн саен артыңнан ялт иткән бүлмәләр кала, күңелдә көн саен бәйрәм! Ә үзебездә мин, дәүләткә мая туплыйм дия-дия, туеплар да беткән идем.

Тегендә, Витебскида чагында, бу яшь, мөлаем хатын почтада да эшләп караган, госстрах агенты булып та йөргән, ә соңгы ике елында саклык кассасында утырган икән. Җанына ятмаган, күрәсең.

— Ә төзелештә ниме, япь-яшь кызлар да күпме?— Рәмилә, тынын кысып, көтә калды. Ул юлда килгәндә дә, җиләк җыйганда да менә болар хакында сорашмакчы булып сүз кузгатырга ниятләгән, әмма җаен китерә алмый йөдәгән иде. Инде хәзер, җае чыгып торганда, барын да ник төпченмәскә, ди?

— Күктән яугандай. Әле күптән түгел генә Воронеж техник училищесыннан ике төркем килде. Байтагының борын аслары да юньләп кипмәгән әле. Дөрес, арада кулында ут уйнатырлыклары да җитәрлек, әмма бер төрлесенә «ике дөнья, бер морҗа» дигәндәйрәк шул.

— Нишләп алай?

— Оеткылары сыек булгангадыр.— Людмила кулларын баш астына куеп, янә чалкан ятты, күзләрен йомды. Күкрәге авыр гына күтәрелеп алды.— Их, өйгә кайтып килсәң иде бер! Үлеп лә сагынам җан күбәләгемне — белсәң иде, Рамилечка!

Соңгы вакытларда ул шулай еш кына уфтангалар иде: тегендә әбкәсе тәрбиясендә калган өч яшьлек нәниен юксынуы көчәйгәннән-көчәя бара иде ахрысы.

— КамГЭСка вагоннар күпләп килә башлаган, ди, инде. Без дә язылдык язылуын. Тик тиз генә эләктереп булырмы, каһәрне? Эләктереп булса, әнкәй белән Димочканы монда алдырыр идем, ичмаса.

— Соң, хәзер үк китерегез,— диде Рәмилә.

— Кеше өстенәме, сезне борчыргамы?

— Сыяр идек әле. Ә ниме...— Рәмилә, сүзен өзеп, чак кына тыелып торды. Кызның, әлбәттә, үз хәсрәте хәсрәт иде, түзмәде, сорап куйды:— Анда, КамГЭС ахры, укыту-өйрәтү пунктлары ачкан, ди. Ничә яшьтәгеләрне алалар икән? Уналтыдан ук түгелме икән?

— Уналтыдандыр. Туктале, сеңлем.— Людмила башын калкытты, аннары торып ук утырды һәм кызның иңбашына орынды.— Син чын-чын-

лап жыенасыңмы? Борын төбендә өлгергәнлек аттестаты. Әниең ни әйтер? Әтиең тагы?

— Ни әйтсәләр дә...

Кызның тигез кара кашлары җимерелде. «Бары бер иш. Бер сүзне тукыйлар. Женя Мындага́ тикле. Сабыр ит, унынчыңны бетер, ди. Бар дөнья каршы. Ә күңел?»

Людмила Крутько, сүзнең мондыен артык тирәнәйтүдән өркеп ахры, кинәт кулларын киң иттереп җәеп җибәрде:

— Ә урман искитмәле монда! Үзе гөмбәле дәдер әле, име?

— Гөмбәле. Тик без аны тибеп кенә йөрибез. Җыя белмибез.

— Нишләп? Гөмбә танымыйсызмы әллә?

— Әйе, бездә аны җыючы бик сирәк. Безнең бабай әйтә: «Урыс кешесе гөмбәне иткә тиңли, ди. Белмәем, әгәренки, ди, гөмбә иткә тиң булса, җыен татар урманга җабырылып җатар ие», ди.

— Кызык икән!— дип, урман яңгыратып көлеп куйды Людмила. Ярар яңгырлар явып, гөмбә генә чыксын. Тозлап-маринадлап та күрсәтермен, кыздырып та ашатырмын үзегезгә — телегезне йотардай итәрмен!

Кайтыр юлларына кузгалып, каенлыкны артта калдырганнар гына иде, бер төштә, яшь наратларга табан сузылган аулак кына куенда, янә әйбәт кенә җиләклеккә тап булдылар. Рәмилә хәтта үзенең салам эшләпәсен дә тутыра язды. Әйе, өйләренә кайткач, авыз суларын китерердәй тәмле җиләкнең бер өлешен кәгазьгә төрер дә ян бакчаларының урам як почмагына яшереп куяр. Бу кичне дә Женя Мында клубка чыкмыйча калмас әле...

## 13

Әлбәттә, Рәмиләгә әнисе белән бер утырып сөйләшмичә һич ярамый иде. Һәм, әлбәттә, ибен-җаен китереп кенә.

Әллә ни озак көтәргә туры килмәде.

Бу җәйне врачларга багылып йөрүенең, ниһаять, көтелгән нәтиҗәсе булды: әнисе ахыргы баруыннан бөтенләй җилкенеп кайтты. «Сәламәтлегең инде ярыйсы ук яхшырды, хәзер җиңелрәк эшкә керешсәң дә зыян итмәс», дигәннәр. Шул хакта әйтеп, кәгазь дә тоттырганнар кулына. Әнисе, билгеле инде, кайта кайтышлый ук, совхоз кәнсәсенә сугылып, анда әлеге кәгазьне җилфердәтеп кенә күрсәткән. «Бик шәп, алайсам, дигәннәр контордагылар да, кулларың аш-суга бик оста, механизаторларга аш пешереп торырсың. Булышчыларың итеп җегәрлерәкләрне куярбыз — үзеңә авырга килмәс. Кайсыбер көнне, уптым килеп төшсәләр, КамАЗ төзүчеләрен дә өлешсез итмәссез — өстәп пешерерсез»,— дигәннәр. Җитмәсә, озакламый, тап солдатларныкы шикелле, поход кухнясына тикле кайтартачаклар, ди.

Мондый хәлләрдә күңел үсмиме соң?

Әнисе, кәефе ал да гөл булып йөргән көнне, олы мичне ягып, камыр ашыннан ни дә булса пешермичә калмый.

Бүген ит бәлеше салырга уйлаган, ә бәлешкә хәтле янып торган мич кызуында, төчегә изеп кенә, коймак чыжлатырга тотынды. Аның шунысы да бар бит әле: ризык пешергәндә, аның тәмен-бәрәкәтен җибәрергә теләмәсәң, һичнинди ызгыш-талаш куптарырга ярамый, ди. Бусы инде Рәмилә өчен алдан ук майлап куйгандай ич: димәк ки, әнисе аңа дуамал кубып ябырылмаячак...

Рәмилә сүзне ерактанрак, уратыбрак һәм чуалтыбрак башлады: иң әүвәл күрше авыл Гәрдәледән бер-ике кызны телгә алды, аннары үз авылларыннан бер иптәшен чаялыгы һәм кыюлыгы өчен мактагандай итте, тик шуннан соң гына үзе мәен-теләген сиздерде.

— Чү, акылыңнан җаздыңмы әллә? Ниткән Чаллы ди сиңа!— диде әнисе, капыл кабынып.

— Ә мин нием белән ким?

— Туктале, кызый. Соң син әле кайчан гына: «Унны бетерәм дә врач булырга китәм», дип авыз суларыңны корытып йөргән иең. Ак халатлар киеп, үз кулларың белән мине — әнәеңне дәваламакчы иең.

— Ә син сәламәтләнден бит инде. Белешмәңне тиккә бирделәрме әллә? Аннары, былтыр әнә Рәмзи абый барып караган иде бит, күрә алдымы бик? Һавадагы төтен генә бит әле ул безнең ишеләргә институтка барып керүләре.

— Синең башыңда төтен! Имештер, авылдан бер-ике укытучы гына чыккан да сыңар агроном. Ә ул, имеш, иң беренче врач булып кайтасы. И чәтнәби!

Рәмилә бәлешкә вак-вак иттереп бәрәңге турап утырган җирендә борын мышкылдатты, әнисенә таба өтәрдәй усал караш ташлап куйгалады. Әнисе мич кызуында таба-табагачлары белән шалтыр-шолтыр итә, коймак чыжлата, үзе тавышын да чыж-пыж чыгара.

— Кемнәр генә котыртты соң сине? Мила апаңмы?

— Нишләп? Котыртырга мин әллә...

— Теге кемең... Женя Мындамы? Молдаван «мыегы»мы?

Кыз үткен пәке белән баш бармагын чак кына кисеп җибәрмәде.

— Син, әни, бигрәк инде.

— Бик сизәм мин! Үзенең кемлеген җүнләп белгән җук, ә син инде ул шәп мыек белән... Чамала, кызый!

— Тай типмәгән әле.

— Типкән шул!— Әнисенең кызарган йөзендә ялкын шәүләсе биешә, күзләрендә дә хәтәр очкыннар уйный иде.— Атасы-анасы кемдер, үзе тагын... Тыштан гына җалтыравы түгелме икән әле ул тәти җегетнең?

— Белмәгән килеш бәйләнмә кешегә! Әтисе дә, әнисе дә эшче, ди. Үзе училище бетергән. Аннары Кишиневның медприборлар заводында эшли башлаган. Һөнәр иясе, бик беләсең килсә! Кул осталыгын үзегез күрдегез ич. Сокланыплар туя алмадыгыз!

— Әһә, чынлап та әнә кем исәрләндергән икән лә синең башкаеңны!— Әнисе табагачын шалт иттереп идәнгә терәде.— Ичмаса, унынчыңны бетереп бетерсәң ие, тилекәй!

— Аны эшләгән көйгә дә бик бетереп була,— диде Рәмилә, суган әрчергә керешеп.— Анда, пажалысты гына, ди, әнә.

— Адәм кыяфәтен җуйган җыен сакаллы албасты арасынамы? Шушы җәшеңдәме?

— Миңа октябрьдә унҗиде тула инде. Ә ник бүтәннәр, синең күк, өркеп ятмый? Мәлифә түтиләр, Фәйзрахман абыйлар? Аларның кызлары бик иплe генә китеп барды бит.

— Ипле сиңа! Ни белән бетәсен белгән җук әле. Бер дә бер көнне кайтып керер иең бугай итәгеңә бәби кыстырып.

— Кермәбез. Ә син үзең соң? Унҗидедә... Ә мин кияүгә чыгарга уйламыйм да әле.

— Ышандырдың бик!

— Алай туарылырга кем нәселе соң мин? И әнкәй!

— Булды, житте, дим! — Әнисе табагачын янә идәнгә шакылдатты.— «Ата кәҗәләнмә» зинһар!

Рәмилә иренен чәйнәде. Управляющий Гарәфша авызыннан чыккан бу алама сүз, һәйбәт тиресле туфракка төшеп, инде тамыр җибәреп өлгергән, ләкин, Рәмиләнең бәхетенә, аны очыргаланып йөргән кыска итәкле бүтән кыз-кыркынга да әйткәлиләр икән авылда. Рәмиләнең күз төбенә бөрчек-бөрчек яшь бәреп чыкты, бераздан ул яшьләр аның янып кызарган бите буйлап түбән таба тәгәрәделәр. Суган әчесеннән генә булдымы икән?

— Кәҗәләнсәм соң?

— Әтиеңә әйтеп, арт сабагыңны бик әйбәтләп укыттырырмын әле менә!

— Укыттырсаң соң?

— Життеме-жукмы, дим! Күр, синең аркаңда монда... ах, аллам, бер таба коймагым каралып ла көйгән!

Бер таба коймак ни әле ул?

Сәерргә, бөтенләй хикмәтлесе соңрак беленде. Бәлешенең йөзе дә һәйбәт килгән, исе дә бик тәмле таралган иде, әмма табынга куеп, тәмләп карасалар, күзләре шакмакланды: аңа бер бөртек тә тоз салынмаган икән ләбаса! Әтисе хәтта токан кашыгын читкә атып бәрде. Шулай булмый ни...

## 14

Дөнья тып-тын. Тик ара-тирә бик югарыдан, йолдызлар астыннан самолет кына гүелдәп үткәли.

Төн әллә ни караңгы түгел. Их, ул чак кына, ичмаса, караңгырак булсачы!

Рәмилә көтә. Берәүнең ян бакчага кереп ян тәрәзәне чиртүен көтә.

Гәүдәсендә дерелдәү. Килерме икән, юкмы икән?

Бүген күрә алмады: егетләр әле кайтып төшмәгән иде. Ә кичә бабасы Туры картка көянтә-чиләге белән «шифалы су» илткән җирендә, капка төбендә бер-ике сүз алыштылар үзе. Женя Мында аңа: «Чыгармасалар, килеп чиртермен», диде. Әллә Чаллыларыннан бөтенләй кайтмый калдылар микән? Анысы да булгалый бит.

Юк, кайткандыр, килердер.

Менә атнадан артык инде чыгармыйлар. Әнисенең сүзе каты, әмере бер: «Җөрмә авылда күз көеге булып!» — ди. Әтисе дә трактор маенда каралган юантык бармагын өстәл читенә куеп: «Ыштубы!» — диде. Абыйлары барында рәхәт иде: аларга ияргәндәй генә йөрер иде. Мила апасы да Рәмиләне кызгана шикелле. Ләкин ни эшли ала соң ул мөлаем карашлы яшь хатын? Җилкә тарткалаудан уздыра алмый — чит гаиләгә катышырга хакы юк.

Житмәсә, әнисе сүзнең әллә нindиләрен ишетеп тора. Кайсы ләчтит сатучысы ташып өлгерә икән? Имештер, Чуар белән Калмашта да шәп кенә тәпәләшүләр булгалаган, ди, имештер, «җыенысы шул пумалабаш, шәрә сыйраклар аркасында гына» ди. Ә бер көнне тагы юлда кайткан-да Әҗергә житеп килгәндә генә мондагы сакалбайлар да сакал йолкышкан, ди. Тагы әллә ниләрне чәйниләр. Әйтерсең, элгәрерәк, авылларын КамАЗ явы басканчы, егетләр арасында тәпәләшүләр булмаган да якалашулар ишетелмәгән. Егет-җилкенчәк булсын да сөзешмичә, йон коймыйча гына йөрсен ди сиңа. Чамасыз күпертеп, яман каралтып сөйләүләрен әйт син тагы!

Чигә тамырлары даң-доң тибә дә тибә. Гәүдәсендә вакыт-вакыт кузгалгалаган калтырауны да бер ничек тә баса алмый. Гыйшык утында янулар шушылай буладыр ахры.

Караңгы күктә йолдызлар җем-җем күз йомгалый.

Болында печән җыюлары рәхәт үзе. Ни алҗымасыннар, ни сусамасыннар — барыбер рәхәт! Онытылырга да җай. Анда уен-көлке дә ташып тора, сүзнең дә төрлесен ишетәсең. Өлкәнрәкләрнең телендә һаман бер нәрсә: «И хәзерге болынның җәме җәммени? Менә ул без җәшрәк чакларда! Их, кайтмас инде ул заманнар!» имеш. Ә өлкәннәрнең дә өлкәнрәк исә шыңгырдавы гына белә: «Трактор белән кырыкканга чабыннарның хәтере калыр, ди. Чалгы белән җалап алуларга ни житә инде! Торабара такырая тугайларыбыз», ди. Рәмилә мондый гәпләргә катышмый, күп нәрсәне белми дә аңламый да — күп нәрсә канына сеңми калган. Аның хәтта шалашта кунып ятуларның да рәхәтен татып караганы юк. Искитмәле, имеш! Ләкин шулай да болынга барулары, болыннан кайтулары чиксез күңелле. Иртән машиналарга чикы-чакы төялешеп китәләр, кичен төялешеп кайталар. Моның да иләсләндергеч үз яме бар ич!

Бүген болыннан, андагы бар булган печәнне җыеп бетереп, җилләр

җиләтеп кайткан чагында, әллә гәүдәсе, әллә җаны өшеп-өшеп куйгалады: кичен янә күрешә алырлармы, җае чыгармы? Аннары күкрәге эчендә нидер сулык-сулык итәргә тотынды: алдагы көннәре ничек булыр, кайларга җитеп терәлер?

Теге чакны җир җиләге җыеп кайткан көннең җылы һәм тыныч кичендә, тыкрыкны байтак буйлап йөрделәр алар. Иркендә азаккы йөрүләре булган икән. Бермәлне, тәмле җиләге бетеп килгәндә, Женя Мында, аның иңбашларыннан кысып алды да кайнар сулышы белән өтә язып: «Инде хәзер җиләктән дә тәмлерәгенә... я инде, я, дим, кара карлыгачым...» дип пышылдауга күчте. Рәмилә шул чакны капыл сыгылып төште, башын читкә борды. Бүген килеп тәрәзәне чиртсәме! Бүген Рәмилә йөзен читкә бормас та әле, бәлкем.

Әнисе белән әтисе алгы бүлмәдә йоклый. Әнисенең йокысы бик тә сак, уяу — чак кына шылт иткәнеңне дә сизә. Шул сәбәпле Рәмилә әле көндездән үк, ачканда шыгырдамасын өчен, тәрәзә рамнарының тимерләренә май тамызгалаган иде, гөл чүлмәкләрен дә кая, ничек күчерәсен чамалап куйган иде.

Ябынган юрганы калынрак булды ахры, тәне эсселәп бетте. Күз кабаклары авырайганнан-авырая бара.

Әнә инде ян бакчада, балан төбендә микән, сайрар чикерткә, таң алдының якынлашуын сизептер, сызгыруын көчәйтә төште. Югарыдан, йолдызлар астыннан ук, янә бер самолет гүелдәп үтте. Ни дип гүелди икән ул? «Җебемә! Канатларың шәлберәймәсен, кызый!» — дипме?

Килмәде, чиртмәде егет ян тәрәзәне.

Иртән торып, болдырга чыгып басса, көн янә чалт аяз: җылыдыр, кояшлыдыр. Рәмиләнең берара хәтта күзләре камашып торды.

Ишегалдында әрле-бирле йөргән арада, капкадан әнисе кайтып керде. Кулында озын чыбык. Каз куып кайтышы. Чыбыкны койма буена ыргытты да, түргәрәк үтеп, аяк астында чыр-чу килгән тавык-чебигә җим сибәргә кереште. Әлегә ләм-мим сүз катмады. Ләкин ул кызы Рәмиләнең юынгыч яныннан читләшүен генә көткән икән. Кыз бауда эленеп торган сөлгегә үрелгән генә иде, әнисе, бер дә ис китәрерлек нәрсә булмаган шикелле иттереп, тыныч кына әйтә куйды:

— Кичәгенәк Женя Мынданны да дөмбәсләп ташлаганнар, ди, әнә.

Рәмилә куырылды да калды, хәтта кулындагы сөлгесе җиргә төшеп китте:

— Кемнәр? Кайда? Ни өчен?

— Мин каян белим? Тыкрыкта бугай. Иснәнеп җөрүе булгандыр. Авылда бер син генәмени пумалабаш! — Бусы инде Рәмиләнең бәгыренә туп-турылай хәнҗәр кадаган сыманрак яңгырады. — Җөрмәс үзе дә! Чит авылга килеп, койрык кысып кына утырасы урында... шәп мыек җибәрдем дигәч тә...

— Кемнәр икән, дим!

— Беткәнмени авылда сугыш чукмарлары! — диде әнисе. Аннары, бушап калган коштабагын әйләндереп, кулы белән аның төбенә шап-шоп суккалады. — Мынданның күз төбе бөтенләй күгәреп чыккан, ди, җодрык тикле, ди. Сугышканнарын үзебезнең Сабир күреп торган. Миңа әткәй әйтте.

Кызның күз алдында кояшлы көн капыл сүрелде. Ничекләй сорашырга инде? Әлбәттә, Туры бабасының күзенә күренү ярамас. Сабир, Сабир... Өендәме икән, әллә тырай тибүдәме? Кайда булса да, әнисе монда тау-тау эш өйгәнче, чыгып сызуың яхшы.

— Туктале, кызым, син кая болай? — дип эндәште әнисе капка тимере шылтырауга. — Җөрмә! Вахта машиналары әллә кайчан китеп барды инде аларның.

— Нишләп? Мин ни, бүген ял бит: берәрсе җиләккә бармас микән дип белешеп кайтмакчы идем. Син бигрәк!

Күршеләрендәге бер кызчыкны Туры бабаларына кертеп чыгарды.

Ләкин Сабир әллә кайчан таярга өлгергән икән инде, келәт алдында, иске бишмәткә башын куеп. Туры бабай гына ятып тора, ди. Яшелчәчелектә кыяр өлгереп килгән вакыт. Сабир, әлбәттә, шул тирәдә буталып йөри торгандыр. Кайчакны көпә-көндез, әмма каравылчы абыйи чәй эчеп, аның ләззәтеннән изрәп киткән мәлдә, кыяр җиренә кереп чыгуы уңайрак икәнен Рәмилә бик белә — үзенең дә элеккерәк елларда бакча басканы бер генә булмады.

Дөрестән дә, Сабир өч-дүрт малай белән шул тирәдәге чокырларның берсендә үләнгә төтен җибәреп ятуда иде. Бүтән чак булса, Рәмилә, әлбәттә, аларның кесәләрен актарып, пыран-заран туздырып ташлар, хәтта «чуерташ» энекәшенең ялган чокырына да бер-икене кундырмый калмас иде. Әмма бүген алай итмәде, елтыр күзле «чуерташ»ны читкә дәшеп алды. Сабир алма апасының ник килүен бер сулыштан ук аңлап, ялындыруны бу юлы ничектер бөтенләй кирәксенмичә, төкрекләрен чәчә дә башлады:

— Соң, ничек дип, киттек без әнә Зөлфәт белән Мында абый артыннан качып-посып кына. Нигәме? Соң, кичләрен үзең күренмәгәч, кайсы нечкәбиләнә ияләшергә чамалый икән бу дип. Шуннан, Мында абый сизнең тыкрыкка борылган гына иде, бер заман ике шәүлә әллә каян килеп чыкмасынмы! И тотындылар, мин сиңа әйтим, бәйләнергә: «Оныттырырбыз без сиңа бу тыкрыкларны!» — дип.

— Кемнәр, дим? Ник әйтмисең?

— Һе, белми, имеш! Соң, авылның Игәч башыннан Әмир инде, тагын аларның кунак егете. Шуннанмы? Шуннан Мында абыйның ачуын чыгарма икән. Әмир абыйга менә болай иттереп берне тамызып торып җиббәргән иде, теге киртә артына ук очып барып төште. Аннары кунак егетен. Бусын читән буендагы кычыткан эченә сеңдерде! Вәйт ул самбо көрәшен белсәң, ничек икән! Тегеләр әпен-тәпен тайдылар тизрәк! Билләһи, үзем дә өйрәнәм әле ул самбога! Мында абыйның ирене канап чыккан иде чыгуын, аннары күз төбендә фонарь. И шулай да, ипидер, чәнчелдерде генә үзләрен!

Рәмилә кичә төн ката йолдыз санап, көтеп ятты, ахырда, үпкәсен басарга теләп, юрган читен чәйнәргә тотынды, ә ул — аның сөйгәне — аларның тыкрык башында, бактың исә, әнә нигә юлыккан икән бит! Сабир бытбылдыкның сүзе моның белән генә бетмәгән икән әле, менә ул, башын түбән иеп, шыңшынып куйды:

— Ә бүген иртән бабай Мында абыйга дапрус ясады.

— Нишләп, анысы ни тагы?

— Соң, мин өйгә кайткач, барын да бабайга текмә-тек сөйләп биргән идем, аңышмыйча. Ә ничек сөйләмисең, ди?— Сабир башын күтәрә төште, күз аклары елтырап китте.— Икәвесен берьюлы әнә шулай әпен-чәпен туздырып ташласын да сиңа!

— Ишкәнсең икән, иләк авыз!— Бу минутта Рәмилә үзе дә малайның җилкә тамырына берне кундырмыйча чак кына тыелып калды.— Нинди «дапрус», дим?

— Соң ни... Иртән теге абый эшкә барырга дип капкадан чыгып китүгә бабай Мында абыйны тоткарлап калды. Имеш, йомышы бар. Келәткә керергә чакырды. Шунда, Мында абый келәткә атлап кергән генә иде, бабай ишекне шалт иттереп бикләде дә куйды. Аннары ябышты инде...

— Нәрсә дип?

— Нәрсә дип, нәрсә дип... Бабай әйтә: «Син чынлап җөрисеңме, уйнап кынамы?» ди. «Менә хәзер көне буе җат инде уйлап!»— ди. Мында абый башта көлде генә: «Яшьләр эшенә, зинһар, кысылма, бабай!» ди. Ә бабай үзенекен тукый: «Уйнап кына булса, бел, ди, безнең кызның бер бөртек чәче генә коелсын, ди, аяк-кулларыңны ботарлап, кояшлы Молдавиңә олактырмагаек»,— ди. Ярты сәгать лә асрагандыр бик астында! Ахырда, Мында абый ишекне дөбердәтә башлады: «Прагул ясаттырсаң, өстеңнән яздыртам, чамала!»— дип. Аннары инде бабай ачты

ишекне: «Бәхетеңә, сәвитский карт без, ату...»— дип. Мында абый көчкә-көчкә генә вахта машинасына өлгергән бугай.

— Күр син карт гыйфритне!

— Аннары мин Мында абыйны яклап ябышкан идем, бабай минем колакны борды: «Тыкшынма, башың җәш!»— дип. Шундый да авырттырды — өзелеп чыга дип торам. Ярар, үзен дә буш итмәм әле: пинжәк кесәсенә гөберле бака тотып салам әле мин аның, билләһи дим! Үзенә дә тыкшынмаска акыл булыр, име, апа?

Рәмилә, яулык очын авызына капкан көенчә, инеш ягы буйлап атлады.

Ул Әмир бичарага ни калган инде? Авыз тутырып сүзен әйтә алмый югыйсә. Рәмилә аңа ничәмә тапкырлар кырт кискән иде бит инде. Каян килгән кыюлык, каян килгән гайрәт диген ул җебегәнгә?! Училищесына үч алып шылмакчы булды микәнни? Ә Туры бабасы? Шул хәтле үк кыланмаса соң! Әйтерсең, үзенең яшь чагы бөтенләй булмаган да...

Көн саен көянтә-чиләкләп колонка суы илтә үзенә. Бүген шулай итсә, Рәмиләгә дә «дапрус» ясамас микән? Бер үк вакытта илтмичә дә ярамый.

Әлбәттә, Рәмилә кичке уңайда зифа буен сыгылдыра-бөгелдерә ике тыкрыкны бердән буйлап узды. Бабасы ишегалдында иде, «кһым» дип тамак кына кырды. Ләкин кыз, өйалдындагы эмаль чапчакка суны бушатып, мыштым гына чыгып барган чагында, бабасы аның көянтәсеннән эләктереп алды.

— Эһем... ни, кызым. Моңа чаклы китергән суларыңда, ипидер, бал тамнәре бар ие. Рәхмәт инде! Әмма ләкин бүген иртән, аннан кире төш турында, самавыр эченә ачуташ салгандай, китергән суың тамагымны бик тә җандырып, бик тә әчеттереп үтте. Болай булса, кое суына күчмәгәемнәр...

Әнә шулай гадәтенчә кыек әйтеп туры бәрде Туры карт. Рәмилә ык-мык итеп калды:

— Соң... соң...

— Иҗле җөре!

Тыкрыкта йомшак чирәм арасыннан сузылган сукмакка утлы күмер сибеп чыкканнар идемени — аяк табаннарына тикле пеште кызның.

## 15

Бу көнне, бу сәгатьләрне зарыгып көтте Рәмзи.

Ике ел буена көтте...

Инде менә авыр һәм киеренке солдат тормышы артта, бик ерактагы Кавказ итәкләрендә торып калды.

Туган ягы белән күрешкән чагында, егет дулкынланмый калмаячагын бик белә, бик абайлаган иде. Ләкин Чаллы туфрагына аяк баскач, күңеле бу тикле үк чайпаланыр дип һич уйламаган иде.

«Камгэсэнергострой» идарәсенең кадрлар бүлеге әллә ничәү икән. Биш катлы таш йортның үзендә дә бар икән, аның аргы башындагы бушлыкта бер-берсенә сыенышып, тыгызланып утырган яшел һәм зәңгәр вагоннарга да сибелеп беткән икән.

Ләкин иң башта кайсына сугылырга, кем белән киңәш-табыш итешергә соң?

— Эһе, путевкасыз гына, димсең? Алайса, син, солдаткай, комсомол штабына керсәң, хәерлерәк булыр. Иң әүвәл биш катлы таш йортка!— диделәр аңа яшел вагоннарның берсендә.

Керде, чиратка басты.

Коридор тар, кысан, бөркү. Әрле-бирле йөреш, гөж-тавыш. Кайберәүләр документларын барлый, икенчеләре бердәнбер өстәл кырыена кысылышып яки тәрәзә төбенә китеп, анкета тутырып азаплана.

Рәмзинең үз ишләре — фуражкалы, яшел киемле егетләр дә аз түгел. Тик иңнәрендәге погоннар, күкрәкләрендәге значоклар гына төрле-

дән төрле. Матрослар да күренгәли. Бүтән халык исә бөтенләй чуар. Ләкин күбесе — аның тиңнәре, яшьләр.

Чират бик акрын бара. Стеналарга төрле игъланнар эленгән. Төзелеш алдынгыларына багышлап чыгарылган плакат-листовкалар тагы. Чү, шул кызыл каймалы матур листовкаларның берсендә аның абыйсы Айдаш түгелме соң? Нәкъ үзе! «Айдаш Хәнәфиевич Бариев» дип кычкырып тора симез хәрефләр! Аның үз бульдозерында кайда, ничек эшләве хакында кыска, әмма бик тә җылы һәм матур итеп әйтелгән.

«Вәт, абый, ничек очраштык, ә?!»

Сурәте болай матур гына: тужурка якасын җилбәгәй салган да, чак кына көлемсерн төшеп, туп-туры болай таба караган. Күзләрендә мөлаем нур, үз итеп, якын итеп карау. «Исән-сау кайтып җиттеңме, энекәш! Әйдә, тәкле аякларың белән!»— ди сыман абыйсы.

Ә иң аста эре кызыл хәрефләр ут булып яна:

«КамАЗ төзелеше ударнигына дан!»

«Дан-дан!»— монысы Рәмзи энекәшенең күңеленә даң-доң кыңгырау сукканДай булып үтеп керде дә анда бер мизгелдә өермә куптарды. Юк, чиратта бүтән тора алмады. Сулышы капканлыгын тойган хәлдә, урамга саф һавага чыкты.

Инде шактый күтәрелеп өлгергән кояш иләмсез кыздыруын белә. Аяк астындагы асфальтка тикле йомшара төшкән шикелле.

«Чулпан» кинотеатрының галәмәт зур тәрәзәләрендә фотовитраж. Төзелеш панорамасы. Солдат аны сокланулы күз карашы белән бердән иңләп чыкты. Ләкин кинәт көлемсерәп куйды: «Соң ул моны чынлыкта, тормышның үзендә күрергә, барын да айкап-гизеп чыгарга тиеш иң. Аннары инде үзенә дә шул заводларның берсендә җиң сызганасы булыр...»

Гидротөзүчеләр урамы шактый ук чибәрләнеп киткән. Урамның ян-якларында тротуар буйлата ямь-яшел газоннар сузылган, пөхтәдер, чиста-дыр үзе.

Солдатка кинәт бик җиңел булып китте. Аяк астындагы җирне гоймыйча диярлек, бер кулында көрәнсу чемоданын селкә-селкә, урам белән түбәнгә Муса Җәлил проспектына таба җил-җил атлады. Ләкин бишәр катлы игезәк таш йортлар турысына җитәрәк, адымын әкренәйтә төште. Тегендә ике таш йорт арасындагы скверга аның ишләре — яшел киемлеләрдән тагын бер төркем килеп төшкән, җитмәсә, чуар киемле кызлар да күбәеп киткән сыман, тегеләре боларын, бал кәрәзенә сарылган умарта кортлары шикелле, сарып алган да гөр килеләр. Иркендә бер рәхәтләнеп, сүз-гәп куертуларны тансыкламас димени солдат!

«Юк, комсомол штабы да, кадрлар бүлеге дә качмас әле. Иң башта туганнар белән күрешмичә, барын да уртага куеп киңәш-табыш итмичә ярамас. Ике абый завод коруда — алар кайда ничек икәнен белми йөрмәс».

* * *

Солдат кайта!

Иминлек сагын Кавказ төбәгендә калдырып, иңнәреннән җир шарын төшергәндәй рәвештә бөтенләй бушап-җиңеләеп кайтып килә.

Каршысына тигез асфальт юл чаба. Колак төбендә җил сызгыра. Юлда машиналар, машиналар — выж да выж! КамАЗ биләмәләре!

Иңбашларына канатлар үсеп чыкканлыгын тоя сыман солдат.

Моннан берничә еллар элегрәк аның Айдаш белән Вәсим абыйсы да шулай канатланып кайтып килгәндер. Хәер, алар икесе дә Минзәлә юлы чатыннан җәяүләгәннәр шикелле. Рәмзи бик хәтерли: өлкән абыйсы кичен күз бәйләнгәч бусагадан атлап кергән иде, аның өсте-башы ап-ак кар иде, ә Вәсим абыйсы исә язгы чәчү бетәр-бетмәстә әче таң белән өй тәрәзәләрен чирткән иде.

Ә ул менә җәй чилләсендә көпә-көндез кайтып килә.

Бик күп еллар әүвәл аның әтисе Хәнәфи дә шушылай җәй уртасында кайтып килгән бит. Аңа да ул чагында нәкъ егерме яшь булган! Ләкин ул Чаллының үзеннән үк җәяүләгән. Әйе, туп-турылай басу сукмагы белән атлаган. Аякларында кирза итекләр, башында төсе уңган пилотка, аркасында солдат биштәре.

Ярты Европаны азат итеп кайтышы.

Хәзер дөньялар бүтән. Солдат булып йөргән ир-егетнең туган якларын сагынуы, сөйгәнен юксынуы, кайткан чагында иңнәренә канатлар үсүен тоюлары гына бер төследер. Хәер, бөтенләй үк бер төсле микән?

«МАЗ» кабинасында алар икәү.

Орловка авылы очындагы юл божрасын дугайлап үтүләренә, Кама тарафларында еракка сузылган сөзәк үр кашында биек ак йортлар калкынды. Ак шәһәр. Ул җирдә түгел дә сыман — сыек рәшә эчендә күктә йөзә кебек. Ә каршы тарафта исә җирдән шактый күтәрелергә өлгергән ТЭЦ торбасы күренде, сул кулдарак яшеллеген җуйган һәм көрәнсу-кучкылланып торган бик тә калын урман абайланды. Юк-юк, болары туып килгән завод корпуслары лабаса!

Солдат тынын кысты.

ТЭЦ торбасы йомшак һәм мул яңгырдан соң капыл күтәрелгән таза саплы гөмбә шикелләрәк. Рәмзи әлегә берни белми, әмма соңыннан чамалар: «гөмбә» эшләпәсе күзгә күренми генә күтәрелә торыр — торба аның саен үсә, күтәрелә барыр.

Шофер-сакалбай газны киметә төшеп, сыңар кулы белән генә сигаретына ут алды:

— Ике йөз дә илле метрга күтәреләсе, ди. Монысын бетерсәләр, янәшәдә тагын бер торба буласы.

— Әһе,— диде солдат.

ТЭЦ торбасы дәвәеп-сузаеп ярыйсы ук якынлашкач, шофер машинаны капыл гына туктатты да:

— Миңа моннан уңга, стройбазага чаптырасы, ә сиңа, туганкай, тегеләйгә китәсе. РИЗ[1] әнә генә,— диде.

— Аңладым. Бик рәхмәт сиңа, дус кеше!

Юлның РИЗ божрасын әйләнеп үтүенә, «берәрсенә янә кул күтәреп иплe генә утырып китәрмен дә бик җәт кайтып җитәрмен болай булгач», дип куанган иде солдат. Ләкин кая ул! РИЗ янында шактыйга тоткарланмыйча һич булдыра алмады.

Чын-чынлап хәйран-тамаша икән лә аның туган як кырларында!

Ул киткән язда монда куәтле экскаваторлар зур чокырны казырга керешкән генә иде әле. Ә сузылып киткән бетон юлның дамбасын өяргә дә тотынмаганнар иде. Нибары әйләнә-тирәнең кара туфрагын гына дөнья җимертеп каезларга ябышканнар иде.

Ә хәзер... Актарылып-чокырланып яткан җир күкрәгеннән, син күр дә мин күр, бөтен завод калкынып чыккан лабаса! Иңлеге дә шактый гына, биеклеге дә шәп, озынлыгы да хәтсез. Инде зәңгәрсу-аксыл панель киемнәрен киенеп, түбәсенә көрәнсу-яшькелт шәлъяулыгын да бөркәнеп алырга өлгергән. Көн яктысына коләчләнеп, күз явын алырдай нурлар сибеп карый!

Солдат тирән-тирән сулап куйгалады һәм сулышы белән бергә, каядыр күкрәк төбеннән, ничектер үзеннән-үзе соклану һәм дәртсену авазы бәреп чыкты:

— Хәлләр диген!

Түзмәде, дамба кашыннан түбәнгә төште дә заводның иләмсез зур ишегеннән атлап керде. Юк, әллә ни айкалып-буталып йөрмәде — завод эчен алай тиз генә айкап чыгарлык та түгел икән — күзләрен киң ачып бер тирәдән генә әйләнде. Аңа беркем борылып карамады, сүз катмады — һәркем үз эшенә чумган, завод эчендәгеләр, гомумән, мәш килә

[1] РИЗ — ремонт-инструментлар заводы.

иде. Әллә ничә төрле, әллә ни хәтле машина-механизмнар! Беришесе туфрак тигезли яисә җир тыгызлый, икенчеләре чокыр казый яисә бетон җәя. Аргы очтарак тип-тигез шомартылган бетон җирлеккә инде үйдык-үйдык тимер плитәләр тезеп яки агач шакмаклардан идән түшәп киләләр. Ә һавасында зәп-зәңгәр сөрем — аның моңарчы һичкайда да тоймаган ачы исе борыннарны яра, житмәсә, һава үзе дә әледән-әле дерелдәп, селкенеп китә: дан да доң, дөмберт тә дөмберт!

Кабалану сизелми, әмма бик тә ашыгалар, кырамсен.

Солдатның күкрәгеннән янә ирекле-ирексездән сәер генә аваз сытылып чыкты:

— Монда инде бетереп тә яталар ич!

Кире дамба кашына күтәрелгәч, фуражкасын баш түбәсенә үк чөеп, әйләнә-тирәгә янә күз йөртеп чыкты.

Әйе, Рәмзинеке әнә анда тоташтан ялангач урман-чытырмандай күренгән көрәнсу-кучкыл корпусларның берсе булыр. Тик аңарчы барын да бер йөреп чыкмыйча, ибен-юнен капшап карамыйча һич ярамас. Җәяүләп, тәпиләп!

РИЗ бинасына күз төшергәч Рәмзи тагын да шаккатты: аның түбәсендә чотыр да чатыр мотороллерлар чабыша иде. Һәммәсе дә әрҗәле мотороллер! Түбә ябучыларга тегесен-бусын китереп, ташып йөрүләре икән. Атланып алган кешеләре дә әллә кемнәр түгел, япь-яшь кенә кызлар! Хәвеф-мазар дигәнен дә исләре китмичә, җифырт-мифырт тегәләйгә дә, болайга да элдертәләр генә. Һавада тик ала-кола яулыклары җилферди дә кайсыберенең чәче тузгый. Менә сиңа шәрә сыйраклы нәзкәй билләр!

Чаллыда кадрлар идарәсе урнашкан биш катлы йорт тирәсендә буталып йөргән чагында Рәмзи-солдат чырык-чарык көлешүдән бушый алмаган кыз-кыркынга сәерсенебрәк, хәтта шикләнебрәк тә күз аткалаган иде. Аларның беришесе, әлбәттә, сынауларга түзә алмыйдыр, чәчеләдер, сибеләдер, әмма, бактың исә, аларның завод түбәләрендә шушылай тыз-быз чабып-очып йөрүчеләре дә шул ук чибәрләр арасыннан килеп чыга бит!

Рәмзи күзләрен йомды һәм шул минутта, томан эченнән калкынып чыккандай, күз алдына сөйгәне Язилә килеп басты. Әйе, өзелеп сөйгәне. Кыйгач кашларын югары чөйгән дә кара күзләрен зур ачып, шикләнү, хәтта куркыну аша карый кебек. РИЗ түбәсендәге житез, кыю кызлар шикелле эш җимертә алыр иде микән ул? Әллә, чыдый алмыйча, ятьрәк койрыкны сыртка салып, читкә элдертү ягын карар иде микән?

«Их, Язилә, Язилә, ник суындың, нигә дип араны өзең син? Иң кирәк чагында...»

Солдатның кул күтәрүенә беренче килеп чыккан КрАЗ ук, авыр пошкырып һәм, юлда тузан болыты куптарып, капыл гына тукталды.

Кабина ишеген ачып, күтәрмәсенә менеп баскач та, Рәмзи РИЗ түбәсенә тагын бер тапкыр күз төшермичә булдыра алмады: бар да иплеме анда, хәлләре ал да гөлме, янәсе, солдат егет саулык, хәвефсезлек тели сезгә, күбәләккәйләр!

Менә инде каршысына туп-туры һәм тип-тигез бетон юл тагын чаба. Туган авылын якынайта ул Рәмзигә.

## 16

Менә инде җәяүләп атлый.

Менә инде Шилнә инеше дә, аның аша салынган яртылаш җимерек иске күпер дә артта калды.

Тыкрык. Балачагында яланаякларын аз чебиләндермәде бит ул монда. Үз сукмагы! Кырыйларында чирәм әле дә куе.

Читән асларындагы кычытканлыкта бүген дә чикерткәләр сайрый. Ә бакчаларында, күр инде, бәрәңгенең яфрак-сабаклары, дымга тилме-

реп, шәлпәрәеп калган. Шомырт белән карама ябалдашларында да...

Бәрәңге бакчасының, шомырт агачының әчкелтем-татлы исе — сагынылган, тансык ис!— егет күңелен, тирәннән айкап, кытыклап алды. Дөнья тып-тын. Һава әлсерәткеч кызу.

Менә инде ас тыкрыкны да үтте. Менә хәзер Түбән урамга кереп борылса, үз тыкрыклары китә.

Таныш өйләр, каралты-куралар, коймалар. Сагындырган тынлык. Зарыктырган туган авылы һавасы.

Чиксез куанычыннан, дәртле ашкынуыннан солдат күкрәгендә илаһи бер дулкын купты, егет хәтта сулышы капканлыгын аермачык тойды. Ләкин адымнары нык, адымнары саллы.

Үз тыкрыгы. Ләкин шуңа борылып китәм дигәндә генә, чаттагы бәләкәй генә өйнең сыңар капкасы кинәт кенә ачылып та китте һәм аның ачылып китү уңаена кемдер бер чүмеч салкын суны солдат өстенә тондырып та җибәрде.

— Син нәрсә?! Син...

Солдат кулъяулыгын чыгарып, битен-муенын сөрткәләгән арада, су сипкән адәм ак чүмече белән бот шапелдәтергә тотынды:

— Һай аллам, син икәнсең бит! Үзебезнең күрше генәсе икән бит! Исән-имин кайтуларыңмы?

— Әйбәт. Ә син, җиңгәчәй, шәп каршылыйсың мине, ә?— диде солдат, авызын үпкәчел кыйшайтып.

— Соң, ни бит, җаңгыр җаумый бит. Син ни инде, зинһар... Үзем тилемсә... Бактың исә, үзебезнең солдат-тансыгыбыз икән лә!..

— Ярый-ярый, җиңгәчәй, зыяны юк.— Солдат кагынды-сугынды да кинәт көлеп куйды:— Югыйсә, кайта-кайта әлсерәп беткән идем. Аның суы да үзебезнеке бит, җиңгәчәй, име!

— Әйтмә инде! Ә сезнекеләр ни бит әле, өйдә җуклардыр.— Күрше хатын шул чагында, исенә килеп, оек керешенә кыстырылган күлмәк итәген капыл төшереп җибәрде, башындагы алсу чәчкәле яшел яулыгын төзәткәндәй иттерде.— Капка тоткагызга да таяк кыстырылган.

— Кайда икән алар?

— Соң, кайда булсын, эштә инде. Әниең җәшелчәчелектә аш-су пешерүдә, әтәең басудадыр. Анда бит ни, басуга су сиптермәкче булып җәфа чигәләр. Туктале, тукта, әнкәеңнең солдат улкае кайтып җатсын да монда...— Җиңгәчәй кулындагы ак чүмечне, җәһәт селтәнеп, ачык капкадан ихатасына ыргытты.— Иң әүвәлтен текер-текер барып, әниеңнән сөенче апкайтаем әле, күгәрченем!

Инде «текердәтергә» җыенган апасының күлмәк җиңеннән эләктереп алды солдат:

— Тукта, сабыр ит, Фагыйләттәй! Мин үзем иплэп кенә... Югыйсә, әнкәйнең котын алып, йөрәген ярырсың — беләм мин сине.

— Нишләп инде? Җөрәге дигәч тә. Хәер, җомшак инде анысы җомшаклыкка. Айсам...

— Кайгырма, җиңгәчәй, бүләктән буш итмәбез!— дип елмайды егет һәм кулындагы чемоданны ихатасының капка почмагына кертеп куйды.

— Бар, айса, күрше генәсе, бар үзең.— Әнәең тепличадан җырак түгелдер, инеш буенда гынадыр. Син аннан әйләнгәләгәнче үзем самавыр җаңарта торырмын. Һай, эттә генәсе, әле кайчан гына киткән иең — үтә ле гомеркәйләр! Берүк җаңгыр апкайтуың булсачы, гөлкәем!

Солдат, билендәге киң каешны ике куллап алдан артка таба сыпырып алды да, урам кырыйлатып, җил-җил түбән очка таба юнәлде.

Атлар җире алай ерак түгел иде. Менә инде совхозның мастерское, машина-трактор утары, аның арт коймасына тоташып ук диярлек яшелчә бакчалары җәелеп киткән. Сул кулда Шилнә буендагы киң генә ачыклыкта янә төрле машина-механизмнар тезелешкән: тырмы-сукадыр, культиватор-чәчкечтәр. Болары коймасыз-нисез генә — үзе бер парк! Каршы якта киртләч-киртләч түбәле һәм һәр яклап ялтыравык полиэтилен белән

капланган киң дә, озын да корылма — Фагыйләттәйнең «теплича» дигәне, әлбәттә, шулдыр. Әле кайчан гына анда сусыл чирәмле зур гына тугайлык иде — кичләрен көтү кайткач, сыер-сарык ише малны бермәл ялмандырып алырга бик тә уңай иде. Бетергәннәр икән...

Болай табарак, һәрьяклап кысылган чирәмлек уртасындарак исә, куе-яшел төстәге вагон кукыраеп утыра. Аның түбәсенә кызыл әләм элгәннәр, ләкин ул, җил әсәре булмаганга, сәлперәеп төшкән. Вагон тирәсендә агач өстәл, эскәмияләр тезелеп киткән — монысы, әлбәттә, дистәләгән кешегә табын урыныдыр. Чак кына кырыйдарак, кара морҗасыннан зәңгәр төтен бөркеп, поход кухнясы тора, аның күтәрмәсенә бәрәү менеп баскан. Башында көрәнсу яулык, өстендә кыска җиңле саргылт-яшел күлмәк, ак алъяпкыч. Һе, кем булсын, әлбәттә, әнисе! Әмма ул, яны белән басканга күрә, җил-җил атлап килгән солдатны күрми дә, сизми дә; озын саплы чүмече белән олы казанны болгатуын белә иде. Аңардан ерак та түгел такыр башлы бер абзый, соры эшләпәсен аяк астына чирәмгә генә ыргыткан да, утын ваклап азаплана. Солдат аны шундук танып алды: «Мәттин агай. Ярата да инде җәйләрен казан тирәсендә кочегар булып йөрүләрне». Кочегар агай балта чәнчегән яркасын иңенә күтәреп, җирдәге тумранга шәплəп ормакчы гына иде, кинәт шул хәрәкәтен өзеп, тораташтай катып алды, күзләрен челт-мелт йомгалады, авызын җәйде һәм аңардан яшелле-зәңгәрле аваз сытылып чыкты:

— Кһи-һи-һем!

Әнисе әллә шул авазны ишетте, әллә күңеле сизенде — ялт кына болай таба борылды. Борылуына, өнсез калды ахры, агач саплы чүмече казан эченә чумды, үзе ике кулын да муен төбенә китерде һәм кисәк, сабагына үткен чалгы тиеп үткән болын чәчкәсе сыман, яшел фуражка өстенә ауды:

— Һай, улым!

Сулышын тиз генә кайтара алмады, кытыршы бармаклары белән егетнең битен-муенын, чәч араларын капшарга тотынды — яшел фуражка җиргә төшеп тәгәрәп китте.

— Көтә-көтә көтәкләр булдык ла инде, улым! — Ана кеше башын егетнең иңенә салган хәлдә, калтыранган куллары белән аны капшавын белде. Үзенең кояшта каралган йөзе буйлап яшь бөртекләре тәгәри, тавышы басынкы сулкылдау аша сынып-сынып чыга иде.

— Өс киемеңне дә җүешләтеп өлгергәннәр икән.

— Соң күрше җиңгәчәй Фагыйләттәй инде.

— Булыр, булыр. Бу эсседә капкасы төбеннән үткән-сүткәнне көннәр буе сагалап кына тора. Җаңгырлар җаумый бит, җаңгырлар! Ә син болай ни... тазарыплар да киткәнсең!

Ана белән улның назлы-иркәле күрешү хәле алай да озакка сузылмады, яннарында, карлыкканрак, әмма бик тә җылы тавыш ишеттеләр:

— Җә, күрешик әле, улым! Инде дә мактап кайтуларың, биллә-һи, тап пешкән аш өсләренә генә инеп төштең лә! Исән-имин генә алайса. Җарый-җарый!— Солдат ике куллап күрешкәч, Мәттин агай, кызгылт йөзендәге бар җыерчыклары белән балкып, хан заманыннан калган соры эшләпәсен һавада чайкап изәп алды. Ә дөнҗалар, шөкер, киңдер, матурдыр! Ием, хикмәтледер дөнҗалар бүгенгесе көнне!

Агайның киң селтәнеп күрсәткән «хикмәтле дөнҗасына» солдат иркенләп күз салырга өлгермәде, каяндыр — әллә яшел вагон эченнән чыгып, әллә Шилнә буеннан менеп, аның каршысында ак алъяпкычлы яшь кенә бер кыз пәйда булды:

— Исән-сау кайтып җиттеңме, Рәмзи абый! — Кызыйның тавышы саф, матур яңгыравыклы — якында гына талир тәңкәләре чылтырап алдымыни! Ә зур коңгырт күзләрендә исә кояш үзе чагылып китте сыман. Менә ул мөлаем елмаюын сүрелдерә төшеп, сул кулы белән ак яулык очына орынды, уңын егеткә сузды һәм кинәт пышылдауга кү-

чеп, әмма тәҗрибәле өлкән апаларча иттереп, әйтә салды:— Инде бәхетле сәгатьләрдә кайтып төшүләрең булсын!

Аның йомшак кулын кыскан чагында, егет бар гәүдәсен эссе дулкын яндырып үткәнлеген тойды. Хәер, бу мизгелдә кызыйның да сөйкемле түгәрәк битендә сирәк сипкелләренә тикле бүртенеп һәм кабынып киткән сыман иде. Солдат тотлыгып калды:

— Рәхмәт жылы сүзләреңә... кем... ни...

— Хәтирә,— дип пышылдады кыз.

— Рәхмәт, Хәтирә! — Солдат аңа янә күз тутырып карады һәм, нәфис чәчкәгә жылы тынын өргән сыман иттереп, бөтенләй үз күреп, әйтә куйды: — Мәнә инде син дә, сеңлем... Авылыбызның суы да, һавасы да бигрәк шифалы шул!

Чак кына читтәрәк әнисе басып тора, аның кояшта янган карасу йөзендәге жыерчыклары жәелеп каткан, әмма күзләре һаман да дымлы һәм шул дымлы күзләренең сүрелмәс нурлары белән улына карап туя алмый иде. Солдат белән кыз арасындагы жылы һәм мөлаем сөйләшү дә аның колагына бөтенләй эленмәде шикелле. Юк, тыңлап торган, ахры:

— Булышчым,— дип пышылдады ул кинәт, йөзен тагын да балкыта төшеп.— Мактавым булсын: инде дә уңган, инде дә жылгыр — күзләр генә тия күрмәсен!

Бу сүзләрдән кыз тәмам ялкынга уралгандай булды һәм иңнәренә сибелеп төшкән коңгырт чәчләрен артка таба ыспай гына сирпеде дә текер-текер ящел вагонга кереп китте. Берәр йомышы булдымы анда, юкмы — үзе белә. Солдат кесәсеннән шакмаклы кульяулыгын чыгарып, маңгаен, муенын сөрткәләде. Эсселәнеп, тирләп китүе көн кызуыннан гына булдымы икән?..

Менә ул, капыл гына әнисенә таба борылды да сулышы капкандай ашкынып сорап куйды:

— Әни, дим, әти еракмы? Кай тирәдәрәк?

Әнисе, кулын кашлары өстенә менгереп, басу ягына төбәлде.

— Әнәтерә, күрәмсең, су сиптерәләр? Жук, жәшелчәчелектәгесе түгел, арырак. Культуралы ни нәмәрсәгә инде...

Солдат кинәт кабалана башлады:

— Алайса, әни, су гына эчим дә... Салкыны булса...

Ана кеше таралып киткән зиһенен шул чакны гына жыя алды, һәм улын да уздырып, кызуланырга тотынды:

— Ниткән су ди синә! Сусының бик кузгалган булса, әнә бидоны белән компот пешереп куйдым.— Шулай дип, ул агач өстәлнең бер очында күләгәдә торган олы ак бидонга ишарә ясады.— КамАЗчылар бик тә жаратып эчә. Кайта-кайта карыннарың да ачыгып беткәндер инде. Иң әүвәл ныгытып тамак туйдырмаска монда.

Аны куәтләп Мәттин агай да гүелдәп жибәрде:

— Әтәең белән дә барып күрешерсең әле, дөнҗаң жанмый — ризыктан өстен булырга жарамый!

Рәмзинең эчендә, әлбәттә, күптәннән инде бүреләр улый, әмма аның алай бик үк сынатасы да килми иде.

— Кая, Рәмзи абый, кулларыңны да чайкаштырып аласыңмы?

Чак кына читтәрәк, вагон почмагындарак, чирәмдә Хәтирә көтеп тора икән, аның кулында суы мөлдерәмә тулган ак чүмеч, иңендә ак сөлге.

— Була гына, сеңлем!

Агач өстәл янына кире әйләнеп килүенә, ни күрсен, әнисе олы казаннан сосып, эмаль тәлинкәдә куе өйрәле ашны инде китереп тә куйган. Шунда ук чынаяк тәлинкәсендә тоздыр, ипи телемнәредер.

— Әйдүк, улым, әйдүк! Үз өебездә булмаса да, барыбер үзем пешергән ризык. Инде тансыклагансыңдыр?

— Тансыкламыйча!

Ләкин, ул да түгел, «жылгыр» Хәтирә — вагоннан алып чыгып ах-

ры, солдат каршысына бер табак яшел кыяр китереп куйды, пышылдап, әмма балкып әйтте:

— Шундый да тәмле — авыз суларын китерә!

Бу хәлдә Мәттин агай да читтә калырга теләмәде, тамагын кыргалап алгач, ятьрәк аныклык кертергә тиеш тапты:

— Кыярны болай май урталарыннан ук өлгертә башладылар үзе, рәхәтләнәбез. КамАЗ төзүчеләренә дә хәтсез генә озаттылар. Май уртасыннан кыяр ашый башла әле — безнең җакларда хикмәти хәл булмый ни!

Һәм ул коры сүз белән генә дә калмады, ашчыдан рөхсәт-мазар да сорап тормастан, агач өстәл уртасында торган олы коштабакның япмасын ачып салды, аннан иң әүвәл кайнар бу болыты күтәрелде һәм шуның артыннан ук... Мәттин агайның уң кулында йодрык чаклы симез ит калҗасы күренде.

— Кинән, улым! Аш булып үтсен!..

Солдат бик киң җәелеп киткән авызын капыл җыя төште, шулай да көлемсерәвен һич тыя алмыйча, баш селеккәләде:

— Син нәрсә, Мәттин агай! Бу хәтлене... кеше өлешенә кереп...

— Ниткән кеше өлеше булсын?! — Агай, өргәләнә-пошкырына, үткен пычак белән кайнар ит калҗасын ваграк кисәкләргә турый башлады.— Син кайда булдың? Әһеме, ил сагындамы? Иминлек хакына утка керергә дә, бозлы суга чумарга да әзер тордыңмы? «Кеше өлеше», имеш! Дувай дим, сыпырттыруыңны бел иплә генә!..

Әле алай гынамы, бер юмартланырга тотынгач, беткәнче булсын диптер инде, Мәттин агай, кызган канын суындырмыйча, тузып беткән соры пиджагының ян кесәсенә кабаланып тыгылды һәм аннан кәгазьгә төрелгән бер нәмәрсә тартып чыгарды. Сүтеп җибәрсә, кызыл эшләпәле җыйнак кына, матур гына борыч савыты икән.

— Мәле, улым. Кара борычымны үз кешеләр өчен генә җөртәмен. Сиңа жәл түгел. Син мул иттереп!

Солдатка бик рәхәт, бик күңелле булып китте. Алдында куе өйрәле тәмле аш, аңардан кайнар бу белән бергә лавр яфрагы һәм кара борыч исе бөркелә, моңа тагы симез калҗа исе белән җиңелчә төтен әчесе дә өстәлә, һәм, бары бергә кушылгач, борынны гына түгел, күңелнең үзен кытыклый иде. Ә үз итеп, үтә якын күреп сөйләшүләре, төрле кыланышлары?

Менә аның янәшәсендә әнисе басып тора һәм kояшлы яз куенында матур гөрләгән күгәрчен сыман, үз җаена, иплә генә сөйләнүен белә:

— Кичкә уңайда олы мичне җагып, ит бәлеше салып җибәрермен. Аннары тагын тавык суярбыз. Мунча да җагарбыз. Бүген дә шәт абыйларың Чаллыда җатып калмас, кичкә уңайда мотоциклларында выжлатып кына кайтып төшәрләр. Кич утырырга Туры бабаңнарны да дәшми калмабыз.

Туган ягыңа кайтып, туган туфрагыңа аяк баскач, мондый сүзләрне ишетәсең инде анысы. Әмма солдатны моңарчы үз авылында беркайчан да күрмәгәне, күрү түгел, һич уена да китерә алмаганы да көтә икән. Бермәлне башын калкытыбрак күз салса, исләре китте, хәтта авызына китерәсе кашыгы ярты юлда тукталып калды: тегеннән, яшелчә бакчасының коймасындагы киң генә ачыклыктан, төркем-төркем хатын-кыз чыгып килә иде. Үзләре, житмәсә, анадан гума диярлек шәрә: өсләрендә нибары трусик та лифчик. Берише кием-салымын култык астына кыстырган, кайсылары, дөрес, өске ягын кофта яисә яулык белән каплый төшкән. Арада зифа сынлылары, яшьрәкләре күбрәк!

Мәттин агай инде хәзер авызына кура җиләге кабып, аны суыргандай кыяфәт алды:

— Хур кызлары. Ике автобус бүген. Күр син, кәз-кәз атлауларын, чикы-чакы килүләрен, күр син теге ни...

— Тагын җабыштыңмы, тагынмы? — Солдат әнисенең тавышы ки-

нэт бик кырыс яңгырады.— КамАЗның шул шәрә пәриләренә кызыгып җенләнмәсәң соң, өрәк! Туйдырдың инде, валлаһи!

— Тавышыңны саклый күр дим, сеңелкәем! Бу эсседә артыгын алҗыганнар, ахры, сылукайлар. Әйтмә инде, шундый нечкәбилләргә җәшелчәчелектә чүп утаталар бит! Атна эчендә кара чуен төсләренә кергәннәре дә байтак күренә әнәтерә. Әрәм, әрәм! Беришесен кантурда кәртинкә итеп кенә тотасы җугыйсә. Житмәсә, син дә, сеңелкәш, чибәркәйләрне шул шәрә көенчә табын янына якын да китермисең, җәл,җәл.

— Китерде ди, табынның җәмен җибәреп монда!

— Их, җәш чаклар бер әйләнеп кайтса ие! Арада шундыйлары бар, улым, бер җандырып караса, көл буласың, тел әйләндереп, берәр сүз әйтсә, җиргә сеңәсең! Сайласа да сайлый белер икән КамАЗ дигәннәре нәзкәй билләрнең кәттәләрен, ә!

— Життеме сиңа? Җугыйсә, менә шушы чүмеч белән пеләшеңне чәрдәклим бит, Әҗер карачкысы!

— Син миңа сеңелкәем, тимә дә, орынма да! Мин синең белән түгел, солдат улың белән солдат булып сөйләшәм. Җегетләрчә!

— Син дә җегет булдың тагы — үләрсең! Житмәсә, әнисе тыңлап торганда монда...

— Тыңласа соң, әни кешегә җегетләрнең хәлен җакыннан белеп торуның гөнаһысы җук диләр әнәтерә — исеңдә тот, җәме!— Мәттин агай эшләпәсен кырын салды да, мут елмаеп, солдатка ым какты.

Егет, әнисеннән уңайсызланганга, сүз катмый, ул хәтта КамАЗ чибәрләре ягына да карамаска тырыша иде, ләкин кашыгын ипле генә йөрткән чагында, «гөнаһлы» тарафка күз атмыйча да булдыра алмый иде.

Мәттин агай, бер аягы белән усак түмәркәсенә баскан килеш, кипшергән иреннәрен ялаштыра-майлаштыра һаман да тел тегермәнен тартуында булды:

— Тиккә генәме әллә абзагыз һәр иртә саен кулына үткен пәкеләр алып, җаңак-иякләрен көзгедәй җалтыратып җибәрә, ә? Карчыгым, җәгъни сез бик әйбәт белгән Шәмсениса апаңаегыз, тәмам шаклар катты инде: «Ниндәен хикмәти хода булды инде ул җәшелчәчелек?!» ди.— Мәттин агай кинәт муенын сузды, аягын тумраннан алды һәм үтә зур мәгънә белән баш бармагын һавага чөйде: тегендә хатын-кызлар төркем-төркем үтеп беткән, инде хәзер инеш буасы ягыннан күкле-яшелле авазлар яңгырый башлаган иде.— Ишетәмсең: иһаһай да миһаһай чумалар, кинәнәләр! Әллә, дим, үземә дә кып-кыска трусикны гына киеп җиб-бәреп шул чибәркәйләр арасына барып чумасы инде, ә?

Хәтирә өстәл башында савыт-саба кыштырдаткан җирендә тыела алмыйча, пырхылдап көлеп җибәрде һәм иелә-сыгыла яшел вагон артына элдертте.

Рәсүлә дә, сынын бөгеп, ике куллап касыгына ябышты:

— Һай аллам, Мәттин. Мөхәммәттин абый... шакыраеп торган кабыргаларың белән ап-ак өрәк булыпмы? Синнән хатын-кыз түгел, буабыздан бар бака качар бит! Һай, имгә-томга да калмас бит!

Мондый гына шомлы кисәтүгә агайның сыңар керфеге дә селкенмәде кебек, үзенекен сипли торды:

— Шәмсениса апаегыз бүген иртән әйтә әле, бахыр: «Инде билләрем дә җазылуга табан китте, күкрәгем дә, шөкер, тартыштырмый, әллә дим, ди, үземә дә җәшелчәчелегегезгә барып тотыныргамы соң, ди, ичмаса, бер җәшлектә, бер картлыкта булыр ие», ди. Кһы-кһы-һы! Минем карчык көнләшү ачуыннан бер җарсынып җабышсамы?! Аңа ияреп авылның бүтән карт-корткасы тагы, ә? Билләһи дим, бөтен КамАЗыңны җәшелчәгә күмеп китмәгәйләре!

Мәттин агай солдат янына эскәмиягә килеп утырды, аякларын чәнчеп куйды. Анын сулышы сизелерлек булып авырайган иде. Бермәл

тын гына утыргач, терсәге белән солдатның янтыгына орынып алды:

— Анысы да монысы, кайры тунның җылысы дигәндәй, син дә солдат улым, дускаем, җиңнәреңне сызганып, хәләл көчләреңне түгәр урын эзләми җөрмәссең. Читкә-чатка каерылма диюем! — Агайның йөз чалымында да, тавышында да инде хәзер шаяртуның исе-әсәре дә калмаган, ул кинәт кенә бөтенләй бүтән кешегә әверелгән иде: уйчандыр, житдидер кыяфәте.— Бүгенгесе көнне бу дөньяның оҗмахы ук димим, әмма ләкин синдәй җегеткә иң кулай урын бер дә әллә кайда түгелдер, тап үзебезнең авылда, авылыбызның да җәшелчәчелек дигән басу иңнәрендәдер. Шәт, махы бирмәс иең, ә?

Рәсүлә сагая калды.

Күр моны, шуклана-мутлана торгач, егетне ипле генә кая китереп терәде тел бистәсе карт төлке! Юк, Рәсүлә үзе дә, ире Хәнәфи дә, күңел түрләрендә андый өметне сакласалар да, төпчек улларына болай ук капыл орынырга җыенмыйлар, бер көн, ике көн, хәтта атна буе сабыр итәрләр иде әле. Ә Мәттин агайга нәрсә — үз улымыни? Аңа дисәң, ике дөнҗа — бер морҗа!

Ләкин инде сорау-киңәш бирелгән, күкрәккә искәрмәстән очлы сөңге китереп терәлгән, боргаланырга һич җай калдырылмаган иде. Җавабы ни булыр?..

Егет исә ак димәде, кара димәде, кашларын җыерды, әмма шуның арты ук аларны язып та җибәрде, елмайгандай иттерде. Аннары торып басты. Тәмле аш-сый өчен рәхмәтен әйтте. Тагын уйчанланып калды һәм кинәт өстәлдә яткан җыйнак кына бер тастымалга үзеннән артып калган бер-ике ит кисәген салды, өстенә тоз сибеп җибәрде, ит янына тагын ипи телеме белән кыяр кушып куйды.

— Әтигә,— диде.

— Һәй, улым.— Ана кеше, капыл исенә килеп, кабаланырга тотынды.— Тукта, алайса, капкачлы банкыга компот та салып җибәрием.

Менә инде илтәсе ризык күн букчага да тутырылды. Солдат, китель итәген тарткалап, төзәткәләгәндәй итте дә, фуражкасын кырынрак салып, кулына букчаны алды һәм:

— Анда алай озак батып ятмам, әни,— диде. Аннары яшелчә бакчасының коймасындагы ачык арага таба юнәлде.

— Минем сүзгә җавап та кайтармады,— диде Мәттин агай тирән көрсенү аша. Ул тез капкачындагы олы ямауны сыйпаштыра, үзенең кара-кучкыл буынтыклы бармаклары сизелер-сизелмәс кенә калтырый да сыман иде.— Җарар, җегет кеше үз җаен белми җөрмәс. Нәселе үл түгел.

Солдат анасы Рәсүләнең күзләре янә дымланган иде, аның да күгелҗем иреннәре кыймылдап алды:

— Малай чагын исенә төшергәндер. Заманасында күн букча тотып, әтисе сызган буразналарны аз таптамады бит ул.

Бу вакытта Шилнә буасында көлеш-кычкырыш тына төшкән, һәм ул тарафтан өсләренә аллы-гөлле киемнәрен киеп алган бер төркем хатын-кыз, дөнья рәхәтендә кинәнүдән соң әле сафка тезелергә керешмәгән киек казлар шикелле, кәлдин-сәлдин генә атлап, болайга таба менеп килә иде инде.

## 17

Авылга көннең көнендә кемнәрдер килә, кемнәрдер китә — танып та, белеп тә өлгерердәй түгел. Беришләре: «Без фәлән итүчеләр, без төгән итүчеләр», дип күкрәк каккалап һәм КамАЗ сүзен кырыкмаса кырык төрлегә әвәләп, лаф орып йөри-йөри дә бу шаулы-гөрле тормышта капыл гына юкка да чыга. Әллә инде Чаллы каласының үзендә берәр тулай торакта яисә вагоннарда үзенә аерым җылы урын хәстәрен шома гына күрә беләә, әллә тәртәсен мыштым гына төзелештән сызу җаена таба борып куя. Барын да каян белеп бетерәсең?

Иллә мәгәр Туры картлар йортында оялап алган ике егет — Вятка буенда туып үскән ерык авыз Габделбәр белән Актаныш марие сакалбай Назар — олы төзелешкә төпле акыл, ныклы ният белән килгәнгә охшый. Дөрес, кай кичләрне алар да төзелештәге төрле чатак-читак якларга ачу сиздереп, теш кайраштыргалыйлар, хәтта моң-зар түккән сәгатьләре дә булмый тормый, әмма «тәртәне кирегә борып койрыкны сыртка салу» җайларына килгәндә исә, ник бер шыгырдау чыксын үзләреннән!

Тулай торакта үзенә аерым җылы урынга ирешү — әлегә татлы хыял гына. Анда әләгә алсаң, әлбәттә, бик күп төрле мәшәкатьләрдән, аерата баткаклы-сазлы юл йөрү газабыннан ансат кына котыласың.

Ләкин Габделбәр белән Назарга тулай торак дигәннәре ишеген ачарга алай бик үк ашыкмый икән әле. Чиратлары әллә кайда койрык очында ук, ди. Шуңа да карамастан, ике егет ирен чәйнәштермәде, уфтану авазы чыгармады, киресенчә:

— Авылда яшәгән көйгә кала салып йөрүләре күңеллерәк тә әле,— дигән булдылар.

Тулай торак хакында сүз купты исә, күз алларына молдаван «мыеккае» Женя Мында килә дә баса. Көннәрнең берендә тайды ул Туры карт йортыннан. Юк, үзенең кояшлы оҗмахы Молдавиягә сыпыртмады егет: ул нибары иске Чаллы читендә гөмбәдәй калкып чыккан өр-яңа йортларның берсендә шыгырдап торган пружиналы, ялтыравык никельле койкага ия булып алган иде. Бүлмәләрендә бары да энә белән жептән генә чыккан, ди, бары да ялт-йолт итә, хәтта шәп кием шкафы белән шоп-шома тумбочкаларга кадәр куелган, ди. Тик су белән генә әлегә җәфалыйлар, әмма анысы да озакламый бер юньгә киләчәк, ди. Боларны ул, бер очрашкач, Назарга сөйләп биргән, имеш.

— Эшнең чын остасы ич ул! Инде хәзер, безнең «Жилстройны» калдырып, турыдан-туры КамАЗның үзен коручы идарәгә күчте. «Иң беренче заводны салуда да катнашам, иң беренче станокны көйләүгә дә үзем тотынам», ди. Тәки үз дигәнен итәчәк ул! — дип бердән тезеп салды мари егете.

Моңа җавапка Туры карт чал башын гына селеккәләде:

— Ием, булдырмастай бәндәгә охшамаган... ихлас!

Картның күңелен егет киткәннән бирле: «Шул Рәмилә бәпкәч аркасында келәткә бикләп дапрус ясамаган булсам, бәлкем ул тикле үк ашыкмаган булыр ие; үземдә ипле генә җәшәп җатар ие әле»,— дигән уй бимазалап тора иде.

Женя Мынданың истәлеге булып, келәт белән ак мунчада электр уты янып калды, әмма иң кирәге, иң кадерлесе — коедагы насос иде. Монысын молдаван егете китәренә берәр атна калганда, Чаллыдан үзе табып алып кайтты, үзе үк көйләп тә куйды. Әкәмәт уңай нәрсә икән: махсус пенопласт «мендәр» — калкавычка беркетелгән җыйнак кына, җиңел генә бу насосны коега төшерәсең дә шнурдагы кнопкага гына басасың — җаның теләгән кадәр суырттыра суны кодрәт иясе! Аннары ишегалды почмагында зур чанда кичкә хәтле талыгып өлгергән суны да шул ук насос ярдәмендә бакчага сиптерәсең. Тамчы да көч түгәсе юк — рәхәтләнә!

Сабир «чуерташ» исә бу шәп нәрсәне бөтенләй уенчыкка әвереләдерде: кирәк булганда да сиптерттерә, кирәк булмаганда да. Ахырда бабасы:

— Бар дөнҗаны сазга әйләндереп бетерер иең бугай, пырдымсыз!— дип оныгын бик яман әрләп ташлады.— Әле җәйләр килми калмас, кирәге бик булыр моның. Аннары адәм рәтле берәүнең матур бер истәлеге дә бит әле ул!

Шул ук кичне бабай, ычкындырыр төшләрен ычкындырып, электр насосын келәткә алып керде дә монда әле кайчан гына молдаван остасы йоклап йөргән сәке астына яшереп куйды.

— Кирәге бик килеп чыкканда гына эшләткәләрбез. Ишетсен колагың, малай актыгы! — диде.

Ләкин Туры карт молдаван егетен әледән-әле Габделбәр белән Назардан сорашмыйча булдыра алмый иде: Чаллыда алай-болай янә очраганы юкмы, ни хәлләрдә йөри икән, исәнме-саумы дигәндәй? Әлбәттә, картның белергә теләгәне тирәндәрәк, нечкәрәк: «Безнең кызый белән арасын өздеме икән, ары таба инде ниләр кыланырга чамалый икән ул иблис җегет?» дигән чамадарак иде. Тик ул монысын туп-туры бәреп сорарга гына кыенсына иде.

Ә Рәмиләнең үзеннән исә... Туры карт үзенең сөекле бәбкәчен андый дорфа сораулар белән җәфалый аламы соң? Шул ук чакны ул, күңелендәгене тышка чыгармаса да, эчтән генә рәнҗеп-сызланып та куйгалый иде: соңгы көннәрдә кызый — кая анда көянтә-чиләкләп тәмле су китерүләр! — бабасының күзенә бөтенләй күренмәскә тырышып йөри иде.

Ә бер кичне, армиядән кайтып төшкән Рәмзи абыйсына ияреп, бәбкәче Рәмилә дә килеп кергәч, Туры карт күңеле тулудан әллә нишләп китте. Солдат оныгының менә шушылай таза-сау хәлләрдә әйләнеп кайтулары, аның көр тавышын ишетүләр, яшьлек дәрте, көч-гайрәт бөркегән нурлы йөзен күрү бәхете Туры картны, әлбәттә, чиксез куандырды. Оныгы белән гөлдер-гөлдер сөйләшкән арада ул, билгеле, күзләрен мөлдерәтеп, бәбкәче Рәмиләгә дә карап куйгалады. Кызыйның да куанычы ташып тора, аның да йөзендә ай да кояш, теленә исә былбыл кунган сыман: чут-чут сайрый, чырык-чырык көлеп җибәрә! Әйе, аның сөйкемлелеге, мөлаемлылыгы тагын да арта төшкән, кыяфәте дә шактый ук үзгә рәвеш алган: кай арада диген, чәчен кыскартып кистергән дә кабартып куйган, нәзек кашлары биеп кенә тора, ә күзләрендә исә моңарчы күренмәгән очкыннар уйнаклый кебек. Тәмам пешеп өлгергән кура җиләге ни дә бу ни! Бүген булмаса, иртәгә тот та кияүгә бир үзен!

* * *

Үз йортында оялап алган ике егет — Габделбәр белән Назардан исә Туры карт бик канәгать, бик разый иде. Икесе дә авылда туып-үскән крестьян малайлары, икесе дә, вакытлары тисә, кул астына керергә генә торалар. Әле килеп төшкән көннәрендә үк капка төпләренә китереп аударылган каен утынын кискәләп-яргалап лапас астына да, урам як койма буена да бик матур итеп әрдәнәләргә өеп куйдылар. Ян бакчадагы умарта ояларын күчерешү, аларның утырган төшләрен чүп-чардан тазарту кебек эшләрдә дә булышмый калмадылар.

Мари егете Назарның туган авылы Агыйделдән әллә ни ерак та түгел, киң генә, матур гына күл буенда урнашкан булган. Ләкин ул авыл хәзер инде юк диярлек икән, нибары өч-дүрт өй генә утырып калган. Чөнки Чаллы ГЭСы корылып беткәч, аларның авылын бөтенләйгә су басып китәсе икән. Шул сәбәпле, боларны күрше татар авылына күчерергә тотынганнар. Назарга, әлбәттә, колхозда да эш бетмәгән булыр иде, әммә ул замана куптарган каты җилләрдә күңелен иләсләндереп, КамАЗ төзелешенә кубарга иткән.

— Алай икән,— дип сузды Туры карт, егетне тыңлап бетерүгә.— Туган-үскән нигезләр, җирдәге гүр ияләре — бары бер өчтән су астында калачак, дисең, алайса? Һай-һай, катырак кизәнгән шул сезнекеләргә җазмыш!

— Бер чараң юк, апаем. Чыпчык дулап киртә җимергәне бармы? Ә мин монда төзелештә ипле генә эшли торгач, бер җаена чыгармын әле. Турысын әйткәндә, соңрак КамАЗның үзенә күчәргә ният. Торабара, бәлкем, техникум ишесен дә ачмый калмаслар әле минем кебегрәкләргә.

Вятка егете Габделбәр исә күңел түрендәгене яктыга чыгарып салырга алай ашыгычлык күрсәтмәде, уратыбрак-чуалтыбрак кыланды. Ул, тегенди-мондый гына сүз чыкканда да, сыңар кулы белән киң яңаклы битен сыпыргалап, туган ягын мактарга тотына иде: «Безнең колхоз бөтен Киров өлкәсендә гөрли. Игенчелек буенча дисеңме, яки, әйтик, мал асраучылык буенча дисеңме — байраклар бездә! Колхоз председателе Таһир абый Хезмәт Герое хәзер, бүтәннәр дә орден-медальләрне аз такмады инде. Менә сезнең якта салам түбәле өйләр әле һаман күренгәли, каралты-құраны әйткән дә юк. Ә безнең авылның төзеклеген сөйләсәмме? Өйләрнең иркенлеген, чибәрлеген күрсәгез икән, берсеннән-берсе уздырган. Тап уенчыклар инде!»

Шушылай мактану-һаваланугa Туры карт, баш түбәсендә кәләпүшен шудыргалап:

— Тукта, нишләп әле син дөнҗаның андыен гүзәл оҗмахын ташлап китәргә иттең соң? — дип текәлде.

— Сере бар аның, бабай, сере! — егетнең коңгырт күзләре кысыла төште.— Менә мин карап-карап торам да шаклар катам: сездә механизаторлар җитми икән, шоферлар да өч бөртек кенә. Ә бездә ике йортның берендә шофер яисә тракторчы. Әле күбрәк тә булмаса. Димәк ки, ул һөнәргә укуның кызыгы юк минем өчен.

— Ә ни нәрсә кызык алайса?

— Төзелеш, дим, төзелеш. Бездә болай төзү бригадалары бар барын, әмма алар ферма каралтыларын кору, күпер салулардан уза алмый. Ник дисеңме? Осталык җитми! Ә шәп клуб, таш мәктәпләрне әрмәннәр генә төзи. Каф таулары артыннан килеп шулар тотына.

— Безнең үзебездә дә клубны шулар өлгертте — җалт иттерделәр. Бөтен Рәчәй буйлап таралган, диләр, хәзер әрмәнне,— диде Туры карт.— Инде дә эшләп күрсәтәләр үзе!

— Умырттырып акчасын да каералар! Анысы да хак: кояш белән чыгалар, кояш баегач кайталар — чыда гына! Үзем эшләп карадым алар янында: комын китереп, ташын-кирпечен әзерләшеп йөрдем, бик беләм! Әмма ләкин алар безнең ишене үз бригадаларына алмый.

— Ә син акча дип теш кайраган идеңмени әле? — диде Туры карт һәм сынаулы, хәтта мыскыллы карашы белән егетне сөзеп алды.

Мондый чеметтерүгә Габделбәр әллә ни ис җибәрмәде, аның сул кашы гына сизелер-сизелмәс кыймылдап алды.

— Һи, эш акчадамыны? Әрмәннәр кебек чын оста бул, кулыңда утлар уйнасын! Менә нигә кирәк булды миңа сезнең Чаллы! Ике-өч елым җәл түгел, боерган булса, остарып кына җитим! Илкәйдә балалар бакчасы, кибетләр саласы бар, Сасмак авылында культура сарае тагы. Үз осталары булганда, колхозга да файда гына ич!

— Синеке хикмәтлерәк икән шул! — диде карт сузып кына һәм аның йөзендәге һәр җыерчыгы капыл гына нурга күмелде. Хуп, улым, бик хуп! Уңарга җазган булсын!

Үз серләрен шул рәвешле — берсе кыекламый-мыекламый, икенчесе уратыбрак-чуалтыбрак — ачып салгач, егетләр бабайның үзен дә читтә калдырырга теләмәде. Аларны күптәннән инде кызыксындырып килгән бер нәрсә бар иде: бабайның үз исеме Әүхәди, заманында мулла кушкан матур гына исем, әмма авыл халкы бу исемне бик сирәк әйтә, аңа ешрак очракта «Туры бабай» яисә «Туры агай» дип эндәшә иде. Ни сәбәптән икән? Кушамат тиккә генә бирелми ич.

Туры картның ак самавырга кушучлап күмер салып маташкан чагы иде, менә ул, гәүдәсен турайта төшеп, җилкәләрен язып җибәрде:

— Нигә дип... соң, ни, җазмыш инде. Элегрәк мин әллә шушылай бөрешеп, җилкә салындырып җөрер иемме? Гәүдәм гренадерныкыдай, күкрәк киереп, туп-турылай басып җөрер ием җиргә, шуңа күрәдер.

Сабир «чуерташ», өстәл читенә таянып, чәй өлгерүен көтеп утыра иде — минуты белән бабасын сатты:

— Хәйләләмә, бабай! Күршедәге Бибинур әби үзе әйтте миңа: «Синең бабаң, диде, сүзнең турысын әйтер, хак сүз әйтер, диде. Әллә нинди нәчәлникләрдән дә куркып тормас, диде. Аның кыек әйтсә дә, туры чыгар» диде. Мәнә нигә такканнар сиңа андый кушаматны!

Мондый «сатуга» бабай тамчы да үпкәләмәде, киресенчә, бик тә кәефле рәвештә тамак төбе белән генә кеткелдәп алды. Аннары капыл гына тынды да авыр сулап куйды һәм ярым пышылдау аша ирен арасыннан сыгып чыгарды:

— Ә сугышка тикле «Инде Әүхәдие» дип җөртерләр ие, бала-чага исә «Инде абый» дияр ие.

— «Инде абый?» Нишләп алай? — дип текәлде Габделбәр, муенын сузып.

Монысы Сабир өчен дә зур яңалык иде, ул, хәтта авыз ачып сорау да бирә алмыйча, зур күзләрен генә челт-челт йомгалады.

— Тотлыкканга күрә, озынрак сүз әйткәндә «инде»не кыстырганга күрә. Әйтик, «мото инде цикл» дип төртелеп торулармы җә исә «ата инде каз» дип буылып калулармы — тәмамлар җөдәр ием. Заманасында селеккәннәр ие шул мине.

— «Селеккәннәр иде»? Анысы ни тагы?

— Соң, капчык киертеп инде. Колхоз корган җылны. Җәгъни, әйтсәм дә әйтим инде, оланнар, тарих мең дә тугыз җөз дә утызынчы җылның җазлыгында, сулар киткәч, сәвер аенда. Җаман ачу тотып. «Әртил кормый җарамый безнең ише җарлы-җабагайга»,— дип бугазны артыграк җыртып җибәргәнмен, күрәмсең. Дөмектермәкче булганнар.

— Ишеткәнем бар: безнең якларда элекке заманнарда капчык киертеп дөмбәсләүләр булгалаган,— диде Назар, җирән сакалын учлаган килеш.

— Ә мине дөмбәсләмәделәр, селектеләр. Ничекләйме? Безнең валус Илбактыда ие, шуннан төн уртасында кайтып килгән чагым. Нишләптер иптәшләрдән арткарак калганмын. Бервакыт Шилнә җары белән ипле генә атлаган җиремдә тал арасыннан килеп чыкмасыннармы! Капчык киерткәннәрен сизми дә калдым.

— Кемнәр, бабай? Каракайлармы? — дип сорады Сабир пышылдап кына. Малайның тамак төбенә кинәт кенә төер менеп кунган һәм ул аны йотып җибәрә алмыйча интегә иде.

— Җарып кына әйтмәем. Әллә дүртәү, әллә бишәү әзмәвир. Җук, ормадылар, бәрмәделәр, капчыкка тыккан көе һавада селектеләр. Ни суккан эзе җук, ни җәрәхәте җук, әмма ләкин эчке әгъзалар урыныннан купкан. Таң аткач, кан косып җаткан җиремнән табып алалар да Чаллы бульнисенә илтеп салалар, аннары Казанның үзенә озаталар. Җан дигәнем нык булгаң, күрәмсең, җата торгач, эчке әгъзаларны рәткә китерә алдылар үзе, тик тотлыгуымның гына дәвасы табылмады.

Бу хәлләрне ишетүгә бабайның оныгы Сабир гына түгел, ике фатирчы егет тә өнсез калган иде, менә, ниһаять, Габделбәр авыр гына көрсенеп куйгач:

— Ә хәзер тотлыкмыйсың бит инде. Әкренләп үзеннән-үзе беттемени? — дип сорады.

— Бетәр сиңа! Шушы азаккы сугыш чик куйды аңа!

Туры карт, бер тотынгач, ярардай хәтлесен яктыга чыгармыйча булмас ахры дип, ясаган чәен бер-ике генә йотты да басынкы тавыш белән язмышының иң саллы гәрәбәләрен ары тезеп китте:

— Башта сугышка алмадылар мине, авылда бригадир булып җөри бирдем. Аннан инде сугышның икенче җылында председатель иттеләр. Авылда җүнле-башлы адәм калмаган, кемне куйсыннар? «Инде» абзаң да җарады. Әмма озак тормадым, очырттылар. «Колхоз милкен туздырган өчен» дип. Эшләр хөрти, хәлләр дуамал начар чак. Бикләннең чана җасаучылары, тугым бөгүчеләре белән алыш-биреш итеп алган ием шул. Алты-җиде баш җәш үгез малыннан колак кагарга туры килгән ие.

Тегеләр акчага сатмый, ә колхозны арба-чанасыз гына өстерәп кара! Хөкемгә тартырга да исәпләре җук түгел ие.

— Соң, колхоз файдасына булган ич! — диде Габделбәр.

— Шулаен шулай да бит. Җарар, колхоз арба-чаналы булып калды, үзем җөрәк җарсуына чыдашмыйча туп-турылай военкоматка киттем. «Ичмаса, обозга булса да җарармын», дип. И тап шуңа охшашлыга җарадым да. Ут эченә ат җигеп кердем, ат җигеп чыктым, дигәндәй. Снарядын-мазарын да ташыдым, җаралыларны да аз апчыкмадым. Гражданнар сугышында һай күп атышырга туры килгән ие, ә монда ник бер атып карасам икән, ник бер фашистны дөмектерә алсам икән. Җугыйсә, арба башына винтовкам да кыстырып куелган иде. Җае чыкмавыннан әйтәм әле. Җарты Җаурупаны буйласам да...

— Шулай йөргәндә тотлыгудан да котылдыңмы? — дип авызын ерды Габделбәр.

— Ашыкма, дим! Герман җиренә барып кергәч булды ул, нимеснең җылкылдап торган шәп алашаларын җигә башлагач. Бер заман дуамал дәһшәткә эләгеп, чат минем җанда диярлек бомба шартлады. Җарый әле иптәшләр казып ала белгән. Җаман контузия. Госпитальдә өч ай җарым җатып чыктым. Бер заман терелеп килгәндә, исләрем-акыллары китте: тотлыгуым беткән!

— Менә сиңа хикмәт!

— Авылга кайткач, элеккеге кушаматны тергезеп тормадылар. «Инде абый» булулар эзсез җугалды шулай иттереп. Үземне хәтта киредән председатель итәргә дә кызыгып җөргәннәр ие, әмма ул арада улым Ризван кайтып төште. Аның орден-медальләре күкрәк тутырук, ә миндә нибары ике җиз медаль генә. Бик авыр җылларда, бик җәшли көенчә өстерәргә туры килде аңа. Тик ул да, колхозларны берләштерә башлагач, очты. Дөресе, Казанга укырга озаттылар үзен.

Туры бабай, башын иеп, тынып калды. Бүтәннәр дә сүз катмас булды. Самавыр инде күптән кайнап чыккан, бүлмәдә аның торган саен тоныклана барган гуләве генә ишетелә иде. Ниһаять, Туры карт башын күтәрә төште һәм, беркемгә дә карамый-нитми, һаман да шул карлыкканрак тавыш белән, әмма һич көтелмәгән тарафтан сорап куйды:

— Теге заманның өермәле җылларында теге кем... Котовский-батыр... милләте белән молдаван булганмы әле?

Сорау егетләрне сискәндереп җибәрде. Алар үтә сәерсенү аша берберсенә күз ташлап алдылар. Әлерәк кенә бөтенләй бүтән төрле кызыклы һәм гыйбрәтле хәлләр турында аңгәмә корып утырганнар иде, ә хәзер, күр инде, һич уйга да килмәгән текә борылыш. Туры карт әлеге соравы белән, әлбәттә, үз күңеле төбендә ни ятканын, кемнәр һәмниләр хакында тынгысыз уйларда ут йотып яшәгәнлеген аермачык сиздерде. Күрәсең, ул, ни тырышмасын, үз эчендә кайнаган пошаманлы уй-хисләрне берничек баса да, тыя да алмый иде бугай.

— Ие, бабай, молдаван булган,— дип иң әүвәл сүз катты Сабир.— Зрә дә гаярь, зрә дә үткен кеше булган ул заманасында!

— Алайсам, монда үзебездә дә буласы икән хәлләр! — дип басынкы гына сузды Туры карт һәм чал кашлары астыннан гына егетләрнең берсенә, үзен Вятка татары дип йөрткәненә күз төшереп алды.— Каршыларында асыл кошның берәгәйлесе, түш кабартып, канат кагарга торганда, татар булган башлары белән ни җөриләрдер җебеп...

Бу сүзләрдән Габделбәр, янтыгына очлы без кадагандай рәвештә йөзен яман чытып, төкселәнеп китте, әмма егет шуның арты ук коңгырт күзләрендә зәһәр очкыннар да кабындыра белде:

— Син, бабай, үз татарыңны алай ансат кына себереп атарга ашыкма әле бик. Арада ташка басса, ут чыгарырдайлар да бөтенләй үк бетмәгәндер, бәлкем. Үзең әйтмешли, дөнья күләсә — бер көендерә дә, бер сөендерә дә белә бугай ул, ә?!

*Дәвамы бар.*

## КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН

Җырлый-җырлый ата көн дә таңнар.
Өр-яңа җыр көн дә Кояшы...
Тоя белсәң әгәр
бер сулавын
иләһи җыр итеп тоясың.
Яңа җырлар кебек йөзә болыт.
Яңа җырлар кебек ага су.
Өр-яңа җыр кебек бөтен дөнья,
югалыр җыр кебек ямансу.
Табылмаган җырдай йолдыз ерак.
Табылмаган җырдай күңелләр.
Табылган җыр кебек туа кеше.
Югалган җыр кебек үлемнәр.
Табылмаган җырлар табылырмы?
Табылганы — Җирдә каласы...
Җырда коенып,
җырга сусап йөри
дөньяларның күпме баласы!
Җырлый белгәннәргә җырлар кирәк,
белмәгәнгә кирәк бигрәк.
Җырны табулары ансат түгел,
җырны югалтулар — гыйбрәт.
Ике гомер безгә насыйп булмас,
бер яшибез Җирдә,
бер туып.
Шушы Җирдә бик каласы килә,
бер югалмый торган җыр булып.

### Ышану

Бер гадәт бар. .
Гадәт кенә түгел,
ул кагыйдә инде тормышта.
...Әйтерсең лә,
шушы кагыйдәләр
ияреп килә безгә тумыштан.
Нигезе бар үзенең,
формуласы:
«Шулай тиеш», «Шулай кирәк»,— ди.
Исбатлап та бирә:
бу дөньяда
ышанырлык кеше сирәк, ди.
Акылга да сыеп бетми кебек:
Кеше дигән затка ышанма!
Актарыла минем хисләр кайчак,
йөрәгеңне тот та тышаула!
Бәгыреңә пычак булып керә,
алдануы авыр авырын...

---

КАДЫЙР СИБГАТУЛЛИН — 1942 елда туган, шагыйрь, татар һәм рус телләрендә берничә шигырь китабы авторы. Брежнев шәһәрендә яши.

кыенлыгын беләм
ышануга
алданулар аша баруның.
Алдасыннар мине.
Бер алдасын,
ике, өч кат мине алдасын.
Түзә алам,
бары минем аңа
ышануымны ул аңласын.

Аллага да,
кешегә дә биргән
ышанырга дигән антым юк.
Ышанмасаң, бәлки, ансат тадыр,
ышанмаска ләкин хакым юк.
Ышанамы миңа кеше үзе?
Ышанмаса, бик тә кызганыч.
җанымдагы бөтен законнарның
кодексы минем ышаныч!

## Яңа сүзләр

Барысы да кергән сүзлекләргә,
юк дөньяда,
телдә яңа сүзләр...
Туа тора ләкин яңа көннәр,
яңа кеше туа,
яңа күзләр.
Яңа шатлык туа,
яңа бәхет.
Мәхәббәтләр туа,
яңаралар...
Яңа хисләр туа,
яңа уйлар,
яңа җаннар Җирдә яралалар.
Мин яңа ди,
миңа дәшегез ди,
яңа итеп,
яңа сүзләр белән.
Яңа җаны белән карый безгә,
карый безгә яңа күзләр белән.
Беркайчан да сүзгә тилмергән юк,
сүзне кеше һич тә кабатламый.
Ни хикмәттер,
шул ук,
бер үк сүзләр
искегә дә,
яңага да ярый.
Юк дөньяда,
телдә яңа сүзләр,
яңа итеп, димәк, әйтеп була.
яңа бәхет туа,
мәхәббәтләр!
Яңа сүзләр шулар белән туа!

*

Бөтен кеше бүген шундый әйбәт,
бөтен кеше шундый мөлаем!..
Кичә әле мондый түгел иде,
үзгәргәндер дөнья, мөгаен.
Дөнья хәтле дөнья үзгәрә алмас,
бүген, бәлки, үзем үзгәдер?
Дикъкать белән карап йөрим әле,
бөтен хикмәт минем күздәдер.

## Илһам Шакировның юбилей концерты

Сүзләре дә шул ук,
көйләр дә шул.
Шул ук Илһам җырлый онытылып:
дөньяларны кабат хәтерләтеп,
дөньяларны кабат оныттырып.
Шул ук халык тыңлый,
бер тапкыр да
ишетмәгән кебек, ләззәтләнеп.
Бер тапкыр да аны күрмәгән күк,
Илһамына карый гаҗәпләнеп.

Әйтерсең лә, яңа гына чыккан
сәхнәләргә,
бер дә китмәгәндә.
Әйтерсең лә,
җырлап килә-килә,
бу гомерләр бер дә үтмәгән дә.
Җырлап кына үтми шул гомерләр...
Кай тарафтан күпме җилләр искән...
Җырчы гына түгел,
җырчыларның
җырлары да үзгәрәләр икән.
Вакыт бара һаман,
гомер бара.
Җил дөрләтеп тора —
йөрәк яна.
Тыңлый халык: Илһамы да шул ук,
җырлары да шул ук —
моңнар яңа!

## Улымның анасына

Үпкәләмә.
Гаеп-мазар эзләп,
кимсетүем диеп карама.
Икебезнең уртак дөньябызга
күз салуым гына яңадан.

Күп вакытта безнең сүзләр уртак.
Күп вакытта уртак уйлар да.
Шулай кирәк.
Бурычыбыз шундый —
бергә яшәп, бергә уйларга.
Матур яшибез дип сөйли кеше,
туры килеп торса уй-шөгыль.
Ә шулай да
төрле чаклар була,
гомер итү җиңел эш түгел.
Җитешмидер кайчак сабырлык та,
хөрмәт-ихтирамда тирәнлек.
Ансат кына гомер уздырырга,
җиңел яшәүләргә өйрәндек.
Ни кадәрле дөнья иркенәйсә,
вакланулар артты шул чаклы.
Ансат түгел җылы тотулары,
сүндермичә өйдә учакны.
Еракларак йөри бугай кайчак
олы хисләр,
тирән төшенчә...
Кешелектән чыгып куймыйбызмы
яшибез дип кайчак кешечә?!
Уйлар уртак безнең,
сүзләр уртак —
шигем дә юк минем бу хакта.

Чатнап-чатнап китә әле тормыш
бер йодрык кебек булсак та.
Шуңа микән,
кайбер вакытларда
бик үк риза түгел икән мин:
синең урыныңда булса әгәр
әни нишләр иде икән? — дим.
Хәтеремә килә күз карашы,
сүзләренең көче, кодрәте...
Үз мисалы белән тудырды ул
әтигә дә безнең хөрмәтне.
Хөрмәт сүзе өйдә бизмән иде,
шуның белән барын үлчәдек.
Ач та булдык,
ялангач та булдык,
гарип рухлы булып үсмәдек.

Үпкәләмә,
кайбер эшләреңә
әни күзлегеннән карасам...
Хатын-кызның мин әнием кебек
булганнарын күбрәк яратам.
Горурлыгы,
олылыгы белән,
тугрылыгы белән хәзер дә,
хатын-кызның эталоны булып
әни яши минем хәтердә.
Инде син дә күптән ана кеше,
кодрәте зур һәрчак ананың...
Тик бер теләк:
безнең әниләрнең
күрәсем бик килә дәвамын.

# Нурия Измайлова

## Бер диңгез мәхәббәт

Суларга салынган балалар,
Утларда яндырган балалар,
Ташларга атылган балалар,
Ачлыкка аш булган балалар!..
Елыйлар, яныйлар, яналар
Кычкырып-кычкырып яңадан!
Котылу юк, юк, юк алардан! —
Минем бит балам бар, балам бар...

Гасырлар буена җыелган
Балалар күз яше — диңгездер.
Шул диңгез эчендә өр-яңа
Бер диңгез — мин бала тергездем.
Мин бала тудырдым үч итеп
Палачка! Көч итеп Шәфкатькә.
Баламның җанында бер диңгез
Мәхәббәт — нәфрәткә каһкаһә!

Мин аны гасырлар буена
Кызгану һәм сөю ялварган
Сабыйлар өчен дә яратам.—
Терелтәм аларны! Мәрхәмәт,
Мәхәббәт, мәхәббәт яңартам!
Бер диңгез Мәхәббәт бу бала!
Палачтан көчлерәк ул диңгез!
Тимәгез! Тисәгез, сезгә әйтәм:
Мәхәббәт үчлерәк нәфрәттән,
Мәхәббәт кичерми — белегез!

●

Кеше үзенең аң мөмкинчелекләрен 7 процентка гына файдалана ала, диләр.

Уйларым җиде кат, җиде кат, җиде кат,
Җидедән башкасын оталмыйм.
Җиде кат җир асты еланның йөргәнен
Беләм дә, сизәм дә, тоталмыйм!
Аңым да, мием дә җиде кат, җиде кат,
Йөзенче катына үтәлмим.
Туксан өч катламы тик үле хәзинә!
Җан өреп, минеке итәлмим!
Тик ята күпме аң, күпме сер, күпме нур!
Ә күзләр, ә башлар җик чигә —
Күрәлми, беләлми, аңламый! Аңларга
Теләвен аңлап тик интегә.
Башымның туксан өч катламы эшләми!
Караңгы башларым тубал күк!
Күңелем күзләрен, акылым чишмәсен
Әллә кем томалап торган күк...

---

НУРИЯ ИЗМАЙЛОВА 1950 елда туган, «Яратам» һәм «Алтын тарак» исемле шигырь китаплары авторы. Шагыйрә Мәскәүдә яши.

Шуңарга — мин сизәм! — Киммен чын Кешедән,
Үземә-үзем дә дошман кук...
Мин әле чын Кеше булырга омтылган
Чак тере, чак кузле бер җан кук...
Камиллек! — кайда ул! Тик аның кирәген
Аңларга җитә бу нәни баш!
Йөз катлы баш белән, их, яшәп карыйсы
Иде бит — кешемен дип, тугач!
Мәгълүмдер — язалар — маймылдан кешегә
Ничә мең еллык юл булганы.
Ә миннән — Кешегә? Ә синнән? — мәгълүмме —
Купме ел кешелек юллары?

## Яз шигыре

Шомырт чәчәкләре мәрҗән-мәрҗән,
Һәр мәрҗәне — гүзәл бер дөнья! —
Ачылган да кузгә бүләк булып,
Рәхмәт итеп куздән нур җыя.
Ышанган ул кузләр сафлыгына,
Бирелгән ул җаннар иркенә.
Нечкә-нәфис, көчсез гүзәллекнең
Сихри көче җилдә җилкенә:
Аклыгында — тотанаклы сөю,
Тынлыгында — тыйнак бөеклек,
Мәңге тоеп, аңлап бетми торган
Ләззәтле сер — классик шигырь кук!
Хуш исенә хисләремне кушам,
Куз нурларым кушам нурына.
Әй, гүзәллек! — язгы халәтемә
Тәңгәл килгән гаҗәп бер дөнья!

*

Мин килермен сиңа дәрья буйлап —
Агыйделдә көймә калдырдым.
Безне бергә курган көймә бит ул,
Саклагандыр аны Агыйдел!

Берәү генә безне күргән көймә,
Безне белгән дәрья бер генә.
Иркәләде безне бердәнбер җәй —
Бер гомердә бар да бер генә...

Ә бердәнбер яшьлегебез безнең
Агыйделдә, бердәнбер ярым!
Көймәбезне кузгат, кодрәтле су!
Юллар тапмыйм, сулардан барыйм!

Еллар аша «Ярым» дидерерлек
Ярату да — бары бер мәллә?!
Каршыларсың микән, бердәнберем,
Яшьлек төяп килсәм көймәгә?..

Әй, бердәнбер яшьлеккәем минем!
Дәрья булып калдың хыялда...
Тормышымда үзең тик бер генә —
Дулкын гына булдың бугай ла!..

## Сиңа да шуны телим

Ярат әле син берәрсен!
Сокландырчы мине бер!
Корбаннар биреп булса да,
Соклану даулый күңел.

Күрим нәкъ мин теләгәнчә
Үзгәргән күзләреңне.
Миңа да яңача карап,
Мине дә күргәнеңне...
Бәхеткә чорналган телең
Көрмәкләнгәнен күрим.
«Гөнаһ» белән сихерләнгән
Романтикаңа керим.

Романтикаңа керсәм дә,
Гөнаһыңа, юк, кермәм —
Керсәм кеше гөнаһына,
Азактан гел үкенәм...

Ярат әле син берәрсен!
Мин көткәнчә яңар бер!
Гаепләүсез, кичерүсез —
Үзем кебек — аңлармын.
Миңа — син ни, я үзем ни!
Яратудырмы — белмим...
Нәрсә теләсәм үземә,
Сиңа да шуны телим...

## Безнең урамда бәйрәм

Мәңгелек кадәр мәңгелек
Безгә колачын җәйгән.
Чем-тулы чәркәләр сузган
Яшәү дигән куллардан.
Безнең урамда бәйрәм бу,
Безнең урамда бәйрәм!

Бер-беребезгә шундый тиңбез! —
Кемнәр белеп сайлаган?
Безгә бит, әй, замандашлар,
Уртак ана бу заман!
Сабантуй — безнең урамга!
Безнең гасырга — мәйдан!

Җиргә килү шундый сирәк!
Кемгә генә тиядер...
Шул бәхет безгә тиде бит!
Таш булгач та сөйләрмен!
Бәхетлеләр киң күңелле —
Кемне дошман күрәлим?!

Шушы чакта, кеше чакта
Тик «Сөям!» дип әйтәлəм.
Ватмыйк! — бергә эчәсе бит
Яшәү дигән чәркәдән:
Безгә бер генә заман бит,
Безгә бер генә бәйрәм...

## Үз күлмәгем

Балачакта вакыт озак үтә —
Җәйне җиткерәлми тилмереп,
Мин кар көри идем, кар астыннан
Җәй чыгарга тиеш дип белеп.
Көри торгач, җәй дә җитә иде —
Үз вакыты аның, үз җае...
Тик мин уйлый идем үзем казып
Алдым диеп ямьле ул җәйне!

Хәзер вакыт никтер бик тиз үтә —
Өлгерәлмим алып көрәкне,
Яңа күлмәк киеп җәйләр җитә,
Бер мин генә иске күлмәкле!..
Яңа күлмәкләрем — иске җәйдә
Кар астында гына калды бит!
Тик, кар казып җәйләр эзләр өчен
Җитми хәзер, җитми сабыйлык...

Юк, үткәнне сагыну ул кадәр үк
Кар тырнарлык түгел анысы.
Яңа җәйләр каршыларга чыгам!
Үз күлмәгем үземә — ярыйсы...

## Җәлилләр исеме

(Җыр)

Илне сакладыгыз,
Саф һәм сау калдыгыз.—
Без саклыйбыз сезне ил белән:
Нурлы исемегез,
Моңлы исемегез
Халык исеменә үрелгән.

Сезнең сагыш җанда —
Мәңге сызлар яра...
Тик иелмәс горур бу башлар!
Безнең маяк бит сез,
Безнең байрак бит сез —
Безнекеләр елак булмаслар!

Без — Җәлил токымы,
Җаваплылык олы:
Шул исемне аклый белергә.
Йөрәктә сезнең кан,
Өйрәтә сезнең дан.—
Хаккыбыз юк түбән булырга!

Утта яна-яна,
Исән кала-кала,
Мәңгелеккә барабыз бергә.
Халык кадәр халык,
Исемегезне алып,
Үлемсезлек кушты гомеренә.

**Рафис Корбанов**

# САНДУГАЧЛЫ ТАЛЛАР

Яши идем туган ягымда мин,
Тыныч кына үскән тал кебек.
Талга оялаган сандугачтай
Күңелемә урнаштың кереп.

Нурга тулы, моңга тулы хәзер
Минем өчен таңнар-иртәләр.
Кешеләр дә миңа карап гүя
Сандугачлы тал дип үтәләр.

## Дәү әни

Каршы килеп кем сүз әйтсен
Дәү әни теләгенә?
Тугач та миләш беләзек
Кигезгән беләгемә.

Сакласын яман күздән, дип,
Догасын аннан өргән.
Муенда — миләш муенса —
Сакласын яман күздән.

Дәү әни, саклап үстердең
Син безне яман сүздән.
Ә үзең сораша идең
Кайтканда һаман бездән:
Яман сүз әйтмәдегезме
Мыскыллап кичеләрне?
Калдыра күрмәгез берүк
Хәтерен кешеләрнең.

---

РАФИС КОРБАНОВ 1957 елда Биектау районының Кече Битаман авылында туган. Казан дәүләт университетын тәмамлаган. Хәзерге вакытта Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакциясендә эшли. Яшь шагыйрьнең шигырьләре журналыбызда беренче мәртәбә басыла.

Кешеләрне яман күздән
Сакладың син, дәү әни.
Кешеләрне нахак сүздән
Якладың син, дәү әни.

Тугач та миләш беләзек
Таккансың беләгемә.
Дәү әни, миләш булып син
Кергәнсең йөрәгемә.

Саклар өчен яман күздән
Зурларны, кечеләрне,
Яклар өчен нахак сүздән
Дусларны, кешеләрне,

Саклар өчен явызлыктан
Кешелекне, дөньяны...
Җирнең миләш беләзеге —
Дәү әни, синең җаның.

●

Кышкы төндә умырзая эзләп
Каруманга киткән кыз бала...
Әкият кенә бары мең кичәдән...
Хәтерләсәң, күңел кузгала.

И үги кыз, синең белән ахры
Минем язмышым да уртактыр.
Ни ул дөрли алда, ашкын, йөрәк —
Уникe ай яккан учактыр.

Карурманга барам синең кебек
Кара төндә мин дә, сеңелем.
Җыр эзләп мин карурманга барам.
Карурман ул — халкым күңеле.

Адашмыйсың анда суык кышта
Син чәчәкләр эзләп барсаң да.
Уникe ай кебек Тукайлары
Яккан җылы учак бар анда.

Уникe ай кебек шагыйрьләре
Якты биреп тора күгемдә.
Һәм мин табам, табам чәчәкләрне —
Моңлы җырым туа күңелдә.

## Ак болыт

Риваятьтә, курку белмәс ирләр
Зур юлларга чыгар алдыннан,
Туып-үскән өйнең матчасына
Ап-ак каурый кадап калдырган.

Таңда торса, килеп ана карчык
Иң элгәре аңа караган:
Улы исән икән, каурый — чиста.
Утка керсә, тамган кара кан...

Каурыйлар да кадап калдырмадык
Җиткерергә сәлам-хәбәрне.
Ак болытка карап белә микән
Әнкәйләр соң безнең хәлләрне?

Әнкәйләр соң безнең хакта ниләр
Уйлый икән шушы минутта:
Саркыганда шәфәкъ кызыллыгы
Баш очыннан узган болытта?

Болыт та шул гел ак кына түгел.
Әнкәйләр дә шуңа борчулы —
Уллары бит йөртә йөрәгендә
Ил шатлыгын һәм ил борчуын.

Бездән яхшы хәбәр көткән чакта
Китмәсен лә бәгыре теленеп:
Баш очында, болыт, әнкәемнең
Гел ак килеш тор син, эленеп.

●

Миңа да килде ул сөю!
Тик әллә ничегрәк.
Кол булып шул бөек хискә
Ашкынды, шашты йөрәк.

Хыялда йолдызлар чүпләп
Бирердәй кебек идем.
Көрешкәндә, җылы апрель
Карыдай, җебек идем.

Беренче, тәүге мәхәббәт!
Хисләрнең сафы, чыны...
Ах, ул туй атларындагы
Кыңгырауларның чыңы!

Хыянәт түгел иде бу,
Тик сөеп йөргән кешем
Туган булган, үскән булган
Икенче бирәү өчен.

Һаман да шул мин, кыюсыз,
Ләкин кайбер «кыю»лар
Сөю юк, дип кычкырганда,
Кабатлыйм: бар сөю, бар!

# Данис Хәйруллин

## Сорау

Күпме сорау яшәештә!
Инде берсенә җавап
Таптым дисәң, шул җаваптан
Ун сорау туа кабат.

Күздә ята, йөздә ята,
Сүздә ята мең сорау.
Сорау дугасында чыңлап
Үтә гомер-кыңгырау.

Мең сорауга бер җавабым,
Диеп тормыш дәшәме?!
Һәркем үзе мең сорау бит,
Бер җавабы — яшәеш.

## Ташта үскән чәчәк

Ташның уемы бу? Я гөлнең
Яшәү өчен ярышымы?
Әллә инде уйлый-уйлый
Ташка әйләнеп барышымы?

## Ни ул бәхет?

Изге җанмы, әллә бер-бер бәдбәхетме —
Һәркем эзли бу дөньяда үз бәхетен.
Табам, диеп, һәркем үзен юатмакчы.
Эзли кайсы үзен-үзе югалтканчы.

Берәү эзли чума-чума, йөзә-йөзә,
Берәү елап, үзәкләрне өзә-өзә,
Усал итеп эзли берәү ярсып, янап,
Шүре кебек бармак белән акча санап.

Ни ул бәхет, нәрсә соң ул? Бармы тапкан?
Һәм ишеттем туксан яшьлек күрше карттан:
— Бәхет, энем, ул гап-гади пыяла кебек —
Ватылмаса, барлыгын да булмый белеп.
Челпәрәмә килгәч кенә, шаклар катып,
Тора кеше башын кашып, уйга батып...

---

ДАНИС ХӘЙРУЛЛИН 1945 елда туган. Брежнев шәһәрендә яши. «Камгэсэнергострой» да эшли. Журналыбызда шигырьләре беренче кабат тәкъдим ителә.

## Озату

Кошлар китә: мең төр аваз чыңлый
Су буйларын моңга тутырып.
Тал-куакта бишек җырын көйләп
Оялары кала утырып.

Кошлар китә — һай мәһабәт күренеш! —
Төркем-төркем күккә сыенып.

Яшьлегемнең җитез канатлары
Офыкларга керә кыелып,
Мамыклары кала коелып...

## Җавапсыз мәхәббәт

Гөлләр яраткансың икән...
Чәчәк кебек чагымда
Өздең дә, салып яндырдың
Мәхәббәт учагында.

Көлгә калгач, көлдең генә:
Җилләр таратыр, дидең...
Кабат гөл булсам, барыбер
Сине яратыр идем!

## Шомыртлар

Ап-аяз көн иде югыйсә,
Кайдан гына чыкты болытлар.
Коелып ла төште боз белән
Күз карасы кебек шомыртлар.

Тилмерешеп ята җир тулып,
Борчак-борчак зәңгәр боз катыш.
Туфан калкып, күкләр иңсә дә,
Агач иңнәренә юк кайтыш.


Тик бер генә мизгел, бер мизгел,
Уйнап кына үтте болытлар.
Күккә карап калды яшь катыш
Күз карасы кебек шомыртлар...

Җан ярасы булды шомыртлар.

Тукайның 100 еллыгына

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул...

Г. Тукай, «Туган авыл».




*Тавил Хаҗиәхмәтов рәсеме.*

# КУШЛАВЫЧ

Тау башына салынган бу авылның Казан ягы урамында Тукайга һәйкәл тормаса, узган-барган кеше, ихтимал, «бу кайсы авыл!» дип тә сорамас иде. Кушлавыч — тыйнак кына аккан инешнең ике яктагы тау кырына «аргы як» һәм «бирге як» булып сузылган. Кыш көне Кушлавычны кар каплагач, ул инеш буендагы өянкеләр бигрәк тә мәһабәт шау белән Җир-анага бишек җыры җырлыйлар, су буеннан күтәрелгән бу шауга Мөхәммәтгариф нигезендәге карт шомырт җыры да кушыла. Яз җиткәндә Казан артында иң беренче булып Кушлавыч тау битләре ачыла, өянке башларында каргалар туй итә, аргы якның казлары бирге як казлары белән аваз алышалар, тал куаклары бүртенеп яфрак ярырга хәзерләнәләр. Тау битендә беренче яшел үлән тибүгә сары-яшел мамык туп булып каз бәбкәләре күренә, бакчалардан, абзар тирәләреннән пар күтәрелә, инеш буе сандугачлы җәйгә әзерләнә башлый. Бу вакытта, әйтерсең лә, Казан арты кояшы бер Кушлавычка гына карый, җылыта, яктырта. Яшел тау битле, гомер агышын санап челтерәп аккан күп чишмәле, таллы-куаклы бу кояш илендә көннәрдән беркөнне ничек инде табигатьнең күңеле бер ташып китмәсен ди? Ничек инде карт өянкеләр, чишмәләр моңы язгы күк шавына кушылган чакта табигать җиргә бер яхшылык эшләми калсын ди? Тукай әнә шундый язгы шауда җир, халык моңын тыңларга, бераздан шуңа кушылып җырларга дип дөньяга килгән.

Бишектәге Габдулла әнисен таный башлаган көннәрдә Кушлавыч авылы сандугач моңына тула, сихри кичләр, аксыл төннәр, алсу таңнарда чутылдаган бу кошчыклар гашыйкларның йөрәген телгәли, хәсрәтлеләрнең бәгырен өзә. Июньнең җылы төннәрендә Мөхәммәтгариф абзый түр тәрәзәсенең яртысын ачып куя — сандугачлар өй түрендәге шомыртлыкка да, якындагы зиратка да килеп тулганнар икән бит! Нигә шулай үзәк өзгеч итеп сайрыйсыз сез, мәхлуклар? Җәй уртасында сандугач сайравы тынгач кына кырык өч яшьлек Мөхәммәтгариф абзый сизенә: дүрт айлык улын ятим калдырып дөньядан китеп бара икән ул. Бу җәй әнә шуңа моңлы булган икән...

Кушлавыч бәләкәй Габдуллага нибары дүрт ай хәсрәтсез, борчусыз гомер бирә. Нибары дүрт ай! Шуннан соңгы Уральскига кадәрге бөтен гомерендә мәхәббәт сакчысы аны һәр ишектән сөрә. Ләкин әнә шул бишектә уздырган, үзе хәтерләмәгән кыска Кушлавыч чоры шагыйрь күңелендә мәңгелек илһам чыганагы булып кала. Әнә шуңа күрә дөньяның байтак ачы-төчесен күреп егерме өч яшенә җиткәч, Кушлавычны сагынып ул болай язган:

Бу дөньяда, бәлки, күп-күп эшләр күрем,  
Билгесездер — кая ташлар бу тәкъдирем;  
Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә,  
Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем.

Казан артының иң типик авылы бу. Анда, Казан артында гел шулай: борыла-сарыла инеш агар, ул инеш буйларында тарихның үзе кебек карт өянкеләр оя-оя булып утырыр, инешнең берәр борылышта текә ярга килеп бәрелгән урынында кызылканат, чабак йөзәр, тирәнрәк урыннар аркылы салынган басма тирәсендә яки яр буендагы тал-куаклы әрәмә белән төрелгән чоңгылларда куркыныч, әмма шигъри серле әкият булып бала күңелендә су анасы яшәр.

Хөрмәтле укучы! Тукай шигырьләренең бөтен аһәңен ишетәсең, аңлыйсың килсә — Кушлавычны күр. Карт өянкеләр моңының күккә ашкан шавын тыңла. Шунда тын калып Мөхәммәтгариф абзый нигезендә бераз басып торсаң, Тукайның нәкъ шушы җирдә дөньяга килүе бик табигый һәм аның бары тик шушы авылда гына тууы мөмкин икәнлегенә ышанасың.

Бөек Тукай бу авылны гомере буе җаны-тәне белән сөйгән.



**Р. И. Зарипов,**
КПССның Кукмара райкомы беренче секретаре

# НУРМИНКӘНЕҢ КӨМЕШ СУЫ

Кукмара районы республикабызның иң төньягына, Вятка елгасының уң ярына сыенып урнашкан. Киров өлкәсе белән чикләнгән бу ягыбыз дистәләрчә километрга сузыла. Елганың сул ягында — Лубян поселогы. Мондагы урманнар Удмуртиягә кадәр барып җитә. Көньяктан Мамадыш, Саба, көнбатыштан Балтач районнары белән чиктәш без. Район биләгән мәйдан 1493 кв. километр, халкы 51 меңнән артык. Биредә татарлар, руслар, удмуртлар, марилар һәм башка милләт вәкилләре яши.

Халкыбызның гореф-гадәтләрен, бүгенге тормыш-көнкүрешен, киләчәген ачыграк күзаллау өчен иң элек районның үзенә хас үзенчәлекле тарихына мөрәҗәгать итми булмый. Кукмарага кем, кайчан нигез салганын тәгаен әйтүе кыен. Халык телендә ул мари халкына бәйләп аңлатыла. Кайчандыр әлеге урынга ике мари килеп яши башлаган, имеш. Кок — марича «ике», мара — «мари» дигәнне аңлата. Авылның исеме шуннан барлыкка килгән, ди. Тагын бер аңлатма бар. Борынгы фарсы телләрендә «кук» сүзе тау төшенчәсен белдерә. Кукмараның тау итәгендә икәнен исәпкә алсаң, бу атама да дөреслеккә туры килә.

Тарих битләрендә Кукмара исеме беренче тапкыр XVII гасыр башларында телгә алына. Бу биредә бакыр ятмалары табылуга бәйле. Бакыр кою өчен Кукмара-Туеш заводы ачыла. Аңа Мәскәүдән җибәрелгән мастер җитәкчелек итә. XVIII гасырда ул тирә-якта дан тотучы заводка әверелә. Кукмара ягы башка һөнәр осталарына да бай була. Берәүләр бакырдан самовар, савыт-саба ясый, башкалар арба-чана, дирбияләр җитештерү, бау ишү, кап сугу, кием тегү, киез итек басу белән шөгыльләнгән. XIX гасыр урталарында сәүдәгәрләр П. Вавилов, бертуган Родыгиннар, С. Комаров итек фабрикалары ачып җибәргәннәр. Комаров барысыннан да уздырган. Ул салдырган яңа фабриканың даны еракларга тарала. Товарларының Парижда уздырылган Бөтендөнья күргәзмәсенә куелуы үзе дә шуңа дәлил. Әмма эшчеләр, фабрикантларның рәхимсез изүенә чыдый алмыйча, 1906 елның 12 октябрендә стачка башлыйлар. Аңа полиция гаскәрләре чакырыла. Шулай да фабрикантлар эшчеләргә кайбер ташламалар ясарга мәҗбүр булалар.

Кукмара төбәгендәге авылларда игенчелек һәм терлек асрау белән дә шөгыльләнгәннәр. Крестьяннар уңдырышлылыгы әллә ни булмаган җирләрдә иген үстереп көн күргән.

Кукмара ягы халкы Бөек Октябрь социалистик революциясен алкышлап каршылый. Власть хезмәт ияләренең үз кулына күчә. Кукмарада ярлылар комитеты оештырыла. Аның председателе итеп агач эше остасы Иван Богомолов сайлана. 1918 елның октябрендә РКП(б) һәм РКСМ ячейкалары төзелә. 1922 елдан Кукмара авылы эшчеләр поселогы итеп үзгәртелә.

Алдан әйтүебезчә, Кукмара биек тау итәгендә утыра. Поселокта яшәүчеләр моннан 20—30 ел элек тауларны яшелләндерә башладылар. Хәзер тау

битләрендә яшь урман күтәрелеп килә. Ул ел саен тулылана. Һәр язда бөтен поселок халкы тау буйларына агач үсентеләре утыртырга чыга.

Яшел бөркәнчекле тау итәгеннән ургылып агучы чишмәләр Нурминкә елгасының суын тагын да ишәйтеп җибәрәләр. Шушы елгачык элек-электән поселокка ямь биреп тора. 1926—1927 елларда Кукмарада яшәгән язучы Ибраһим Гази биредә язган әсәрләренең берсен «Көмеш сулы Нурминкә» дип атаган. «Бригадир кыз» дигән күләмле әсәрендә дә геройлар итеп Кукмара кешеләре алынган. Соңрак атаклы язучы булып танылган Ибраһим Гази бу елларда комсомолның Кукмара волосте комитеты секретаре булып эшли. Ул партия, комсомол, сугыш һәм хезмәт ветераны Л. Сидоренко белән бер квартирада яшәгән, бергәләп яңа тормыш өчен көрәш алып барганнар.

Беренче бишьеллыклар Кукмарада яңарыш башлап җибәрә. Фабрикаларда социалистик ярыш киң җәелә. Эшкә иҗади мөнәсәбәт үрнәкләре күрсәтүче эшче-ударниклар, стахановчылар саны күбәя. Киез итек фабрикасы эшчесе Маһинур Шәрипова районда беренче стахановчы була. Аны Татарстан АССР Верховный Советына депутат итеп сайлыйлар.

Бөек Ватан сугышы елларында меңнәрчә кеше фронтка китә. Дүрт якташыбыз — Танькино авылыннан Петр Воробьев, Байлангар авылыннан Фәхретдин Заһидуллин, Лубян поселогыннан Николай Савин, Түбән Өскебаш авылыннан Сабир Әхмәтовка Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Битлянгур авылы егете, лейтенант Нух Идрисов Александр Матросов батырлыгын кабатлый. Бу каһарманлыгы өчен ул I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Кызыл Йолдыз һәм башка орден-медальләр белән бүләкләнгән элеккеге артиллерист, бүгенге көннәргәчә «Восток» колхозы председателе булып эшләгән Гафият Гарифуллинның батырлыклары да яшьләргә үрнәк итеп сөйләрлек. Ул Варшава өчен барган сугышларда, Берлинны штурмлауда катнаша. Фронтовик җитәкче сугыштан соң колхоз авылларын ныгыту өчен бөтен көчен биреп эшли. Хәзер ул җитәкләгән колхоз үзәге Ядегәр авылы бик матурланды. Икешәр катлы биналар: культура сарае, мәктәп, заманча кибет, пекарня, торак йортлар аның йөзен нык үзгәрттеләр. Күптән түгел иптәш Гарифуллин пенсиягә чыкты, әмма колхозыннан аерылганы юк. Аның урынына үз кулы астында эшкә өйрәнгән И. Ибраһимов сайланды. Гафият ага колхозның профсоюз комитеты председателе буларак актив эш алып бара. Районда терлекләрне кышлату һәм җәйләү чоры йомгаклары буенча иң күп сөт җитештергән хуҗалыкка тапшыру өчен Г. Гарифуллин исемендәге бүләк булдырылды.

Өлкәннәр башлаган эшне районгагы яшьләрнең дәвам итүен күреп күңел сөенә. Авыллар һәм поселоклар, кем әйтмешли, ел үсәсен ай үсә. Соңгы берничә елда, моңа кадәр артка калып килгән «Маяк» колхозы, әнә шундый тизлек белән үсте. Бу хәл тракторчы булып эшләгәндә авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган һәм баш инженер дәрәҗәсенә күтәрелгән коммунист Ф. Кәримуллинның председательлеккә сайлануы белән бәйле. Яшь җитәкче эшне кадрлардан һәм төзелештән башлады. Фермаларда, машина-трактор паркларында, ындыр табагында дистәләрчә яңа биналар үсеп чыкты. Авылда балалар өчен ак-кызыл кирпечләрдән бизәп салынган, бөтен уңайлыклары булган бакча файдалануга тапшырылды. Байлангар авылында культура йорты сала башладылар. Белгечләр һәм колхозчылар өчен төзелгән йортлардан яңа урам барлыкка килде.

Мондый күркәм үзгәрешләр Вахитов исемендәге колхозга да, «Россия» һәм «Коммунизмга» колхозларына да, XXI партсъезд исемендәге колхозга да, «Правда» колхозына да хас.

Авыл төзелешләре челтәренең киңәюе колхоз һәм совхоз авылларындагы культура үсешенә этәргеч булып тора. Хәзер районда 18 урта, 11 сигезьеллык мәктәп бар. Хәзер аларның барысы да диярлек әйбәт, яңа биналарга урнашты. Укытучыларыбыз арасында Татарстанның атказанган — 11, «Халык мәгарифе отличнигы» исемен алган 58 укытучы бар! Ә Зур Сәрдек Урта

мәктәбе директоры З. Сабитов РСФСРның атказанган укытучысы исеменә лаек булды. Районда ике профессиональ-техник училище бар. Аның берсе — механизаторлар, икенчесе эшчеләр һәм төзүчеләр әзерли. Лубяндагы техникум урман белгечләре чыгара. Авыл эшчәннәренә район культура йорты, 21 авыл культура йорты, 38 клуб, 45 китапханә хезмәт күрсәтә. Медицина, көнкүреш, сәүдә хезмәте күрсәтү елдан-ел яхшыра. Соңгы елларда авылларны табигый газ, яхшы юллар белән тәэмин итүгә җитди игътибар юнәлтелә.

Кукмара үзе дә үсә, матурлана бара. Ул хәзер уңайлыклары булган шәһәр тибындагы поселокка әверелде. Соңгы 5—10 ел эчендә калыккан биналарны санап чыгу өчен дә шактый вакыт кирәк булыр иде: республика күләмендә иң яхшылардан саналган больница комплексы, аптека, китапханә, өч катлы мәктәп, көнкүреш йорты, сәүдә үзәге, колхоз базары, балалар бакчалары, биш̆әр катлы торак йортлар... Ә тиздән файдалануга тапшырылачаклары тагын да күбрәк.

Районда башланып киткән киң колачлы корылышларны нигездә колхозара ПМК һәм ПМК-90 коллективлары башкара. Һәр икесе республика күләмендә алдагы урыннарны тота. Колхозара ПМК төзүчесе Ф. Фәйзетдинов Ленин комсомолы премиясенә лаек булды.

Кукмара данын еракларга таратучы, гасырлык тарихы булган киез итек фабрикасы хәзер икенче яшьлеген кичерә. Эшчеләр иркен, якты, чиста цехларда эшлиләр. Итек басу тулысынча механикалаштырылган. Хәзер бездә ел саен 2 миллион пар чамасы итек басыла. Яңа төзелгән цехта киез эшләү үзләштерелде. Кайбер мәгълүматларга караганда, 1944 елда һәр 10 нчы сугышчының аягында Кукмара итеге булган. Бөек Ватан сугышы чорында фабрика фронтка 2 млн. пар итек озаткан, төрле фронтлардан кайтартылган 7 млн. пар итекне реставрацияләгән. Ул елларда итекчеләр ярышын ТАССР Верховный Советына депутат булып сайланган коммунист Маһинур Шәрипова, Сәрвәр Фатыйхова, Гөлсем Шәрипова кебек стахановчылар әйдәгән. Бүген аларның данлы традициясен кызлары дәвам итә. Ярыш алдынгылары рәтендә Гөлсем апаның киленe ТАССР Верховный Советы депутаты, биш баладанасы Әнисә Шәрипова атлый.

Элекке вак артельләр урынына алмашка килгән 6 нчы тегү, 9 нчы мех фабрикалары, кирпеч заводы һәм башка предприятиеләр үсеш юлыннан атлыйлар. Кукмарада тегелгән плащ-курткалар, бүрек-туннар халыкның ихтыяҗын канәгатьләндерүдә зур урын тота.

Үткән бишьеллыкта ике бишьеллык планны үтәгән «Почет билгесе» ордены кавалеры, 6 нчы тегү фабрикасы тегүчесе Д. Зәйнетдинова, киез итек фабрикасы эшчесе, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Ә. Шәрипова, шушы ук фабрикадан Бөтенроссия ярышында җиңеп чыккан Л. Рәхмәтуллина, мехчылар М. Хаҗиева, Н. Маркова һәм башка күпләр инде уникенче бишьеллык исәбенә эшлиләр.

Илебезнең Азык-төлек программасын тормышка ашыру өчен көрәштә авыл хезмәтчәннәре зур тырышлык куя. Район Бөек Октябрьнең 68 еллыгы алдыннан ук игенчелек һәм терлекчелек продуктлары сатуның бишьеллык планын арттырып үтәде. Хезмәттә ирешкән уңышларыбыз өчен агымдагы бишьеллыкта КПСС өлкә комитеты, ТАССР Министрлар Советы, профсоюзлар өлкә Советы һәм ВЛКСМ өлкә комитетының күчмә Кызыл Байрагын берничә тапкыр яулап алдык.

Мондый җиңүләр авыл эшчәннәренең гаять зур тырышлыгы нәтиҗәсендә яулана. Табигать безнең якка «юмарт» туфрак бүләк итмәгән. Җиребез кара туфраклы түгел, составы ягыннан ул авыр балчыклы, кәслекөлсу.

Бишьеллыкның дүртенче-бишенче елларында шундый җирләрдә әйбәт уңыш үстерелде. Бөртекле һәм кузаклы культураларның һәр гектарыннан 20 центнердан артык уңыш җыелды. Бу сан үзе генә дә әле кайчан гына 7—8 центнер уңыш алу белән чикләнгән безнең район игенчеләренең тиңсез батырлыгын күрсәтә. Игенчелектә туфрак саклауның фәнни нигезләнгән яңа

системасын кертүгә аеруча зур игътибар бирелә. Хәзер күпчелек мәйдан камылны тырнату юлы һәм калаксыз сабаннар белән эшкәртелә. Сөрү катламын тирәнәйтү, органик һәм минераль ашламаларны мул кертү, аммиак суын киң куллану, орлыкның сыйфатын яхшырту һәм башка мөһим чаралар уңышны күтәрергә ярдәм итә.

Авылга коллектив подряды үтеп керде. Сөрү җирләренең 70 проценты диярлек коллектив подряды белән эшләүче бригадаларга һәм звеноларга тапшырылды инде. Бу ысул җирне файдалануда иясезлекне бетерүгә китерде.

Районда елның-елында мул уңыш үстерүче «Урал» колхозы беренче урынны тота (председателе М. Фәләхов, партоешма секретаре Ә. Әхмәтҗанов). Бу колхоз эшчәннәре соңгы елларда бөртекле һәм кузаклы культураларның һәр гектарыннан 30,3 центнер уңыш җыюга ирештеләр.

Һәр гектардан 23,4—26,8 центнер уңыш үстергән Вахитов исемендәге, «Коммунизмга» колхозлары П—Ш дәрәҗә Дипломнар алдылар.

Бәрәңге үстерүдә «Әсәнбаш» колхозы уңганнарына тиңнәр юк. Алар һәр гектардан 210 центнер уңыш җыйдылар. Колхоз тарихында моңа кадәр күрелмәгән уңыш иде бу.

Уңыш өчен көрәш йөзләгән хезмәт батырларын тудыра. «Ударник» колхозы комбайнчысы Руфин Александров урып-җыю чорында бөтен район халкын таң калдырырлык итеп эшләде. Ул кайбер җәйләрдә 9 мең центнерга якын ашлык суктыра. Руфин — җитмеш төрле һөнәр иясе. Үзе балта остасы, тимерче, кирәк булса, мич чыгара, умартачы, радиотехниканы белә. Шофер булып та, тракторчы булып та эшли ала. Өстәвенә, менә дигән культура хезмәткәре дә. Оештыру сәләтен, культура-сәнгатькә гашыйклыгын күреп, бервакыт аны Кәркәвеч авылы культура йортына директор итеп куялар. Куюын куялар, әмма үзе гармунда да уйный белми бу. Мондый хәлдә ничек итеп культура эшен җанландырырга кирәк? Шулай итеп, ул беренче көннәрдән үк баян уйнарга өйрәнә башлый. Озак та үтми, авылның менә дигән гармунчысына әйләнә егет. Аның белән генә дә чикләнми, үзе курай ясый, концертларда курай моңнарын сибә, мандолина чиртә.

Тик егет күңелен техника үзенә тартып тора. Бу юлы инде ул комбайнда да эшләргә алына. Игеннәрне урып-җыюда бишенче сезонын түгәрәкләгәндә Александров районның абсолют чемпионы булып танылды.

Аның хатыны Мәймүнә дә бик уңган. Ул да — үзе шофер, үзе тракторчы. Алар өч ел ирле-хатынлы бер комбайнда эшлиләр, штурвалга алмаштилмәш утыралар. Үзләрендә уракны төгәлләгәч, башка колхозларга ярдәмгә баралар.

Икенче-өченче урыннарны яулаган комбайнчылар — «Правда» колхозыннан Рәфыйк Гыйниятов, Вахитов исемендәге колхоздан район Советы депутаты коммунист Рәкыйп Нигъмәтуллин. Рәкыйп аеруча кешелекле. Аның авыр минутта башкаларга ярдәмгә әзер торуын чагылдыручы бер хәл күңелдә саклана.

Кылны кырыкка ярырдай кызу урак өстендә колхозга өр-яңа комбайн кайтып төшә. Яңа булса да, берәү дә үзенекен ташлап монысын кабул итәргә теләми. Чөнки аны корып җибәргәнче бер атна вакыт үтүе мөмкин. Әмма өр-яңа комбайнны файдаланмый яткыру да җинаять булыр кебек. Коммунист комбайнчы моны йөрәге белән әнә шулай кабул итә. Ул үзенең көйле комбайнын башка механизаторга тапшырып, яңа комбайнны уракка әзерләргә керешә. Көн-төн белән исәпләшми, ул аны экияттәгедәй тизлек белән корып куя. Иптәш Нигъмәтуллин бу елны шул комбайны белән район буенча беренче урынны яулаган иде.

Терлекчелек тармагы да бишьеллыкның соңгы елына якты йөз белән килде. «Урал» колхозы терлекчеләре беренчеләрдән булып дәүләткә ит сатуның бишьеллык планын үтәү турында рапорт бирделәр. Моңа ирешүдә РСФСРның атказанган авыл хуҗалыгы работнигы Илдар Гобәйдуллин, терлек симертү осталары Рауза Насрыева, Хәертдин Садриевның өлешләре аеруча зур.

Районда гына түгел, республикада сөт житештерү буенча дан тотучы «Восток» колхозының көндәшләре ишәя. «Дружба» колхозы терлекчеләре хәзер востоклыларга тиңләшү өчен киеренке көрәш алып баралар. Мондый үсеш-үзгәреш колхозны элеккеге ветеринария работнигы М. Гарипов кабул итеп алганнан соң башланды. Яшь житәкче беренче көннәрдән үк терлекчелеккә зур игътибар бирде. Үзләре турында зур кайгыртучанлык тойган терлекчеләр дә икеләтә энергия белән эшли башладылар. Шушы колхоздан ике терлекче: КПСС члены Гөлнур Гыйләжева һәм комсомолка Кадрия Мөхәрләмова район тарихында беренче булып үз группаларындагы һәр сыердан уртача 5 мең килограммнан күбрәк сөт савып алдылар. Бу жиңүне фермаларда терлекчеләр өчен уңайлыклар артуы, эшнең индустриаль нигезгә күчә баруы, ике сменалы эшкә күчү һәм бригада подряды белән эшли башлау белән аңлатырга кирәк.

Шуның белән бергә охшаш шартларда эшләп тә районның уртача күрсәткеченнән шактый артка калучы хужалыкларның да булуы борчылу тудыра. Болар партия житәкчелеген тагын да камилләштерүне, оештыру һәм политик эш формаларын һәм алымнарын яхшыртуны таләп итә. Партия оешмалары, авылдагы барлык коммунистлар үзләренең бөтен көчләрен бүгенге көннең конкрет бурычларын хәл итүгә туплыйлар.

Кукмара ягы халкы әдәбият-сәнгатькә, жыр-музыкага гашыйк. Тырыш хезмәттән соң һәркемгә китапханәләр, культура йортлары, клублар үзләренең ишекләрен киң ачалар.

Анда безнең районда туып үскән һәм хәзер киң мәйданга чыккан әдәбият-сәнгать әһелләренең әсәрләре белән дә танышырга мөмкин. Язучылар Мәгъсүм Насыйбуллин, Рәшит Бәшәров, Удмурт АССРның атказанган культура эшлеклесе һәм Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Гай Сабитов, РСФСРның Глинка исемендәге премия лауреаты композитор Фасил Әхмәтов, ТАССРның атказанган артисткасы, жырчы Алла Фадеечева белән без ихластан горурланабыз.

Район газетасы каршында «Салават күпере» исемле иҗат берләшмәсе эшләп килә. Ул әдәбият сөюче дистәләрчә кешене берләштерә. Аларның язмалары республика матбугатында еш күренә. Һәвәскәр башкаручыларыбыз республика радиосында һәм телевидениесендә чыгышлар ясыйлар. Зур Кукмара, Сәрдекбаш, Әсән Елга, Кәркәвеч авыллары һәвәскәрләре аеруча зур уңыш казаналар.

Күптән түгел киносөючеләр түгәрәге барлыкка килде. Аңа сугыш һәм хезмәт ветераны С. Минһаҗев нигез салды. Әлеге түгәрәк членнары төшергән фильм республика күләмендә беренче урынга лаек дип табылды.

«Көмеш сулы Нурминкә» үзенең нурларын көннән-көн, елдан-ел мулрак сибә. Элек-электән тырышлыклары, хезмәт сөючәнлекләре белән танылган кукмаралылар туган якларын яңа хезмәт җиңүләре белән данлыйлар, яңа биеклекләргә омтылып эшлиләр, иҗат итәләр.

Казан утлары
АЭС
әдәби пост

## Марат Әмирханов

# НИЗАГ

ТӨЗЕЛЕШ КӨНДӘЛЕГЕННӘН

Галимуллин, гармун күрегедәй җыерылган муенын алгарак сузып, Баязитка текәлде. Миһербансыз, җанны өшетә торган салкын караш иде бу. Ләкин Баязит күзләрен читкә бормады. Идарә начальнигы исә моны көтмәгән иде булса кирәк, аның итләч йөзендә аптырау катыш гаҗәпләнү галәмәтләре чагылып китте.

— Кабатла әле,— диде ул ачу белән.

— «Кабатла» түгел, Мөхәммәт Галиханович, «кабатлагыз»,— диде Баязит тыныч кына.— Складка килгәндә, аның урыны дөрес сайланмаган, проектны үзгәртергә кирәк.

Галимуллин көлемсерәп башын чайкады.

— Кыю егет син, Бәширов, ләкин дә шуны онытма: төзүче төзергә тиеш, проект белән заказчы шөгыльләнә, институтта өйрәткәннәрдер, шәт.

— Өйрәттеләр анысы, мин...

— «Мин» дип сөйләшергә иртәрәк әле сиңа, Бәширов, ә планны өзәсең икән, рәхимшәфкать көтмә!

Идарә начальнигы алдындагы кәгазьләрне өстәл тартмасына төшерде дә телефон трубкасына үрелде. Бу инде әңгәмә тәмамланды дигән сүз иде.

Алдагы бүлмәдә начальникның бушаганын юан гына бер кеше көтеп утыра. Баязит бусагада күренүгә, туп шикелле аның янына тәгәрәде.

— Буранның кәефе ничек? — диде ул.

Баязит иңсәләрен сикертеп куйды. Чыннан да ул әле күп нәрсәне белми, чөнки атом электр станциясе төзелешенә килгәненә бер ай чамасы гына. Моңа кадәр Саратов далаларында сугару корылмалары сузды. Институтны бетергәч, шунда җибәргәннәр иде. Күңеле туган якка тартты. Әле шактый эшләргә тиеш булса да, бик үтенеп сорагач, каршы килмәделәр тагын. Хәзер инде үкенергә туры килмәгәе. Мондый дорфа, киребеткән житәкче белән ботка пешереп булулары, ай-һай, икеле. Баязитны өлкән прораб итеп трестта ук билгеләделәр. Әллә абзаң шуның өчен тузынамы?

Планны үтәмәскә, әлбәттә, берәүнең дә хакы юк. шулай да шаулап утыручы ямьяшел урман тезмәсен күрәләтә актарып-җимертеп склад төзетәләрме, беткәнмени башка урын? Сугыштан соңгы иң авыр елларда, юкны бар итеп утыртылган урманны һәйкәл итеп сакларга кирәк! Далада яшәтәсе иде бу Галимуллинны, шәп-шәрә далада. Бер көн барасың, ике көн, өч, дүрт... Алда һаман шул уңган ашъяулыктай төссез кылган диңгезе чайкала, очы да, кырые да юк, күз карашын куандырырлык ник бер яшеллек очрасын! Бертөрлелектән күңел үрталергә тотына, кычкырышасы, тәпәләшәсе килә башлый. Ул эсселеге тагын?! Әйтерсең лә кояш даланы җан дошманыннан саный, шул хәтле рәхимсез өтә, яндыра, көйдерә — чыдап кына тор!

Баязитны кызгылт төстәге «КамАЗ» көтеп торырга тиеш иде, ләкин тукталышта андый машина күренмәде.

Көн иртәдән үк болытлы. Дөресрәге, тирә-юньне аксыл томан чолгап алган да һич таралмый. Сәгать сигезләрдә генә Кама аръягыннан җил исә башлады. Йортларга, агач яфракларына, торбаларга чат сыланган томан челтәре чайкалып куйгандай итте. Шулай да аңа карап көн яктырмады, киресенчә, томан урыны-урыны белән куера төште, машиналар хәтта яктырткычларын кабызырга мәҗбүр булдылар. Җилнең дә тукталырга исәбе юк. Ул аксыл япманы ерткалый-ерткалый җирдән кубарды, аннан соң күккә чөеп менгерде дә тау ягына куарга тотынды. Офык акрынлап киңәя барды, инде әнә, әрәмәлекләр ачылды. Ширәмәт тавының карга оясыдай җәлпәк түбәсе пәйда бул-

ды. Баязит урамга чыкканда, кояшның кызгылт шәүләсе сәләмә болытлар арасыннан күренеп-күренеп ала иде инде. Башын артка чөеп бермәл шушы тамашаны күзәтеп торды өлкән прораб. Машина килми дә килми. Җәяүләп бара торуың хәерлерәк, дип уйлады ул. Тик шунда ук бу уеннан кире кайтты, АЭС дирекциясенә кереп чыгасы бар ич әле аның, кем әйтмешли, ятып калганчы атып кал.

Дирекция биш катлы торак йортның беренче катына урнашкан. Бинаның сул канатындагы тәрәзәне зурайтып, ишек ясаганнар, юан-юан тимер торбалардан баскыч әмәлләп куйганнар, тар, караңгы коридорның ике ягына бүлмәләр тезелешкән. «Менә иҗ! Үзләре дә проектны үзгәрткән: нинди мәһабәт йортны тавык кетәгенә әйләндереп бетергәннәр».

Монда аның Василий исемле сабакташы эшли. Институтта бергә укыдылар. Василийның, гадәттәгечә, авызы ерык иде.

— Слушай, мыек килешә икән иҗ сиңа,— дип тезеп китте тел бистәсе,— үзем дә үстереп караган ием, малай каныкты бит каһәр, берәмтекләп йолкый, ут борчасыннан ким түгел инде мәгәр.

— Йомышым бар иде сиңа, Вася,— дип бүлдерде Баязит.

Кабинет хуҗасы, аксыл керфекләрен челт-челт йомгалап, дустына карап торды, аннан соң авырсынып кына урындыгына чумды. Баязит гозерен сөйләп бирде. Василий өстәл тартмасыннан мунчалага әйләнеп беткән кәгазь төргәге тартып чыгарды да:

— Проектны Ленинградта эшләделәр, менә кара, аны бозып булмый,— диде.

— Анысы заказчыдан тора.

— Һи, слушай, проектка үзгәреш кертергә теләүчеләр син генә мәллә?!

— Склад өчен дә урман турыйбызмы инде?

— Исең киткән икән иске чикмәнгә, урман түгел, авылларны да күчерәбез әле...

Машинада да шушы уй тынгылык бирмәде Баязитка. Урманнарны кешеләр матурлык өчен генә утыртмыйлар иҗ. Җир-ана вакытыннан элек таушалмасын, көче кимеп, яраксыз хәлгә килмәсен, киләчәк буыннарга да ашы җитсен өчен тырышу лабаса бу. Туган ил, Ватан төшенчәсе авылдагы каеннардан, елга-таулардан башлана дип тә әйтәбез үзебез.

...Алар авылында да бар иде шундый изге урын. Өянке яланы, дип йөртәләр иде аны. Хак булса, элекке заманнарда монда бәллүр сулы күл җәйрәп яткан, имеш. Тик аны тәгаен гына хәтерләүче юк хәзер. Яланның нәкъ уртасында, чукларын җилфердәтеп, өч-дүрт колачлы мәгърур өянке үсеп утыра. Ел саен яшен ата аны, кәүсәсе коры сөяк кебек калтаеп, җыерчыкланып беткән, ә үзе бернигә карамыйча яши дә яши. Җәен анда шау-гөр тынып тормый, көндез бала-чага туп тибә, кичләрен яшь-җилкенчәк җыела. Озату-каршы алулар да шушында үтә. Баязитлар армиягә киткән чакта да туганнары, авылдашлары белән өянке яланында саубуллашканнар иде. Хезмәтен тутырып кайтканда, өянке дә, ялан да юк иде инде. Авыл — койрыгын кискән әтәчкә охшап калган. Күп тә үтми, Баязит укырга китеп барды, яшьләрнең башкалары да таралышты, авыл бушап калды. Картлар моны өянке яланын сөрүгә сылтыйлар...

— Әйберләрне кайда бушатабыз? — диде шофер.— Ары китәргә булса, сезне юл чатында төшереп калдырам.

— Йөкне?! Ә, монда, монда, әйдә, борыл!

Баязит кила-килешкә кешеләр янына ашыкты. Ләкин аны кычкырып туктаттылар. Берәү белән дә бәхәскә кермәүче, сүз тыңлаучан Сабирҗан исемле бригадир иде бу. Баязит, ни сәбәпледер, аны ошатып бетерми. Нигә шулай, сорасалар аңлатып та бирә алмас иде, мөгаен. Югыйсә, шатланырга гына кирәк, чөнки төзелештә нәкъ менә шундыйлар, оран салмый гына үз вазифаларын җиренә җиткереп башкаручылар җитенкерәми.

— Нәрсә бар? — диде Баязит.

— Әле генә рациядән хәбәр иттеләр — Галимуллин килә!

Иртәнге сөйләшүдән соң Галимуллинның участокка килеп чыгуы бер дә гаҗәп түгел иде. Ләкин Баязит нигәдер каушап төште: әллә урманны үзе карап торып кырдырмакчымы? Булыр аннан, бик үзсүзле күренә.

— Әнә, килеп тә җитте инде,— диде бригадир һәм, аю кебек аумаклый-аумаклый, машина ягына атлады.

Галимуллин аны кочаклап ук алды.

— Егет кеше син, Сабирҗан, яратам шундыйларны, ә эчтә бүреләр улый, брат, бүген эчкә бер кабым ризык кермәгән, каткан сыныкларың юкмы шунда?

— Бар, Мөхәммәт Галиханович, ник булмасын, хәзер әмәллибез аны.

Будкага кергәч, Сабирҗан өстәлгә иске газета җәеп, аның өстенә май ягылган зур гына телем ипи, ике-өч йомырка, колбаса кисәкләре чыгарып куйды. Галимуллин кыстатмыйча гына сөйләнә-сөйләнә ашарга тотынды. Ризыкның тәмен тоеп, ләззәтләнеп ашый, колаклары гына түгел, керпе энәләредәй тырпаеп торган чәчләренә кадәр

селкенә үзенең. Кабинеттагы утчәчәр начальникка бөтенләй охшамаган иде ул, хәтта йөзе дә, күзләре дә яктырып, нурланып киткәндәй тоела, алыштырып куйганнар, диярсең. Аягында Сабирҗанныкы кебек озын кунычлы итек, шакмаклы күлмәге өстеннән куртка киеп җибәргән, изүе ачык, чалбарының тез туры бүлтәйгән. Гадилек килешә икән аңа!

— Ә без, Бәширов, беләсең килсә, Сабирҗан белән ун елдан артык инде бергә эшлибез, төрлесен күрдек: БАМы, КамАЗы, ГЭСы калмады.

Сабирҗанның саргылт кашлары җыерылып маңгаена менде, күзләре төймәдәй түгәрәкләнеп алды:

— Рәхмәт инде, Мөхәммәт абый...

— Тайгада адашып йөрүләрне хәтереңә төшергәлисеңме соң?

— Ул чакларны онытсаң, аяз көнне яшен сугар, әйтергә генә ансат, атна буе вертолет белән эзләгәннәр бит.

Галимуллин белән бригадир арасындагы эчкерсез дустанә мөнәсәбәт, аларның мавыктыргыч язмышы Баязитны да кызыктырды. Ике төзүченең узгандагы хәлләрне сагынып искә алуларын ул мөкиббән китеп тыңлап торды, тыңлаган саен аларга ихтирамы арта барды. Ындыр артындагы Идел даласы түгел иде инде бу сиңа! Баязит шуның белән мактанмакчы иде бит әле. Оят, валлаһи. Үзсүзле, дорфа, имеш, эш вакытында төрлесе була.

Галимуллин, ашап туйгач, кәгазь кисәге белән майлы иреннәрен сөртеп алды да:

— Хәзер хуҗалыгыгызны күрсәтегез инде,— диде.

Баязит җитәкчелегендәге төзүчеләр промбазаның вакытлы корылмасын салалар. Монда сантехник җиһазлар сакланачак. Ләкин кайбер материаллар җитешми, шуңа күрә бераүләр вак-төяк эш белән мәшгуль. Болай планны үтәп булмый, әлбәттә. Бер үк вакытта әлеге бинаһая зур таш складны төзи башласаң, эш муеннан булачак. Мондый калҗа һәркемгә тәтеми. Өлкән прорабның шуны аңламавына тузына Галимуллин.

Идарә башлыгы һәркем белән диярлек кул биреп күреште, якын танышларыдай хәл-әхвәл сорашты.

— Я, баһадир, безгә нинди дәгъваларың бар, әйтеп җибәр әле,— диде ул бастырыктай юан беләкле, кыска муенлы дәү гәүдәле төзүчегә. Тегесенең дә сүзе күптән әзер икән.

— Безнеке билгеле инде, теге... сәмән ягы саерак бит әле, кысалар дип әйтимме, бәлки ялгышамдыр, безнеке ни... шул инде, иптәш Галимуллин.

— Дөрес,— дип күтәреп алды аны берничә кеше.

Шул вакыт Галимуллин каршына зәңгәр күзле сары чәчле хатын чәчрәп чыкты.

— Боларга, иптәш начальник,— дип тәтелдәргә кереште ул,— капчыклап бирсәң дә җитмәс, әнәтерәк, шул кадәр бирән булсалар да булырлар икән, һәммәсенең машинасы бар, фатир, һаман аз, һаман җитми.

Баязитка ничектер уңайсыз булып китте, ни пычагыма тәгәрмәчкә таяк тыгам соң әле мин, дип уйлады ул, проект өлешләп булса да расланган, җавабын аңа бирәсе түгел, өстәвенә, АЭС — бик катлаулы корылма, объектлар технологик яктан бер-берсенә тыгыз бәйләнгән, бер буынны үзгәрттеңме, башкаларына зыян килүе бар.

— Төзүче хатынына акчаны учлап алып кайтып бирергә тиеш,— диде Галимуллин, әлеге бәхәскә нокта куеп,— урманны ега башларга кирәк, акча үзе кесәгезгә керәм дип тора.

Галимуллин китеп барды, машинасы артыннан купкан тузан болыты да күптән җиргә ятты, ә Баязит әле һаман басып тора.

— Баязит Әхмәтович, тәвәккәлләдекме?— диде Сабирҗан.

Баязит аксыл кәүсәле шырпыдай төз тирәкләргә күз төшерде. Алар ниндидер хәвеф киләсен сизенгән кебек бер-берсенә сыенышып тын калганнар, ара-тирә куркынган яфраклар гына серләшеп ала.

— Юк, бригадир, рөхсәт бирмим, аңлыйсыңмы, бир-мим!

* * *

Кичке якта Баязитны идарәгә чакыртып алдылар. Галимуллин үзе юк иде, приказны нечкә билле кыз тоттырды. Приказ өлкән прораб Бәшировны эш максатларында вакытлыча икенче участокка күчереп тору турында иде. Барысы да уйланылган, бәйләнергә бернинди урын юк.

Баязит шытырдап торган саргылт кәгазь кисәген учына йомарлады да, ләм-мим әйтмичә бүлмәдән чыгып китте. Күңелен ниндидер сәер битарафлык биләп алган иде аның. Тулай торакка кайткач та киенгән килеш ятагына ауды. Шактый вакыт бернәрсә хакында да уйламыйча түшәмгә карап ятты. Мәдинәсе исенә төшкәч кенә, йөрәге

сыкранып куйды, сикереп торды да чемоданын тутыра башлады. Әле ярый ул килеп җитмәгән иде дип куанды Баязит, югыйсә, иренең итек олтанына да яраксыз бер хөрәсән, бушкуык икәнен күрсә күңеле төшәр иде.

Кемдер ишек шакыды. Василий икән.

— Тешең сызлыймы әллә, слушай, йөзең сытылган,— диде ул хәйләкәр генә елмаеп.

— Әйе лә, аналгинны таба алмый изаланам,— дип, дусты сузган җепкә тотынды Баязит.

— Даруны чемоданда тотсаң, шулай ул.

Василий көлемсерәп колак артын кашып куйды һәм стенага эленгән кечкенә агач тартмадан таблетка алып, аны сабакташына сузды:

— Мә, тот, миннән күр игелек.

Баязит чемоданын кровать астына шудырды.

— Кеше белән әрепләшкән саен болай чемоданга ябыша торган булсаң, белмим, төзүче чыгар микән синнән?

— Кем әйтте?

— Андый хәбәр космик тизлек белән йөри.

Василий ашыкмый гына өстәл өстендәге графиннан су агызып эчте, аннан соң кулларын артына куйган хәлдә ишекле-түрле йөренеп алды.

— Шешә авызыннан сөт эчкәнең бармы синең? — дип сорады ул искәртмәстән.— Беренче йотымда ни эләгә, ә? Кай-мак! Соңыннан шешәне уптым илаһи бушатсаң да, хикмәт юк инде, дускай. Мәнә шул беренче йотымны ифрат яратучылар бар бу фани дөньяда.

* * *

Галимуллин белән өлкән прораб арасындагы низагны төрле кеше төрлечә бәяләде. Аны күпертеп, үзләреннән өсти-өсти сөйләүчеләр дә булмады түгел. Һәр мәсьәләне үз дигәнчә, ләкин чама белән генә хәл итәргә күнеккән Галимуллин исә чын-чынлап куркуга төште, бу аның абруена кизәнү ләбаса, әйе, кизәнү. Юк моңа һич тә юл куярга ярамый. Галимуллин исеменә тап төшәргә тиеш түгел, кирәк чаклары алда әле аның дип уйлады ул, урман тезмәсе имеш. Себердә әнә, шәмдәй төз әрбет агачларын да гектарлап кына аударалар иде, чөнки план үтәргә кирәк.

Галимуллин кесәсенән валидол алып тел астына салды, бу арада йөрәге бимазалап тора. Ләкин аңа тынычланып утырырга туры килмәде, телефон шалтырады. Станция дирекциясеннән икән.

— Складка тотынмый торыгыз әле, Мөхәммәт Галиханович,— диде директор урынбасары, үзгәреш кертергә туры килер, мөгаен.

— Шул бушкуык сүзенә карапмы?

— Кызма әле, Мөхәммәт Галиханович, проект ашыгыч төзелде, ялгышларны эш барышында төзәтергә туры килә.

— Безгә эш фронты кирәк, аңлыйсыңмы, эш фронты,— дип кычкырды Галимуллин.

Ул ачуыннан валидол сәдәфен йотып җибәрде һәм шунда ук йөзе чытылды, бал тәме күңеленә тия иде аның. Балдан битәр торгынлыкны яратмый идарә башлыгы, аңа шөгыль, зур-зур мәсьәләләр хәл итү кирәк. Склад урыны турында бәхәс купкач та бер оешмадан икенчесенә чапты, ләкин сүзен өскә чыгара алмады. Шулай да планны үтәтте, төп көчләрне тиз генә шәһәрне су һәм пар белән тәэмин итәчәк станция төзелешенә күчереп, җитешмәгән материалларны үзе заводта куна-төнә ятып эшләттерде, чын мәгънәсендә буран уйнатты ул бу көннәрдә, үҗәтлек күрсәтте.

Яшерен-батырын түгел, Баязит аның булдыклылыгына бераз көнләшеп тә карый иде, шул ук вакытта горурлана да, чөнки җыелышларда аларны мактап телгә ала башладылар.

* * *

Июнь аен җиткерә алмый азапланды Баязит. Көткәндә шулай бит ул, көннәр акрын уза. Телеграмма килеп төшкәч, тынычлыгын бөтенләй җуйды. Саратовтан самолет көндезге берләрдә генә киләсе булса да, аэропортка кич тән үк элдертте. Сагынган иде ул Мәдинәсен. Самолет ишегеннән хатынының ыспай гәүдәсе күренүгә, дежур кызны бер читкә этәреп, шул якка йөгерде.

Мәдинәсен ул траптан ук җитәкләп алды, алды да беркемгә игътибар итмичә аның хуш исле чәчләрен, шомырттай кара күзләрен, кабарып торган иреннәрен үбә башлады.

Тәртипсезлеге өчен Баязитны орышырга килгән дежур кыз бер мәл алар янында басып торды да кулын селтәп китеп барды.

Бу көнне алар хәзер генә өйләнешкән яшьләр кебек иркәләнеп-назланып үткәрделәр. Иртәгәсен өлкән прораб таң белән эштә иде инде. Ул туп-туры Сабирҗан бригадасына юнәлде. Бригада су һәм пар станциясе бинасының терәк балкаларын монтажлый башлаган иде. Бу эштә кечкенә генә төгәлсезлектән дә зур күңелсезлек чыгаруы ихтимал. Хәзергә эш мактанырлык түгел, ник дисәң, әлеге дә баягы материал җитешми, балкаларның яңа өеге һаман юк. Өлкән прорабны иң борчыганы шул иде.

Ләкин хафалануы юкка гына булган икән. Монтажчы егетләр инде күптән менеп кунаклаганнар, ерактан алар телеграф чыбыгына тезелешкән кошларны хәтерләтәләр. Җирдәгеләре дә ыгы-зыгы килә, бетон кабул итәләр. Гөрләп эшләп утырган машина цемент боткасын беләк юанлыгы сыгылмалы көпшә аша тимер челтәрле нигезгә кудыра.

Баязитның кәефе болай да шәп иде, боларны күргәч, күңеле тагын да үсеп китте.

— Шактый эш майтаргансыз сез монда,— диде ул, Сабирҗанның киң җилкәсеннән каккалап. Тегесе сирәк тешләрен ялтыратып елмаеп җибәрде.

— Моңарчы йөзгә кызыллык китергән юк ие әле, Баязит Әхмәтович.

— Түбән камалылар да сүзләрендә торган икән, ә!

— Торыр, кот алардан!

— Ник? Бу балкаларны каян алдыгыз соң?

— Тегеләр инде...

Шул сүзне ишетүгә Баязит бригадирның изүеннән эләктереп алды:

— Кем кушты?

Сабирҗан куркуыннан калтыранып төште, өлкән прорабның мондый ачулы чагын күргәне юк иде әле аның.

— Мө-ө-хәммәт Га-а-алиханович...

— Үзең утырган ботакка балта чабу ич бу, аңлыйсыңмы!

Үтә чыдам һәм гаять кыйммәтле әлеге балкаларны Тольятти шәһәрендә генә ясыйлар. Аралар ерак. Заказ биргәнче, алып кайтканчы, ярты еллап вакыт үтә. Менә хәзер бөтенләй төп башына утырып калдылар, чөнки бүген-иртәгә станция бинасының машина залын монтажлый башларга торалар иде... Их, Галимуллин, Галимуллин!

Баязитның тәмам ачуы чыкты, тиз-тиз генә җыенды да идарәгә юнәлде. Галимуллин белән аңлашырга кирәк иде. Әмма идарә башлыгын урынында очрата алмады, шуңа күрә трест управляющие урынбасарының ишегеи шакыды.

— Ә мин сине төзелештән эзләтәм, панимаешь,— дип каршылады аны урынбасар.— Әйдә, уз, утыр!

Озын буйлы, ябык чырайлы бу кешене төзелештә бик ихтирам итәләр иде, аның барны — бар, юкны юк дип, өздереп әйтүе ошый иде кешеләргә, ни дә булса эшләргә алына икән, таш яуса да, очына чыга.

— Мөхәммәт Галихановичны эзләп йөрү иде,— диде Баязит, дулкынлануын тыя алмыйча,— ничек шулай мөмкин?

— Аның турында сөйләшергә соң инде. Галимуллин яңа төзелешкә...

Урынбасарның сүзен бүлеп телефон шалтырады. Ул кем беләндер бәхәсләшә-бәхәсләшә сөйләшергә тотынды. Баязит читтәге урындыкларның берсенә барып утырды. Шунда кылт итеп сабакташының шешәле сөт турындагы кинаяле мәзәге хәтеренә төште. Тукта, тукта, беренче йотым дигәне яңа төзелеш булып чыга түгелме соң? Күпме баш ватып йөрде бит, әй, баксаң, гади генә табышмак икән. Сер түгел, һәр төзелешнең баштагы чоры — сөт өстенә утырган каймак ул: акчасы да, даны да. Димәк, Галимуллин Кама аръягына сызган. Анда хәзер зур завод кора башлаячаклар, имеш. Көт тә тор, атна-ун көннән Сабирҗаннар да кузгалачак.

Урынбасар трубкасын куйды.

— Без сине, Баязит Әхмәтович, Галимуллин урынына тәкъдим итәргә уйлыйбыз,— диде ул җитди генә,— сынау срогы белән, әлбәттә.

Көтелмәгән бу хәбәрдән Баязитның тез буыннары йомшарып төште. Урамга чыккач та өянәге тоткан хастадай стенага сөялгән хәлдә озак кына басып торды. Күңелен шатлык, шик-шөбһә, икеләнү хисләре биләп алган иде: булдыра алырмы, аклармы ул бу олы ышанычны, Мәдинәсе ни әйтер?

Ә тирә-як гөж килеп, кайнап тора. Зәңгәр күккә ашкан краннар бер урында бөтергечтәй бөтереләләр, җирне дер селкетеп әледән-әле куәтле машиналар узып китә, шуларга кушылып кешеләрнең хор авазлары, күңелле җырлары яңгырап ала. Бер генә минутка да тынып тормый, язгы ташкындай, йөрәкләрне ашкындырып, гөрли төзелеш.

**Флүн Мусин**

# КҮРКӘМ БӘЙРӘМЕБЕЗ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Без туган әдәбиятыбыздагы олы бәйрәмнәр елына аяк бастык. 1986 ел — Габдулла Тукайның, Фатих Әмирханның тууына 100 ел, Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулу елы һәм әле тагын күп кенә әдәби юбилейлар елы. Шушы күркәм бәйрәмнәрнең түр башында булырлык тагын бер юбилей бар. Быел яңа, реализм заманы татар әдәбиятына нигез салган, аның беренче карлыгачы булган әсәр — Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы дөнья күрүгә 100 ел тула. Рус әдәбиятындагы: «Без Гогольнең «Шинель»еннән чыктык»,— дигән мәгълүм фикерне бездә менә шушы әсәргә карата әйтергә мөмкин. Әйе, М. Акъегет романы яңа заман татар прозасының гына түгел, бәлки мәгърифәтчеләр башлап җибәргән бөтен реалистик әдәбиятыбызның программ характердагы беренче әсәрләреннән булды. Аңарда чагылган идеяләрне һәм проблемаларны күп кенә татар әдипләре күтәреп алдылар, үстерделәр. Әдәбиятыбыз тарихында якты эз калдырган бу романның бер гасырлык юбилеен билгеләп үткән көннәрдә безнең алга бу тарихның әле моңа кадәр ныклап өйрәнелмәгән кайбер мөһим теоретик мәсьәләләре дә ачыграк булып баса. Филология фәннәре докторы Ф. Мусинның сезнең игътибарга тәкъдим ителә торган мәкаләсе шушы юбилейга һәм татар романы тарихына караган кайбер мәсьәләләргә багышлана.

Туган әдәбиятыбыз тарихында мөһим вакыйгага булган датаны — Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла»сы дөнья күрүгә тулы бер гасыр тулуны билгеләп үткәндә барыннан да элек татар романы тарихын өйрәнүгә игътибар итү сорала. Монда беренче чиратта романның ничек формалашуы мәсьәләсе алга баса. Гәрчә бөтенсоюз һәм дөнья әдәбият фәнендә бу мәсьәләгә дикъкать соңгы вакытларда бермә-бер көчәйсә дә, бездә әле ул моңа кадәр ничектер күләгәдә калып килде. Хәлбуки, романның формалашу тарихын өйрәнүнең әһәмияте зур. Эстетик планда гына түгел, бәлки идеологик яссылыкта да. Мәгълүм ки, реализмга каршы көрәштә буржуаз модернизм тарафдарлары үз һөҗүмнәрен еш кына роман жанрына юнәлтәләр, аның үткәненә һәм киләчәгенә пессимистик яки нигилистик карашларны алга сөрәләр. Чөнки роман язмышы ул байтак дәрәҗәдә реализм язмышы булып тора. Романның формалашуы да реализм әдәбиятының туу һәм җитлегү процессын ачыграк күзалларга булыша.

Роман тарихын өйрәнгәндә соңгы вакытта бу тарихның вакыт чикләрен киңәйтү күзгә ташлана. Элеккерәк елларда Гегельнең: «Роман — ул яңа заманның буржуаз эпопеясы» дигән сүзләренә таянып, бу жанрның формалашуын капитализм чоры белән бәйләп карау киң таралган иде. Ә инде борынгырак чорларга караган роман тибындагы әсәрләр бу жанрның башлангыч формалары гына дип бәяләнделәр. Соңгы еллар хезмәтләрендә (Михайлов А. Д. Французский рыцарский роман и вопросы типологии жанра в средневековой литературе. М., 1976; Гринцер П. А. Две эпохи романа.— Генезис романа в литературах Азии и Африки. М., 1980; Мелетинский Е. М. Средневековый роман. Происхождение и классические формы. М., 1983.) мондый караш тәнкыйть астына алына, әлеге жанр тарихын антик роман, урта гасыр романы һәм яңа заман романы чорларына бүлеп карау идеясе яклана. Дөрес, әлеге авторларның ул чорлар арасында эстетик тигезлек куярга омтылулары шактый бәхәсле. Аннан соң антик роман гына түгел, урта гасырныкы да бөтен регионнарда да табылмый. Мәсәлән, урта гасыр романы үрнәкләре гарәп илләрендә бөтенләй диярлек очрамый, ә фарсы һәм төрки тел әдәбиятларында ул, киресенчә, зур гына үсешкә ирешә. Бу регионда әлеге чор романчыл эпосы еш кына шигырь белән языла. Урта гасыр көнчыгыш романчыл эпосының классик үрнәкләрен Низами поэ-

малары тәшкил итә. Романның аңа кадәр булган яки аның белән янәшәдә яшәгән башка эпик формалардан аерып торган төп үзенчәлекләреннән берсе шунда: аңарда игътибар этник коллективтан аерыла башлаган яки инде аерылган һәм мөстәкыйльлек алган геройның шәхси язмышына, эчке кичерешләренә, гомумән, хосусый тормышына юнәлдерелә. Персонажның иҗтимагый-рухи үсеше күрсәтелә башлый.

Урта гасыр романына хас булган мондый тенденцияләр, инде әйтелгәнчә, Низами поэмаларында ачык күренә. Аларда романчыл фикерләүнең көчәюен галимнәр, аерым алганда, Фирдәүси поэмалары белән чагыштырып ачалар. Мәсәлән, «Шаһнамә» әле романчылыкка дәгъва итми, чөнки аңарда авторны Хөсрәү белән Ширинның күбрәк патшалык сыйфатлары, власть мәсьәләсе кызыксындыра. Низаминың «Хөсрәү вә Ширин»ында исә геройларның шәхси-әхлакый мөнәсәбәтләрен ачуга басым ясала. Бу мөнәсәбәтләрнең конфликтлар аша үсүен, камилләшүен күрсәтү әсәрнең төп романчыл сюжет сызыгын тәшкил итә. Әлбәттә, урта гасыр романы геройны сурәтләүдә әле яңа заман романыннан шактый аерыла. Аларның беренчесендә герой башлыча легендар материалга нигезләнеп, миф һәм фольклор (әкият) поэтикасын турыдан-туры файдаланып күрсәтелә.

Шундый төр урта гасыр романының беренче үрнәкләреннән итеп безнең әдәбиятта Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» романчыл поэмасын санарга мөмкин. Әсәр авторның үз заманы алга куйган идея-эстетик таләпләрне яхшы белеп һәм шул дәвер дөнья әдәбиятының иң күркәм үрнәкләре югарылыгында иҗат итүе турында сөйли. Традиция буенча дини-мифологик материалга нигезләнеп язса да, Кол Гали үз кыйссасын реаль тормышка якынайтырга, «җирләштерергә» тырыша. Шушы максатта ул әсәрендә үз дәвере тормыш-көнкүрешенең төрле-төрле күренешләрен, гореф-гадәтләрен, эш-гамәлләрен чагылдыра, җәмгыятьнең төрле катлау вәкилләрен саран, әмма җанлы тасвир ярдәмендә күз алдына бастыра. Абстракт мифологизмнан арынырга һәм хикәяләүнең дөньявилыгына омтылу геройларны сурәтләүдә тагын да көчәя төшә. Мәсәлән, үзәк герой Йосыф мифологиягә хас илаһилык сыйфатларыннан шактый арындырылган. Тикшеренүчеләр әйткәнчә, ул Кол Галидә — «иң нечкә хисләргә, акыл көченә, шатлык һәм хәсрәт тойгыларына, турылыклы мәхәббәт кичерешләренә ия булган җир кешесе, яхшылыкны яклаучы, явызлыкка яхшылык белән җавап кайтаручы, ил, халык турында кайгыртучы, шул юнәлештә чаралар күрүче» (Татар әдәбияты тарихы, алты томда. 1 том. Казан, 1984, 131 бит.) Хәтта Йосыфны идеаль дәүләт башлыгы, хөкемдар итеп тасвирлаганда да Кол Гали аның шәхси-әхлакый йөзен ачуга игътибарын киметми. Геройны хосусый планда сурәтләгәндә автор, әлбәттә, аның башкалар белән шәхси мөнәсәбәтләрен ачуга басым ясый. Йосыфның этисе Йагкуб белән, абыйлары белән үзара мөгамәләләрен яктыртуга зур игътибар бирелә, биредә һәр ике якның мораль-этик сыйфатлары калку булып гәүдәләнә. Урта гасыр романында геройны тасвирлауда һәм бәяләүдә аны мәхәббәт җирлегендә күрсәтү аеруча мөһим урын тота. Кол Гали дә бу традициягә турылыклы. Мәхәббәт планында Зөләйха образы тәэсирлерәк итеп гәүдәләндерелә. Чөнки ул Йосыфка карагандә тирәнрәк һәм каршылыклырак уй-кичерешләргә дучар була. Алай гына түгел, ул мәхәббәт фаҗигасен кичерә. Башта Йосыфка булган тирән һәм көчле, әмма җавапсыз мәхәббәте аны нык газаплый, ул вакытыннан элек сукырая, картая. «Кырык ел буе синең дәртеңдә янып шушы хәлгә төштем»,— ди ул Йосыфка. Кыскасы, мәхәббәттә Зөләйханың эчке дөньясы аның сөйгәненекенә караганда да тирәнрәк ачыла. Болар барысы Зөләйханы чын мәгънәсендә урта гасыр романы героинясы итәләр. Мифологик фигураны роман герое итүдә тагын Йосыфның этисе Йагкуб образы игътибарга лаеклы. Әгәр борынгы сюжетта Йагкуб башта зур ыру башлыгы, ә соңыннан яһүд һәм ислам диннәрендә пәйгамбәр рәвешендә тасвирланса, Кол Гали әсәрендә ул семья башлыгы, бала җанлы ата булып алга баса, автор аның шушы шәхси сыйфатларын ачуга басым ясый. Героенның мондый сыйфатларын Кол Гали бик үтемле детальләр ярдәмендә ача. Сөйгән улын югалткач, аның:

Егълый-егълый ике күзе күрмәс булды,
Көчсезлектән буыннары тотмас булды,
Бернинди дә эшкә көче җитмәс булды...

«Берәзлексез Йосыф диеп егълаганга» Йагкубның «яшь урынына күзеннән кан агар», шул хәсрәттән ул «авызына ризык капмас, бу җиһанга күзен ачып һичбер бакмас» иде.

Дини-мифологик материалны дөньяви максатларда, ягъни заман таләпләреннән чыгып файдаланып, легендар образларны «җирләштереп» һәм аларда үз чоры кешеләренең реаль уй-кичерешләрен, омтылышхыялларын чагылдырып, Кол Гали «Кыйссаи Йосыф»та урта гасыр романчыл эпосының күркәм үрнәген бирде. Ул дәвер әдәбиятыннан бу жанрның классик таләпләренә җавап бирерлек тагын бер әсәрне искә алырга кирәк. Сүз Котбның «Хөсрәү вә Ширин»е турында бара. Низаминың шул исемдәге атаклы шигъри романының иркен тәрҗемәсе булган бу әсәр татар әдәбияты тарихында мөһим урын тота. Алтын Урда составындагы Ак Урда ханы Тенибәккә һәм аның хатыны Мәликәгә багышлап язып, Котб оригиналның тормыш җирлеген шактый үзгәртә, вакыйгаларны Низами әсәрендә сурәтләнгән борынгы Иранннан үзе яшәгән Алтын Урда җирлегенә күчерә. Нәтиҗәдә хикәяләү

бермә-бер җырләшә, аның тормышчанлыгы, заманча яңгырашы көчәя. Котб үз әсәрендә җырле төрки халык авыз иҗатыннан актив файдалана. Болар барысы Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ен урта гасыр татар әдәбиятының романчыл эпос өлкәсендәге әһәмиятле казанышы дип карарга мөмкинлек бирә.

Шушындый күркәм уңышларга ирешкән урта гасыр романчыл эпосы, гасырдан-гасырга күчә килеп, алга табан, XIX йөздә яңа заман татар романының мөһим әдәби чыганакларыннан берсенә әверелә. Мәгълүм ки, соңгы вакытларда әдәбият фәнендә романның әдәби-эстетик чишмә башын ачыклауга игътибар артты. Тикшеренүчеләр биредә тагын халык иҗаты жанрларының зур роль уйнаганын күрсәтәләр. Төрки әдәбиятларда роман жанры туудa бу халыкларда киң таралган һәм бай традицияләре булган эпик форма — дастанның актив катнашуына дикъкать ителә. Татар халкының күпгасырлык авыз һәм язма иҗатында да дастан әһәмиятле урын тота. Биредә бездәге дастаннарның бер сыйфатына аеруча дикъкать итәсе килә. Мин аларның нигездә чәчмә хикәяләүгә корылуларын күздә тотам. Бу хәл, бер яктан, дастаннарга әкият йогынтысы белән аңлатылса (аларның кайберләре тора-бара әкиятләшеп тә киткәннәр), икенче яктан, аларга безнең әдәбиятта бик күптәннән яшәп килгән чәчмә хикәяләү традицияләре тәэсир иткән. Бу традицияләрнең әдәбияттагы роле турында сөйләгәндә бер гыйбрәтле факт искә төшә. Таһир һәм Зөһрә турындагы борынгы шигъри сюжет нигезендә XV гасыр шагыйре Сайяди поэтик әсәр «Дастаны Бабахан» поэмасын язса, XIX йөздә яшәгән Әхмәт Курмаши исә чәчмә әсәр — «Таһир илә Зөһрә» кыйссасын тудыра. Борынгы поэтик сюжетның шулай соңрак чәчмә әсәргә әверелдерелүе һәм укучылар арасында зур популярлык казануы һич тә очраклы хәл түгел. Киресенчә, бу факт соңгырак дәверләрдә татар әдәбиятында чәчмә хикәяләүнең тагын да көчәя төшүен күрсәтә. Чыннан да, XVI йөздән башлап бездә чәчмә хикәяләү бермә-бер активлаша. Ул төрле-төрле сәбәпләргә бәйле. Аерым алганда, бу чорларда татарларда дипломатик язышуларның, канцелярия эшләренең шактый активлашуы, тарих китаплары, һәртөрле елъязмалар, васыятьнамәләр, сәяхәтнамәләр, шәҗәрәләр күп язылу чәчмә хикәяләүнең әдәбияттa да роле үсүгә китерә. Шул ук вакытта бу төр язмаларның үзләрендә дә кайчак әдәбилек арту күзгә ташлана. «XVII—XVIII гасыр татар тарихи чыганаклары» дигән хезмәтендә М. Госманов шул дәверләрдә язылган тарихи китапларда (мисал өчен Кадир Галибәкнең «Җәмигъ әт-тәварихы»нда, аноним авторның «Дәфтәре Чыңгыз-намә»сендә, Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария»сендә) һәм шәҗәрәләрдә, башка кайбер халыклардагы шундый ук характердагы язмалар белән чагыштырганда, әдәби башлангычның шактый көчәюен искәртә һәм бу хәлнең конкрет тарихи сәбәпләр белән бәйләнгәнлеген әйтә. Кыскасы, аларда документаль төгәллек кимеп, матур әдәбиятка якынлык арта төшкән.

Татар әдәбиятында чәчмә хикәяләүнең (димәк, прозаның да) үсешенә тагын китап басу эше зур гына йогынты ясаган булырга тиеш. Мәгълүм ки, бездә бу эш 1800 елдан башлана, һәм басма китап бик тиз арада татарлар арасында зур популярлык казана. (Болар хакында Ә. Кәримуллинның «У истоков татарской книги» дигән хезмәтендә бай мәгълүмат бар.) Басма китап ярдәмендә проза яңа баскычка күтәрелә, сәнгатьтә яңа үрләр яулый. Ул роман жанры үсешенә аеруча нык тәэсир итә. Күренекле инглиз әдәбиятчысы Ральф Фоксның: «Роман... Ул китап басу станогы җимеше булып тора»,— дип белдерүе бер дә очраклы хәл түгел (Фокс Р. Роман и народ. М., 1939, 36 бит.). Дөрестән дә, дөнья әдәбиятындагы беренче басма китаплар романнар һәм повестьлар булганнар. Алар XVI гасыр урталарында Испаниядә дөнья күрәләр. Әйтергә кирәк, татар телендә чыккан беренче басма әдәби әсәр дә повесть була («Сәйфелмөлек», 1807).

Яңа заман татар прозасы, аның жанрлары формалашу өчен югарыда әйтелгәннәр ныклы әдәби-эстетик җирлек тәшкил иттеләр. Мәгърифәтче әдипләр тудырган бу прозага нигез салучыларның берсе К. Насыйри була. Аның әдәби иҗатында мәгърифәтчелек прозасының беренче һәм шактый үзенчәлекле адымнары чагылыш таба. Эш шунда ки, бу проза Көнчыгыш халыкларының борынгыдан килә торган традицион легендаларын яки язма әсәрләрен татарчага ирекле тәрҗемә итеп һәм эшкәртеп бирү юлы белән формалаша. Әйтергә кирәк, мондый иҗат мәгърифәтчелек әдәбиятының башлангыч чоры өчен табигый һәм зарури хәл булып тора. Бу уңайдан Г. Ибраһимов та яңа әдәбият формалашканда «һәр милләт тәрҗемәне оригиналдан да алда торганлыгы тарихта ачык күренә», дип язды. Әгәр башка күп кенә әдәбиятлар, мисал өчен, ул дәверда безгә иң якын булган рус һәм төрек әдәбиятлары тарихына гына күз салсак та, без аларда да мәгърифәтчелек прозасы беренче адымнарын ирекле тәрҗемәләрдән башлаганын күрербез. Рус һәм төрек прозаиклары башлыча француз мәгърифәтчеләре әсәрләрен тәрҗемә иткәннәр.

Үз заманының иң алдынгы һәм прогрессив карашлы эшлеклеләреннән берсе булган Ф. Әмирхан әйткәнчә, «күпгасырлык шәрык тәэсире белән килгәннән соң, акрын гына гәреп тәэсире астына» керә башлаган әдәбиятыбызның башында торган, татар халкын Европа, беренче чиратта прогрессив рус культурасына якынайту юлында армый-талмый эшләгән К. Насыйри исә үзенең әдәби иҗатында Көнчыгышның традицион сюжетларыннан киң файдалана. Әмма монда эш һич тә

күренекле мәгърифәтчебезнең традицияләргә турылыклы булырга теләвендә генә түгел. Төп сәбәпләрнең берсе, һичшиксез, К. Насыйриның үз фикерләрен, заманының яңа идеяләрен шул чор татар укучысына җиткерү өчен аеруча кулай әдәби чаралар һәм формалар эзләвендә. «Әбугалисина кыйссасы» һәм «Кырык вәзир кыйссасы» кебек Көнчыгыш дөньясында бик популяр төс алган, татар укучыларына да байтактан таныш булган әсәрләр К. Насыйриның әлеге максатларын тормышка ашыру өчен киң мөмкинлек биргәннәр. Көнчыгыш сюжетына нигезләнеп, ул «Афсанаи Гөлрох вә Камәрҗан» исемле роман да яза башлый, әмма аны тәмамларга өлгерә алмый кала.

Татар мәгърифәтчелек романының беренче һәм классик үрнәген исә М. Акъегет бирде. Шул ук вакытта аның 1886 елда дөнья күргән «Хисаметдин менла»сы гомумән яңа заман татар романының беренче карлыгачы булып тарихка керде. Әйе, бу әсәр һәм формасы, һәм эчтәлеге белән шул дәвер татар әдәбияты өчен яңа, новаторлык күренеше иде. Мәгърифәтче әдип анда татар халкының күпгасырлык авыз иҗаты һәм язма әдәби традицияләренә ныклап таяну белән бергә, бу традицияләрне Европа романы тәҗрибәсе белән баетты һәм шул нигездә Көнчыгыш белән Көнбатыш әдәби синтезын хасил итте. Шушы рәвешле туган шактый катлаулы һәм камил форма капитализм заманы алга куйган яңа зур идея-эстетик бурычларны яктырту максатына хезмәт итә. М. Акъегет беренчеләрдән булып буржуаз мөнәсәбәтләр юлына аяк баскан татар җәмгыятенең мөһим проблемаларын танып-белергә алына.

«Хисаметдин менла»да күтәрелгән үзәк мәсьәләләрнең берсе — шәхес иреге мәсьәләсе. Аны шул тарихи чор үзе көн тәртибенә куйган иде. 1861 елгы реформадан соң Россиядә буржуаз тәртипләр һәм мөнәсәбәтләр көчәя башлау татар җәмгыяте үсешенә дә йогынты ясый. Бу үсешнең мөһим бер күрсәткече булып шәхесне феодаль-патриархаль богаулардан азат итү өчен көрәш тора. «Хисаметдин менла»да нәкъ менә шушы көрәшне сурәтләү үзәк урын ала. М. Акъегет бу көрәшне тасвирлауга башлыча мәгърифәтчелек позициясеннән чыгып килә. Ачыграк әйткәндә, ул шәхеснең мәхәббәттәге һәм семьядагы азатлыгы өчен көрәшә. Романның үзәк геройлары Хисаметдин менла белән Хәнифә туташ та шулай аңлатылган шәхес иреге өчен көрәшәләр. Бер-берсен яратазн бу яшь егет белән кыз шул заман татар тормышының реаль шартларында күрсәтеләләр. Аларның бер-берсе белән кавышу юлларында бик тормышчан каршылыклар һәм киртәләр очрый. «Бәек вә бай адәмнәр арасына кереп әкърибалык вә руглык кәсеп» итү турында хыялланган Габбас ага белән Шәмси абыстай, кызлары Хәнифәне «вилаятьтә бөек һәм мәшһүр» сәүдәгәр Гали бай Җәматовның улы Сибгатуллага хатынлыкка сорап килгәч, бу тәкъдимгә шатланып риза булалар. Ә кызның ризалыгын сорап та тормыйлар. Хәнифәнең Хисаметдин менлага гыйшык тотуын белгәч исә кызларын үгет-нәсихәт һәм им-том ярдәмендә яраткан егетеннән биздерергә тырышалар. Нәтиҗәдә Хәнифә белән Хисаметдин үткәндәге кайбер әсәрләр, мисал өчен Ә. Курмашиның «Таһир илә Зөһрә» һәм «Буз егет» геройлары хәлендәрәк калалар. Әмма гашыйклар юлында хасил булган бу кыен ситуациянең хәл ителеше буенча «Хисаметдин менла» Ә. Курмаши әсәрләреннән шактый аерыла. Биредә М. Акъегетнең мәгърифәтчелек реализмы вәкиле булуы, шушы метод принципларыннан чыгып эш итүе аеруча нык күзгә ташлана. Ә. Курмаши кыйссаларында гашыйкларның язмышы фаҗигале рәвештә тәмамлана. Алар бер-берсеннән көчләп аерылдырылалар һәм аерылу газабын күтәрә алмыйча һәлак булалар. Хәнифә белән Хисаметдин менла язмышы исә мәгърифәтчелек реализмының мөһим принцибы булган рационализм рухында тасвирлана. Автор шәхес ирегенә беренче чиратта югары әхлаклы кеше ия булырга тиеш дигән карашта тора. Аның геройлары үзләре дә кешенең иң мөһим сыйфаты итеп әхлаклылыкны саныйлар. Кешене белү алар өчен аның әхлагын белү дигән сүз. Үзенең мәхәббәтен белдереп хат язгач, Хисаметдин менлага кыз башта кире җавап бирә. Чөнки ул егет аның тышкы матурлыгына гына гашыйк булган дип уйлый һәм: «Куәтле гыйшык икемезнең дә әхлак вә табигатемез беленгәч вөҗүдә кәлер»,— ди. Моңа Хисаметдин менла: «Газизә Хәнифә, синең ялгыз заһири кыяфәтеңә дәгел, хәсне әхлакыңа кәзалик гашыйк улдым»,— дип җавап бирә. Кызның әхлаклылыгын исә егет барыннан да элек аның мәгърифәтле булуында күрә. Аныңча, «яшьлектән гыйлем вә укымак сәүгән инсанның әхлак вә әфкяренең яман улмагы шөбһәледер».

Кыскасы, Хисаметдин белән Хәнифәне әхлаклы, димәк, мәгърифәтле затлар итеп күрсәтеп, М. Акъегет аларның тормышта үз теләкләренә ирешүләрен тасвирларга алына. Геройларның төп теләге исә шәхси ирекле булу. Хәнифәнең Сибгатуллага хатынлыкка бирeләчәге мәгълүм булгач, егет белән кыз арасында автор идеалын чагылдырган мондый сөйләшү була. Хисаметдин үз-үзенә нык ышанган хәлдә кызга болай ди: «Безем ихтыяр вә хөрриятемезне ала алмаслар. Җаным! Инсан мәгыйшәтендә бер баһалы вә яхшы шәй хөрриятер. Без үз хөрриятемезне саклый белермез.

— Хөрриятсез яшәмәк көч вә зәхмәт идекене бән дә белермен,— диде Хәнифә туташ».

Моннан соң Хисаметдин белән Хәнифәнең «хөрриятка», ягъни шәхси ирекккә ирешүләрен, барлык кыенлыкларны җиңеп кавышуларын һәм бәхетле семья коруларын автор аларны заман герое исеменә лаек итәрлек зур казанышлары дип бәяли. Күренә ки, яңа туып

килгән реалистик әдәбият өчен бик әһәмиятле булган, аның йөзен һәм үсеш юнәлешен билгеләгән герой мәсьәләсен М. Акъегет мәгърифәтчелек карашларыннан чыгып яктырта. Шушы карашлары белән бәйле рәвештә заман героеның тагын бер мөһим сыйфатын ул аның эшлеклелегендә күрә. Әдипнең бу сыйфатка дикъкать итүендә шул чорда татар дөньясына үтеп кергән буржуаз тәртипләрнең йогынтысы да бар, әлбәттә. Биредә автор реаль тормыштан чыгып фикер йөртә дияргә мөмкин. Хисаметдин шул заманның эшлекле герое булып алга баса. Яңа метод белән укытып, ул ике ел эчендә үзендә укыган балаларга «язу язмак, хат танымак, гыйльме хисап, гыйльме халь» өйрәтүгә ирешә. «Указной мелла» Бикбулатта укучы балалар исә шул вакыт эчендә көчкә-көчкә хәреф таный башлаудан ары китмиләр. Моның сәбәбе — Бикбулатның үз эшендә надан һәм булдыксыз булуында, гайбәт сатып, «тәзйигы гомер итеп» (гомерен бушка уздырып) яшәвендә. Уңган хәлфә, тәрбияче булудан тыш, Хисаметдин тагын «хәрәкәт вә кәсеп сәвән менла иде». Ул игенче эше белән дә бик теләп шөгыльләнә. Чөнки аныңча, «кәсеп вә эш шәригатә бинаән намаз вә уруҗ (ураза) кеби фарыз вә гыйбадәттер». Шушы фикергә иманган мәгърифәтче М. Акъегет башка уңай геройларының да эш сөючән һәм кәсепле затлар булуларына басым ясый. Хәнифә туку, тегү эшләрен ярата. Хисаметдиннең якын дусты, «ислам вә рус, гыйлем вә һөнәр китапларын укымага һәваскяр» булган Гайса Зурколаков бакырчылык эше белән шөгыльләнә. Әсәрдә гыйлемле һәм һөнәрле, булдыклы һәм эшлекле булу кебек сыйфатларның аерым кешеләргә генә түгел, бәлки бөтен милләткә кирәклеге турында сүз алып барыла. Автор үз фикерләрен заманының кайбер консерватив карашлары белән бәхәскә кереп әйтә. Әдипне бик тә борчыган шундый ялгыш һәм зарарлы карашларның берсе түбәндәгедән гыйбарәт: «һөнәркяр, мәгълүматлы кавем улмак, әлбәттә, яхшыдыр, ләкин татар милләте һөнәркяр ула алмас. Бик күп еллар кәчте, татар милләте зыяланмады... бу мөмкин дәгел». Татар халкының культура һәм профессиональ үсешенә мондый пессимистик карашка М. Акъегет кискен рәвештә каршы чыга, ә бу үсешнең хәзергә акрынрак баруын «әчемездә мәгълүмат таләпкярлыгы» җитмәү белән бәйләп аңлата. Шулай М. Акъегет мәгърифәтче әдипләр өчен тагын да мөһимрәк мәсьәләгә — милләт язмышы турында уйлануга килә. Биредә хикәяләүнең тоны да үзгәрә. Бу хакта автор турыдан-туры укучыга мөрәҗәгать итеп һәм публицистик пафос белән сөйли. Татар милләтенең рухи мөмкинлекләренә шикләнеп караган кешеләргә автор исеменнән сөйләүче гимназист Әбүзәр «ачыйгланып» болай мөрәҗәгать итә: «Уйганыңыз, кардәшләр! Уйганыңыз, бунын кеби гакылсыз дәлилләреңезлә үзеңездән келдермәңез! Бакыңыз башка милләтләрә, иштә французлара, иштә немецләрә; бунлар дәгел суда кимдә балык кеби йөзмәки, һавада кош кеби очмак машинасы төзә беләләр. Әммә безнең сукаламак илә вак сәүдәдән башка һөнәремез юк кебидер...» Шул нигездә әсәрдә мәгърифәтчел милләтпәрвәрлек (милләт мәнфәгатен кайгырту) идеясе күтәрелә. Әдипнең үзе өчен бик кадерле булган бу идея романда төрле сыйныф вәкилләре булган өч кешене — бәк улы Әбүзәрне, Хисаметдин менланы һәм теләнче егет Мохтарны бер-берсенә якынайта һәм дуслаштыра. Милләтпәрвәрлек идеясен яктыртуда М. Акъегет мәгърифәтче әдипләрнең мөһим карашларыннан берсен чагылдыра. Сүз мәгърифәтчеләрнең халыкны сыйныфларга аерып карамаулары, гомумән, милләт хакында сөйләүләре турында бара. Бу хәлне В. И. Ленин Көнбатыш Европа һәм рус мәгърифәтчеләре иҗат иткән чордагы иҗтимагый-социаль обстановка белән бәйләп аңлата: «XVIII гасыр мәгърифәтчеләре (гомуми танылган фикер аларны буржуазия юлбашчылары рәтенә кертә) язган вакытларда, безнең 40 нчы елдан 60 нчы елларга кадәр булган мәгърифәтчеләр язган вакытларда, барлык иҗтимагый мәсьәләләр крепостное правога һәм аның калдыкларына каршы көрәшкә кайтып кала иде. Яңа иҗтимагый-экономик мөнәсәбәтләр һәм аларның каршылыклары ул чакта әле яралгы хәлендә иде. Шуңа күрә ул вакытта буржуазия идеологларында үз файдаларын күзәтү һич булмады; киресенчә, Көнбатышта да, Россиядә дә алар бөтен кешенең рәхәттә яшәячәгенә тәмам чын күңелдән ышандылар һәм шуны чын күңелдән теләделәр, крепостной стройдан үсеп чыга торган стройдагы каршылыкларны чын күңелдән күрмәделәр (кисәкчә әле күрә дә алмадылар)». (Ленин В. И. Әсәрләр. Дүртенче басмадан тәрҗемә. 2 т. Казан, 1955. 498 бит).

Туып килүче буржуаз стройның сыйнфый каршылыкларын әле күрә алмаган М. Акъегет тә үз чорындагы татар җәмгыятен сыйныфларга бүлеп карамый, бөтен милләт турында кайгырта. Үзәк герой Хисаметдин менла исә «кәнду (үз) милләтене, ягъни татарларны чук сәвән адәм» итеп кенә түгел, бәлки «Россиядә сакин (яшәүче) ун миллион ислам кардәшләрене ядына» алган шәхес рәвешендә күрсәтелә. Милләтпәрвәрлекне, мәгърифәтчеләргә хас булганча, заманның иң мөһим идеалларыннан берсе итеп караган М. Акъегет бу идеал өчен көрәшүче үрнәге итеп патша Петр I не ала һәм аның бу өлкәдәге эшчәнлеген түбәндәгечә тасвирлый: «Бу падишаһымыз Петрның милләтпәрвәрлеге сәясендә Россиядә низамәте җәдидә вә ислахат (яңа законнар һәм реформалар) юлында тәбәтделат (алмашынулар) мәйданә чыкты. Хәзердә мәүҗәт университетлар, ягъни дарелфөнүннәр ачылды. Мәзкүр падишаһның милләтпәрвәрлеге сәясендә руслар диңгез

фәннәрен өйрәнмәя башлап, пароход вә хәреп көймәләре мәйданә чыкты. Руслар гыйльме механика, гыйльме техника өйрәнмәя башладылар. Олуг Петр милләтеннән бәһалы бер шәй белмәз иде. Башында һәрвакыт рус вә рус, вә рус иде. Диде ки, миллионнар илә русларым бәңа бер углымнан бәһалыдыр, мәйданә куйдыгым ислахат углым тарафыннан бозылса, русларым хәрабаты халә килмәсеннәр...»

М. Акъегет милләтпәрвәрлекнең әһәмияте турында сөйләп кенә калмый, бәлки үз геройларының сүздән эшкә дә күчүләрен күрсәтә.

Кыскасы, «Хисаметдин менла»да мәгърифәтчелек идеологиясенең һәм фәлсәфәсенең күп кенә мөһим положениеләре чагылыш таба. Шул ук вакытта әсәрдә мәгърифәтчелек реализмының һәм бу метод әдәбиятының әйдәп баручы жанрына әверелгән романның әһәмиятле сыйфатлары гәүдәләнә. Барыннан да элек, роман мәхәббәт-авантюралы сюжетка корылган. Әсәрнең бу жанр үзенчәлегенә аның беренче рецензенты булган профессор В. Д. Смирнов та игътибар иткән иде. Ул М. Акъегет романында «мәхәббәт тә, гүзәл кыз урлау да» булуын һәм мондый «романтик маҗаралар герое итеп яшь мулла» күрсәтелүен билгеләп үтә. (Записки Восточного отделения Императорского археологического общества. III—IV т. 1888, 97 бит.)

Авторның әсәрдәге актив роле үз уйфикерләрен турыдан-туры һәм публицистик пафос белән чагылдырып баруына кайтып калмый. Ул үзен хикәяләүдә, сюжет агышында да актив тота. Бу хәл бер вакыйгадан икенчесенә күчкәндә авторның шул хакта укучыга белдереп баруында еш күренә. Мәсәлән, әдип шәһәрдәге Габбас ага мөсафирханәсендәге хәлләр турында сөйләп килә дә, аннары укучыларга мөрәҗәгать итеп болай ди: «Н» карьясенә кайтамыз, хөрмәтле укучыларым. «Н» ханәләре кечек вә саламнан вә бәгъзылары агач тактасы илә ябылмыш улдыкларыны язмыш идек». Икенче бер очракларда автор укучының сөйләгәннәргә дикъкатен җәлеп итү өчен хикәяләүгә турыдан-туры катнашып китә. Менә бер мисал: «Бернечә көн кичте. Хәзердә белешемез Хисаметдин менла шәһәрнең тимер юл мәүкыйфендәдер (станциясендә). Фикереңезлә ахшам вакытларыны тасавыр итеңез (күз алдына китерегез), укучылар! Шәһәремезнең һәмма әһалисе мәзкүр мәүкыйфә тупланмышлар». Мәгърифәтче әдипләргә хас сыйфат — хикәяләүдә һәрвакыт укучы белән тыгыз контактта булырга омтылу, икенче яктан, халык иҗатына, аерым алганда, әкияткә барып тоташа. Мәгълүм булганча, милләт тормышына һәм язмышына игътибарларын арттырган мәгърифәтчеләр халык иҗаты белән дә якыннан кызыксыналар. Әдипләр исә бу иҗат белән кызыксынып кына калмыйлар, бәлки аңардан үз иҗатларында киң файдаланалар. Үз заманына хас булганча, гарәп, фарсы һәм төрки сүзләре белән чуарланган авыр телдә язган М. Акъегет тә әледән-әле хикәяләүгә:

> Каенсар төбендә кар булмас,
> Кайгылы йөрәктә май булмас,

яки:

> Ак эшләпә мамыктан, кызлар карый ярыктан,
> Карамас иде ярыктан, бер күрергә зарыккан,—

кебек саф татар халык җырларын, «эшләэшлә — әүвал җәфа, соңра сафа, сән бала, бән ана: баштан колак зур булмас» һ. б. мәкальләрне кертеп җибәрә, халыкчан чагыштырулардан («муртадан чыккан корт кеби», «үлек кеби агарып», «аучы куян вә үрдәкне өмет итеп сакладыкы кеби» һ. б.) оста файдалана.

«Хисаметдин менла»да әкиятләрдә үк башланып роман жанрында яңа сулыш һәм зур үсеш алган бер тенденция — геройларның шәхси тормыш-көнкүрешенә игътибарлы булу чагыла. Биредә тагын мәгърифәтчеләрнең реаль чынбарлыкка йөз тотып, аны башлыча көнкүреш рәвешендә аңлаулары зур гына роль уйный. Алар тормыш дөреслеген күбрәк көнкүрешне дөрес сурәтләүдә күрәләр. Шундый дөреслеккә омтылган М. Акъегет тә көнкүреш күренешләренә шактый игътибар бирә. Дөрес, ул, укучыларның «зиһеннәрен арытмактан чикенеп», бу күренешләрне тәфсыйлләп тасвирлауга омтылмый, еш кына саран буяулар белән эш итә. Әмма шунда да сурәтләү объектын яхшы белгән автор әлеге чынбарлыкның җанлы күренешләрен тудыра. Шул ук вакытта әдип өчен бу эшнең үзмаксат булмавы, билгеле бер идея-эстетик максатка хезмәт итүе күренә. Мәсәлән, Хәнифәне Сибгатуллага хатынлыкка сорарга килгән Бикбулат мулланы Габбас ага өендә сыйлау күренешен М. Акъегет «мөдәррис хәзрәтләренең» тәмле һәм күп ашарга күнеккән сорыкорт зат булуын ачу өчен файдалана: «Шурпалар, пылаулар кунаклар өчен кайнап-кайный, хәтта ки, мөдәррис хәзрәтләре йортка гизмәгә чыкканда, майлы ашларның кухусы вә исе ашханәдән борынына җитешеп, ләззәт хис улынып, деле тирәсеннән төкерек чыкты». Әсәрдә чагыштырмача тулырак сурәтләнгән туйга бару күренешендә булачак кияү Сибгатулла әфәнденең кыланышларын тасвирлауга бигрәк тә игътибар итеплә. Автор Гали бай малаеның башбаштак һәм дуамал зат булуын күрсәтә, моның өчен үтемле детальләр таба. Туй җәмгыяте урамнан үткәндә «мылтык атмактан, зәк вә кыңгырау тавышыннан колаклар агырар. Урамны тетен алды, санасәң ки (уйлыйсың) бер мохарәбә (сугыш) купты, алдагы каләсканең мылтыклары артыграк гөрелтәйөрләр, бу каләскәдә Сибгатулла әфәнде, кияү егетләре илә бәрабәрлектә, яшен кеби йөкерерләр».

Шунда ук автор бу дуамаллыкларның күңелсез нәтиҗәләрен дә күрсәтеп үтә. Бердән, урам аша чыгып барган эт, «өлгермәеп, каләскәнең көпчәкләре астында калып, уртага ярылып, эчәкләре һаваны бераз исләттеләр». Икенчедән, буза эчеп шактый кызган туйчы егетләр «табгиятлә порхны күбрәк салып мылтык аттыкларыннан бармакларыны яралмыш иделәр». Гомумән алганда исә, автор туй бәйрәменең бик күркәм күренеш булуын күрсәтә, моның өчен табигатькә дә дикъкать итә. Мәгърифәтчеләр тарафыннан табигый гүзәллекнең, гармониянең үрнәге итеп каралган саф табигать күренешләрен М. Акъегет нәкъ менә тормыш матурлыгын, яшәүнең күркәм милли традицияләрен эмоциональ көч белән һәм экспрессив рәвештә ачу максатында файдалана. Туйчылар авылдан чыкканда «көндез дүрт сәгатьләр вар иде. Көнәш (кояш) нур вә эсселекне чыбарланмыш кырларда чәчмеш иде. Яравой намле магруф кырларның күренеше пәк гүзәл иде: тәртипбәтәртип солы, карабодай вә тары игкмәкләреннән кырлар күзләрә кызгылт, аксыл, саргылт рәңдә күренерләр иде. Кырларның гүзәллеге шат туйчыларны янә шат итәр иде».

Тормыш-көнкүреш һәм табигать күренешләрен шулай җанлы һәм тәэсирле итеп сурәтләүдән тыш, М. Акъегет тагын геройларның тышкы портретларын оста гына бирә. Автор идеалы булып торган Хисаметдин менла белән Хәнифә тулаш портретлары, әлбәттә, идеаль төсләрдә тасвирлана. Менә Хисаметдин менланың портреты: «Йөзе гүзәл ачык. Яңадан чыкмыш кечек сакаллы вә мыеклары вә кечек чәче коңгырт рәңдә (төстә) улып, җәмаләтле йөзеннән гүзәллеген дәһа зиядәләштерерләр. Нурлы вә күк күзләре сәтрә-бәсәтра сәхифәгә китап битенең юлыннан-юлына йөгереп кәчәерләр. Башында бархат тәкъясының көмеш ае ялт-йолт ялтырар». Геройның матурлыгын М. Акъегет, мәгърифәтчеләргә хас булганча, аның килешкилбәтенең гармонияле, ягъни бар җире дә килгән булуында күрә. Хәнифәне тасвирлаганда автор үзенең бу карашын турыдан-туры белдереп үтә. Хисаметдин менланы да кызның матур киеме түгел, бәлки табигый матурлыгы, бөтен җире килгән булуы белән җәлеп итә. «Бу нәзек бил вә җәмилә кыз,— ди автор,— менланың күзенә тәмамән күренде». Ләкин әдип геройларын тышкы «тәмамәнлеге», ягъни гармониялелеге буенча гына бәяләүдән ерак тора. Аның шәхес идеалы — тышкы матурлык белән эчке матурлыкның тәңгәл килүе. Эчке матурлыкны исә М. Акъегет кешенең әхлаклы һәм мәгърифәтле булуында күрә. Әсәрнең үзәк геройлары менә шушы ике төрле матурлыкның органик берлеген тәшкил итүче шәхесләр. Гомумән алганда, М. Акъегет тышкы — «заһири» матурлык эчке — «батини» матурлыктан башка була алмый, алар бер-берсеннән аерым хәлдә яши алмыйлар дигән карашта тора һәм бу карашын Хисаметдин менла белән Хәнифә образларында ачык чагылдыра. Бу геройларның үзара органик бәйләнештә яшәгән һәм шуның белән башкаларга үрнәк булган тышкы һәм эчке портретларын мөмкин кадәр тулы бирергә тырышыла. Ә инде шушындый шәхес булудан ерак торган персонажларны — Бикбулат менланы, Гали байны, аның улы Сибгатулланы сурәтләгәндә әдип мондый тулы тасвирга һич тә омтылмый, киресенчә, биредә саранлык күрсәтә. Ул башлыча бу персонажларның үз-үзләрен ничек тотулары, гореф-гадәтләре белән кызыксына һәм болардан аларның күңел матурлыгыннан мәхрүм булулары ачыклана. Шул сәбәпле, алар тышкы матурлыкка да ия була алмыйлар. Күбрәк геройларының идеаль сыйфатлары белән кызыксынган М. Акъегет, әлбәттә, Бикбулат хәзрәт, Гали бай һәм Сибгатуллаларның идеальлектән ерак торган заһири күренешләрен бирүне кирәк тапмый.

Алдарак «Хисаметдин менла»да мәгърифәтчелек эстетикасының характерлы принцибы — яхшы яки яман зат кына итеп каралган геройның статик хәлдә күрсәтелүе — ачык чагылуы турында әйтелгән иде. Үзәк геройларны сурәтләгәндә шушы принципка турылыклы булган хәлдә, М. Акъегет аерым очракларда персонажның дөньясында үзгәреш барлыкка килүен дә күрсәтә. Геройны рухи үсеш-үзгәрештә бирергә омтылу, аерым алганда, Хәнифәнең әнисе Шәмси абыстай образында сизелә. Башта Гали байлар һәм үзенең ире Габбас кебек, кешенең дәрәҗәсе һәм бәхете аның бай булуында дигән карашта торган Шәмси абыстай кызын Сибгатуллага биреп, аны «ризыклы вә бай кадын» итү турында хыяллана, чөнки шул юл белән Хәнифәне бәхетле итәчәгенә чын күңелдән ышана. Туй алдыннан кызы юкка чыккач һәм Гали байлар өйләренә килеп гауга куптаргач исә ул әлеге карашының ялгыш булуын аңлый һәм Гали байга ачынып болай ди:

— Алла, алла, байлыгыңыза инанып, кызымны көчләдем, харап улдым, йөрәк бәгърем баламнан аердың...

Мәгърифәтчелек реализмы принциплары «Хисаметдин менла»ның жанрын сайлауга да билгеле бер эз сала. М. Акъегет аны «милли роман яки хикәя» дип атый. Әсәр жанрының мондый ике төрле булуы очраклы хәл түгелдер, күрәсең. Ул, безнеңчә, байтак дәрәҗәдә ике фактор белән бәйләнгән булырга тиеш. Бердән, үзе яхшы таныш башка әдәбиятлар үрнәгенә ияреп, яшь автор татар милли романын тудырырга алынган. Мәгълүм ки, француз, рус, төрек һ. б. әдәбиятлар тарихы күрсәткәнчә, мәгърифәтчелек прозасы үзенең беренче адымнарын гадәттә романнан башлый. Бу жанрга зур игътибар мәгърифәтчеләрнең конкрет идея-эстетик карашлары белән бәйләнгән. Алар чынбарлыкны кисәкләргә бүлмичә, табигый бөтенлегендә алырга,

аның гармониясен, вакыйгаларның идеаль тигезләнешен күрсәтергә омтылдылар. Бу хәл, әлбәттә, мәгърифәтчелек философиясенең «табигый тәртип» концепциясе белән бәйләнгән иде. «Хисаметдин мелла»да конфликтлылыкның йомшаклыгы да автор кимчелегеннән бигрәк аның әлеге концепциягә турылыклы булырга теләве нәтиҗәсе дип карарга кирәк. М. Акъегет геройлар арасында хасил булган кайбер каршылыкларны куертып, кискенләштереп, вакыйгаларның табигый агышын, гармониясен бозарга теләми. Әсәрнең: «Башка бәлешләремез һәр кәс (һәркем) үз эшләрендә калдылар», дигән җөмлә белән тәмамлануы да очраклы түгел. Әгәр мәгърифәтчел максатларына ирешүдә зур гына киенлекларга очраган Хисаметдин белән Хәнифә, ахырдан боларны җиңеп үз теләкләренә ирешсәләр, ягъни «бәхетле» финалга килсәләр, романның башка күпчелек геройлары бернинди дә үзгәреш кичермиләр, әсәргә нинди хәлдә килеп керсәләр, шул килеш чыгып китәләр. Икенче төрле әйткәндә, чынбарлыкның табигый агышы саклана. Ә инде тормышны табигый хәлендә күрсәтү өчен иң кулай форма — роман, чөнки бу жанр әдипкә чынбарлык турында иркенләп һәм иркенле төстә хикәяләргә киң мөмкинлек бирә. М. Акъегетнең дә роман жанрына мөрәҗәгать итүенең шәхси сәбәпләреннән берсе шундадыр, күрәсең.

Әдипнең «милли роман» төшенчәсе белән генә канәгатьләнмичә «яки хикәя» дип тә өстәве исә милли әдәби традицияләр йогынтысы белән бәйле булырга тиеш. Татар әдәбиятының борынгыдан килә торган традицияләреннән берсен хикәячелек тәшкил итә. Хикәячелек аны чынбарлык күренешләрен һәм герой тормышын табигый хәлендә һәм агышында күрсәтергә мөмкинлек бирүе белән дә җәлеп иткәндер.

Яңа заман татар прозасына һәм аның «генераль» жанры — романга нигез салган «Хисаметдин мелла» үзеннән соңгы милли әдәби хәрәкәткә зур гына йогынты ясый. Әйе, М. Акъегетнең күркәм башлангычы татар әдәбиятында киң яклау таба һәм алга таба дәвам итәлә. Моңа профессор В. Д. Смирнов та дикъкать иткән иде. Ул М. Акъегет үрнәгенең татар әдәби дөньясында бик тиз үз дәвамчыларын табуын әйтте һәм моның беренче мисалларыннан итеп З. Бигиевнең «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә» романын (1887) санады.

«Хисаметдин мелла»ның башкаларга йогынтысы барыннан да элек мәгърифәтче әдипләр иҗатында күзгә ташлана. Әмма сүз бирәдә М. Акъегеткә турыдан-туры ияру яки аңарга охшарга тырышу турында гына барырга тиеш түгел. Аның башлангычы бүтәннәрне актив иҗатка, яңа эзләнүләргә рухландырды. Шуңа күрә М. Акъегеттән соң әдәбиятка килгән мәгърифәтче әдипләр әсәрләрендә «Хисаметдин мелла» белән күп меңдер дәрәҗәдә аваздашлык та бар һәм яңалыклар да юк түгел. Мәсәлән, «Хисаметдин мелла»да үзәк урын алган заман герое мәсьәләсе белән башка әдипләр дә актив кызыксыналар. Аерма тик шунда: әгәр М. Акъегет аны төрле яклабрак яктыртырга алынса, бүтән мәгърифәтче авторлар игътибарларын мәсьәләнең аерым аспектларына юнәлтәләр, геройның теге яки бу сыйфатын калку итеп күрсәтергә тырышалар. Р. Фәхретдиновның «Әсма яки гамәл вә җәза» повестенда (1903) Габбас мелланың, Хисаметдин кебек үк, авыл балаларын яңача укытучы гыйлемле мулла, «мәгыйшәтене сорыкорт низамына куймый, бәлки бал корты ысулына бинаи әйләмеш», ягъни үзе иген игеп, бакча үстереп көн күрүче хезмәт сөючән кеше булуына басым ясала. Шул ук вакытта Р. Фәхретдинов героеның ничек шундый шәхес булып җитлегүе белән кызыксына һәм аның рухи үсешен мәгърифәтчеләрчә аңлата. Габбасның үсешендә төп рольне аның хатыны Гайшә уйный. Әгәр Габбас мелла, ди автор, үзе кебек «җиңел фикерле, дөньяга илтифатсыз бер хатынга тугры килмеш улса иде, гомерене ахмаклар гадәте үзрә сәфаһәт дөньяларында кичермәк вә бөтен фамилиясенең шәрафәтенә дегет буяп, дөньясына вәдагь идәчәк иде». Әмма ул, бәхетенә каршы, «гакыллы, тәкъва, диндар, җәсур, мәрхәмәтле бер хатын» булган Гайшәгә өйләнә һәм аның йогынтысында «кәндәсенә ябышмыш улан фәна гадәтләрене берәм-берәм өстеннән төшермәгә вә табигый истигъдатны хәрәкәтләндермәгә» башлый. Икенче яктан, Габбасның рухи үсешендә ул укыган әдәбифәнни китапларның роле зур булуы күрсәтелә. Андый китапларны әдип «адәм угылы өчен иң куәтле тәрбиячеләрдән» дип бәяли.

Заман героен, М. Акъегет кебек үк, укымышлы кеше итеп күрсәтүгә басым ясау белән бергә, мәгърифәтче әдипләр тора-бара аның гомумән генә гыйлемле булуы турында түгел, ә практик файдасы булырлык белем алулары хакында кайгырта башлыйлар. Мәсәлән, Ш. Мөхәммәдовның «Яфрак асты яки Мәкәрҗә ярминкәсе» повестеның (1901) уңай герое Гали, мәдрәсәдә укудан тыш, рус гимназиясен бетерә, ә каникул вакытларында атисеннән сабын кайнатырга өйрәнә. Әтисе үлгәч исә сабын кайнату заводы хуҗасы булып калган Гали, заводта эшне заманча оештыру белән бергә, оста сәүдә итәргә дә өйрәнә. Авторның бу моментларга дикъкать итүе бер дә очраклы түгел. Әсәрләрендә күбрәк татар сәүдәгәрләре белән кызыксынып, Ш. Мөхәммәдов аларны үз эшләрен искечә, ата-бабаларча алып барулары, заманча сәүдә итә белмәүләре өчен кискен тәнкыйтьли.

Үз эшен дөрес алып барып һәм заманча сәүдә итеп баегач, Гали, М. Акъегетнең Мохтары кебек, байлыгын мәгърифәт эшенә

сарыф кыла, ятим балалар өчен һөнәр мәктәбе ача. Героеның бу күркәм эше турында әдип тирән канәгатьләнү белән һәм рухланып яза.

З. Һади әсәрләрендә Хисаметдин мәнла кебек укымышлы геройларның авылдагы эшчәнлегенең конкрет нәтиҗәләрен күрсәтүгә күбрәк игътибар бирелә. «Бәхетле кыз» повестендагы Габбас, Казандагы күренекле бер мәдрәсәне бетереп һәм үзлегеннән күп кенә дөньяви фәннәрне өйрәнеп, зур гыйлемле булып туган авылына кайткач, анда мәгърифәт һәм мәгыйшәт өлкәсендә үзенә бер «революция» ясый. Авылдашларының наданлыгына бик борчылган герой, кайту белән, зур эшләр башлап җибәрә. Яңа зур мәктәп ачып, балаларны яңача укыта башлый, иң яхшы укыганнарын Казанга яки Оренбургка укырга җибәрә. Алар шәһәрдән «сүзләре ачык, зиһеннәре үткен, табигатьләре мөләем», ягъни төпле белемле һәм тәрбияле кешеләр булып кайталар. Икенче яктан, Габбас авылдашларын иген игәргә өйрәтә. Аңардан үрнәк алып, кешеләр эшкә бирелеп китәләр, «эшсез, бүрәнәләр өстендә утырып хикәят сөйләүчеләр» күзгә күренеп кими. Нәтиҗәдә авылның тормыш-көнкүреше рәтләнә, кешеләрнең хәлкы яхшыра. «Җиһанша хәзрәт»тә гыйлемле Хәсән мулла тырышлыгы белән аның авылдашлары «берничә елдан соң башка авылларга караганда яхшыгына алга» китәләр, иген игә, сәүдә итә башлыйлар. Авыл культура ягыннан да күзгә күренеп үзгәрә.

Бикбулат хәзрәт турында сөйләгәндә М. Акъегет аның наданлыгын, мәдрәсәсендә дә укыту-тәрбия эшенең бик начар торуын күрсәткән иде. Бераздан моның белән М. Акъегетнең татар җәмәгатьчелеген нык борчыган мәсьәләне күтәрүе ачыкланды. Чөнки аңардан соң әлеге мәсьәлә мәгърифәтчеләр иҗатында шактый киң яңгыраш алды. З. Бигиев, З. Һади, Ф. Кәрими һ. б. прозаиклар әсәрләрендә надан һәм булдыксыз мулла-хәзрәтләр, мәдрәсәләрдәге тәртипсезлекләр, кадимчә укытуның шәкертләргә кире тәэсире фаш ителә.

«Хисаметдин мәнла»да күтәрелеп, алга табан тагын да активрак яктыртылган мәсьәлә — ул, әлбәттә, татар хатын-кызы мәсьәләсе. Шул заман татар җәмгыяте өчен бик актуаль торган бу проблеманы әдипләр төрле яклап яктыртырга алыналар. Аларның игътибарын еш кына мөселман дөньясында хатынкызга нинди мөнәсәбәт булуы җәлеп итә. Бу мәсьәләгә караш әсәрләрдә аерым шәхеснең, мохитның, җәмгыятьнең мораль йөзен ачу чарасына әверелә. Ирләрнең кешелеклелеген, инсаниятен, табигыйлеген авторлар әледән-әле аның хатын-кызга мөнәсәбәтеннән чыгып бәялиләр. Мәсәлән, З. Бигиевнең «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә» (1887) һәм «Гөнаһе кәбаир» (1890) романнарында геройларның мораль-политик йөзе нәкъ менә аларның героиняларга карашыннан чыгып ачыла. Беренче романда үзәк герой Мусаның Зөләйха белән Хәдичәгә мөнәсәбәте аша капитализм формалашкан чор өчен характерлы күренеш — буржуаз җилкуарның ничек тууы күрсәтелә. Шул ук вакытта бу яңа тип геройның мәгърифәтчел идеалларга чит зат булуы ачыклана. Мәгълүм ки, мәгърифәтчеләр шәхес идеалын кешенең рухи-әхлакый яктан камил һәм мәгърифәтле зат булуында күрәләр иде. Муса исә героиняларның үзләре белән түгел, ә күбрәк аларның байлыклары белән кызыксына. Ул Хәдичәнең йөз мең сум приданына кызыгып, төп байлыгы акыл һәм белем булган Зөләйхадан баш тарта. Моның белән эшкуар Муса Салихов мәгърифәтчеләр идеалын да кире кага. Геройның уңайлыгын яки тискәрелеген хатын-кызга мөнәсәбәт аша чагылдыруга «Гөнаһе кәбаир»дә тагын да ныграк игътибар бирелә. Геройлардан берсе Якуп Галиевне автор әхлаксыз, бозык зат итеп күрсәтә һәм аның мондый сыйфатларын Маһруйга мөнәсәбәтендә гәүдәләндерә. Бозыклыкның чигенә җиткән Якуп хәтта хатын-кыз идеалы булырлык Маһруйны да юлдан яздыра. Әмма бу юлы мәгърифәтчелек идеалларын җиргә салып таптаган герой тиешле җәзасын ала. Бу кеше белән бәйләнеп нинди зур хата эшләгәнен аңлаган Маһруй аны мунчада кайнар су сибеп үтерә. Романның уңай герое Җиһангир образы да башлыча Маһруйга мөнәсәбәттә ачыла. Тормышта зур ялгышлыклар җибәргән хатынына карашында Җиһангир җитди әхлакый сынауга дучар була һәм, ул сынауны намус белән үтеп, мәгърифәтчел уңай герой исеменә лаеклы булып кала.

М. Акъегет башлангычын дәвам иттерүчеләр тагын үзләренең мәгърифәтчел хатынкыз идеалын чагылдыруга басым ясыйлар. Мәсәлән, Р. Фәхретдиновның «Сәлимә...» һәм «Әсма...» повестьларында, З. Һади хикәяләрендә, «Хисаметдин мәнла»дагы кебек үк, әлеге идеаль героиняны физик һәм рухи камиллеккә ирешкән шәхес итеп күрүдән гыйбарәт. Авторлар героиняларның әхлакый дөньясына, аң-белем дәрәҗәсенә аеруча дикъкать итәләр, геройлар да яраткан кызларының шушы сыйфатларын барыннан да өстен куялар.

Моңа кадәр без М. Акъегет романында күтәрелгән идеяләрнең һәм проблемаларның озын гомерле булуы, алга табан да әдипләребез тарафыннан өйрәнелүе һәм яктыртылуы турында сүз алып бардык. «Хисаметдин мәнла» үзенең формасы белән дә киләчәк буын әдипләр өчен өлге һәм үрнәк булды. Мәгълүм ки, М. Акъегетнең бу әсәрен язуда төп максатларыннан берсе татар милли романын тудыру иде. Европа әдәбиятлары практикасы белән яхшы таныш булган М. Акъегет аларда романның нинди зур роль уйнаганын белә һәм аның туган әдәбиятында да тиешле урын яулавын тели. Үзләре башлап җибәргән

яңа реализм заманы прозасының һәм, гомумән, бөтен әдәбиятның үсеш перспективалары байтак дәрәҗәдә роман жанры белән бәйләнгәнлеген З. Бигиев тә яхшы аңлаган, күрәсең. Көнбатыш, рус һәм төрек романнарын мавыгып укыган бу яшь әдип тә татар әдәбиятында әлеге жанрның тизрәк тамыр җәюен теләгәндер. Бер үк вакытта З. Бигиев романның форма төрлелегенә омтыла. Башка күп кенә әдәбиятларда һәм укучылар арасында да инде зур популярлык казанып өлгергән детектив роман белән кызыксынып китеп, ул, безнең әдәбиятта бу төр форманың беренче үрнәкләрен бирә. Әйе, аның әсәрләре, бигрәк тә «Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә», Көнбатышта Э. По, Э. Габорио, У. Коллинз кебек әдипләр тарафыннан тудырылган детективның классик сюжет алымнарына таянып язылган. Күренә ки, яңа заман татар романы үзенең беренче адымнарыннан ук төрле формаларда үсә башлый.

Әмма М. Акъегет белән З. Бигиевтән соң беркадәр вакыт бездә романнар күренми тора. Дөрес, бу өлкәдә әледән-әле омтылышлар ясала, ләкин алар еш кына тормышка ашмый калалар. XX йөз башы татар прозасында роман жанрының бермәл ничектер «югалып» торуына шул чордагы тәнкыйть тә дикъкать итә. Г. Ибраһимов, мәсәлән, роман «үзенең тәмамы вә бөтен торышы белән аерым, билгеле һәм бөтен бер мәгънәне күрсәтергә тиеш», ди. Әмма романнарның еш кына бик өзгәләнеп басылулары яки тәгәлләнми калуларын күрсәтә. Бу хәлне Г. Ибраһимов башлыча субъектив сәбәпләр белән, ачыграк әйтсәк, әдипләрне бу эшкә «игътисат мәҗбүр итүе» белән аңлата. Ләкин монда җитдирәк объектив сәбәпләр дә булгандыр ахры. Моңа охшашлы күренешләр белән без шул чордагы рус прозасында да очрашабыз. Анда да XX йөз башында роман язарга ниятләнеп тә, бу эш я хыялда гына калган, яисә ахыргача башкарып чыгылмаган очраклар еш була. Икенче яктан, рус романы тарихын тикшерүчеләр «XIX гасырның ахырына якынлашкан саен монументальлектән читләшү тагын да ачыграк күренүен, бу хәрәкәтнең торган саен күбрәк язучыларны үз эченә алуын, аның хәтта монументаль формаларның иң зур остасы Л. Толстой иҗатында да чагылуын» әйтәләр (История русского романа, в двух томах. Т. 2. М.— Л., 1962, 350 бит.) Дөрестән дә, XIX гасырның 80—90 елларында Толстой иҗатында кече жанрлар — повесть һәм хикәя өстенлек итә. Рус прозасында кече формаларның хакимлеге XX йөз башында да күзаллана. Әдәбиятчылар бу хәлне башлыча ике фактор белән бәйләп аңлаталар. Бердән, рус прозасы бу чорда заманның үсештәге тормышына йөз белән борыла, аның яңа таләпләренә оператив рәвештә җавап бирергә омтыла башлый. Икенчедән, әдәбиятның жанр табигатенә шул тарихи чор үзе җитди эз сала. Мәгълүм ки, XX йөз башы — Россия тормышында тирән революцион кузгалышлар белән бәйләнгән көчеш дәвере ул. Ул чор җәмгыять үсешенең бермәбер катлаулануы һәм хәтта буталчык төс алуы белән аерылып тора. Табигый, бу дәвер тормышын сәнгатьчә аңлау һәм аның турында, роман жанры таләп иткәнчә, бөтен бер мәгънә бирү эше дә шактый кыенлаша. Ул чынбарлык синтездан битәр анализны, ныклап өйрәнүне, ачыклауны сорый.

Ике гасыр чигендә бездә дә роман күренми торуның төп сәбәпләреннән берсе шуннан гыйбарәт булырга тиеш. Дөрес, бу жанрда эшләргә омтылыш һич тә кимеми. Киресенчә, роман тудыру теләге көчәйгәннән-көчәя генә бара. Һәм, ниһаять, бу теләк тормышка аша башлый. Ф. Әмирханның язылып бетмәгән «Урталыкта» сыннан (1912) соң Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр»е (1913) дөнья күрә.

Шул ук вакытта Г. Ибраһимов мәгърифәтчеләр бик теләп һәм зур өметләр баглап сурәтләгән урта катлау татар зыялылары арасында үзенең герой идеалына лаек булырлык кешеләрне очратмый. Бераздан «Безнең көннәр» романында ул заман героен яшәп килгән гаделсез тәртипләрне җимерү өчен революцион көрәшкә күтәрелгән массалар — көрәшчеләр арасыннан таба.

XX йөз башы татар әдәбиятында алып барылган эзләнүләрдәге мондый үсешне аныклау, әлбәттә, мәгърифәтчеләр иҗатының әһәмиятен кечерәйтеп күрсәтүгә китерергә тиеш түгел. Монда мәсьәләгә тарихи караш сорала. Яңа, реализм дәвере әдәбиятына нигез салган мәгърифәтчеләр тормыш алга куйган күп кенә мәсьәләләрне, беренче чиратта, заман герое мәсьәләсен күтәреп чыктылар. Герой идеалын гомум мәнфәгатьләрне кайгыртып, халык язмышы турында уйланып, яшәү максатын халыкка хезмәт итүдә күргән шәхесләрдә табулары аларның тарихи әһәмиятле зур казанышы иде. Шул ук вакытта геройның гармоник үсешкә ирешкән, бигрәк тә әхлакый яктан күркәм зат булырга тиешлегенә басым ясаулары да бүгенге көнгә кадәр әһәмиятен югалтмый гына түгел, бәлки тагын да актуальләшә бара. Мәгълүм ки, болар хәзерге герой идеалының асыл сыйфатларын тәшкил итәләр.

Мондый эзләнүләрендә мәгърифәтчеләр үткәннәр тәҗрибәсенә нык таяндылар, аны заман рухы белән сугардылар, үстерделәр. Гомумән, мәгърифәтчеләр халыкның күпгасырлык иҗтимагый-рухи идеалларын һәм иҗади традицияләрен барлап, аларга яңа сулыш өрделәр һәм XX гасырның киеренке әхлакый һәм эстетик эзләнүләре дөньясына алып керделәр. М. Акъегетнең «Хисаметдин менла»сы да татар әдәбиятында һәм, аерым алганда, роман жанры үсешендә әнә шундый күпер ролен уйнады. Туган әдәбиятыбызда гасырлар дәвамында яшәп килгән романчыл хикәяләү традицияләрен үзләштереп һәм башка әдәбиятлар тәҗрибәсе белән баетып, М. Акъегет яңа заман татар романына нигез салды, аның киләчәк үсешенә ышанычлы юл ярды.

библиография

# БИЕКЛЕК

Язучыларның нечкәләп белеп иҗат иткән өлкәләре-тармаклары була. Әйтик, Атилла ага Расих терлекчелек-кошчылык галимнәре турында яза икән, аның китабын кулга алганда ук чынлык хисен тойгандай буласың. Ник дигәндә, ул үзе шул дөнья галиме һәм педагогы.

Мөхәммәт Мәһдиев диңгезчеләр, авыл укытучылары, филолог галимнәр хакында роман яки повесть бүләк иткән икән, укый башлау белән, авторның диңгездә хәрби хезмәт үткәненә, укытучы булганлыгына, аннары фән баскычына күтәрелгәненә ышанабыз.

Шәриф Хөсәенов медицинаны нечкәләп белә, һәм шул төбәккә кагылышлы язганда аны уңыш көтә икән, бу да бик аңлаешлы хәл: ул — талантлы драматург һәм прозаик булу өстенә, тәҗрибәле врач та.

Сафа абый Сабиров — елгачыларны, Миргазыян Юныс сәүдә флоты кешеләрен әйбәт беләләр һәм оста тасвирлыйлар.

Байтагыбыз — әдәбиятыбыз аксакаллары да, урта һәм яшь буын вәкилләре дә — нигездә авыл тормышына таянып язарга омтыла. Моның да сәбәбе ачык: һәрхәлдә, авылны беләрәк төшәбез. Бик күбебез авылда туып үскән, мәгълүм еллар буе сала кешеләре белән аралашып эшләгән, яшәгән.

Авылда дөньяга килгән, Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, мөстәкыйль тормышының башыннан ук зур төзелешкә килеп береккән Рәфкать Кәрами төзүчеләр тормышына гашыйк булып яза. Аның «Очар кошлар белән янәшә» дигән уртак исемгә берләшкән өч повестьлы зур китабының өч повесте да укучы кулына керде инде.

Беренче китапка язучы уртак исемне биргән иде. Икенчесе «Ашкыну» дип атала. Повестьлар трилогиясенең өченче китабы — «Чыныгу чоры». Ул быел басылып чыкты.

Трилогиягә тулаем нигез материал «Казаньхимстрой» трестындагы төзелеш идарәләренең берсеннән алынган. Бөтенсоюз комсомол удар корылышыннан.

Әсәрләрдәге күпчелек персонажларның яшьләр булуы да аңлашыла. Әле күптән түгел генә мәктәп белән хушлашканнары да, Совет Армиясендә хезмәт итеп кайтканнары да бар аларның. Төзелештә булудан мәгънә һәм ләззәт тапканнары да, «зур тәңкә» эзләп килгәннәре дә. Өлкәннәрнең дә үз кыйблаларын төрлечә тапканнары бар әлеге повестьларда. Автор аларны детальләп белә, чөнки махсус өйрәнеп кенә йөрмәгән, геройлары белән бер мәйданда эшләгән, еллар дәвамында бер тулай торакта яшәгән. Рәфкать Кәрами бу төзелештә иң әүвәле электрик булды. Аннары тырыш яшь коммунистны төзелеш идарәсенең профсоюз оешмасы башлыгы иттеләр. Укуы да бүгенге эшче яшьләрнеке төсле иде аның. Төзелештә чагында ул читтән торып университетның тарих бүлеген тәмамлады, газета хәбәрчесе булып китте, беренче китапларын чыгарды (укучылар аның «Дүрт кешелек каюта», «Кичке уйлар», «Капитан Хәкимов» һ. б. әсәрләре белән таныш). Аннары аны СССР Язучылар союзына әгъза итеп алдылар, Мәскәүдә Югары әдәби курсларда каләм шомартып кайтты. Әйтергә теләгәнем шул: «Очар кошлар белән янәшә» китапларының авторы биографиясез түгел. Ә бу — иҗатта бик мөһим фактор.

Шуңа күрә, трилогия повестьларының өчесен дә дөньяга чыгаргач, авторга җитди таләпләр куеп сөйләшергә тулы җай бар. Һәммәсен бергә куеп анализлау мөмкинлеге туды.

Әүвәле авторның бу әсәрләрендәге күркәм якларга тукталыйк.

Аның иң беренче отышы — төзүчеләр хезмәтенең пафосын тоя белүе. Икенче җәһәттән килсәк, Рәфкать Кәрами характерлар кою осталыгын чигенүләрсез үзләштереп бара, бу бурычны хәл кылуга сюжет бормаларын шактый оста җигә, композициядә кәеф кырырдай «бүлтәюләр»гә юл куймый. Телгә игътибарлылыгын да, Сарман ягынча матур тасвир көченә ия булуын да автор файдасына әйтү зарур. Персонажлар сөйләменә дә кызыгып куясың.

Трилогиядә персонажлар күп. Беренче китапны укып барганда, сагаеп куйганым да булды: һәммәсенә тиешенчә эш табып җиткерерме, кысыр чәчәкне хәтерләткән-

нәрә ишәеп китмәсме? Өч китапны бергә кушып күздән кичергәч, ачыкланды. Бөтенләй дә «эшсез» персонажлар юк. Эпизодик затлар әлбәттә, күренгәли, әмма бит, әдәби практика раслаганча, алар да зарур. Һич югы баш каһарманнарны тулырак ачу өчен кирәк алар.

Өченче китапта — «Чыныгу чоры»нда вакыйгалар сыекланып китмәсме? Башта бу сорау да борчып торган иде. Образлар вакланмасмы? Шөкер дигәндәй, андый хәл сизелми. Повестьларның һәммәсе бертигез дия торгЃн. Алай гына да түгел, өченче повестьта персонажлар психологиясен бирүдә авторның тирәннәнрәк алдырып эш итүе дә ачык. Югыйсә бит ике-өч кисәктән торган әсәр язарга алынучылар булмады түгел, икенче китапларына дәрт-дәрман җитмәү очраклары да булгалады. Ә җирдән күтәрелмәгән ниятләр дә, канатлары гарип характерлар да замандашларны каңәгатьләндерми.

Төп персонажлардан, һичшиксез, беренче чиратта төзелеш идарәсе башлыгы Ислам Бакирович Мәхмүтовны атарга кирәк. Ул, автор раслаганча, «беренче караштан ук үзенә соклану тудыра ала торган кеше иде». Аның карамагында йөзләгән эшче, дистәләгән объект. Ул шулар өчен һәр сәгать, һәр минут җаваплы. Караш киңлеге бар Мәхмүтовта. Исламның холкы-фигыле, бер яктан, гади төзүчеләр белән бәйләнештә, икенче тарафтан, үзеннән югары җитәкчеләр белән мөнәсәбәттә ачыла. Ул кешелекле һәм ярдәмчел дә, таләпчән һәм үтә принципиаль дә. Нервылары бәйдән ычкынып, дулап киткән чаклары да була. Мондый хәлне исә ул гаҗәеп авыр кичерә. Әлегә җәһәттән фронтташ дусты, хәзер идарә партбюросы секретаре, кадрлар бүлеге начальнигы Александр Семагин белән ике арада булган бәрелешне телгә алып китик.

«...Мәхмүтов, саташкан кешедәй, беравык үзенең кайда икәнен аңышмыйча ятты. Сашка Семагин... Туктале, ул бит бүген (сәгать ничә икән соң), бәлки кичәдер, әйе, кичә булса кирәк, рәнҗеп чыгып китте. Чөнки Мәхмүтов аның хәтерен калдырды. «Ах, Сашок, Сашок, нишләдек соң әле без?!» Мәхмүтовның күзенә яшь килде. Әгәр дә менә хәзер, шушы минутта каршында Семагин торса, ул аны кочаклап, бер дә тартынмыйча ирләрчә бер елар иде. Тавышын чыгармыйча, бөтен гәүдәсе белән калтырап, иңбашларын дерелдәтеп бер елар иде. «Эх, нишләп болай тупасландык соң әле без? Бер генә изге нәрсә дә калмадымыни соң? Ничек минем телем барды аңа шундый сүзләр әйтергә? Күпме асыл егетләрдән исән калган бердәнбер дустымны, ничә мәртәбәләр үлемгә каршы барган, күпме газапларга дучар булган фронтташымны ничек шулай җәберсетә алдым мин? Нишләп алай гаделсезгә әйләндем? Семагин дөрес әйтә: тыярга кирәк үзеңне. Ә ничек тыясың? Нервылар какшаган. Әллә бераз дәваланып алыргамы? Ятып чыкканда да начар булмас иде. Ә кем сине больницада яткырсын эшнең урак өстедәй иң кызган вакытында? Үзең дә риза булмассың. Мәҗбүри салсалар да, палата тәрәзәсеннән чыгып качарсың. Эш, эш...»

Эш дип кенә дорфаланырга һич кенә дә ярамаганны белеп өзгәләнә шул идарә башлыгы. Әгәр партбюро секретареның да шундый ук газап кичерү картинасын да китереп өстәсәк, авторның рухи биеклекнең мөһим бер ягы хакында тирәннән уйлануын күрербез. Кешеләргә бернинди сылтау белән дә җан яулаган биеклектән төшмәскә, һәрчак очар кошлар биеклегендә булырга кирәклекне сөйләп чаң сугуы бу авторның.

Участок башлыгы Җиһангир Әхмәтовны да, бригадирлар Яббаров һәм Мәрдәновларны да, прораб Петр Ефимовичны да, төзү идарәсенең комсомол комитеты секретаре Әзһәм Шәриповны да каннары-сүлләре эчләрендә булган замана кешеләре итеп кабул кылу кыен түгел. Мондый кешеләр бар, төзелештә төп йөкне шулар тарта. Бу юлларның авторы заманасында, комсомол матбугатында эшләгәндә, нәкъ шушы төзелешнең башлангыч дәверендә алар белән бик еш очраша иде. Бәләкәй генә шул тәҗрибәгә таянып булса да әйтим: төзелешнең үз сулышы бар, һәм Рәфкать Кәрами аны шәп тоемлый.

Алда телгә алынган персонажлардан тыш, хәтергә уелып кала торган тагын берничә герой бар. Әйтик, электрик Илфир һәм аның сөйгәне, ә соңыннан хатыны Галя. Аларның керсез мәхәббәтләре сокланырлык тасвирланган. Эш процессында да бик калку һәм саф күңелле итеп сурәтләнгәннәр алар. Бүгенге яшьләргә шундый энтузиастларны, шундый сөешүчеләрне кыю күрсәтергә кирәк.

Укучы яратып кына өлгергән Илфир үлеп китә. Җитмәсә, автор моны Семагин көндәлегендәге юллар аша гына бирә: «Бүген бездә траур. Иң яхшы эшчеләребезнең берсе — Илфир Садриев һәлак булды. Илфир безнең үзебезгә дә, хатыны Галяга да һәм туачак нарасыена да бик кирәк иде».

Турысын әйтим, трилогиянең ике китабы белән генә таныш чакта мин авторның Илфир тикле Илфирне тиктомалдан үтереп куюына каршы идем. Өченче китап белән танышканнан соң, Рәфкать Кәрамига булган дәгъвамны кире алам. Өченче повестьтагы логика, Галяның тормыш юлын, яшь тол хатынның образ буларак үсеш юлын тасвирлау логикасы бәхәскә урын калдырмый. Галяның тормыш имтиханнарын кичерүләрен кирәгенчә тасвирлау өчен генә дә Илфир һәлакәте кирәк икән. Алай дип карау гына да җитенкерәми. Өченче китап-

та. Илфир үзе булмауга карамастан, аның образы ачылганнан-ачыла бара. Бу тиклесе дә инде язучының осталыгына бәйләнгән.

Хәтергә керергә үзе сорап торган тагын бер персонаж турында әйтми узу дөрес булмаячак. Ул — кранчы Тәскирә. Әллә исеме үк халык җырына бизәк булып кергәнгә, әллә трилогия авторы аеруча үз итеп, яратып, кирәгенчә тасвирлаганга, бу кызый өченче китапта сәхнә алдына чыга һәм, күләгәгә керми, гел янәшәбездә була. Чая, үткен, сүзен өздереп сөйли, егет халкын үчекли дә, шелтәли дә белә. Эшендә — ут борчасы. Шул ук вакытта гаҗәеп саф күңелле, самими һәм гел кәтмәгәндә... оялчан да була белә. Итагатьле, әдәпле татар кызы. Кемнеңдер киләчәк бәхете!

...Тәскирә өскә үрмәли. Текә баскычның тимер араталарыннан кул-аяклар таеп-таеп китә. Кулың ычкыныр да егылырсың кебек. Шулай да югары менү Тәскирә өчен үзе бер ләззәт. Син өскә күтәрелгән саен йөрәк ешрак тибә, куллар тирли, тән җылына башлый, беләк мускуллары тыгызлана.

Сине астан кешеләр күзәтеп торуын һәм кайберләренең көнләшеп каравын сизү дә горурлык өсти. Ә егетләр... Тәскирә меңә шунысына һич ияләнә алмый: ул һәрвакыт аларның нәфесле күз карашларын бөтен аркасы белән тоя. Моңа әһәмият бирмәскә, гадәти нәрсә итеп карарга тырыша. Әнә Зиннәт, Тәскирә күтәрелә башлагач та, читкә китеп барды бит. Ә башкалар...

...Иң азакккы зиратны атлап, мәйданчыкка баскач, җиңел сулап куясың: синнән дә бәхетле кеше юк бу дөньяда! Син биектә! Хәзерге космос заманында егерме-егерме биш метр ул әллә ни искитәрлек биеклек түгел түгелен, ләкин шулай да бу инде җир түгел, ә очар кошлар биеклеге...

Эшче кеше бәхетен, ялан кырда үсеп чыккан сокланырлык зур химкомбинат төзүгә үзеннән өлеш кертү горурлыгын да автор яраткан героинясенең күңел биеклеге белән — очар кошлар югарылыгы белән үлчи. Һәрьяклап гүзәллекнең өлгесе булган эшче кыз күңелендәге уйлар аша гомумиләштерүгә килүе — шулай ук авторның казанышы. Әсәр бит олы мәгънәсендә эшче-иҗатчыларның рухи киңлекләрен, җан биеклекләрен күрсәтү максаты белән язылган.

Сүзне түгәрәкләр алдыннан бер искәрмә. Әсәрнең телен уңай бәяләп уздык. Тулаем тәэсир бәхәссез. Әмма ни гаҗәп (өченче китапта бигрәк күзгә ташлана): Рәфкать Кәрами бихисап җөмләләрне теркәгечләрдән башлап язарга өйрәнеп киткән. Өздереп әйтү читен, җөмләләрне ничек башлау һәм тәмамлау кадәресе — авторның үз эше, үз теләге. Шулай булганы хәлендә дә, бер биттә «ләкин» һәм «чөнки» белән башланган җөмләләр дистәгә якынлашса, колакка бәрә башлый лабаса!

Бу ятышсыз хәлгә, барыннан да битәр, без үзебез, язучылар, дикъкать итәргә бурычлыбыз. Топ коралыбыз сүз икән, коралны кугәртмик тә, тупасландырмыйк та. Аннан килеп, хөрмәтле редакторларыбыз да бар бит әле. Аларның чыбыркы очындагы кыл үзәкне өзәрдәй булырга тиеш. Редакторларыбыз таләпчәнрәк була барган саен, ташка басылган әсәрләребезнең сыйфаты яхшыра гына төшәчәк.

Бу повестьлар барсы бергә дә басылмый калмаслар дип уйларга нигез бар. Бербөтен итеп укыйсы килә аларны. Икенче басма күрергә насыйп икән, телдәге әнә шундый минуска игътибарлырак булу сорала.

**Барлас КАМАЛОВ.**

# МУЗЫКА САРАЕ

Кырык бишенче елның язында Ленин бакчасының яшел агачларына күмелеп утырган ике катлы җыйнак кына бинада госпиталь урнашкан булса, инде көзге салкыннар килеп җиткәндә, пыялалары ватылган тәрәзәләрдән төрле музыка авазлары яңгырый башлады. Үзләренең һөнәрләренә сусап, Бөек Ватан сугышын тәмамлап кайткан солдатлар, әнә шулай, окопларда тупасланган бармакларын дәртләнеп йомшатырга тырышалар. Кичәге госпиталь бинасында Җиңү елының беренче көзендә туган Казан дәүләт консерваториясе үзенең эшен башлап җибәрде.

Кырык ел элек, Бөек Ватан сугышы тәмамланырга бер ай чамасы калганда (13 апрель), СССР Халык Комиссарлары Советы Казанда консерватория ачу турында карар кабул итә. Шул мәшәкатьле көннәрдә, әле сугыш барганда, меңләгән авыллар, шәһәрләр җимерелгән, бомбалар белән кырларның асты өскә китерелгән, халык икмәккә туймаган вакытта, партия һәм хөкүмәтебезнең яңа музыкаль уку йорты ачу турында кайгыртуы, милли музыкаль культураларны үстерү мәсьәләләрен мөһим экономик бурычлар белән бер рәткә куюы чын мәгънәсендә сокландыра. Димәк, партия, бер яктан, музыкага җимерелгән хуҗалыкны торгызу эшен тизләтергә ярдәм итүче итеп карый, икенче яктан, күпмилләтле совет сәнгатен тигез үстерү өчен шартлар булдыру турында кайгырта.

Авыр сынау елларында музыка үзенең көчле йогынтылы сәнгать икәнлеген тагын бер мәртәбә исбат итте. Татарстан композиторлары, музыкантларының бер өлеше, кулларына мылтык тотып, икенчеләре үзләренең ялкынлы җырлары белән Җиңү яулаштылар һәм, әйтергә кирәк, бәхетле тормышыбызның гүзәл сарайларыннан берсе— консерватория ачылу көнен дә якынайттылар.

Консерваториянең беренче адымнары тәҗрибәле зур музыкантлар белән бәйле. Монда Мәскәү консерваториясе профессорлары Г. Литинский, Г. Коган, Г. Луковский, виолончель укытучысы А. Броун, ленинградлылардан профессор М. Юдин, композитор А. Леман, республикабызның күренекле профессоры М. Пятницкая, заманында бөтен Россиядә атаклы булган опера җырчысы Е. Ковелькова, пианистка М. Берлин-Печникова, музыка белгече Ю. Виноградовлар бөтен күңелләрен биреп эшли башладылар. Алар белән рәттән Мәскәүдә югары белем алып кайткан милли композиторлар Н. Җиһанов (беренче көннән — ректор), М. Мозаффаров, җырчы З. Байрашева, музыка белгече Х. Терегулова һәм башкалар укыту-тәрбия эшен югары профессиональ дәрәҗәдә оештыра да, алып та бара белделәр.

Биш еллап вакыт узды. һәм, ниһаять, беренче чыгарылыш тантанасында махсус югары белем алган 39 белгечкә Казан дәүләт консерваториясе дипломнары тапшырылды. Шул вакыттан алып Татарстан музыкаль культурасы үсешендә яңа чор башланды дип әйтү хата булмас, чөнки шуннан соң инде ел саен опера театрына, филармониягә, музыкаль уку йортларына югары белемле белгечләр килеп тора. Белгәнебезчә, 1967 елда республикада симфоник оркестр барлыкка килде (анда хәзер туксан процентка якын музыкантлар шушы консерваториядән), Казан педагогия институтында 1960 елда музыкаль-педагогика факультеты ачылды. Культура институтында да музыкаль дәресләр алып баручы педагоглар Казан консерваториясендә белем алганнар. Республикада балалар музыка мәктәпләренең саны йөздән артты, өч яңа музыкаль училище ачылды. Татарстан Композиторлар союзында өлкән яшьтәге дүрт композитордан башкалары Казан консерваториясендә укыганнар.

Казанда консерватория ачарга карар кабул иткәндә, милли музыкалары үзенчәлекләре белән безнекенә якын булган Урта Идел, Себер автономияле республикалары өчен дә композиторлар, музыкантлар, җырчылар әзерләү күздә тотылды. Бу вазифа педагоглардан шул уртак үзенчәлекләрне

исәпкә ала торган махсус укыту программалары һәм методикалар әзерләүне таләп итте.

Гомумән, консерваториянең беренче көннәреннән башлап **нәрсәгә** һәм **ничек** өйрәтергә дигән проблема иң мөһим мәсьәлә булып торды. Кайберәүләргә татар музыкасын иҗат итүче яки башкаручы рус, Көнбатыш Европа тәҗрибәсен үзләштерсә, музыка үзенең милли сыйфатларын югалта төсле тоела иде. Андый фикерләрнең тууына кайбер башкаручыларның һәм композиторларның иҗатлары берникадәр нигез булды. Бу очракларда академмәктәп гаепле ме, укыту программасымы, әллә укытучының халык иҗатына карашымы? Җаваплар өзлексез эзләнүләр нәтиҗәсендә бүген инде табылдылар дип әйтә алабыз. Моны раслау өчен Казан консерваториясен тәмамлаучылардан берничә генә исемне искә төшерик: татар халык көйләрен зур осталык белән башкаручылардан РСФСРның халык артисты Илһам Шакиров, ТАССРның халык артисткасы Зөһрә Сәхабиева, чын милли әсәрләр иҗат итүчеләрдән РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Фасил Әхмәтов, яшь композитор Шамил Шәрифуллин һ. б.

Һәркемгә мәгълүм ки, музыкаль культураның биеклеге һәм уңышлы үсүе профессиональ композиторлык культурасының дәрәҗәсе белән тәэмин ителә. Шуңа күрә консерватория коллективы композиторлар әзерләүгә бик зур игътибар бирә. Педагоглар яшьләрне композиторлык һөнәренә өйрәтү белән бергә, аларның гражданлык хисләрен формалаштырырга ярдәм итәләр, аларның иҗатын зур күләмле, идея ягыннан әһәмиятле әсәрләр булдыруга юнәлтәләр. Еш кына диплом эше генә булып туган әсәр милли культура өчен шактый мөһим әсәр булып танылa. Беренче чыгарылышларны искә төшерик. Мәсәлән, Х. Вәлиуллинның «Самат» операсы диплом эше булып язылды. Ә ул татар совет музыкасында заман темасына язылган беренче лирик опера булып танылды. Шулай ук Ф. Васильев «Шывармянь» («Тегермән») дигән беренче чуваш операсын да консерваториядә язды; Э. Сапаев та беренче мари операсы «Акпатыр»ны һәм беренче симфониясен Казанда уку елларында иҗат итте. Беренче тува композиторлары, беренче калмык, алтай композиторлары да үзләренең милли культуралары өчен беренче профессиональ әсәрләрен Казанда язып киттеләр.

Соңрак укыган композиторларның иҗатлары милли сәнгатьнең башка проблемаларын чишү белән бәйле. Алар яңа жанрларга юл ачалар, милли музыкаль телне баеталар. Уртача һәм яшьрәк буын композиторларыбыз камера жанрларын үзләштерәләр, симфоник музыканы баеталар, төрле уен кораллары өчен концертлар язалар һәм халык иҗатының югала язган үрнәкләрен халыкка эшкәртеп, баетып кайтаралар.

Берничә буын композиторлар тәрбияләгән консерватория ректоры, Социалистик Хезмәт Герое, СССРның халык артисты, профессор Н. Җиһанов еш кына болай ди: «Яшьләргә яңалыкка омтылу, ялгышу, сынап карау, инкарь итү хас. Бу хәлдән курыкмаска кирәк. Аларның үз юлларын эзләүләре — яхшы хәл. Композиторларыбыз музыкаларының тамырлары милли җирлектә, ләкин аларга рус һәм бөтендөнья музыкаль культурасының йогынтысы булуы бик табигый».

Соңгы вакытта кафедра яшьләрнең үз халыклары иҗатлары белән мөнәсәбәтләрен ныгыту буенча күп эшли. Студентлар ел саен фольклор экспедицияләренә чыгалар, аннары алып кайткан көйләрне эшкәртеп, имтиханда күрсәтәләр. Соңыннан, халык көйләреннән файдаланып, төрле жанрда кызыклы әсәрләр язалар. Композиторлар классының эше пленумнарда, съездларда, смотрларда югары бәя ала. Даими уздырыла торган укучы-композиторларның Бөтенсоюз конкурсларында безнең студентлар һәрчак беренче-икенче премияләрне яулыйлар. Ә соңгысында — СССРның 60 еллыгына багышланган конкурста — татар, рус, чуваш студентларының биш әсәреннән дүртесе премияләргә лаек булды. Шулар арасында Рәшит Кәлимуллинның агачтан эшләнгән тынлы уен кораллары өчен квартеты да бар.

Урта Идел халыкларының музыка сәнгатен фәнни тикшерү консерватория педагогларының да, студентларның да төп эшләре булып тора. Һәр ел өч-дүрт диплом эше җирле темаларга багышланган була. Гадәттә, диплом эшләре нигезендә соңрак фәнни мәкаләләр, китаплар, диссертацияләр языла. Шундый фәнни хезмәтләрдән М. Нигъмәтҗановның татар халык көйләренә, Й. Исәнбәтнең М. Җәлил һәм музыка темасына, З. Сәйдәшеваның татар композиторлары җырлары турында, Ф. Шәмсетдиноваың Н. Җиһановның симфоник иҗатына, М. Кондратьевның чуваш халык көйләренә, Т. Эррэның чуваш операсына, М. Хрущеваның удмурт халык көйләренә багышланган диссертацияләрен һәм китапларын әйтеп үтик. Урта Идел республикаларының милли музыкаль культуралары үсешенең катлаулы процесслары, иҗатта һәм башкаручылар сәнгатендә очрый торган уртак һәм аерылып торган үзенчәлекләрне ачыклау, бу процессларның тарихи һәм теоретик аспектларын өйрәнү — консерватория педагогларының фәнни эзләнүләренең төп проблемалары әнә шулар.

Белгечләрне әзерләүнең сыйфаты буенча Казан консерваториясе Россия Федерациясендә яхшылардан санала. Педагоглар укыту-тәрбия эшен өзлексез камилләштерергә омтыла. Студентларның махсус (профессиональ) осталыклары һәм белем-

нәренең дәрәҗәләре төрле конкурсларда лауреат исеме яки дипломнар алып кайтуларыннан да күренә. Консерваториядә укыган чакта ук җырчылар Р. Волкова (хәзер Ленинград опера театры солисткасы, РСФСРның атказанган артисткасы), Р. Ибраһимов (РСФСРның халык артисты), пианистлардан Л. Донец, И. Лазаревалар Халыкара конкурслардан премияләр алып кайттылар. Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия конкурсларында җиңүчеләр исә ел саен диярлек була.

Консерватория коллективы укыту эше белән генә чикләнмәде, кырык ел элек үк республикада музыкаль-пропаганда эшен җәелдереп җибәрде. Бүгенге көндә консерватория үз залларында гына да елына йөз илледән артык ачык концертлар үткәрә. Мәктәпләрдә, клубларда, эшче-яшьләр тораклары
рында, авылларда да шактый күп концертлар бирелә, музыкаль агарту эше даими рәвештә бара. Мәсәлән, профессор С. Казачков җитәкчелегендәге студентлар хоры егерме ел буе атна саен Казан мәктәпләрендә аңлатмалы концертлар үткәрә. Әлеге хор Мәскәүдә, Ленинградта, Балтик буе шәһәрләрендә чыгышлар ясап, югары уңыш казанды. Хор Татарстан композиторларының әсәрләрен дә өйрәнеп халыкка җиткерә. Заманында ул А. Ключарев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов әсәрләрен, соңгы елларда А. Лупповның Казанга багышланган кантатасын, Ш. Шәрифуллинның махсус ялгыз хор өчен халык көйләренә таянып концерт жанрында язган «Мөнәҗәт», «Авыл көйләре» дигән әсәрләрен һәм кырым татарлары җырларын зур уңыш белән башкарды.

Симфоник оркестр, кыллы оркестр, халык уен кораллары оркестры... Игътибар итегез: өстәмә түләүсез эшли торган нинди зур музыкаль армия! Белем алу белән беррәттән, җәмәгать эшен хөрмәт һәм җаваплылык белән үтәргә кирәклеген яшь белгеч нәкъ менә студент чагында нык үзләштерергә тиеш. Бу җәһәттән консерватория студентлары үзләренең киләчәктәге вазифаларын дөрес аңлыйлар. Гомумән, консерватория коллективы укытуның беренче адымнарыннан ук шул традицияләрнең нигезен салды.

Бүгенге көнгә Казан консерваториясен барлыгы 3079 музыкант тәмамлады (татарлар 1220). Алар безнең илебезнең төрле почмакларында күпмилләтле совет музыкаль культурасын үстерүгә зур өлеш кертәләр. «Казанлылар» инде үзләре меңнәрчә музыкантлар, консерваториянең «онык»-ларын үстерделәр, яңадан-яңа хорлар, оркестрлар, ансамбльләр тудырдылар. Безгә билгеле булганча, консерваторияне тәмамлаучыларның уку чорында алган иҗтимагый активлыклары мөстәкыйль эштә үсә бара. Аларның күбесе зур коллективларның җитәкчеләре булдылар, күренекле иҗат эшлеклеләре булып җитештеләр. Шуңа күрә безнең консерваторияне тәмамлаучыларның бик күбесе югары исемнәргә лаек булулары гаҗәп түгел. Алар арасында инде СССР халык артисты да бар (бу югары исем А. Б. Чыргал-оолга — тува халкының беренче композиторына бирелде).

Партия һәм хөкүмәтебезнең Казан консерваториясенә игътибары һәрвакыт зур булды. Консерватория үзенең эшен башлаганда бары тик ун аудитория, унбиш рояль, пианинолар, аз гына кыллы һәм тынлы уен кораллары бар иде. Нота һәм китапларны студентлар училищедан алып торалар иде. 1962 елны консерватория зур бинага күчте, концерт залы төзелде. Камера концертлары өчен ике кечерәк заллар бар. Концерт залында һәм кече залда Чехословакия һәм ГДР фирмалары ике орган куйдылар. Рояль-пианинолар саны хәзер йөз илледән артык. Китапханәдә йөз илле ике мең данә нота һәм махсус фәнни китаплар саклана, фонотекада пластинкалар, музыка язмалары, аларны яза һәм тыңлый торган кыйммәтле аппаратлар бар. Татарстан авылларында һәм тугандаш республикаларда булган талантлы балаларны укытыр өчен 1960 елда консерватория каршында интернатлы махсус музыкаль урта мәктәп ачылды.

Казан консерваториясе — интернациональ уку йорты. Биредә унбиш милләт вәкилләре укый. Педагоглар арасында да руслар, татарлар, украинлылар, чувашлар, марилар, удмуртлар, әрмәннәр һәм башка милләт кешеләре бар. Уртак эш, тугандаш республикалар белән даими аралашу интернациональ дуслыкны көннән-көн ныгыта. Кыскасы, Казан консерваториясе коллективының укыту һәм җәмәгать эшләре безнең социалистик яшәешне тулы чагылдыра.

**Чулпан БӘХТИЯРОВА,**
консерваториянең фәнни эшләр буенча
проректоры, сәнгать фәннәре кандидаты.

## Альберт Хәсәнов

# КАГЫЛМЫЙ?

хикәя

Бу юеш борыннар, ягъни әлеге маэмай халкы белән күптәннән әшнәлек йөртүемне дус-ишләрем яхшы белә. Шулай инде, яшермим, башымны иеп сәлам бирмичә, кочагыма алып сөймичә, алар яныннан битараф кына узып китә алганым юк. Минемчә, бу мөмкин дә түгел. Яфрак колакларын салындырып, сөйләп бетерә алмаслык тирән сагышлар тулы акыллы күзләрен төбәп, сиңа карап торалар бит алар. Авызыңнан чыккан бар сүзеңне төшенеп, аңлап, отып баралар. Кайтарып җавап бирергә бары телләре генә юк, бичаракайларның. Тузанга-пычракка батканнарын да, баштанаяк тигәнәк сарганнарын да, барып сиңа сыеныр почмак таба алмыйча, вокзал-пристань тирәсендә көн итәргә азапланып йөргәннәрен дә ишегалдыма күп күтәреп кайткаладым. Аларның миндә өчкә-дүрткә, хәтта бишкә җиткән чаклары да булды. Аңа карап иза чиктермәделәр, кеше теленә дә эләкмәдем. Әмма бераз тернәкләнү белән каядыр чыгып югала да бардылар алар. Ләкин алдан ук әйтеп куям, болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый.

Әйе, Джек турында сөйләмәкче идем бит әле. Мин аны шактый сәер шартларда кулга төшергән идем шул. Җәйнең искиткеч матур бер көнендә Казаннан кайтып килешем иде. Машиналар тезелешкән Кама ярында байтак вакыт паром көтәргә туры килде. Ике яр арасында әрле-бирле йөреп торган дүрт паромның бүген нигәдер берсе генә күренә. Андый чакта, билгеле инде, халык гасабиләнә. Катлап-катлап пристань хуҗаларын сүгүчеләр дә бар, эч пошканнан, кан оешканнан берәрсе белән якалашып, тарткалашып алырга кеше эзләп йөрүчеләр дә юк түгел. Ләкин болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Шунда күрәм: чал чәчле, изүләре ачык шакмаклы күлмәк өстенә төссез җилән кигән бер ир уртасы дебаркадер төбендә овчарка сатарга ниятләнеп тора. Мондый чакта халыкта аның кайгысымы соң! Һәркем яктыда тизрәк өенә кайтып җитәргә ашыга, дүрт күз белән теге яктан паром чыкканны көтәләр. Ә мин бу кеше яныннан алай битараф кына узып китә алмадым. Янына килеп сигарет суздым. Безнең ир-ат халкының тел ачкычы шул бит инде. Көйрәтеп җибәрдек. Карыйм, овчаркасы шәп моның. Бер дигән европейский овчарка, каһәр! «Утыр!» — дисәң, шып итеп утыра. «Ят!» — дигәч, шундук җиргә сузыла. «Ярат мине, Джек!» — дигәние, тегесе, арт аякларына басып, хуҗасының, инде атна-ун көннәр чамасы пычак-пәке күрмәгән кытыршы битеннән ялап та алды. Кыскасы, ни боерсаң, шуны үтәргә әзер тора. Акыллы, укымышлы, маэмайлар вузын кызыл диплом белән тәмамлаган овчаркага ошый бу. Тик шунысы бераз сәеррәк, хуҗасы аңа бик арзан, нибары ун сум гына сорый. Мондый «югары белемлеләре» түгел, алардан туган нәселле көчекләр дә йөз сумнан күп өстә йөриләр. Хәер, монысы хуҗаның үз эше. Бәлкем аның гаиләсе ишәеп китеп, торыр җире, фатиры кысынкыдыр. Бәлкем хатыны усал, киребеткән бер нәрсәдер. Бу әрәм тамагыңны теләсәң кая куй, олактыр, юкса өйгә үзеңне дә кайтарып кертмим дип, нык кисәтеп чыгаргандыр. Дөнья булгач, төрле хәлләр килеп чыга. Шәһәр җирендә яшәп, тугызынчы, унынчы кат балконнарында да эт асрарга тырышып интегүчеләрне күргәнем бар.

Ә минем шатлыгым эчемә сыймый. Шушындый овчаркалы булырга күптән кызыгып йөри идем. Ун сум белән генә калмадым. Шыгырдап торган егер-

ме бишлекне теге кешегә бер дә күпсенми суздым да муенчакны кулыма алдым. Кешенең эчендәгеи белеп булмый, кире уйлап куймасын тагын, дим.

Укыган, өйрәтелгән этләр белән эш итүе җан рәхәте ул. Муенчакны кулга тотуга, Джек мине, хуҗасы итеп тануын күрсәтеп, шунда ук кулымнан ялап алды.

— Менә картлач, һич көтмәгән җирдән миңа күңелле юлдаш булып куйдың бит. Син шатмы шуңа? — дип башыннан сыйпыйм.— Кайгырма бер дә без синең белән бик якын дуслар булырбыз. Сезнең халыкны яратам мин...

Ә хуҗасы Джек белән саубуллашып та тормады. Үз нәүбәтендә ул да, бу иптәш кире уйлап куймагае дип, курыкты, ахрысы. Арт ягына ут капкандай, кабаланып китеп тә барды.

Без кайтасы якка ул көнне машиналар булмады. Караңгыга калынды. Чистайда куныл чыгарга туры килде. Гостиницага эт белән урнашу да җиңел түгел иде. Хәер, болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Бездә тәртибе шулай инде аның, кайту белән Джекны чылбырга утырттым. Күрәм, үз кулым белән ясап куйган ояны ул да ошатты. Ике-өч тапкыр эченә кереп чыкты. Менеп ятарга, утырып торырга уңай яссы түбәсен дә килештерде. Боларына да сөенеп торам. Игелекле мал булырга ошый бит бу, ә?

Башта әле, юлдан кайткан шәпкә, күлгә төшеп коенып мендек. Джек күземә генә карап тора. Әмер генә бир, теләсә нинди боерыгыңны үтәргә әзер. «Сакла!» — дигәч, шып итеп киемнәр янына килеп утырды. «Суга кер!» — дип боергач, шупыр-шупыр килеп коенып чыкты. Аның акылына, зирәклегенә хәйран калам. Аннары ул бик тә шат күңелле, койрык чәнчеп уйнарга, шаярырга ярата торган эт икән. Йөгереп килеп, аңламастан гына кулдан каптырып ала. Әгәр шунда куркып, сискәнеп китсәң, аның йөзендә шаян көлү, чын елмаю чаткылары чагыла. «Менә, хуҗам, күрдеңме, мин сине ничек куркыттым», дип уйнаклап читкә сикерә.

Шулай сокланырлык матур итеп ул бездә ике-өч атналар яшәгәндер. Аннары исә холкын күрсәтә башлады бу, мин сиңа әйтим, түз генә! Очлы танавын күккә төбәп уларга керешә, хет өеңнән чыгып кач. Төннәр буе шулай ямьсез улап чыга. Каршына басып бармак янап, кисәтеп карадым. Үз башыңа булгыры, дип орышып та бактым. Алай да аңламагач, ишегалды себеркесе белән берәрне сыпыргалап та алам. Барыбер файдасы юк, улавын гына белә. Ни булды моңа, дибез. Төрлечә уйлап карыйбыз. Чү әле, мин әйтәм, бу бит бер диган эт егете, күршебездәге берәр эт кызына күзе төшкәнме? Әллә инде күрше урамда эт туе барамы, шунда баш кода булып йөрисе килеп улавымы? Була торган хәл, барыбызның да башыннан үткән нәрсәләр бит инде. Әйдә алайса, мин әйтәм, бераз җилләнеп кайт. Чылбырдан ычкындыруым булды, Джегым капканы ачканны да көтмәде — ике метр биеклектәге койма аша урамга сикерде дә юк булды. Хәер, болары аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да...

Шул китүеннән Джек ун көннәр чамасы югалып торды. Мин чыгып эзләмим, ул кайтмый. Үзегез беләсез, артыннан хуҗасы чыгып эзләргә калган эт игелекле мал түгел инде ул. Югалуы шушы булды, күрәсең, элеккеге хуҗасына качуыдыр, дип тора идек инде. Әмма беркөнне әйләнеп кайткан бу. Тавыклар казынып туздырган туфракта аунап, оясы алдында гамьсез йоклап ята. Шул тирәдә тирес актарып йөргән ике тавык чебеше моның башына ук менеп кунаклап, тәмләп черем итеп утыралар. Бу хәлне күрешкә йөрәгем жу итеп китте. Нидер эчерткәннәр бит моңа, әллә агу биргәннәрме, дип килсәм, күзләремә ышанмый торам, овчаркам лаякыл исерек. Иртән торса ике күзе гел безнең ишегалдында гына булган күрше хатыны кереп җиткән.

— И ходаем, бу хәлендә ничек кайтып ауган диген? Ничек әле милициягә эләкмәгән? — дип бот чаба.

Рәткә керә алмыйча Джек өч көннәр газапланды. Тәгам ризык капмады. Алдына әледән-әле куеп торган салкын суны гына шупырдата, бичара. Ни булды, нәрсә ашаган идең соң балакаем, дим. Башыннан сыйпыйм. Әллә берәрсе юри шаярып, аракыга манып колбаса кисәге каптырдымы? Кем ул, хайваннан туган нәрсә? Күрсәт син аны миңа. Синең күз алдыңда муенын борып ташлармын.

Маэмаем дәшми. Зур гаебе бар кешедәй башын аска ия. Оятыннан керер җир тапмагандай кылана.

Ул арада печән өсләре җитте. Урманчылар белән сөйләшеп без дә бер түгәрәк алан алган идек. Өмә ясап шуның печәнен чабарга керештек. Печән мәшәкатьләре белән Джекның «салып» кайтуы да онытылды. Урманда шалаш корып, төн куныл, аның белән икәүләп бер атналар чамасы шул печәнне сакла-

дык. Бу көннәрдә ул аеруча игелекле булды. Авызына зур сумканы каптырам да иртәнге якта бер, кичке якта кабат өйгә озатам. Бару-кайту уналты-унҗиде чакрымлык җирне арага да санамый. Печәнчеләргә ризыкның кайнарын, казаннан гына бүлгәндәй кайнар, салкынын, баздан гына алып менгәндәй, салкын килеш китереп кенә бастыра. Куе сөткә, салкын куаска кинәндерде генә. Ә караңгы төшсә, ник бер керфек каксын. Түгәрәк аланны кат-кат әйләнеп килеп, печән саклый. Төштән соң, көн үтә эссе чакта, шалаш күләгәсенә җыйналышып барыбыз да бераз черем итеп алабыз. Джек та безнең янга килеп ята. Алгы тәпиләре өстенә акыллы башын салып, уйчан күзләрен бер ачып, бер йомып, ниләр, нәрсәләр турындадыр уйлана. Катлаулы мәсьәлә, бер-бер башваткыч чишәме дип уйларсың. Андый чакларны борчымыйм. Уйлансын әнә. Уйлану, кемгә дә мишәйт итми. Ә Джекка бигрәк тә...

Печәннәрдән кайткач, мин аны тагын чылбырга бәйләдем. Күп тә узмады, бу тагын дөнья бетереп уларга тотынды. Башка чара калмагач, янәдән ирегенә җибәрдем. Берәр атна югалып торганнан соң тагын шулай ләх булып исереп кайтты. Анысы әле бер хәл. Таныш-белешләр аны пивнушка тирәсендә күргәннәр. Джек анда теге айнымаслар белән дуслашып алган. Шулар тирәсендә бутала, бөтерелә икән. Тегеләр ни кушса, шуны үти, ята, тора, шуыша, ди. Тегеләре исә, билгеле инде, моңа аракыга манып ипи сыныклары, сыр-колбаса каптыралар икән. Ни өчен алар тирәсендә бөтерелүен бик тиз сизгәннәр. Хәтта бер танышым Джекның пивнушкада, өстәл янында арт аякларына басып, бер айнымас белән кружкадан сыра чөмереп торганын күргән.

Ниһаять, төшендем мин. Теге чакта хуҗасы аны миңа менә ни өчен арзанга биреп киткән! Джек — алкоголик. Хронический әле җитмәсә. Запой белән эчә. Бераз басылып тора да тагын чыгырыннан ычкына. Ничек ул бу хәлгә төшкән? Кем төшергән? Әллә бу коточкыч чирне аңа атасы, әнкәсе мирас итеп биргәннәрме? Әллә элекке хуҗасы аңа уйнап-шаярып спиртка-аракыга манылган калҗалар каптыргалап, көчек чагыннан ук бозганмы? Башыма мең төрле сораулар килә. Хәтеремдә әле, яшь чакларны андый наянлыкларны үзебез дә эшләп куя торган идек. Аракыга манган ипи кисәкләре биреп, күрше әтәчләрен исертә торган идек.

Әгәр Джекны хуҗасы күрәләтә торып бозган булса, ул очракта бу җирбит дүрт аяклы дусты каршында гына түгел, анабыз табигать каршында да гафу ителмәслек җинаять кылган. Дөнья булгач, үземнең дә эчкече ирләрне, хәтта хатыннарны да күргәнем бар. Берсенең дә авызларына коймаганнар, үзләре теләп алган казалары. Аннары бит аларны дәвалау, яңадан кеше итү учреждениеләре дә бар. Ә менә Джекны, табигатьнең дүрт аяклы нарасыен кайда, ничек дәваларга? Мөмкинме бу эш? Андый табиплар бармы?

Джек шулай бер көйгә яши бирде. Хәер, яшәми нишләсен? Тәмәке төпчеге генә түгел, чүплек башына ташлап китә алмыйсың. Ике-өч атна күзен дә йоммый ишегалдын саклый. Айнык чагында аннан намуслы этне таба алмыйсың. Ягымлы. Керсәң, чыксаң, эндәшми калмый. Янына килеп иркәләгәнне, башыннан сыйпаганны көтеп кенә тора. Йомшак кына, вак-вак кына өреп, шуны үтенә. Айнык чагында ишегалдына чит тавыкны да кертми. Аннары инде бер атна югалып тора. Андый чакта, бәйдән үзең ычкындырмасаң, муенчагын чәйнәп, чылбырын өзеп кача. Качуына да, кем әйтмешли, эчүенә дә түзәр идең. Кешедән, таныш-белештән уңайсыз. Очраша-нитә калсаң, әйтерсең, бу дөньяның бар кызыгы шул, барысы да Джекны сораша башлый. Имеш, ул әле ни хәлдә? Айныткычка эләккәне юкмы? Штрафлар түләтеп теңкәгезне корытмыйлармы?

Ә Джек бераз югалып тора да кайтып егыла. Ике-өч көн аунап ята, аннан тагын аяклана да.

— Монысы соңгы тапкыр, хуҗам, кичер мине. Ул кабахәт нәрсәне бүтән гомеремдә дә авызыма аласым юк,— дип ялварып шыңшый, аягыма ятып гафу үтенә. Айнымасларның ике аяклылары төсле кайнар ант тота, бичара.

Ул шулай яшәгән дә булыр иде. Кая куясың һәм бу хәлендә ул кемгә хаҗәт? Куып чыгарсаң, барыбер кайтачак. Капканы бикләп куйсаң, капка өстеннән сикереп төшәчәк. Безнең башка төшкән аяклы бәла иде ул. Аннары, кызганабыз да, ни дисәң дә, тере җан бит. Аның да йөрәге бар. Ләкин Джек сыраханәләр тирәсендә соңгы тапкыр югалып йөргәндә ниндидер малайлар кереп, ишегалдында торган бишекле мотоциклны «чишендереп» чыкканнар. Ансыз инде мин хәзер ике кулсыз. Бу юлы бигрәк тә ачуым чиктән ашты. Ишегалдында тана хәтле овчарка асра, ә мотоциклыңның рулендәге көзгесенә хәтле салдырсыннар. Бу хәтле басымчак итүгә белмим кем генә түзәр иде икән. Джекка да ышанычым тәмам бетте, күңелем суынды. Мин аннан котылырга карар иттем. Баш-

ка чара юк, аттырырга туры киләчәк. Ләкин моны да бик яшерен эшләргә кирәк. Чөнки хатыным да, балалар да Джекны бик кызганалар. Мин орыша башласам, бердәм булып аны яклыйлар. Ул гынамы әле? Минем каядыр өйдә юк чак. Ә Джек махмырдан азаплана икән. Суыткычта кунаклардан калган бер «чәкушка» булган. Үзем сорасаммы? Жиңгәгез күрсәтмәгән дә булыр иде әле. Күрсәтер, бар. Шушында егылам, үләм дисәң дә тоттырасы юк. Ә Джекның башын тезәттергән. Жиңгәгез бөеренә таянган да: «Сез азгыннар шулай бозган, хур иткән, дүрт аяклы нарасый бит ул. Мин дә кызганмагач, хәленә кермәгәч, аны кем кызгана?» — дип, безнең братны орыша. Әйе, Джекка бер дә сүз әйттермиләр.

Әмма мин үзем дә үзсүзлеләрдән. Әйттемме, кайттым юк инде. Котылырга булгач, котылырга. Капка төбенә өсте бөркәүле машина белән кайтып туктадым. Соңгы запоеннан соң ике көн аяклана алмый яткан ярты центнер авырлыгындагы Джекны шофер егет белән икәүләп күтәреп кузовка салдык. Шәһәрне яшелләндерү, төзекләндерү конторына төшеп киттек. Анда минем күптәнге танышым каравыл тора. Менә шуңарда бөтен өмет. «Эчүен ташламаса, син аны минем янга гына алып төш. Уналты калибрлы мылтыгым баш очында гына тора. Мин аны эһ иткәнче юкка чыгарырмын»,— дип сөйләнгән иде...

Джекны әйтәм, кая алып баруыбызны сизенде, ахры. Маэмаем кинәттән айнып китте, күзләре җанланды. Алай да карышмый тагын үзе. Кузовка менгереп салгач, почмакка бәйләп куйдык.

Тормышта ул син дигәнчә генә булып торса икән. Тормый шул. Төшсәк, әлеге агай үзе ләх, аякларын як-якка ташлап, гараж күләгәсендә мәртәкә китеп йоклап ята. Барып уяттым, әлбәттә. Баш ими хәлең юк. Җәллад булырга бераү дә атылып тормый. Ярады тагын, ничек изрәп йокласа, шулай кырт кына уянып китте. Йөгереп барып Джекны карап килде.

— Кыш чыккан тана хәтле бар икән, валлаһи! Ун ҩүрек, кимендә ун бүрек чыгачак моның тиресеннән! — дип куйды. Әмма «баш очында гына торган мылтыгын» бу юлы тиз генә таба алмады. Озак баш ватып тормады, гараждан зур пычак тотып чыкты. Рубильникны тоташтырып, наждакта кайрый башлады:

— Хәз-зер кых итеп ташлыйбыз аны...

— Юк, пычак белән кых иттертмим,— дидем мин.— Мылтык белән булганда әле бер хәер. Пычак белән кагылдыртмыйм.

— Ул бит нәселле овчарка, агай. Пычак белән өстенә килсәгез, үзегезне буып ташлар, шул булыр,— дип шофер егет тә миңа ярдәмгә килде.

— Алайса, калдырыгыз. Әнә теге почмакка төшереп бәйләгез. Үземнекен тапмасам, иртәгә күрше мылтыгын алып төшәрмен.

— Ә ул үзен тотып атканны көтеп иртәгә кадәр шушында кагаермы? — дидем мин, бу сорауны беренче чиратта үземә биргәндәй итеп.— Калдырмыйм. Без алай сөйләшмәдек.

Әлеге агай минем хәлемне аңлагандай булып, башын кашып:

— Кызык та кеше инде син, туган,— дип куйды.— Ул чагында болай... Инде машина яллагансың икән, көнеңне бушка уздырма. Тот та заготконторага мен. Андагы егетләр мин түгел. Тиресен салдырып, ничек казыкка элгәннәрен маэмаең сизми дә калыр. Ә үзеңә бер яртылык акча да тоттырырлар әле. Аһ, каһәр, пушкамны кая гына куйдым икән соң! Нинди табыш кулдан ычкына бит.

Күңелдәге хисләрне әйтеп аңлату кыен. Әмма бу ишегалдыннан тизрәк чыгып китәсе килде. Мин тирән хәсрәт эчендә. Ә теге агай шуны гади бер бүрек үлчәме белән үлчәмәкче. Имеш, ун бүреклек тире кулдан ычкына. Я ходай, бу дөньяда нинди генә кешеләр юк. Шунда бик тәти булып кыланма, дип үземне дә сүгеп ташладым. Дәшеп төшермәде, маэмаеңны җитәкләп, аның каршына син үзең килдең. Шулай булгач, кеше тикшереп маташмасаңчы. Шунда ук күңелгә, мәлҗерәп төшмә әле син, бу алкоголик маэмаеңнан кайчан да булса барыбер котылырга туры киләчәк, дигән уйлар да килә. Кизәнеп кенә калма, ди күңел...

Ә машина инде заготконторага җитеп тә килә. Күңел төрлесен уйлый. Башымда — әллә нинди каршылыклы теләкләр. Әле соң түгел, әллә кире борылыргамы? Ул арада заготконтораның алгы ягына болан, кыр кәҗәсе, кабан дуңгызы рәсемнәре төшерелгән биек капкасы күренде. Кулымны рульгә салдым, кире борылырга ишарәләдем. Җитмәсә, шоферы да аның шундый, кеше халәтен аңлый, төшенә торган акыллы бер егет булып чыкты. Кай якка ымласам, машинасын шул якка бора. Төбәп кенә барыр җиребез дә юк. Тигез асфальт юллардан соң яңа гына сөрелгән иген кырларына килеп чыктык, ул көнне байтак җирләрне айкадык. Күп нәрсәләр турында уйлап бетердем. Тирән сыкрау бе-

лән, кара син бу алкоголь афәтен, дим. Шушы хашәрәт нинди ир-егетләрне хур итеп ташлый. Инде хәзер дүрт аяклылар арасына да ояламакчы, алар арасыннан корбаннар эзләмәкче. Чик куймасаң, керәчәк, аларны да хур итәчәк.

Шунда кылт итеп, күрше районда бер таныш умартачым искә килеп төште. Аның белән әле узган елны гына Казанда киңәшмәдә булып, кунакханәдә бер бүлмәдә торган идек. Умарталык авылдан еракта, урман эчендә, шуны сакларга бер усалрак маэмай табасы иде, дип сөйләнгәне хәтеремдә. Арабыз туксанйөз чакрымнар гына булыр. Әмма шул фикеремне әйткәч, шофер егетем башын гына какты.

— Киттек!

Умарталыкка кичке якта гына килеп җиттек. Каршыбызга чәң-чәң килеп бер нәни маэмай йөгереп чыкты. Бәхеткә каршы, Тимерша агай үзе дә умарталыгында иде. Сәлам бирештек, күрештек. Учагын тергезеп җибәрде, су өстәп шундук чәйнеген асты. Джекны да җиргә төшереп бастырдык. Көне буе кузовта җилләнә торгач, ул инде тәмам айнып өлгергәнгә охшый. Бөтен урманны яңгыратып ик-өч тапкыр һау-һау дип тә куйды. Койрык чәнчеп чабып, әйләнә-тирәне барлап килергә дә исәбе юк түгел. Сизгер җан түгел диген син аны, кая эләгүен бу юлы да бик тиз аңлап алды. Кәефе бөтенләй башкача. Күреп тора, биредә аңа, һәрхәлдә, мылтык белән янамаячаклар.

— Джек, тавышланма, кил, минем янга ят, җиргә сузыл,— дим.

Тимерша агайның күзе аңарда гына. Умартачы турыдан гына бәрдереп:

— Күпме сорасаң да сора, сат син бу этне миңа! — диде.

Без шофер егет белән күзгә-күз карашып алдык. Икебез дә елмаеп куйдык.

— Бушлай бирәм, Тимерша агай, тик алып кына кала күр,— дидем.— Әмма соңыннан үкенмә, берүк. Бу кара борынның бик начар гадәтләре бар...

Калганын инде яшерми-нитми генә сөйләп бирдем.

— Һәй, исең киткән икән! Уламагае, уласын! — дип Тимерша агай сүземне ярты юлда ук бүлде.— Улый гына бирсен. Умарталыкка карак-угры килмәс. Җаным тыныч булыр. Рәхәтләнеп, татлы төшләр күреп йокలармын.

— Улап кына калса икән. Аның әле кача торган гадәтләре дә бар. Муенчакларын салып, чылбырларын өзеп...

— Миннән кача алма-ас. Боларны миңа авылга электр керткәндә монтажчылар биреп калдырган иде,— дип Тимерша агай түбә астыннан ике колачлар чамасы озынлыктагы өр-яңа, әле тутыгырга да өлгермәгән чылбыр кисәге алып чыкты.— Бу чылбыр белән, энем, нәсел үгезеңне арканларга була. Миннән ычкына алма-ас...

Мәсьәләнең шулай уңай хәл ителүенә сөенеп бетә алмый кайтыр юлга чыктык. Әйе, урыны яхшы, тик улап ятсын. Үземнең дә эчкә җылы керде. Югыйсә, чак кына җәллад булмый калдым бит. Аннары ничек өйдәгеләрнең күзенә кайтып күренгән булыр идем. Хәзер тынычландым инде. Бик сагынсак, юксынсак, бер араны килеп, күреп тә китәрбез әле үзен.

Әмма Джек бик үзсүзле җан иде шул. Умарталыктан да качкан. Шул тирәдәге авыл кибетләре янында буталып йөргәнен дә, тузанда аунап ятканын да күрүчеләр булган. Мин барып эзләп тә карадым, тапмадым. Бәлкем берәр ничек дәвалап караган булыр идек. Кайларда михнәт чигә торгандыр инде, мескенем? Исәнме икән әле үзе — хәмер корбаны? Хәер, монысы инде аның вак нәрсә һәм төп мәсьәләгә кагылмый да... Кагылмый?..

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫ

Россия Федерациясе язучыларының VI съезды 11 декабрьдә Мәскәүдә Кремльнең Зур сараенда ачылды.

Делегатлар һәм кунаклар М. С. Горбачев, Г. А. Алиев, В. И. Воротников, В. В. Гришин, А. А. Громыко, Е. К. Лигачев, Н. И. Рыжков, М. С. Соломенцев, Э. А. Шеварднадзе, П. Н. Демичев, В. И. Долгих, В. В. Кузнецов, Б. Н. Пономарев, Н. В. Талызин, Б. Н. Ельцин, Л. Н. Зайков, М. В. Зимянин, И. В. Капитонов иптәшләрне озакка сузылган көчле кул чабулар белән каршыладылар. Язучылар форумы кунаклары арасында — тугандаш әдәбиятлар вәкилләре, Мәскәү хезмәт ияләре вәкилләре, сәнгать эшлекләре, галимнәр, партия һәм совет работниклары, Кораллы Көчләр сугышчылары.

РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. В. Михалков «Партия бурычлары — әдәбият бурычлары» дигән доклад белән чыкты. Ул бүгенге шартларда язучыларыбыз алдында торган җитди бурычлар турында сөйләде; күпмилләтле Россия халыклары әдәбиятларының үсеш үзенчәлекләрен, мөһим проблемаларын анализлады. С. В. Михалков проза, публицистика, поэзия, драматургия, балалар һәм үсмерләр әдәбияты өлкәсендә, тәнкыйть фикерләрен үстерүдә, тәрҗемә эшчәнлегендә «әдәби бишьеллык» казанышларына җентекләп тукталды. Россия язучылары — партиянең тугрылыклы ярдәмчеләре, совет җәмгыятен үстерүнең хәзерге мөһим этабында әдәбиятның гаять зур роль уйнарга тиешлеген аңлап, халык ышанычын, Ленин партиясе ышанычын аклау өчен барысын да эшләрләр, диде докладчы.

РСФСР Язучылар союзының ревизия комиссиясе докладын аның председателе С. М. Борзунов ясады.

Съезд үзенең эшен Союзлар йортының Колонналы залында дәвам иттерде. Илебезнең социаль-экономик үсешен тизләтүгә һәрьяклап булышлык итәргә — язучылар форумы делегатлары үзләренең төп бурычларыннан берсен әнә шулай билгеләделәр. Фикер алышуларда М. Алексеев (Мәскәү), Ф. Кузнецов (Мәскәү), Р. Гамзатов (Махачкала), М. Кәрим (Уфа), Е. Евтушенко (Мәскәү), В. Белов (Вологда), Т. Миңнуллин (Казан), С. Данилов (Якутск), С. Залыгин (Мәскәү) һ. б. чыгып сөйләделәр.

С. Михалков отчет доклады буенча йомгаклау сүзе белән чыкты.

Делегатлар съезд резолюциясен кабул иттеләр.

14 декабрьдә РСФСР язучыларының VI съезды үзенең эшен тәмамлады.

Съездда катнашучылар зур рухлану белән КПСС Үзәк Комитетына хат кабул иттеләр.

Съезд РСФСР Язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составларын сайлады. Язучыларның VIII Бөтенсоюз съездына делегатлар сайланды.

Съездның йомгаклау утырышында П. Н. Демичев, М. В. Зимянин иптәшләр катнашты.

РСФСР Язучылар союзы идарәсенең беренче пленумында РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе итеп С. В. Михалков, председатель урынбасары итеп Ю. В. Бондарев сайланды.

РСФСР Язучылар союзы ревизия комиссиясенең беренче пленумында аның председателе итеп С. М. Борзунов сайланды.

Татарстан язучыларыннан Т. Миңнуллин — РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, С. Хәким, Р. Фәйзуллин һәм Р. Хәмид — идарә членнары, Р. Харис һәм Ә. Гаффар ревизия комиссиясе членнары итеп сайландылар.

СССР язучыларының VIII съездына делегат итеп Татарстаннан түбәндәге язучылар сайланды: Т. Галиуллин, Р. Гатауллин, Ә. Еники, Т. Миңнуллин, Н. Орешина, М. Усманов, Р. Фәйзуллин, Н. Фәттах, Р. Харис, С. Хәким, И. Юзеев.

РСФСР язучыларының VI съездында Татарстаннан делегат булырак түбәндәге әдипләр катнашты: Г. Ахунов, Н. Беляев, К. Булатова, Д. Вәлиев, Ш. Галиев, А. Гыйләжев, Ә. Гаффар, Н. Гыйматдинова, Л. Ихсанова, Ә. Кәримуллин, Р. Кутуй, Р. Миңнуллин, Т. Миңнуллин, Ф. Мусин, Р. Мөхәммәдиев, В. Нуруллин, К. Сибгатуллин, М. Хәбибуллин, Р. Хәмид, Р. Харис, М. Хәсәнов, Н. Юзиев.

Съезд эшендә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

14 ноябрьдә Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының отчет-сайлау җыелышы булып узды. Партбюроның отчет чорындагы эше турындагы доклад белән партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев чыкты. Ул партия оешмасының еллык эшенә һәм язучыларның шул чордагы иҗат эшчәнлегенә анализ ясады, алда торган бурычлар турында сөйләде.

Фикер алышуларда Язучылар союзы идарәсе председателе Т. Миңнуллин, язучылар С. Хәким, Р. Ишморат, Л. Ихсанова, М. Хәсәнов, Р. Мостафин, «Казан утлары» журналының баш редакторы Р. Харис, Р. Фәйзуллин, Р. Кәрами, Д. Вәлиев, Р. Хәмид чыгыш ясадылар.

Җыелышта Татарстан Язучылар союзы башлангыч партия оешмасының яңа бюросы

сайланды. Бюро утырышы секретарь итеп Р. Мостафинны сайлады.

Җыелышта КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова чыгыш ясады. Җыелышта шулай ук КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре Ф. Г. Зиатдинова, КПССның Казан шәһәре Бауман районы комитетының беренче секретаре В. Н. Липужина катнашты.

## ЯШЬ ПРОЗАИКЛАРНЫҢ РЕСПУБЛИКА СЕМИНАРЫ

28—29 ноябрьдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында яшь прозаикларның республика семинары булып узды. Аңа төрле төбәкләрдән 16 яшь прозаик чакырылган иде. Семинарны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары И. Юзеев ачты.

Семинарның беренче көнендә ТАССР язучылар партия оешмасы секретаре тәнкыйтьче Р. Мостафин яшь прозаиклар алдында торган бурычлар турында сөйләде. Язучы Г. Бәширов үзенең иҗат тәҗрибәсен уртаклашып, проза жанрының серләре турында әңгәмә уздырды.

Икенче көнне республикабызның танылган әдипләре җитәкчелегендә яшь прозаикларның әсәрләре тикшерелде, иҗат юнәлешләре билгеләнде.

## МУЗЫКА БӘЙРӘМЕ

18—22 ноябрьдә Йошкар-Олада Идел буе һәм Урал яны автономияле республикалары композиторларының IV музыка фестивале булып узды. Фестиваль концертларында Мари, Башкортстан, Мордовия, Удмуртия, Чувашия һәм Татарстан композиторларының әсәрләре яңгырады.

Фестивальдә республикабызның бер төркем композиторлары, музыка белгечләре, артистлары һәм Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры, Казан культура институтының халык уен кораллары оркестры, Казан дәүләт консерваториясенең кыллы квартеты, «Татарстан пионериясе» исемле балалар студиясе хоры чыгыш ясады.

22 ноябрьдә Мари музыкаль драма театры бинасында алты автономияле республика сәнгать осталары катнашында фестивальнең йомгаклау кичәсе булды.

## МУЗЫКА ҺӘМ МӘКТӘП

10—11 декабрьдә Казанда «Музыка һәм мәктәп» дигән девиз белән Татарстан АССР Композиторлар союзы идарәсенең пленумы булып узды. Ул КПСС Үзәк Комитетының апрель һәм октябрь (1985 ел) Пленумнары таләпләре яктылыгында яшь буынга музыка белеме һәм эстетик тәрбия бирү мәсьәләләренә багышланды. Пленумны ТАССР Культура һәм Мәгариф министрлыклары, Профтехбелем идарәсе, ВЛКСМ өлкә комитеты һәм Татарстанның хор җәмгыяте бергәләп оештырдылар.

Пленар утырышта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, РСФСР Композиторлар союзы идарәсе секретаре В. Г. Агафонников һәм РСФСР Композиторлар союзының иҗат комиссиясе председателе А. А. Бузовкин, ТАССР культура министры М. М. Таишев катнашты.

Шул ук көнне консерваториянең Актлар залында пленум рамкаларында симфоник музыка концерты булды. ТАССР Дәүләт симфоник оркестры башкаруында СССР халык артисты Н. Җиһановның 16 нчы симфониясе, Р. Кәлимуллин, Р. Билалов һәм Б. Трубин әсәрләре яңгырады.

## ӘДИП ЮБИЛЕЕНА БАГЫШЛАП

18 ноябрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында күренекле драматург, РСФСРның К. Станиславский, ТАССРның Г. Тукай, Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре лауреаты, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, ТАССР Верховный Советы депутаты Туфан Миңнуллинга 50 яшь тулуга багышланган иҗат кичәсе булды. Юбилярны котларга республикабызның хезмәт коллективлары, партия, совет, профсоюз, комсомол оешмалары вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, тугандаш республикалардан кунаклар килгәннәр иде.

Кичәне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М.-Х. Хәсәнов ачты.

КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев юбилярны җылы котлап, аңа КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасын тапшырды.

Юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турында язучы А. Гыйләҗев доклад сөйләде.

КПССның Казан шәһәр комитеты һәм шәһәр Советы башкарма комитеты, Бауман район партия оешмасы, ТАССР Культура министрлыгы, республика иҗат союзлары, Татарстан китап нәшрияты исеменнән һәм тугандаш республикадан килгән кунаклар тарафыннан да әдипкә котлаулар әйтелде. Шулай ук телеграммалар укылды.

Юбилей кичәсендә Т. Миңнуллин әсәрләре буенча куелган спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

Кичәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

25 ноябрьдә Казан дәүләт педагогия институтының Актлар залында Г. Тукайның 100 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Студентлар белән очрашуга республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары шагыйрьләр С. Хәким, И. Юзеев, филология фәннәре докторы Н. Юзиев килгән иде.

Кичәне институтның ректоры, филология фәннәре докторы профессор М. З. Зәкиев ачты. Бөек шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләшүдә Г. Тукай шигырьләре һәм аңа багышланып язылган әсәрләр яңгырады.

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт пре-

миясе лауреаты композитор Б. Мулюков Г. Тукайга багышланган яңа оратория иҗат итте. Либретто авторы — Х. Гарданов. Музыканың беренче мәртәбә яңгырашыннан туган фикерләр Татарстан Композиторлар союзындагы чираттагы музыкаль пәнҗешәмбедә әйтелде.

## КОНСЕРВАТОРИЯГӘ — 40 ЕЛ

6 декабрьдә Казан дәүләт консерваториясенең Актлар залында бу уку йортының 40 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булды.

Казан дәүләт консерваториясе ректоры, СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое, профессор Н. Г. Җиһанов консерватория эшчәнлегенең йомгаклары һәм перспективалары турында доклад ясады.

Совет музыка сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Казан консерваториясе коллективында Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасын КПСС өлкә комитетының фән һәм югары уку йортлары бүлеге мөдире Р. И. Әдһәмов тапшырды.

Җыелыш эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова, ТАССР культура министры М. М. Таишев катнашты.

## ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘ ЮБИЛЕЕ

29 ноябрьдә Әлмәт шәһәренең М. Горький исемендәге культура сараенда С. Сөләйманова исемендәге әдәбият берләшмәсенең 30 еллыгына багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды. Утыздан артык СССР Язучылар союзы члены тәрбияләнеп чыккан берләшмәнең иҗади эшчәнлеге турында шагыйрь Ә. Маликов сөйләде.

Кичәдә шәһәр җәмәгатьчелеге, Әлмәт язучылар оешмасына караган әдәби берләшмә вәкилләре, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре катнашты. Кичәне шагыйрә К. Булатова алып барды.

## ИҖАТ КИЧӘЛӘРЕ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе җерым шагыйрьләр иҗатына багышлап әдәби-музыкаль кичәләр уздыруны гамәлгә кертеп җибәргән иде.

2 декабрьдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында уздырылган әдәби-музыкаль кичә РСФСРның М. Горький, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким иҗатына багышланды.

Татарстанның атказанган артисткасы Ф. Хәмитова алып барган бу кичәдә фронтовик шагыйрь С. Хәким үзенең туган як кешеләренең тырыш хезмәтен, җирдә тыныч тормышны данлаган шигырьләрен укыды. Аннары шагыйрьнең әсәрләрен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе һәм Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары А. Арсланов, Р. Сабиров, Ф. Хәмитова, И. Әхмәтҗанов башкардылар.

15 ноябрьдә Казанның Актерлар йортында ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Гәрәй Рәхимнең иҗат кичәсе булды. Анда шагыйрь тамашачыларга үзенең соңгы елларда язган әсәрләрен укыды, күпсанлы сорауларга җаваплар бирде.

М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры солистлары К. Хәйретдинова, В. Ганиева Г. Рәхим сүзләренә язылган җырларны башкардылар.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫН УКУЧЫЛАР КОНФЕРЕНЦИЯЛӘРЕ

23—24 ноябрьдә Куйбышев өлкәсендә «Казан утлары» журналының укучылар конференцияләре булып узды.

Шәһәрнең Металлурглар культура сараенда узган конференциядә шагыйрьләр — журналның баш редакторы Р. Харис, Р. Фәйзуллин һәм хатлар бүлеге редакторы Рәшит Әхмәтҗанов бүгенге татар әдәбияты, әдәбият алдында торган актуаль проблемалар, «Казан утлары» журналында басылган һәм басылып чыгачак әсәрләр турында сөйләделәр, үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, әдәбият сөючеләрнең сорауларына җавап бирделәр.

Соңыннан «Казан утлары» журналына багышланган зур концерт булды. Анда РСФСРның һәм Татарстанның халык артисты И. Шакиров, җырчы Г. Сафиуллина, композитор Р. Гатауллин, Н. Колючев житәкчелегендә металлурглар культура сарае каршындагы эшләүче «Канатлы яшьлек» татар җыр һәм бию ансамбле чыгыш ясады. Шундый ук конференция Тольятти шәһәренең «Юбилейный» культура сараенда да узды.

## «ЯШЬЛЕК» АНСАМБЛЕ

1960 елда Ташкент шәһәренең Ю. Ахунбаев исемендәге культура йорты каршында опера солисты Гали Нуриәхмәтов татар һәм башкорт яшьләрен җыеп, «Яшьлек» исемле җыр ансамбле оештыра. Аның репертуарына татар, үзбәк, башкорт, казах җырлары алына. 25 ел дәверендә бу коллектив Үзбәкстан, Казахстан, Таҗикстан союздаш республикаларында меңгә якын концерт куйды. Ә 1978 елда ул халык ансамбле исеменә лаек булды.

«Яшьлек» халык ансамбле Үзбәкстан ССР төзелүгә — 60 ел, Бөек Җиңүгә 40 ел тулуга багышланган конкурста җиңүче дип табылды.

Күптән түгел ансамбль үзенең 25 еллык юбилеен бәйрәм итте.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНДӘ

Татарстан Язучылар союзы идарәсенең 5 декабрьдәге утырышында ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателенең урынбасары итеп драматург Ризван Хәмид расланды.

# ШИГЪРИ ПЕЙЗАЖ ОСТАСЫ

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Николай Кузнецов остаханәсендә булган кешеләр хәтерлидер: анда күпсанлы этюд һәм картиналар түгел, ә рәссамга палитра сыйфатында хезмәт иткән биек урындык беренче булып күзгә ташлана иде. Сынлы сәнгать остасының тылсымлы кулы салават күпере төсләрендә җемелдәүче әлеге буяуларны полотноларга соклandыргыч рәвештә күчерә иде...

Күренекле пейзаж остасы Н. Кузнецовның кабатланмас үзенчәлеген тышкы сурәтләү алымнары гына түгел, ә әсәрләрне эчтән яктыртып торучы рухи-эмоциональ башлангыч билгели. Рәссамның зурлыгы да нәкъ менә шунда күренә. Гомерлеккә сайлаган пейзаж жанрында ул үз йөзен дә, замана образын да оста чагылдыруга иреште. Татарстан башкаласындагы төзелешләр, Иделдәге яңарышлар, нефть төбәкләрендәге үзгәрешләр туган ягына җаны-тәне белән гашыйк рәссамга төп җирлек булып хезмәт итәләр.

Алтмышынчы елларда республикада нефть-химия гигантлары күпләп күтәрелә башлый, һәм рәссам менә шундый төзелешләрдә отышлы сюжетларга юлыга, аларны бербөтен сериягә берләштерә: «Нефть чыккан якларда» (1964), «Киләчәк силуэтлары» һәм «Могҗиза-гигант» (1963—1964), «Миннебай газ-бензин заводы» (1965—1967)... Җемелдәп торучы манара һәм торбалар рәссам күңелендә хыялый күренешләр дә тудыра. Кайчак мондый корылмалар борынгы замоклар силуэтын хәтерләтеп куялар. Шулар арасыннан «Кышкы салкын» дип исемләнгән картина (1974—1976) үзгә бер шигърилеге белән аерылып тора.

...Аклык белән капланган җир өстенә кышкы әңгер иңеп килә. Зәңгәрсу киңлектәге утлар күзгә күренеп җетеләнә шикелле. Күккә ашып торган завод корпуслары кышның салкын шәмәхә һавасында эреп китәрләр төсле. Яшь агачларның бәсле ябалдашлары зур-зур тимер конструкцияләргә шигъри матурлык өсти. Картинадагы завод силуэтын караганда, зәңгәр киңлектәге әкияти кораб күзаллана. Образга салынган шигърилек интонациясе рәссамга кышкы кичнең кабатланмас халәтен күрсәтергә, лирик һәм индустриаль пейзажның үзгә бер кушылмасын тудырырга ярдәм иткән.

**Вера ЦОЙ,**
Татарстан сынлы сәнгать
музееның бүлек мөдире.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле әдип, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәширов.

Рөстәм **МАНСУРОВ** һәм Зөфәр **БӘШИРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)